Татарстан Республикасы Фәннәр Академиясе
Г.Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты

Ф.С. Баязитова

ХАЛЫК ТРАДИЦИЯЛӘРЕ ЛЕКСИКАСЫ:

# СОҢГЫ ТУЙ

Дини фольклор һәм җирле сөйләш текстлары яссылыгында

Казан • 2015

# КЕРЕШ

Һәр халыкның да гаилә йолаларында , тормыш-көнкүрешендә яшәү белән үлем, шатлык белән кайгы янәшә йөриләр.

Гаилә йолалары кешене гомер буе озатып баралар һәм этник культураның тотрыклы компонентларыннан саналалар. Гаилә йола---ларында этнопедагогик һәм эстетик карашлар, дини йолалар, борын---гы ышанулар бергә үрелеп баралар. Шуның өчен аларны төрле яклап: тел, фольклор һәм этнография ягыннан өйрәнү бүгенге көннәрдә дә бик актуаль.

Гаилә йолалары өч зур циклдан тора:

бала туу йолалары;
өйләнешү, туй итү йолалары;
күмү һәм искә алу йолалары.

Менә шушы өч зур вакыйганың һәркайсын халык телендә «туй» дип, зурлап әйтүләр дә күзәтелә. Бу түбәндәге гыйбарәләрдә чагылыш таба:

«бишек туе — и шатлыктыр,
никах туе — и аклыктыр,
әҗәл туе — фираклыктыр».

*Фирак* — гарәп теленнән кергән сүз, *фираклык* — аерылышу, хуш---лашу. Әлеге сүзләр халык мөнәҗәтләрендә еш кулланыла:

Фирак җиле каты исә, бәгырьләрне кисеп үтә,
Акылларны вәйран итә, күзләреңдин кан-яшь түгә.

Фираклыклыкның хәле каты, ничек бәндә түзә икән?
Сабырлыкның суы белән, аның уты сүнәр микән?
(«Ничек бәндә түзә икән?»)

Үлем — кеше тормышының соңгы ноктасы. Ул якты дөньяны, туганнарыңны, якыннарыңны, эшләнеп бетмәгән эшләреңне калды---рып, мәңгелеккә «теге дөньяга» китү. Үлем хәле ул исән калганнар өчен дә бик авыр, газаплы, зур тетрәнүләр, тирән кичерешләр калды---ра. Шуның өчен кешене соңгы юлга озатканда «ата-баба йоласы бу---енча , җиренә җиткереп җирләү» үлгән кеше алдында соңгы бурычны үтәү булып кабул ителгән.

Үлем хәле, үлгән кешене озату — авыр, кайгылы халәт. Шуның өстенә ул әле зур гына физик көч һәм төрле чыгымнар да сорый. Шатлыклы, куанычлы вакыйгалардан саналган өйләнешү, бәбәй туй---ларын берләшеп, «ил белән күргән туй» дип зурлап үткәргән кебек, үлгән кешене җирләү, искә алуларны, кайгыларны да бүлешеп, ур---таклашып, һәркем хәленнән килгәнчә, булдыра алганча ярдәмләшеп башкару авыл халкы өчен гадәти хәл, язылмаган закон булып калган.

Кешенең үлеменә бәйләнешле йолалар, ышанулар берничә өлештән тора:

1) үлгән кешене күмәргә әзерләү, юу һәм кәфенләү;
2) җеназа һәм кабер казу;
3) зиратка алып китү һәм җирләү;
4) мәет чыккан өйдә үткәрелә торган гореф-гадәтләр;
5) үлгән кешене искә алу йолалары;
6) үлем йоласы белән бәйле төрле ышанулар, мифология һ.б.

Ислам дине кабул ителгәннән соң үлгән кешене җирләүләр һәм искә алулар нигездә, бер төрле итеп башкарыла, ул инде калыплаш---кан гадәт. Шуңа күрә, дини йолалар һәм халык традицияләре, борын---гыдан килгән ышанулар бергә үрелеп баралар һәм бүгенге көннәрдә дә алар тотрыклы рәвештә сакланып киләләр. Әлеге үтә катлаулы һәм әһәмиятле теманы өйрәнү өчен халыкта сакланган мәгълүматларны туплау бик әһәмиятле. Безгә соңгы берничә дистә еллар дәвамында татар халкы бергә тупланып яшәгән бик күп төбәкләрдә экспедицияләрдә булып, өлкән буын кешеләре, йола белгечләре, тел осталары, дин һәм җәмгать эшлеклеләре белән очрашып, гаилә йолаларының бик тирән катламнарына караган тел, этнография һәм фольклор материаллары туплау насыйп булды.

Экспедиция материаллары күрсәткәнчә, татар халкының төрле этнографик төркемнәрендә, аеруча Татарстаннан читтә яшәүчеләрнең тел- сөйләшендә, җирле үзенчәлекләр булган кебек, күмү һәм искә алу йолаларында да җирле үзенчәлекләр сакланып килә. Алар рухи һәм матди культураның чагылышы булган лексик катламда, татарча әйтелә торган дини догаларда, рифмалашкан яки прозаик характер---дагы теләкләр һәм ялваруларга караган фольклор текстларында да чагылыш таба. Борыңгыдан килгән җирле үзенчәлекләр бигрәк тә ерактагы архаик зоналарда: себер диалектларында,

эстерхан, касыйм, урал, перм-нократ сөйләшләрендә, мишәр диалекты сөйләшләрендә, керәшен сөйләшләрендә табыла.

Һәр халык мәет күмүләрне дини йола буенча башкарырга ты---рыша. **Мөселманнарның** күмү йолалары — мәетне күмүгә бәйле дини карашларга нигезләнгән гадәтләр һәм йолалар. Ислам дине өйрәтүләренчә, мәетне мөмкин кадәр тизрәк, кеше үлгән көнне үк яки икенче көнне күмәргә кушыла. Мәетне юалар (бу эшне гадәтт ә мәет юучы махсус кешеләр башкара), кәфенгә төрәләр, аның баш очын--да махсус намаз (салат әл-җеназа) һәм Коръәннән аятьләр укыйлар. Гадәттә мәетне кәфенгә төргән килеш күмәләр. Җир бик йомшак бу---лып, кабердә тиешле форманы саклау мөмкин булмаганда гына аны табутка салалар. Кабердә мәетне йөзе белән кыйблага каратып, уң ягына яткыралар. **Керәшеннәрнең** күмү йолаларында христиан дине белән кергән һәм бик күп борынгы ышануларга нигезләнгән гадәтләр һәм йолалар сакланган: үлг ән кеше янында «Алла китаплары», ягъни татарчага тәрҗемә ителгән христиан дине китаплары уку, шәм янды---рып кую, юып киендереп, гробка (табут дип тә әйтәләр) салып күмү, искә алу йолаларында тугыз көнен үткәрү, иман җырлау һ.б. (Воробьев 1927: 62; Гаврилов 1874: 11)

Ләкин керәшеннәрнең мәетне җирләү һәм аны искә алу йолаларын---да үзенчә лекле борынгы ышанулар, дин ягыннан кайбер аермалыклар булса да, тел ягыннан лексика, терминология, нигездә, төрки-татар һәм гарәп-фарсы сүзләреннән торалар. Күп очракта алар ерактагы архаик зоналарда: себер, әстерхан, касыйм, урал, нократ, перм һ.б. сөйләшләрдә чагылыш табалар.

Татар халкының мәетне җирләү, искә алу йолалары этнографлар һәм фольклорчылар тарафыннан шактый нык өйрәнелгән, монографияләр, мәкаләләр язылган (Уразманова 1984: 146; 2006: 840—849; Урманчеев 2002: 45—79; Бакиров 2008: 87—89; Шарафутдинов 2012: 55—73).

Тел ягыннан, терминология ягыннан чыгып системага салу, тематик төркем итеп, диалектлар һәм җирле сөйләш текстларына таянып монографик планда язу эшләре дә башланып киткән иде (Баязитова 1992: 295).

Гарәп-фарсы телләреннә н кергән дини терминология мәетне күмү, искә алу йолаларында төрки халыкларның уртак байлыгы бу---лып тора.

Үлгән кешене соңгы юлга озату да, ягъни мәетне җирләүдә алгы планга дини йолалар чыга, дип әйтелсә дә, монда борынгыдан килгән бик күп ышанулар, ырымнар, йола хәрәкәтләре бергә үрелеп бар--‑ган. Алар әле безнең көннәрдә дә сакланалар. Менә шушы катлаулы күренешне халыкның үзеннән сөйләтеп, өйрәнеп язып алынган материаллар күмү һәм искә алу йолаларын этнолингвистик яктан системага салу, тематик яктан классификацияләү өчен бай җирлек булып торалар.

Үлгән кешене җирләү һәм искә алуда йола терминнарының, синонимнарның байлыгы, гарәп-фарсыдан кергән һәм татар сүзләренең, җирле сөйләшкә караган сүзләрнең янәшә кулланылуы хас. Алар ба---рысы да халыкта билгеле булган, еш әйтелә торган мөнәҗәтләрдә, бәетләрдә, дога багышлаудагы гыйбарәләрдә чагылыш таба. Мәсәлән, *әҗәл* [< гарәпчә үлем] белән бәйле мөнәҗәтләрдән мисаллар.

*Әҗәл җиле*:

Әҗәл җиле — ис ә торыр,
Wакыты җиткәч — күчә торыр;

*Әҗәл шәрабы*:

Әҗәл шәрабын
Без бер эчәрбез.
Йакты дөнйадан
Бер көн күчәрбез.

*Әҗәл* сүзе XIII гасыр язма истәлеге «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (1983, 78) дә кулланылган:

Һәмандәм ул заһидә әҗәл ирди, —
Йусеф анда кайгулу калыр имди.

Шул вакытта ул заһидка әҗәл килде, —
Йосыф аннан зур хәсрәткә төшәр имди.

Җирле сөйләшләрдән мисаллар.

*Әҗәл кастасы* [гарәп] — әҗәл авыруы.

Әгәр килсә *әҗәл кастасы,*
Ачык булсын җәннәт капкасы (каз.ар.)

— Ә җәл қастасы тигән булса, имчегә баралар. Қайсы имче терелтә кешене *(т.кам.-крш.)*.

*Әсәл* [< гарәп. үлем] *(себ.)* әҗәл, үлем.

Әсәлләрең йеңел булсын,
Әсәл wақытларың йетсә,
Үтеп китү йеңел булсын,
Урыннарың тыныц булсын.

*Ә җәл* сүзе күбрәк дини фольклорда, дога багышлауларда, ә *үлем* сүзе халык гадәти сөйләшүдә, бәетләрдә кулланыла.

*Ару үлем (хвл.)* хәвефсез, кадерле булып, вакыт җитеп үлү.

— Ару үлем, ак кифен (әйтем).

*Үлем ачысы, үлем угы* — мөнәҗәтләрдә:

Йул буйындагы печәнне
Йулаучы аты ашый.
Дөнйа ачысы ачы түгел
Үлем ачысы бик ачы.

Үлем ачысы шундый агу
Берәү дә татымый калмас.
Үлем угын атар туры
Берәү дә котыла алмас (каз.ар.).

Кешенең үлеп китү, яшәүдән туктау халәте халык телендә түбәндәге сүзләр белән белдерелә: *өзелү* — казан арты сөйләшләрендә; *кичелү, киченү* — әстерхан, волгоград сөйләшләрендә; гарәп теленнән кергән һәм ярдәмлек сүзләр белән: *wафат булу* — үлү, *җан биру* һ.б.

Кеше, каты авырып китеп, үлем якынлашуын сизгәндә, яки кай---тып булмастай ерак юлга , сугышка киткәндә *бәхилләшү, бәхиллек со---рау* гадәте бар. *Бәхиллек* — үзара мөнәсә бәтләрнең соңгы йомгагы, нәтиҗәсе, бөтен төенне чишү яисә кисеп ныгыту була. Шулай итеп кеше хәлиткеч яисә соңгы моментларда бүтән кешедән, туганнарын---нан, балаларыннан, ата-анасыннан бәхиллек сорый.

*Бәхилләү, бәхил* сүзләре — бик җаваплы, эчтәлекле сүзләр. *Бәхил* сүзе үзе татар телендә гарәпчәдән *бихаль-бихәл* дигән сүздән үзгәртелгән. *Би* — юклыкны белдерә торган *-сыз, -сез* кушымчасы, ягъни *хәлсез, көчсез, үлем түшәгендә* дигәнне аңлата.

Барчагыз бәхил булыгыз,
Мин китәмен йыракка,
Барып коръәннәр укыгыз
Мине күмгән зиратка.

Зинһар әйтәм, туганнарым,
Бәхил булып миннән калыгыз.
Алып барып гүргә иңдергәч тә
Тәһлил әйтеп туфрак салыгыз (мөнәҗәттән).

Бу сүз керәшен сөйләшләрендә дә кулланыла: *бәқил*, чистай керәшеннәрендә *бакил* формасында.
— *Бакил, бакил, Ибан күршем, китәсең бит, без мәңге бакил, син дә безне бакиллә.*

Урта Идел регионындагы күрше халыклар: чуваш, мари, удмурт---лар да *бәхил* сүзен һәм бәхилләшү йоласын татарлардан алганнар.

Кеше үлгәч башкарыла торган йолалар: қыйблага таба борып кую, мәетне һәм шул йорттагы кешеләрне ялгыз калдырмыйча, күршеләре һәм якыннарының бергә җыелып кайгы уртаклашып, хәл беле---шеп утырулары татар халкының барлык төркемнәрендә дә бар. Ул түбәндәге сүзләр һәм сүзтезмәләр белән белдерелә: *мәйет қараулау (к.-уф.), мәйет қара wыллау (перм.), сөйәк караwыллау, үлек сақлау (себ.), мәйет сақлау, төн сақлау, төн утыру (глз.), төн утыруцылар, төннә утыруцылар (себ.), төнәү, төнәткәле бару, төнәп утырган қортқайақлар (себ.), төнәтү, төнәтүчеләр (әстр., влгг., урт.д.), төнге теләү* (*крш.), сақлап утыручылар* (крш.) һ.б. Татар халкында мәет әле юылмаган, җирләүгә әзерләнмәгән хәлдә булганда, аның якында мөнәҗәтләр, бәетләр әйтеп утыру гадәте саклана. Мәсәлән, керәшеннәрдә мә етне саклаганда «ахирәт бәете» әйтеп утыру турын---да мәгълүматлар язып алынган иде:

Ахирәт хә лен белмәдем,
Бер хәйер дә бирмәдем.
Бер хәйер дә бирмәдем,
Монда килерем димәдем (чст.-крш.).

Зәй төбәге керәшеннәрендә «түшәк саклау, урын саклау җырула---ры»н җырлап, «кенәгәләр»не, ягъни христиан дине китапларын укып утыру гадәтләре сакланган. «Урын саклау җырулары»ннан мисаллар:

Кара да кара күренәдер
Кара карлыганнарның куwагы.
Караңгылар дийеп килми калма
Сез караңгы төннәрнең кунагы.

Урман аwызлары ла тарлар аwыз
Агач башы сары ла балаwыз.
Сагынган ла сайын ла күрешергә
Җырагырак булды ла арабыз.

Җирле сөйләшләрдә үлгән кешене юарга су алып кайту, юу, юган суны түгү кебек җаваплы, җиренә җиткереп эшләнәсе эшләр белән бәйле күп кенә ырымнар, ышанулар һәм шуларга караган сүзләр, гыйбарәләр дә бик күп. Шулар арасында күп якларда бил---геле булганнары: *койаш туганчы, ягъни кояш чыкканчы су алып кайту; су алып кайтканда сөйл әшмичә кайту, өч чил әк белән* (ягъни сыңарлы итеп) *су алып кайту; суны агымга каршы алу* һ.б. Себер диалектларында да шундый ук үзенчәлеклә р бар: — *Таң башы белән көн (кояш) цыкмайын сыу алып қайталар — (туб.) — Көн (кояш) цыкмастан суны алып қуйғалы кирәк — (тара).* Перм татарлары сөйләшендә: — *Су алғанда айателкөрси уқып алабыз.*

«*Ахирәт тәһарәте алмаға,*
*зәхмәтләр ийәрмәсен*».

Керәшен сөйләшләрендә шулай ук *өч чиләкләп су алып кайту*; су алырга төшкәндә *таба тимере* (табагач) яки *тимер көрәк* тотып төшү («тимердән җен курка»), *су уңаена тегәрҗеп агызып җибәрү бар*:

«*Аның җулы чиста җул булсын*» (т.я.-крш.).

Мәет юганда т әҗрибәле, оста кеше «төп йуучы» була, шулай ук *су җылытучы, су биреп торучы, су йараштырып торучы* кебек ярдәмчеләрнең, *тастар башы тотучыларның* (мәет өстендә зур җәймә тотып торучылар) да булышлыгы, өлеше керә.

Мәет юган суны түгү дә бик ырымлы. Аны кеше аяк басмый торган җиргә чокыр казып, чокырына тимер әйбере салып («ийәләнмәсен») күмү тиеш санала. Мәсәлән, себер һәм әстерхан төбәге сөйләшләреннән язып алынган мисаллар:

— *Қыбыла йаққа қарап, песмилла әйтеп түгәсең сыуны. Кеше йөрми торған йиргә бер чоқырға қойғалы кәрәк. Суға тәшерме, қазақмы ташлап күмеп қуйалар* (бараба).

— *Йуған суны ура (чокыр) касып, мал, бәндә айақ басмас йергә қойоп, өстөнә песмилла уғынып тәмер (тимер) ташладылар.*

«*Тәмер (тимер) салсаң, ийәләнми*».

«*Иске балтамы, күбрәк сынган синәк салады*» *(бараба).*

**Мәйет җыйған су** — перм сөйләшендә:

— *Мәйет җыйған суны қадақ салып, бер чоқырға күмеп қуйалар.* Ислам дине йолалары буенча мәетне, гадәттә кәфенләп, табутка салмыйча гына күмәләр. Ләкин җир йомшак, комлы булган якларда, мә сәлән, Әстерхан өлкәсе татарларында мә етне юып, кәфенләп, табут---ка салып күмү йолалары да бар. Христиан динендәге татарлар, ягъни керәшеннәр, мәетне юып, киендереп гробка салып күмәләр. Гроб — рус теленнән кергән сүз. Керәшеннәр арасында гарәп теленнән кергән **табут** сүзен кулланучылар да бар: — Табутка кайын миллеге җәйәләр, баш астына чабыр үләне белән мендәр җүләп салалар — *т.я.-крш.*

**Табут** — гарәп теленнән кергән сүз. XIII йөз язма истәлеге «Кыйс---саи Йосыф»та кулланылган:

Ул сиддикның табутини хазир кылди, —
бер хуш йирә аны мәдфүн кылур имди.

Аннан аңа табутын ә зер кылдылар, —
Бер хуш урынга аны күмәрләр имди.

Әстерхан сөйләшендә **табут түгәрәгенә** кирәкле әйберләр, ягъни табут өстенә ябу әйберләре турында үзенчәлекле мәгълүматлар язып алынды:

— Ике-өч митыр йәшел зат (әйбер) алалар йабарға. Аны җил белән очып китмәсен дип, тәрәт йаулық (сөлге) белән бәйлиләр.

«Без үлгәндә йәшел зат (әйбер) йабың», — диделәр.

Табутка яба торган әйберләрнең төсләренә карата да әстерхан төбәге сөйләшендә түбәндәге тыемнар сакланган:

**Қызыл төс** — йарамый. Қызылны табутқа йапса — балаларда қызылча (авыру) күп була.

**Күк төс** — йарамый. Күкне йапса — балаларда күк йүтәл күп була.

**Сары төс** — йарамый. Сарыны йапса — балаларда сары аwыруы була (Баязитова 2002: 186).

Керәшеннәрдә табут белән бәйле түбәндәге йола хәрәкәтләре язып алынды.

— Кыруг сызалар балта белән. Табутны өч тапқыр әйләнеп чыга---лар, қойаш чығышына балтаны ырғыталар (*нгб.-крш.*).

Табутка үлгән кеше янына ашамлык кую да керәшеннәрдә саклан---ган йола:

**Кәлбә** [гар.] — хәлвә.

— Кәлбәне мәйет озатасы көнне пешерәләр, майға он, бал салып. Аны әркемгә аwыз иттерәләр дә бер кечти төйенчек белән үлекнең қултық астына табутқа қуйалар:

«Анда барғач үлеләргә өләшергә».

**Умач** — көнбагыш мае белән оннан ясалган умач. Аны табутка куялар.

— Кеше үлгән көнне айбағыр майы белән оннан умач уwып, аны бер кечти җанчық белән үленең қултық астына, табутқа қуйып җибәрәбез (*каз.ар.-крш.*).

Үлгән кешене төреп күмү өчен әзерләнгән тукыма гарәп теленнән кергән *кәфен* сүзе белән белдерелә, җирле сөйләшләрдә аның төрле фонетик вариантлары бар: *кипен, кифен, кәбен, кәфеллек, кипеннек* һ.б.

**Кәфен сару** — «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (1983, 162) дә кулла---нылган:

Күрклү йүзләр кәфен сарыб гүргә керсә,
үкүш дәгүл, гүр эчендә үч күн дорсә...
Күрекле йөз кәфен сарып гүргә керсә,
Күп тә түгел, гүрендә тик өч көн торса...

Мөнәҗәтләрдә «*кәфен сару*» шулай ук бик еш очрый:

Кәфен сарырлар
Зифа буйыңа.
Илтеп қуйарлар
Җирнең қуйнына
(«Мөнәҗәтләр», 464 б.).

Себер диалектларында фарсы теленнән кергән *чатыр* сүзе дә *кәфен* мәгънәсендә кулланыла:

**Чатыр** [фарсы. чадор] *(төм., туб.)*:

**Тышқы чатыр, урта чатыр, эчке чатыр** — кәфенлек: тышкы, урта, эчке кәфенлек.

— Тышқы чатыр, урта чатыр, эчке чатыр була. Эчке қаты йәшел, тышкы қаты ақ таwардан булса саwап *(туб.)*.

Себер диалектларында *кәфен, кәфенлек* сүзләре урынында борын---гы төрки телдә гомумән кием мәгънәсен белдергән *тун* сүзен куллану өлкән буын кешеләре сөйләшендә еш очрый.

**Тунның** *(себ.)* үлгән кешене төрү, киендерү өчен әзерләнгән туқы---ма, кәфенлек.

— Тунныкларны тақ қыласың. Хатын кешегә биш қат исәпләнгән, ирәннәргә (ирләргә) өц қат. **Тунныклау** *(себ.)* кәфенләү. — Ақ таwар алып қуйғаммын үсемә тунныклағалы. **Кәбен туны** *(туб.)* кәфенлек. — Кәбен тунын әргем әсерләгәле тейеш. Кәбен туныннан қалған малны кешегә өлиләр.

**Азақ тун, ақтық тун** гыйбарәсе еш кына акбүз сүзе белән янәшә куеп искә алына:

Бу дөнйаларны сөйсәм дә
Йакшы кейемнәр кимәдем.
*Азақ туным ақбүз* булуын
Нигә хисапламадым.

«*Ақ бүз* — ақтық тун», — дигәннәр *(к.-уф.)*.

*Ақ бүз күлмәк, ақ бүз җәймә, ақ бүз кәфен* сүзтезмәләре дә мөнәҗәтләрдә еш кабатланалар:

Ақ бүз күлмәгем
Кийеп китәрмен.
Атнакичләрне
Килеп җитәрмен...
Күлмәк теккәннәр
Ақ бүз җәймәдән...
Қуйып киткәннәр

Ак бүз кәфенгә...

Мәет җирләү йолаларында *бүз* сүзенең кулланылуы «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә дә бар (1983, 282):

Ул ук сагә т фә рештәләр аны йуды,
уҗмахдан бүз китүреб кәфен сарды...

**Тегәрҗеп** — киндер яки җитеннән эрләп катылган, нык, чыдам---лы җеп. Тегәрҗеп — тормыш-көнкүрештә, халык традицияләрендә, төрле ышанулар, ырымнар белән бәйле йолаларда киң файдаланыл---ган. Кәфен теккәндә дә «үзе эрләгән җеп, тегәрҗеп» белән тегү сава---плы дип саналган:

— Әwәле үсе йергән йеп белән теккәннәр кәбенне (кәфенне), үсе йергән йеп саwаплы булґан (төм.).

Тегәрҗеп — саwаплы җеп, «үлгән кешенең җулы», — дип суга агы---залар:

— Тегәрҗепне су уңғайына агызып җибәрәләр.

«Аның җулы чичта җул булсын», — дигән сүз була (т.я.-крш.).

Кәфен теккәндә энәне каршыга атлатып тегү, җепне төенләргә яра---мау турында җирле сөйләшләрдән бик күп мисаллар язып алынды. Мәсәлән:

— Кәбенне тегәбес, йеп оцыкларын төймибез кәбен теккәндә (туб.).

«Кәбен (кәфен) теккәннән қалған йеп» — шулай ук ырымлы:

— Кәбен теккәннән қалған йепне урап-урап, кәләпләп (киләпләп) биргән:

«Аның йәшен бирсен», — тип биргән (төм.).

Борынгыдан килгән мифологик күзаллаулар буенча, барлык Һинд-Европа телләрендә дә «нить жизни» — ягъни «тормыш җебе» гыйбарәсе кулланылган (Афанасьев 1982: 362). Кешенең гомере — су---зылган җеп кебек, ул өзелсә, кеше гомере дә өзелә. Татар халкында да мәет җирләү йолаларында аеруча еш кулланылган тегәрҗеп, аны кеше үлгәч тә өләшеп бирү, төенләмичә генә кәфен тегү башка бик күп халыкларның борынгылыклары белән тәңгәлләшә.

Кәфен теккәннән калган энәне һәм җепне урнаштыру, кәфеннән калган тукыманы өләшеп бирү шулай ук үтә сакраль, бик борын---гыдан килә торган ышанулар һәм йола элементлары дип саналырга хаклы (Фурсова 2009: 11; Смирнова 2009: 107—108; Бодрова 2009: 33—39).

Тау ягы авылларында (мәсәлән, Апас районы) үлемтеккә дип әзерләп куйган тукыманы яки сөлгене кул белән ертып-ертып өләшәләр:

«Җыртыш җырту әле дә бар ул.
Җыртышны тегәрҗеп бәйләп, кеше сайын өләшәләр».

«Дөнйалықта кешенең битен җыртқан гөнаһларын җарлықа---сын», — дип җырталар җыртышны.

«Сөлге җыртышы бик файдалы ,
тәмуғ утын селкеп сүндерә», — ди.

«Қайчы белән кисәргә түгел, җыртып қына бирергә қушалар. Мәйетнең үз өстендә җыртып тарataлар җыртышны, қулҗаулық хәтле генә итеп. Ғайбәтлә ре, сүзе айақ астында қалсын, җыртылып қалсын, таралып қалсын», — дип (Тутай).

Себер диалектларында һәм әстерхан сөйләшләрендә үлг ән кеше өчен өләшенә торган тукыма *тибәрлек* (әстр.), *тәбәрлек* (себ.) дип ата---ла. Татар теленең башка диалект һәм сөйләшләрендә күмү һәм искә алу йолаларында мондый сүзләр очрамады. Без аны йола башкарганда әйтелә торган үтенү-сораулар, теләкләргә карап *тәңре бирлек, тәңрегә бирлек* сүзләренә барып чыгадыр дип уйлыйбыз. Керәшеннәрдә дә шулай *т әберсен, тәберсен итү* — үлгән кешене искә алганда дини теләкләр теләүне *тәңре бирсен* сүзләреннән килә дип таныйбыз.

**Тәбәрлек** — тубыл, төмән сөйләшлә рендә: олы яшькә җитеп үлгән кешенең кәфенлек тукымасыннан яки калган киеменнән кисеп яки ертып алып өләшенә торган тар гына тукыма. Аны тылсымлы, магик көчкә ия дип беләкләренә бәйләп йөрткәннәр. *Тәбәрлек бәйләү*: — Тәбәрлек бәйләй тегән итек қартайып үлгән қартларныкын. Менә мин сиксән биш йәш, мин үләм, минекен бәйләйтеләр. Кәбеннегемнән қалған малны йыртқылап бәйләйтеләр. Тәбәрлек тип әйтелә.

Мин әйттем: «Инәмнең йәшен пир миңә».

— Тәбәрлек өләшәтеләр сиксән-туқсан йәшлек картларныкын.

«Аларның йәшенә йетәйен», — тип атайсың.

— Тәбәрлек ул оллы гешенең ғомерен сорап қалу булаты.

«Алла паба,
пы пабаның йәшен
миңа калдырцы,

пы оллатаның йәшен пирце», —

тип, тәбәрлекне пеләккә урайсың *(туб.)*.

— Кәбеннектән калган малны йыртып, күмелгән көнне анта булған кешеләргә өләшәтләр:

«Писмилла, аның йәшен бирсен».

— Көрмәттә үлгән, төнйатан киткән оллы қортқайақларнықын тәбәрлеген бәйләйтеләр. Алай-болай үлгән, арақ эцкән кешене---кен бәйләмәйтеләр. Ыруларыннан берәү йыртып-йыртып бирәте, кәбеннек малы қаламы, йаулығын йә көйләген йыртыпмы. Қайсы кеше сурап алаты тәбәрлеген:

«Аның йәшенә мин т ә цығайын,
антай қәтерле булып төнйатан китәйен», —

тип сурайтылар. Кәбен туннан йыртып бирәтеләр.

Тәбәрлекне утта яндырырга ярамый, җиргә күмәргә кушканнар:

— Ир кешеләр тәбәрлекне күкрәк кесәләренә салып қуйалар да қырығынаца йөретәләр. Қырығы булған сун алып йиргә күмәтеләр:

«Утқа тықмаң, төтен булып бараты үлгән кешенең қаберенә, ул анта төтенгә тончыға» — тиде *(туб.)*.

— Җеназада иң күп кулланыла торган әйбер — *сөлге* яки *тасты---мал* — өчәр митерле сөлгеләр әзерләп қуйғаллар. Қабергә төшергәндә мәйетне ипләп кенә шул сөлге белән ике кеше төшерәләр. Ул сөлгеләр шул гүргә төшергән кешеләрнең үзләренә була (*бер.*).

Җеназада син, ак сөлге,
Безнең кулда.
Озатасың гүр иясен
Соңгы юлга (Р.Харис).

«Сөлге ул тамуг утын селкеп сүндерә, мазар өстендә (зиратта) сөлге өләшәләр» (*т.я.-крш.*).

Мәйет озату, мәет җыйу, җирләү, күмү сүзләре белән бергә, аерым сөйләшләрдә, мәс әлән, глазов сөйләшендә (Удмуртия) *мәйет й әшеру* сүзе дә сакланып калган. Бу, күрәсең, бик борынгы чорлардан, тарих чоңгылыннан килеп җиткән сүз булса кирәк.

— Кичтән үк әйтеп куйалар:

«Үлек йәшерәсе бар», — дип.

«Үлек йәшерәсе бар, кайгылы көн бүген», — дип.

Сугыш өстөндә кайын тузына салып та йәшергәләделәр үлекне

*(глз)*.

Тау ягы керәшен сөйләшендә *уле тыгу* — мә ет җирләү. — Үле тык---кан көндә дә, өчендә, тугызында, кырыгында да мунча йагалар. Өч кеше йага мунчаны. Тыккан көнне таwык суйалар.

Татар теленең барлык сөйләшләрендә дә гарәп теленнән кергән *кабер*, фарсы теленнән кергән *гүр* сүзләре кулланыла. Бары тик алда искә алынган тау ягы керәшен сөйләшендә генә аерым өлкән кешеләр кабер мәгънәсендә *тишек* сүзен дә еш кына әйтеп куялар:

«Үлегә тишек казалар алмаш-тилмәш. Бер митыр җарымнык ти---шек казилар да тубыкны (табутны) җиргә тыгалар:

«Җирдән булган,
Кабат җиргә кайт», — дип.

Үле мәндә тишектән чыгып җөрмәлле. Чакырганда ызбасына кат'ып утыра. Аны өчен үлене чабата кигезеп күммәлле, чабата уңай була тишектән чыгып җөргәндә» *(т.я.-крш)*.

Мәетне кабергә салганда яки күмеп беткәч әйтелә торган теләк---дога сүзләре һә р төбәктә дә үзенчәлекле җирле төсмерләр белән бае---тыла. Мәсәлән, бараба диалектында:

Йатқан йирең — йарық булсын,
Тар гүрең — кәң булсын.
Аwыр балчықларың йиңел булсын,
Аллаһы тәгалә тел ачкычлары бирсен.
Қабереӊ — нур булсын,
Иманың — йулташ булсын,
Алдың — үзеңә,
Артың — безгә, —

тип туwа қылабыс.

Минзәлә сөйләшендә:

Тар қаберләрен киң қыл,
Қараңғы гүрләрен йақты қыл,

Иман белән хөрмәтлә,
Ахирә ткә иман белән кучә ргә нәсиб ит,
Тәмуғ утларын харам қыл, йарабби
Аwыр туфрагың җиңел булсын,
Қабереӊ йақты булсын,
Иманың камил булсын,
Урыннарың җәннәттә булсын.

Кабер өстенә агачтан яки таштан куела торган билгелә рнең, кабер---не уратып алган коймаларның атамалары да гаҗәп күп төрле, алар тарихның борынгы чорларына кайтып калалар. Мәсәлән, *башагач (глз.)* — кабер өстенә куела торган агач. Ул артыштан куелган: — Башагачны артыш агачтан қуйалар. Ул саwаплы ағач булган артыш агач. *Башмата, башбата* (нокр.) — кабер өстенә куелган таш яки агач казык. *Таш башбата, ағач башбата* булган.

Үлдем исә хәберемне
Ләхет белән алыгыз.
Артыштан башмата салып
Исемемне йазыгыз.

*Башказык* (срг., кузн.), *башқазық* (әстр.) — кабергә куелган казык. — Башказыгына тал агачы утырткан. Йеслекне (сөлгене) каберенә илтеп, башказыгына бәләп қуйалар (кузн.). — Кас'ы тамгасы бар үз йирендә, шыл тамганы куйа башказыкка (срг.). *Қабер баганасы* (т.кам.-крш.) ка---бер өстенә утыртылган багана, анда тастымал элгәннә р: — *Қабернең бағанасы* була. Анда тастымал эләләр. «Йул ачқычы» дип. Аламала---ның бетсә, ул тастымалны алып, икенчене элеп қуйалар.

*Билге, билгеташ* < билге + таш *(әстр.)*.

*Кабер ташы (каз.ар):*

Бар күңелләрдән жылы,
Йомшак синең кабер ташы.
Шунда тамсын күз яшемнең
Иң ачы һәм татлысы! (Г.Тукай)

*Ташбилге* < таш + билге *(каз.ар.-крш.)* — кабер ташы.

*Ташбилге* < таш + билге *(т.я.-к.т.)* — иске зираттагы каберлек, изгеләр зираты дип йөртелә. *Қылпыташ* < қылпы + таш *(әстр.)* — ка---бер ташы. *Тораташ (чст.)* — изгеләрдән дип санала торган таш сыннар.

Каберне әйләндереп алган рәшәткәле койма әдәби телдә фарсы теленнән кергән *чардуган* сүзе белән белдерелә. Ләкин аның җирле сөйләшләрдәге атамалары күп төрле. Мәсәлән, *чардак* (лмб., кузн., тмн.), *рашутка (чпр.)* < рус. решетка һ.б.

Себер диалектларында һәм Урта Урал тирәсе сөйләшләрендә ка---берне әйләндереп, *буралап* кую гадәте булган. Аны өч рәт бүрәнәдән, кадак какмыйча гына куярға тиеш булганнар.

— Бура қуйалар қабер өстенә.

«Бура өскә мәйетләр сығып утырыр», — тип әйткәннәр элекеләр *(к.-уф.)*.

*Киртмә, киртмә киртү, киртмә түбә, киртмә сарай (туб., төм., тара), кәртмә, кәртмә кәртү (бараба), кәртә (к.-уф.), текмә, тесмә (туб.), сарай* (төм., тара), *киртмә сарай* (төм.), *йақшылар сарайы* (төм.) — изгеләр кабере өстенә куелган агач корылма.

Әле соңгы чорларга кадәр мәет өстенә бары тик агач корылма гына куелырга тиеш, тимер ярамый, ул мәеткә авыр була дип себер авылла---рында тимер чардуганнар куймаска тырышканнар. Кабер өстенә агач---тан ясалган корылманы «*мәйетнең өйе*», «*мәңгелек өй*» дип әйткәннәр.

— Пороңгы кешеләр қабер өстенә өй йасағаннар. Киртмәне «мәйетнең өйе» тип әйткәннәр.

«Өйгә кереп китте инте», — тиләр. Киртмәтән өй йасаса, иң өстөнә пер пүрәнә салғалы тейеш, ул «түбә» булаты. Өц рәт, йә биш рәт пүрәнә салына.

«Өйемнең түбәсе йуқ», — тип әйтәте мәйет, киртмәнең өсте ацық булса (туб.).

Кабер өстенә агачтан бура ясап кую табигать шартлары һәм бо---рынгы ышанулар белән бәйле рәвештә безнең көннәргә кадәр ки---леп җиткән. Бу турыда тикшерүче галимнәр түбәндәге фикерне әйткәннәр: «Сруб над могилой стал результатом механического соединения двух разных по происхождению способов захоронения — наземного («таежного») и погребения в могиле («степного»). Подобные пути развития похоронных традиций народов Сибири в XIX в. скорее был правилом, чем исключением» (Грачев, 2010: 330).

Үлгәннәрне күмү урыны, каберлек *зират* (< гар. зиярәт) сүзе белән белдерелә. Зират сүзенең җирле сөйләшләрдә түбәндәге фонетик һәм лексик вариантлары бар: *зиратлык (трбс.), зәрәтлек*

*(тмн.), изгеләр зираты, әүлийә зираты (нокр., глз.), қырбаш (себ.), мазар (крш., нокр.), мәйет (әстр.), үлемтек (крш.), түбә, үле түбә, бабай түбә (әстр.)* һ.б.

Себер диалектларыннан мисал: — Белгән, ишеткән бөтен кеше йөрите қырбашқа. Саwаплы була. Қырбаштан килгән кешеләргә бөтөннәй қуй пешерәтләр, қартлар өйгә керәтеләр. Аш таратасың аларға (*төм.*).

Әстерхан сөйләшендә мәет күмү урыннары *түбә*: *үле түбә, бабай түбә* дип атала.

— Үлене бабай түбәгә алып киткәч, балта белән ишек төбен чабабыз. «Артық үлем булмасын».

— Үле түбәдән қайтқан әйберләрне йумыйлар, әүләдә (ишек алдында) җепкә генә элеп қуйалар. «Йолдыз чықсын, йолдыз күрсеннәр әйберләр». Йолдыз күргәннән соң җыйыб алып, үтүкләп урынына салдылар *(әстр)*.

Нократ сөйләшендә мәет күмү урынын, иске зиратны «Мазар таwы» дип атап йөртәләр. Төрки халыклар, мәетне, гомумән, биегрәк урында, калкулыкларда, тау башында яки тау итәгендә җирләргә тырышканнар ( Мажитов 1977: 126; Бутанаев 1988: 112). Татар диалектларында зират мәгънәсендә *кырбаш, түбә, бабай түбә, мазар таwы* һ.б. сүзләрнең кулланылуы да шуны күрсәтә.

Дөньядагы башка бик күп халыклардагы кебек үк, татар халкында да, кеше үзе вафат булса да, аның җаны үлми дип ышанулар яшәп килә. Ахирәт [гарәпчә «теге дөнья»], дин өйрәтүенчә, кеше кыямәт көнендә кабат терелеп, мәңге яшәячәк дөнья. Кешене юып кәфенләгәндә «ахирәт күлмәге», «ахирәт йаулыгы» сүзләренең кулланылуы да шуны күрсәтә.

Кеше үзе үлсә дә аның җаны үлми, дигән ышанулар бик күп ха---лыкларга хас: татар, рус, удмурт һ.б. (Носова 1993: 75—76; Касимова 2003: 149; Мухамедова 1972: 83; Листова 1993: 5; Валиди 1930: 6; Попова 1998: 174).

Җан ул чыккан уңайына күккә аша, җыл тулғанчы җамансулап килеп җөри, ди. Йыл тулгач, сур мөгезенә кергәч җаны қайта ал---мас, ди (минз.). Сур [< гар.] — быргы. Исрафил — мәшһүр фәрештә. Мөнәҗәтләрдә:

Исрафил сурын өргәй,
Йә, Хәбибем, тор дигәй.

Кешенең җаны кошка яки күбә ләккә әйләнеп кайтып йөри дигән ышанулар татар халкының барлык төркемнәрендә дә бар, ул борынгы язма истәлекләрдә күзәтелә.

XIII йөз язма истәлеге «Кыйссаи Йосыф» (1983, 282) әсәрендә шун---дый юллар бар:

Шәриф тәндин айырулды ғәзиз җаны, —
кушә бинзәб уҗмах таба учар имди.

(Изге тәннән аерылды газиз җаны, —
кошка охшап, оҗмах таба очар имди.)

Җирле сөйләшләрдә өйгә очып кергән күбәләкне *җан күбәләге (каз. ар., перм.), үлекнекесе күбәләк (глз.), җанпапа (нокр., глз.)* дип атаулар, тотып алып кире очыртып җибәрү турында язмалар бар. *Җанпапа* — *җан* < гарәп сүзе, *папа* < удмурт телендә кош, икесе бергә килгәндә күбәләк мәгънәсен белдерә.

— *Җанпапаны бездә карчыклар изге саныйлар.*
«*Бабамыгыз кайткан*», — *дип, әбей садака бирмәгә әйтә иде (глз.).*

Кешенең җаны күбәләк булып кайту турында себердә язып алган мөнәҗәтләрдә дә бар:

Атна кич җиткәч йаным кайтыр
Ак күбәләк булып, бәбкәйем *(том.).*

Үлгән кешенең җаны турындагы ышанулар үзе бер бик зур тема булырлык мифологик материаллардан туплана. Мә сәлән, *гонаһлы кешенең җаны, имеш, қаберне тишеп чығып йөри, убырға әйләнә. Җаны убыр булып чыгып йөрмәсен дип, имән қазық қагып қуйалар ул қабергә* (минз.). Керәшеннәрдә искә алу көннәрендә зиратка барып «*җанын чақырып кайту*», мәҗлес үткәргәч «*җанын озатып җибәрү*» йолалары бөтен нечкәлекләре белән бүгенге көннәргә кадәр сакланган.

— *Үле ашын үткәргәндә зиратқа барып чақырабыз. Өч кеше барабыз. Ипиләр алып барабыз, су, чәй, ризыклар.*

«*Сине алырға килдек, бүген синең ашың.*
*Туганнар, тумачалар, барығыз да өйгә қайтығыз*».

Үлгән кешенең «җанын озату» вакытында әйтелә торган теләк сүзләре һәм «үле озату» җырулары өлкән кешеләрдән язып алынган бик күп этнолингвистик текстларда чагылыш таба.

— *Келәүләр беткәч үлене озатып җибәрәбез инде. Қойаш чығышына қарап озаталар аны, игенче өйнең почмағына кадар.*

«*Урыны очтомакта бусын,*
*Туклыкта җөрсен*», — дип.

Урындыққа мендәр қуйып, табаққа қоймақ қуйып тәберсе итәргә чығалар.

«*Безнең кебек ашап-эч,*
*Безнең кебек туклыкта бул,*
*Очтомагыңда бул,*
*Җақшы урын булсын*», — дибез.

Бүгенге көндә «*әйтә белүче*», « *әйтеп ашый белүче*», «*тәберсен әйтүче*» дип йөртелә торган өлкән кешеләр күп түгел. Шуның өчен без аларның әйткән теләк-сүзләрен зур табыш дип санап, бөртекләп туплап калдырырга тырыштык:

*Ахирәттә алдыгызда булсын,*
*Тук булыгыз,*
*Кыйаматлык дөнйагыз йакты булсын,*
*Йаткан җирегез йомшак булсын,*
*Безгә тормышка җүн биреп торыгыз,*
*Усаллардан, дошманнардан саклагыз, —*

дип әйтәләр дә кереп китәләр.

«*Бик сыйландык, бик рәхмәт*», —

дип әйтеп киттеләр, дип керәләр...

Себер диалектларында кешенең җанын *йола* дип тә атаганнар (Баязитова, 2010: 313). Йола ул кеше үзе исән чагында аның белән янәшә йөри, нәкъ үзе төсле булып ара-тирә күренеп тә ала икән. Әлеге мифологик күзаллаулар күньяк Себер халыкларында да сакланган. Мәсәлән, *чула // шула* сүзе кешенең җаны, аның үзе кебек үк рәвеше (двойнигы) дип ышанулар хакас халкында бар. Кеше үлгәннән соң *чула* чыгып китә, *сӱрӱн* (тат. сөрән?)гә әйләнә, искә алган көннәрдә кайтып килә икән.

«Чула является хозяином человека и якобы сосредоточивается в зрачках. После смерти она выходит из глаз и превращается в *сӱрӱн* или *сӱне*, т.е. поминальную душу. В течение года во время поминок она незримо присутствовала среди живых людей». (Грачев 2010: 302— 332; Бутанаев 1988:112).

Телеут халкында *јула* яки *кут* кешедән кечкенә генә ут булып чыга икән.

*Јула* (=дьюла, чула) сүзе М.Кашгарый сүзлегендә ялкын, факел мәгънәсендә бирелгән. «Слово *јула* (*=дьюла, чула*) имеется у Махмуда Кашгарского, которое имело значение «пламя, факел», а у телеутов есть рассказ о том, что выходит *јула* или *кут* из человека в виде маленького огонька [ Потапов 1991: 46—47]. И, как монголоязычное *сулдэ*, эта сакральная субстанция была связана с головой (*чула* находилась в голове человека) [Там же: 49] или деревом. У хакасов «информаторы, помнившие о «принадлежности» отца или матери к тому или иному дереву, говорили: «Чула отца — береза, матери — лиственница, моя чула — береза». Слово *чула* / *шула* в значении « душа, духовный облик, двойник человека» известно всем группам хакасов» [Традиционное мировоззрение... 1990: 56].

Шулай итеп, себер диалектларындагы *йола* — кешенең рухы, җаны. Ул, кеше үлгәнче үк, чыгып, күренеп йөри, имеш. «*Йола* » сүзе төрки халыкларда җан белән рухны билгеләгән «рух», «тын», «кот» мәгънәләрен дә аңлаткан булса кирәк. Димәк, «йола» төшенчәсе бо---рынгы төрки телдә киң мәгънәле, универсаль төшенчә формасында яшәгән бер уртак сүз вазифасын үтәгәндер дип фараз ителә.

Себер диалектларында безгә тагын бик борынгыдан калган, үлгән кешенең җанына ышануларга мөнәсәбәтт ә булган курчакка, қоңырчакка табыну йолаларын язып алу мөмкин булды. Хәзерге ва---кытта алар инде юк, ләкин өлкән кешеләр аны сөйләп искә алалар (Баязитова 2010: 450—460). Шундый ук йолалар себернең угор ха---лыкларында да булганлыгы билгеле: «До настоящего времени манси изготовляют изображение (куклу) умершего. Это фигура из дерева, которую кормят и одевают. Считается, что в нее вселяется душа умершего» (Иванова 2009: 75—79).

Мәет җирләүгә, аны искә алуга багышланган һәрбер мәҗлес ты---ныч, салмак бара, кайгы-хәсрәтле тантана белән сугарылган була. Керәшеннәрдә искә алу мәҗлеслә рендә кайғы-хәсрәтле җырлар да җырлап утыралар. Мәсәлән, Түбән Кама ягы керәшеннәреннән түбән---дәге җырларны язып алган идек:

*Әйдәгез лә, туганайлар, ай сунарга,*
*Төлке айакайларын ла тунарга.*
*Урыннары җәйгән, киеме калган,*
*Туганайлар кайтмый ла кунарга...*
*Көймә генә көймә керләр дә җудым,*

*Кибәр генә дидем лә, кипмәдей.*
*Кайтыр гына ди-ди көткәннәр ийем,*
*Қайтыр да җирләргә лә китмәдей.*

Татар халкында кеше үлгәндә, кайгы никадәрле тирән булса да, кычкырып, такмаклап елау ярамый диг әннәр. «Йыламагыз, үлене суда батырасыз», — дигән сүзләр булган. Ләкин безнең үзебез авыл---ларда йөреп өйрәнг ән материаллар күрсәткәнчә, татар халкының кай---бер төркемнә рендә мәетне елап-сыктап, җыр яки билгеле бер ритмга салынган сүз тезмәләре әйтеп озату гадәте булуы турында өлкән әби---бабайлар күңелендә әле безнең көннәргә хәтле сакланган. Мәсәлән, себер диалектларында шундый әйтем бар:

«*Туй — үпкәсес пулмыйты,*
*Үлем — сыктаусыс пулмыйты*».

Әстерхан татарларында:

*Үле күрке — җылау*
*Туй күрке — җыр*, — диләр.

Мәет күмгәндә җырлап елауның борынгы болгарларда булуы ту---рында мәгълүматлар Ибне Фадлан язмаларында бар. (Путешествие 1939: 77).

Төрки кавемнәрдә йола буенча такмаклап елау гадәте булу турында кытай чыганакларында һәм Орхон-Енисей язмаларында да әйтелгән. (Лю Маоцай 2002: 21, 23, 43; Күлтәгин 2003: 199, 215; Кызласов 2013: 87—88).

Борынгы төрки Кюль-Тегин язмаларында кеше үлгәндә йола буен---ча җырлап елау, такмаклау турында мәгълүматлар бар. Анда *сыгыт* термины һәм *сыгытчы* — елаучы, ыңгырашучы сүзләре кулланылган (Малов 1954: 36, 43).

Йола буенча такмаклап елау хәзер дә төрки халыкларда бар, мәсәлән, алтай, хакас, тува, кыргыз, казакъ, нугайларда (Дьяконова 14975: 53—54, 155; Потапов 1991: 152—153; Стасевич 2004: 83—88); Фиельструп 2002: 98—100, 108, 115, 118—123). Нугай телендә *бузлау---чы* — үлгән кеше янында такмаклап елаучы. Элекке вакытларда мах---сус тел остасы булган «бузлаучы» хатыннарны чакыра торган булл---ганнар. Нугай телендә *бозлау* — үлгән кеше янында такмаклап елау (Калмаков 1988: 102).

Көнкүреш һәм йола үзенчәлеклә ренә бай булган «Казакъ кызы» романында Г.Ибраһимов тугандаш казакъ халкының революциягә кадә рге дала тормышын сурәтли, аларның теленә хас сүзләрне кулла---нып әсәрнең милли колоритын тагын да көчәйтә.

Төрки халыкларның бик күп борынгы уртаклыкларын чагыл---дырган йола — мәрхүмнең җеназасы, соңгы юлга озату йолаларын---да кешенең яхшы якларын әйтеп, образлы итеп такмаклап җырлау, сыктауның акын авызыннан башкарылуы бик үзенчәлекле. Бүгенге көндә бу йола берникадәр дәрәҗәдә себер, әстерхан, мордва-каратай, керәшен сөйләшләрендә сакланган.

«Акын туктамады, һаман төрле көйгә салып җырлый бирде:

— Бүгенге хә срәтне әйтү өчен чичәнлек кирәк имәс. Күңелең ак булса, йөрәгеңдә илгә мәхәббәт кипмәсә, син телсез булсаң да, бүгенге кайгы җырын көйләрсең!

Ай, Байтүрәм, син бер идең!
Каның Чингиздан килә!
Ата-бабаларың ханнар, солтаннар иде!
Яшьлегеңдә азамат булдың!
Ир чагыңда ил өчен кан койдың.
Картлыгың килгәч, көн димәдең, төн димәдең,
Йортның, аләүмәтнең кайгысы синең кайгың булды!
~~Тәңрем сиңа меңләгән җылкы, төя,~~
исәпсез куй бирде,
болардан йортың бары туйды!
Син киттең, исемең далада мәңге яшәр,
мәгәр безне кемгә калдырдың, ау! —

дигән мәгънәдә, байның зур нәселен, исәпсез байлыгын, илдә өстенлеген җырлады...»

«Мәрхүмнең дуслары моны әләктереп алдылар, акынның эзе бу---енча үзләре арттырып, бөтен җыелган халыкка сүз күбәйттеләр» (Г.Ибраһимов, 2 том, 1975, 197).

Кеше үлгәч, аның яхшы сыйфатларын әйтеп такмаклап елау төрки халыкларның гына түгел, славян һәм фин-угор (мордва , коми, карел, эстон һ.б.) халыклары йолаларында да уртак компонент булып санала (Чистов 1987: 396—407).

Экспедиция вакытларында кеше үлг әч такмаклап елауның ярым чәчмә, ярым шигъри үрнәкләрен дә язып алырга туры килде. Мәсәлән, Әстерхан өлкәсенең Кундрау һәм Сәетләр авылларында язып алын---ган үрнәкләр:

«Үлгән кеше әле түрдә жатқанда да тақмақ әйтеп җылайлар, үзендәге эчендәген әйтеп-әйтеп:

Әни, без синсез ничек торыбыз,
Фәрештә кебек идең, бөтен серебез
Сиңа сыйа иде, инде кемгә сөйләрбез, —

дип, кычкырып, тақмағын әйтеп йыламаға тийеш.

Әйем, ау, җаным, ау,
Үстердең безне, йақшылығымны
күрәлмадың, нигә үлеп киттең, —

дип җылай.

— Тақмақлап йылау бар. Армастан (яшь көенчә, картаймыйча) үлеп киткән кешегә бик тақмақлап йылыйлар. Шунда муллалар шам---гана (ачулана):

«Бик алай йыламағыз, үлене суда йөздерәсез», — дип» (Кундрау).

Себер татарларында мәет белән хушлашканда тақмақлап сықтау булган:

— Үлмәстән алда әйтеп қуйған була. Син минем пөтөн қылған эшемне әйтеп, тақмақлап-тақмақлап сықта, қысым, тип. Қысы пөтөн нимәсен әйтеп-әйтеп сықтайты. Пөтөн кеше сықтайты.

Пөтөн нимәсен әйтеп сықтайлар йақын туғаннары.

«Бу төнйада ицбер рәхәт күрмәте,
очмағынта пулсын рәқәте».

Қарт қортқайақ үлсә:

Алланың рәхмәтендә булсын
Пала-пақраларға синең йәшең пирсен,
Киң дәүләтләр бирсен,
Сиңа туй инде қарт кешегә,
Син аш ашадың, йәш йәшәдең, —

тип сықтайсың. Сықтаған сығытларым кән (күп).

Мәетне озатканда аңа төрле теләкләр теләгәннәр:

Алланың рәхмәтендә булсын,
Урыны очмақта булсын,
Қараңгы гүрләре йарық (якты) булсын,
Иманы йулташ булсын.

Татар теленең мордва-каратай (татарлашкан мордвалар) сөйләшендә без такмаклап елап мәет озатуның бигрәк тә эчтәлекле һәм зур кү---ләмле вариантларын язып алган идек. М.-каратайларда шундый әйтем дә бар:

Туйны иләме (яме) — җыр белән,
Үлене иләме (яме) — җылату белән.

Адикайым (әнекәем) үлде менә, җылатып илттем гүрләр өстенә:

Адикай дим, қайсы сандугачтан тыңларым инде
сине таwышыңны,
Кайсы сандугачка калдырып китәсең телеңе, адикай.
Читтәге әрем кебек селкенергә калдырасың, адикай.

Гүрләргә төшергәнче урамнан кычкырып җылатып бара. Гүргә төшергәндә, гүрләр эстендә дә җылата:

Актык узуын инде киң урамнан, адикай,
Пачиба кара калыкка,
Бар да сине затырга килде, адикай.

Сау бул инде, адикай ,
Ничек қайтып керем инде игә, адикай,
Син булмагач, иләмсез кала,
Ташлап киттең багытсыз,
Аwыр тупырагың җиңгел булсын,
Артын бәк булсын,

дип, тупырак сибәсен гүргә эч тапкыр.

Җирле сөйләшләрдә үлгән кешене искә алу мәҗлесләре һәм ул мәҗлесләргә әзерләнә торган ашамлыклар, аларның атамалары, борынгыдан килгән төрле ышанулар һәм ырымнар бик күп сакла---ган. Үлг әннәрне искә алу, мәҗлесләр үткәрү, аларга «өлеш», хәер бирүләр — барысы да үлгәннәрнең рухын канәгатьләндерү, исәннәр белән үлгәннәр арасында тыныч бәйләнеш булдыру теләгеннән чыгып эшләнгән. Мәсәлән, әстерхан өлкәсе татарларында «Үлене сыйлаганның — тересе дә ач булмас» дигән әйтем бар. Шулай итеп, үлгәннәрне искә алу — ул «теге дөнья» белән бәйләнештә тору дигән сүз. Борынгы төрки халыкларда үлгәннәрне искә алулар ел саен яз һәм көз айларында үткәрелә торган булган: «У древних тюрков погребально-поминальные церемонии приурочивались ко времени поздней осени или весны — «когда лист на деревьях и растениях начнет желтеть и опадать», или «когда цветы начнут развертываться» (Бичурин 1950: 230).

Рязань өлкә се Бастан авылы сөйләшеннән язып алынган мисал нәкъ менә шул турыда сөйли. Бу авылда искә алу мәҗлесен «җыйын» дип атыйлар.

— Җыйын көздә була. Берсе җаз башын (яз көне) була. Әби---бабайларны, ыру-кардашларны сагыну була. Җыл да кирәк җыйын итмә, табис чыгарып хатем укытма кирәк».

Керәшен авылларында «җафрак бәйрәме» көнне «үлеләрне кунак---ка чакыру» турында текстлар язып алынды:

— Җафрак бәйрәме җитте. «Әйдәгез, безгә қунаққа», — дип чакы---рып қайтабыз. Ипи илтәбез қаберенә, ипи илтеп қайтабыз.

«Нәсел-ырулар, барыгыз да қайтыгыз», — дип.

Май аенда барлык үлгәннәрне искә алу себернең тубыл сөйләшендә *цым* дип атала. Бу көнне өйдә пешеренәләр, изге догалар, қоръән укыталар, зиратка пешкән йомыркалар алып баралар. *Цым* — үлгән кешеләрнең рухын канәгатьләндерү, аларны зурлау йоласы. *Цым* — татар әдәби телендә *җим,* ягъни *җим > йим, чим, цым* (ц-лаштыручы сөйләштә). Үлгәннәрне, әрwахларны туендыру, ашату, аларның ру---хын олылап искә алуга кайтып кала. *Цымлылар* — соңгы бер ел эчендә үлгәннәр. Аларның каберенә «өй», ягъни бура ясап куела. *Цымқатым* — дини мәҗлес. — Цымта бөтен тоғомына тоға қылалар:

> Йетмеш тоғомына,
> пөтөн ыруwына,
> әбәсенә (апасына), әкәләренә (агаларына),
> тәтәләренә, пала-пакраға (бала-чагага),
> цицәләргә (аналарга), өннәмә (әбиемә),
> күрше-кунақларға,
> үле-тереләргә,
> ибенә ыруwына тоға қылатлар (туб.).

— Цымта йомортқаны пыйас қабықларға (суган кабыгына) буйап, балаларга өләшәтеләр.

Казан татарлары, мишәрләр мәет чыккан көнне өйдә аш-су куз---гатмыйлар, өч көнгә хәтле өйдә ашамыйлар, күршеләре яки туган---нары чакырып алалар. Ләкин татар халкының борынгылык саклан---ган кайбер төркемнәрендә, мәсәлән, перм, красноуфим, керәшен һәм себер татарларында мәет чыккан көнне корбанга хайван суеп («кан чыгарып»), аш мәҗлесе ясау йолалары сакланган. Гадәттә сарык яки кош-корт суйганнар, ул қорбаннық дип әйтелгән. Керәшеннәрдә дә қорбаннық суйу булган, ләкин дуңгыз суйу ярамый дигәннәр. Керәшен сөйләшеннән мисал:

— Үлгән көнне қорбанныққа сарық суйалар. Сул җагын салалар, уң җагы калып тора. Кәҗә җарамый, дуңгыз җарамый. Сүwәкләрен тутырып мазар эстенә алып китәләр (т.я.-крш.). Перм сөйләшеннән мисал: — Элек мәйетне җыйганда ук, үлгән көнне үк суйалар ыйы «*қорбаннық*» дип. «Ахирәткә бара ул *қорбаннық*», — диделәр. Красноуфим сөйләшендә: — *Үлгән туйы — қорбаннық* суйа, кабер казучы---ларны ашата. Себернең тубыл-иртыш диалектында *гүр қорманныгы*: Куцқар суйатлар үлгән көнне гүр қорманнық тип, қан цығаратлар. Сиратқа алып цыгып киткәнтә қасанға салып йийатылар пешергәле. Сират күперен кицкән wақыт куцқарға атланып, мейесенә йабышып цығып китә имеш (туб.).

Әстерхан сөйләшендә: җиргә төшкән көнне, ягъни кешене күмгән көнне куй суялар. — Җиргә төшкән көнне бабай түбәгә (зиратка) алып киткән халық өйгә килә. Қуй суйалар. Бабай түбәдән қайтқан ирләр кулларын йуwып утыралар, аш бирелә, ит. Қоръән уқыйлар, таралалар.

Үлгәннәрне искә алу көннәре өчесен, җидесен (керәшеннәрдә ту---гызын), кырыгын, бер елын үткәрү дип атала. Искә алу көннәренең гомуми атамалары да бар: *атау, түгем, түгем-чәчем* (керәшеннәрдә), *цым* (себер татарларында), *үле бар'амы* (мишәр диалектында), *түр, җыйын* (бастан), *үлдүкләр келәве* (м.кар.). Үлгән кешене искә алуны глазов сөйләшендә *йаз итү*, тау ягы керәшен, бастан

сөйләшләрендә *сагыну* дип әйтәләр. — «Барыгызның да алдында булсын», — дип, әби-бабамнарны йаз итәм, бийем-бийаталарны йаз итәм (глз.). — Җыл да үлгән көне дип сагынып алабыз. Мазар эстенә барып чакырабыз: «Беген сине чакырабыз, кат», — дип. Коймак пешерәбез.

Тук булсын, бакилләсен,
Кыйын — азап бирмәсен ,
Багытлы килеп, багытлы китсен,
Саулык бирсен,
Безнең кебек ул да тук булсын, — дип.

— Әби-бабайларны сагына, кан чыгарма кирәк. Каз суйа, кем куй да суйа. Үзенең радн'аларын (туганнарын), мосафирларны чакырып ашата. Кулҗаулыклар өләштермә кирәк (баст.).

Мишәр диалекты сөйләшләрендә *хатем, хатем аш*, себер диалектларында *қатым, қатым аш* — дини мәҗлес, үлгәннәрне искә алу мәҗлесе. *Хатем* — гарәп теленнән кергән, коръән уку дигән сүз. Хатем, қатым ашын үткәрүнең үзенең таләпләре, ырымнары бар:

— «аш-йес, май-йес» чыгару (туб.);
— қатым ашны тақ санда қуйалар (туб.);
— қатым ашны өстәп салу йарамайты (туб.);
— қатымға пирбай кергәндә шәрбәт су (баллы су) қуйалар, шуны аwыс итәләр:

«Үлеккә шунтай су насыйп итсен».

Үлгәннәрне искә алып өчесен, җидесен, кырыгын, бер елын үткәрү догалар укып багышлау һәм һәр якта кабул ителгән тиешле аш-сулар белән бара. *Өчесе, өч көне* (урт.д.), *өч киче, өч кичәсе* (миш.д.); *җидесе* (урт.д.), *зидесен күтәрү* (крш.), *җиде көнен уқу* (кас.) һ.б. Шулар ара---сында иң үзенчәлеклесе, тел һәм йола ягыннан аеруча борынгылык күренешләре сакланганы — *кырыгын үткәрү көне*. Кайсыбер төрки халыкларда, мәсәлән, хакасларда һәрбер искә алу көнен *кирек* (кы---рык?) дип атаганнар (Грачев 2010: 321), шулай ук искә алуларның санын *тугызга* тутырырга тырышканнар: «Согласно традициям, отмечали поминки на третий, седьмой (или девятый), двадцатый, сороковой, сотый (полгода) день и по истечении года. Есть сведения, что в XIX в. отмечали два года и три года, таким образом доведя количество поминальных дней до девяти ( Бутанаев 1988: 129). Искә алу мәҗлесләрендә *тугыз* санына аеруча игътибар итү Кемерово өлкәсендәге Кышлау (Зимник) авылы сөйләшендә сакланган. Әлеге авылның тел үзенчәлекләре том диалектының калмак сөйләшенә карый. Мисал: — Үле ашына сөртмәч бешерәтләр. Сөртмәчне май---да қазанда, йуқа ғына итеп бешерәтлә р дә туғыз җиргә туғызарны қуйғаннар. Ник туғызны бешергәннәр? Белмим.

Җирле сөйләшләрдә кырыгын үткәрү йоласының лексикасы һәм шул темага карата тупланган текстлар гаять зур этнолингвистик мәгълүматларны берләштерәләр. Мәсәлән, *кырыгына қырық күмәч пешерү* — себер диалектларында һәм керәшен сөйләшләрендә бар. — Қырығын үткәргәндә қырық күмәче була ә ркемгә (төм.). — Қырығына қырық күмәч пешерәләр. Шул қырық күмәчне қырық кешегә өләшәләр, килгән кешегә табаққа салалар:

Җомақлы булсын ,
Бәхилләп китсен, — дип *(каз.ар.-крш.)*.

Шулай ук *қырық гердә* — вак күмәч, *кырық перәннек* (крш.), *қырық қашық он* (крш.) һ.б. Тубыл-иртеш диалектының түбән сөйләшендә: *қырықбер күс кәпкер* — юка күзикмәк. Аны тишекле итеп пешерәләр (имеш, үлгән кешегә каберендә яктылык кереп торсын өчен). — Қырықбер күс кәпкер пешерәте үлгән көнне. Үлекнең ашы пулаты ул. Қырбаштан килгән кешеләргә пешерәтләр. Тақ кирәк.

Бер ел үткәч уздырыла торган дини мәҗлесләр: *йыл кичәсе* (лмб.), *йыл билгесе* (тмн.), *җыллық атау* (баст.), *йылтәүлек* (нокр.), *йыл ғораны* (әстр.), *бер йылы, зур хатем* (срг.), *йылтәүлек* (глз.), *йыл қатымы, йыл қатым -туwасы* (төм.) һ.б. Мәсәлән, төмән сөйләшендә: — Йыл қатымында қуй бәрән суйып, қатым-туwа үткәсәләр, қан цығаратылар, кешеләрне цағыратылар кергетәйләрне.

Аш-сыуларығысқа бәр әкәтләр бирсен,
Аш-сыуларығыс өстә л қашлартан өселмәсен,
Кыйәмәт көнен көтеп йатқан әрwахларыбысға
Бүләкләр булып барсын,
Рухлары шат булсын,
Бәндәчелек белән қылған гөнаһларын йарлықағыл, —

дип тоға қылабыс (төм.).

Үлгән кешене искә алу мәҗлесенә, дини мәҗлескә очраклы рәвештә, чакырылмыйча гына килеп керг ән кешене «тәңре кунагы» дип, сөенеп кабул итәләр: — Хатемдә бер курка (чүмеч) ашны артык салдыра. «Тәңре кунагы эчен булсын», — дип. Кошмасын (киезен) җәйә, идәнгә утыра хатемдә (мәл.).

Үлгәннәрне искә алып, алар рухына багышлап бирелә торган әйберләр: хәер, ашамлыклар, сөлге-тастымаллар һ.б. җирле сөйләшләрдә *өлеш* дип, *үлекләр өлеше* дип аталып йөртелә.

— Ашка-сыуга килгән кешеләргә йаулык та айыралар, ойоқ та бирәләр:

«Аның өлеше булсын», — дип (глз.).

Керәшеннәрдә «*мунча өлеше айыру*» — борынгыдан калган йола. Әле хәзерге чорда да «пуминка» көннәрендә мунча ягып, үлгәннәр өчен «өлеш салып чыгу», ягъни ташка су сибеп, «эссе салып чыгу» турында бик күп мәгълүматлар язып алынды.

— Мунчада үзебез жуwынғачын эссе салып чығабыз чыкканда:

Бар күршеләргә,
Нигез ийәләренә,
Җорт ийәләренә,
Үзебезнең үлгәннәргә,
Нәнәйләр, тәтәйләр,
Суғышта үлгәннәр —
«Әрберсе өлешле булсыннар»
Белгәне-белмәгәне,
Бездән көткәннәре —
«Барысы да өлешле булсыннар».

— Үлгәннәр өчен мунчада «өлеш айырабыз». Өлеш айырғач, мунчаға керергә җарамый, үзебез жуwынмыйбыз инде. Әйтеп чақырабыз:

«Без ничек чабынабыз,
Шулай чабыныгыз,
Җәшегез-қартығыз,
Бала-чағаларығыз,
Нәсел-ыруwыбыз,
Бөтенегез дә шушылай чабыныгыз», —

дип, себеркене, җомшакны, җапрақлыны қуйам (җүкәче).

«Аның өлеше, ахирәтлек өлеш » дип, пуминкада, ягъни искә алу мәҗлесендә махсус табак куеп, табакка ашамлыклардан өлеш салу барлык керәшен сөйләшләре өчен дә хас.

— Үлгән кешегә дип атап җасалған табақ була. Шул табаққа ба---рыннан да жыйалар «аның өлеше» дип. Аннары шуны бер ақ бүзгә төйнәп, қайыр итеп бирәләр.

И, туганнар, туғаннар,
Туғаннардан кемнәр туйғаннар.
Үз туғаннарыбыз килер дийеп
Күпме *өлеш* бүлеп қуйғаннар.

— Үле өчен дип т әлинкәсен дә, қашығын да қуйалар. Ул аны қайтып ашамый инде. Барыбер «аның өлеше, ахирәтлек өлеш» дип қуйалар. Ул ашамлықны суңынтын малға бирәсең.

Табаққа салам табикмәк
*Ахир әтлек өлеш*, дип.
Изге җаннар қуансыннар
Безгә шулай тийеш, дип (Җөри).

Гомумән, үлгәннә рне искә алуга әзерләнә торган аш-сулар, кор---банныклар, аларның атамалары, табынга бирүләр (так санда, тишек тишеп, сул ягын пешерү һ.б.) бик тирән борынгылыклар белән үрелеп барган, бүгенге көннәрдә дә алар әле сакланып киләләр. Шулай ук искә алуга караган дини мәҗлесләрдә укыла торган гарәп телендәге догалардан тыш, татар телендә, җирле үзенчәлекләре белән башкары---ла торган багышлау текстлары һәм ялварулы теләкләр бу хезмәттә, беренчеләрдән булып, фәнни әйләнешкә кертеләләр. Әлеге ярым рифмалашкан багышлаулар яки теләк текстларында һәр төбәкнең мифологик затлары да, дини-мифологик персонажлар да, туганлык, нә сел-ыру атамаларының бик борынгы катламнарына караган лексика да фәнни яктан зур игътибарга, махсус өйрәнелүгә лаек. Мәсәлән, Волгоград өлкәсендә Лятошинка (Йеруслан) авылында язып алынган «дога багышлау»дан өзек китерәбез:

Рухларыгызның рухлары шат булсын, йарабби,
Мәрхүм булган әни кәбәсенең рухы шат булсын,

Кабере нурлы булсын ,
Бакый иманы йулдаш булсын,
Йатыр урыннары җәннәттә булсын,
Мәрхүм эти кәбәсенең,
Бер тума кардәшләренең
Кан' эткәләренең,
Кан' әнкәләренең,
Кан' быратларының,
Кан' бабаларыгызның,
Кан' әбиләрегезнең,
Тума-тумачиларның,
Тудык-тудыкаларның,
Кода-кодагиларның,
Барчасының рухлары шат булсын,
Йатыр урыннары җәннәттә булсын.

Шулай итеп, соңгы юлга озату йолалары дигәндә, без бер мәет җирләүне генә түгел, ә тулаем бер катлаулы циклны күз алдында то---табыз.

Бу хезмәтне эшләгәндә түбәндәге максатлар күз алдында тотылды:

— татар халкы яшәгән барлык төбәкләрдән, бигрәк тә ерактагы архаик зоналардан (себер, әстерхан, урал, нократ, мишәр диалекты һ.б. сөйләшләрдән) берничә дистә еллар дәвамында җыйналган экспедиция материалларын да кертеп, соңгы юлга озату һәм искә алу, аш---сулар, дини терминология тел, фольклор һәм этнография синтезында чагылдырылды;

— сүзләрне, терминнарны ачыклау, аңлату, йолалар турында мөмкин кадәр күбрәк мәгълүмат бирү өчен, авыллардагы йола белгеч---ләреннән һәм тел осталарыннан язып алынган сөйләш үрнәкләре, халыкның хәтерендә сакланып калган борынгы йолалар, гореф-гадәтләр турындагы истәлекләр җирле сөйләшләрдә ничек булса, шул көенчә, үзгәртелмәгән хәлдә, бернәрсә дә өстәлмичә язылды, ягъни йолалар һәм йола сүзләре җирле сөйләшләр һәм фольклор текстлары яссылыгында күтәрелде;

— материалларның қайсы төбәктән язып алынганлыгы төгәл адреслары белән күрсәтеп барылды, ягъни географик таралыш аре---аллары билгеләнде;

— йолаларга караган терминология һәм иллюстратив материал итеп китерелгән сөйләү үрнәкләре һәм фольклор материаллары, эчтәлекләре ягыннан берләштерелеп, тематик төркемнәргә тупланды, семантик «оялар» мөмкин кадәр тулырак, җентеклерәк тезеп бирелде.

## Транскрипция

Җирле сөйләш үзенчәлекләрен чагылдыру өчен гамәлдәге татар алфавиты нигезендә гадиләштереп төзелгән транскрипция кулланылды, өстәмә билгеләрдән түбәндәгеләр файдаланылды:

‘ — хәмзә, бугазда ясала торган йомык аваз;

*ʹ* — тартык авазларның йомшартылуын белдерә;

*w* — ирен-ирен өрелмәле тартык аваз билгесе;

*d* — әдәби телдәге «з»ны алмаштырып килә торган тел-теш арасы авазы, «сакау» *з* билгесе;

*қ- ғ* — тирән тел арты тартыклары;

*я, ю, е* хәрефләре урынына *йа, йә, йу, йү, йы, йе* билгеләре алынды.

## КЕШЕ ҮЛЕМ ХӘЛЕНДӘ БУЛГАНДА БАШКАРЫЛА ТОРГАН ЙОЛАЛАР

### Йасин уқу, йасин чығу

**Йасин, җасин** [< гар.] ясин, Коръәндәге сүрә исеме (36 нчы сүрәсе).

Ул гарәп алфавитындагы «й» һәм «с» хәрефләренең исемнәре. «Ясин» сүрә сен юлга чыгар алдыннан да, үлем түшәгендә яткан кешенең баш очында да, мәет өстендә дә укыйлар.

### Йасин уқу

— Йасин уқыдың исә үлем ғазабы җиңеләйә ди — *каз. ар.-блт.*

— Йасин укыдылар исә йәне тиз чығар ди — *перм*.

— Мәйетне жуа башлағач жиде қарчық жасин уқыйлар, шунарға жиде қарчыққа жиде баш жаулығы бирәләр — *т.я.-к.т*.

### Йасин чыгу

— Үлте — мулла корткайак йасин чыга — *туб*.

### Қырық йасин, қырықбер йасин чығу

— Үлгәннән сун қырықбер йасин чығатылар. Қырық йасин чығып, қырықберенцесен өй қучасына барып уғығалы. Өй қучасы төрле тәғамнәр әсерлите, қортқайақлар чақыраты. Қырығынаца қырық йа---син, қырық беренце йасинны уғыйтылар. Қырығына тағы башқа айәт тә уқыйлар — *төм*.

— Мин қырықбер йасин уқыйм қырықбер көн буйына. Қырығына хәтле уқыйм йасинны. Қырық беренче көнне бағышлыйм — *бәр*.

### Тим салу

**Тим салу** *төм*. кеше үлем хәлендә булганда ясин догасын укыту.

— Инәң үлә, *тим* салтырайык, мулланы алып киләйек, ти. Парып мулланы алып килтем, тим салтыртым. Тим салып алғацын сақлаң, көтең, тиде. Тим салғанта биш-алты битле китабы, уқыйты муллабыс.

## ҮЛЕМ ХӘЛЕ
## ӘҖӘЛ, АРУ ҮЛЕМ, ӨЗЕЛҮ, КИЧЕЛҮ, WАФАТ БУЛУ

### Әҗәл, үлем

**Әҗәл** [< гар.] — үлем.

Ашайақ тәғамың бетсә,
Кийәйәк кийемең бетсә,
Менә *әҗәлең* житә,
Ғомере бетеп китә, wафат буласың инде — *әстр*.

**Әҗәл** сүзе XIII йөз язма истәлеге «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (1983, 78):

Һәмандәм ул заһидә *әҗәл* ирди, —
Йусеф андә қайғулу қалыр имди.

Шул вакытта ул заһидка әҗәл килде, —
Йосыф аннан зур хәсрәткә төшәр имди.

**Әҗәл wақыты** — үлү вакыты.

Үлем безгә күренеп килми,
Дәхи алдан хәбәр бирми.
*Әҗәл* wақыты килеп җитсә,
Үлемдин һич қотылып булмый.
(Мөнәҗәтләр, 29)

**Әҗәл қастасы** [< гар.] — әҗәл авыруы.

Әгәр килсә *әҗәл* қастасы,
Ачық булсын җәннәт қапқасы — *каз.ар*.
— Әҗәл кастасы тигән булса имчегә баралар,
қайсы имче терелтә кешене — *т.кам.-крш*.

### Әҗәл җиле

Әҗәл җиле — исә торыр
Wақыты җиткәч — күчә торыр (мөнәҗәттән).

## Әҗәл шәрабы

Әҗәл шәрабын
Без бер эчәрбез.
Йакты дөнйадан
Бер көн күчәрбез (мөнәҗәттән).

## Әсәл

**Әсәл** [< гар.] *себ.* әҗәл, үлем.
Әсәлләрең йеңел булсын,
Әсәл wақытларың йетсә,
Үтеп китү йеңел булсын,
Урыннарың тыныц булсын — *төм.* (Каскара).

## Әзәл

**Әзәл** [< гар.] *миш.д.* әҗәл, үлем.
Сулышым бетәр,
Әзәлем йитәр.
Йасин укырга
Wакытлар йитәр — *тмн.*

## Армастан үлү

**Армастан үлү** *әстр.* яшьләй, картаймыйча үлү.
— Армастан үлгән кешене озатқанда бик такмақлап җылайлар (Кызан).

## Ару үлем, мордар үлем

**Ару үлем** *хвл.* хәвефсез, кадерле булып, вакыт җитеп үлү.
— Ару үлем, ак кифен (әйтем).
**Мордар үлем** *каз.ар.* үзен-үзе үтерү турында әйтелә.
— Мордар үлемгә теге дөнйада сорау қаты була ди (Биктәш).
**Шаит** [< гар.] **үлем** *себ.* вакытсыз, хәвеф-хәтәргә очрап үлү.
— Шаит үлем тиделәр суға гитеп үлгәнне. Сорау йуқ теге төнйада тиделәр — *тара* (Тускимә).

## Үлем ачысы, үлем уғы

Йул буйындагы печәнне
Йулаучы аты ашый.
Дөнйа ачысы ачы түгел
Үлем ачысы бик ачы — *т.я.-к.т.* (күкшем).

Үлем ачысы шундый агу
Берәү дә татымый калмас.
Үлем уғын атар туры
Берәү дә котыла алмас — *каз.ар.* (Уразбахтино).

## Үлем, фирак

**Фирак, фираклык** [< гар.] — аерылышу.
Қызыл гөл булмаса идее
Чәчелеп тормаса иде.
Бере — үлем, бере — фирак,

Икесе булмаса иде — *каз.ар*.

Су буйына төшкән идем
Йар буйлары куwак кына.
Кадерләреп белеп йәшик
Без дөнйада кунак кына.

Әр кешегә үлем килә
Килгән кебек караңгы төн.
Йакты дөнйа бәйрәм булып
Кала бер көн, кала бер көн (Чүпрәле районы, Теке авылы).

### Өзелү

**Өзелү** *каз.ар*. үлү.

— Йақын туғаным өзелде дип хәбәр җибәрделә р. Кичтән өзелә икән бәндә, төннең буйы сақлап утыралар. Иртәгесен кешеләр җыйылып, җуып, күмәргә әзерлиләр (Салавыч).

### Wафат булу

**Wафат** [< гар.] — үлем.

**Wафат булу** — үлү.

— Аллаhы тәғаләнең үлчәп биргән ғомере бетеп китә, wафат буласың — *әстр*. (Кызан).

### Җан бирү, җан тәслим қылу

**Җан** [< гар.] **бирү** — үлү.

**Җаны чығу**:

— Кешенең җаны чығу белән таба исе чығарабыз — *т.кам-крш*. (Ләке).

— Җан бирүwе бик аwыр. Җан чыккач, әдәмне шул урында тота---быз азрак.

— Киблага каратып икенце урынга күцерәбез, йал иттерәбез, өстөнә царшау корабыз — *чпр*. (Каракитә).

### Йән бирү

**Йән бирү** *себ*. җан бирү, үлү.

**Кеше йән бирәлми изаланса** [ырым]:

— Йән бирәлми изаланса қурас[1] суйатылар, ченаса[2] уқытатлар. Ул кеше әйбәт кенә үлеп китәт. Қурас суйып муллаға биреләте. Тисерәк асаптан қотқарғылары килсә, алай итәтләр — *төм*. (Ямбай).

### Кичелү, киченү

**Кичелү, киченү** *әстр., влгг*. үлү, вафат булу.

— Кеше кичелде дип йақын-йуwықлары киләде башынсауға — *әстр*.

— Қодағайыбыз киченде. Икенче қодағайыбыз уқыды йоқламай утырып — *әстр*.

[1] *Қурас* — әтәч.
[2] *Ченаса* — җеназа.

— Ирем киченде, ыруларын җазмаға кирәк қылпыташқа[1] — *әстр*.

— Кеше кичелгәндә күп киләләр, алай олылап озаталар — *әстр*. (Кундрау).

**Волгоград сөйләшендә**:

— «Карале, кызы корчак кебек матур, әмән[2] кукла», — дигәннәр. Иртә белән зәрә йактырды[3], хазер бала кичелә. Күз тигән. «Эстәл латламагыз[4], кичелде бала», — диделәр — *влгг*. (чапурник).

### Күзе ачык китү

**Күзе ачык киту** *әстр.* үлгән кеше үзенең якын кешесен күрә ал---мыйча үлеп китсә әйтелә.

— Кеше үзенең йақын күргән кешесен көтеп йата икән үлә алмый.

«*Күзе ачық китте* » диләр, әгәр дә үзенең бер йаратқан кешесе қайта алмаса, күрми китсә шуны. Қайнанамның энесе ике хатын алған иде, ул утырды қайнанамның йанында. «Қайнанам күзен ача да йома, ача да йома», — диде, «кемнедер көтә», — диде. Менә шул үле үзенең йаратқан кешесен көтә икән. Аны күрә алмаса күзе ачық китә икән.

«*И, күзең ачык киткере*» дип қарғағанны ишеткәнем бар минем (Картузан).

### Бәхил, бәхилләү

**Бәхил** [< гар.], **бәхилләү** < бәхил + -ләү гафу итү, кичерү.

*Барчагыз бәхил булыгыз,*
*Мин китәмен йыракка.*
*Барып қоръәннәр укыгыз,*
*Мине күмгән зиратка.*

Зинһар әйтәм, туғаннарым,
Бәхил булып миннән қалығыз.
Алып барып гүргә иңдергәч тә,
Тәһлил әйтеп туфрақ салығыз.

[1] *Қылпыташ* — кабер ташы.
[2] *Әмән* — кебек.
[3] *Зәрә йактыру* — таң ату.
[4] *Латлау* < рус. лад + лау — әзерләү.

**Бакил** *чст.-крш.* бәхил.

— Бакил, бакил, Ибан күршем, китәсең бит, без мәңге бакил, син дә безне бакиллә (Кәләй).

### Мәрхүм, мәрхүмә

**Мәрхүм, мәрхүмә, әлмәрхүм** [< гар.] — вафат булган, үлгән кешеләргә карата әйтелә торган әдәп сүзләре.

— Мәрхүм, мәрхүмәләр рухына багышлап та корбан чалдыр---дым — *влгг.* (Лятошинка).

## КЕШЕ ҮЛГӘЧ БАШКАРЫЛА ТОРГАН ЙОЛАЛАР

### Қыйблаға борып қуйу

**Қыйбла** [< гар.] — көньяк.

Жаным чыкса, т әнем суынса
Борып салыгыз, қыйблаға таба...
(Мөнәҗәтләр, 36).

— Мәйетне иңгелек қыйблаға таба қаратып салабыз, күзен йомды---рабыз.

Кеше қыйблаға таба қарап, ике тапқыр айағын сузып йата икән:

берсе — исем қушқанда,
берсе — үлгәч.

Ул инде үле туйы, соңғы туй була — *бәр.*

**Көзгене каплау**:

— Кеше үлгәч, *көзгене каплилар*, сын тотарга йарами мәйет күмгән чагында. Йәшендереп куйалар көзгеләрне — *мәл.* (Калда).

## ТӨН САКЛАУ, ТӨН САКЛАУЧЫЛАР

### Қараwыллау, қараулау

**Мәйет қараулау** *к.-уф.* мәет саклау.

— Мәйет қараулағанда мин мөнәҗәтләр әйтәм.

**Қараулаған кеше** *к.-уф.* мәет янында төн саклап утырган кеше.

— *Қараулаған кешеләргә* дә йаулықлар тараталар. Алар төннең буйына утыра қый йоқламый. Шулай *қараулыйбыз* кеше үлсә.

— Кеше үлгәс мәйетне ташлап сықмыйсың, сүрәләй қараwыллап утырабыз. *Қараулаған кешегә* тастымал, сабын тараталар.

— Менә мәйетне *қараулаған кешеләр* қайсы-берсе кеше сүләп уты---ралар. Ә мин менә ике қолағыма мамық тығып барамын. Сүләнәләр, әйтәм, мин саңғыраумын. Нийә ишетмисеңме? Мин тыңлап та утыр---мыймын кеше сүләгәнен. Тыңлап қына утырсаң да барыбер кеше сүләгән кебексең. Алар үлгән кешене дә сүлиләр. Үлгән кешене бигерәк тә сүләргә йарамый, бик зур гөнаһ икән. Тик сүләнеп утыр---сыннар димен, тыңламыйм берсен дә (Ләмте).

### Мәйет қараwыллау

**Мәйет қараwыллау** *перм*. мәет саклау.

— Мәйет қараwыллағанда алмаш-тилмәш утыралар. Берсе қайта, икенчесе килә.

### Сөйәк қараwыллау, үлек сақлау

**Сөйәк қараwыллау** *себ.* үлгән кеше янында төн саклап утыру.

— Сөйәк қараwыллап утыру саwаплы. Мәйетне йалғыс қалдыру йарамас, үлек сақлау була.

### Мәйет көткәле бару

**Мәйет көткәле бару** *бараба*. үлгән кеше янында утырып төн үткәрергә бару.

— Мәйет көткәле Қошкүл аwылына китептеләр (Тармакүл).

### Көзәт

**Көзәт** *әстр*. үлгән кеше янында төн утыру.

— *Көзәт* булат, *көзәтеп* утыратлар кеше үлгәндә. *Көзәткә* жақын---жуwығы, қуншылары[1] киләде. Көзәттә коран уқып утырмак тийәм (Кундрау).

### Көзәткә килгәннәр

**Көзәткә килгәннәр** *әстр*. үлгән кеше янында утырып төн саклау---чылар.

— Көзәткә килгәннәр жаҫ тығын салып көрпәгә утырады. Жоқламаға тийеш түгел. Көзәткә жақын-жуwығы киләде (Кундрау).

### Көзәтү

**Көзәтү** *әстр*. үлем хәлендә булган кеше янында утыру.

— Қайнанам аурап йатты. Қәйнесе, үзенең энесе-нәғаше, минем ирем, өч ир утырып *көзәттеләр*, уқыдылар. Жиде көн йатты үлә ал---мый, хәлсез йатты (Сәетләр).

### Мәйет саклау, төн саклау

**Мәйет сақлау, төн сақлау** *урт.д.* үлгән кеше янында утырып төн үткәрү.

— Таң атқанчы утырабыз, *сақлыйбыз мәйетне*. Йаулық тараталар сақлаучыларға.

— Әби-сәбиләр *мәйетне сақлап* салаwат әйтеп утыралар. *Төн сақламаға* барам, диләр, икенче ызбаға чығып ашыйлар.

— *Сақламаға* киләләр әбиләр, күпме әби бар, барысы да жыйыла. Үксез-үрәчә[2] килә инде, китаплар уқыйлар, тыңлап утыралар. Таң атқанчы утырабыз мәйетне сақлап — *перм*.

[1] *Қуншы* — күрше.
[2] *Үксез-үрәчә* — ялгыз, ятим.

— Мәйет сақлаганда қоръән уқымыйбыз. Мәйет әле йуылмаган була. Анда тәһлил әйтәләр, китап уқыйлар, мөнәжәтләр әйтәләр.

Олуғланма дөнйаның байлығына,
Горурланма йөзеңнең айлығына.
Дөнйа малы бетә торған қырау тик,
Қарыйлықлар[1] киләдер йөгереп ат тик.

— Мәйет өстендә, мәйет сақлағанда мөнәжәтләр уқыйбыз.

Қартлар килерләр,
Сәләм бирерләр.
Қабереӊ нурлы
Булсын дийерләр.

— **Мәйет сақларға** бик түзем кешеләр киләләр. Китап сөйләп уты---ралар мәйет сақлағанда. Төнге сәғәт уникегә хәтле утырған кешеләргә, төн сақлап утыручыларға йә йаулық, йә тастымал бирәләр. Шул уты---рып қалғалларға йаулық бирәсен төн уртасы узғачыннан.

Шулай **төн сақлыйбыз**. Күрше-күбәләр[2], туған-тумачалар жыйыла төн сақламаға. Алар тәсбих тартып утыралар төн буйынча — *бәр*. (Портянур).

## Мәйет кичләү

**Мәйет кичләү** *перм*. мәет янында утырып төн саклау.

— Мәйет кичләү дип әйтәбез, сықташма[3] йарамый мәйет кичләгәндә. Намазлы-нийазлы кешеләр утыралар күберәк (Сараш).

## Төн кичү, төн кицү

**Төн кичү** *т.я.-к.т*. мәет янында утырып, догалар укып төн үткәрү.

— «Төн кичәргә килегез әле», — дип чақыралар. Анда тәһлил чығып утырырға кирәк (Турай).

**Төн кицү** *чпр*. мәет янында утырып, догалар укып төн үткәрү.

— Төн кицкәндә тәһлил укып утырабыз. Тәһлил укып утырганда кәфенен дә йүлибез.

## Төн саклау

**Төн сақлау** *урт.д*. үлгән кешенеӊ өенә жыелып, догалар укып, мөнәжәтләр әйтеп утыру.

— *Төн сақларға* килү зур саwап диләр, мәйетне йалғыз қалдырырға йарамый, диләр.

[1] *Қарыйлық* — картлык.
[2] *Күрше-күбәләр* — күрше-тирәләр.
[3] *Сықташма* — еларга.

## Төнге саклау

**Төнге саклау** *каз.ар.-мам*. мәет булган өйдә утыру.

— Төнге саклау дип тәсбих тартып утырабыз. Чәй аппаралар:
«Бөртеге сайын саwап», — дип.

## Төн утыру

**Төн утыру** *глз*. төн үткәрү, мәет булган өйдә утыру.

— Төн утыру бар. Менә минем әни үлгәчен сәгәт икегә кәдәрле утыргаладылар. Элек йаман кунма калалар иде карчыклар. Йедесенә кадарлы үлек чыккан өйдә кунып йөриләр иде. Қәзер алай йук.

— Кич утырма барабыз үлекне заткачтын. Өч, йә биш көн утыра---быз. Үлек артыннан алай утырма йөриләр. Үлек киткәчтен моңгайыч кала ич инде өйләре (Кистем).

### Төн утыручылар

**Төн утыручылар** *глз*. үлгән кеше янында төн уздырып, бергә җыелып догалар укып утыручы, мәет саклаучылар.

— Төн утырма хәрендәш-йәwерне[1] чакыра. *Төн утыручылар* йокла---мый инде, утырып чыгалар, үле эстендә укый торган мөнәҗәтләрне укыйлар. Үле өстендә мөхәммәдийә укыйлар бездә.

— *Төн утыручылар* укып утыралар мөнәҗәт. Йылайбыз, тынна---шып утырабыз (Кистем).

### Төн утыручылар, төннә утыруцылар

**Төн утыручылар** *себ*. үлгән кеше янында догалар укып, мәет са---клап төн уздыручылар.

— Төн утыручылар киләте, үлек сақлау була.

— Пицәләр[2] утыратылар. Айәт әйтеп қуйатылар төннә утыруцы---лар үлек йанында утырғанда:

Тар қабере — киң булсын,
Йатқан урыны — йомошақ булсын,
Очмақта булсын, —

тип теләп утыралар төннә утыруцылар, қортқайақлар[3], пицәләр.

[1] *Хәрендәш-йәwер* — нәсел-ыру.
[2] *Пицә* — хатын.
[3] *Қортқайақ* — карчык.

Төннә утыруцыларға йаулықлар қуйатлар — *туб*.

### Төнәү, төнәткәле бару

**Төнәү** *себ*. төн үткәрү, мәет саклау.

— Мәйет йанына утырыға йөрибес, төнибес.

**Төнәткәле бару** *себ*. төн сакларга бару.

— Үлгән көнне қөрмәтләп қундырабыс, өстенә қайцы салабыс, ки---тап.

— Төнәткәле баралар, қортқайақлар уқынып утыралар. Үwендә[1] йидергән[2] йоқ.

### Төнәп утырған қортқайақлар

**Төнәп утырған қортқайақлар** *төм*. мәет янында төн саклап утырган карчыклар.

— Төнәп утырған қортқайақларның қайсы сықтап[3] алаты:

Сәғр әләрдә үскән чәчкәләр
Паш ийәләр, wақыт үтте, тип.
Мин тә уйлыйм, йақты төнйаларны
Ташлап китәр wақыт йетте, тип — *төм*. (Каскара).

### Төнәтү, төннәтү

**Төнәтү, төннәтү** *әстр., влгг., срг*. төн саклау, мәйет янында утыру.

— Төнгә қалса *төнәтәләр*. Ир кеше үлсә ир қардәшләре килеп *төнәтәләр*, қатын-қыз үлсә қатыннар *төнәтәләр*. Кичелде диләр.

— Иркәкләр[4] үлсә иркәкләр *төннәтә*, қысқайақлар[5] үлсә кимперләр[6], қортқалар[7] *төннәтә*.

[1] *Үwендә* — өендә.
[2] *Йидергән* — ашаткан.
[3] *Сықтап* — елап.
[4] *Иркәк* — ир.
[5] *Қысқайақ* — хатын-кыз.
[6] *Кимпер* — хатын.
[7] *Қортқа* — карчык.

— Кеше үлгәч, җыйылғанчы бөтен аwыл килә, йәшләр, қартлар, барысы да килеп тәсбихләр белән утыралар. Йақыннары *төнәтеп* утыралар, йоқламыйча. Үле киткәнче тәсбих тартып, тәһлилләрен бағышлап җибәрәләр. Үеләрне қадерлиләр бездә — *әстр.*

— Кемнәр **төннәтә**, төн йоқламый утыралар, шуларга бирәләр та---стымаллар, сабыннар, чолкалар — *влгг.*

— **Төнәтү** диләр. Алар укып куналар. Башкалары тыңлап тора---лар — *срг.*
— Төнәтергә барабыз. Төн ката укибыз, тәлил тартабыз. Атына ки---леп алалар. Үле турысында мөнәҗәтләр әтәбез — *чпр.*

## Төнәтүчеләр

**Төнәтүчеләр** *урт.д.* мәет саклап төн уздыручылар.
— Төнәткәндә төн буйы утырып йоқламыйча төнәтәләр. Төнәткәндә күрше-тирәләре чақыралар чәйгә. Төнәтүчеләрне зурлыйлар — *минз.*

## Төнге теләү

**Төнге теләү** *каз.ар.-крш.* мәет саклап төн уздыру.
— Кеше үлгәч төнге теләү дип әйтәбез. Анда бер кеше кенәгә[1] уқый, без «амин» дип әйтәбез, үзебез белгәннәрне җырлап уқыйбыз.

— Үлгәннәр кенәгәсенә қарап та уқыйбыз. Шулай җыйылышып, әбиләр иман уқып утыралар. Аларға әйбер өләшәләр, җаулықлар, са---быннар. Биргән бүләкләре өчен аларға да уқыйбыз:
«Үлгән кешенең җазықлары кичерелсен,
И, қодай,
Қалқымны сақла,
Җортома бәрәкәт бир,
И, қодай, җарлықа!» (Чура).

## Сақлап утыручылар

**Сақлап утыручылар** *каз.ар.-крш.* үлгән кеше янында утырып төн уздыручылар.

[1] *Кенәгә* — дини китап.

— Иман уқып сақлап утыралар. Бик ололап озаталар бездә үлене. Сақлап утыручыларға хәйер итеп йаулық, тастымал өләшәләр.
Мин әйтәм:
«Бу үлгән кешенең җазықлары кичерелсен,
биргән бүләкләре буш қалмасын.
И, қотқаручы,
И, кеше сөйүче, и қодай!
Сине олылыйбыз.
И, қодай, җарлықа, бәқиллә!
Җирдәге дәүләтеңә тау итәбез,
Күктәге дәүләтеңнән дә безне буш қалдырма! —

дип теләп утырам (Дорга).

**Сақлап қунучылар, төн кичүчеләр**

**Сақлап қунучы, төн кичүче** *т.я.-к.т.* мәет янында утырып төн үткәрүчеләр.
— Сақлап қунучылар була. Аларга җаулық, сөлге, йә сарфиткә бирәсең.

— **Төн** кичәргә чақырмыйчы да киләләр. Үзебез дә чақырабыз: «Төн кичәргә килегез әле» дип. Төн кичүчеләргә, тәһлил чыгып утыручы---ларга сәдәхә өләшәбез, берәр җаулық бирәбез — *т.я.-к.т.* (Турай).

**Кунарга бару**

**Кунарга бару** *м.-кар.* мәет янында төн үткәрергә бару.
— Кеше үлгәч кунарга барабыз җанына, силәшеп утырабыз.

**Башынсау, башынсауға килү**

**Башынсау** < башын + сау — әстерхан сөйләшендә кулланыла тор---ган сүз.
**Башынсауга килү** *әстр.* кеше үлгәч аның өенә килеп, туганнарының хәлен белеп, теләкләр әйтеп китү.
— Үлгән кешенең өйенә бөтен аwыл кешесе ақча төреп, нийаз (хәер) төреп башынсауға киләде. Қәрдәш-туғаннары җиде көн утырады, шул аwыл халқының килгәнен көтеп утырады. Ул инде башынсауға килү булады.

«Башын сау булсын,
арты хәйерле булсын,
қалғаннарға хәйерле сәламәтлек бир», —

дип әйтеп чығар өчен җиде көнгә хәтле йөри иде аwыл халқы.
Җиде көнгә хәтле килә алмаса, қырқында киләләр башын сау итеп. Бездә мәйет қадерле.

— «Башынсауға барып килийек» дип баралар. Бездә җиде көнгә қадәрле киләләр башынсауға. Туған-қардәш кенә түгел, бөтен аwыл барады башынсауға.
«Башын сау булсын, қалғаннарға саулық бирсен», — дип әйтәсең.
— Мәйеткә бөтен аwыл килә, башынсауға киләләр. Чақырмыйлар да, үзләре килә. Келдермештә дә, Қанғада да, Биштүбәдә дә баш---сау булсынға бөтен аwыл кешесе килә. Килгәндә қоры килми, чәй, кәнфит, пичинйә алып килә.

— Бөтен туған-хәрдәшләре киләде җидесенә хәдәрле. Йегермеләп булады, йегерме бишләп булады, кемдә туған күп, барысы да киләделәр. Җидесенә хәдәрле бөтен аwыл килеп бетәде инде. Туған---хәрдәшләре барысы да «синен башын сауға» дип киләделәр. Килгәндә йылашалар, китәләр. Җидесенә кеше күп чақырылды, җиде коранын уқыталар.

Башынсау итеп киләбез:
«Башың сау булсын,
Алдың үзенә йарасын,
Артың безгә йарасын,
Балаларға туй булсын,
Алланың рәхмәтендә булсын», — дип әйтәбез. — *әстр.*

**Үлек өсте**

**Үлек өсте** *глз.* мәет яны; үлгән кеше яткан урын.
— Үлек өстөләрдә йаман моно йырлайлар иде:

Бер кодайым сезгә бирсен,
Пәйгамбәрләр сабырлыгын...

## Үлегә бару

**Үлегә бару** *глз*. үлгән кешене озатырга бару.

— Тумак бар, үлмәк бар. Кеше үлгәч, үлегә барганда нидә булл---са илтәсин. Күммәстән алда андай гадат, илтеп баралар ризыклар (Иманай).

## Өстенә керү

**Өстенә керү** *әстр*. мәет булган өйгә керү, озатырга булышу.

— Өстенә кергән кешегә күләк алып бирәделәр, матасын бирәсен.

— Өстенә керергә әйтәсең, йуарға инде. Биш кеше йуа. Қайсы кеше үзе әйтеп қалдыра, өстемә керергә монарға әйтерсең, монарға әйтерсең, дип.

## Өстенә кергәннәр

**Өстенә кергәннәр** *әстр*. мәетне озатырга кергән кешеләр.

— Өстенә кергәннәргә, йуwындырма кергәннәргә ақ башйаулық. Мийешенә[1] йегерме маниттан ақча салып бирделәр.

## Өстенә йаба торған әйбер

**Өстенә йаба торган әйбер** *әстр*. үлгән кеше өчен хәер итеп китерелә торган әйбер, яулык яки тукыма һ.б. Ул әйберне үлгән кешенең өстенә куеп алалар.

— Үлгән көнне туталары, йақын қардәшләре өстенә йаба тоған әйбер китерәт бездә: күлмәк, мата китерә (Кундрау).

## Өстенә салу

**Өстенә салу** *әстр*. үлгән кешенең өстенә яулык яки сөлге кую.

— Икенче көнне аwыл халқы киләде. Өстенә қуйадлар *йаулықмы*, *тәрәт йаулықмы*[2] *салалар*. Күтәрәләр, йуwалар, арулыйлар, хәләмпер сибәләр. Күтәреп чығаралар балалары, қызлары, киленнәре.

[1] *Мийеш* — почмак.
[2] *Тәрәт йаулық* — сөлге.

[Тыем: үлгән кеше өстенә күк төсле әйбер салырга ярамый, дигәннәр]:

— Үлгән кешенең өстенә сала торған булғаннар матамы[1], йаулықмы. «Қук төсле мата салырға йарамый» дип әйтә торған булғаннар, күк читле йаулық булмасын. Шуннан да балаларға күк йүтәл була, аwырлық була дип әйткәннәр (Ямәле).

## Мәйет өстенә тимер әйбер қуйу:

— Мәйетнең өстенә қазақмы, қайсымы қуйаң, тимер әйбер. Қалыққан җиргә, күкерәк аwызына қуйаң бисмилла әйтеп — *к.-уф*.

## Йабу йабу

**Йабу йабу** *әстр*. мәет өстенә кием ябу.

— Йуwалар да өстенә җиде кийем йабалар, *йабу йабалар*, йә бишне йабалар. *Җиде йабу* йабалар. Улы, қызы, абасымы[2], сеңлесеме, йақын кешеләренекен. Өйдән чығарайақтан алда йабу йабалар, җеназа уқыр алдыннан.

— Үлгән кешенең өстенә йапқанда биш, җиде, туғыз қат *кийем йа---бадылар*.

— Үлгән көнне туталары, йақын қардәшләре *өстенә йаба тоған әйбер китерәт бездә. Күлмәк, мата китерә*.

— Йаулык, сабын экитә мәйет өстенә. Йаулык эченә сабын, акча куйа. Тәсбих тарта, тәһлил әйтеп утыра.

### Йөзенә йабарга илтү

**Йөзенә йабарга илтү** *срг.* үлгән кешене озатырга барганда сөлге, яулык һ.б. әйберләр алып бару.

— Бездә беркем дә калмый, мәйет өстенә барган кеше буж бармый, йөзенә йабарга илтә тастымал, йаулык.

[1] *Мата* — тукыма.
[2] *Абасы* — апасы.

### Үдер, үдергә бару

**Үдергә бару** *срг.* үлгән кеше белән хушлашырга, озатырга бару; төн саклап утыру.

— Үдергә барабыз. Үдердә тәлил тартабыз, садака илтәсең, сөлгеме анда. Мәйетне йуwындырып ченазага салып цыгаргац, мулла барлык тәлилләрне багышлый бергә. Әллә кайлардан да киләләр үдергә.

— Үдергә бару соңгы йулга озату, хушлашу була. Төн кунабыз, дисбе тартып утырабыз төн ката.

— Үдергә цакырмыйца йөриләр. Йийылалар кеше үлсә. Үдергә ба---рабыз дийеп йардам итәргә баралар. Үдергә кем нәрсә китерә. Күбесе сөлгеләр, ир күлмәкләре, садакалар куйалар.

— Үдергә тәлилгә барабыз. Садака алып киләбез, төн ката[1] уты---рабыз. Мин йоклами идем. Кас'ы кеше йоклап, каталап китә[2] тәлил тартканда. Көнсәтә[3] дә утыралар, төн ката[4] да — *срг.*

— Үдергә бер кеше дә бушлый килми, садака алып киләләр. Күлмәк, йә ситсылата китерәләр, сөлгеләр, йаулыклар китерәләр — *срг.* (Чембили).

### Кенәгә укып утыру

**Кенәгә укып утыру** *каз.ар.-крш.* мәет булган өйдә христиан дине китапларын укып утыру.

— Кеше үлгәчен жуwабыз, кийендерәбез, гырупка салабыз. Кенәгә укып утырабыз. Пысалтар кенәгәсе укып утырабыз. Ул кенәгәне кырыгына хәтле укырга кушалар.

### Книжник

**Книжник** *м.-кар.* дини китаплар укучы.

— Книжник булса уки үлдүкләр эчен, без мулитваларны[5] белми---без.

[1.] *Төн ката* — төн буе.
[2] *Каталап китә* — авып китә.
[3] *Көнсәтә* — көне буе.
[4] *Төн ката* — төне буе.
[5] *Мулитва* [< рус. молитва] — дога.

### Пуитса итү

**Пуитса итү** *м.-кар.* көйләп дини китап уку.

— Карчык жәшәлә р, книжник диләр, пуитса итәләр. Чукыналар, жоморткa, икмәк, тыз куйалар, пыдаука[1] белән журна[2] куйалар пуит---са иткәндә.

### Түшәк саклау, урын саклау

**Түшәк сақлау** *нгб.-крш.*,

**Урын сақлау** *т.кам.-крш.* үлгән кешене күмгәннән соң, аның яткан урыны янында җыелып, иман укып, урын саклау җырларын җырлап утыру.

— Кәтүк әбинең түшәген сақларға бардым. Күмеп қайтқач түшәк сақлау була. Җәшрәк булса, қызғанып утырасың, қартырақ булса, сөйләшеп утырабыз. Шушылай дөм бирүзебез утырмыйбыз — *нгб.-крш.*

— Кеше үлгәчен өч көн *урын саклыйбыз*. Җыйылып утырабыз, иман укыйбыз. Көлке-көлке дә сөйләп аласың инде, төрле сүз дә сөйләп аласың.

— Элеке чирткеч уйныйлар ыйы урын саклаганда. Тал кисеп алып кайталар ыйы да берсенә-берсе чийертеп утыралар ыйы — *т.кам.-крш.*

## Урын саклау җырулары

**Урын сақлау җырулары** *т.кам.-крш.* үлгән кешенең урыны янын---да җырлана торган җырлар.

— Кеше үлгәчен, урын сақлыйбыз дип җамансылап җырлап уты---рабыз.

— Мына *урын сақлағанда* Марҗа[3] урсанай[4] җырлады моны:

Кимә генә кимә керләр дә җудым
Кибәр генә дидем лә кипмәде.
Кайтыр гына ди-ди көткәннәр идем
Кайтыр гына җирләргә китмәде (Сәвәләй).

[1] *Пыдаука* [< рус. пудовка] — бер пот сыешлы агач савыт.
[2] *Җурна* [< рус. зерно] — ашлык.
[3] *Марҗа* — Мария.
[4] *Урсанай* — керәшен сөйләшләрендә: баланы чукындырганда «икенче әни» итеп билгеләп куелган кеше (крестная мать).

## Ахирәт бәйете

**Ахирәт** [< гар. теге дөнья] **бәйете** *т.кам.-крш.* үлгән кеше янында төн саклап утырганда әйтелә торган мөнәҗәт

Ахирәт хә лен белмәдем,
Бер хәйер дә бирмәдем.
Бер хәйер дә бирмәдем,
Монда килерем димәдем.

Изге йулны йулдаш итик,
Йаман йулға йулықмыйқ.
Бу дөнйада қунақ қына
Булуыбызны онытмыйк (Ялтан).

## Мәет янында утырганда тыемнар

**Әстерхан сөйләшендә:**

— Мәйет йанында утырғанда *чөчкермәгә[1] йарамый*. Чөчкерсә, тиз барып берәү аның түбәсенә төртергә тийеш, йә үзең үзеңә түбәңә төртәсең.

— Үле йанында утырғанда *бер айақ өстенә икенчесен салып утырмаға йарамый*. Әйтәләр: «Үле артыннан тағын бер үле булыр», — дип. Ике айақны йәнәшә қуйып утырмаға қушалар (Картузан).

# МӘЙЕТ, ҮЛЕ, ҮЛЕК

## Мәйет

**Мәйет** [< гар.] үлек гәүдә, үлгән кеше.
— *Мәйетләр* садақа көтәләр алар, садақа бирми башласаң, төшкә инәләр — *к.-уф*.

[1] *Чөчкермәгә* — төчкерергә.

**Мәйет жыйу**

**Мәйет жыйу** *перм*. үлгән кешене күмү, җирләү.
— Мәйет жыйган көнне қорбанның суйалар. Миңке бабай әйтеп қуйды: «Мине жыйғанда да суй, жыллығымда да суй», — дип.
**Оло мәйет** — олы яшьтә үлгән кешенең мәете.
— Оло мәйеткә гүр садақасына сарық бирәләр, *кечерәк мәйеткә* таwық та йарый — *минз*.

**Мәйет булу ырымнары**

[Ырым — себер диалектларында:
Күке авылга килеп кычкырса, мәет була, дигәннәр]:
**Кәкүк килсә, мәйет була** *төм*.:
— Кәкүкләрдән ырымлана песнең аwыл халық. Шул кәкүкләр аwыл буйлап йөрделәр қыцқырып.
«Аwыр хәл булғалы тейеш», — тиделәр. Менә өц мәйет берйулы булты. Қарағай башқа утырып кәкүк қыцқыраты.

— Кәкүк қатқыраты[1], кәкүк йөрепте.
«Мәйет пулгалы», — тиләр.
«Таш пелән орың», — тиләр кәкүккә.
**Кәwек килсә, мәйет була** *туб*. авылга күке килсә, мәет була, имеш.
— Кәwек[2] аw ылға килсә, йарамайты.
«Мәйет була, үлем була», — тиделәр.
Аwыл уртаға, цитәнгә килеп кәwек күкелтәте[3]. Менә өйләре қоуғыс[4] утырып қалты, ире тә, үсе тә үлеп қуйтылар.

— Пер картуп утыстабыс, менә қураға кәwек килепте. Қыцқырат тиде, қыwабыс та, китмәй ицбер тиде.
«Палцық ырғытың кәwеккә» тиделәр. Кәwек оцып китте. Шыл йылны қышын ире үлте күршенең.
Кәwекнең аwылға килеwен йаратмайтылар. Ул қай wақыт аwылтан оцаты туры, менә пер ағацлыктан игенце ағацлыққа. Аwыл аша оцаты. Аны йаратмайтылар.

[1] *Қатқыра* — кычкыра.
[2] *Кәwек* — күке.
[3] *Кәwек күкелти* — күке күкелти.
[4] *Қоуғыс* — ялгыз, буш.

«Мәйет пулаты» тип әйтәтеләр.
— **Туқранны** да йаратмайтылар аwыл араға килсә.
— **Эт оласа** да йаратмайтылар, «кайғы булаты» тип әйтәтеләр.
**Кәwек утырған йиргә сөт қойу** [ырым] *туб*.:
— Кәwек күкелтәгәнне күреп қалсаң, шул посып утырған йиренә сөт қойоп йийатылар игән. Аны пелмәй қаласың, ғуй.
«Менә басып утырған йиренә, күкелтәп утырған йиренә сөт қойғалы кәрәк», — тиләр.
Цитән башқа сөт қойатылар пелеп қалсалар. Қурабашқа[1] килеп қысқырца қыwатылар.
[Ырым]: **аwылга кисәртке (кәлтә) килсә, мәйет була**:
— Кисәртке[2] ул менә кеше үләтегән өйгә киләтегән. Пес қырата цалғы белән пецән цалабыс[3]. Пецән белән бергә кисәртке килепте ишегалға. Пецәнебестә йөреп утыраты. Оллы атам[4] менә үлеп кит--
-те — *туб*.

[Ырым]: **аwылға сыйарат[5] қошы килсә, мәйет була** *тара.*:

— Сыйарат қошы килеп аwылта сайраса, пер кеше үләте, мәйет булаты. Аны, сыйарат қошын күреп булмый, таwышын айырам. Сый---арат қошы талларға килеп қунаты. Үсе күренмәйте. Сысғырған ши---келле сайрайты сыйарат қошы.

**Мәцкәй қош** *туб.* кукене шулай атыйлар.
**Мәцкәй қош килсә мәйет була** *туб.*:
— Мәцкәй қош үләтегән кешенең өйалтына килеп қыцқырса, кеше үләте. Үлек пулыр алтан қыцқыраты мәцкәй қош. Үлек пулса тағын пер үлек пулаты тип әйтәтеләр. Чәкмәй мамай алай әйтәте.

### Мәйетләр руғы

**Мәйетләр руғы** *төм.* мәетләр рухы; дога кылганда искә алыналар.

Мәйетләр руғына,
Эрбет сираттағы,
Кирәйет сираттағы,
Искеләр (изгеләр) сиратындағы
мәйетләр руғына бағышлатым — *төм.*

[1] *Қурабаш* — абзар түбәсе.
[2] *Кисәртке* — кәлтә.
[3] *Пецән цала* — печән чаба.
[4] *Оллы атам* — бабам.
[5] *Сыйарат* — зират.

### Мәйетнең айағын ошлау

**Мәйетнең айағын ошлау** *туб.* үлгән кешенең аягын тотып саубул---лашу.
— Мәйетнең айағын ошлағалы әйтәтләр.
«Айағын ошла, ич қурқытмайты», — тиләр.
**Мәйетләр килә** *тмн.* үлгән кешенең җаны, рухы кайта дип ышану.
— *Кечатна көн[1] мәйетләр килә* эвенә.
«Мәйетләр килер, дыва салырга[2] кәрәк», — диләр.

### Үле, үлек

**Үле, үлек** — үлгән, яшәүдән туктаган; мәет.
Бу сүзләр җирле сөйләшләрдә үлгән кешене озату, искә алу, җирләү белән бәйле йолаларга караган түбәндәге сүзтезмәләрдә күзәтеләләр.

### Үле ашы

**Үле ашы** *т.кам.-крш.* — үлгән кешене искә алу мәҗлесе.
— Ару әйбер утыртасың *уле ашына. Уле ашына* канатлы кош кирәк. Уле ашына кан чыгарып этәч суйарым дигән ийем — *т.кам.-крш.*

### Үле бар'амы

**Үле бар'амы** *чпр.* үлгән кешене искә алу көннәре.
— *Уле бар'амнарында* селге эләшәбез. Үле бар'амы була өце, зидесе, кырыгы, йыл ашы.
— Үле бар'амнарын кадерләп уздыралар. Үлекләр кимсенеп китмәсен дийеп, матур итеп өстәл төзиләр.
Үле бар'амына буш кул белән барми, сөлгеме, йаулыкмы илтәләр — *чпр.*
— Үле бар'амында шулай этеп бит себерәләр:

[1] *Кечатна көн* — пәнҗешәмбе.
[2] *Дыва салу* — дога уку.

Амин-амин өммәти,
Амин җәннәт нигъмәти.
Шәфәгәти җәннәти
Бирәхмәти дәүләти — *чпр.* (Каракитә).

## Үле бәйрәме

**Үле бәйрәме** *каз.ар.-крш.* үлгәннәрне искә алу, зиратка бару көннәре.
— Үеләр бәйрәме олы көннән бер атна торғач, сишәмбе көнне була, зиратқа бару көне була.

## Үле гүчтинәче

**Үле гүчтинәче** *крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә китерелә торган күчтәнәч-ашамлык. Башламаган, түгәрәк ашамлык булырга тиеш, диләр.
— Үле өчен биргәндә *гүчтинәче* шулай башламаган, түгәрәк булл---сын, диг әннәр. Шул табак алып килгән кешеләргә гердәне[1] берне саласың, тәбикмәк, пирук саласың, табакны буш җибәрмисең, үле гүчтинәче белән җибәрәсең үзең дә.

**Үле гүчтинәче** *крш.* үлгән кешене өйдән алып чыгып, күмәргә илткәндә бирелә торган ашамлык.
— Капкадан чыкканда кем очорый, шуңға бирәбез күчтәнәч. Ул тәбикмәк була, бүз белән төреп, тегә рҗеп белән бәйләгән була. Кем очорый, олы кешеме, баламы, кулына бирәбез.

## Үле иләме

**Үле иләме** *м.- кар.* үлгән кешене озату тәртибе, рәте, яме.
«*Үле иләме* — җылату белән», — диләр.

## Үле keләwe, үлеләр keләwe

**Үлеләр keләwe** *крш.* (Алабуга р-ны) үлеләрне искә алу көне.

[1] *Гердә* — кечкенә түгәрәк ипи.

— Үлеләр keләwенә үлемтеккә (зиратка) барабыз, тәбикмәк, күкәй, балық пешереп keләү итәбез.

— Үле keләwендә ашка keләү итәләр дә утыралар. Утыргачын башта тәбикмәк белән бал қабалар, шулай тийеш. Иң башта ашқа утырғачын да тәбикмәкләр белән бал қабалар.

## Үле кабырлау

**Үле кабырлау** *т.я.-крш.* үле күмү.
— Мазарда[1] бер митыр җарымлык тишек[2] казилар да үленең тубы---гын (табутын) тишеккә төшерәләр, үлене тыгалар. Өч кеше мунчада җуwыналар. Ирләр кабырлап кала, катыннар кайтып китә.

## Үле карасы

**Үле карасы** *т.я.-крш.* үленең киемнәре, урын-җир әйберләре.
**Үле карасын җуу, урнаштыру** *т.я.-крш.*:
— Үле карасын өч кеше җу wалар да җан чыккан кийемнәрен, ка---раларын мазарга алып китеп үленең тишегенә үк тыгып куйалар, өскәрәк энде тишегенә җибәрәләр.

## Үлене мазарга озату

**Үлене мазарга озату** *т.я.-крш.* искә алу мәҗлесендә үленең «җанын» зиратка озату:

— Үлене сагыналар, ашилар, эчәләр дә мазарга озаталар. Мазарга озатырга киткәндә *өч тапкыр* өстәл тирәли *әйләнәләр*. Кем бара ма---зарга, шалар әйләнә өч тапкыр.

— *Парсыз* булып баралар, так кирәк. Анчак *таба тимере*[3] *тотып*,

*үленең мендәрен тотып, табак белән ашамлыкларын, кашыгын* то---тып баралар. Табагын да, кашыгын да *үленең тишеге* (кабере) *өстенә куйып калдыралар*.

[1] *Мазар* [гар.] — зират.
[2] *Тишек* — кабер.
[3] *Таба тимере* — таба тоткыч (ухват).

— Мазар өстендә шәм җандыралар, салам, йомычка йандыралар, тишек тирәли өч тапкыр әйләнәләр, йактысы төшә диләр. Койаш унайли өч тапкыр әйләнәләр.

### Үленең җене

**Үленең җене** *влгг.* үлене озатканда , «җене калмасын», — дип, бик иплəп, ишеккә, стеналарга тидермичә генә чыгаралар.

— Мәйетне чыгарганда ишек кас'агына[1] тигезмиләр. Тигезсәң, ул күзеңә күренә ди.

«Җене қала үленең, ишеккә тигезмә», —

дигәннәр. Ул үдә тыныч булмый, кемдер йөри сынны тойола башлый---дыр.

— Үлене ызбадан[2] чыгарганда ишеккә, пәрдәләргә тигезмә, шылай бездә. Тотып торалар шылайгага. «Чыгарыгыз, тигезмәгез, тиха бу---лыгыз».

Җене кала ди үленеке. Ул күзеңә күренергә мужыт. Шыпырт-шыпырт йатасың, ә ызбада йөридер (Лятошинка).

### Үле зийу

**Үле зийу** *чпр.* үлгән кешене күмү.

— Үле зидылар әнәйләр. Үле зиганнарын шыпырт кына карап тора идем. Әнәй үле йугалады.

### Үлегә бару

**Үлегә бару** *нокр., әстр.* — үлгән кешене озатырга бару, анда ашам---лыклар алып баралар.

— Тумак бар, үлмәк бар. Кеше үлгәч, *үлегә барганда* нидә булса ил---тәсин. Күммәстэн алда андай гадәт, илтеп баралар ризыклар — *нокр*.

— Үлегә бармаға тийеш.

«Үлегә бармаған кеше — үчле кеше» дип әйтәделәр — *әстр*.

[1] *Ишек кас'агы* — ишек яңагы.
[2] *Ызба* — өй.

### Үлене сагыну

**Үлене сагыну** *т.я.-крш.* үлгән кешене искә алу.

— Ашыйбыз, эчәбез, *үлене сагынабыз* да мазар эстенә китәбез.

### Үле садакасы

**Үле садакасы** *әстр.* үлгән кеше рухы өчен бирелә торган хәер.

— *Үле садакасын* йаланғач қул бирергә йарамый дип әйтәләр, йаулыққа урап бирәләр ақчамы, қашықмы бирәләр.

## Үле суwы

**Үле суwы** *əстр., к.-уф.* мəет юган су.
— *Үле суын* электə чоқыр қазып əүлəдə[1] күмə булғаннар, хəзер инде үлеккə[2] китеп түгəлəр.
*Үле суын үле* белəн бергə алып китəлəр, анда қоршап[3] қуйылған — *əстр.*
— Үле суын алып килгəн кешегə йаулық бирəлəр — *к.-уф.*

## Үле — суда йөзə

**Үле — суда йөзə** *əстр.* үлгəн кеше янында күп еларга ярамый дигəндə əйтелə.
Йылағанда да күп йыларға йарамый.
«Күп йыласаң, *үле суда йөзə*», — дип əйтəлəр.
Муллалар шамғана[4]: «Бик алай йыламағыз, *үлене суда йөздерəсез*», — дип.

## Үле килмəсен

**Үле килмəсен** *əстр.* үлене күмəргə алып киткəч ырымлаганда əйтелə торган сүз.
— Бусағаға балта белəн чапқан булады үлене алып чығып киткəч.
«Артық үле булмасын,
бусағаға үле килмəсен», — дип (Кундрау).

[1] *Əүлə* — ишегалды.
[2] *Үлек* — зират.
[3] *Қоршап* — киртəлəп.
[4] *Шамғана* — ачулана.

## Үле кораны

**Үле кораны** *əстр.* үлгəн кешене искə алу мəҗлесе, дини мəҗлес.
— Үле қоранына ирлəрне чақыра, қысқайақларны[1] чақырмый. Ирсез хатыннарны ғына чақыра, ире бар кешенең ирен генə чақыра. Ирен чақырғач хатыны белəн, қоран ашына барырға кирəк.
Ике қазан пылау пешерəлəр əүлəдə, бөтен аwыл килə. Күп килə халық.
— Ирлəрне ашатып чығарасы чақырып, қатыннар бары да үзе килə:
«Баш сау булсын» əйтеп чығабыз, «йақшы түгел килмичə», — дип.

— Үле қоранына аwыл халқы чақырмыйчы да килə. Аш-су, пы---лау пешерəделəр үле қоранына. Татулықта, берлектə уздырдық. Чақырмыйчы да килəлəр үле қоранына.

— Үле қоранына халва пешермəгə кирəк. Нəлбəклəргə[2] салып қуйады халваны (Кызан).

## Үле кашыгы, үле табагы

**Үле кашыгы, үле табагы** *т.я.-крш.* үлгəн кешене искə алганда аның өчен дип куелган кашык, табак.
— Үле кашыгын, үле табагы[3] белəн бергə мазар өстенə алып китəлəр, шанда тишек[4] өстөнə куйып калдыралар (Ырым Тəрбит).

## Үле күрке

**Үле күрке** *əстр.* — үлене озату рəте, тəртибе.
«Үле күрке — җылау,
Туй күрке — җыр», — дилəр.

[1] *Қысқайақ* — хатын-кыз.
[2] *Нəлбəк* — тəлинкə.

[3] *Уле табагы* — үлгән кешене искә алу мәҗлесендә үлгән кешенең җаны өчен дип, ашамлыклар салып куелган табак.

[4] *Тишек* — кабер.

### Үле мендәре

**Үле мендәре** *т.я.-крш.* үлгән кешене искә алган көнне аны зиратка барып «чакыру» өчен ясалган махсус мендәр.

— Үле мендәре круслап[1] җүләгән була. Мазар өстөнә киткәндә үле мендәре алып баралар, шанда чакырып кайталар. Өстәл арасына куй---алар мендәрне. Ул шанда утыра була. Озатканда шал мендәрне алып чыгып китәләр. «Әйдә, киттек» дип.

— Өстәл йанында үлегә дип салган үле мендәре була. Үлене оза---тырга чыкканда ул мендәрне дә тотып чыгалар.

### Үле мунчасы

**Үле мунчасы** *т. я.-крш., каз.ар.-крш.* кеше үлгән көнне һәм аны искә алган көннәрдә ягып әзерләнә торган мунча.

— Үле чығу көнне мунча җагалар. Үле чығу көне паскыдан бер атна алдан була. Ул симеттә була, өч көн була. Үлеләрне мунча кертәбез, эсвичәләр куйабыз, зиратка барабыз.

Мунчаға кергәндә үлгәннәрне чақырабыз. Кичкә әзерлиләр мунча, йаңа себерке, миллек кертәләр. Таз, су, мунчала, сабын куйасың.

«Әйдә, йуыныгыз», — дисен.

— Үзең чабынасың. Чабынган миллекне жуып җибәрәсең дә үлгән кеше исеменә жар бирәсең. Аннары әйтәсең инде:

«Менә сезгә мунча жақтық бүген» — *каз.ар.-крш.*

— Мунча кергәндә миллек белән парит' итәбез. Исемнәп-исемнәп чақырабыз, кемне чақырасың килә. Бер үлгән кешенең исемен әйтәбез. Әр қайсын әйткәндә, миллекне лаукага сугып алабыз.

Шул мунча йаға торған көндә мин чақырам барысын да. Менә кемнең искә алыр кешесе йуқ, чақырып алыр кешесе йуқ. Кемне беләм, шуларны чақырам мунчаға. Татарларны да, урысларны да чақырам — *каз.ар.-крш*.

— Үлеләр өчен мунча җағу дүшәмбе көнне, зиратқа менү алдын---нан була. Зиратқа бару ул олы көннең икенче атна сишәмбесендә була. Зиратқа күкәйләр, тәбикмәкләр пешереп алып барабыз, қач төбенә са---лабыз.

[1] *Круслап* [< рус. крест + -лап] — тәре ясап.

Үлеләр өчен жаққан мунчаға исемнәп әйтеп-әйтеп чақырабыз:

«Қара Бәси бабайлар, Ақсақ бабайлар, Пидучлар, Әркипләр барығыз да килегез, күршеләрне дә алып килегез», — дип, әйтеп-әйтеп чақырабыз.

Әйтмиче генә чақырсаң, төшкә керә. Гел исемнәп әйтеп-әйтеп чақырабыз, ташқа эссе салабыз әйтеп-әйтеп:

«Барысы да өлешле булсыннар», — дип *каз.ар.-мам.* (*керәшен*).

### Үле мунчасы көне

— Олы көн алдыннан читвирг үлеләр чыққан көн була, **үле мун---часы көне** дип тә әйтәбез. Ул көнне мунча жағасың үлеләргә атап. Ул көнне үзең тиз генә жуынып чығасың да бөтен жирне чичтартып қуйасың. Ләүкәдән тотынып, сабынын, себеркесен әзерләп қуйасың.

«Кемнәрнең қайтасы килә,
Әрберегез монда қайтып жуыныгыз», —

дип әйтеп чығам үле мунчасы көнне мунчадан жуwынып чыққанда. Жуwыналар, без күрмибез аларны — *каз.ар.-мам.* (*керәшен*).

— Лаукага менеп утырасын, үзен җуынасын, аларны чакырасын үзен җуынып бетергәч: «Әйдәгез, минем белән бергә җуыныгыз инде», — дийеп.

Үзен җуынасын, алар да чичта була.

Җуынып беткәч, қойынырға бағыт җитә. Шул бағытта башта үзен кийынасын, аннан үлг әннәр, чақырып алғаннар өчен җасыйсың су аларға. Аласың виник, виник өстөнә өч мәртәбә су саласың. Аннары түгәсең.

Мунчадан қайткач пура (буза, квас) куйасың, чәй қуйасың өстәлгә, аш, қоймақ.

«Әйдәгез, ашағыз инде безнең белән бергә» — *каз.ар.-кpш.*

— Тыккан көнендә[1] дә, өчендә, тугызында , кырыгында да мунча йагалар. Үле тыгып кайткистан кас′ы мунчада җуwынып чыга.

«Барлык үлгән мәндәләр килә ди җуwынмаллы» — *т.я.-крш.* (Янсурино).

[1] *Тыккан көне* — күмгән көне.

— Үле мунчасын өч кеше җага, мунча җагучыларга тастымал бирәләр.

— Мунча җагалар үлекне тыккачтан. Тыгып кайткистан мун---ча керәләр. Анда миллекләрне җуwып, чиста сулар салып куйалар. Бөтен үлгән кешеләр килеп җуwына ди.

— Бийанам сүләде. Суга барам ди. Мунча кереп чыктылар ди кы---рыкында. Ырым суwына барам ди. Капкадан мунчага кадәр халык күрдем ди. Үлгән кешеләр килгән җуwынмаллы. Менә кычкырды ди. Чаwып чыктык. Праскига нәстә булган. «И кодай, сезнең күзгә күренәме, дөнйа хәтле халык диб әйтә ди, мунчага керә» дип әйтә ди, мунча керегә барганнар. Күзенә күренгән монарга — *т.я-крш.* (Ырым Тәрбит).

— Кечатна көнне муча йағабыз, алар йуwынырға киләләр. Тәйекмәк, қыстыбыйлар пешерәбез. Алар төшеңә дә керә бит.

Иртәгә қырығы дигән көнне дә муча йағарға кирәк.

Олы көн бәйрәмендә үлеләргә мунча йағарға кирәк. Мунча йаққаннан соң тәбикмәк пешерә — *т.кам.-крш.* (Мәлкән).

### Үле тоту

**Үле тоту** *т.я.- крш.* үлгән кешенең рухын ризалатмасаң берәр авы---ру яки зыян килә дип уйлыйлар, «үле тота» диләр.

— Үле тоту бар ул. Үлене тыккан көндә[1] бармасан, менә кы---рык көнен сагынганда[2] бармасан да үле тота. Йә үзен чирлисен, йә таwыгын, йә сарыгын үлә. Барас була. Бармасан үле тота. Wакытын булмача йат аwылга бара алмасан, үдә үзен генә сагынып та түкмәлле диләр. Куймак, йомыркалар пешерәсен, келәү итәсен дә калганын капка төбенә чыгарып түкмәлле.

«Үлгән мәндәләр, бәкилләгез», — дип.

### Үле тыгу

**Үле тыгу** *т.я.-крш.* үлгән кешене күмү.

[1] *Тыккан көндә* — күмгән көндә.
[2] *Сагынганда* — искә алганда.

— Үле тыгу аwыр энде ул. Үле тыгып кайткистан ук мунчада йуwынып чыгалар. Үлене тыккынсы келәү итәләр, келәү итмәчә чы---гармилар.

— Үлене тыккынсы келәү итәләр, келәү итмәчә чыгармыйлар. Батышкы[1] килгистән бар да чукынып торалар. Үле өстендә «Алла китаплары»[2] укилар.

### Үле тыккан көн

**Үле тыккан көн** *т.я.-крш.* үлгән кешене җирләгән көн.

— Үле тыккан көндә дә, өчендә, тугызында, кырыгында да мунча йагалар. Өч кеше йага мунчаны. «Барлык үлгән мәндәләр жуwынып чыга», — диләр.

— Тыккан көнне таwык суйалар. Кеше үлгистән дә өч җан өзмәлле кирәк, бер җылга хәтле сарык, таwык икене суйалар. Балык куймаган---нар «Балык шуа» дип. Дуңгыз ите дә пешермиләр.

**Үле чыгу көне**

**Үле чығу көне** *каз.ар.-крш.* пасхадан бер атна алдан үлгән кешеләрне искә алу көне.

— Үле чығу көнне муча җағалар. Үле чығу көне паскыдан бер атна алдан була. Сабыннар, сулар салып қуйалар, тарақлар қуйалар, табақларға су салып қуйалар. Үлгәннәр қайта да җуына диләр.

Эссе салып қуйалар үлгәннәргә. Үзе җуынып беткәч, шулай эссе салып чығып китәләр.

— Үле чыққан көнгә қаршы мунча җағабыз. Үле чыққан көнне «без сезне чақырабыз», — дип саwытлар тезеп җөриләр ийе. Тупылларға меңгереп қуйғаннар саwытларны. Өй ийәсенә, абзар ийәсенә қуйабыз.

«*Зыйан китермә*», — дип.

[1] *Батышкы* [< рус. батюшка] — атакай, христиан дине башлыгы.
[2] *Алла китаплары* — дини китаплар.

— Шул үле чыққан көнне өй түбәсенә менеп җиде қат қыл иләктән қарасаң, **үлгән кешеләрнең қайтқаны** күренә дип әйтәләр.

**Үле чыққан көн**

— Үле чыққан көн — паскының алдағы читбиригендә була инде ул. Үле чыгуга каршы бөтөн кеше мунча җаға. Үлгәннәрне искә ала торған көн дибез инде.

Үле чығу көнне үзенең электән қалған җолалары бар:

Үле чығу көнне иртүк торалар да бақчаға туқмақ аталар:

«Бәрәңгеләр туқмақ шикелле булсын».

Аннары бақчаға чығып уттан сикерәләр:

«Гәүдәләр җиңгел булсын».

Чишмә башында бөтен кеше кер җуwа чиратлашып. Кер җусаң, имеш:

«Җитеннәр озон була».

Элеке бит җитен чәчкәннәр. Җитен суғып киндер җасағаннар. Озон җитеннеке әйбәт чыға киндере.

«Үле чыққан көнне иртүк торып таwықларны қырақлатабыз».

«Қойаш чыққанчы иртүк торып қоймақ пеширәбез».

«Бақчаға чығып ут җағып, утын туқмақлары чығарып атабыз».

— Үле чыққан көн була. Җиде атна ураза тотабыз паскыга хәтле, ахырғы атнасы үле чыққан көн була.

«Үле чыққан көнне җил булса, җыл буйы җил була», — дип әйтәләр ийе бабайлар.

Үле чыққан көнгә қаршы мунча җағалар. «Үлеләр өчен» дип эссе салып чығабыз мунчадан.

Үле чыққан көнне урманға ылысқа менәләр, ақ шыршы ылысы---на. Чәнечкене булырға тийеш түгел. Исус Кристусны чәнечкеле ағач белән қыйнағаннар ди. Шуның өчөн, безгә, керәшеннәргә, чәнечкеле ағач җарамый — *каз.ар.-крш.*

### Үле түбә

**Үле түбә** *эстр.* зират.

— Таш белән куралған[1] булган *үле түбә*. *Үле түбәне* тимердән қоршадылар. *Үле түбәдә* әүлийәләребез йата. Қараwыл салдылар *үле түбәгә*.

### Үлене урнаштыру

**Үлене урнаштыру** *крш.* үлгән кешенең «җанын озату».

— *Үлене урнаштыру* диләр, пуминка көнне ашап-эчкәч «*урнаш---тырасы* инде *үлене*» дип озатырға чығалар, қойаш чығышына таба озаталар.

### Үленең урыны

**Үленең урыны** *т.кам.-крш.* искә алу мәҗлесендә үлгән кеше өчен дип махсус урын, савыт-саба, ашамлыклар куялар.

— *Үленең урыны* пич җанында була. Киштәгә тастымалын эләләр, урындыққа әйбер җәйәләр, шунда утыра диләр. Өстәл өстенә аның өчен дип бер қоштабақ, қашық қуйалар, йомырқасын, ботқасын қуйалар.

«*Туқлықта йөрсен, ач йөрмәсен*».

### Үлене чакыру

**Үлене чакыру, җанын чакыру** *т.я.-крш.* үлгән кешене искә алу көнендә зиратка барып, аны «чакырып» кайту.

— Үле ашын үткәргәндә зиратқа барып чақырабыз. Өч кеше бара---быз. Ипиләр алып барабыз.

«Сине алырға килдек,
бүген синең ашың.
Туғаннар, тумачалар,
Барығыз да өйгә қайтығыз», — дип.

Аңа өстәл башында урын қуйабыз, кийемен, җаулығын, тәлинкә белән ашамлығын қуйабыз — *каз.ар.-крш.*

[1] *Қуралган* — киртәләнгән.

### Үле чеперәге

**Үле чеперәге** *м.-кар.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә ашамлы---клар төреп китерү өчен әзерләнгән тастымал.

— Витрасны (питрачны, ягъни кечкенә ипине) алда *үле чеперәгенә* тереп алып киләләр, круслы тергеч белән. Карадан тегеп куйган була крус (тәре), җә җүләп куйган була.

### Үле тастымалы

**Үле тастымалы** *каз.ар.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесләрендә генә кулланыла торган тастымал.

— Шул үлгәннәрне искә алғанда ғына тота торған бер тастымал була. Үлгәннәрне искә алу бетте — ул тастымалны җуып тағын салып қуйалар ыйы.

### Үле зату

**Үле зату тастымалы** *каз.ар.-крш.* үлгән кешене искә алу беткәч «озатырга» чыкканда ашамлыклар төреп куела торган тастымал.

— Теге үле саwытын, үле зату тастымалын тотып, үле затырга чы---галар барысы да.

### Үлеләр белә

**Үлеләр беләҙ** *әстр.*:

— Беренче алла тәгаләм, икенче үле беләде, барын беләде үлеләр.

### Үлеләр төшкә керә

**Үлеләр төшкә керә** *әстр.*:

— Үлеләр төшемә керсәләр: «Төшемә инмәгез, ыриза булыңыз, ата---ларым, аналарым өчен», — дип җатам, *нийаз күтәрәм үлеләргә* дип.

«Қодай тәғаләм, теләкче бул.

Минем атым морза.
Мин ходайға ыриза.
Минем атым ақ
Мин қодайға чақ», дип.

### Үле өстенә бару

**Үле өстенә бару** *әстр.* мәет булган өйгә бару.

— *Үле өстенә барганда* мата[1] учлап барабыз. Электә аны кешегә күрсәтеп үленең өстенә салганнар. Хәзер инде өстенә салмыйлар, өй хуҗасына ғына бирәләр.

— *Үле өстенә* мата, йә йаулык куйалар, нийаз алып бара, бөтен күршеләр, кардәшләре бара үле өстенә.

### Үле өстәле

**Үле өстәле** *т.кам.-крш.* искә алу мәҗлесендә үлгән кешенең җаны өчен дип ашамлыклар куелган өстәл.

— Тәре алдына менә монда өстәл көйлибез, *үле өстәле*. Шул өстәлгә нәстә куйылган, шуны сәдәкә итеп кешегә бирәсең. Йалгыз---ларга, белгәнерәк кешегә бирәсең.

— Шәм җаға да үлегә дип айырым өстәл қуйа, *үле өстәле* дип. Қоймагын қуйа, шуны тәре почмағына қуйа.

### Үле — үлене чақыра

**Үле — үлене чақыра** *әстр.* дип, мәет озатканда артыннан чык---мыйлар.

— Кә феннәр салып җеназа укығач бер минут та тотмый алып китәләр. Үленең артыннан чықмыйлар бездә:

«*Үле — үлене чақыра*», — диләр.

### Үле-терегә дога қылу

**Үле-терегә доға қылу** *себ.* үлгәннәргә һәм тереләргә дога кылу.

— *Үле-терегә дип доға қылабыс* цымта[2], астанаға йомортқа пеше---реп паратлар.

[1] *Мата* — тукыма.
[2] *Цым* — яз көне үлгән кешеләрне искә алу көне.

### Үле — терене искә алу

**Үле-терене искә алу** *нгб.-крш.* үлгәннәр һәм тереләр өчен хәер бирү.

— Мына атап саласын табаға қоймақ. Барына да мына, оло-қарыға, атам-инәмә дип ул қоймақны бер әбигә бирәсен.

«Минем *үле-теремне искә ал*», — дип.

### Үле-тере кузгалган көн

**Үле-тере кузгалган көн** *чпр*. дүшәмбе, пәнҗешәмбе көннәрен олылап, садака бирү көне.

**Башкиц** *чпр*. дүшәмбе.

**Кецатна, атнакиц** *чпр*. пәнҗешәмбе.

— Кецатна ул атнакиц тә әтелә.

Атнакиц, иртәгә йома дигән көнне садака бирәбез. Аннары башкиц садака.

«Үле-тере кузгалган көн».
«Башкиц бик саwаплы көн».
«Башкиц, кецатна үлекләр килә», — дир (Каракитә).

### Үле-тереләргә хәйер, Үле-тереләргә өлеш

**Үле-тереләргә хәйер** *әстр*.,

**Үле- тереләргә өлеш** *әстр*. хәер итеп, үлгән кешеләр һәм исәннәр рухына багышлап пешерелә торган ашамлык, хәер-садака.

— *Үле-тереләргә хәйер* булсын, —
пешерәм баwырсак, ис чығарам.

— *Үле-тереләргә өлеш*
дип мичеткә тамақ (ашамлык) илтәм.

— Қайсы баwырсак, қайсы лақсалба[1] пешереп илтә. Кемнәр өлеш бирде, шул өлештән балаларға бүлеп бирәбез.

«Йақшы булыңыз», — дип.

Үзеңнең ашайағыңнан өлеш бирмәгә кирәк үле-терегә.

[1] *Лақсалба* — чәкчәк.

### Үле чик, чик бирү

**Үле чик** *әстр*. үлеләрне искә алу.

**Тере чик** *әстр*. терелә рне искә алу.

**Чик бирү** *әстр*. дини мәҗлес үткәрү.

— Қорман бәйрәме, ураза бәйрәме алдыннан чик бирәмез, қоран уқытамыз. Беренче — *үле чик*, икенче көн — *тере чик* булаты, өченче көн — ғайет бәйрәм булаты, қуй суйатылар чик биргәндә.

### Үле җырулары

**Үле җырулары** *крш*. үлгән кеше янында төн саклап утырганда җырлый торган мөнәҗәтләр.

— Үле җыруларын барыбыз да беләбез, үле җыруын җырлап оза---табыз.

Қара да қара күренәдер
Қара қарлуғаннарның ла қуағы.
Қараңғылар дийеп килми қалма
Сез қараңгы төннәрнең лә қунағы.

### Үлеләр аwыз ачкан көн

**Үлеләр аwыз ачкан көн** *крш*. пасханың соңгы көне.

— Паскының соңгы көне **үлеләр аwыз ачкан көн** дип әйтелә. Үлеләр безнең белән бергә аwыз ачмый икән, алар шул буш көнне[1] ачалар икән. Шунда үлеләр өстендә йасаган өстәлләр бар, шунда

алып килгән ашларыбызны куйабыз. Әзерәк утырып, ипийен-тозын кабып, шунда тәберсен итәбез[2] — *т.я.-крш*.

### Үеләр олы көне

**Үеләр оло көне** *крш*. пасха үтеп бер атнадан соң үлгән кешеләрне искә алу көне.

— Оло көн үткәч бер атнадан соң *үелэрнең оло көне* дип зиратка барабыз — *т.кам.-крш*.

[1] *Буш көн* — сишәмбе
[2] *Тәберсен итү* — дини теләкләр теләү

— Паскыдан соң буш көнне (сишәмбе көнне) *үеләр оло көне* була, бөтөн халық зиратқа бара — *т.кам.-крш*.

### Үеләр табагы

**Үеләр табағы** *крш*. үлгән кешене искә алу мәҗлесендә үлгән кешеләрнең рухына багышлап куелган ашамлыклар табагы.

— Тәре алдына табақ қуйалар, *үеләр табағы* дип. Шунда салалар ризықлар үлгән кешеләргә атап.

— Үле табагына бары да өзеп-өзеп салалар туганнары. Нинди ри---зыклар бар, барын да салалар.
«Бәкиллә, куркызма», — дип.

— Үле табагын да мазар өстенә алып китәләр озата барганда. Шал табакны, кашыкны да тишек (кабер) өстенә утыртып калдыралар. Шан---да кала табагы да, кашыгы да. Шанда килеп ашилар була — *т.я.-крш*.

### Үеләр эсте

**Үеләр эсте** *чст.-крш*. зират.

— Түгемдә піруклар пешереп *үеләр эстенә* баралар.

— Симеттә әйбер аруландыралар да үеләр өстөнә баралар. Үзенең теләген әйтеп, иман әйтеп куйалар аруландырган әйберне. Җорт бо---дай ононнан кабартма пешерәләр симеттә.

— Таwык суйабыз, йомырка пешерәбез, коймаклар. Йомыркаларны дүрткә бүләсен дә саласын бисмилла әйтеп үлгән
кеше өстөнә, үле өстөнә.
«*Син ашаган-эчкән күк булсын*».
Каргалар ашый аны.

### Үлгән мәндә

**Үлгән мәндә** *крш*. үлгән кеше.

— «Менә, *үлгән мәндәләр*, шуны ашаб -эчеп китегез, игенче без---не аптыратып җөрмәгез, үзегез жул белән үзегез җөрегез», — диләр. Қалған ашамлықларны кеше йөрмәгән җиргә қуйалар — *т.кам.-крш*.

### Алдан үлгән мәндә

**Алдан үлгән мәндәләр** *т.я.-крш*.: — Чакыралар үле мәндәне. Куй---магын алып баралар да азырак салып куйалар тишек (кабер) өстенә.
«*Җибәрегез, менә сезгә алдан үлгән мәндәләр*».

### Үлек

**Үлек** — 1. үлгән кеше, мәет — Үлектән қурықма, теректән қурық; 2. тубыл, әстерхан сөйләшләрендә *үлек* сүзе зират мәгънәсендә дә кулланыла.

### Иске үлекләр

**Иске үлекләр** *туб*. изгеләр зираты.

— Иске үлекләртә нәрәситә йақшылар йата. Цитәннәгән ул иске үлекләрне, анта астана булып қалған.

— Иске үлекләр тип әwәлге қаберләрне әйтәбес, искеләрнең руғына тип бағышлап уқыйтылар.

— Бездә берничә *үлек*, менә *Бабай атам үлеге* бар, анда да күмәбез - *әстр*.

### Үлек ашы

**Үлек ашы** *том*. мәет ашы; искә алу.

— Без үлек ашына боға (үгез) суйдық.

### Үлек өсте

**Үлек өсте** *әстр*. — зират.

— Мәйетне чығарғачтын табутқа салып күтәреп экитәде үлек өстөнә.

**Үлек өсте** *глз*. мәет яны.

— Үлек өстөндә без урынтын гына утырабыз. Китап укилар, абы---стай китерәбез.

Көндөз дә барып утырабыз. Көндөз утырганы кичкә таба китә инде. Үзләре дә кайбан бага, өйне йаңгыз калдырмыйлар.

— *Үлек өстөләрдә* йаман моно йырлайлар иде:

Барып кердем өйөгезгә
Тәсбих күрдем чөйөгездә.
Тәсбих саwаплары бирсен
Бер кодайым үзегезгә.

И кодайым, син беләсең
Фаный дөнйа аwырлыгын.
Бер кодайым сезгә бирсен
Пәйгамбәрләр сабырлыгын.

### Йаңа үлек, иске үлек

**Йаңа үлек** *чпр*. яңа гына үлгән кеше.

**Иске үлек** *чпр*. күптән үлгән кеше.

— Йаңа үлекләргә атына[1] укырга, иске үлекләргә атына укырга. Алар бергә булалмыйлар. Йаңа үлекләр алар иске үлекләр белән бергә бармый.

### Үлек, терек

**Үлек** *чпр*. үлгән кеше.

**Терек** *чпр*. тере кеше.

**Мәйет чыккан өйнең** кешеләрен өйдән-өйгә йөртеп хөрмәт итәләр.

«Үлек — ачар,
Терек — йабар», —

дигәннәр — *минз*.

— *Үлекләр* туwа көтеп йататы. Пөтөн кеше қылаты цымны[2] — *туб*.

### Үлекнең аты

**Үлекнең аты** *глз*. кеше үлгән йортка күбәләк очып керсә, үлгән кешенең җаны, аның аты дип әйтәләр.

— «*Үлекнең аты килгән, үтермәгез, үлекнең аты ул*», —

дилир. Козыллы папа[3], козыллы күбилик килсә.

[1] *Атына* [< рус. отдельно] — аерым.
[2] *Цым* — үлеләрне искә алу көне.
[3] *Папа* [<удм.] — күбәләк.

**Үлек аш Үлек аш** *глз*. искә алу көненә пешерелә торган аш-сулар.

— Кабарчысын да, тәбиген дә бешерәсе була *үлек ашка*.

— Wак тәбик[1] түгәләр пич алдында таба белән.

— Коймак пешерәләр май эчендә, андай әйбер.

Бөккән пешергәлилә р, кайсы шоморт белән, кайсы геби[2] белән. Йе---ралма шанги, курайләк шанги пешерәләр.

### Үлекнең үс ашы

**Үлекнең үс ашы** *себ*. искә алу мәҗлесенә генә пешерелә торган ашамлыклар.

— Үлекнең үс ашы пулаты, қырбаштан килгән кешеләргә пешерәт---ләр. Кәпкер пешерәте қырықбер күс (кәпкер — тишекле күзикмәк).

### Үлекнең чәчүе, чәчү чәчү

**Үлекнең чәчүе, чәчү чәчү** *әстр*. үлгән кешене искә алу мәҗлесендә өләшенгән акча.

— Өченә, җидесенә, кырыгына кергән халыкка йаулыкка урап акча өләшәләр. Ул чәчү чәчү, *үлекнең чәчүе* дип әйтелә. Өй хуҗасы бирә. Күпме кешегә нийәтләгән, биреп бетерә. Зиратта да *чәчү чәчәләр*.

### Үлек җыйу

**Үлек җыйу** *том*. үлгән кешене күмү.

— Мәликә мамай үлек җыйарға киткән — *том*.

### Үлек сақлау

**Үлек сақлау** *себ*. мәет янында төн саклап утыру.

— *Үлек сақлау* тиләр, төн утыралар. Сөйәк қараwыллап утыру саwаплы. Мәйетне йалғыс қалдыру йарамас.

### Үлекне искә алу

**Үлекне искә алу** *себ*. үлгән кешене искә алып дини мәҗлес үткәрү.

— Үлекне искә алып қатым аш үткәрәләр.

[1] *Тәбик* — тәбикмәк.
[2] *Геби* — гөмбә.

### Үлекләрнең қатымы

**Үлекләрнең қатымы** *себ*. үлгән кешеләр өчен үткәрелә торган мәҗлес.

— Цым — үлекләрнең қатымы булаты, әргемнең үлеге йата, қатым уқытатлар.

Үлек — қатымға туймайты,
Йир — суға туймайты — *туб*.

### Үлекләрнең цымы

**Үлекләрнең цымы** *себ.* үлгән кешеләрне искә алу, ашамлыклар белән зиратка бару. (Цым > җим, йим).

— Үлекләрнең цымы майның туғысларынта башланаты, астанада қарлар бетсә. Қырбашқа барып әркем қатым уқытады. Тәрилкә белән утысабыс пашырсақны, йомортқаны — *туб.*

### Үлек йәшерәсе көн

**Үлек йәшерәсе көн** *глз.* мәетне җирләү көне.

— *Үлек йәшерәсе* көндә үлек чыгасы өйдә артыш йандыралар. «Ар---тыш исе чыксын», — дип.

— Үлек йәшерәсе көнне кеше күп җыйылгалады, үзләре белеп, ишетеп киләләр, «саwаплы» дип — *глз.*

### Үлек йәшерү, үлек җыйу

**Үлек йәшерү** *глз.* үлгән кешене күмү.

— Үлек йәшерү диләр, қабер казырга баралар. Үлек йәшергән йиргә күп кеше килә безнен аwылда.

— «Үлек йәшерәсе бар әле, кайгылы көн бүген», — дигәләделәр.

— Кичтән үк әйтеп куйалар:

«Үлек йәшерәсе бар», — дип.

Шулай әйтәләр: «йәшерәсе бар әле», — дип.

Хәзер үлекләрне туйдан да зур итеп йәшерәләр, ашларны күп йа---сыйлар. Беркемне дә аштан-судан калдырмыйлар.

— Сугыш өстөндә кайын тузына салып та, киндер капчык белән дә йәшергәләделәр үлекне.

Хәзер инде кәфен белән йәшерәләр. Йахшыдан, бүздән йасыйлар кәфеннек. Ак булсын, бүз булсын, диләр. Йәшелне дә кушканнар — *глз.*

**Үлек җыйу** *том.* үлгән кешене күмү.

— Мәликә мамай үлек җыйарга киткән.

### Үлек күммә

**Үлек күммә** *глз.* үлек күмәргә.

— Үлекне зыйаратка күммә илтәләр. Каршыларына бер айак---ка сикереп баручы шайтан очрый. Андан сорыйлар: «Ниге алай сикерәсин?» Ул әйтепте: «Мәрхүм андай гөнаһлы иде, айагым белән басмага ару йир тапмаймин».

### Үлек күмү

**Үлек күмү** *глз.* бисерманнар сөйләшендә (Тегермән авылы):

— Гыруп йасайлар. Гыруп йасагач йуwабыз мына бу куйкыга са---лып. Сунгырак кийындырабыз. Йуучысы бутан, гур индыручысы бутан, су тугучысы бутан. Гырупка салабыз, Гырубына миллык[1], ба---лакайсын[2] салалар баш аска . Тыры кышы кыбык. Сынгра йабабыз. Чыгартабыз ийалдыга. Икы кын, ыч кын кундырабыз ийалдында. Куршылар кила. Чыгарткач силашып утырабыз. Кутарып чыгарта---лар йолга кадар. Ирларга сыл’гы биралар, катыннарга ситса кычтик---мычтик. Йуган кышыга барын да биралар, кул’магын, бийалайын. Оч кон торгач аш италар. Тугыз конно, корок конно италар. Йыл йиткач йыл ашын уткаралар. Аш пышыралар, пугриҗмы[3], балыкмы куйалар ыстал’ ыстына. Чакырган кышылар ипи был’а килалар. Артында ба---ралар затып. Мин айакчу эстели[4] бардым анам үлгәч. Ийыбызда бик йабынгыч[5] булып калды.

[1] *Миллык* [< рус. веник] — себерке.

[2] *Балакай, бәләкәй* — мендәр.
[3] *Пугриж* [< удм.] — кыяр.
[4] *Айакчу эстели* — аякчу кигән килеш.
[5] *Йабынгыч* — күңелсез, ямансу.

### Үлекләр тота

**Үлекләр тота** *глз.* үлгән кешеләрнең рухы зыян китерә дип ышану.

— Зиратка исерекләр кергәләсә дә үлекләр тота. Садака бирмәгә кушалар.

### Үлек чыққан ызба

**Үлек чыққан ызба** *т.я.-к.т.* үлгән кеше, мәет чыккан өй.

— Үлек чыққан ызбаның тәрәзә элеңгеләрен қороп қуйалар. Ызба моңсуланып торорға тийеш.

### Үлдүкләр

**Үлдүкләр** *м.-кар.* үлгән кешеләр, аларның җаны.

— Үлдүкләр эчен дип түргә, тәре алдына ыстакан белән су куйа---лар, ипи, кашык куйалар. Ул аши була инде. Тәре алдында тора.

### Үлдүкләр ашы

**Үлдүкләр ашы** *м.-кар.* үлгән кешеләр өчен дип тәре алдына куела торган ашамлыклар.

— *Үлдүкл әр ашы* дип эчкен ашында куйалар да тугыз кенендә ала---лар, бүтәнне куйалар. Алты атнасына хәтле куйып тора. Анда ипи, су, кашык куйа. Анан сун ул ипиләрне очар кошларга бирәләр.

### Үлдүкләр keләwe

**Үлдүкләр keләwe** *м.-кар.* үлгән кешеләрне искә алу мәҗлесе.

— Карендәшләрне җәшәләр дә келәү җасилар, *үлдүкләр keләwe* була. *Үлдүкләр keләweнә* карчыклар җомортка, икмәк, тоз куйалар, пыдаука белән журна (бөртекле ашлык) куйалар.

[Ырым] *м.-кар.*:

— *Үлдүкләр keләweннән* калган әйберләрне, эскәтерне капкадан чыккач турыга селкиләр икән. Аны ычар кышлар, үлдүкләр аши инде.

[Тыем] *себ.*:

— Үлгән кешегә килтеңме — туры өйеңә қайт. Туғаныңа та кермәң, йарамайты — *төм.*

— Үлгән кеше төшеңә керсә, шабала[1] йә таштабақ[2] хәйер биргәле кирәк. Анта мәхрүм булып утыраты — *тевр.*

— Кеше үлсә, йылағалы тийеш түгел, таш йаңғыр булып йаwаты — *тара.*

— Қатым ашны өстәп салма, тағы өстәлеп утыраты. Икенце кеше үлеп қуйуwы бар. Мәйеткә йарамайты алай — *туб.*

— Күмеп килгән кешеләрне көтеп утырапыс сираттан килгәнен.
«Күснең нурын алып китәте», — тигәннәр — *том.*

**Үлгән кеше төшеңә керсә** *әстр.*:

— Үлгән кеше төшеңә керсә, қаберенә барып қазық қақ диде.

— «Бусағаңа бер чәйнек су қайнатып қой», — диде.
Бер чәйнек суны қойасың қайнатып бусағаңа, эссе су қойасың.

— Ишекне ачқанда ишекнең шыңгаларын[3] да ырымлайды эссе су қойоп, өч қатар бисмилла әйтеп қойады эссе суны. Аннан суң төшеңә иңмиде.

**Үлгән кешедән курыкса** *әстр.*:

— Үлгән кешедән қурыкса қабер өстенә аның күләгеен итеп йаба, тупыраҕ алып килә бер уч, шуны суҕа сала, қойона.

**Үлгән кешенең кийемнәрен урнаштыру** *әстр., себ.*:

— Бер зат да қалдырмыйбыз үленең, айақ басмас җиргә күмәләр — *әстр.*

— Әбәм (апам) үлгәндә кейемнәрен йуwып йиргә күмделәр. Көйдергәле (яндырырга) йарамайты — *том.*

[1] *Шабала* — кашык.
[2] *Таштабақ* — аш т әлинкәсе, аш савыты.
[3] *Ишек шыңғасы* — ишек күгәне.

## МӘЕТ ЮУ ӘЙБЕРЛӘРЕ

### Қабық

**Қабық** *урт.д.* юкә кабыгы; аны үлгән кешене юу өчен җайлап, улак сыман итеп эшлиләр.
— Кеше үлгәч қабыққа салып җуwабыз — *каз.ар.-блт.*
— Элек қабыққа салдылар. Қабыққа салҕан мәйет саwаплы була тей — *к.-уф.*

— Қабыққа салып җуабыз. Җуарға әзерләгәндә иңгелек қабықны кертеп салабыз. Ул қабықны эссе су белән пакләгәннән соң, мәйетне шунда салып шишендерәбез.
Әwәле шулай қабыққа салып җуалар ыйы, шулай бөтөн тәнен җуwабыз да ахирәт ғоселе[1] дип қойондырабыз — *бәр.*

— Элек җүкә қабыққа салып, алты кеше күтәреп бара торғаныйы зиратка — *т.кам.-крш.*

### Җеназа тақтасы

**Җеназа тақтасы** *урт.д.* — мәетне зиратка алып китү өчен эшләнгән җайланма.
— Зыйаратқа алып киткәндә бөгәлҗәле *җеназа тақтасына* салып алып китәләр. Аның өстенә чаршау йабалар — *каз.ар.*

### Тақта

**Ләхет тақтасы,**
**таба тақта, табут тақта,**
**тәбет тақта, әүле тақта,**
**үлек тақта** *себ.* мәет юу өчен әзерләнгән такта.
— Таба тақтаға салып йуwалар, таба тақтаға салып илтәләр қырбашқа.

— Ләхет тақтасына салып йуwатлар үлг ән кешене. Ләхет тақтасы диләр, шунаға салып сиратқа алып баралар — *том.*

[1] *Ахирәт ғоселе* — мәетне юганда соңгы тапкыр коендыру.

— Табут тақта булаты үлекне салып йуған. Табут тақта айақлы өстәл шикелле, өстәлдән тәбәшәк[1]. Табут тақтаны астанадан алып киләтләр.

### Салача тақта

**Салача тақта** *себ.* җеназа тактасы.

— Мәйетне салача тақтаға салып апкит әделәр, аны мән күтәреп алып китәделәр. Табут тақта өйтә қалаты — *тевр*.

### Сосқы тақта

**Сосқы тақта** *туб*. мәетне зиратка илтү өчен ясалган җеназа так---тасы.

— Мәйетне сосқы тақтаға салып қырбашка алып китәтләр. Үлекне күмеп қуйатлар. Ул сосқы тақта сиратта қабер өстендә қалаты, қалдырып китәтләр.

Тә беттақтаға[2] салып йуwалар, айақ очында тишеге бар, йуған суwы ағып тора. Әwәле ике тақтаны бергә бәйләүлейе, шаңа салып йуған.

### Үлек тақта

**Үлек тақта** *тара*. җеназа тактасы.

— Үлек тақтаны сыйаратта қалдыратылар. Үлек тақтаны сөйәп қуйарға йарамайты, аны йатқысып қуйатылар.

### Қолаша

**Қолаша** *төм*. мәет юу тактасы.

— Мәйет йуwа торган қолаша була, аңа тимер қаққаннар. Ти---мер өстенә йәймә йәйеп йуwасың, мәйеткә салқын булмасын өчен. Аны йуwалар, урынға салып кәбенниләр, ике йақлап күтәреп алып чығалар — *төм*.

**Колаша** *глз., минз*. мәетне салып юу өчен ясалган җайланма, ул кабыктан ясала.

[1] *Тәбәшәк* — тәбәнәк.
[2] *Тәбеттақта* — мәет юу өчен әзерләнгән такта.

— *Колашага* салып йуwалар, колаша бар йумага. *Колаша* астына чилак салалар, чилакка салам салган була чачырамаска — *глз*.

*Қолашаға* салып йуwабыз, қомғаннар, таслар бар. Мәйетне *қолашаға* күтәреп салабыз, чәчләрен сүтәбез — *минз*.

**Қолаша** *т.я*. мәетне күтәреп зиратка илтү өчен ясалган җайланма.

— Мәйет сала торған қолаша бар, қолашаға салып күтәреп китәләр. Алдан ике кеше күтәрә, арттан ике кеше күтәрә. Бераз барғач қуйалар, күтәреп баручылар алмашына, ченаза уқыйлар — *т.я.-к.т*.

### Әрчә

**Әрчә** *себ*. җеназа тактасы; әрҗә.

— Әрчәгә салып аппарасың сиратқа , айақ белән чығаты өйтән. Қырбашқа[1] барғанда баш белән баратлар — *тара*.

### Дуска

**Дуска** [рус.] *глз*. мәет юу өчен җайланган такта.

— Калын дуска була үлек йу wа торган, анда салып йугалаганнар. Дуска ул зират өйөндә тора, кем ки үлсә китерәләр.

### Қомған

**Қомған** — тоткалы һәм борынлы кувшин сыман савыт. Комганнан су коеп мәет юу саваплы дип әйтелә.

— Ике кеше йуwа, ике кеше қомғанға су сала. Ике кеше фәрдә тота, үлекнең өстенә. Аны йуwып бетергәч кәфенниләр, йуғанчыға қадәр бөтен туғаннарына күрсәтәләр.

### Хәләмпер

**Хәләмпер** — канәфер.
**Хәләмпер сибү** *әстр.* мәетне югач, хуш исләндерү өчен канәфер сибәләр.
— Үлгән кешене йуwалар, арулыйлар, хәләмпер сибәләр.

[1] *Қырбаш* — зират.

## МӘЕТ ЮГАНДА КУЛГА КИЮ ӘЙБЕРЛӘРЕ, ӨС КИЕМНӘРЕ

### Бийәләй

— Бер кеше *бий әләй* биргәләп тора йуучыларга. *Бийәләй* белән йуwалар ич. Әминә аппак[1] бийәләй биргәләр инде, ул булдырса, үзе үлмәсә миндән алдантын — *глз*.

### Қулғалта

**Қулғалта** < *қул + ғалта, қалта төм*. бияләй.
— Әwәле қулғалталар әсерләп қуйылаты. Мәйетне йу wap wақытта тегеп йибәргән. Ошо йиргә бәйләп қуйған. Бәйләмәсәң, ул бушаныр китәте. Баулы итеп тегеп беләккә бәйләп қуйған.

### Қулғап

**Қулғап** < *қул + ғап, қап тара*. бияләй. Мәет юганда киелгән бияләйне ташламыйлар, аны ырымлы дип саныйлар: сызлаган аяк---кулны төзәтә һ.б. очракларда ярдәме тия, диләр.
— Қулғап тегәте түртне. Мәйетне йуған қулғап белән сыйыр имчәкләрен йышаты[2] чешеп китсә. Айағың сыслыймы, ул қулғапны кейеп қуйаты.

### Қулғапчық, қулқапчық

**Қулғапчық** < кул — ғап + чық,
**Кулқапчық** < кул — кап + чык *себ*. бияләй.
— Қулның тискәре йағына су салып қулыңны йуwып аласың, қулғапчық кийеп йуwасың — *бараба*.

— Қулқапчық кейеп йуwабыз мәйетне. Сабынны алдан күбек---ләндереп қуйабыз. Қулқапчықны элеп қуйатлар, киптерәтләр. Сыйыр җилене шешсә шул қулғап белән ышқыйтылар. Пайдасы пулаты — *тара*.

[1] *Аппак* — апа.
[2] *Йыша* — сөртә.

### Сапуннық

**Сапуннық** < сапун — рус. запон + -нық *төм*. мәет юганда кию өчен әзерләнгән алъяпкыч.
— Сапуннықларны, қулғапларны үсепес әсерләп қуйабыс.

### Селте сабын

**Селте сабын** *себ*. үзлә ре кайнатып ясаган сабын. Мәетне «селте сабын» белән юу саваплы, дигәннәр.

### Селте сабын йасау

**Себер диалектларында:**

— Селте сабын йасап алатылар ыйы. Пичнеңке көлен иләк белән он иләгән шикелле илисең. Сур қазанны утыртасың чоғыр қазып. Иләгән көлне су қойоп қасанға саласың, қайнатасың сап-сары булып суwы сарғайғанға хәтле. Сыwын сөзәсең, тонықтырасың. Тап-таса тоныққан сыуға иске сөйәкләрне йыwып-йыwып саласың, бик озақ итеп қайнатасың. Сосоп алып тағын көне буйы қайнатасың, қуйы булып чығаты қур[1] шикелле. Таса чүперәккә ақтарып[2] эссе көйенә әwәлиләр — *тара*.

— Сабынын күздән аwырып йөргән кешеләр сорап алалар дуwа қылып. Йортта қалдырмайдық — *бараба — Шагир*.

— Йыwан қасанта көл қайнатабыс. Ул көл қайнатқан сыуға кән[3] сөйәкләрне салып қайнатабыс. Ул қуйырылаты қайнай-қайнай. Аны түрт мийешләп[4] сабын қылатық. Селте сабын қылғаннар алай итеп.

[1] *Қур* — камыр.
[2] *Ақтарып* — аударып.
[3] *Кән* — барлык.
[4] *Түрт мийешләп* — дүрт почмаклап.

— Порон саманта калкус пулмастан алта сапын қайнату пул---ты. Қөлне иләйтеләр көлиләк[1] мән. Астына төшкән тап-таса көлне қайнатып-қайнатып, су сарғайып алса, әкеренләп сөсөп, тыныктырып куйатылар. Сөйәкләрне йуwып-йуwып, тасартып, әлеге тыныққан таса селте суға салатылар, қайнататылар. Өстеннән майын сөсөп алып әлеге майын қайнататылар, өстеннән йийып алып әлеге қуйысын тағын қайнататылар. Ул үсе қуйыраты. Аны йомарлап-йомарлап қуйатылар wақ-wақ қылып, посауцық тип, кецкентәй тип. Үлгән ке---шене селте сабын ман ғына йу wатылар, саwаплы тип. Хәсер инте йис---ле сабыннар бар, йисле сабын ман йуwалар — *тара*.

## Мәетне юу, күмәргә әзерләү

Жирле сөйләшләрдә үлгән кешене юарга су алып кайту, юу, юган суны түгү белән бәйле күп кенә ырымнар, ышанулар һәм шуларга ка---раган сүзләр, гыйбарәләр сакланып килә. Түбәндә шуларга караган мәгълүматлар китерелә.

## Су алып кайту

### *Әстерхан сөйләшендә үлгән кешене йуwарга су алып кайту*

— Кешене йуwарга ике бидерә (чиләк) су алып қайта, **исәнләшми** кеше белән, йаулықлар бәйләп чиләк өстенә, қаплап алып килә.

Қойаш туар-тумаста ике жиңгә ике чумалақ[2], ике чиләк мән суға китәтләр. Суны қойаштан алда чайқап-чайқап алмаға тийеш. Боронғылар шулай эшләгән. Ақ мата[3] белән суның өстен җабып алып килеп қуйатылар. Қойаш туғанчы[4] дип ашығып таза су алып қайтатылар.

Биш кеше, жиде кеше йуwабыз үлгән кешене. Суны үзебезнең үзәктән, йағадан алып қайтабыз. Өч чиләк белән китәбез. Бер зур тәтә уқый. Сүләшмичә, чиләкнең өстен ақ мата белән йабып су алып қайтабыз, бисмилланы әйтеп алабыз.

[1] *Көлиләк* — көл иләге.
[2] *Чумалақ* — чүмеч.
[3] *Мата* — тукыма.
[4] *Қойаш туғанчы* — кояш чыкканчы.

### *Пермь сөйләшендә су алып кайту*

— Кийәнтәләп ақайта, бидерәне қыйбла тарафына қаратып суны ала. Су алып қайтқан кешегә йаулық бирәләр — *перм*.

— Қойаш туғанчы сәғәт йарым элек салаwат әйтеп, су алып қайтабыз. Су ағымына қаршы алабыз суны бидерә-күwәнтә белән — *перм*.

***Урта Урал (к.-уф.) сөйләшендә су алып қайту***

— Мәйет йуwарға сыуға ике кеше бараң. Бер кеше *көйәнтәләп* китерә, берсе *сыңарлап*. *Өс бидерә* сыу булсын мәйет йуwарға.

***Мәйет сыwы***

**Мәйет сыwы** *к.уф*. мәет юарга әзерләнгән су.
— Хәзер өс бидерә сыу китердек исә *мәйет сыwы* булыр, өс бидерә белән йөремә, диләр ийе.
— Кийәнтәләп ақайта. Чырақ[1] булса да сала суwына, бидерәне қыйбла тарафына қаратып суны ала.

***Тау ягы сөйләшендә су алып қайту***

— Күwәндәле чиләгеңне асып чығып китәсең. Чиләкләреңне өч қат чайқисың, уқыйсың, чиләгеңне тутырасың, бер чичта җиргә генә қуйасың.
Суны сөйләшмичә алып қайталар. Киткәндә дә, қайтқанда да бер сүз дә сөйләшмиләр.
Су алырға барғанда **камил тәһарәтле** булырға кирәк. Ике кеше бара.
Бисмилла әйтеп алырға, чиләкләреңне салфиткә белән йабып алып қайтырға. Шулай алып қайтасың да су җылытқан wақытта қапқач йабарға йарамый, парланып тамчы тамарға тийеш түгел.
Су өстенә бисмилла әйтеп арқылы бер ағач — уқлаумы анда қуйасың. Комғаннарыңны да өч қат җақшылап чайқап қуйасың — *т.я.-к.т*.

— Ике күwәндә белән ике кеше барып дүрт чиләк су алып қайталар мәйет йуwарға. Мәйетнең аның қат-қат йумаллысы да була, чичта---сы да була. Шунарға күрә дүрт чиләк су алып қайталар. Ике чиләген җылытырға қуйа, ике чиләге торып тора. Шуны қушып, қомғанга су салып, биреп торалар **су бирүчеләр —** *т.я.-к.т*.

[1] *Чырақ* — чыра.

— Су алып кайтқанда теләк теләп қайтам:

Кәүсәр чишмә буйларында
Утырырға насыйб ит.
Кәүсәр чишмә суы белән
Шушы мәйетне пак ит.

Әһлем иман, әһлем нур,
Әһлем ислам, әһлем нур.
Әһлем қоръән, әһлем нур,
Әһлем җәннәт, әһлем нур.

Лә илаһе илаллаһ,
Қабрем эче тулсын нур,
Лә илаһе илаллаһ
Гөнаһларымны ғафу қыйл — *т.я.-к.т*.

***Нократ сөйләшендә (глазов урынчылыгы) су алып кайту***

— Кем булса да үлсә ки, *койаш туганчы* йумага су китерәләр. Кой---аш чыккынчы китерәләр *үлек йуwа торган суны*.

### *Себер диалектларында мәет юарга су алып кайту*

**Көн цыкмайын, көн цыкмастан су алып кайту** *туб.* кояш чык---канчы су алып кайту.

— Таң башы белән көн цыкмайын[1] сыу алып қайталар. Аны йылым---ца итеп йылытатлар, пәтрәле[2] суға берәр митер питйаулық[3] йабалар.

— Көн цықмастан[4] суны алып қуйғалы кирәк. Мәйет йуғалы суны алай көн цықмастан алалар, таң суwы дип. Алып қайтқанда уқ өстенә йабып алып қайталар — *тара*.

— Өц кеше китәте сыуға. Аны тойоқлап йылытатылар. Сыуны өстенә йабып алып қайтатылар көн цықмастан элек. Утырып тәсбих тарталар сыу алып қайтқан сун — *туб*.

[1] *Көн цықмайын* — кояш чыкканчы.
[2] *Пәтрә* — чиләк.
[3] *Питйаулық* — сөлге.
[4] *Көн цықмастан* — кояш чыкканчы.

### *Суны иман әйтеп, дога укып алалар*

— Суны алып өстен йабып алып қайттық. **Иман әйтеп, уғып алғалы** қушайды муллабыс. Бер бәдрәсен[1] йылытып қуйайдек, бер бәдрәсен суыққа қуйайдек — *том*.

**Суны салаwат әйтеп, айателкөрси әйтеп алалар, тәкбир әйтеп кайталар**:

— Суны йапқалы йаулықлар алып барасың. Салаwат әйтеп барасың. Сосоп аласың, айателкөрси әйтеп суны йабасың. Қайтқан чақта өйгә йиткинцә тәкбир әйтеп қайтасың, сөйләшмисең, күрешмисең — *туб*.

— Су алғанда айателкөрси уқып алабыз:

«Ахирәт т әһарәте алмаға,
зәхмәтләр ийәрмәсен», — *перм*.

### *Керәшен сөйләшләрендә мәет юарга су алып кайту*

— Кеше үлә инде менә. Өч чиләк белән суга китәбез. *Өч чиләкләп су* алып кайтабыз да ул суны җылытабыз казанга салып. Аннары шул су белән җуабыз кабыкка салып. Әйбәтләп эчке күлмәк кигертәбез, тыш---кы күлмәк кигертәбез, айагына ойок кигертәбез, наски кигертәбез, чүбәк кигертәбез. Ул көнне кундырабыз, төне буйы саклыйбыз — *т.кам.-крш*.

— Агым судан *ырымчаклап* (ырымлап) алалар суны үле җуwарга — *т.я.-крш*.

### *Су алырга барганда таба тимере (әд. табагач) тотып төшәләр*

— Җуwарга су алырга киткәндә *таба тимере* тотоп төшәсен, өч кеше китәләр су алырга, икәү генә булса *таба тимере* алып китәләр — *т.я.-крш*.

### *Тегәрҗеп, үле тегәрҗебе белән ырымлап су алып кайту*

— Су ыңгайына җепне круслап куйып, шаннан су алалар үле җуарга, агым судан ырымчыклап алалар суны. Суга киткәндә *таба тимере* тотып төшәсен, *тимер көрәк* тотарга. Су ыңгайына агызып җибәрәләр *тегәрҗепне*.

[1] *Бәдрә* — чиләк.

«Аның җулы чиста җул булсын», — дигән сүз — *т.я.-крш*.

— *Өч бөртек тегәрҗепне* су алгис, киндер җапкис, киндер өстенә дә куйып акайталар. Ул *тегәрҗеп ырымлы* була. Бер кешенең әйбере җугалса, шул тегәрҗепне өстәл айагына бәйләп куйа. Урлаган кешенең айагы-кулы бәйләшә, акилә дә куйа ырлаган әйберен. Аны өч тапкыр кирегә түнәп-түнәп бәйлиләр өстәл айагына. Эче поша ди урлаган кешенең. Үле тегәрҗебе китереп бәйләдем дә китереп мендәр астына куйган урлаган әйберен — *т.я.-крш*.

## Су аныкълаучы

**Су аныкълаучы** *нокр*. мәет юарга су әзерләүче.

— *Су аныкълаучыга* бирә, кем ки аныклап тора, акчалаймы, читсы---лаймы бирә. Әлфийә су аныклар, дип әйтеп куйдым.

## Сигеd оҗмах суы

**Сигеd оҗмах суы** *минз*. мәет югaнда әйтелә торган гыйбарә.

> И раббым солтаным,
> Сән җараттың бу мәйетнең үdeн.
> Сигеd оҗмах суы белән
> Җуа күрегеd җөdөн (Тәйсуган).

## Су салып торучы

**Су салып торучы** *т.я.-к.т.*:

— Мәйет йуганда су салып торучы була. Анарға *су тустыганы*[1] бирәләр. Ул тустыганга кайсы он, кайсы камфит салып бирәләр.

## Су биргән кеше

**Су бирү** *әстр*.:

— Берәү су бирә, су биргән кешегә айак кийеме тийешле. Йуганда җидәү, йә бишәү булады, җуwындырасың, тәһлил әйтәсең.

**Су биреп тору** *кузн*.:

— Эч кеше су биреп тора, эч кеше былгап тыра, ишег ашали, чар---шау ашали гына бирәләр суны — *кузн*.

**Су җылытучы, су бирүче**:

— *Су җылытучы* айырым була, *су бирүче* айырым була.

## Тастар башы тоту

**Дастар** < фарс. **баш тоту** *глз*., **тастар башы тоту** *каз.ар., бәр*. мәет йуганда аның өстендә җәймә тотып тору.

— Дүрт кеше *дастар баш тота* дүрт сирэктин, кешеләр багыш---масын.

— Дүрт кеше йуwалар исе ке *дастар баш дыталар*. Үлдең ки, йумага кирэк. *Дастар баш тыттым* мин йуганда.

— *Дастар баш тотарлар* нәсел-тамырларым: Минсылу, Мөнирә, Әлфийә, Фәрзийә килен.

**Тастар башы тоту бар.** Мәйетне җуа башлаганчы тастар башын тоталар, суын биреп торалар, укып, салаwат әйтеп — *минз*.

— Дүрт кеше дүрт баштан тастар башын тоталар. Өй кечкенә булганда тастар кирәк. Тастар ул җука гына ак келинкур. Без тастар астында җуабыз мәйетне. Андары тастарны алып, ахирәт госеле койондырабыз.

Тастар башы тотарга кайсы кеше әйтеп калдыра: «Мин үлгәч син тастар башы тотарсың», — дип. Әйтеп калдырмаган булса, үзебез әйтәбез олорак кешеләргә.

Тастар башы тотқан кеше мәйеткә күз төшереп тә қарамый, тәртипле булырға тийеш. Мәйет ул бик ойалыр ди.

Тастар башы тотучыларға җаулықлар, тастымаллар бирәбез.

«Монсо тастар башы тотқанға» дип әзерләп қуйабыз тастымалны җә җаулықны.

Ул тастарны җуып, әзерләп қуйабыз, икенче мәйет җуғанда кирәк булыр, дип — *бәр*.

## Пәрдә, фәрдә тоту

**Пәрдә тоту** *к.-уф.* үлгән кешене юганда өстендә җәймә тотып тору.

**Пәрдә чепериге** *к.-уф.* мәет өстендә тотып тору өчен әзерләнгән җәймә.

— Пәрдә тоталар дүрт кеше, сабыннап тороп йыwалар, мәйет қызарып, ыспайланып кит ә wы. Қабыққа салып йуwалар, йалғашы була. Берәү су сала, берәү йуwа. Пәрдә чепериге була, читтән кеше қарап тормасын.

## Фәрдә тоту, чымылдық тоту

**Фәрдә тоту, чымылдық тоту** *төм*. үлгән кешене юганда өстендә җәймә тотып тору.

— Ике кеше фәрдә тота үлекнең өстендә.

— Чымылдық тоталар йуған чақта.

## Мәет юучылар

**Боручы** *глз*. мәетне әйләндерүче.

— Дүрт кеше боралар мәйетне. *Боручылар* була. Әйтеп, йазып куй---дым: Әклимә, Мәдинә кодагый, Йофарбикә, Рәхимә — алар борырлар мине йуганда.

**Йуучылар** *әстр., чпр., влгг.*:

— *Йуучыларга* йыл коранында йаңа нәлбәккә (тәлинкәгә) пылау салып, қашық салып җибәрәләр, ул шунда қала, кире бушатылып қайтарылмый.

Ул инде мәйетнең, үлгән кешенең ашайақ заты була.

— Элгәре йуучыларга үзе бәләгән өц кийем ойок-барига[1] бирергә тийеш булган — *чпр*.

**Йуучы** — биш кеше булады.

— Чаршау астында гына йывабыз мәйетне. Ун кеше була. Су салу---чы, комган биреп торучы, йывучылар. Шул ун кешене бәхилләтәбез, күлмәкләр бирәбез — *влгг*.

**Җуучы** *минз.*:

*Җуучыларға* шуны әйтәм
Таман булсын җуар суығыз.
И қардәшләр шуны әйтәм
Тәһлил-тәсбих белән җуығыз.

[1] *Ойок-барига* — оек-бияләй.

**Зудацы** *күрш.*, **җудацы** *баст*. мәет юучы.

— *Зудацыларны* тегәндисен инде, бирәсен күләкләр и акца. Түтешемә бирдем, түтешем зуды кан□н□ам үлгәцен — *күрш*.

— Җидесендә җуған кешеләргә күләкләр бирәләр, ә кем инде төп *җудацы*, ағары инде баштин-айак бирә, наски ды бирә, күләк тә, битенә җапқан чеперәген дә бирә — *баст*.

— Кеше үлгәч жума керәләр. Карындашлары, тәтәләре, дәдәләре жуа, җат кешене қуймайлар бит жума — *баст*.

— Җидесендә *җудацыларны* чақыралар, наски, майкы бирәләр — *баст*.

## Мәйет йуwар қортқайақлар

**Мәйет йуwар қортқайақлар** *төм*. мәет юучы карчыклар.

— Мәйет йуwар қортқайақлар киләте. Берәү суны җараштырып тораты, берсе суны қойоп тораты, берсе қушып тораты.

**Қул йуу** *бараба*.:

— Қулның тискәре йағына су салып, қулыңны йуwып аласың.

**Мәйет йуу** *минз*.

«Нийәт қылдым мәйеткә ғосел қойондырмағ өчен»,

— дип әйтеп җуа башлыйбыз. Уң йағыннан торып, йуwа баш---лыйбыз. Бөтен тәнен җылы су белән чылатып чығабыз, сабын белән җуабыз, мәсих тартабыз.

**Су җылытучы, су бирүче** айырым була. «Қабер өлгерде» — дип әйтәләр дә без мәйетне җуа башлыйбыз.

### Мәйет йуу

— Йуғанда өч кеше. Берәү қомғанға су қойа, берәү йуwа. Күтәргәле бер кеше кирә. Йуғалы башлаған чақта уң йағыннан тороп сул йағы белән башлайсың. Перәү су қойаты, ике қортқайақ ике йақтан йуwаты — *төм*.

перәwе — **сыу йараштырып торатқан**,

перәwе — **сыу қойоп торатқан**,

перәwе — **йыwып торатқан қортқайақ булаты**.

### Ахирәт ғоселе, камил тәһәрәт

Ахирәт ғоселе, камил т әһарәт алдыра жуып бетергәндә.

«Илаһи нийәт қылдым ахирәт ғоселе қойындырмаға.

Илаһи үзең рәхмәтең wә кәрамың белән қабул қыл, ошбу бәндәнең белеп қылған, белми қылған гөнаһларын қабул қыл, тулы җәннәтләреңә насип қыл», — дибез — *минз*.

— Мәйетне йуwып бетергәц, иң ахырдан ахирәт госеле кийынды---рабыз.

«Илаһи нийәт кылдым
Ошбу бәндәне ахирәт госеле
Кийындырмакка», —

дип әтәбез.

Буйдан-буйга өц мәртәбә су салабыз. Ару паклап кийындырабыз, бусы ахыргы госеле була.

«И адәми сөннәти,
Бул Мөхәммәт өммәти», —

дип әтәләр мәйетне госел кийындырганда — *чпр*.

Аннары өстөнә *тән киптергец* йәйәбез, зур йәймә белән тәнен киптерәбез — *чпр*.

— Илаһи раббым,
Ошбу қолыңны
Үзеңнең хозурыңа барырға
Ахирәт ғоселе қойондырмаққа әзерлибез.

Аллаһы тәғалә җиңеллекләр бирсен — *каз.ар.-мам*.

### Мәйет йуган кешене ризалату, кийем бирү

— Кем йуған, әйбер бирәтләр, таwарлай[1] бирәтләр, йышым[2], калу---ша[3] бирәтләр — *төм*.

— Мәйет йуған кешегә көйләклек[4] бирәтләр — *төм*.

— Мәйет йуған кешегә қайсына чөлкә (оек), қайсына рубашка (күлмәк), қайсына башқа кийем сала.

[1] *Таwарлай* — тукыма, ситсы көенчә.
[2] *Йышым* — оекбаш.
[3] *Калуша* — галош.
[4] *Көйләклек* — күлмәклек.

«Үле йаланғач булмасын, қыйәмәт көнендә йаланғач қупмасын», — дип — *әстр.*

— Йуучыларға читсымы, күлмәклекме, чүпләмәме (сөлге) бирә---ләр — *т.я.*

— Йуwарга биш-алты кеше керә. Аларга зурлак әйбер бирәләр, күлмәк тә бирәләр, тапычка да бирәләр. Эрәддән эләшәләр кулйаулы---клар — *срг.*

— Мәйет йуған кешегә йышым (оекбаш), калуша (галош) бирәтләр, көйләклек бирәтләр — *төм.*

— Мәйет йуғанда җиде қарчық йасин уқыйлар. Ул җиде қарчыққа йасин уқыған өчен җиде баш йаулығы бирәләр — *т.я.-к.т.*

**Үлгән кешенең киемнәрен урнаштыру**

— Әбәм[1] үлгәнтә кейемнәрен йуwып йиргә күмтеләр. Көйдергәле[2] йарамайты — *төм.*

— Үленең кийемнәрен, карасын тиз генә йуwалар да җан чыккан---нарын мазарга алып китәләр, тишегенә (каберенә) күмеп куйалар — *т.я.-крш.*

**Мәйет йуған су, үле суwы**

Мәет юган суны түгү бик ырымлы, аны кеше аяк басмый торган җиргә чокыр казып, чокырына тимер әйбере салып («ийәләнмәсен» дип) күмәләр.

**Мәйет йуған суны түгү**

— Балчықны қазалар да *кеше басмаған җиргә түгәләр.*
«*Тимер салып қуйың*», — тиләр. Кем басса да қағылмас, суғылмас ти — *к.-уф.*

[1] *Әбәм* — апам.
[2] *Көйдергәле* — яндырырга

— Мәйет йуған суны тимер салып күмеп қуймаға қуштылар инде. Теләсә қайа чәчкәләмәгә йарамый аны. Бисмилла әйтеп күмәсең — *перм.*

— Мәйет җуған суны *қойаш байышына, чичта урынға түгәләр* — *т.я.-трх.*

— Җуған суларын бер җантыққа күмәләр, қайа булса да *айаг асқа түгел* — *баст.*

**Себер диалектларында мәйет йуган суны түгү**

— Қыбыла йаққа қарап, песмилла әйтеп түгәсең сыуны, кеше йөрми тоған йиргә бер чоқырға қойғалы кәрәк. Суга **тәмерме, қазақмы ташлап** күмеп қуйа — *бараба.*

— Йуған суны кеше йөрмәй тоған йиргә тесмә итәктә (читән буена) генә түгәсең, қоршаған қойма төбенә генә. Кеше йөритегән йиргә йа---рамай түгәргә — *бараба.*

— Йуған суны ура (чокыр) қасып, мал, бәндә айак басмас йергә кой---оп, өстөнә песмилла угынып тәмер (тимер) ташлады. «Тәмер салсаң, ийәләнми[1]». Кеше басса аwыру алырға мужыт — *бараба.*

— Қайда ды кеше йөрмәс йиргә түгеп, бесмилла әйтеп тәмер салып күмәде мәйет йыуған сыуны. Синәкме сынған, иске балтамы, күбрәк сынған синәк салады — *бараба.*
**Мәйет җыйған су** *перм.* мәет юган су.
— Мәйет җыйған суны қадақ салып, бер чоқырға күмеп қуйалар.

### Үле суwы

**Үле суwы** *әстр*. — мәет юган су.

— Үле суын электә чоқыр қазып әүләдә (ишек алдында) күмә булғаннар, хәзер инде үлеккә (зиратка) китеп түгәләр.

Үле суын үле белән бергә алып китәләр, анда қоршап қуйылған.

«Үле суы ул бик җәберчән су[2]»,

— диләр. Зыйан итәсе килг ән кеше балчығы белән шул суны алса, нинди зыйан итәсе килсә дә зыйан итә диләр.

[1] *Ийәләнми* — җенләнми; пәри-җен килми.
[2] *Җәберчән су* — зыянлы су.

«Үле суыннан килгән зыйан ул бер дә қайтмый торган зыйан», — дип төшендерде мулла бабай.

Табытқа салып йуwындырабыз. Йуwындырған суны ару йиргә түгәбез. Йөрми торған йиргә, чәчә дә торған, йөри дә торған йир бул---масын — *әстр*.

### Су түгүче

**Су түгүче** *нокр*. мәет юган суны түгүче.

— *Су түгүчеләр* йуған суны анда-монда табылмасын дип қа ки урынтын, қа ки қайбан йөрми, андайырақ урыннарға түгәләр. Йофарбикә су түгәр дип әйттем.

## ГРОБ, ТАБУТ, ТУБЫК

### Гыруп

**Гыруп** [< рус. гроб] *крш., глз*. гроб.

— Гырупқа салып күмәләр безнең керәшеннәр — *т.кам-крш.*

— Гырубына балакайсын[1] салалар, кайын мил□л□ыгы салалар — *глз.*

### Табут

**Табут** сүзе 13 йөз язма истәлеге «Кыйссаи Йосыф»та кулланылган:

Ул сиддиқның табутини хазир қылди, —
бер хуш йирә аны мәдфүн қылур имди.
Аннан аңа табутын ә зер кылдылар, —
Бер хуш урынга аны күмәрләр имди.

**Дабут, табут** [< гар.] *әстр., крш., м.-кар*. христиан динендәге татар---лар һәм әстерхан татарлары мәетне табутка салып күмәләр.

[1] *Балакайсы* — мендәре.

— *Табутка* кайын миллеге җәйәләр, баш астына чабыр үләне белән мендәр җүләгәннәр — *т.я.-крш.*

— Үлгән кешене *табуты* белән алып чығып әүләгә[1] салалар. Мулла коран укый. *Табутны* тиз-тиз алып китәләр — *әстр.*

— Мәйетне чығарғачтын *табутқа* салып күтәреп әкитәде үлек өстенә[2]. Муллалар уқыйды — *әстр.*

## Табут түгәрәге

**Табут түгәрәге** *әстр.* табут өстенә ябу өчен кирәкле әйберләр.

— Табут түгәрәгенә дип әзерләп қуйған затым[3] бар. Алар үле түбәгә[4] ике йул барып қайттылар инде.

— Күршем табут түгәрәгенә дип ақ йулақлы[5] бер шыт[6] бирде. Қыз баланы шуның белән җибәрәме кеше. Мин үземнекен биреп қуйдым. Бирергә кирәк иде йәшелне.

Мин үземә йәшел адийал алып қуйдым табут түгәрәгенә, гөлле бизәкле шәл алып қуйдым. Өстемә йаптырғым keләде.

## Әстерхан сөйләшендә табутның өстенә ябу ырымнары

— Қәрдәшләре җиде җабу җабалар үлек өстенә, әрү затлар җабалар. Җидесендә шуларны өләштерәде җуғаннарға, җир қазған кешеләргә, муллаларға.

— Табутның өстенә *махмал* (бәрхет) *йабалар*.

**Қызыл төс — йарамый:**

— Табут өстенә *қызыл төслене йапмый*. Қызылны табутқа йап---са — балаларда *қызылча күп* була — *әстр.*

**Күк төс — йарамый:**

[1] *Әүлә* — ишегалды.
[2] *Үлек өсте* — зират өсте.
[3] *Затым* — әйберләрем.
[4] *Үле түбә* — зират.
[5] *Йулақлы* — йуллы.
[6] *Шыт* — ситсы.

— *Күкне йапса* — балаларда *күк йүтәл күп була*.

**Сары төс — йарамый:**

— *Сарыны* йапса — сары аwыруы була — *әстр.*

**Йәшел мата** (тукыма) **йабалар**:

— Ике-өч митыр йәшел зат[1] алалар йабарға. Аны җил белән очып китмәсен дип, тәрәт йаулық (сөлге) белән бәйлиләр.

«Без үлгәндә йәшел зат (әйбер) йабың», — диделәр.

Табут өстенә йәшелне йабады, қызыл, күк, сары йарамайды.

— Табут өстенә шәл йабатылар, йәшел мата. Алып бара йатқанда белеп торалар, иркәк[2] бара йатырмы, хатын-қызмы — *әстр.*

**Мәетне табутка салгач үтәлә торган ырымнар:**

— Кыруг сызалар балта белән, *табутны* өч тапқыр әйләнеп чығалар, қойаш чығышына балтаны ырғыталар — *нгб.-крш.*

— Таwық сикертү була. Тере таwықны *табут* арқылы сикертәләр эч тапқыр. Аны йаңғыз ғына торған бер җитем әбигә бирәләр — *нгб.-крш.*

**Табутқа үлгән кеше янына ашамлык куйу** (керәшеннәрдә).

**Кәлбә** *т.кам.-крш.* хәлвә.

— Кәлбәне мәйет озатасы көнне пешерәләр, майға он, бал салып. Аны әркемгә аwыз иттерәләр дә бер кечти төйенчек белән үлекнең култық астына, табутка куйалар.

«Үлеләргә өләшергә»

**Умач** *каз.ар.-крш.* көнбагыш мае белән оннан ясалган умач, аны табутка куялар.

— Кеше үлгән көнне айбағыр майы белән оннан умач уwып, аны бер кечти җанчық белән үленең қултық астына, табутқа қуйып җибәрәбез.

## Тубык, тәбет

**Тубык** [< гар.] *т.я.-крш.* табут.

— Үлене тубыкка салалар кийендереп, мазар эстенә[3] алып китәләр. Тишек[4] йанына тубыкны куйалар ике тәнкәл[5] эстенә, җиргә куйми---лар.

[1] *Зат* — әйбер.
[2] *Иркәк* — ир кеше.
[3] *Мазар эсте* — зират өсте.
[4] *Тишек* — кабер.
[5] *Тәнкәл* — урындык.

— Үлене бар да карилар тубыкка салгис, айагын тоталар үленең.

«Куркызма», — дип. Тубыкны тишеккә тыккис та бар да тупрак салалар тубык эстенә:

«Куркызма, бакиллә», — дип.

**Тәбет** [< гар.] *кузн.*, **тәбут** *тмн.* — мәетне салып зиратка илтә тор---ган җайланма.

## Кәфенлек

**Кәфен** [< гар. мәет күлмәге].

**Кәфенлек** — кәфен тегү өчен әзерләнгән тукыма. Җирле сөйләшләрдә бу сүзнең түбәндәге фонетик вариантлары бар:

**Кипеннек** *әстр.*, *нгб.-крш.*, **кифенлек** *лмб.*, **кифеллек** *баст.*, *күрш.*, **кифеннек** *срг.*, **кәфеллек** *каз.ар.-дөб.* кәфенлекнең төсләре: **ак таwар, йәшел таwар**.

**Кәфеннек** *минз.*:

— *Кәфеннекләрне* алдан алып қуйған иде инәм. Ул ғомер теләп тора икән, дийә иде. Ап-ақ ташлы чишмә чылтырап аға, чишмәгә ба---рып, кәфеннекләрне чәйкап киптереп, чәйләр қайнатып эчеп қайталар иде — *минз.*

**Кәфеннек** *к.-уф.*:

— Умбер-унике митыр кәрәк қатын-қызларға кәфеннек. Хәзер текмейләр, шу[w] көйе генә салалар. Иңе тар була икән, өсте-өстенә салалар да сормап қына қуйалар. Хәзер шулай үрәнделәр. Анда тегә башласаң күп тегәргә кәрәк.

*Кәфеннеге, ақ бүзе* мул булса, айақ йөзлегеннән итәбез — *к.-уф.*

**Кәфеннек** *т.я.-к.т.*:

— Үз қулың белән, үзеңнең хәләл көчең белән алған кәфеннекләр үзеңә гумереңне озынайтып тора ди, ғомер теләп тора ди. Шуның өчен кәфеннекләрне, үлемтек әйберләрен җиренә җиткереп әзерләп қуйарға тырышабыз.

Кәфеннекләре булмаған кешеләр дә булған әwәле. Ат җабуына төргәннәр дә күмгәннәр — *т.я.-к.т.*

**Кәфеннек** *себ.* кәфен тегү өчен әзерләнгән тукыма.

— Кәфеннекнең **эчке қаты йәшел, тышқы қатын ақтан** әзерлибез. Марлыдан саwап ти.

## Кәфеллек

**Кәфеллек** *бәр.* кәфенлек.

— Мәйетне җуа башлыйбыз, тәһарәт алдырабыз, аwызын, қулларын җуабыз, башына **мәсих қылабыз**, қойондырабыз. Аннан мәйетне **кәфеллеккә** салабыз.

— «Қызым, әбийеңнең кәфеллеге җуқ», — ди әни. Көн сайын ун чақырымға урманға барып, бер чиләк қура җиләге җыйып қайтыр ыйым. Әни әйтер ийе: «Ул җиләкне сатып, әбийеңә кәфеллек алып қуйарбыз. Минем үземнеке дә җуқ кәфеллегем», ди, үлеп китсәк ди. Шулай җиде кила кипкән җиләк сатып кәфеллекләр алып бирдем әбигә дә, әнигә дә.

«Кәфеллеге әзер торса, кеше озын ғомерле була», — дигәлләр.

## Кифен көйнүк

**Кифен көйнүк** *том*. кәфенлек күлмәк.
— Кифен көйнүк кийертәләр мәйеткә.

**Кәбен, кәбеннек**

**Кәбен, кәбеннек** *туб*. кәфен. Ул яшелдән булса саваплы, диләр.
— Кәбен йәшел булса — оллы саwап, қортқайақларға йәшел йаулық булса — оллы саwап. Йәшелдән қылу — әшкәрә оллы саwап. Ике рәт кәбен урыйсың, йәшел йаулық йабындырасың — *туб*.

— Кәбеннекне[1] баш йақтан бәйләгәле, айақ йақтан бәйләгәле. Йарты митыр қалдырасың айақ очқа. Оллы сантығым тулы кәбеннекләрем — *тара*.

**Кәфен**

**Кәфен** [< гар. мәет күлмәге] — үлгән кешене төреп күмү өчен әзерләнгән тукыма.
Җирле сөйләшләрдә бу сүзнең фонетик вариантлары күп: **гәфен** *глз*. **кипен, кифен** *миш.д*., **кәбен** *себ*., **кәпен** *перм*.

[1] *Кәбеннек* — кәфенлек.

**Гәфен, кәфен** *глз*. кәфен.
— Гәфен эстегә салалар, мәрлә астындин йибәрәләр ару су.

— Күммәстән элеке көнне, кайчакта күмгән көнне гәфен тегәбез. Гәфен тегүчеләргә садака айыралар — *глз*.
**Гәфен йәйү** *глз*. кәфен җәю.
— Ике кеше гәфен йәйәләр. Кодагый белән тәтәйем гәфен йәйәрләр дип әйттем.

**Кәпен: тышқы кәпен, эчке кәпен** *к.-уф*.:
*Эчке кәпен, тышқы кәпен* була. Олап (ялгап) тегәбез.

**Кипен**

**Кипен** *әстр., т.кам.-крш., нгб.-крш*. кәфен.

Ак җүкәгач суйдыгыз,
Кабыгын кайа куйдыгыз.
Ак кипенгә сардыгыз,
Туганайны қайа қуйдығыз — *т.кам.-крш*.

**Кипеннек**

**Кипеннек** *әстр., нгб.-крш*. кәфенлек.
— Кипеннеген кийертеп, йәшелгә урап салатылар қабергә — *әстр*.

Ақ қайыннарны чапқаннар
Җомочқасын қайа қуйғаннар.
Ак кипеннекләргә урап
Туганайны қайа қуйғаннар — *нгб.-крш*.

**Кәфенләү**

**Кәфенләү** < кәфен + -ләү — үлгән кешене кәфенгә төрү.
**Кифелләү** *баст*., **қәфиннәү** *нокр*. — кәфенләү, кәфенгә төрү.
— Җугач инде кифенен печәсен, *кифеллисен*, сун инде алып бара---лар — *баст*.

— Җугач бирнә айыралар, *кәфиннәгәч* бирнә айыралар — *нокр*.
**Кәфелләү** *бәр*. кәфенләү.

— Ахирәт күлмәге кийертеп *кәфеллиләр*.

### Кәфен сару

**Кәфен сару** сүзе «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (1983, 162):

Күрклү йүзләр кәфен сарыб гүргә керсә,
үкүш дәгүл, гүр эчендә үч күн дорсә.
Күрекле йөз кәфен сарып гүргә керсә,
Күп тә түгел, гүрендә тик өч көн торса...

### Кәфен сару

Буй-сыннарыңны
Үлчәп алырлар.
Йуwып пакьләгәч
Кәфен сарырлар.

Кәфен сарырлар
Зифа буйыңа.
Илтеп куйарлар
Җирнең куйнына («Мөнәҗәтләр», 464 б.)

### Чатыр

**Чатыр** [ фарсы. чадор] *төм., туб.*:

**Тышқы чатыр, урта чатыр, эчке чатыр** — кәфенлек: тышкы, урта, эчке кәфенлек.

— Тышқы чатыр, урта чатыр, эчке чатыр була. Эчке қаты йәшел, тышқы қаты ақ таwардан булса саwап. Абабыз[1] үрәтәде, кәбенне менә болай йаса, дип — *туб*.

### Кәфен кисү

**Кәфен кисү** — үлгән кешене төреп күмү өчен тукыма кисеп әзерләү. Җирле сөйләшләрдә аның борынгы төрки *печү* (< пыч тамырыннан: пычак, пычкы, почкак, почмак) сүзе белән кулланылуы да еш очрый.

**Кәфен кисү**:

[1] *Аба* — апа.

— Кәфенгә умбиш митыр кирәк, кешенең озынлығына карап. *Ақтан кисәбез кәфенне*. Қатыннарга биш қат, ирләргә җиде қат кирәк. Кәфенне үзем дә кисәм, *эстинҗә*[1] алып киләм дә кисәм — *минз*.

**Кәфен кисү** *каз.ар.-мам.*:

Илаһи нийәт қылдым
Кәфен кисмәккә.
Гафурын рәхим,
Әҗерен кәрим,
Сирател мөстәкыйм, әмин.

Бу кеше инде җаwабын биреп килде, дип әйтерләр ди.

**Кәфен кисү** *т.я.-к.т.*:

— Кәфенне салаwат әйтеп кисәләр. Менә мин үзем кисәм кәфенне. Кәфен кисә башлағанда күләп әйтә башлыйм, тәһлилгә кергән хатын---нар, әбиләр барысы да қушыла:

«Сөбханаллаһи , wә биһәмдиһи,
Сөбханаллаһи, wә биһәмдиһи».

**Кәфен кисүчеләр** *т.я.-к.т.*:

— Кәфен кисүчеләр мәйетне үлчәп алалар, баш очыннан да, айақ очыннан да бәйләрлек урын қалдырып кисәләр.

**Кәбен кисү** *туб*. кәфен кисү.
— Иман әйтеп кәбен кисәсең.

## Кәфен печү, кипен печү

**Кәфен печү** *әстр., кас*. кәфен кисү.
— Кәфен ак булады. *Кәфенне* мин үзем дә *печәм — әстр*.
— Кәфенне ’эм печи? — ’Эм бели, шул печи — *кас*.
**Гәфен печү** *глз*. — кәфен кисү. — Абыстай гәфен печте, төн уты---ручылар текте.

## Кипеннек печү

**Кипеннек печү** *әстр*. кәфенлек тегү.
— *Кипеннеген печеп*, барын да әзерләп тегәделә р. Сәгәт уникедән сун йуwындыра башлыйды. Йуwындырганнан сун *кипеннеген* кийер---теп, йәшелгә урап табутка салады. Бары да йәшелдән булады.

[1] *Эстинҗә* — тәһәрәт.

## Кипен печүче

**Кипен печүче** *әстр*. кәфен кисүче.
— *Кипен печүчеләр* кичкә килеп кипеннәрен печәләр, тегәләр.

## Кифен печү

**Кифен печү** *кузн*., **кифенлек печмә** *баст*. кәфен кисү.
— *Кифенем печкән* дә, йүләгән дә. Берсе кифен печә, катыннар тегә — *кузн*.
— *Кифеллек печмә* җөрим мин — *баст*.
— *Кифенне* үзебез печәбез, үзебез тегәбез. Ахирәт күлмәге, бөркәнчек тегәбез — *влгг*.

## Кифен пецү

**Кифен пецү** *срг*. кәфен кисү.
— Кифен пецәргә үзем йөрим. Кифен пецкәндә шылай әтәм:

Тар қаберең киң булсын, илаһи,
Қараңгы гүрең иман нуры белән тулсын, илаһи,
Белеп кылган, белми кылган гөнаһларың
Дөнйалыкта калган булсын, илаһи.
Иманыңны йулдаш кыл, илаһи,
Калебеңне пак кыл, илаһи,

Кифен пецкәндә, йүләгәндә әммәбез шылай әтәбез:

Сөбханаллаһи, вә биһәмдиһи,
Сөбханаллаһи, вә биһәмдиһи.
Лә илаһы илалаһы Караңгы гүрем йактысы.
Лә илаһы илаллаһы Сигез оҗмах ачкычы.

## Кифеннек пецү

**Кифеннек пецү, кифенне цамбыр** (чабыр) **белән төтәштерү** *срг*.:
— Цамбыр исе цыгарабыз. Цамбыр йандырып төтәштерәбез ки---феннек пецкәндә.

## Кифеннек пецүце

**Кифеннек пецүце** *срг*. кәфенлек кисүче.
— *Кифеннек пецүцеләргә* кас'ы йаулык, кас'ы сабын бирә.

## КӘФЕН ТЕГҮ

Мишәр диалектында һәм себер диалекты сөйләшләрендә *йүләү* сүзе дә кулланыла:

### Йүләүце

**Йүләүце** *чпр*. кәфен тегүче.
**Йүләүцеләр** кәфен йүлиләр айателкөрси укып. Иң беренце айателкөрси укибыз.

### Кифен йүләү

**Кифен йүләү** *кузн*., **кәбен йүләү** *себ*. кәфен тегү.
— *Кифенемне йүләргә* Хан'ук күршемә әтеп куйдым — *кузн*.
— **Кәфен җәйүче, кәфен кисүче, кәфен җүләүчеләр була**.
«Мин дә җүлим әле», — дип әйтеп җүлиләр.
«Аның әҗере күп була», диләр — *т.я.-к.т*.

### Кәфен кигезү

**Кәфен кигезү** *минз*.:

Кәфенне кигезгәч, шулай әйтәбез:
И раббым солтаным,
Сән җараттың бу мәйетнең үdeн,
Сигеd оҗмах суы белән
Җуа күрегеd җөdөн, —

дип әйтәбеd.

Қалған кешеләргә тәннәренә тазалық бир,
Җаннарына тынычлық бир,
Хәwеф-хәтәрләрдән үзең сақла.

Йарабби, уқыған догаларыбыз қабул булсын дибез, мәйетләргә дә багышлыйбыз, үзебезнең әрwахларға доға қылабыз.

### Кәбен йүләү, кәбен тегү

**Кәбен йүләү** *төм*. кәфен тегү.
— Кәбен йүләгәннәргә сәтәқә өлиләр — *төм*.

### Кәфен тегү җебе

#### *Кифен теккәндә йепне тевеннәмиләр*

— Берсе кифен печә, катыннар тегә. Кифенне теккәндә *йепне тевеннәмиләр*. Йакыннарын кычкыралар, катнын, тәтәләрен. Йакын---нары эчәр кат кади энәне. Эч кат кадаса инде йерәгенә кадалып тыр---ми, сывына башли — *кузн*.

— Кәфенне қабер қазғансы тегәләр. Тәһарәт аласың да барасың, өч---дүрт кеше тегә. Мин кисеп тектереп қуйдым кәфенне — *к.-уф*.

#### *Гәфен теккәндә йепне түнәмиләр*

— Абыстай гәфен печте, төн утыручылар текте. Гәфенне баштан да, айактан да ике карыш калдырабыз бәйләмәгә. Йебен йарамый түнәргә гәфен теккәндә — *глз*.

— Чәнечкән чағында сүләшмичә тегәбез — *минз*.

***Йепне төйгәле йарамайты***

**Йепне төйгәле йарамайты** *тара*. җепне төенләргә ярамый.
— Кәбен теккәндә йепне төйгәле йарамайты, аны беләтеләр кәбен тегеп йөрүцеләр.

***Йеп оцыкларын төймиләр***

**Йеп оцыкларын төймиләр** *туб*. җеп очларын төенләмиләр.
— Кәбенне тегәбес, йеп оцыкларын төймибес кәбен теккәндә.

***Үсе йергән йеп***

**Үсе йергән йеп** *төм*. үзе эрләгән җеп.
— Әwәле үсе йергән йеп белән теккәннәр кәбенне, үсе йергән йеп саwаплы булган.

***Кәләпләп биргән йеп***

**Кәләпләп биргән йеп** *төм*. киләпләп биргән җеп.
— Кәбен теккәннән қалған йепне урап-урап, кәләпләп биргән:
«Аның йәшен бирсен», — тип биргән.

***Бер қат ақ йеп***

— Кәбен тегәргә бер қат ақ йеп кәрәк, ике қат йеп йарамайты — *тара*.

**Кәфен теккән энә**

— Қайсы-берсе кәфен теккән энәне сорап алалар. Нәмәгә сорый---лар?
«Әпсен-төпсен итмәгә»
Энә белән әпсен-төпсен итәләр.
«Бер-берсенә қадалып торсоннар», — дип — *перм*.

— *Кәфен теккән инәне* җиргә күмәләр, сабыннарын йуған кешеләргә бирәләр — *к.-уф*.

***Энә чәнчү***

**Энә чәнчү** *себ.*:
— Энәне қаршыға атлатып тегәтеләр кәбенне. Бер ғабат чәнчеп. Қайымайтылар. Кәбенне теккәндә әйтәтләр:
«Очмах көйләкләре[1] булсын».
Энәне үсеңә тартып алмыйсың, артқа таба тартып алып утырасың. Бер генә қат йеп мән тегәсең.

— Иман әйтеп кәфен кисәсең. Кәфен теккәндә өчне уңайдан, түртенчесен қаршы чәнчеп аласың:
«Лә илаһе илаллаһ,
Мөхәммәде рәсүл Аллаһ» — дигәндә.

[1] *Очмах көйләкләре* — оҗмах күлмәкләре.

***Энә өләү***

**Энә өләү** *туб*. кәфен тегүчеләргә энә өләшү.

— Кәфен тегәләр дә қалған энәләрне өлиләр. Раднуйлары[1] тегә бит, аларға өлиләр. Кәбен йүләгәннәргә сәтәқә өлиләр. Энә йастықтан[2] алып энәләр өләп йөрителәр.

### *Энә белән җеп өләшү*

**Энә белән җеп өләшү** *т.я.-к.т.*:

— Мәйет сақлап төн утыручыларға, төн кичүчеләрг ә энәг ә җеп саплап өләшәләр. Үзе эрләгән, үзе әзерләгән җепне үзем үлгәч энәгә сапларсыз дип торадырыйы безнең әни. Хәзер **кәтүк җебе** инде. Элек җеп тә қадерле булған. Энә белән җеп:

«Мәйетне җылан-чайаннардан сақлый», — диләр.

**Энә белән җепне сул җағына қадыйлар:**

— Тәһлилгә кергәннәргә күкрәгенә энә белән җеп қадыйлар. Сул җағына қадыйлар.

**Йөкле хатын булса, энәне кире йагы белән қадыйлар:**

— Җөкле хатын булса, энәне кире җағы белән қадыйлар. Ә хәзер күбрәк булафкы өләшәләр. Мин хәстәрләп қуйдым җеп саплап энәсен дә, җебен дә — *т.я.-к.т.*

### Ахирәт күлмәге, оҗмах күлмәге

**Ахирәт** [гар. теге дөнья].

Үлгән кешене төрә торган кәфенлекнең төрле өлешләрен кием-салым итеп кабул итү, кием исемнәре белән атау җирле сөйләшләрдә киң таралган.

**Ахирәт йаулыгы, ахирәт ыштаны** *әстр.*:

— Электә *ахирәт күләге* йәшелдән иде. *Ахирәт йаулығы*, *ахирәт ыштаны* тегәтләр. Җиде қат була.

— *Ахирәт йаулығы* була ирләргә дә, қысқайақларға да.

— *Ахирәт ыштаны* тегәтләр кипен печүчеләр.

**Ахирәт** (гар. теге дөнья) **күлмәге** *урт.д.*, *миш.д.*, **ахирәт күләге** *әстр.*, *баст.*, *күрш*. үлгән кешегә беренче кат итеп киертелә торган күлмәк.

[1] *Раднуйлары* — туганнары.
[2] *Энә йастық* — энәне чәнчеп куйю өчен әзерләнгән кечкенә мендәрчек.

— *Ахирәт күләген* кидертәләр, кифеллеген чорнап қуйалар, өч җирдән бәлиләр — *баст*.

— *Ахирәт күләге* йәшел булсын, нәзек булсын, нәзек булған сайын саwаплы ди — *әстр*.

— Йәшелдән ахирәт күлмәге кигезәбез, аннан соң аққа урыйбыз. Өч җирдән бәйлибез — *әстр*.

**Ахирәт күлмәге** *глз*. кәфен.

— Ахирәт күлмәген кыз-катынга айак корсагына хәтле кисәбез, ә ирләргә тезгә хәтле. Икенче каты айак балтырга хәтле була. Ахирәт күлмәге тегелмичә кийелә — *глз*.

**Ахирәт күлмәге** җилкәдән алып айак җөзөнә хәтле төшеп тора. Ахирәт күлмәге ул тегелми. Муйын турысын җарып куйабыз.

— Мәйетнең беренче *эчке күлмәге* була. Ахирәт күлмәге дибез аны---сын. Тубықтан түбән торорға тейеш. Хатын кешенең айақ йөзлеген күмеп тороға тейеш — *минз*.

### Әхирәтлек күлмәк

**Әхирәтлек күлмәк** *бараба*. кәфенлек.

— «Әхирәтлек күлмәкләр алмақсың ахыры син әби?».

«Алмақмын. Йылқы[1] йигеп бардым, ақ таwар[2] алдым.

### Әхирәтлек йастық

**Әхирәтлек йастық** *төм*. мәетнең баш астына салу өчен каен яфра---кларыннан ясалган мендәр.

— Йастық тыш[3] тегеп, анның эценә каен йафрақларын цыбығыннан сыбырып-сыбырып салабыс. Шаны мәйетнең баш астына салабыс.

### Ахирәт мендәре

**Ахирәт мендәре** *к.-уф.* кабердә мәет баш астына салына торган мендәр.

[1] *Йылқы* — ат.
[2] Тawар — тукыма.
[3] *Йастық тыш* — мендәр тышы.

— Кеше үзенә үзе баш астына салырға йапырақтан *ахирәт мендәре* тегә, астына. Қырда үскән қамышларны киптереп қорытып қуйа дәртле кеше, қаты балчыққа йатасы килмәсә.

### Очмақ көйләк, чомақ көйләк

**Очмах көйләк, чомақ көйләк** *себ.* оҗмах күлмәге; кәфенлек.
— Йәшел төс бик саwап тиләр очмах көйләккә.
Очмах көйләк — йәшел малтан — *тара*.

— Чомақ көйләген кигезәсең, **йаулығын йабындырасың**, айақ ту---нын урыйсың, ике рәт кәбен урыйсың.
Кемдә бар **йәшел йаулық**, йәшел йаулық йабындырасың.

### Очтомақ күлмәге

**Очтомак** (оҗмах) **күлмәге** *перм., к.-уф.* ахирәт күлмәге.
— *Очтомақ күлмәгенең* үңерен ачалар баш сыйарлық итеп, арулағач кийертәләр.

— *Очтомақ күлмәген* мәйеткә арулағанда кийертәләр — *к.-уф*.

### Эч күләге

**Эч күләге** *әстр.* эчке кәфен.
— Қысқайақларга (хатын-кызларга) *эч күләген* йәшелдән тегәде.

## ҮЛЕМТЕК ТУКЫМАЛАРЫ

### Ақ бүз, бүз

**Ақ бүз** *крш., к.-уф.* — бәз; киҗе-мамык тукыма.
— Үлгән кешегә атап җасалған табақны «анның өлеше» дип, ақ бүзгә төйнәп, кайыр итеп бирәләр — *т.кам.-крш*.
— Мәйет озатканда кем очырый, *ақ бүзгә* төреп, тегәрҗеп белән бәйләгән табикмәк бирәләр — *т.кам.-крш*.
**Ақ бүз күлмәк, ақ бүз җәймә** *каз.ар.* кәфеннек.

— Ак бүз күлмәгем
Кийеп китәрмен.
Атнакичләрне
Килеп җитәрмен...
Иптәш калмаган,
Түшәк җәймәгән.
Күлмәк теккәннәр
Ақбүз җәймәдән...

**Ақ бүз кәфен**:

— Ҡуйып киткәннәр,
Аҡ бүз кәфенгә.

— Ҡатып ҡалған гәүдәләргә
Кәфенлекләр иңә бүздән.
Ҡараңғы гүрләргә кергәч
Ни җаwаплар көтә бездән — *каз.ар.*

**Аҡ бүз — аҡтыҡ тун** — *к.-уф.*
— *Аҡ бүз* — аҡтыҡ тун (кием) дигәннәр — *к.-уф.*

**Бүз** сүзе «Кыйссай Йосыф» әсәрендә (1983, 282):

Ул уҡ сағәт фәрештәләр ани йуды,
уҗмахдан бүз китүреб кәфен сарды...

Шул ук сәгать фәрештәләр аны юды,
Оҗмахтан бүз китерде һәм кәфен сарды...

### Кәфен бүзләрен зәмзәм суына ману

**Зәмзәм** — гарәп мифлары буенча изге су. Ул, имеш, мөселман илләрендәге мәчет коелары белән җир асты каналлары буенча килеп тоташа.

Зәмзәм суы төрле авыруларга каршы тора, җен-пә ридән дә саклый дип ышанганнар. Зәмзәм суына кәфеннек бүзләрен ману изге йола---лардан саналган. Әлеге йолага караган сүзләр XX йөз башы татар шагыйре Дәрдмәнд (Мөхәммәтзакир Рәмиев — 1859-1921) иҗатында чагылыш тапкан.

Биғре милләт, маэи зәмзәм
Күзләдем еллар буе.
Җитте дәфнем вакыты,
Кәфнем бүзләрен маналмадым!
Вәйлә
Дәри-и-и-гъ!
Бүзләрем маналмадым!..
(Дәрдмәнд. Шигырьләр. Казан, 2009, 160 б.)

### Аҡ мал

**Аҡ мал** *себ.* ак тукыма.

— *Аҡ малны* үсең буйы итеп ике ҡабат итеп кисәсең, игенчесен баштан алып айаҡ башына ҡадәр урайсың.

— Үсебесне урап йебәргәле мал әсерләйбес йегерме митыр. Аҡ малға урайтылар, алып китәтеләр. Аҡ малны үсең буйы итеп кисәтеләр.

### Ак китән

**Ак китән** *м.-кар., крш., себ.* кулдан сугылган ак тукыма, ак бәз. Алтай телендә кеден-җитен тукыма.

— Кеше үлгәчен җуwалар, киндерәләр дә эстән ак китән җабалар — *м.-кар.*

— Аппак-аппаҡ җудылар,
Ак китәнгә төрделәр.
Ак китәнгә төргәчен
Селкенчәккә салдылар — *каз.ар.-крш.*

— Ахирәтлек көйләк — ак китәннән булса йаҡшы. Ак китән булма---са, марлы да йарый — *том.*
— Ахирәтлек китән көйләк әсерләгән кеше, бай булса — *төм.*

### Йәшел мал

**Йәшел мал** *себ.* яшел тукыма.
— Очмах көйләк — *йәшел малтан. Йәшел малтан* кәбен (кәфен) әшкәрә оллы саwап.

### Ақ таwар

**Ақ таwар** *бараба.* ак тукыма.
— Әхирәтлек күлмәкләр[1] ақ таwардан қылалар.

[1] *Әхирәтлек күлмәкләр* — кәфеннекләр.

### Йуқа таwар, қалын таwар

**Йуқа таwар** *бараба.* марля.
— Кәфенгә, әхирәтлек күлмәккә йуқа таwар булса йақшы.
**Қалын таwар** *бараба.* кәфенгә калын әйбер ярамый, юка булырга тиеш, диләр.
— Кәфенгә *қалын таwар* йарамый, марлы булса, йуқа булса йақшы.

### Рагужа

**Рагужа** [рус.] *чпр.* калын итеп, тупас җептән сугылган тукыма.
— Рагужа диләр. Шул рагужа белән дә күмгәләделәр. Сугыш елла---рында кәфеннек булмады.

### Киндер капчык, кайын тузы

**Киндер капчык , кайын тузы** *глз.* ярлы, авыр елларда , кәфенлек тукыма булмаганда шушы әйберләргә салып та мәет күмү очраклары булган.
— Сугыш өстөндә кәфеннек булмады ич. Киндер капчык белән, кайын тузы белән дә үлек йәшергәләделәр[1]. Хәзер кәфен белән йәшерәләр. Йахшыдан бүздән йасилар кәфеннек.

### Ат җабуы

**Ат җабуы** *т.я.-к.т.* суык вакытларда атның өстенә ябу өчен әзерләнгән киндер тукыма.
— Кәфеннекләре булмаған кешеләр дә булған әwәле. Ат җабуына төргәннәр дә күмгәннәр.

### Чәллә чәлү

**Чәллә чәлү** *тара.* чалма чалу.
— Үлгәч ирләрнеке башына ақ малдан чәллә чәләбес.

[1] *Үлек йәшерү* — үлек күмү.

## ТЕГӘРҖЕП — КЕШЕНЕ СОҢГЫ ЮЛГА ОЗАТУ, КҮМҮ ЙОЛАЛАРЫНДА

### Тегәрҗеп

**Тегәрҗеп** — киндер яки җитеннән эрләп катылган, нык, чыдам---лы җеп. Тегәрҗеп — тормыш-көнкүрештә, халык традицияләрендә, төрле ышанулар, ырымнар белән бәйле йолаларда киң файдаланыл---ган.

### Тегәрҗеп — үлгәч өләшергә

— Элек wақытларда үлем өстендә тегерҗеп өләшкәннәр.

— Тегәрҗеп эрлидерийек. Ул җепне қатадырыйық ике қатлап. Үз қулыбыз белән әзерләп қуйадырыйық:

«Үлгәч өләшергә булыр», — дип — *т.я.-к.т.*

**Бер саплам, ике саплам тегәрҗеп**

— Бер саплам, ике саплам дип, ничә саплам итеп әзерләп қуйасың тегәрҗепне. Үз қул көчең бит — *т.я.-к.т.*

Ничә саплам тегәрҗеп дип сапламлап-сапламлап қуйарлар ыйы шушылай. Кәтүк җепләр бик җуғыйы ул. Ул җитен җебе ағара да, ма---тур да була. Берсесе — бер саплам җеп була.

**Басмалап қуйған тегәрҗеп, бер басма тегәрҗеп**

— Басмалап қуйған үзе эрләгән тегәрҗепне. Бер басмада утыз бөртек тегәрҗеп булған. Басмасын бөтенесен бертигез итеп җасап қуйганнар қарчықлар җасый алғаны.

«Мин үлгәч өләшерсез», — дип. Ул саwаплы булған. Эрләгән, қатқан тегәрҗеп булган — *каз.ар.-мам.*

Тегәрҗепне унар, йә йегермешәр бөртек санап, басмалап қуйарлар ыйы, чуwалмыйдырыйы ул.

— Шулай тегәрҗеп өләшкәннәр элек. Басма дип әзерләп қуйғаннар. Қысып тотсаң, бармақ җуанлығы җеп булғандыр инде ул — *каз.ар.-мам.*

— Басмалап қуйған тегәрҗепне хәйергә өләшәлә р ийе. Аннарығы---сын кирәгенә тота инде ул җепне. Тегәрҗеп — таза җеп, қәдерле бул---ган ул. Җасый алған қарчықлар шулай басмалап қуйарлар ыйы җеп---не. Башта эрләгән, қатқан, тегәрҗеп итеп әзерләп қуйған — *мам.*

**Айақлап қуйған тегәрҗеп**

— Элек қарчықлар үлемтеккә дип айақлап-айақлап қуйарлар ыйы җитен тегәрҗепне. Җитеннеке тегә рҗеп була, киндернеке тегәрҗеп түгел. Ап-ақ булыр ыйы ул, селтегә салып қайнатырлар ыйы.

**Киләпкә сарған җеп**

— Тегәрҗеп бик нәзек эрләнгән була. Қайсысы җыйып қуйа аны, киләпкә сарып қуйа — *т.я.-к.т.*

**Кәфен җүләргә тегәрҗеп**

— Кәфенне дә тегәрҗеп белән җүлиләр ийе. Кәтүк җепләре җуғыйы безнең заманда.

«Бу тегәрҗеп үзем үлгәч кәфен җүләргә булыр», — дип әзерләп қуйған — *т.я.-к.т.*

**Тегәрҗеп өләшү**

— Үле өстенә кем килә тәлил тартырға, шуларға өләшәләр тегәрҗеп.

«Җуқ , наным, аны әз- әз генә өләшәләр тегәрҗепне». Менә әле генә:

«Әни эрләгән, әнидән қалған җеп», — дип өләштеләр — *т.я.-к.т.*

**Бәйләм-бәйләм тегәрҗеп**

— Тәһлил чығып утыручыларға бәйләм-бәйләм тегәрҗеп өләшкәннәр, шунда утырған қарчықларға — *т.я.-к.т.*

**Әҗерле, саwаплы тегәрҗеп**

— Тегәрҗеп — үз қул көчең. Үле өстендә өләшәбез.

«Әҗерле, саwаплы ул тегәрҗеп», — диләр.

— Бер саплам тегәрҗеп өләшәләр, энәгә саплап. Ул инде бик тә әҗерле тегәрҗеп була.
«Әҗерле тегәрҗеп, җыйып қуйығыз, җигүле ат биргән хөкемдә була ул», — дип әйтерләр ийе.

**Үзе буйы, җепләтә бирелгән тегәрҗеп**

— Хәзер менә сабын, бит җаулығы өләшәләр, кәтүк җебе өләшәләр. Элек менә үзе буйы итеп, җепләтә тегәрҗеп өләшәләр ийе — *т.я.-к.т.*

**Ақ тегәрҗеп**

— Ақ тегәрҗепне әзерләп қуйған әwәле.
«Үлгәч бирергә», — дип — *т.я.-к.т.*

— Ақ тегәрҗеп бирәләр кеше сайын. Аны қулға бәйләп қуйалар:
«Көзән җыйырмасынға» — *каз.ар.-крш.*

**Төйеннәгән тегәрҗеп**

— Тегәрҗепне йөз бисмилла әйтеп төйнәгәннәр дә үлгәч кәфеннек қырыйына тыққаннар шул тегәрҗепне. Бисмилла әйткән сайын төйөннәп барғаннар җепне — *каз.ар.-мам.*

**Өч бөртек тегәрҗеп**

— Үле өстендә шалай үлчәп кисәләр дә өч бөртек тегәрҗеп бирәләр.

— Өч бөртек тегәрҗепне су алгис, киндер җапкис, киндер өстенә дә куйып апкайталар. Җортка ничә кеше килә, барына да шул тегәрҗепне өләшәләр — *т.я.-крш.*
— **Өч бөртек тегәрҗеп** салып, суны чумылдырып алалар. Бидрә[1] өстенә ак бүз җабалар, чишмәдән су алалар. Ырымчаклары[2] бар, әwәлгеләрдән калган. Балалар белмәсә, картлар эрәтә — *т.я.-крш.*

— Үлгәченнән өч бөртек җеп өләшү бар. Кергән бер кешегә өч бөртек җеп бирәләр.

[1] *Бидрә* — чиләк.
[2] *Ырымчак* — ырым.

Җул җөрүчеләр ул җепне ақча йанчығына тығып сақлыйлар:
«Саwаплы җеп» дип.
Җуғалтасы түгел аны, җә сәдәп тағасы, җә җамау җамыйсы — *каз.ар.-крш.*

— Үлене озатырға килгән кешеләргә өч бөртек тегәрҗеп бирәләр ийе. Аның белән инде җамау җамыйсыңмы, сәдәп тағасыңмы, ул таза җеп була инде.
Әле дә бар ул олырақ кешеләрдә тегәрҗеп. Тегәрҗеп булмаса, кәтүктән алып бирә. Тег әрҗепне өч бөртек җасап, чәч үргән шикелле үреп, шуннан суwырып бирәләр ийе.
Менә шул үле тегәрҗебен җулға чығучыларға, қайтучыларға биреп җибәрәләр ийе. Менә мин онығым әрмийәгә киткәндә, онығымның баш бармағына чорнадым шул җепне:
«Җулы уңсын,
Әйбәт җиргә туры килсен».
Қайсының түшенә тағып җибә рәләр ул җепне армийәгә киткәндә. Җә кесәсенә салып җибәрә. Хәзер менә тегәрҗеп җуғ инде, элгәре шу---лай булды.

**Тегәрҗеп кисү**

— Бездә кеше үлгис үк тегәрҗеп кисәләр. Тегәрҗепне алалар да, өстенә крус[1] салалар да пычак белән кисәләр — *т.я.-крш.*

### Тегәрҗепне су алып кайтканда куллану

— Ул тегәрҗепне су алырга киткәндә алып баралар, үлене җуwарга су алып кайтканда. Өчәү китәләр, кулларына **таба тимере**[2] тотып ба---ралар — *т.я.-крш.*

### Тегәрҗепне су уңайына круслап куйа

— Тегәрҗепне су уңгайына круслап куйалар да шаннан су алалар үлене җуwарга. Агым судан алалар да шаны беләп җуwалар — *т.я.-крш.*

[1] *Крус [<рус.крест]* — тәре.
[2] *Таба тимере* — таба тоткыч.

### Тегәрҗепне су уңайына агызалар

— Тегәрҗепне су уңгайына агызып җибәрәләр:
«Аның җулы чичта җул булсын», — дигән сүз — *т.я.-крш.*

### Тегәрҗеп — үлгән кешенең җулы

— Тег әрҗепне бирмәсәләр, сорап аласың. Җеп алмача кайтмилар:
«Мин җеп алмаган әле», — дип.
Шалай чорнисың да кисәсең **ак тегәрҗепне, кара тегел**.
«Тегәрҗеп — үлгән кешенең җулы», — дип өләшәләр. Элек сүс булган, тегәрҗеп булган. Хазер **ак шпул'ка** бирәләр.
Мин дә әзерләп куйган менә ак тегәрҗепне — *т.я.-крш. (Ырым Тәрбит)*

### Тегәрҗеп белән ураган тәбикмәк

— Үлгән кешене алып чыгып киткәндә кем очырый, балалармы, олы кешеме, бүз белән төреп, тегәрҗеп белән ураған тәбикмәкне бирәләр — *т.кам.-крш.*

### Үле тегәрҗебе — ырымчаклы

— Бер кешенең әйбере җугалса, шул тегәрҗепне өстәл айагы---на китереп бәйләп куйа , үле тегәрҗебен. Урлаган кешенең айа-гы-кулы бәйләнә, апкилә дә куйа ырлаган әйберен. Аны өч тапкыр кирегә түнәп-түнәп бәйлиләр ди өстәл айагына. Эче поша ди урлаган кешенең.
«Үле тег әрҗебе китереп бәйләдем дә китереп мендәр астына куй---ган», — ди урлаган әйберен — *т.я.-крш.*

## ЙЫРТЫШ, ҖЫРТЫШ, ҖЫРТКЫЧ

### Йыртыш

**Йыртыш** *хвл.* мәетне кабергә төшергәндә ертып өләшү өчен әзерләнгән тукыма.
— *Йыртышка* бирдек ыштапыл□не, *йыртыш* алып баралар.

### Җырткыч

**Җырткыч** *каз.ар.-лш.* җеназа күтәреп баручыларга бирелә торган тастымаллар яки ярты метр чамасында тукыма кисәкләре.

### Җыртыш

**Җыртыш** *т.я.* мәет өстендә ертылып таратыла торган ситсы яки сөлге.

### Җыртыш җырту

**Җыртыш җырту** — мәет янында тукыманы яки сөлгене ертып-ертып өләшү.

— «Дөнйалыкта кешенең битен җырткан гөнаһларын җарлыка---сын», — дип җырталар җыртышны — *т.я.-крш.*

### Җыртышны мәйетнең өстендә җырталар

— Җыртыш дип үлемтеккә бер өч-дүрт митыр читсы әзерләп ҡуйабыз. Мәйетне йуwып кәфеннәгәч, җыртыш читсысын[1] мәйетнең күкерәгенә ҡуйып җыртып-җыртып өләшәләр кеше сайын. Җыртыш инде ул бер әйбер йасарлыҡ булырға тийеш. Җыртыш җырту әле дә бар.

— Элек **мәйет өстендә җыртыш җыртҡаннар**. Мәйет өстенә җәймә җәйеп, җыртышны мәйет өстендә өләшкәннәр.

— Мәйетнең үз өстендә җыртып тараталар җыртышны, ҡулҗаулыҡ хәтле генә итеп.

«Бөтен гөнаһлары шунда бетә», — дип.

«Монсы җыртышҡа булыр», — дип читсыны җыйып ҡуйадырыйыҡ үлемтеккә дип — *т.я.-к.т.*

### Җыртышны тегәрҗеп бәйләп өләшәләр

— **Җыртышны тегәрҗеп бәйләп** өләшәләр. Кеше сайын бирелергә тийеш җыртыш белән тегәрҗеп. Җыртышҡа җеп бәйлисең дә таратып чығасың тәһлил әйтеп утырғаннарга — *т.я.-к.т.*

[1] *Җыртыш читсысы* — ертып өләшенергә тиешле ситсы.

### Җыртыш — тәмуғ утыннан пәрдә

«Җыртыш — битне ҡапларлыҡ булырға тийеш», — диләр. «Ул тәмуғ утыннан пәрдә булып тора», — ди, «синең гөнаһыңны киметә», — ди — *т.я.-к.т.*

### Җыртыш — тәмуғ утын сүндерә

— Күтәреп барган кешеләрг ә, күмәргә килгән кешеләргә җыртып-җыртып сөлге эләшәләр, сөлге җыртышын[1] эләшәләр.

«Сөлге җыртышы бик файдалы,
тәмуғ утын селкеп сүндерә», — ди — *т.я.-крш.*

### Җыртышны ҡайчы белән кисәргә йарамый

— Ҡайчы белән кисәргә түгел, җыртып ҡына бирергә ҡушалар. Әwәле шулай митырлы читсыларны җырталар ыйы, өләшәләр ийе ҡалған кешеләргә — *т.я.-к.т.*

### Җыртыш — ғайбәтләрне ҡуып тарата

— Безнең тәтәйнең җыйып ҡуйған җыртышлары күп. Йаҡын туғаннары биреп ҡуйалар читса.

«Өстендә җыртыш җыртырсыз», — дип.

«Ғайбәтләре, сүзе айаҡ астында ҡалсын, җыртылып ҡалсын, тара---лып ҡалсын», дип.

### Җыртыш — күкерәк җасарлыҡ булсын

— Җыртыштан күкерәк җасарлыҡ булырға тийеш, диләр. Җыртыш инде ул менә шушы күкерәк җасарлыҡ булырға тийеш. Менә күлмәк эченнән күкерәк кийәбез бит — *т.я.-к.т.*

**Җыртыш күкерәге**

«Җыртыш күкерәге ул бик саwаплы», — диләр.

[1] *Сөлге җыртышы* — ертып өләшенгә сөлге тукымасы.

«Мине искә алып күкерәк кийәрсез», — дип әзерләп қуйганнар.

Әwәле менә шулай булған. Инде менә хәзер күкерәк кимиләр. Менә минем дә җыртышым бар. Җыртсыннар әле үлгәч.

Җыртыш читсысыннан күкерәк тегеп кийәләр. Ташларға, әйбер сөртергә җарамый. Җыртышны җыйып барабыз — *т.я.-к.т.*

**Җыртыш бөтийе, әҗерле җыртыш**

— Җыртыштан бөти җыйып, әйбер йасыйлар.

— Зурырақ қулҗаулық хәтле була җыртыш. **Җурғаннар җасый** торған ыйы безнең әни шул җыртышлардан, бизәкләрен туры ки---тереп. **Бөти җыйу** диләр ийе. Кисәк-кисәкләрне җыйып җурған җасағаннар. Бөти җыйу дип **урындық битләре** җасый торган ыйы безнең әни. Асқа җәйә торған көрпәләрне дә бөти җыйып эшли торғаннар ыйы. Хәленнән килгәнчә, җыртышларны да қушып, бөти җыйып эшләгәннәр — *т.я.-к.т.*

— Үлек өстендә, мәйет өстендә җырталар җыртышны. Ул җыртышлардан бөти җасап теккәннәр, дәү җурған тышы җасап қуйған ыйы безнең әни.

Җыртыштан җасаған әйберне «әҗерле» диләр. *Бөти* диләр берсенә---берсен җалғап, кисәкләрдән җалғап теккәнне.

## ТИБӘРЛЕК, ТӘБӘРЛЕК

**Тибәрлек**

**Тибәрлек** *әстр*. дини мәҗлестә өләшенә торган әйбер: яулык яки тукыма.

**Тибәрлек бирү**

**Тиб әрлек бирү** *әстр*. бер елын үткәрү мәҗлесенә килгән куна---кларга бүләк өләшү. Аны хуҗа хатын өләшә.

— Мәйет чыққан өйдәге хуҗа җыл азағында барына да тибәрлек биреп чыға, мата бирә, тәрәт җаулық бирә бер йылның коранында. Алар бит өчендә дә барды, җидесендә дә барды, буш бармады бит, шуның өчен тибәрлек биреп чыға.

**Тәбәрлек**

**Тәбәрлек** — тубыл, төмән сөйләшлә рендә: олы яшькә җитеп үлгән кешенең кәфенлек тукымасыннан яки калган киеменнән кисеп яки ертып алып өләшенә торган тар гына тукыма. Аны тылсымлы, магик көчкә ия дип исәпләп, беләкләренә бәйләп йөрткәннәр.

**Тәбәрлек бәйләү**

— Тәбәрлек бәйләй тегән итек қартайып үлгән қартларнықын. Менә мин сиксән биш йәш, мин үләм, минекен бәйләйтеләр. Кәбеннегемнән қалған малны йыртқылап бәйләйтеләр. Тәбәрлек тип әйтелә. Мин әйттем:

«Инәмнең йәшен пир миңә».

Менә инәм йәшенә йитеп қуйтым хәсер. Ул тәбәрлек үсе өселеп төшкенце йөргән, ташламайтылар үсе өселеп төшкинцә.

— Тәбәрлекне бирәтеләр. Кән[1] йөремәсен, үсе өсөлеп төшсен тип. Йаңа мал өсөлми, иске малтан бирәтеләр — *туб.*

«Осон ғомерле пулың», — тип тәбәрлек бирәтеләр қарт кеше үлсә. Аны өстеннән төшкән көйләгеннән йыртып бирәтеләр, йә кисеп ала---тылар, беләккә бәйләйтеләр.

— Тәбәрлек өләшәтеләр сиксән-туқсан йәшлек қартларнықын.

«Оллы ғатын булырсың, тәбәрлек сурап алың», —
тиделәр қортқайақлар[2] — *туб.*

— Осақ йәшәгән қарт қортқайақларнықын тәбәрлек, — тип әйтәтләр.

«*Аларның йәшенә йетәйен*» тип атайсын.

Менә қарт қортқайақның берәр нәмәсен йыртып өләшәтләр. Қатымда пулғаннар алайтылар, апқайтатылар. Ул тәбәрлекне пеләккә пәйләйтеләр йескәрәк кенә итеп, аны йыwан итмәйтеләр. Қарт қортқайақларнықын әле хәсер тә алатылар, сиксән-туқсан йәштәге қортқайақларнықын.

[1] *Кән* — озак, күп.
[2] *Қортқайақ* — карчык.

— Оллы кешеләрнеке кибеннегеннән йыртып, талашмақ белән[1] беләкләренә бәйлиләр.

«Аның йәшен бирсен».

Ул тәбәрлек булаты. Қартайып үлгән кешенекен талашмақ белән алып бәйлиткән. Кибеннек кисәгеннән алатылар аны йескә генә қылып. Үсе өселгәнце йөриткән ите.

— Тәбәрлек бәйләү кә рәк уң қулға. Йәш йәшәгән қортқайақларныкын---нан алатылар тәбәрлек.

«Аның йәшен бирсен», — тип.

— Кәбеннектән қалған малны йыртып, күмелгән көнне анта булған кешеләргә өләшәтләр:

«*Писмилла, аның йәшен бирсен*».

— Қөрмәттә үлгән, төнйатан киткән оллы қортқайақларнықын тәбәрлеген бәйләйтеләр. Алай-болай үлгән, арақ эцкән кешене---кен бәйләмәйтеләр. Ыруларыннан берәү йыртып-йыртып бирәте, кәбеннек малы қаламы, көйләген йә йаулығын йыртыпмы. Қайсы кеше сурап алаты тәбәрлеген:

«*Аның йәшенә мин тә цығайын, Антай қәтерле булып төнйатан китәйен*», —
тип сурайтылар.

— Йоқарақ қына мал әсерләп қуйасың. Шал малны йыртып-йыртып кешегә өләшеп чығалар. Тәбәрлек тиләр аны. Әwәле қулға мар---лы бәйләп чығарғаннар, беләзек инде. Ул үсе өселеп төшкәнче торған беләктә.

Тәбәрлек тип қарт кешенең кәбеннегеннән кисеп биргәннәр:

«*Аның йәшен бирсен*!»

— Тәбәрлек ул оллы гешенең ғомерен сорап қалу булаты.

«***Алла паба***[2]*,*
*пы пабаның йәшен*

[1] *Талашмақ белән* — талашып.
[2] *Алла паба* — Алла бабай.

*миңа қалдырцы»,*
*«пы оллатаның[1] йәшен пирце*», —
тип тәбәрлекне пеләккә урайсың — *туб.*

**Тәбәрлекне кәбен туннан, тунныктан** (ягъни кәфенлектән) **йыр---тып бирәләр** *төм.*:

— Минтәй қартайған гешенең туннығыннан, кәбеннегеннән йыр---тып тәбәрлек бирәтеләр әwәле. Кәбен туннан[2] йыртып бирәтеләр.

— Сиксән-туқсан йәш йәшәгәннәрнең тунныгыннан тәбәрлек бәйләү гәрәк.
«*Аның йәшен бирсен*».
**Тәбәрлек — кәбеннән қалған ақ мал** *төм.*:

— Тәбәрлекне кәбеннегеннән қалған ақмални йыртып бирәләр. Беләк киңнегендә генә итеп йырталар.
Тәбәрлекне уң йақ беләккә бәйлиләр:
«*Аның шикелле қарт булайық*».
Кем бәйләйен килә, шаңа биргәннәр. Миңа гел бәйләгәннәр.
«*Шаның йәшен йәшәткәле бирәбез*» — *төм.*

## Тәбәрлек — кәбеннән қалған посқақ

— Кәбеннең қалған посқағыннан[3] полай йыртып тәбәрлек бәйләй тегән. Пер кисәк йыртып бирә тегән.
«*Аны үсе өселеп төшмәйенцә шишеп атып йийма*», — тигән. Ул үсе өселеп төшеп қалаты — *туб.*

## Тәбәрлек йаулық

**Тәбәрлек йаулық** *төм.* кәфенлек тукымадан кулъяулык кадәр итеп ертып өләшенә.
— Хәсер менә тунныктан қалған малтан қулйаулық сурлық итеп йыртып-йыртып өләшәлә р қортқайақларға. Аны өйгә апқайтабыс та ул тәбәрлек йаулыкқа менә садақаға йөрткән ақчаны урайбыс. Үлгәннең өчендә өләшәләр. Миңа гел тәбәрлек йаулық биргәннәр.

[1] *Оллата < олы + ата* — карт, өлкән ир.
[2] *Кәбен тун* — кәфенлек.
[3] *Посқақ* — калган тукыма кисәге.

## Тәбәрлек күмү

**Тәбәрлек күмү** *туб.* үленең кырыгы үткәннән соң тәбәрлекне күмәләр.
«Тәбәрлеген пирең» тип сурап алатылар. Пер көйләгенме, йаулыгынмы йыртып бирәтеләр.
Ир кешеләр тәбәрлекне күкрәк кесәләренә салып қуйалар да қырығынаца йөретәләр. Қырығы булған сун алып йиргә күмәтеләр.

«*Утқа тықмаң, ул анта төтенгә тончыга*» тиде.

Кейемен тә утка тықмайтылар:

«*төтен булып бараты үлгән кешенең қаберенә*» тиде — *туб.*

## Мата

**Мата** *әстр.* — тукыма. *Мата* сүзе себердәге рус сөйләшләрендә дә мамық-җеп тукыманы белдерә. *Мата* — кытай теленнән кергән сүз дип карала, казах. *mata*, калм. *mātā* (Фасмер, II, 258).
— Түбәдә нийаз өләшәләр, *мата* өләшәләр.

— Ире үлгән булса хатынына йыл кораны булғач қына *мата* бирәләр, йаулық бирәләр, «ақлыққа чыга» — *әстр.*
Йегерме бер митыр *мата* ала, шуннан күләк, *эч күләген*, башына *йаулық* тегә. Коранға бер кисәк *мата* қалдыра. Йылында шул *матаны* муллаға бирәт.

## Чәчү

**Чәчү** *кузн.*, **чәчү чәчү** *әстр.* үлгән кешене искә алу мәҗлесендә хәер өләшү.
— Атауда шәлме, тастымалмы бирәсен, чолкамы, күлмәкме бирә, *чәчү* була ул мәйеткә — *кузн.*

**Чәчү чәчү**

— Чәчү чәчү дип йаулыкка урап акча өләшәләр зиратта, *чәчү чәчәләр — әстр.*

**Үлекнең чәчүе**

**Үлекнең чәчүе** *әстр.*:
— Кырыгында халыкка акча өләшәләр, ул *үлекнең чәчүwе* була.

**Нийаз**

**Нийаз** [< гар. үтенү, ялыну] *әстр.* хәергә бирелә торган акча яки бирәр әйбер.
— Үлгән кешенең өйенә бөтен аwыл кешесе акча төреп, *нийаз* төреп, башынсауга киләде.

— Түбәдә *нийаз* өләшәләр, маты өләшәләр.

**Нийаз-су**

**Нийаз-су** *әстр.* хәер-дога.
— Бөтен затларым шул зийаратта, мамам, агам бар. *Нийаз-суны* барына да багышлыйсың.

**Өлеш, өлешле булсыннар**

**Өлеш** — үлгән кеше рухы өчен бирелә торган әйбер, хәер һ.б.
— Ашка-сыуга килгән кешеләргә йаулык та айыралар, ойок та бирәләр.
«*Аның өлеше булсын*», — дип — *глз.*
— Үле коранына чакырмыйчы килгәнне бик саwаплы кеше дип әйтәбез. Болай инде аwыл җирендә чакырып чыгабыз, йырактагы туганнарыбызга әйттерәбез, көнен белсеннәр дип, көнен-сәгәтен белсеннәр дип. Йырактан килгән туганнарына, килмәгәннәренә па---китка салып бирәбез. Киткәндә үк *өлешен* салып куйабыз. Тирә---кунчыга[1] бирәсең. Йакшы, рәтле аwылыбыз — *әстр.*

— Зур куwашна. Ике пот он салып басабыз. Безнең әби бар иде. Әпәйне әwәләгән сайын шының тәкле алып әwәләп куйа иде. Пиц кун′ына сала иде аны питырац итеп.
«Үлгән кешеләр өцен,
**Өлешләре** булсын» —
дип куйа иде.
«Кан′н′ам өцен,
Үлгән бабам өцен,
Алар өлешләре булсын», —
дип, йәтим әбигә бирә иде — *чпр.*

[1] *Тирә-кунчы* — тирә-күрше.

— Кажный пицтән йаси питырац[1]:
«Үлекләремнең **өлеше**», — дийеп.
Атына йаси питырац. Шылай садакага бирергә.
«Үлекләр өцен», — дип,
укыган кешегә биргәннәр питырацны.
«Бисмилла, үлекләремә садака булсын» — *чпр.*

**Мунча өлеше айыру**

**Керәшен сөйләшләрендә:**

— Үлгәннәр өчен мунчада «өлеш айырабыз». Өлеш айырғач мунчаға керергә җарамый, үзебез жуwынмыйбыз инде. Әйтеп чақырабыз:

«Без ничек чабынабыз,
шулай чабыныгыз,
җәшегез-қартығыз,
бала-чағаларыгыз,
нәсел-ыруwыбыз,
бөтенегез дә шушылай чабыныгыз»

дип, себеркеңне қуйасың (Чиябаш).

Мин себеркене үзем бәйләгәнне қуйам, җомшақ исле җапрақлыны. Сабын қуйам, мунчала қуйам. Су салам тазға. Ул тора иртә беләнгә хәтле. Ул суны түкмим, аны малларға салалар. Менә шул «мунча өлеше айыру» була.

«Нәсел-ыру,
бөтенегез дә
безнең күк чабыныгыз», — дисең (Җөри).

— Қырығына қаршы мунча җағабыз. Зиратқа барып үлеләрне чақырып қайтабыз.

«Кемнәрнең қайтасы килә, әрберегез қайтыгыз».

Мунчада үзебез жуwынғачын эссе салып чығабыз чыққанда:

Бар күршеләргә,
Нигез ийәләренә,
Җорт ийәләренә,
Үзебезнең үлгәннәргә,
Нәнәйләр, тәтәйләр,
Суғышта үлгәннәр,
Җир өстендә үлгәннәр —
«Әрберсе өлешле булсыннар».
Белгәне-белмәгәне,
Бездән көткәннәре —
«Барысы да өлешле булсыннар».
Ийәсез қалған кешеләр дә бар бит
«Барысы да өлешле булсыннар» — *т.кам.-крш.* (Мәлкән).

[1] *Питырац* — кечкенә ипи.

— Үлеләр өчен мунча җағу дүшәмбе көнне, зиратқа менү алдын---нан була. Мунчага барлық үлгәннәрне чақырабыз: «Қара Бәси бабай---лар, Аксақ бабайлар, Пидучлар, Әркипләр, барыгыз да безгә килегез, күршеләрне дә алып килегез», — дип әйтеп-әйтеп чақырабыз.

Әйтмиче генә чақырсаң, төшкә керә. Гел исемнәп әйтеп-әйтеп чақырабыз, ташқа эссе салабыз әйтеп-әйтеп:

«Өлешле булсыннар», — дип — *каз.ар.-крш.* (Җөри).

— Мунчада жуwынабыз да арттан чабынып чыққан кеше бөтен әйберләрне жуwып, чичтартып чыға.

«Үлеләргә өлеш салып чыктыңмы?» — дип әйтерләр ийе. Ташқа эссе салып чығарға тийеш була — *каз.ар.-мам.* (Җүкәче).

— Мунчада үлеләр өчен өлеш салабыз. Ике ләгәнгә су салып қалдырам. Себеркене жуwып, ләүкәгә қуйып қалдырам. Сабын қуйам, тарақ қуйам.

«Барығыз да килегез, жуwыныгыз, безне бахилләгез», — дип, ишекләрен ачып алам мунчаның.

Мунчадан чығып киткәндә, ташқа эссе салғанда болай әйтәбез:

Мунча өлеше,
Үле-тере өлеше,
Ташның җылысы,
Тәмле — татлысы,
Барығыз да өлешле булығыз», —
дип әйтәбез үзебез белгән буйынча.

Қойаш байыр алдыннан барып, мунча ишекләрен җабып қайтам.
Шулай мунча сайын эссе салып қалдырабыз мунча җаққан көннәрдә.
«Үле-тереләргә, барысына да өлеш», — дип.
Эссе суны да, суwық суны да қалдырабыз «өлеш булсын» дип.

(Самара өлкәсе Урдалы авылы).

**Ийәреп қайтқаннарға өлеш**

**Ийәреп қайтқаннарға өлеш** *каз.ар.-крш.*

— Менә қырықларында қырық күмәч, йә қырық қатлама пешерәбез бит. Шуны килгән кешеләрнең барысына да өләшәбез. Ул инде үлгән кеше өчен генә түгел, барлык әрwахларға, аның белән бергә ийәреп қайтқаннарға да өлеш бирү була. Чақырып қайтарабыз бит:

«Барығыз да қайтығыз, ашағыз, туқ булығыз», — дип (Албай).

**Үле-тереләргә өлеш**

**Үле-тереләргә өлеш** *әстр.*:

— Мичеттә қәтем-қоран булады. *Үле-тереләргә өлеш* дип тамақ[1] илтәләр мичеткә. Қайсы баwырсақ, қайсы лақсалба пешереп илтә. Кемнәр *өлеш* бирде, шул өлештән балаларга бүлеп бирәбез, «йақшы булыңыз», — дип. Үзеңнең ашайағыңнан *өлеш* бирмәгә кирәк *үле---терегә*.

— Қатым аштан (хатем аш, коръән ашы) баwырсақны биреп җибәрә.

«*Өлеш булсын*» — *себ.*

**Өлеш — керәшен сөйләшләрендә**

**Беркем йуклар өлеше,**
**йардәмчеләр өлеше,**
**кечеләр өлеше,**

**ололар өлеше** дип, үсемлек майын тамызып қамыр басып җуқалар, күзикмәкләр пешерәбез, өләшеп ашыйбыз — *т.кам.-крш.* (Кәләй).

**Аның өлеше, ахирәтлек өлеш**

— Үлгән кешегә дип атап җасалған табақ була. Шул табаққа ба---рыннан да җыйалар «аның *өлеше*», — дип. Аннары шуны бер ақ бүзгә төйнәп, кайыр итеп бирәләр — *т.кам.-крш.*

[1] *Тамақ* — ашамлык.

И туғаннар, туғаннар,
Туғаннардан кемнәр туйганнар.
Үз туғаннарыбыз килер дийеп

Күпме **өлеш** бүлеп қуйғаннар — *т.кам.-крш.* (Мәләкәс).

— Үле өчен дип тәлинкәсен дә, қашығын да қуйалар. Ул аны қайтып ашамый инде. Барыбер «аның өлеше» дип қуйалар. Ул ашамлықны суынтын малға бирәсен.

Табаққа салам табикмәк

**Ахирәтлек өлеш** дип.
Изге җаннар куансыннар
Безгә шулай тийеш дип — *каз.ар.крш.* (Җүкәче).

### Тун, туннык

**Тун** сүзе *себер, әстерхан, к.-уф.* сөйләшләрендә гомумән кием мәгънәсен дә белдерә.
**Тун** сүзе «Кыйссаи Йосыф» (13 йөз) әсәрендә дә кием мәгънәсендә кулланылган:

*Паласлардан чыкарыб, тун кийүрди,*
*Һәм т әүәдән индерди , ат бендерди.*
Тупас кием урынына күлмәк кидерде,
Дөядән төшереп, бер атка мендерде.

### Туннық

**Туннық** *себ.* — үлгән кешене төрү, киендерү өчен әзерләнгән ту---кыма, кәфенлек.
— Туннықларны тақ кыласың, биш қат кигезәсең. Хатын кешегә биш қат исәпләнгән. Ирәннәргә[1] өц қат. Туннықларны да үсеп тегәмен. Үлгән кешегә туннық кирәк — *төм.*

— Ақ малны үсең буйы итеп ике қабат итеп кисәсең, игенчесен баштан алып айақ башына қадәр пырастина шикелле итеп төрәсең. Аны урағацын йаулық бәйләтәләр. Түшелдерек[2] кигезә.
— Туннық әсерлибес, туннық астына өч питйаулық алып салып қуйабыс өчәр митер итеп урап-урап — *төм.*

[1] *Ирән* — ир кеше.

[2] *Түшелдерек* — түшлек, күкрәкчә.

### Туннықлау

**Туннықлау** *себ.* кәфенләү.
— Туннықлағац қабырғасы белән қыйблаға қаратып салабыс, тәлил тартабыс — *төм.*

— Ақ таwар алып қуйғаммын үсемә туннықлағалы — *тара.*

— Туннықлағалы туннығы булмаған кешегә мал ошлап алып ба---рабыс. Төрле геше төрле нимә алып барады, қайсы питйаулық, қайсы йаулық, қайсы мал алып киләде — *төм.*

### Айақ туны

**Айақ туны** *себ.* мәеткә билдән түбән өлешенә урый торган тукыма.

— Йаулығын йабындырасың, ике рәт кәбен урыйсың, айақ тунын урыйсың.

### Кәбен туны

**Кәбен туны** *туб.* кәфенлек.
— Кәбен тунын әргем әсерләгәле тейеш. Кәбен тунынннан қалған малны кешегә өлиләр.

### Азақ тун

**Азақ тун** *к.-уф.* соңгы кием (кәфен турында).
**Азақ тун — акбүз** *к.-уф.*

*Бу дөнйаларны сөйсәм дә*
*Йаќшы кейемнәр кимәдем.*
*Азаќ туным аќбүз булуын*
*Нигә хисапламадым.*

**Үлемнек чабатасы**

**Үлемнек чабатасы** тау ягы керәшен сөйләшендә: үлгән кешегә ки---ертеп күмү өчен махсус әзерләп куелган чабата. Чабата киертеп күмү бик дөрес дип санаганнар.

— *Чабата* йасаган үлемнеккә, үле мәндәгә чабата кигезеп күмгән.
«*Айак кийеме белән күмсәң , тишегеннән чыга алмый*
*чабата белән генә күммәле кирәк*» —

дигәннәр. *Чабата* кигезсәң чыгып йөри икән ул тишегеннән, чабата кигезгән элек шалай (Ырым Тәрбит).

**Ак чулка белән чабата**

**Ак чулка белән чабата** *т.я.-крш.* үлгән кешегә киертеп күмү өчен әзерләнгән оек белән чабата.
— Ак чулка белән чабатаны мин дә әзерләп куйган үлемнеккә (Ырым Тәрбит).

**Үлемнек запуны**

**Үлемнек запуны** *т.я.-крш.* үлемтек алъяпкычы.

**Үлемнек җаулыгы**

**Үлемнек җаулыгы** *т.я.-крш.* үлемтек яулыгы.
— «Бу запун, бу җаулык матур булды, үлемнеккә куйыйм әле мон---сон», — диләр (Янсурино).

**Билбау, билбуғыч, бута**

**Билбау, билбуғыч, бута** — кәфен өстеннән бәйләп кую өчен әзерләнгән озын тукыма.
— **Билбау** дип, мәйетне төргәннән соң бил турысыннан уратып ќуйабыз.
Бута саласың кәпенне бәйләү өчөн, билбуғыч өч җирдән була — *минз*.

**Хирка**

**Хирка** [гар.] — мәетне кәфеннәгәч чормап куя торган бау.
— Хирканы өцне йасилар. Өц хирка була. Моннан ук цорнап йибәрәсең. Кә феннәгәц астыннан бау калдырып бәйләп куйалар, шуннан тотып төшерәләр гүргә куйганда.

Хирка түгәрәк була,
Йаннар күбәләк була.
Шул хирканың уртасында
**Мәрйәм анабыз** тора.
Ул безгә дийа кыла
Дийасы кабул була.

Хирка түгәрәк булла
Йаннар күбәләк була.
Шул хирканың уртасында

**Хадичә анабыз** тора.
Ул безгә дийа кыла,
Дийасы кабул була.

Шулай унбер анабызны да искә алалар иде. Әминә анабыз, Фатыйма анабызны да искә алабыз. Әминә — Мөхәммәт пәйгамбәрнең анасы, Хәдичә — Мөхәммәт пәйгамбәрнең хатыны, Фатыйма — Мөхәммәт пәйгамбәрнең кызы булган — *чпр*. (Шәйморза).

**Бөркәнчек**

— Ахирәт күлмәге эченнән йөзләрен йабып бөркәнчек сала---быз — *к.-уф*.

**Пөргәнцек, эрәйбәк**

**Пөргәнцек** *себ*. бөркәнчек.
— Очмах көйләкне баш сыйарлық тегәсең, пөргәнцек йабып қалдырасың — *төм*.
**Эрәйбәк** *төм*. пөркәнчек.
— Эрәйбәкне йаланғачлый кигесәләр муйыннан.

**Ыштан, күкрәкчә, фирқа**

**Бөркәнчек, ыштан, күкрәкчә, фирқа** була.
— Ахирәт күлмәген қуйғанчы **бөркәнчек** қуйабыз, **ыштан** қуйабыз, **күкрәкчә** қуйабыз, **фирка** дигән әйберне қуйабыз, ир-атқа **фирқа** йуқ.
— Очмах күлмәген кигесеп күкрәгенә күкрәкчә йабалар ақ мал---тан — *тара*.
— Фирка дибез. Ахирәт күлмәгенең астына йәйеп куйабыз. Ул тез башыннан алып, култык астына хәтле була бер ин — *чпр*.

**Түшелдерек**

— Хатын кешенең беренче *түшелдерегe* була, анан ахирәт күлмәге кидерәбез — *к.-уф*.

**Түшелдерек**

**Түшелдерек** *себ*. күкрәкчә.
— Түшелдерек кигесә үлгән кешегә, мәйеткә.

**Эстинҗә чепериге**

**Эстинҗә** [< гар. ] **чепериге** *перм*. тәһарәт чүпрәге.
— *Эстинҗә чепериге* қуйалар мәйеткә.

**Нәүрәт чапқыц**

**Нәүрәт** [гар. гаурәт] *себ*. тәннең кешегә күрсәтергә ярамый торган, оят җире.
**Нәүрәт чапқыц** *себ*. гаурәт япкыч.
— Нәүрәт чапқыц қуйасың очмах көйләк өстөнә, бәйләп қуйасың — *тара*.

**Әтәплек**

**Әтәплек** [гар. әдәп + -лек] *туб*. тәннең оят җиренә каплау өчен әзерләнгән тукыма кисәге.
— Әтәплек тип ақ таwардан[1] әсерләп қуйабыс. Ә тәплекне кибен---нектән кисеп салалар. Кентектән айақ йөслегенә тийен йабатылар.

**Үлемтек**

**Үлемтек** — 1. мәетне күмү йоласы өчен кирәк булган кием-салым, кәфенлек, сөлге-тастымаллар һ.б.; 2. *т.кам.-крш*. зират.

— Төнәтергә[2] барабыз. Үле өстөндә «үлемтегемә булыр», — дип әзерләгән баж йаулыкларын, шәл баласын[3] өләшәләр — *чпр*.

[1]*Ақ таwар* — ак тукыма.
[2]*Төнәтергә* — тон сакларга.
[3]*Шәл баласы* — шәлъяулык.

**Үлемтек әйберләре**

**Үлемтек әйберләре** *урт.д*. үлгәч өләшенәсе әйберләр.

— *Үлемтек әйберл әре* дип элгәре үлемтеккә дә битҗаулықлар суғадырыйық. Суққан битҗаулықларым бар сандықта — *минз*.

**Үлемтек әйбере**

— Кеше үлгәч таратырға дип үзе исән чағында уқ әзерләп қалдыра *үлемтек әйберен*. Қайсы тастымал, қайсы күлмәклек тарата — *к.уф*.

**Үлемтек әрбире**

— *Үлемтек әрбире* калырга тийеш ди ул. Әтидән калса ир балага, әнидән калса кыз балага. Кийәмәт кендә табышырга булыша ди ул әрбирләр — *чст*.

**Үлемтек әйберләре зәкәте**

[**Зәкәт** < гар. зәкят — керемнән түләнә торган акча].

— *Үлемтек әйберләре зәкәте* дип, мәйеткә дип алып қуйған әйберләремнең зәкәте дип чығарып барырға кирәк — *минз*.

**Үлемтек күлмәге**

**Үлемтек күлмәге** *т.я.-крш*. — туйга киелгән күлмәк, туй күлмәген үлемтеккә саклап, үлгәч киертеп күмгәннәр.

— Минчәт (< рус. венчать) күлмәкләрен үлгенче сакли. Үлгәндә шаның белән, минчәт күлмәге белән күмәләр. Жиргә керә шал күлмәге белән. *Үлемтеккә* асыраган *туй күлмәген*. Кан’анам туйга теккән күлмәген кийеп җатты үлгәндә.

— Баш сарганын кийендерәләр, иргә чыккан чактагыны гатаулап куйган. **Баш сарган күлмәгем**, диде.

**Үлемтек таwарлары**

**Үлемтек таwарлары** *том*. үлгәч өләшенәсе әйберләр; күмү өчен кирәкле сөлге-тастымаллар.

— *Үлемтек таwарлары* әзерләп қуйабыз, сабын, сөлгеләребез әзер була.

**Бирнә**

**Бирнә айыру** *нокр*. үлгән кешене күмгәндә хәер итеп әйбер өләшү.

— Җуғач бирнә айыралар, кәфиннәгәч бирнә айыралар.

**Кийетләү**

**Кийетләү** *әстр*. кием яки тукыма кебек әйберләрне бүләк итеп өләшү.

«Ахтығы шул булсын,
артық үлем булмасын», —

дип кийетләйләр.

### Чылка өләшү

**Чылка өләшү** *влгг.* оек өләшү.

— Үле эчен чылка бирергә кирәк. Әтәләр:

«Бер йылдан сың үлене кәрван ала», — дип. Чылкасы булмаса, әтәләр: «Син чылкасыз, сине кәрванга алмибыз».

**Үле төшеңә иңсә дә** чылкамы, наскимы бирергә кирәк.

«Кәрванга алсыннар үзен» (Лятошинка).

### Қулжаулык өләшү

— Қулжаулық өләшәләр қайсы кешеләр қырықларында. Ул жаулық та шул жул жөргәндә әйбәт.

«Саwаплы әйбер», — дибез.

Қайсы-берсе ул жаулықны машина белән жөргәндә жулға алып жөриләр. «Сақлый ул», — диләр — *каз.ар.-крш.* (Жүкәче).

### Үлемтек яулыклары

**Жаулык** *к.-уф.*, *т.я.-к.т.* баш яулыгы.

— Үлемтекләрне әзерләйсең инде аны, илле-алтмыш *жаулық* мин дә әзерләп қуйғаммын (куйдым) инде аны — *к.-уф.* (Әрәкәй).

Үлемтек йаулықлары хәстәрлисең, йаулық читенә ақча түнисең. Бер унике-унсигез йаулық мин дә әзерләп қуйдым ыйы — *т.я.-к.т.* (Турай).

### Ақлық йаулығы

**Ақлық йаулығы** *әстр.* бер ел үткәч, кешенең кайгыру халәтеннән чыгу билгесе итеп бәйләтелә торган ак яулык.

— Йыл кораны көнне коранға хәтле иртә белән йаулығын чишеп, *ақлық йаулығы* бәйләтәләр, халық жыйылғынчы (Киләчи).

### Башйаулык

**Башйаулық** < баш + йаулык *әстр.* — баш яулыгы.

— Үле чыққан өйнең хужасы да бер башйаулық булса да ақлық өләшә, қоры чығармый (Кызан).

### Йәшел йаулык

**Йәшел йаулық** *әстр., себ.* мәеткә баш ягына урый торган яулык, ул яшелдән булса саваплы диләр.

— Кемдә бар *йәшел йаулық*, йәшел йаулық йабындырасың. Қортқайақларға йәшел йаулық булса — оллы саwап — *әстр.*

**Йәшел йаулык** *туб.* мәеткә баш ягына урый торган яулык. Ул яшелдән булса саваплы, диләр.

— Үленең башына йәшел йаулық йабатылар, йәшел йаулық әсерләп қуйатылар. Йәшел йаулық — саwаплы. Қортқайақларға йәшел йаулық — әшкәрә оллы саwап.

### Кер сақлағандағы йаулык

**Кер сақлағандағы йаулық** *әстр.* — кеше үлгәч бер ел дәвамында кайгылы халәт саклап бөркәнеп йөргән яулык.

— Йыл узғанда *кер сақлағандағы йаулықны* чишәделәр дә башына *ақлық йаулығы* бәйләтәләр.

### Шәлжаулык

**Шәлҗаулык** < шәл + җаулык *каз.ар*. бизәкле затлы зур яулык.

— *Шәлҗаулыкны* кеше үлгәч битенә җабалар. Йакын кешесеннән ачтыралар. Кем ача, җаулыкны аңа бирәләр — *каз.ар.-блт*.

### Үлемтек сөлгеләре

**Сөлге** — җеназада иң күп кулланыла торган әйбер.

— Өчәр митерле сөлгеләр әзерләп куйғаллар. Қабергә төшергәндә мәйетне ипләп кенә шул сөлге белән төшерәләр ике кеше. Ул сөлгеләр шул гүргә төшергән кешеләрнең үзләренә була — *бәр*.

Җеназада син, ак сөлге,
Безнең кулда.
Озатасың гүр иясен
Соңгы юлга (Ренат Харис).

### Бистәр

**Бистәр** *крш*. сөлге.

— Қабер қазучыларға *бистәрен* бирә, күмүчеләргә җаулық бирәләр.

### Бистәр элеп куйу

— Тәре буйына *бистәрен элеп куйасың*. Кырык көн җаны шунда торор ди, шул *бистәргә кунып*.

— Шушылай **җан сәке** буладырыйы бит, шунда инде урын җәйеп куйалар ыйы. Бүтән кеше җатмый анда аның урынына. **Күпчек** куй---алар инде кырык көненә чәкле... Үлгәч тә бер *бистәрне элеп куйабыз* бит, кырык көн шул бистәр шунда тора, аныкы була — *т.кам.-крш*.

### Битйаулык, питйаулык

**Битйаулык** < бит + йаулык *минз*.,
**Питйаулык** < пит, бит + йаулык *себ*. — сөлге.

— Қырык *битйаулығым* бар сандыкта, исемләп йазып қуйдым үлгәч өләшергә — *минз*.

### Питйаулык

**Питйаулык** < пит, бит + йаулык *себ*. сөлге.
— Қабер ацқан кешегә питйаулык пирәтеләр.
— Питйаулыклар өцәр митер кирәк — *төм*.
**Битсебер** *м.кар*. сөлге.
— *Битсеберләр* бирәләр ирләргә, хатын-кызларга җаулыклар бирәләр гүргә төшергәндә — *м.-кар*.

### Сулык

**Сулык** *әстр*. сөлге.
— Ақлыкқа килгәндә қайсы мата (тукыма), қайсы сулык әкиләде.

### Сөлге

**Сөлге өләшү** *т.я.-крш*. зиратта сөлге өләшү.
— Мазар өстендә сөлге өләшәләр, сөлге ул тамуг утын селкеп сүндерә.

### Крус сөлгесе

**Крус сөлгесе** *т.я.-криш., м.-кар.* тәре сөлгесе.

— Үлене мазарга илткәндә алдан крус күтәреп баралар, круска сөлге элгән була. Крус сөлгесе кара нагыш белән круслап теккән була. Мазарда тишегенә (каберенә) крус утырталар, круска крус сөлгесе элеп калдыралар — *т.я.-криш.*

— Үлене күмгәчен дә айаг ычка крус утырта, круска селгене бәйли бантиклап. Шул селге шунда тыра, алмилар — *м.-кар.*

## Тәрәт йаулық

**Тәрәт** [гар.] **йаулық** *туб.* сөлге.

— Туннықлап алғаннан сун күтәреп алғалы ике йағына тәрәт йаулық салатлар. Аны күтәреп цығатлар йақыннары сиратқа хәдәре — *туб.*

**Тәрәт җаулық** *әстр.* сөлге.

— Мәйет чыққан өйдәге хужа йыл коранында тәрәт җаулық бирә.

## Тастымал

**Тастымал** [< фарс.]:

**Тәһлил тастымалы** *минз.* үлгәч өләшергә дип әзерләнгән сөлге---тастымаллар.

— Тәһлил тастымалы дийеп җеназа уқығаннан соң қартларға садақа, тастымал йә битйаулығы тараталар.

— Ирләр җеназаны күтәреп алып чығып киткәнче ирләргә таратырға дип әзерләп қуйған тастымалым бар. Әнә оло сандықта ирләргә тәһлил тастымалым да күп, шәлҗаулығым да күп. Ишегал--дында тәһлил тастымалы тараталар.

## Чүпләмә

**Чүпләмә** *т.я.-к.т.* кулдан сугылган сөлге.

— Үлемтеккә чүпләмәләр әзерләгән. Гүр аузы ачучыға да, қабер қазучыға да, җеназа күтәрүчеләргә дә чүпләмәләр биргән. Җеназа ба---шына да чүпләмәләр бәйләгән.

# ҖЕНАЗА, ЧЕНАСА

**Җеназа** [*гар.* күмәргә әзерләнгән мәет; мәет күмү]:

1) мәетне озату; 2) җеназа агачы; үлгән кешене күтәреп зиратка илтү өчен махсус җайланма.

## Җеназа такта

**Җеназа такта** *глз.* мәетне салып юу һәм күтәреп зиратка илтү өчен ясалган җайланма.

— *Җеназа такта* эстигә салып чыгаралар, анда салып йуwалар. Җеназаны йәшләр күтәреп баралар.

**Җеназа тактасы** *минз.*: — Зыйаратка алып киткәндә бөгәлҗәле *җеназа тақтасына* салып алып китәләр, аның өстенә **чаршау** йаба---лар.

## Җеназабаш

**Җеназабаш** < җеназа + баш *глз.* җеназа күтәрүче.

— *Җеназабашлар* дүрт кеше була, алар җеназаны күтәреп зиратка илтәләр. *Җеназабашларга* күлмәк тә, акча да биргәләделәр.

## Җеназа башына тастымал бәйләү

**Җеназа башына тастымал бәйләү** *т.я.-к.т., каз.ар.-мам.*

— Җеназа башында күтәреп барған җирдә өч ағач бар. Шуларға тастымаллар бәйлибез, унмы-уникеме тастымал. Күтәреп баралар бит — *т.я.-к.т.*

— Җеназаны дүртәр кеше күтәреп бара, тастымал бәйләгән була җеназага. Шул бәйләгәнне алалар күтәреп баручылар мәйетне, шуның сабына тастымалны бер генә мәртәбә бәйләп қуйалар. Кем күтәреп бара, шуларга була. Қапқадан чығып әзерәк киткәч чишеп алалар, икенчеләре күтәреп китә — *каз.ар.-мам*.

## Җеназа уқу

**Җеназа уқу** *минз.*: — Җеназа уқыйбыз ишек алдына чығарып. Монда ишег алдында уқып җибәрәбез, тегендә барғач тағын уқыйлар, қыш булса өйдә уқыйлар.

— Мулла җеназа уқый. Шулай җеназа уқып қуйыш ыйы.

Илаһи нийәт қылдым
Җеназа намазын уқымаққа.
Аллаһы тәғаләгә сөннәт өчен,

Пәйғамбәребезгә салаwат өчен,
Йүнәлдем қыйбыла тарафына...

Җеназаны ир кеше уқый, қатын-қызға җеназа уқырға йарамый.

**Җеназа уқу** *бәр., каз.ар.*:

— Җеназа тақтасына салып зиратқа алып китәләр.

Җеназаны зиратта уқыйлар, мулла уқый. Аның қаршысына тағы берәү килеп утыра. Ул тегенең уқығанын йабсарып бара инде «амин---амин» ди-ди.

**Җеназа уку** *глз.*:

— Җеназаны ишек алдында укыйлар. Элеке тау башта укыганнар җеназаны. Анда тау башта зират, зират йанында укыгаладылар.

Тау астыда йәшел тирәк
Аның йафырагын җил қойар.

Чит җирләрдә үлеп wафат булсам,
Җеназалар уқып кем қуйар — *каз.ар.*

**Җеназа уқу** *әстр.*:

— Табутты қыбыла җағына қаратып җеназасын уқыйды. Кәфеннәп салып җеназа уқыйды, җеназаға халықны чақырадылар, әүләдә уқыйдылар.

## Дүрт сирэккә укыганнар

**Дүрт сирэккә укыганнар** *глз.* җеназа янында дүрт урында уты---рып укыган кешеләр. **Сирэк** < удм. почмак.

— *Дүрт сирэккә* укыганнарга күлмәкләр, акча, сөлгеләр биргәләделәр.

## Ченаза

**Ченаза** *миш.д.* җеназа.

— Ченазага куйалар үлекне башы белән кибла йагына таба. Укилар урамда, мулла ченаза уки, нийәтлиләр. Ченазаны унике кеше күтәреп илтә каберлеккә — *срг.*

## Ченаза астыннан үтү

**Ченаза астыннан үтү** *срг*. мәетне салган җеназа агачын кешеләр күтәргәч, шуның астыннан якыннарын үткәреп җибәрү.

— *Ченаза астыннан* йакыны, улы, кардашы үтә. Мулла үтсә дә йа---рый. Элек мулла гына үтә иде.

**Ченаза башына дуга куйу**

**Ченаза башына дуга куйу** *срг*. яшь кыз үлгән вакытта, аның җеназасы өстенә дуга ясап куеп, чаршау белән каплау.
— *Ченаза башына* дуга куйалар, анарга царшау, мәдәк коралар кыз бала үлсә.

**Ченаза намазы индерү**

**Ченаза намазы иңдерү** *тмн*. зиратта намаз укып мәетне кабергә кую.
— Зийәрәттә *ченаза намазын* мулла уки.

**Ченаза намазы уку**

**Ченаза намазы уку** *срг*.:
— Азбарда ченаза намазы укилар, садака өләшәләр. Ченазаны йилкәләренә күтәреп китәләр каберлеккә.

— Мулла уки ченаза намазын. Ченаза белән илтәләр каберлеккә. Ченазага куйалар үлекне башы белән кибла йагына таба. Укилар урамда, мулла уки, нийәтли.

**Ченазага сөлге элү**

**Ченазага сөлге элү** *срг*.
— Ченазага сөлгеләр бәләп куйалар, ап-ак сөлгеләр. Ул сөлгеләрне каберләр өстендә ченазадан алалар күтәреп баруцылар.

**Ченаза тақта**

**Ченаза тақта** *к.-уф*. җеназа тактасы.
— Ченаза тақта өстенә көймә йасап қуйып чаршау йабалар.

**Ченаза уқу**

**Ченаза уқу** *к.-уф*. җеназа уку.
— *Ченазаны мулла укый*, йәшләр дә үрәнә хәзер уқырға.
— *Ченаза уқырға* ғыйлем кешеләр булсайы димен.
**Ченаза уку** *чпр*. җеназа уку.
— Мәйетне кырык адым алып китәләр дә йиргә куйып, рәт-рәт ба---сып ченаза укилар. Урамда ирләр уки.
Кыз-катыннар теләк теләп калабыз.
«Бу мәйетнең иманын арттырсын.
Әгәр иманга басмаган булса,
Иманлы булып китәргә насип ит», — дип.
Кыз-катыннар теләгән теләк кабул була ди — *чпр*.

— Шулай үлене алып цыгалар да кырык адым киткәцтән, ченаза---ны йиргә куйып, ченаза намазы укилар, **киблага карап**.

Өц кеше булса йари ченаза укыганда, күп кеше булса, тагы да йари ченазада.
Мулла тайагын ченазаның өстөнә куя, аннары шулай укилар — *чпр*.

## Ченаса

**Ченаса** *себ.* җеназа.

## Ченаса астыннан чыгу

**Ченаса астынна чыгу** *төм.* мәетне салган җеназа агачын кешеләр күтәргәч, шуның астыннан якыннарын һәм мулланы үткәреп җибәрү.

— Ченасаны өйдә уқыйлар. Аннары сиратқа барғанда ченаса астыннан чығып мулла уғып ала. Шалай алып чығып китәләр.

## Ченаса намасы уқу

**Ченаса намасы уқу** *туб.* мәетне өйдән алып чыгар алдыннан на---маз уку.

— Ченаса намасын уқығалы биш кеше кирәк, тақ кирәк уқығалы. Алып китәр алдыннан уқыйлар.

— Ченаса намасы айагүрә угыла. Ченаса намасы өйтә мәйет йуған йиртә, қыйбылаға қарап уғыла. Ир гешеләр рәттән торалар, алар арқасынта қатыннар тораты.

Ченаса намасын сийаратта уғыйпыс, айағүрә пасып уғыйпыс. Айақ-қулларын өц мәртәбә палцыққа суға-суға уғыйлар.

Ченаса уғығанда әйтәтеләр:

Илаһи нийәт қылтым
Ченаса намасын үтәмәккә.
Ошбу мәйеткә саwап өчен,
Пәйғамбәребескә салаwат өчен...

Қолақ қақмастан, қул күтәрмәстән тоға уғыйпыс, раббананы уғыйпыс ((Абаул).

## Ченаса чығу, ченаса уқу

**Ченаса чығу** *тара.* җеназа уку.

— Ченаса чығу кәрәк үлгән кешегә. Өйөндә дә, сиратта да уғыйдылар.
**Ченаса уқу** *тара.* җеназа намазы уку.
— Өйдә ченаса уқыйлар, хәйерләр өлиләр[1] раднуйлары. Өйдән айағы белән чығаралар.

Чымылтығым чуп-чуwар
Чебен қунса кем қу wар,
Чит илләрдә wафат булсам
Ченаса уқып кем қуйар.

— Ирәннәр айақтан басып, пицәләр утырып уқыйлар ченасаны (Шыклар).

## Көймә, мәдәк

**Көймә** *к.уф.* мәет өстенә дуга ясап куела, шуны көймә дип әйтәләр.
— Көймә қуйалар үлгәч тә. Йәшиккә дуға эшлиләр дә аның өстөнә чеперәк қуйалар. Йәшик белә қуйалар. Йәшик аwызын йапмыйлар.

— Үлгәч зиратқа илткәндә мине *көймә* белән илтең, дигән. Мин йәш чағында *көймә* белән бардым, дигән — *төм*.

**Мәдәк** [фарсы] *хвл., срг.* хатын-кыз мәетен зиратка күтәреп илткәндә аның өстенә чатырсыман итеп корылган җайланма.

— Царшау, *мәдәк* коралар кыз бала үлсә, ченазаның баш йагына дуга куйалар.

— Кыз бала үлсә, ченаза өстенә өц мәдәк куйалар. Шылай мәдәк куйып алып китәләр каберлеккә. Ул мәдәк кабер өстендә кала. Кыз---лата үлсә шылай куйалар. Кийәүгә цыкмыйца үлсә, карт кыз булса да мәдәк куйалар — *срг*.

[1] *Өли* — өләшә.

**Көймәлек**

**Көймә лек** *бәр*. мәетне зиратка илткәндә җеназа өстөнә корып куе---ла торган тукыма.
— Җеназа тақтасының өстөнә көймәлек қороп қуйалар, көймәлек йәшел туқымадан була.

**Мөгәтәк**

**Мөгәтәк** *төм*. хатын-кыз мәетен зиратка күтәреп илткәндә аның өстенә чатырсыман итеп корылган җайланма.
— Мөгәтәк қороп алып китәтләр сиратқа. Иргә йуқ, қортқайақлар, қысларға ғына.

Мәйетне зиратқа алып киткәч:
— Мәйетне алып киткән кешеләрнең зираттан қайтқанын көтеп алғалы қушалар. Озатасың бит, көткәле дә кирәк.
Күрмәсәң — йазық дип әйтәләр — *том*.

**Чаршау, ченаза чаршаwы**

**Ченаза чаршаwы** *т.я.-трх*. мәетне зиратка илткәндә җеназа өстенә корып куела торган чаршау.
— **Ченаза чаршаwы** була. Ченаза өстенә қора торған чаршауны алдан хәстәрлиләр, қайсы кешенеке атластан була.

**Киҗеле чаршау** *к.-уф.*:
— Үлгәч шушы *киҗеле чаршаwымны* өстемә йабып алып барығыз дей, матур булып барыйм дей.
Мулла бабай өстөнә *киҗеле чаршау йабып* менгезде зиратқа, өстенә йабып қалдырды. Гүргә төшергәндә дә. Ул сизгән аның ул чаршауны йаратқанын.
*Кимә йасыйсың* мәйет өстөнә. Шаршау, шаршау эчендә бара мәйет.

## МӘЙЕТНЕ ӨЙДӘН АЛЫП ЧЫГУ

**Волгоград сөйләшендә:**

**Үлене ызбадан чыгару**

— Үлене ызбадан чыгарганда ишеккә, пәрдәләргә тигезмә, шылай бездә. Тотып торалар шылайгага. «Чыгарыгыз, тигезмәгез, тиха бу---лыгыз».
Җене кала ди үленеке. Ул күзеңә күренергә мужыт. Шыпырт-шыпырт йатасың, ә ызбада йөридер.

Бездә ишекләр зур, киң. Үлене турыга чыгаралар. Ә бар шынди кысык ызбалар, мәйет чыгарганда тәрәзне алып чыгаргаладылар. Бөгелмәсен дип паласка чормап чыгаралар.

— Мәйетне чыгарганда ишек кас'агына тигезмиләр. Тигезсәң, ул күзеңә күренә ди.

« Җене кала үленең, — ишеккә тигезмә», — дигәннәр. Ул үдә ты---ныч булмый, кемдер йөри сынны тойола башлыйдыр — *влгг*.

**Әстерхан сөйләшендә:**

— Табутны өйдән алып чыкканда *мәйетнең айағын ишеккә қаратып алып чығалар*. Бернигә бәрелмәсен, суғылмасын, туры бул---сын. Туры булмаса, қайсы кеше ишеген дә кисә.

— Мәйет чығайақта мәйеткә *ишекне бер җақын кешесе ачады*.
«Безгә рәнҗеп китмә, жақшы җулға бар», — дисең.

— Мәйетне экиткәннән сун қапқаңды, ишегеңде жаwып, *балта белән уңға, суңға чапмаға кирәк*:

«*Үлем киселсен инде,*
артық үлем чықмасын ишектән»,
үлемнең соңғысы булсын,
бу өйдә артық үле булмасын.

— Мин ишекне ачып җибәрдем қайнанам үлгәч.
«Бар, әйем, жақшы җулға бар, рәнҗемә безгә», — дидем. Ана сун қапқаның ишеген җаптым да *балта белән чаптым*.
«Киселеп қал, киселеп қал», — дидем.
— Үлене алып чыққач та *қапқадан балта белән йулға чаwып чыға*, мичтә қағаз йағып җибәрә.

— Кәфеннәр салып җеназа уқығач бер минут та тотмый алып китәләр. *Үленең артыннан чықмыйлар* бездә:

«Үле — үлене чақыра», — диләр. Йылаганда да күп йыларга йарамый.
«Күп йыласаң, үле суда йөзә», — дип әйтәләр.

— *Бусағаға балта белән чапқан* булады үлене алып чығып киткәч.

«Артық үле булмасын,
бусағаға үле килмәсен», — дип.

— Үлене алып чыққач уқ, артқа таба қайта-қайта барып, балта белән менә болай чабалар, қапыға (капкага) җиткәнче чабалар.

«Мондый хәсрәт артық килмәсен,
үлем киселеп қалсын», —

дип балта белән җирне чабабыз. Үлекне тиз генә алып китәләр бабай түбәгә.

— Бер мосафир күрсә үлене алып киткәнне, ул мосафир булса да, тиз генә тәһарәтләнеп үлене озатып барырга тийеш. Мысылман кеше---се шулай соңгы йулға озатырга тийеш бабай түбәгә барганда — *әстр*.

— Табутны бөтен туғаннары йуwыртақлашып күтәреп китәләр үле түбәгә — *әстр*.

— Мәйетне өйдән чығарғанда әйтәләр:
«Иманың жулдаш булсын, чырағым,
Алдың — үзеңә йарасын,
Артың — безгә йарасын», — дип — *әстр*.

**Тау ягы сөйләшендә**:
— Ап-ақ кийемле берәү чықты зираттан ди.
«Монда килмә жыларға» дип әйтте ди.

Мәйеткә жыларға қушмыйлар. «Жыласаң, мәйет суда жата», — диләр бит — *т.я.-к.т*.

— Мәйетне алып чыкканда пичкә тиз генә җанып бетә торған әйбер тығып җандырып алалар. Саламмыниме салалар да җандырып алалар. Ул қабергә барып җиткәнче морҗаларны ачып қуйып, пичне элдереп җандырып җибәрәләр:

«Өйдәге җылыны алып китмәсен» — *т.я.-к.т.*

**Минзәлә сөйләшендә:**

**Айателкөрси уку, тәбәрәк уку, тәһлил чығу**:

— Озатқан чағында **айателкөрси укып, тәһлил чығып**, тәбәрәк уқып қалабыз.

Мәйетне өйдән алып чыкканда әйтәбез:

Аwыр туфрағың җиңел булсын,
Қаберең йақты булсын,
Иманың қамил булсын,
Урыннарың җәннәттә булсын.

Зират күперен кичкәндә
Айағымны тайдырма,
Иманымнан айырма.

Нур кебек кичәргә насыйп булсын,
Йарабби, Ходайым.

— Үлене алып киткәц, белгән карцык ызбада калып **тәбәрәк** уки — *чпр*.

— Мәйетне алып цыгып җеназа укыганның соңонда **тәбәрәк уки---быз**:

«Үлеккә йиңел булсын өцен».
«Тәбәрәк ул үлеккә нур булып барыр», — ди — *чпр*.

**Перм сөйләшендә**:

**«Таба ис» чығаралар** — *перм.*:

— Мәйетне алып чығып китүгә, мичкә йағып, қоймақ қойалар, таба ис чығаралар.

— Мәйетне алып чығып китүгә, мичкә йағып җибәрәләр:

«Төтен чықсын, таба исе чықсын».

**Қабыққа салып алып чығалар** — *перм.*:

— Ызбадан чыққанда айағы белән алдан чығаралар, аннары чыққач башы белән алдан алып баралар.

Қабық белән күтәреп алып чығалар зиратқа озатқанда.

**Урта Урал** (*к.-уф.*) **сөйләшендә**:

— Өйдән алып чығып киткәндә бөтөн аwыл җыйылғандый җыйыла, кеше күп килә мәйетне озатып қалырға.

— Қыйблаға қаратып борып қуйалар, чыққанда айағы белән алып чығып китәләр, айақны алдан қуйып.

**Себер диалектларында:**

**Тәрәт йаулык белән күтәрәләр** *төм*:

— Тунныклап[1] алғаннан суң күтәреп алғалы ике йағына тәрәт йаулық салатлар. Аны күтәреп цығатлар йақыннары сиратқа хәдәре — *төм*. (Каскара).

### Керәшен сөйләшләрендә үлене зиратка илтү

— Зиратка илткәндә **криска[2] чиккән сөлге элеп** баралар — *т.кам.-крш.*

— Зиратқа илткәндә кем очрый, **тегәрҗеп белән ак йаулыкқа ураған тәбикмәк** бирәләр — *т.кам.-крш*.

— Үлекне зиратқа алып киткәндә **өч җыру җырларға** тийеш. Теге дөнҗаға барғач:

«Сина җырладылармы, җуқмы», — дип әйтерләр ди.
Җырламасалар:

«Син әйбәт кеше булмағансың икән», — дип әйтерләр ди.

Ақ тастымал элдем читәнгә
Җилфер-җилфер итәргә.
Туғанқайым җөри китәргә
Без белмибез нихәл итәргә.

Урман аwызлары ла тарлар аwыз
Ағач башы сары ла балаwыз.
Сағынған да сайын ла күрешергә
Җырағайа инде лә арабыз.

Кара да қара күренәдер
Кара қарлыганнарның қуағы.

Қараңғылар дийеп килми қалма
Сез қараңгы төннәрнең лә қунағы — *т.кам.-крш*.

[1] *Туннықлап* — кәфенләп.

[2] *Крис* [< рус. крест] — тәре.

## Мәйет йатқан урынға он куйу

**Бер қоштабақ он қуйу** *каз.ар.*:
— Өйдән мәйетне алып чығып киткәчтен урынына он қуйу ыйы, бер қоштабақ он қуйу ыйы. Хәзер инде аны да қуймыйлар, ақча ғына бирәләр — *каз.ар*.

— Үлекне алып цыгып киткәц, урынына он куйалар, тоз куйалар. Катыннар кала дисбе тартып — *срг*.
**Бер кәнди он қуйу** *минз.*:
— *Мәйет йаткан урынга* бер бәләкәйрәк *кәнди*[1] *белән он* кертеп куйалар:

«Мәйет инде ыризыгын калдырып киткән булсын, эрәнҗеп китмәсен» дип. Ул *онны дога кылып бер йәтим әбигә бирәләр — минз*.

**Лампы қуйу** *әстр.*, **шәм йандырып қуйу** *крш.*:
— Йатқан урынына **лампы қуйалар, лампы торады, ут йанып торады**. Қараңғы итмә йарамиды, фәрештәләр килеп торады. Шуның өчен лампы йағып қуйалар — *әстр*.

— Кеше үлгән җиргә шәмнәр җандырып қуйабыз — *каз.ар.-крш*.
**Керәшен сөйләшләрендә** мәет яткан урынга әйбер кую.

**Бистәр (сөлге) элеп куйу, күпчек (мендәр) куйу**:
— Тәре буйына ***бистәрен*** *элеп куйасың*. Кырык көн җаны шунда торор ди, шул бистәргә кунып.

— Шушылай **җан сәке** буладырыйы бит, шунда инде урын җәйеп куйалар ыйы. Бүтән кеше җатмый анда аның урынына. **Күпчек**[2] куй---алар инде кырык көненә чәкле... Үлгәч тә бер ***бистәрне***[3] *элеп куйабыз* бит, кырык көн шул *бистәр шунда тора*, аныкы була.

— Шул ***бистәр*** *кырыгына хәтле тора* да аны кырыгында гына бирәләр бер җәтим карчыкка.

— Үле чыгып киткәч ***урынын җәйеп*** *куйалар*, җаулык йабалар мендәргә, пешеренәләр. Сөйәк чыгып киттисә, *ипи-тозларны бирәләр, онын бирәләр*, тозын урынына куйалар — *т.кам.-крш*.

[1]*Кәнди* — кечкенә табак
[2]*Күпчек* — мендәр.
[3]*Бистәр* — сөлге.

— Үлгән кешене алып чыккан урынга **тимер ташлап** куйалар, тәртешкәме[1] ташли — *т.я.-крш.*

— Үле йатқан урынға изәнгә кирбеч қуйалар, пычақ аталар үле йатқан урынға.
«Зәхмәте қалмасын» — *каз.ар.-крш.*

— Үлене алып чығып киткәч, гыруп қуйған урындықны аударып қуйалар.

Ишек алдына қуйалар гырупны. Аннан үлене алып чығып киткәч, урындықны тағын аударып қалдыралар. Шулай тийеш, дигәннәр әwәлгеләр — *каз.ар.-крш.*

— Үлгән кешенең урнысына тимер куйалар, йә кайчы куйалар — *тмн.*

**Перм сөйләшендә**:

**Мәйет йаткан урынга кадак кагалар**

— Қадақ қағалар мәйетне җыйып алып чығып киткәч. Ул җатқан урынға идәнгә өчне қадақ қағалар.
«Қадақ қақтырмаға җарамый, гүрендә тыныч йатмый», — ти қай---сы кеше.

Мин үзем җарыққа ғына салам қадақны, өстенә кийез җәйеп қуйам — *перм.*

— Мәйет чыққан урынға өчне қадақ қағалар:
«Зәхмәт килмәс өчен», — дип әйтәләр — *перм.*
**Волгоград сөйләшендә**:

**Үле йаткан урынга гывуз (кадак) кагалар**

— Үлене чыгарганда идәнгә төшерәбез. Идәнгә сузма[2] җәйәбез, үле астына җәймә җәйәбез, йаткызабыз, багабыз: кай турыда башы. Шул турыга идәнгә гывуз кагабыз. **Малатук**[3] белән **гывуз**[4] әзер тора үлене чыгарганда:
«Арты тыныч булсын, сывынсын» — *влгг.*

[1] *Тәртешкә* — кисәү агачы.

[2] *Сузма* — идән паласы (дорожка).
[3] *Малатук* [< рус.] — чүкеч.

[4] *Гывуз* [< рус.] — кадак.

**Үле йаткан урынга кайчы куйалар**

— Кырык көненә ләп качы[1] тыра йаткан урынында, шылай куйа---лар, алмилар кырыгына ләп[2].

— Өченә тике мәйет йаткан урынга **качы куйалар**. Ут йанып тора. Мулла зәрәттән кат'ып киләдә мәйет йаткан урынга утырып коръән уки.

Мәйет йаткан урынга **шып**[3] кагалар:

«Шайтан иләшмәсен, үленең йене калмасын» — *влгг*.

**Мичкә йагып мөрҗәдән төтен чыгаралар**

— Үлене алып чыгып киткәч үк мичкә йагып җибәрәләр.
«Мөрҗәдән төтен чыгарга тийеш» — *влгг*.
— Мәйетне алып чығып китүгә, мичкә йағып җибәрәләр:
«Төтен чықсын, таба исе чықсын» — *перм*.

**Үле чыккач та дийа (дога) укыталар**

— Үле чыккач та **т әбарә кә** укыталар, шундый дийа. Үле барып җиткәнче аны каршы алыр ди, аңа җаwап бирергә җиңгел булыр ди. Үлене ләхеткә куйып күмгенче шул дийалар анарга җиңгел була ди — *влгг*.

**Үлене урамга чыгару**

— Үлене урамга чыгаргач мулла сори халыктан:
«Йакшымы кеше иде?
Халык әйтә:
«Йакшы иде».
Әтергә кирәк икән:
«Алла йакшы итсен».

[1] *Качы* — кайчы.

[2] *Кырыгына ләп* — кырыгына кадәр
[3] *Шып* — кадак

Нәк дисән, син аны белмисен, шуның өчен кирәк әтергә: «Алла йакшы итсен», — дип — *влгг*.

**Үлене зиратка озатучылар**

Үлене зиратка озатучылар **ак чалма бәйләп** баралар:
— Ирләр, йәше-карты бара мәйет озатырга. Башларына ак чалма---лар бәлиләр. Чыгып кит әләр, йөзәр кеше бара. Оныкам[1] да чалма чала мәйет озатканда. Сорап ала: «Минем чалмалар чилмы?» «Чил, чил[2], балам» — *влгг*.

## МӘЙЕТНЕ ЗИРАТКА АЛЫП КИТКӘЧ

— **Мәйетне алып киткәч** хатын-қызлар җыйылып керәбез дә белгәннәребезне уқып, әрwахның рухына бағышлап доға қылабыз. Бар да садақа бирә, доға қылып қалабыз — *минз*.

— Мәйетне алып чығып киткәч, өстәлгә җәймә җәйеп муллаға қоръән уқытабыз. Аннары ул җәймәне мулланың үзенә бирәсең, ул **қоръән җәймәсе** була — *минз*.

— Мәйетне алып киткән кешеләрнең зираттан қайтқанын көтеп алғалы қушалар. Озатасың бит, көткәле дә кирәк. Күрмәсәң — йазық дип әйтәләр — *том*.

**Мичкә йағу, қоймақ қойу** *перм.*:

— Мәйетне җыйып, зиратқа алып чығып киткәч тә мичкә йағып җибәрәләр, қоймақ қойып мичтә пешереп алалар. Озатып қалучылар да, зираттан қайтучылар да қоймақ белән чәй эчәләр.

— Қоймақ қойалар. Мәйетне җыйып ишек алдына алып чығып салғач та йағып җибәрәләр мичне. Ишек алдыннан алып киткәнче қоймақ әзер була — *перм*.

**Мунча җагу** *т.я.-крш.*:

[1] *Оныкам* — оныгым.

[2] *Чил* [рус.] — бөтен, әйбәт.

— *Мунча җагалар* үлене күмгәчтән, бар да күмеп кайткачтан мунча керә. Бөтен үлгән кешеләр җуwына, диләр.

— Бийанам сүләде, суга барам ди, ырым суwына, ди. Мунча ке---реп чыктылар, ди. Капкадан мунчага кадәр халык күрдем, ди. Күзенә күренгән монарга.

**Әстерхан сөйләшендә**:

— Өйдән *мәйетне алып* чыгып киткәч һәркем үзе комган алып битен-кулын йуwа.

## Үлек чыққан өй

**Үлек цыккан ү** *срг.*: — Үлек цыккан **үдә ашамыйлар**, күршеләренә кереп цәй эцәләр. Алар цакырып алалар.

**Үлек чыққан йорт** *т.я.-к.т.*:

— Үлек чыққан йортның тәрәзә эленгеләрен[1] қорып қуйалар. Ызба моңсуланып торырға тийеш, диләр.

## Мәйет чыккан өй

**Мәйет чыққан өй** *т.я.-к.т.*:

— Мәйет чыққан өйдәге кешеләрне өч көн тирә-күршеләре йәшеп ашатырға тийеш. Ул ачлықтан түгел. Үлгән кешенең өйөндә хуҗалары йә балалары бойоғып утырмасын, әз булса да кеше йанында утыр---сын, әз булса да ашасын ди-ди булған ул. Шуның өчөн йәшкәннәр аны күршеләре — *т.я.-к.т*.

**Мәйет чыккан ү** *влгг.*:

— Мәйет чыккан үдә өч көн ашамибыз, күршеләр чакыра. Чакыру---чы булмаса, ишектән чыгып:

«Мине бүген кем дә чакырмады», — дип эч кат әтәсең дә үгә кереп үзең ашисың — *влгг*.

**Мәйет чыккан өйнең** кешеләрен өйдән-өйгә йөртеп хөрмәт итәләр.

«*Үлек — ачар,*
*Терек — йабар*», — дигәннәр — *минз*.

[1] *Тәрәзә эленге* — тәрәзә пәрдәсе

Әстерхан сөйләшендә үлене алып чыгып киткәндә түбәндәге мөнәҗәт юлларын әйтеп көйләп калалар:

Йакты дөнйаны
ташлап китәмен,

Караңгы гүрдә
нихәл итәрмен.

Зифа буйымны
үлчәп алдыгыз,

Караңгы гүргә
илтеп салдыгыз.

Караңгы гүрдә
калыр бу башым,

Ак фәрештәләр
булсын йулдашым.

Йырак җирләрдән
дуслар килгәннәр,

Карап калсыннар
йакын күргәннәр.

Рәсүл алла
баскычлары,

Йакут җәүһәр
тойаклары,

Бергә-бергә
дога қылыйқ

Без бу дөнйа
кунаклары.

Изге йулны йулдаш итик,
Йаман йулға йулықмыйқ.
Бу дөнйада қунақ қына
Булуыбызны онытмыйқ.

Ғорурланма йөзеңнең айлығына,
Масайма син байлығыңа.
Дөнйа малы —

бетә торған буйау тик,
Йәш ғомерләр үтә —

чылтырап аққан чишмә тик,
Қарыйлықлар киләдер йөгереп —
ат тик.

Сират күперен кичкәндә җәшен тик тизлек белән кичәргә насыйб итсен! (Кызан).

**Мәйет чыккан өйне йуу**

**Мәет чыккан өйне юу** *миш.д.*:

— Үлене алып чыгып киткәч бармы сывыры, йукмы сывыры[1], ишек тептән түргә чәре[2] идәнне себерәләр, бөтен нәрсәне йывалар, пичкә кагызлар куйып пичтән төтен уздыралар. Күршеләр килә йыварга. Йат кешегә нәүмәт[3] кабарга йарами. Эч кичендә ашилар — *кузн.*

— Ызбадан үле чыккач бер нәстә дә калми йумийынчы. Путалакны[4] да йуалар, эстананы да, кагыз йандырып тетәштерәләр. Тетен йеретәләр, пичне йагып уздыралар.

— Ишек төбеннән түргә себерәләр, аннан инде путалакны йуганда да ишектән түргә йуалар.

— Ызбаны йывалар үлекне алып киткәц тә, циллата йывалар. Элеңгеләрне[5], үлек урынын йывалар, пицкә йагып төтен уздыралар мөрзәдән — *срг.*

— Идәннәрне ишек төбеннән түргә таба сыптырып алалар, түшәм---нәрне дә сөртеп алалар. Ызбаны бич җуwалар — *т.я.-к.т.*

— Үлене алып чыгып киткәч, идәннәрне, сәкеләрне җуып чыга---ралар, эстәлләрне куйалар да ашилар. Идәннәрне ишектән түргә таба җуа’лар:

«Арты бәк[6] булсын, артыннан үле булмасын», — дип шулай җуа’лар — *м.-кар.*

[1] *Сывыр* [< рус. сор] — чүп.
[2] *Түргә чәре* — түргә кадәр.
[3] *Нәүмәт* [< гар.] — ашамлык.

[4] *Путалак* [< рус. потолок] — түшәм.
[5] *Элеңге* — пәрдә.

[6] *Бәк булсын* — тыныч булсын.

— Алып китәләр күммә. Тиз генә өстәл, тәрәзә төп, путалакларны[1] җуып чыгалар — *баст.*

**Урта диалектның бәрәңге сөйләшендә**

— Мәйетне алып чыгып киткәч өйне җуалар, керләрен уwалар.
Андары бездә шулай. Кеше үлгәч, кем үлсә дә, мәйетне алып чығып киткәч тә күршесе *бер чүлмәк қайнар аш кертәдерийе.*
Өч көн рә ттән шулай тәмле итеп бер чүлмәк аш кертәләр ийе күршеләре — *бәр.*

**Себер диалектында мәет чыккан өй**

***Өйне йуу***

— Мәйет цыгып киткәннән суң ишек төптән, тупсатан[2] башлап йуwатлар. Түртән башласаң — үрцәй тиләр. Тупсатан башласаң — үрцемәй тиләр.

— Мәйетнең йан биргән йирен ағартып, йуwып чығалар. Ишек төптән йуwа, түргә оңғайына.

— Өйне тупсатан пашлап йуғалы кәрәк.

— Идәнне ишек йақтан башлап йуwатлар. «Тағы мәйет пулма---сын» — *төм.*

— Мәйетне күмеп қайтқанчы бөтен әйберне йуwып-йуwып эләләр. Күшәгәләрне[3] йуwып эләйләр, ишектән түргә таба өйне йуwайлар — *Том-Йәwештә.*

— Өйне ишектән башлап йуwалар, бер уңайға ғына ышқып йуwалар, ич нимә қалмасын тип. Тупсатан алып сыңар кул белән йы---шып[4] чығатлар. Қан чачылат — тиләр — *тевр.*

[1] *Путалак* [< рус. потолок] — түшәм.
[2] *Тупса* — бусага.
[3] *Күшәгә* — пәрдә.
[4] *Йышып* — сөртеп.

**Урта Урал (*к.уф.*) сөйләшендә**

— Бөтөн нимәне, өйне дә, өйдә булған нимәләрне дә йыwасың. Йыумаған нимә булмый.

**Идән йуған, кер йуған кеше**:

— Идән йуған, кер йуған кешеләргә йаулыкҷлар бирәләр. Болай халыкҷка акҷча ғына да биреп китәләр.

Җите кешегә җите күлмәк әзерләгәнмен — *к.-уф*.

**Ырым**: Мәйетне чығарғанда керне җуwып кҷалма кҷушмыйлар, тағы килер ди мәйет — *к.-уф*.

**Перм сөйләшендә**

— Мәйетне чығарып җыйғач та иң беренче ызбаны йуwып алалар. Мәйет йаткҷан урынны әйбәтләп йуwалар.

Аннан соң мичкә йағалар да кҷоймакҷ кҷойоп пешереп алалар. Мәйетне җыйып озаткҷач, озатучылар да зираттан кҷайткҷач, кҷоймакҷ белән чәй эчәләр.

**Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә**

— Үлене алып чыккис **өч кеше идән** җумаллы калалар. Так кирәк, өч кеше җуа.

— Үлене алып чыгып киткис **артыш җандыралар**, ишек катын---нан башлап идәннәрне җуwалар.

**Артыш, салам, шәм яндыру**

**Артыш агач йандыру** *глз., бәр.*:

— Үлене күммэстэн алда да, күмгэчтен дә артыш агач йандыралар. Йалды башларга салалар артыш агач.

«Шайтан бастырмага килә үле булган өйгә», —

дилэр, артыштан курка җен-шайтан — *глз*.

— Мәйет булған өйдә, мәйетне озаткҷач та артыш җандыралар.

«Аwыр исләр бетсен, җелләр килмәсен», — *бәр*.

**Артыш белән төтәсләү** *перм.*:

— Артыш белән төтәсләп җөриләр. Ишек төпләрен, тәрәзә тоткҷаларын төтәслиләр.

«Миңке кҷулым түгел,
Әйшә-Батма кҷулы»

Мүгешләргә[1] дә артыш кҷуйабыз ый.

**Салам йандыру**

**Салам йандыру** *т.я.-к.т.*:

— Мәйетне алып чыкҷканда пичкә тиз генә җанып бетә торған әйбер тығып җандырып алалар. Саламмы, җомочкҷамы салалар. Мәйет кҷабергә барып җиткәнче, морҗаларны ачып кҷуйып, пичне элдереп җандырып җибәрәләр:

«Өйдәге җылыны алып китмәсен».

**Мәтерүшкә йандыру**

**Мәтерүшкә йандыру** *к.-уф.*:

— Без мәтерушкә йандырабыз, ис сығарабыз.

**Цамбыр йандыру**

**Цамбыр (чабыр) йандыру** *срг.*

— Үлене алып цыгып китәләр дә цамбыр (чабыр) йандыралар — *срг.*

### Төтен чыгару

**Төтен чыгару** *баст.*:
— Пичкә ут куйалар, йә гәзит, йә шишкалар, төтен чыксын — *баст.*

### Шәм җандыру

**Шәм җандыру** *крш.* кеше үлгәч тә шәм яки лампа яндырып кую.

[1] *Мүгеш* — пөчмак.

### Шәм җасау

**Шәм җасау** *каз.ар.-крш.*:
— Шәмне үзебез җасыйбыз. Мин бик озын шәм җасыйм. Балаwызны эрет әсен, марлыға саласын да тәгәрәтәсен. Озын шәм, өчәр митырлы шәм була.

Мин ишеткәнем бар. Шәмне қайчы белән түгел, пәке белән кисәсе. Мин тақтаға салам да пәке белән кисәм. Шәм қысқа булырға тийеш түгел.

«Ул шәмне үлгән кешеләр қулларына тотып,
йақтыртып җөрөрләр икән».
«Кечкенә шәм аларның қулларын җандырыр» —

дигәннәр.

Шуңа күрә шәм қуйғанда әйтәләр:

«Кийаматлык дунйалар йақты булсын».

Өченә, җидесенә, қырығына да шәм җандыралар.

**Шәм** < гар. шәмгъ — балавыз, шәм.

— Кеше үлеп җаны чығу белән шәм җандырып қуйабыз — *т.кам.-крш.*

— Әрбер килгән кеше қулына шәм тотып килә. Шәмнәр күп җандыралар.

«Шәм җандырсаң, үлгән кешегә җақтылык бара», —

ди — *каз.ар.-крш.*

**Шәм йағу** *төм.* шәм яндыру.
— Қырық көнгәцә рухы килеп тораты. Шәмне йағып қуйасың қырк көнгәцә. Қаранғыға килмәсен.

**Мазар эстә** (зират өстендә) **шәм җандыру** *крш.*:
— Мазар эстә эч шәм җандыралар, салам, жымычка җандырып алалар: «Ул үлгән кешегә җақтылык биреп тора», — диләр энде.

**Өйдә ут йағып қалалар**:
— Ут йағып қалатлар мәйетне алып цығып киткәц. Мейесне[1], пәлитәне йағып қалатлар — *төм.*

[1] *Мейес* — мич.

## ҮЛГӘННӘРНЕ КҮМҮ УРЫНЫ: ЗИРАТ, МАЗАР, ҚЫРБАШ Һ.Б.

### Зират

**Зират** (< гар. — зиярәт) — үлг әннәрне күмү урыны, каберлек. Зират сүзенең җирле сөйләшләрдә түбәндәге фонетик һәм лексик вариантлары бар: **зиратлық** *трбс.*, **зәрәтлек** *тмн.*, **изгеләр зираты, әүлийә зираты** *нокр.*, *глз.*, **қырбаш** *себ.*, **мазар** *нокр.*, *т.я.-крш.*, **мәйет** *әстр.*, **түб ә** *әстр.*, **үле түбә** *әстр.* «Зират»ка карата түбәндәге тыюлар, ырымнар, ышануларны чагылдырган мисаллар:

— «*Зиарат* — аwылдан биш йөз адым булсын», — дигәннәр — *к.-уф.*

— «*Зиратка* кырык адым йитмис элек[1] ойалып узасы» — *нокр.*

— Хатын-кызга *зиратка* керү тыйыла. Кергән очракта да айагын---да ойогы, башында йаулыгы булырга тийеш. Бармак белән төртеп күрсәтергә йарамый. Йаңгыш төртеп күрсәтәсен икән «анакайым, йаңгыштым» дип, күккә карап төкерергә кушканнар.

Төртеп күрсәтергә, кычкырып силәшергә, ашап-эцәргә, тышка чы---гарга гомумән өрөхсәт ителми торган әйберләр — *чст.*

— Қысқайақларға[2] зиратқа барырға йарамый. Йарый шул кешеләргә, қайсылары итәккердән[3] қалған, ырудан қалған. Ә йәш қысқайақларға йарамыйты зиратқа барырға. Минем әйем[4] әйтәде, чеперәктән қырқ қат урап бармаға диде, қырқ чеперәк салып диде. Бездә бармыйлар зиратқа — *әстр*.

— Мулла йаулық алып бара зиратқа. Шул йаулыққа туған---тохомнары, қысқайақлары туфрақ салып җибәрәде. Шунда доғасын уқыйлар зиратта, шул доғаны уқып, шул йаулықтағы затны, туфрақны өстенә сибәләр, йаулықны йорт ийәсенә қайтарып биряләр.

Қу дала[5] диделәр эстипне. Безнең зийарәтта қу дала — *әстр*.

[1] *Йитмис элек* — җиткәнче.
[2] *Қысқайақлар* — хатын-кызлар.
[3] *Итәккертән қалу* — хатын-кызның күреме тукталу.
[4] *Әйем* — әнием.
[5] *Қу дала* — ялангач дала.

— Мазарбаш зиратында да, Оло Қыр зиратында да изгеләр бар диләр. Доға қылып йөрибез аларға. Исемнәре дә бар аларның. Ололар белә.

Шунда Оло Қыр зыйаратындағы изгеләргә,
Әрwахларға, туған-тумачаларға,
Су ийәләре, урман ийәләре,
Җир ийәләренә, — дип доға қылабыз — *бәр*.

## Зират бәйрәме

**Зират бәйрәме** *әстр*. үлгән кешеләр рухына багышлап уздырыла торган бәйрәм. Ул яз көне уздырыла.

— *Зират бәйрәменә* зур мал сатып алалар. Зур қазаннарда пе---шереп аwыл халқы җыйылып, бала-чаған хөрмәтләп ашата-эчерә иделәр, қорән укыйлар иде қартлар қычқырып-қычқырып. Йаз ба---шында була иде ул, үлән йәм-йәшел булып үсеп киткәндә. Қартузан, Кәменни, Канга, Келдермеш, Биш Түбә, Урта аwыл, Солянкадан килә. Менә без инде Йанға-Әскәр булабыз. Бездә менә бик зур әүлийә Нурмөхәммәт әүлийә булған. Зур-зур қазаннар җыйалар халықтан, ашлар пешерәләр, арбалар белән, атлар белән киләләр. Үткән йылда да булды, қуй суйдылар. Йаңғыр қойоп йауды, җебенеп лычқый бу---лып қайттылар. Қоролық иде, қыздыра, эссе. Мә сиңа, қойоп йаңғыр йаwып җебенеп қайттылар. Әүлийә шулай безнең (Янга-Әскәр).

## Зыйарат бәйрәме

— Зыйарат бәйрәме үзебезнең аwылда Қартузанда зыйаратлар буй---ында була ул. Анда чоқыр қазып, зур қазаннарда ашлар пешерәләр, өлкән қара мал (сыер) суйып пешерәләр, халықны җыйып ашаталар. Көзләктә була ул. Күп киләләр иде. Йанға-ә скәрдән, Қанғадан киләләр иде, бик күп киләләр иде. Урамыбызның уртасында йарыш, көрәш була иде. Ул бик зур бәйрәм була иде, ураза бәйрәменнән, қорбан бәйрәменнән дә артық була иде, атақлы бәйрәм була иде. Өлкүн қазаннарда аш пешә. Бабалар[1] пешерә, мамалар[2] пешерми. Без бала---лар да бара идек. Қазаннан нәлбәклә ргә[3] салып-салып бир әләр. Үзең шунда бесмилланы әйтеп утырып ашыйсың. Тастархан кебек зат җәйелгән була иде. Хәзер бетте ул бәйрәм (Картузан).

[1] *Баба* — өлкән ир кеше.
[2] *Мама* — өлкән хатын-кыз.
[3] *Нәлбәк* — тәлинкә.

**Зират теләк** *әстр*. зират янында җыелышып яңгыр теләү.

— Зират теләккә йыл да барабыз, ару, затлы кийенеп барабыз. Зират бәйрәменә шунда арба-арба халык килә, кем ни зат тели аш пешә дә коран укыйлар, теләк телиләр. Теләк йасый булганнар. «Ки---легез балалар, су сибешегез», — ди — *әстр*.

## Зират кылма

**Зират кылма** *глз*. — зират кылырга, корбан чалып үлгәннәрне искә алырга.

— Урйа-калага (ав. ис.) *зират кылма* киләләр картлар, укып утыр---галилар. Анда бөтен аwыл йукаланып[1] корбан чалабыз. Анда йомыр---ка илтеп барабыз, йарма илтеп барабыз.

Мин белдектә Кистем апайлар зират кылма киләләр иде Әхмәдигә. Зиратны кутыртлап[2] йөриләр иде.

«Без зират кылма килдек, машинага утырма йарамый», — дип әйтәләр иде.

Җийәү килеп, җийәү китәләр иде.

Алар зират эченә кермиләр иде, сирәктән-сирәккә[3] кругум киртә буйы йөриләр иде. Садака айыралар иде аwылда.

### Зийәрәт кылмага

**Зийәрәт кылмага** *чст.* — зират кылырга, намаз укырга.
— Йар астыннан дүрт бабай цыктылар урманнан кат'ып килгәндә. Шыл Бустрәй зийәрәтенә *зийәрәт кылмага* килгәннәр. Аларның берсе Тубылгы тауның, берсе Йылан таwының, берсе Зирекленеке булган. Тәһарәтләнеп цыктылар, кә ркешләрен[4] цабата эстенә куйып, айакла---рын ышкып кына баралар, күтәреп бармыйлар, шуытып кына бара---лар. Шыл дүрт бабай бардылар зийәрә тнең дүрт нүwешенә[5] дә сәләм биреп дога кылдылар да колак кагып намаз укыдылар ике рәкәгат. Тагын икенце нүwешкә дә намаз укып цыктылар. Айакны күтәреп атламилар, шуытып кына барыга икән.

[1] *Йукаланып* [< удм.] — җыелып.
[2] *Кутыртлап* [< удм.] — әйләнеп.
[3] *Сирәктән-сирәккә* [< удм.] — почмактан почмакка.
[4] *Кәркеш* — чабата киндерәсе.
[5] *Нүwеш* — почмак.

### Изгеләр зираты

**Изгеләр зираты** *т.я.-к.т.*:

— Менә Күкшем дигән аwылда изгеләр зираты бар, тирәсен тотқан, қайыннар утыртқан. Әгәр йаумаса, қорылыққа китсә, қарчықлар җыйылышып, тәһарәтләнеп изгеләр зиратына барабыз. Чирәм өстенә намазлықларыбызны җәйеп намаз уқыйбыз, ходайдан сорыйбыз, йа---лынабыз, йаңгыр йаwып китә (Күкшем).

— Бар бездә изгеләр зираты Турай аwылында. Аны иннекләр (киртәләр) белән тотып алғаннар ыйы. Фәнилә белән барып қарадық без аны.

Җаныкам, менә шулай җаңгыр булмаған чағында әйтәлә р ийе:

«Изгеләр зиратына барып намаз уқыйқ әле», — дип. Зират әйләнәсен йөреп чығабыз, уқыйбыз. Шуннан қайтқанда җаңгыр җаwадырыйы.

Без бала чағында ул изгеләр зиратын иннекләр белән тотып алғаннар ыйы.

«Изгеләр зиратына кереп җиләк җыймағыз», — дип әйтәләр ийе әтиләр — *т.я.-к.т.* (Турай).

— Изгеләр зираты бар бездә. Арттағы урамда кизләү бар. Ызбала---ры матурлап, сырлап ағачтан эшләнгән, улақлары бик матур, сөлгесе, тустағаны бар. Шулай изгеләр зиратына баралар безнең Чирмешән аwылында — *т.я.-к.т.* (Чирмешән).

**Изгеләр зираты — Баба таwында** *т.я.-к.т.*:

— **Изгеләр зираты** ул **Баба таwында**. Менә беренчесе — Бирге Баба, аннары Арғы Баба. Менә бу Бирге Бабада изгеләр зираты. Баба таwына барабыз изгеләр зиратына. Менә шул тауға менәләр ийе әниләр заманында. Шунда изгеләр зиратында теләк телиләр ийе — *т.я.-к.т.* (Турай).

**Изгеләр зираты — Биби чирәмендә** *т.я.-к.т.*:

— **Биби чирәме** бар бездә Қараборнаш белән Қоштаwы арасында. Анда **изгеләр зираты**. Җаңғыр җаумаса Биби чирәмендәге изгеләр қаберенә барып, шул зиратқа барып намаз уқыйлар — *т.я.-к.т.* (Караборнаш).

**Изгеләр зираты — Алмагач чирәмендә** *т.я.-к.т.*:

— **Алмағач чирәме** ул **изгеләр зираты**. Анда изгеләр күмелгән урын.

Қоръән бағышлағанда, доға бағышлағанда шундағы изгеләрне искә алып, аларға бағышлап уқыйбыз (Караборнаш).

**Ташбилге зираты** *т.я.-к.т.*:

— **Ташбилге зиратындагы** изгеләр бар Қолғына аwылында.

«Ташбилге зиратындагы,
Тыштағы wә эчтәге изгеләренә», —

дип адарынып хәйер бирәбез — *т.я.-к.т.* (Колгына)

**Мәмәт чардыwаны — изгеләр зираты** *т.я.-к.т.*:

**Мәмәт чардыwаны** бар безнең **Дәwеш** җанында. Әнә ындырға чығып қарасаң күренеп кенә тора.

Мәмәт чардыwанына йаңғыр теләргә бардылар. Ул безнең изге урын. Қайын үсеп утыра анда. Мәмәт баба күмелгән, изге кеше булған диләр. Шул Мәмәт чарды wанына барып доғалар қылғаннар, рәшәткә җасап қуйған анда. Хәзер җаңғыр сораучы да жук (Дәвеш).

### Уҡсын тawы, Ҡыз тawы, Кирәмәт тawы

— **Уҡсын тawы изгеләре** Апас йанында ғына. Ҡоръән уҡығанда, бағышлағанда искә алабыз — *т.я.-к.т.* (Апас).

— **Ҡыз тawына** барып намазлар уҡыдылар, йаңғыр сорадылар. Доға бағышлағанда ҡушасың инде:

«Ҡыз тawындағы изге ҡызға бағышладым», — дип (Тутай).

### Кирәмәт, кирәмәт тawы

— Кирәмәт ул тау, Безнең Турай жанында. Анда изгеләр күмелгән. Әwәле ул жирләрне суҡаламыйлар ийы. Өч кирәмәт бар. Беренче, урта, өченче кирәмәт.

Әwәле Кирәмәт тawына барып йаңғыр теләгәннәр. Ике рәҡәғәт намаз уҡып сорағаннар:

«И, Раббым, хәйерле йаңғырлар бир».

**Кирәмәт асты** — ҡалку жир, Ҡыштаwына таба. Изге урын ул (Турай).

### Иске зират

**Иске зират** *глз.* — изгеләр зираты.

— *Иске зират* бар безнеке. Анда изге су, догалы су, аны төшереп эчкәлиләр. Анда күмелгән әүлийәләр (Гүрия-кала).

### Әүлийа зираты

**Әүлийа зираты** *каз.ар.-дөб.* изгеләр зираты.

— *Әүлийа зиратына* адарыналар, жаулыҡма, ситсама ҡуйалар чардуған ҡырыйына. Мин дә жыл сайын бер жаулыҡ бәйләп ҡуйам (Әлдермеш).

### Кужа-кала зират

**Кужа-кала зират** *глз.* изгеләр зираты.

— Кужа-кала зиратларга багышлап сәдәкә салам корман ашына барган көнне (Гүрия-кала).

### Зиратҡа бару көне

— Олы көн үтә. Олы көннең икенче атна сишәмбесендә зиратҡа бару көне. Зиратҡа күкәйләр, тәбикмәкләр пешереп алып барабыз, ҡач төбенә салабыз — *каз.ар.-крш.*

### Зәрәт, зәрәтлек

**Зәрәт,**
**Зәрәтлек** *миш.д.* зират.

— *Зәрәтлеккә* карап тырдым сине гүргә күмгенчә.

— *Зәрәтлектә* агачлар күп, кошлар сайрап тыралар — *лмб.*

— Зәрәтләргә менеп намаз укилар картлар, йаңгыр сорилар — *чпр.*

**Зәрәтлек өсте** *кузн.* — зират өсте.

— *Зәрәтлек өстендә* бабайлар йаңгыр сорыйлар.

### Зират, сират

Зират сүзенең себер диалектларында фонетик һәм лексик вариант---лары бар: сират, ҡырбаш, үлек һ.б.

— Зиратҡа ҡырыҡ адым йетмәстән ченаса уҡыйлар.

— Ҡатын-ҡызға ҡырыҡ атлам зиратҡа йаҡын йөргәле ҡушҡан йуҡ электән — *том.*

— Зиратта ҡабер өстенә утырып Ҡоръән уҡыйлар, аҡца өләшәтләр ибенә[1] кешегә ҡалтацыҡлар беләән.

— «Зираттан ҡайтҡан халыҡны көтеп алмасаң, күзеңнең нуры китәр». — ди. Мәйетне алып киткән кешеләр ҡайтҡанны көтеп алғалы ҡушалар. Озатасың бит, көткәле дә кирәк. «Күрмәсәң — **йазыҡ**», — дип әйтәләр. Ҡайтҡач бабайлар Ҡоръән уҡыйлар. Аларға хәйер өлиләр — *том.*

### Сират

**Сират** *себ.* зират.

— Сиратқа күмгәле киткән гешеләрне көтеп алу гә рәк.
«Көтмәсәң, күсеңнең нуры китәте», — дийептеләр — *төм.*

— Сиратқа алып цығып китә үлекне, қасанға қорманнық итен са---лып йийаты пешергәле — *туб.*

**Эске сират**

**Эске сират** *төм.* изгеләр зираты; иске зират.
— «Эске сират әһелләренә», — тип туwа уғыйбыс. Эскеләр йататы эске сиратта.
**[Ырым]:**

[1] *Ибенә* — барлык.

— Үлгән кешене күтәреп сиратқа алып китеп утырған wақытта қойма йарықтан қарасаң, син күремче булып қаласың икән — *төм.*

— Менә кеше үлә бит, мәйетне алып чығалар сиратқа қуйғалы. Аның өстенә әрчәдә икенче үлә торған кешенең әрwағы утырып чыға тигән. Менә ул кеше тис үләтегән тигән. Аны күремче кеше күреп қала, тигән, утырып чыққанын таный тигән. Хәсер тә бар антайлар — *төм.*

**Қырбаш**

**Қырбаш** *төм.* зират.
— Икешәр кеше, алты кеше алып пара қырбашқа. Ипләп атлап, алыштырып паралар.
— Өц йиргә туқтатқалы кәрәк кешене қырбашқа әпкиткәнтә.
— Пицәләр қырбаш төпкәцә баралар, эценә кермиләр.
— Қырбашқа барабыс қәбер қасқалы. Оллорақлар ләхет қасапыс тиләр. Қырбаштан күмеп қайтқаннар кереп утыра аш эцкәле.

— Қырбаштан килгән кешеләргә бөтөннәй қуй пешерәтләр. Қарт---лар қырбаштан килеп қатым уқып алғасын аш таратасың аларға.

— Қырбаштан күмеп килүләренә қуй суйып, аш тайарлайтылар. Қартлар өйгә керәтеләр.
Қырбаштан килгән кешеләргә сатақа салмайтылар. Қырбашта ғы---на салатылар сатақа.

— Белгән, ишеткән бөтен кеше йөрите қырбашқа. Саwаплы була.
«Бүген қырбаш, қырбашқа барың» тип цақыратылар кем үлсә тә.
Ә пестәйләр, қортқайақлар, пицәләр қырбашқа пармайтоғаннар ите.
«Қырбашта арығанцы қасығалы йарамайты, алышынып торың, әргемнең қулы тигәле тейеш», —
тип әйтәтеләр қартлар, оллаталар.
«Әргем тупрақ салсын қырбашта күмгәле».
Шалай тупрақ салу гәрәк — *туб.*

**Астана**

**Астана** < фарсы телендә: бусага, сарайга керү урыны (*Миллер, 1953, 19*). Шундый ук мәгънәдә астана сүзе үзбәк, уйгур, азербайжан, казах телләрендә дә кулланыла.
**Астана** *төм., туб.* изгеләр, мөселман миссионерлар кабере; бүрәнәләрдән алты почмаклы итеп эшләнгән, түбәсез, кереп йөрү өчен ишеге ясалган була.

Астанада «йақшылар», ягъни изгеләр күмелгән:
— Оллы астана пестә. Анта йақшылар йата. Қәсим ата рухына уқыйтлар. Түгәрәк булып тора астана. Сәйел түбә, қатымын уқыйтлар анта. Пөтөн тогомнарым анта минең. Түрт йеңкәм анта минең.

— Астана сиратның эцентә. Күрше аwыллар хәйер биреп торалар астанаға. Йақшылар күмелгән анта, әргем садақа салды йақшыларның рухына дип.

— Йақшылар йататы астаната. Йосып Шәйехләр, Қәсән-Қөсәйеннәр күмелгән. Ағацтан өй салған астанаға, әүwәл-әүwәлтеннән алай.
— Астаната өц қыс тиделәр. Әүлийалар: Сабира, Сәрбийамал, Сариба — әүлийа қыслар тиделәр аларны. Алар итәкләре белән йер ташып түбә қылғаннар, өчтүбә тип атаганнар. Астананың сарайы бар, анда мал суйатылар.

**Баш астана**

**Баш астана** *төм.* изгеләр каберенең, астананың иң олысы, сава---плысы.

— Баш астаната оллы геше күмелгән. Анта барып, аш үткәсеп, хәйер салып қайталар. Қуй суйатлар астаната.

Астананы йаңартмыйлар, церсә церсен.

### Астана сарайы, йақшылар сарайы

**Астана сарайы** *төм., туб.* изгеләр кабере, астана өстенә ясалган агач корылма.

**Йақшылар** *төм., туб.* астанага күмелгән изгеләрне шулай дип атыйлар.

— Астананың сарайы бар, анда мал суйатылар. Сарайның түбәсе йуқ, ул черсә йаңартып қуйатылар. Йақшыларның сарайы тиделәр аларны. Ике рәқәғәт намас уғып алабыс, илебесгә-йортыбысға ты---нычлык булсын дип, исән-сау йәшәйек дип.

### Астана өй, әүлийә өйе

**Астана өй** *төм.* изгеләр каберен, астананы карап торучы кеше өчен салынган өй.

— Астана өйтә астананы қарауцы қарт тораты. Уқығалы беләте ул қарт.

**Әүлийә өйе** *төм.* астана.

— Пестән түрт чағырым ғына астана, әүлийаларның өйе бар, анда әүлийалар йатқан. Аннан гармун тартып уса алмайсың, сөйләшеп уса алмайсың. Йул буйынта ғына астана. Гармун тартып йырлап узсаң аwыру табылаты. Или ат булып цығаты, или кеше булып цығаты, или қуй булып цығаты.

— Астана өй қырларында, әүлийә өйе қырларында, әүлийәләр йатқан йирдә атрасман[1] үсә. Башында ошолай ғына сары чәчәге була.

### Астана баба, астана мама

**Астана баба, астана мама** *туб.* астанага күмелгәннәрне олылап әйтү.

— Сатақа салсаң, астана бабабыс, астана мамабыс руғына тип са---лабыс. Менә Бәйектә оллы бабабыс — астана бабабыс йата.

### Астана әһелләре, сират әһелләре

**Астана әһелләре** *төм.* дога багышлаганда искә алыналар.

Wагай астаната — Wәғрәм шәйех,
Күбәк астаната — Кәсим шәйех, Туғыс астаната — Қарлығац өннә,
Пайыш астаната — Хәким шәйех атабыс йататы.

[1] *Атрасман* — дару үләне (гармала).

— Астана әһелләренә, сират әһелләренә тип исемнәтә бағышлайым уқығанда.

**Паш астана** *төм.* изгеләр каберенең иң саваплысы дип исәпләнелә.

— Паш астаната оллы геше күмелгән. Анта барып, аш үткәсеп, хәйер салып қайталар. Қуй суйатлар астаната. Астананы йаңартмыйлар, церсә церсен.

### Пайыш астана, күлцәк астана

**Пайыш астана** *туб.* Баеш авылындагы астана.

— Пайыш астананың астанасы искергән ите, аны йаңарттылар. Анта үгес килеп ашанып торған. Өч йәш үгес, аны алла тәлә йибәрепте. Ул үгесне суйып, қорбаннық үткәстеләр.

Иртеш итәктә утыраты Пайыш астана. Кеше атқа утырып усса, Пайыш астана қабатыннан, пер йире сәйепләнә тигән. Аның өцөн туй булса та, күц килсә тә атлардан, машиналардан төшеп, йәйәүләп уса---лар астана турдан. Утырып усған кеше сәйипләнеп[1] қуйа тигән. Оллы астана бу түгәрәктә. Анта туwар[2] суйып, пешереп ашатып қатым уқыйтылар.

— Йыwан үгес килеп төшкән Байыш астанаға, бергем дә йыға алмаған аны. Аннары оллы қасан ығып[3] килгән. Үгесне суйып аш пешергәннәр, Иртеш буйда ашанғаннар. Иң оллы астана — Байыш астана, аңа хәйер бирәтеләр.

Цитәннәп қуйған астана, аwылтан алыс[4] түгел. Анта йасулы, уқығалы булаты.

**Күлцәк астана** *туб.*:

— Күлцәк астана күл итәгентә. Әргем үсенеке исәннек-саулыгына қорманнық қылаты. Қалықны йийатылар, мулла уқыйты.

### Астана қатым

**Астана қатым** *төм*. астана хатеме: изгеләр рухына багышлап кор---бан чалып, догалар укып үткәрелә торган дини мәҗлес.

[1] *Сәйипләнеп* — зәгыйфьләнеп.
[2] *Туwар* — хайван.
[3] *Ығып* — агып.
[4] *Алыс* — ерак.

— Астана қатым үткәреп торатылар. Кем таwық, кем қуй, кем каз апкерәте астанаға. Аны суйып, қатым уқытып торатылар. Астана---та қарағай, анта йәшик қағулы. Кем үтте, анта сатақа салып усаты. Ул сатақаны өләшәтеләр. Аннан йырлап, сүгешеп үткән кеше аwыру пулаты. Исерек кеше астана турытан үтсә аwыру пулаты. Аның ай---ырым қатымы бар, астана қатымы. Атна сайын уқытадылар. Аста---налы аwылта йәшәгән мин. Атам-инәм астанаta йататы. Астаната әүлийаларның өйе, чересә йаңартып торадылар. Исерекләр астанага садақа салған йәшикка. Кеше булып қаршыларына цыққаннар. Қан эц, дигәннәр. Алар аwыруға табылдылар. Кинтер қалым тигән суwы бар астаната, сандығацлар сайрый, кәкүкләр қыцқыра торған — *төм*.

— Өчтүбә астаналы аwыл ул, йақшылар күмелгән йер ул. Астананың йанында су булған, йақшыларның су қырынта утырғанын күргәләгәннәр. Әшүрә бәйрәм[1], әйет бәйрәмнәрдә[2] чығып утыраты---лар йақшылар. Менә қуй қуслайты[3] ғуй, бер куцқарны, инә қуйны суйғалы кәрәк астана қатымға.

— Қатым-дуwаларда тәкбир акцаға ике баш қуй алдылар, шал қуйларны астанада суйдылар. Тәкбир акца йийылаты, без қортқайақлар барып пешерәбес — *төм*.

## Астана садақа

**Астана садақа** *туб*. астанада күмелгән изгеләр рухына багышлап бирелгән садака.
— Аwыртсағыс астана садақа биргәле кәрәк.
«Пашығыс аwыртса — Пайыш астанаға,
Күсегес аwыртса — Күбәк астанаға садақа бирең», —
тип оллолар әйтеп қуйған. Аны пес йәшләргә әйтәбес.
Астаналарға садақа биреп йибәрәсең.
«Айақ-қулыңнан садақа».
Күл итәгентәге Күлцәк астанаға йибәрәсең.

[1] *Әшүрә бәйрәм* — гашүрә бәйрәме.
[2] *Әйет бәйрәм* — гает бәйрәме.
[3] *Қуй қуслайты* — сарык бәрәнли.

## Мазар

**Мазар** [*гар*. мазар] *нокр., т.я.-крш., м.-кар*. зират.
— Ашыйбыз, эчәбез, үлене сагынабыз да *мазар эстенә* китәбез. *Мазар эстендә* эч шәм җандырабыз, җымычка, салам җандырып ала---быз. Ул үлгән кешегә җактысын биреп тыра диләр энде — *т.я.-кр*ш.

## Мазар башлыклары

**Мазар башлыклары** *т.я.-крш*. дини мифологиядә генә телгә алы---налар.
— Үле мәндәне чакыралар. Тишеге өстенә куймагын куйалар да әйтәләр: «*Мазар башлыклары*, алып йөрүчеләр, алдан үлгән мәндәләр, җибәрегез, бүген кырыгын сагынабыз», — дип. Әйдә, китәбез, дип алып китәләр.

## Үлене мазарга илтү

**Үлене мазарга илтү** *т.я.-крш*. үлгән кешене зиратка күмәргә илтү:
— Үлене мазарга илткәндә алдан крус (тәре) күтәреп баралар. Крус алдыннан бер кеше *бодай сибеп* бара:
«Кошлар ашасын,
Җингеллек бирсен,
Җакшы урында булсын».

— Мазарга кырус (тәре) күт әреп, кыруска сөлге элеп барабыз. *Крус сөлгесен* крус йасап нагышлап теккән элек. Крус күтәреп барган кеше иман җырлап бара:

«И күктәге атабыз,
данлы бул.
Бүгенге көнне икмәгебезне
бир безгә,
Бурычларыбызны кичер,
Без наданнарны усаллардан сакла!»

Крустан алда берәү **иген чәчеп бара, бодай**:

«Тынычлык бирсен,
Үлгән мәндәләр бакилләсен», — диләр

**Мазар таwы**

**Мазар таwы** *нокр*. зират тавы.

Арталар да қалғыр *мазар таwы*
Йиз тағалы атым менәлми
(борынгы җырдан).

— Кемнең йәwерләре[1], қардәшләре *мазар тауда* йата, анда күмәләр — *нокр*.

**Мазар хәберлеге**

**Мазар хәберлеге** *нокр*. зират урыны.

— *Мазар хәберлеге* кара урман булган, дилир.

**Мазар эсте**

**Мазар эс, мазар эсте** *т.я.-крш*. зират өсте.

— Калач, чыгыт[2] алып баралар *мазар эскә*, шәм җандыралар, түгеп куйалар.

«Син каласын энде, җакшы урында бул, безгә дә җакшылык, җинеллек биреп тор», — ди, чыгып китәләр.

**Мазарлык, мазарлык эсте**

**Мазарлык** < мазар + -лык *т.я.-крш*.
**Мазарлык эсте** *т.я.-крш*. зират өсте.
— Эч атна була иде уйын, эч атнага тике ат'а идек уйын *мазарлык эстенә* җыйылып.
**Мазарлык эстенә су сибү** *т.я.-крш*.:
— Мазар эстенә китеп, келәү итеп кат'кан. Мазар эстенә су алып барган.

«Тук булыгыз мәңгегә», —

дип, себеркеләр белән мазарлык эстенә су сипкән — *т.я.-крш*.

[1]*Йәwер* — нәсел
[2] *Чыгыт* — түгәрәкләп пешерелгән эремчек күмәче; сыр.

**Мәйет**

**Мәйет** сүзе гарәп теленнән кергән: үлек, үләксә, үлек гәүдә; үлгән кеше.

Әстерхан сөйләшендә мәйет сүзенең зират мәгънәсендә кулланы---луы да очрый (мәсәлән, кундрау төркеме сөйләшендә).

**Мәйет** *әстр.-кунд*. зират.

— Мәйет үзебезнеке бар, җақын-җуwығыбызны мөселман мәйетенә күмәбез, далаға ташламыйбыз, қоршап[1] қуйған мәйет.

— Мәйетебез бездән дүрт чақырым. Аның аръйағында Хожатай дигән аwыл булған, җиде мичет, җиде ыру булған. Шул мәйеткә илтәбез без. Қуралған мәйетебез. Әүлийә қыз бар мәйетебездә, *ис чығарганда* искә алабыз.

— Анам, тутам кичелделәр[2]. Бары да бер мәйеттә җаталар. Қорман, ураза бәйрәмнәрендә мәйеткә барамыз, айақ кийемен алыштырып керәмез.

**Түбә, үле түбә, бабай түбә**

**Түбә** *әстр*. зират.
**Түбәгә алып китү** *әстр*. зиратка алып китү.

— *Түбәгә* йәшләр *йоғортып алып китәләр*, атлап та җитә алмыйсың, «йоғортып алып киткән үле — бик саwаплы», — ди. Йәшләр қош итеп очорып алып баралар.

— Түбәдә нийаз[3] өләшәләр, маты[4] өләшәләр. Түбәдә мулла қалып қорән укый.

— Үле өстендә гүрне җаwып бетергәч мулла қала. Ул җаwаплама қайтарып торма тийеш, уқып торма тийеш. Үлене күмеп қырық адым киткәннән сун фәрештәләр килер ди сорау сорама. Мулла аған уқып торма тийеш.

[1] *Қоршап* — киртәләп.
[2] *Кичелде* — үлде.
[3] *Нийаз* — хәер; садака.
[4] *Маты* — тукыма, ситсы.

## Үле түбә

**Үле түбә** *әстр*. зират.

— *Үле түбәдә* әүлийәләребез йата. Әүлийә қаберләре бар. Өйләрен батпақ (балчык) изеп сыладық. Өй эчендә утырғыч бар. Нораты әүлийә бар үле түбәбездә. Әүлийә қаберенең өй түбәсендә байрақ тора, ақ байрақ.

— Безнең *үле түбә* тулған диләр, безне қайа күмәрләр инде.
*Үле түбәне* қоршадылар тимердән, қараwыл салдылар үле түбәгә.

— Таш белән қуралған булган *үле түбә*.

## Үле түбәдән қайтқан әйберләр

**Үле түбәдән кайтқан әйберләр** *әстр*. зиратта мәетне җирләгәннән соң өйгә алып кайтылган әйберләр.
— Үле түбәдән қайтқан әйберләрне йумыйлар, әүләдә[1] җепкә генә элеп қуйалар.
«Йолдыз чықсын,
Йолдыз күрсеннәр әйберләр», диде.
Йолдыз күргәннән соң җыйыб алып, үтүкләп урынына салдылар.

## Бабай түбә

**Бабай түбә** *әстр*. зират.
— Үлене *бабай түбәгә* алып киткәч, балта белән ишек төбен чаба---быз. «Артық үлем булмасын» (Кундрау).

— *Бабай түбәдә* мулла қоръән уқый, нийаз өләшәләр.
*Үле түбәдән* иркәкләр[2] килә ләр, *бабай т*үбәдән. Алба[3] қуырылған, баwырсақлар пешкән. Түбәдән қайтқан затлар киләләр бар да.
**Бабай түбәгә бару** *әстр*. зиратка бару.

[1] *Әүлә* — ишек алды.
[2] *Иркәк* — ир.
[3] *Алба* — хәлвә.

— Атайлар мал суйып, бабай түбәгә барып коран уқыталар. «Игеннәр уңышлы булсын », — дип. Бабай түбәгә барып, әүлийәләребезне йаз итәбез[1], утызлап әүлийә бар бездә.

Әүлийәләр рухына бағышлап доға уқыйлар.
Җайдақ бабаның рухына бағышладым,
Йаңғырчы бабаның рухына бағышладым,
Сынық бабаның рухына бағышладым
Қырда Қызыр бабаның,
Суда Султан бабаның,
Мәгъриптән Мәшриккә
Исемен белмәгән әүлийәләргә багышладым.

## Үлек

**Үлек** *әстр.* зират.
— Сезнең *үлегегез* кайда?
*Сағызлы үлек, Қурал үлек* бездә, берничә үлек. Кем кайсы ыруw ына қарый. Әwәлдә тоқом-туғаннары қайда булған, шунда әкитәләр иде мәйетне.

— *Бабай атам дигән үлек* бар, анда да күмәләр. Қуралган[2] ул *үлек*. Менә әле ул *үлектән* барып туфрақ алып кайттым. Ул *үлекнең* хуҗасы булған, аның өйе бар, тәрәзәсе бар. Аның туфрағын китерәләр аурап киткән кешеләр. Туфрағын суға салып ырым итәләр.

— Қуралға үлене алып киткән сун барына да қомғабарны[3] қап---тырып чыға.

## Иске үлек

**Иске үлек** *туб.* изгеләр зираты.
— Иске үлекләртә нәрәситә йақшылар[4] йата, цитәннәгән ул иске үлекләрне, анта астана булып қалған.
Иске үлекләр тип әwәлге қаберләрне әйтәбес.

[1] *Йаз итү* — искә алу.
[2] *Қуралган* — киртәләнгән.
[3] *Қомғабар* — хәлвә.
[4] *Нәрәситә йакшылар* — бала вакытта үлгән изгеләр.

## Үлемтек

**Үлемтек** *т.кам.-крш.* зират (Менделеевск р-ны, керәшен сөйләшендә). — *Үлемтеккә* үле келәwенә барабыз көз көне. Үлеләр келәwе *үлемтектә* чәчемнек җанында була.

— *Үлемтеккә* синтәбер айында , йегерме беренче синтәбердә бара---быз, ул изге кыз Марийәнең туган көне була. Үлемтеккә барып, қабер өстендә утырабыз, булған ашамлықларны алып барып бер-беребезне сыйлашабыз. Башқаwыллардан да киләләр, иман җырлыйбыз.

## Каберлек, каберләр өсте

**Каберлек** [гар. кабер + -лек], **каберләр өсте** *срг.* зират, мәет күмү урыны.
— Мулла уки ченаза намазын. Ченаза белән илтәлә р дә каберлеккә. Ченазага сөлгелә р белән куйалар, ап-ак сөлгеләр. Ул сөлгеләрне каберләр өстендә ченазадан алалар күтәреп баруцылар.

## Иске каберлек

**Иске каберлек** *срг.* иске зират.
— Бер күл бар, төпсез күл. Төпсез күлнең бу йагында иске каберлекләр. Элгәре сука белән сукалаганнар, кеше сүwәкләре цыккан. Сүwәк цыккац шында йама[1] күтәрәләр, шыл иске каберлекләр була. Элек халык бик зур булган, кесәләренә сукаларын тыгып йөргәннәр, себеркеләрен (тырмаларын) аркаларына асып йөреткәннәр. Шылай сүли иде әти. Әцәтләр[2] кыцкыра икән. Шындагы кабер әһелләренең рухына дыва кылабыз, йад итәбез[3].

## Гүр, кабер, тишек

Үлгән кешене күмәр өчен казылган чокыр әдәби телдә кабер яки гүр дип атала.
**Гүр** — фарсы теленнән.

[1] *Йама* [рус.] — чокыр.
[2] *Әцәт* — әтәч.
[3] *Йад итү* — искә алу.

**Кабер** — гарәп теленнән кергән сүзләр. Җирле сөйләшләрдә дә шул ук сүзләр кулланыла. Тау ягы керәшеннәре сөйләшендә **тишек** сүзенең кулланылуы кызыклы.

## Тишек

**Тишек** — тау ягы керәшеннәре сөйләшендә кабер мәгънәсендә кулланыла.
— Мазарда (зиратта) тупыракны казилар өч кеше, *тишек* җасилар тубык (табут) керерлек итеп. Бер митыр җарымнык тишек казилар да җиргә тыгалар тубыкны.

«Җирдән булган,

кабат җиргә кайтып җат», —

диләр.

— Үлегә *тишек* казилар алмаш-тилмәш. Тупырагын аталар читкә.

— Тишек өстенә крус[1] куйалар үлене каберләгәч. Крус өстенә та---стымал элеп куйалар.

### Тишек урыны

**Тишек урыны** *т.я.-крш.* кабер урыны.

— *Тишек урынын* казый башлагинса иман әйтеп тимер көрәк белән кырус (тәре) сызып куйалар.

**Урын акчасы** *т.я.-крш.*: — Кабергә тийенле акча тәңкәләре таш---лыйлар башта, «урын акчасы» дип.

**Тишектән чыгып җөрмәлле** *т.я.-крш.*:

— Үле мәндә *тишектән* чыгып җөрмәлле, сагынганда, чакыр---ганда ызбасына кат'ып утыра. Анн өчен үле мәндәне чабата кигезеп күммәлле, чабата унай була тишектән чыгып җөргәндә. Чулка[2] белән чабата кигезә, тишектән чыкмаллы дип.

### Тишек казучы

**Тишек казучы** *т.я.-крш.* кабер казучы.

— *Тишек казучыларга* бирнә бирәләр, тастымал.

[1] *Крус* [< рус. крест] — тәре.
[2] *Чулка* — оек.

### Тишек өстенә куймак (коймак) куйу

**Тишек өстенә куймак куйу** *т.я.-крш.* кабер өстенә ашамлыклар кую.

— Үле мәндәне сағынғанда тишек өстенә куймак куйалар.

«Җибәрегез өйенә, менә сезгә алдан үлгән мәндәләр».

### Гүр

**Гүр** [< фарсы] кабер, кабернең эчке өлеше.

**Гүр турында мөнәҗәт** *каз.ар.*:

Зифа буйыңны
Үлчәп алырлар,
Караңгы гүргә
Илтеп салырлар.
  Шатланыр ыйым
  Атнакич үлсәм.
  Йомага хәтле
  Гүрләргә керсәм.

**Гүр** сүзе «Кыйссаи Йосыф»та (162 б.)

Күрклү йүзләр кәфен сарыб гүргә керсә,
Үкүш дәгүл, гүр эчендә үч күн дорсә...
  Күрекле йөз кәфен сарып гүргә керсә;
  Күп тә түгел, гүрендә тик өч көн торса...

**Гүрестан** [< фарсы] каберлек.

— *Гүрестаннары* билгеле, шунда күмгәннәр без әле чумылмаған[1] чақта — *каз.ар.-крш.*

### Гүр аузы ачу

**Гүр аузы ачу** *крш.* — кабер казый башлау. — Зиратта җирне кы---рислап (рус. крест + лап) куйа да *гүр аузы ача*, чирәмне күтәрә. Кабер казып бетергәчен, шул кырислаган чирәм белән өстән каплап куйа — *т.кам.-крш.*

[1] *Чумылмаған* — христиан диненә кертелмәгән

### Гүр аузы ачучы

**Гүр аузы ачучы** *чст.-крш.*, *т.я.* — кабер башлаучы. — *Гүр аузы ачучыны чакырабыз* җыллыг ашка — *чст.-крш.*

— Гүр аузы ачучыға чүпләмә[1] бирәләр, чүпләмә дип әйтәбез ша---дра сөлгене — *т.я.*

**Гүр аузы ачучы** *т.я.-к.т.*:

— **Гүр аузы ачучы** була,
**булышучылар** була,
**дүрт чатлыққа** қалучылар була. Алар зират өстендә қалып уқыйлар.
**қабер қазучылар**,
**ләхет алучылар, күмүчеләр** була.

Барысына сәдәхә бирәбез, қулҗаулыққа, йә тастымалға төреп ақча бирәбез — *т.я.-к.т.*

## Гүр казучы

**Гүр казучы** *м.-кар.* кабер казучы.

— Гүр казучыларга шулба пешерә, эшти, бутка пешерә, кесәл куйа. Иң актыктан бал куйалар.
«Бал — әҗәл ачысын бетерә»

Чугынган вакытта да бал куйалар.

## Гүр цабу

**Гүр цабу** *срг.* гүр чабу, ягъни кабер урынын билгеләп, балта белән чабып кую.

— Каберне үлциләр буйын, аткырысын. Гүр цабу диләр. Бер кеше балта белән цабып цыга, шыл кырыйдан тотыналар кабер казарга. Гүр цаба уки белгән кеше. Әлхәмне, кылыхуалланы уки. Үлцәп буйын алган агацка **салыр**[2] әтәләр, аны кабер өстендә калдыралар. Икенце кешегә кабер казыганда шыл салыр белән үлциләр.

[1] *Чүпләмә* — кулдан сугылган сөяге.
[2] *Салыр* — кабернең озынлыгын билгеләү агачы.

## Гүр цабуцы

**Гүр цабуцы** *срг.* гүр, ягъни кабер башлаучы.

— Гүр садакасын гүр цабуцыга бирәләр, кем гүрне пирбуй цаба.

## Гүр ашы

**Гүр ашы** *туб.* кеше үлгән көнне пешерелгән ашамлык, гадәттә, қоймак пешерәләр.

— Гүр ашы дип қоймақ қойатылар, қырбаштан күмеп қайтқан кешеләр керәте қоймақ белән цай эцкәле.

## Гүр ийәсе булу

**Гүр ийәсе булу** — вафат булу, үлү.

## Гүр ишеге

**Гүр ишеге** *м.-кар., глз.* — фольклорда телгә алына торган гыйбарә.

— Барып карар идем гүреңе,
чыгып сүләшергә *ишегең* булмас — *м.-кар.*

Аклы ситса күлмәгемнең
Сәдәб ачыклары йук.
Үлгәченнән күрешергә
*Гүрнең ишекләре* йук — *глз.*

## Гүр қорманнығы

**Гүр қорманнығы** *туб.* кеше үлгән көнне корбан чалып уздырыла торган мәҗлесе.

— Гүр қорманнығы тиде үлгән көнне. Пер қуйны[1] пешерәсең күмгән көнне.

— Сиратқа алып цығып китә үлекне, қасанға қорманнық итен са---лып йийаты пешергәле.

[1] *Қуй* — сарык.

## Гүр садақасы

**Гүр садақасы** *том., бәр., минз.* үлгән кеше өчен бирелә торган хәер.

— Гүр садақасына бер боға[1] биргәннәр — *том.*

— Элек гүр садакасына дип мәйетне алып чығып киткәнче таwық бирә торғаллар ыйы. Мәйеттән алдан уқ алып чығып китә торғаллар ыйы инде муллаға бирергә.

Таwықның айақларын жуып, чичтартып бирә торғаллар ыйы гүр садакасына.

Гүр садакасына қара таwық биргәлләр элгәре, хәзер нинди таwық та йарый — *бәр.*

— Гүр садақасын хужаның үзенә кире қайтарып, садақа итеп бирәм ди, доға қылыйк ди.

Биргән садақаң қабер эчләрендә нур булсын,

Зират күперен кичкәндә җитәкче булсын,
Тамуғ утларына пәрдә булсын,
Кылған гөнаһларын йарлықасын, — дип доға қыласың.

— Өй хуҗасы әйтә: «Мулла абзый, миннән гүр садақасына сарық», — дип әйтә йә таwық ди, йә ақча бирә.

Гүр садақасына дип доға қылдырғачын, «Менә хөрмә тле қунақлар, гүр садақасы дип әйтелгән таwықны шушында пешереп турадық», — дип доға қылырсыз, диләр.

## Гүрләр эсте

**Гүрләр эсте** *м.-кар.*, **гүрләр өсте** *крш.* зират өсте.

## Гүрләр эстенә бару

**Гүрләр эстенә бару** *м.-кар., крш.* ашау әйберләре алып зиратка бару.

— Чугынгачын, кешеләрне ызаткач *гүрләр эстенә* бара, алып бара җоморткалар, табикмәкләр, җарма. Шунда гүр эстенә ватасын, җарма сибәсен, ашау әйберләрен вата’лар гүрләр эстендә.

[1] *Боға* — үгез.

*Гүрләр эстенә*:

— Трус’кай кенендә — троицын көнендә,

— Пәтрау кенендә — питрау көнендә,

— Ол’о кен кенендә барабыз — пасха көнендә барабыз.

— Бетен кеше бара *гүрләр эстенә*. Үзенн туганнарына бетенесенә гүрләргә сибеп чыгасын шулай, тары җармасы, пичинҗе ватасын, җомортка ватасын, бетенесен ватып чыгасын гүрләр эстендә. Әйтәсен инде:

Усал сагынма инде,
Куркытма, эркетмә инде,
Артын бәк булсын,
Йакшы бул, тынгыч бул,
Күңрәнмә (күңелсезләнмә), дисен.

— Мына без дә *гүрләр эстенә* бардык, бабайны ашаттык, чушыны-чушыны илттек. Шикәр кирәг иде илтәргә, ди, малайым әйтә, бабай чәйне шикәр белән эчә иде, әйтә — *м.кар.*

**Гүрләр өстенә бару** *т.кам.-крш.*:

— Түгемнәрдә *гүрләр өстенә* барабыз, **иман җырлап** кайтабыз. Өйдә нәрсәкәй пешкән булса, шуны гүр өстенә алып барып, ашап, ***тәберсе итеп***, калганын шунда *кач* төбенә иман әйтеп куйып калды---рабыз. Анда өч төрле әйбер кала: *йомырка, су, күзикмәк*.

«Әрберсе *өлешле* булсын, берсе дә кул сузып миңа булмады дип тормасын», — дип әйтеп әйбәтләп куйып калдырабыз **гүр тәберсене** итеп.

— Үле күмгәндә дә, үзебез генә зиратларга барганда да башта кап---ка төбенә килеп чукынабыз иман әйтеп. Капкадан кергәндә ике йакка да «әрберсенә» дип ыризык куйып, су куйып калдырабыз. Зираттагы әрберсе өчен дип, өлешсез калмасыннар дип куйабыз.

— Зиратта ыризыкны калдырганда «әрбере өчен» дип әйтеп куй---арга кирәк, барысы өчен дә дип әйтү дөрес түгел. Бари дигән бер бик начар күңелле әдәм булган. Ул үлгән. Шул барын җыя, алып үзенә туплар икән дә үле-тереләребез сусыз калыр, ач калыр, өлешсез калыр ди. Шуның өчен *әрбере* дип әйтергә кирәк ди.

Зиратта гүрләр өстендә җыйылышып утырып тәберсен әйтәбез.

## Гүрләр өстенә су сибү

— Җаңгыр сорап келәү итәләр иде карчыклар, картлар. Кажни кырга тәреләр белән чыгалар иде. Ул кенне кийа иде йаңгыр.

Гүрләр эстенә баралар иде тәрелә р белән. Ул кенне дә йаңгыр йаwадыр иде. Каберләргә чиләк белән су илтәләр иде. Шулай вис си---беп җөридер иделә р гүрләргә. Саңа да вис сибә суны, саңа тарыса да җарый. Бу капкага баралар иде бежек тәреләр белән. Ничә капка бар аwылдан чыга торган, вис баралар иде тәреләр белән. Су сибәләр иде. Шул кенне бик җаңгыр җаwадыр иде — *м.-кар*.

**Гүрләр өстендә туwа (дога) уку** *себ*.

Тар гүрең кәң (киң) булсын,
Қараңгы гүрең йарық булсын,
Йатқан йирең йомошақ булсын,
Аwыр балчықларың йиңел булсын,
Аллаһы тәгалә иман байлығы бирсен,
Мөхәммәт өммәтләрендә бул,
Урының очмах булсын,
Риса бәхил бул.

Йалған дөнйа қалды, иткән тәрбийәгә, әхирәтлеккә ыриса бул — *бараба*.

Минем бүген түрем,
Иртәгә гүрем,
Ышанма йәшлегеңә,
Тайанма саулығыңа.
Йәшлегең җил тик үтәр,
Қарыйлық ни хәл итәр, диде — *әстр*.

### Гүргә индерүче

**Гүргә индерүче** *глз*., *т.я.-к.т*. мәетне кабергә төшерүче.

— *Гүргә индерүчегә* бер сыл’гы биралар — *глз*.

— Мәйетне гүргә индерүче қайта, қоръән уқый җәймә җәйеп. Аңа шул қоръән җәймәсен биреп җибәрәләр — *т.я.-к.т*.

### Гүргә куйу

**Гүргә куйу** *кузн*. үлгән кешене кабергә төшерү.

— *Гүргә куйганда* әз генә уң йаккарак йаткызалар.

### Гүргә төшерү

**Гүргә төшерү** *срг*. кабергә төшерү.

— Сөлгеләр белән алып бер кеше төшерә гүргә өцәр митырлы сөлгеләр белән. Күлдән камыш урып китерәләр, кабергә салалар.

**Гүргә тешерү** *м.-кар*. кабергә төшерү.

— Гүргә тешергәндә битсеберләр[1] бирәләр ирләргә.

### Гүргә салучы

**Гүргә салучы** *тмн*. мәетне кабергә төшерүче.

— *Гүргә салучыларга* йеслек (сөлге) бирәләр.

### Гүргә туфрак сибү

**Гүргә туфрак сибү** *м.-кар*.

«Аwыр тупрагың җиңел булсын.
Артың бәк калсын», —

дип, *тупрак сибәсең* гүргә эч тапкыр.

### Гүрләндергән кеше

**Гүрләндергән кеше** *глз*. мәетне кабергә төшергән кеше.

— *Гүрләндергән кешегә* селге айыралар. Гүргә тешергән кешегә аның элеше, элеш-тырышы дип.

### Гүрләү

**Гүрләү** *глз*. күмү.

— Сагат умбердә апайымны гүрләмәгә йердем. Апайымны гүрләмәгә Парҗы аwылына бардым.

### Кабер

**Ққабер** — гарәп теленнән кергән сүз: үлгән кешене күмәр өчен ка---зылган махсус чокыр; үлек күмелгән урын.

[1] *Битсебер* — сөлге.

### Ққаберстан

**Ққаберстан** *әстр*. каберлек.
— *Ққаберстанның* аwызы ачық торор ди, бәбәй туған (тудырган) хатынға қырқыннан чыкқанчы эш эшләмәгә қушмыйлар, қазан-айақ астырма җарамай.

### Ққабер аузы ачу

**Ққабер аузы ачу** — каберне казый башлау.
— Айателкөрси уқып, әлхәмне уқып, **қабер аузы ачалар**. **Ққабер аузы ачучыға** зурырақ бүләк бирәләр инде. Йә күлмәк, йә тасты---мал — *к.-уф*.

### Ққабер аузы ачқан кеше

**Ққабер аузы ачқан кеше** — каберне беренче булып казый башла---ган кеше.
— *Ққабер аузы ачқан кешегә* җә башай[1], җә эрзиңкә, җә жақшы та---стымалын бирәләр — *минз*.
— *Қәбер аузы ачқан кешегә* тастымал, сөртүләр[2] бирдек — *к.-уф*.

### Ққабер почмағында утыручы

**Ққабер почмағында утыручы** *каз.ар.-мам*. кабер янында утырып дога укучы.
— Қабер почмағында утыручы дүрт кеше була.
«Қабергә җен төшмәсен», — дип.
Аларға тастымал бирәләр.

### Дүрт мүгешкә уқу

— Дүрт мүгешкә[3] уқыйлар қәбердә, сәдәқә тараталар, тастымал бирәләр қартларға — *к.-уф*.

[1] *Башай* — оекбаш
[2] *Сөртү* — сөлге.
[3] *Мүгеш* — почмак.

## Қабер ацқан кеше

**Қабер ацқан кеше** *төм*. кабер казучы.

— Қабер ацқан кешегә питйаулықҰ[1] пирәтеләр.

## Кабер башлаучы

**Кабер башлауцы** *срг*., **хәбер башлаучы** *кузн*. каберне казый баш---лаучы кеше.

— *Хәбер башлый* бер бабай, ике катмы, эч катмы кази да китә — *кузн*.

— Кифенне печә, *хәберне барып башлап килә* мулла. Хәбер бетә, йывындырыга ылатлана[2] — *тмн*.

— *Кабер башлауцыга* йә күлмәк, йә зур селге бирәләр. Нәсел---нәсәбәсеннән укымыш кеше булса башлый кабер — *срг*.

**Кабер башлаучыга** бирәләр **тимер** акча. Анда үлчиләр ди, ә тимер манит ул аwыр тарта. Аның әҗере бар — *влгг*.

## Қабер башлап қуйу

**Қабер башлап қуйу, кәс алу, чирәм алу** *к.-уф*. кабер башлау.

— *Кәс алу, чирәм алу* диләр, анына ойоқбаш йә бийәләй бирәләр, иләсә[3] инде. Ул *қабер башлап қуйа* қый.

[Ырым]:

— Қәбер ачқач күwәнтәләп суға бармаға қушмыйлар, қәбере җабылғач җарый. Қәберен қузғатқанчы су алып қалығыз, ти.

## Қабер қазарға йөрү

**Қабер қазарға йөрү** *к.-уф*.:

— *Қабер қазарға* йөриләр йәшләр, күп булып баралар зиратқа. Туй шикелле була.

[1]*Питйаулық* — сөлге.
[2]*Ылатлана* — җайлана.
[3]*Иләсә* — бияләй.

## Қабер казучы

**Қабер қазучы** *урт.д*.:

— *Қабер қазучыларға* чатына ақча түнәп җаулықлар әзерлибез, ирләр қулҗаулығына түнибез, садақалар өләшәбез — *т.я.-к.т*.

**Кабер казуцы** *чст*.:

*Кабер казуцыларга* — акца да, салфит (тастымал) та бирә.

— Кулйаулыкка унар сум акца түнәп бирәләр нүwешенә[1]. *Кабер казуцыларга* күберәк бирәләр, салфит бирәләр.

**Кабер қазучы, күмүче:** — *Қазучыларга* бистәрен[2] (сөлге) бирә, *күмүчеләргә* җаулық бирәләр — *каз.ар.-крш*.

## Қабер қасқалы пару

**Қабер қасқалы пару** *төм*. кабер казырга бару.

— Қырбашқа[3] парапыс қасқалы, қабер қасқалы парапыс тиләр.

## Қабер қасырғалы

**Қабер қасырғалы** *төм*. кабер казырга.

— Қабер қасырғалы пөтен йәшләр цығаты. Қабергә түрт мөйөшенә[4] перәр манит салапыс.

## Қабергә салу

**Қабергә салу** *минз*.:

— Қабергә салғанда әйтәләр:

Тар қаберләрен киң қыл,
Қараңғы гүрләрен йақты қыл,
Иман белән хөрмәтлә,
Ахирә ткә иман белән кучә ргә нәсиб ит,
Тәмуғ утларын харам қыл, йарабби.
Илаһи нийәт қылтым
Бу қатым-кучаның тоғаларын уқымаққа,
Тән wә җан сәләмәтлегенә,
Дөнйа wә ахирәт өчен,
Қабул иткәй идең,
Қоръән нуры белән
нурландырғай идең, амин.

[1] *Нүwеш* — почмак.
[2] *Бистәр* — сөлге.
[3] *Қырбаш* — зират.
[4] *Мөйөш* — почмак.

## Астана қатым

**Астана қатым** *себ.* изгеләр каберенә, изгеләргә багышланган дини мәҗлес.
— Астана қатымнарны үткәреп торатылар — *туб.*

## Йақшылар қатымы

**Йақшылар қатымы** *туб.* изгеләр рухына багышлап үткәреләә тор---ган дини мәҗлес.
— Йақшылар қатымына атақлап қуцқар суйабыс.

— Йақшылар қатымын уқытып торабыс, менә үткәсәм йақшылар қатымын. Аwылтағы қортқайақлар, қартлар киләте. Патиға қылды---рып, атақлап суйдырдым қуцқарны. Аwылтағы қортқайақлар, қартлар киләте. Патиға қылдырып, атақлап суйдырдым. Сөйәкләрен таса йиргә генә күмгәле. Қортқайақлар үсепес қызмәт қылғалы барапыс табақ-саwытлар алып. Ике рәқәғәт намас уқып алапыс:

Илебесгә-йортыбысға,
Күрше қунағыбысға
Тыныцлықлар булсын — *туб.*

## Мәүлет қатым

**Мәүлет қатым** *себ.* мәүлит бәйрәме мәҗлесе.
— Пес мәүлет қатымны уғытабыс, менә монтай баwырсақ, урама---лар, кисмәләр бешерәбес — *туб.*
— Мәүлет қатым уғытқаннарның теге төнйата маңлайлары йалты---рап тора, имеш — *туб.*

## Үлекләр қатымы

**Үлекләр қатымы** *туб.* барлык үлгән кешеләр рухына багышлан---ган дини мәҗлес.
— Үлекләр қатымын цым көнентә[1], май айында йасайтылар.

## Қәтем-қоран

**Қәтем-қоран** *әстр.* дини мәҗлес.
— Мичеттә қәтем-қоран булады. «Үле-тереләргә өлеш» дип тамақ (ашамлык) илтәләр мичеткә.

## Өчесе

**Өч ақшамы** *т.я.-трх.*, **эченче акшамы** *тмн.* өчесе, өченче көнендә үлгән кешене искә алу.
**Акшам** [фарс.] — кич, эңгер-меңгер.
— Пешерәсе килгән кеше *өч ақшамына* жуқа пешереп килә, саwым белән. *Эченче ақшамын* үткәргәндә умбишәр, җегермешәр саwым була, биш күмәч, жуқа була, парсыз була — *т.я.-трх.*
— *Эченче ақшамына* дыва кылдырасын — *тмн.*
— **Өч ақшамын уқытқанчыға** хәтле өйдә ашамыйлар. Ул wақытта эш эшләргә дә, ашарға да рәтең булмый.

Күмгән көнне бер ақшамы, икенче көнне икенче ақшамы, өченче көнне **өченче ақшам**. Ақшам намазы бар бит инде, кич белән ақшам намазы уқыйбыз бит. Дүртенче көнне қөръән уқытып өйдә ашағаннар инде — *т.я.-к.т.*

**Өче, өчесе, өч көне** *урт.д.*, **эченче кене** *кузн.*, **өч киче** *кузн.* — кеше үлгәч өченче көнен искә алу мәҗлесе.

— *Өченә* пылау бастырады, қуй суйады, пилмән кешерәде — *әстр*.
— *Эченче кенендә* йертүк белен пешерәләр, ыланнар йийа, сары май белән генә ашилар — *кузн*.
— *Өч көненә* кимак пешереп сагынып ашилар.
«Үлгән мәндәләргә туклык булсын» — диләр.

[1] *Цым көне* — үлгәннәрне искә алу көне. Цым < әд. җим.

— *Өч кичендә* чәре[1] ашарга йарами үле чыккан үдә. Өч көнендә май исе чыгарырга кирәк. Катлама пешерәләр, өстәлгә тоз куйарга кирәк — *кузн*.
— Үлекне искә алып өцесенә қатым аш йасый.
— Ирләр үлсә ки өчендә ирләр була үлек ашында, йедесендә ка---тыннар — *нокр*.
Катыннар үлсә ки, өчесендә катыннар була үлек ашында, *йедесендә* ирләр — *нокр*.
— Бездә, Камкада, өц кицәсе йуктыр, зиде кицәсенә тәкле[2] мулла уки каберләр өстендә — *срг*.

— Өчесендә өч тапқыр әйләнәбез қаберен.
«Әйдә, синең бәйрәмең, қайт», — дибез.
Җидесендә дә шулай җиде тапқыр әйләнәбез қаберен — *т.кам-крш*.

— Зиратқа чығып киткәнче сарық суйалар. Алар чақырып қайтуға қазан асалар, әзерлиләр, туғаннарын чақыралар. Кем **боламық,** кем **қыстыбый** пешерә. Һәрқайсы үзенең тәлинкәсе белән күтәреп киләлә р ийе элек. Ике-өч көн торғач, теге саwытларын алып китәләр ийе — *т.кам.-крш*.

**Өц кицәсе** *срг*. өчесе.
— Өц кицәсенә үдәге таwыкны суйып хатем укыталар.
— Бездә, Камкада өц кицәсе йуктыр.
— Бездә Чембилидә өц кицәсенә кимак пешерәләр. Түлке бутка куймилар. Бутка бүртә, куйыра. «Үле куйыра, күбәйә», — дир. **Wак бөкмә**[3] йасилар, ит бөкмәсе[4].

**Өче**

**Өче** *әстр*.:
*Өче*, җидесе, кыркына пылау бастырады, куй суйады. Шул куйны пешереп бетерәде.

[1] *Чәре* — кадәр, хәтле.
[2] *Тәкле* — кадәр, хәтле.
[3] *Wак бөкмә* — кечкенә бөккән.
[4] *Ит бөкмәсе* — ит бөккәне.

— *Өчендә* пешермәгә кирәк колак пилмән[1], ак пилмән, колак бүрәк[2]. Шулпа пешерелә. «Мәйетнең күзенә ком кермәсен», — дип ко---лак пилмән пешерелә.
*Өченә* инде җир алганнарын, *өстенә кергәннәрен*, йуганнарын ча---кырып корән укытасың.

— *Өченә* әзерләнәделәр. Өченә инде аш йасыйлар инде бездә, пил---мән. Шулпалы итәсеңме анда, шулпасызмы, ничек тели җорт ийәсе.

— *Өченә*, җидесенә, кырыгына бөтен аwыл килә. Кем җуган, кем ләхеткә иңдергән алар килә, аларны ыризалаталар.
Икешәр куй суйалар үле ашына. Алдан картыраклар, алар ар---тыннан йәшрәкләр, алар артыннан балалар керә. Күбесенчә шулпа пешерәләр.
**Өче** *к.-уф*.:
— *Өчен* уздырғанда қан чығарыға кәрәк дип мал суйабыз.
— Қан сығаралар, сарық суйалар өсөнә.
**Мәйет күмгән көнне өчесен уздыру** *к.-уф*.:
— Безнең аwыл халқы қайсы-берсе мәйет күмгән көнне үк *өчесен* уздырып қайтып китә.

— Мәйетне алып чығып киттеләр, өйен йыудылар, мичкә йақтық, мийа қоймақ пешерегә құштылар, балалары өстәл әзерләргә йәбеште. Бабайлар зийәраттән төшүгә без өстәл әзерләдек. *Өчесен* шулай узғырдылар.

— Қайсысы үлгән көнне үк *өчесен* дә, *җитесен* дә уздырып қуйалар. Алдан йарамый дей ул — *к.-уф.*

**Җидесе**

**Җидесе** — үлгән кешене җиденче көндә искә алу, дини мәҗлес.

**Зиде киҵәсе, йедесе**

**Зиде киҵә се** *срг.*, **зидесе, зидесен күтәрү** *күрш.* җиденче көнендә үлгән кешене искә алу.

[1] *Қолак пилмән* — пилмән.
[2] *Қолак бүрәк* — кечкенә бөккән.

— *Зиде киҵәсендә зиде әйбер пешерәләр.* Белем, бераз кимак, цигелдәк[1], әрбер киц башында бер аш була зиде киҵәсендә. *Зиде киҵәсендә* халкны цакыралар — *срг.*

**Зиде азбарга эләштерү**

**Зиде азбарга эләштерү, зиде зиргә бирү** *күрш.*:
— Кимаклар пешерәсен и шуны зиде азбарга эләштермә кирәк *зидесенә* — *күрш.*
— Пишкаларны[2] зиде зиргә цырнап бирәсен көпшәкләрне[3], күләкләргә[4] цырнап — *күрш.*

**Зидесен күтәрү**

**Зидесен күтәрү** *күрш.*:
— Үлгәц ницек күмәләр? Бер киц кундыралар, икенце кенне күмәләр. Эц көн узгац хатемен кылалар, сун *зидесен күтәрәләр* зиде кен узгац — *күрш.*
**Зиде киҵәсенә сетләш** (ботка) куймыйлар *срг.*:
— Зиде киҵәсендә *сетләш куймилар*, аның урынына куйалар *зиде төрле* аш. Кимактыр, цигелдәк, сомса[5] шундилар куйалар. *Сетләшне куймилар* шуның эцен, йорттан үле кат-кат цыкмасын эцен, куйырма---сын, күбәймәсен, дип. *Сетләш бутка* куйырта, дир — *срг.*

— Зиде киҵәсе — аш була, шурба. *Бутка куйылмый*, үле куйыра, ди. Коры ашлардан[6] зиде төрле аш була: цәй, кан’ар аш, пилминчә, катык йазалар, катлама, белен, кимак, цөце катлама, кыстырма, умак, күптермә, цигелдәк кәкәш — *срг.*

— Зиде киҵәсенә тәкле бабай йөретә идек. Мулла килеп пирут каберләр өстендә уки, аннан үгә килеп уки — *срг.*

[1] *Цигелдәк* — чәкчәк.
[2] *Пишка* [< рус. пышка] — кабартма.
[3] *Көпшәк* — икмәк.
[4] *Күләк* — күлмәк.
[5] Сомса — сумса, бөккән.
[6] *Коры аш* — камыр ашамлыклары.

— Зидесенә аш суйалар, куй. Шул ук иттән пәрәмәцләр пешерәләр wакларны гына. **Үлек пәрәмәце**[1] пешерәләр. Кырыгында инде пәрәмәц пешермиләр — *срг.*

**Җиде көнен уку**

**Җиде көнен уку** *кас.*:
— *Җиде ’энен* зират’а барып у’исын ’ош булса инде зират’а бара ал---масан дала’а чы’ып, абзар’амы чы’ып, ’аба’ теп’әме чы’ып у’исын — *кас.*
**Җидесендә куй** (сарык) **сую, кан чыгару**:
— *Зидесендә* кирәк *куй суйма*, күбрәк кан цыгарма кирәк — *күрш.*

— Кан’ар аш китергәнче катлама белән майны ашаклилар. Сун китерәләр ит, иттән сун бутка, бутка ашагач лакша[2]. Кул күтәреп тарилкәләрне җыйабыз да камыр ашлары төзиләр. Кан чыгарма кирәк җиде көнендә. Зур тувар суймыйлар, тавыкмы суйалар. Элеке заман---да кийгән кеше итә иде бәлешләр хатемгә. Бер унике бәлеш җыйыла иде. Кагыт[3] саламысыз чәйгә? *Рязань өлк., Әзи ав.*
— *Җидесендә* дә қан чыҕара қайсы кеше. Аш пешерегә кәрәк бит барыбер — *к.-уф.*
**Җиде көнендә табисе** (таба исе) **чыгару** *т.я.-крш.*:
— *Җиде көнендә* табисе чыгарып кимак пешерә, үлене сагынып ашилар.

**Җидесе, җиде кораны** *әстр.*:

— *Җидесенә* кеше күп чақырылады, *җиде коранын* укыталар. Җиде коранында коран чыгартабыз.

**Җидесенә хәтле үле чыққан өйгә әйбер китермиләр** *әстр.*:

— Җидесенә хәтле китермиләр әйбер *үле чыққан өйгә.*

«Җидесенә хәтле китерсә, *җитәкли ди үле*».

Қырығына, йөзенә, йылына китерәләр.

**Җидесендә юган, күмгән, кешеләрне ризалату**:

— *Җидесендә* йуған халыққа қайсына чөлкә (оек), кайсына рубашка, кайсына башка кийем сала.

«Үле йаланғач булмасын, қыйәмәт көнендә йаланғач қупмасын», — дип. — Үлгән көннән алып җиде көн йылашып утыралар — *әстр.*

[1] *Үлек пәрәмәце* — бик вак пәрәмәчләр.

[2] *Лакша* — токмач.

[3] *Кагыт* — как.

## Җиде қаберче, җиде кораны

— Җиде қаберчегә җиде коранында **пылау** җибәрәләр өйенә. Пы---лау өстөнә өч төрле **бәйрәмашлар** салалар: **қузбурәк, қатланчық, пәрәмәчә** — *әстр.*

— Җидесендә инде ир кеше үлсә ир күлмәкләре бирәсең йуындырған, ләхеткә иңдергәннәргә. Хатын-қыз булса хатын-қызларға **таwар материаллар** бирәсең. Өйеңне җыйыштырған кешеләргә дә йаулықлар, сөлгеләр булсын бирәсең, ыризалатасың. *Җиде қоранында* инде қоран чығартабыз, қырқында, йылында саубуллашу қораны уқытыла.

— Җидесенә инде өстен йуған белән қабер алғаннар керә, чақырырға тийешле. Чақырмады дип әйтәләр. Чақырып та килмәсә, ашын, суын, пылаwын, барын да җибәрәләр. Җир алғанға, өстенә кергәнгә бирмәгә тийешле ашын-суын.

— Аwылда кем әкитеп барған үлене, җидесенә, қырқына, йылы---на барысы да чақырыла. Сиксән кешеме, йөз кешеме. Бер қазан да әзерлисең инде, биш қазан да әзерлисең. Әwәлдә шулай булган. Утыз---утыз биш кила дөге пешә.

Җидесенә әбизәтелни пылау булады.

— Үлене зиратқа алып киткәч, йылашып қалған хатын-кызларға мин қорән укыйм. Үлгән көнендә ашамыйлар, чәй эчмиләр, тик *җидесендә*, қырқында пылау, бәйрәмашлар[1] пешә — *әстр.*

— Уздырыгыз, балакайлар, җидемне,
Минем рухым қайтыр сезләргә — *әстр.*

## Йетесе

**Йетесе** *туб.* җидесе.

— Йетесенә қучқар суйып қатым ашқа йәшәләр.

## Кырыгы

**Кырыгы** *урт.д.*, **кырыгын күтәрү** *күрш.*, **кырык кене, кырк кичәсе** *миш.д.*, **’ыры’ ’ичисе, ’ыры’ ’эне** *кас.* кырыгынчы көндә үлгән кешене искә алу.

[1] *Бәйрәмаш* — пәрәмәч.

— *Кырк кичәсе* куй чалалар, эч-карын эчле бәлеш салалар — *тмн.*

— Кырк кицәсендә йууцыларга калуш, йон ойокбаш, барига[1] бирәләр, садака бирәләр — *чпр.*

— Ак сарык суйабыз кыркысына. Карадан суймыйбыз, тәкәдән суймыйбыз, бикәчтән суйабыз — *т.кам.-крш.*

— ’ыры ’ичисини үтми’ ’үмиче[2] салабыз, үтми’ үмичне үтми’ ’амырыннан ва’-ва’ итеп пешерилир — *кас.*

— Зийаратта ләхеткә иңдергәч өчесен укырга ди, алты көннән җидесен, аннары *кырыгын* үткәрәләр — *минз.*

**Кырыгы** — волгоград сөйләшендә:

— Кеше үлгәч:

«Кырыгына ләб кырыкбер энә кадала ди әдәм баласына, йөрәгенә, калганнарның кеңеленә кадала ди. Кырыгында шыл кырык энә төшеп бетә, бер энә генә кеңелендә кала», — ди.

«Кырыгына ләп[3] йери ди үле. Кунарга йерделәр, ут йандырдылар, сәдәхә бирделәр. Монда сәдәхә бирүче булмаса, тагын эзли китә ди шылай, дыва эзли».

«Үле — дывадан туймый», — диләр.

«Битенә йапкан йеслеге дә кырыгына ләп кезгә башында тыр---сын», — диләр.

**Кырыгы** *срг.*: — Кырыгында инде пәрәмәц пешермиләр, куй суй---ып хатем укилар.

**Қырқы** *әстр.* кырык көнен искә алу.

— *Қырқы* булғанда жақын-жулығың киләде, үзең чақырған кешеләр киләде. Қуй аласың, қуй суйасың. Қуйың булмаса пылау ба---стырады[4], пилмән йасайды. Мал суйу кирәк, бишбармақ[5] пешермәгә кирәк.

*Қырқы* үткән суң синең жақын-жулығың чақырып алады қунаққа. «Бер үзең қайғырып утырма, синең күңелең бүленсен», — диде. Қырығы үткәннән суң жөзен уқытасың. Әр кече йомада коран уқытып торасың үлгән кешегә.

[1] *Барига* [< рус.] — бияләй.
[2] *Үтми' 'үмиче* — кечкенә икмәк.
[3] *Ләп* — кадәр, хәтле.
[4] *Пылау бастыру* — пылау пешерү.
[5] *Бишбармак* — эре кисәкле итеп киселгән токмач белән ит.

### Қырық ахшам, қырық көне, қырығы

— *Қырық ахшамнарын* уқыталар үлгәс. Қырық ахшамын қырығы тулғансы уқыйлар қый — *к.-уф.*

— Көмеш әбей үлде, *қырық көнен* ул уқый ыйы, сәй эсеп уқый ыйы — *к.-уф.*

— Қырығына қорбаннық суйарға тейеш — *к.-уф.*

### Қырығы

— Қырығына қуй, йә қучқар суйапыс.

— Ут йандырып йоқлағаннар төне белән. Қырығына хәтле йандырғаннар. Қырығына хәтле килеп йөри диләр.

«Қараңғы йиргә килмәсен», — диләр — *туб.*

### Қырығында қан чығару

— Қырығында қан чығарабыз:

«Жан урынына — жан,
Қан урынына — қан», —

дип, малны чалдыралар. Үзеңнең бер жақын туғаның мал чала инде.

Мал чалған жиргә бәләкәй генә қоштабақ белән **тәбикмәк** алып чығалар да ул тәбикмәкне эткә бирәләр — *каз.ар.-крш.*

### Қырығында мунча йағу, өлеш салу

— Қырығында мунча жағабыз қызу итеп.

«Мунчаға қайтығыз,
Сезгә өлеш салабыз», —

дип әйтеп, мунча ташына эссе салып чығып китәбез. Қайын セберке---сен жаңаны қуйабыз. Шул мунча өлеше салу була — *каз.ар.-крш.*

### Қырық күмәче

**Қырық күмәче** *төм., крш.* кырыгын үткәрү мәҗлесенә пешерелә торган күмәчләр.

— Қырығын үткәргәндә қырық күмәче була болай-болай ғына әркемгә — *төм.*

### Қырық йасин

**Қырық йасин** *төм.* үлгән кешегә багышлап укыла торган догалар.

— Қырық йасин цығу кәрәк. Мәйеткә қырық көн булса, бағышлайтылар қырық йасинны.

## Керәшен сөйләшләрендә кырыгын үткәрү

### *Қырық көне*

**Қырық көне** *каз.ар.-крш.* кырык көнгә хәтле үлгән кеше өчен ашамлык һәм урын-җир әзерләп торалар.

— Кырық көнгә тикле безнен шундый ғәдәт. Убизәтелени иртән дә, көндез дә, кичен дә үлегә ашарға қуйасың.

Ару тастымал өстөнә саwытын қуйасың, ашарға саласың аңға.

Кич белән пустил гатувит итәләр аңға.

«Әйдә кил, йоқла инде».

Иртә белән:

«Әйдә, тор инде», — дип пустилне жыйып қуйалар.

Өстәлгә қоймақлар, майлар қуйалар. «Алар бик булышалар тор---мошта», — дип әйтәләр ийе. Чыннап та, менә шушындый ғына бәкәй ала, сарай тулы сарықлары буладырыйы күршенең. Үрчиләр ийе мал---лары. Сынаған.

«Үлгән кешеләрне бик қадерләргә кирәк», — дип әйтерләр ийе.

### *Қырығын йандыру*

**Қырығын йандыру** *т.кам.-крш.* кырык көнендә шәм яндыру.

— Қырығын йандырғанда зиратқа барып чақырып қайталар да балаwыз шәме йандыралар, йақты йана. Тәбикмәкләр пешерәләр, мунча йағалар.

### *Қырқысы*

**Қырқысы** *т.кам.-крш.* — ак сарык суялар.

— Ақ сарық суйабыз қырқысына, алай қарадан суймыйбыз инде. Бикәчтән суйабыз. Аш пешерәбез дә аш пешкәчен зиратқа менәбез чақырырға — *т.кам.-крш.*

**Қырқысы** *т.кам.-крш.* таба исе чыгаралар.

— Қырқысында таба исе чығарып атап бер мал суйа инде, анда бәрәнме, қазмы. Туған-тумачаны жыйып, шәм жағып утыралар.

— Қырығына тикле китми диләр инде үлене. Қырығына тикле без үлене үзебез белән бергә ашарға утыртабыз, айырым саwыт, қашық қуйабыз.

«Әйдә, безнең белән бергә утыр, ашыйбыз», — дибез.

Қырығына сарық суйып, бер сөйәген дә қалдырмыйчы пешерергә тийеш буласың. Итен ашап бетерәләр, сөйәкләрен қалдырмыйбыз, түгәбез — *т.кам.-крш.*

### *Қырығына хәтле бистәр (сөлге) элеп куйу*

**Қырығына хәтле үленең жаны** бистәргә (сөлгегә) кунып тора, дип ышаналар — *т.кам.-крш.*:

— Үлгән кеше йатқан урын йанына бистәрен (сөлгесен) элеп қуйалар. *Қырық көн* үлгән кешенең жаны шул бистәргә қунып торор ди.

— Шул бистәр[1] қырығына хәтле тора да аны қырығында гына бирәләр бер жәтим қарчыққа.

### *Қырық қашық он*

**Қырық қашық он салып бару** *т.кам.-крш., каз.ар.-крш.*:

— Қырығына хәтле көн дә бер қашық он салып бара тәлинкәгә, қырық қашық он санап салып бара, шулай тийешле. Шуны қырығы көнне бирә бер жәтим қарчыққа.

— Кеше үлгән көннән алып бер қашық он салып барабыз көн сайын иртә белән. Қырығына хәтле бар эшебез шул була инде битне жуғач та. Аны қашық белән жамайаққа салып барабыз. Он белән қашықны жанға қуйабыз. Иртә белән тороп битне жуғач та, қач қылып, шул онны салабыз.

Атаның-улның,

Святой Тынның исеменә амин! — дип — *каз.ар.-крш.*

[1] *Бистәр* — сөлге.

### *Қырық көнлек хәйерлек*

**Қырық көнлек хәйерлек** *каз.ар.-крш.*:

— Без қырық қашық он салып барабыз

«Қырық көнлек хәйерлек», — дип.

Шулай көн сайын бер қашық он өстәп барабыз. Аннары ул онны праспара[1] пешерергә бирәбез.

— Җамайакқа қырык қашык он салып барабыз да қырығында ул оннан қырык күмәч пешерәбез. Кеше сайын бер күмәч, ул инде «қырык көн хәйере».

### *Қырыгына хәйер кертү*

**Қоймақ пешереп хәйер кертү** *каз.ар.-крш.*

— Қырығында қойаш чыкқанчы қоймақ пешереп хәйер кертәсең. **Кырыгын тегәлсез (так санлы) көндә уздыру** — *т.я.-крш.*

— Тегәлсез кендә уздыралар *кырыгын*, барын да чакыралар. Ашлар гатаулибыз, тастымал бирәбез — *т.я.-крш.*

### *Қырық гердә*

**Қырқысына — қырык гердә** (күмәч) **пешерү** *крш.*:

— *Қырқысына қырык гердә*[2] пешерәбез, *қырық берне* дә пешерәбез. Табақ сайын берәр гердә салабыз.

### *Қырық күмәч*

**Қырығына қырык күмәч пешерү.**

— Қырығына қырык күмәч пешерәбез, қойаш чыкқанчы хәйерен бирәсен, туғисын да қоймақ пешереп хәйерен кертәсен. Табақка сала---сын қырык күмәчне, түлке парлы салмыйлар, парсыз салалар — *каз.ар.крш.*

— Қырығына хәтле бер қашык он салып барабыз көн сайын. Ашы буласы көнне ул оннан қырык күмәче пешерәбез. Ул қырык

[1] *Праспара* — чиркәүдә өләшү пешерелгә торган төче күмәч.
[2] *Гердә* — төче күмәч.

күмәчен ашқа килгән бөтен кешегә өләшәбез. Баwырсақ фурмы---сында була ул.

Қырық күмәчне шул он белән, тағын да он өстәп пешерәбез. Теге салып барған он ғына җитми инде ул.

Қырык күмәчне шул қырығына килгән кешеләргә таратырлар ыйы. Таратып бетермәгәнен балаларға өләшерләр ийе.

— Элек қырығына кечти-кечти генә итеп қырык күмәч пешерәләр ийе. Шуны нәнә (әни) алып қайтып безгә ашата торған ыйы. Шул қырык күмәчне қырык кешегә өләшәләр ийе.

— Қырық күмәче пешерәбез төче қамырдан. Қырык берне пешерә. Зиратқа алып баралар, табақ белән киләләр. Табаққа салабыз күзикмәк, тәбикмәк, дурочмақлар[1], күмәч тә салабыз.

Хәзер менә элеккеге табақлар жук, кибеттән генә әйбер алалар да баралар — *каз.ар.-крш.*

— Қырык күмәч пешерәләр қырығына. Килгән кешегә табаққа са---лалар.

Атаның, улның
Святой Тынның исеменә, Амин.
Җомақлы булсын ,
Бәхилләп китсен, — дип.

Қалған күмәчләрне малларға бирәбез — *каз.ар.-крш.*

### *Қырыгына қырык қатлама*

**Қатлама** *каз.ар.-крш.* кабартма.

— Қырығында қырык қатлама пешерәләр дә табақларға салалар берән-берәнне. Үле табағындағы қатламаны зиратқа алып менәләр дә шунда қалдыралар.

### *Қырық перәннек*

**Қырығына қырык перәннек өләшү** *каз.ар.-крш.*:

— Хә зер инде қырык күмәч пешермиләр, қырык перәннек өләшәләр кибеттән алып. Қырык перәннекне шул қырык күмәч уры---нына өләшәләр.

[1] *Дурочмақ* — пәрәмәч.

### *Кесәллек күмәче*

**Қырығына кесәллек күмәче пешерү** *каз.ар.-крш.* солы ярмасы белән күмәч пешерү.

— Солы йармасыннан йасаған **кесәллек** күмәче пешерәләр ийе қырығына. Ул да бик йарады әwәле.

### *Кырк та бер кимак*

**Кырыгына кырк та бер wак кимак пешерү.**

— *Кырыгында кырк та бер вак кимак* җасадык, аны кошларга утырттык, мазар эстенә акиттек — *т.я.-крш*.

### *Кырыкбер келчә, кырыкбер җука*

**Кырыгына — кырыкбер келчә,**
**кырыкбер җука.**

— *Кырыгына кырыкбер келч ә, кырыкбер җука* җасыйбыз, килгән табакларга салып җибәрәбез — *чст.-крш*.

### *Қырықбер күс кәппер*

**Қырықбер күс к әпкер** *төм*. кеше үлгән көнне пешерелә торган юка күзикмәк кәпкер дип атала. Аны тишекле итеп пешерәләр (имеш, үлгән кешегә каберендә яктылык кереп торсын өчен).

— Қырықбер күс кәпкер пешерәте үлгән көнне. Үлекнең ашы пула---ты ул. Қырбаштан килгән кешеләргә пешерәтләр. Тақ кирәк.

### Мөчәле көне, илле бер көне

Илле беренче көндә үлгән кеше рухына багышлап коръән укыты---ла. **Әстерхан сөйләшендә** аны *мөчәле көне* дип әйтәләр. *Мөчә* — буын дигән сүз.

— *Мөчәле көне* диләр илле беренче көнен. Шул көндә адәм баласының мөчәләре бер- берсеннән айырыла диләр. «Илаһи нийәтләнеп қоран уқымаққа булдым ошбу *мөчәле көнендә*», — дип башлыйм қоранны — *әстр*.

— Уздырыгыз илле бер көнемне,
Бергәләшеп искә төшерерсез,
Минем баштан узган гөмеремне (мөнәҗәттән).

### Бер елы

**Зылын күтәрү** *күрш*., **йыл билгесе** *тмн*., **йыл кичәсе** *лмб*., **йылтәүлек** *нокр*., **җыллык атау** *баст*. бер ел үткәч үлгән кешене искә алу мәҗлесе.

— *Йыл кичәсе* йитә, картук тарткан чагында[1] үлде — *лмб*.
— *Йыл билгесенә* ашлар менән киләләр инде, тывар[2] чалалар, куй чалалар — *тмн*.
— *Йылтәүлек* була бер йылдан сун, йылтәүлек укыталар — *нокр*.
— *Зылын күтәрәләр*, куй суйалар, кан цыгаралар — *күрш*.
— *Җыллық атаулары* булды, таwық суйып қан чығаралар — *баст*.
— *Йылын үткәрәләр*, кан цыгаралар. Пецтергән куй кирәк, куцкар[3] йарами — *срг*.

### Йыл коранын уқыту, йылын уқыту

— *Йыл коранын* укытқанда қаберчеләргә, йуучыларға бүләк бирәбез. *Йыл коранына* пылау пешердем, йимешләр қуйдым.

— Йылын уқытқачтын ул инде кердән чыға, ақлыққа чыға — *әстр*.

### Йылғораны

**Йылғораны** *әстр*. ел коръәне, ягъни үлгәненә бер ел булгач укы---тыла торган коръән; дини мәҗлес.

— Йылғоранында ире үлгән булса, үлгән кешенең хазәйкәсенә башына ақ йаулық бәйлиләр, пылау, бәлешләр пешереп йылғоранын уқыталар.

**Йылғоранда артық табақ җасыйлар, табақларны тақ санда җасыйлар**:

— Унөч, умбиш табақ җасыйлар йылғоранда. Берне **артық табақ** та җасыйлар «тәңре қунағы килсә» дип. Үлек ашын, табақларны тақ җасыйлар.

[1] *Картук тарткан чак* — бәрәңге казыган чак.
[2] *Тывар* — хайван.
[3] *Куцкар* — тәкә.

Тастырханға[1] биргәндә, табақлар өстенә җәймәне сындырып-сын---дырып салалар — *әстр*.

## Бер йылы, зур хатем

— Бер йылында зур хатем була. Хатемдә ирләр кәпәцтән[2], хатын---кызлар ак йаулыктан утыралар — *срг*.

Зур хатемдә элек цәй эцә идек **таба ашы** белән. Әле инде таба ашы тегел, әле пирут үрә ашилар.

— Үзең кулдан кискән тыкмач куй ите белән, казан катламасы, ур---тасын тишкән, пәрәмәчә, челдермәк (кош теле), шәкәр, варинйә куйа---быз — *срг*.

— Теләгән кеше цәпесен[3] өләшә, акца өләшә. Әле инде кем барды үлек бар'амына, әммесе акца өләшә.

Йылын үткәрәләр, кан цыгаралар. Пецтергән куй кирәк, куцкар йарами — *срг*.

## Йыл қатымы, йыл қатым-туwасы

— Қуй бәрән суйып қатым-туwа үткәсәләр, қан цығаратылар, кешеләрне цағыратылар кергетәйләрне — *төм*.

Аш-сыуларығысқа бәрәкәтләр бирсен,
Аш-сыуларығыс өстәл қашлартан өселмәсен,
Қыйәмәт көнен көтеп йатқан әрwахларыбысға
    бүләк булып барсын,
Рухлары шат булсын,
Қабер ғазаплары йиңел булсын,
Бәндәчелек белән қылған гөнаһларын йарлықағыл,
    дип тоға қылабыс — *төм*.

[1] *Тастырхан* — ашъяулык.
[2] *Кәпәц* — түбәтәй.
[3] *Цәпе* — тукыма.

## Йылтәүлек

**Йылтәүлек** *глз*. бер елын искә алу көне.

— Эч кене, йеде кене, корок кенен укыталар. *Йылтәүлек* була, бер йылдан сун *йылтәүлек* укыталар. Пышырып китыралар пирамач, буккан, наста булдыра пышырма. *Йылтәүлек* уздырдым, бийемем бе---лән бийатам үлде.

— Шомортлы беккән, шанги, тәбикмәк, суганны ипиләр, ак калач салган. Эстәл тулы ризык. Алдан чәй, корән укыйлар. Сунгра бөккән, дөге йарма, йемеш белән бәк тәмле итеп пешерешәләр. Дустыганга[1] салып йемеш суы бирә. Кәткәндә бешкән ашны гүчнич[2] итеп биреп йибәрә. Әнкуй әйтте: «үлгич мине үри аш белән йаз ит», — дигәләде. *Йылтәүлекләргә* йә таwык чалалар, йә сарык суйалар — *глз*.

## Тәүлеге

**Тәүлеге** *к.-уф., перм*. бер елы.

— *Тәүлеге* җитсә туған-тумалары килә, ашны зурлап пешерәләр. Қорбанның суйалар, сарық. Туған-тумалары килә.

— Җирләгәч өч көннән өчесен, җиде көннән җидесен, шунан қырығын уздыралар. Анан *йыл тәүлеген* уздыралар — *к.-уф*.

— *Тәүлеген* үткәрәбез. Тырышқан кешеләр йыл сайын да үткәрәләр. Шулай үткәргән кешеләр бар. Тәһлил белән үткәрергә кушқан.

— Тәүлегенә ызба тутырып кеше җыйалар. Үрә пешерәләр, қатламалар, чәкчәкләр — *перм*.

## Таwап

**Таwап** [< гар. таваф] *туб.* тирә-як авылларның картлары бер астана---лы авылга җыелып, яки шәһә рдәге мәчеткә килеп, барлык изгеләрне, әүлияләрне искә алып намаз укыйлар, корбан чалып уртак мәҗлес ясыйлар.

[1]*Дустыган* — стакан.
[2] *Гүчнич* — күчтәнәч.

— Йыл сайын бер wақытны үсебес билгеләп қуйабыс бер көн.
«Бөтен йақтан килең, таwап қылабыс», — тип.
Әүлийәләрнең, йақшыларның қаберләрен цит әннәп, сырлап, Қоръән уқып, садақа өләшеп, тәкбирләр әйтеп таwап қылабыс. Оллы---лар тасартып торалар астананы.
Таwапқа тип атарлаған[1] пер қуйым бар. Төшемә инәтеләр[2]. Аның өцен мин уқытам қатым.
Ағыт буйында, Иртеш буйында өч йөз алтмыш әүлийә бар диләр. Мөселманға, дингә индергәле килгәннәр.

### Пайыш астаната таwап

— Пес менә таwапны үткәрәбес. Пайышта, цай мәзлесе[3] йасай---быс, намас уқыйбыс. Ул таwап булаты. Оллы астаналы аwылға барып таwап қылалар, қатым уқытатлар, ийылып баралар.
«Пайыш астанага барып таwап қылсағыс, сес қачқа[4] барып туwа қылған сынны буласыс».

— Пайыш астанаға таwапқа әллә қайлардан киләләр, қуй суйып қатым уқытатлар. Таwапқа килгән кешеләргә мәчеттә ашау әсерләп торалар.
Пайыш астаната Хәким ата сарайы бар.
Пайыш астаната аwатан үгес төшкән, қорманның үгес. Анта қасан та төшкән. Қасаны цыңлап тораты. Пайышта йақшы қортқайақ бар, астананы қарайты.

— Ул Пайыш астанага таwапқа йәйәү баратылар.
«Йәйәү барса, қачқа барған сынны булыр», — тип әйтептеләр.

### Цым, цымсалыр

**Цым** *туб.* май аенда барлык үлгән кешеләрне искә алу көне.
Бу көндә өйдә пешеренәлә р, изге догалар, Қоръән укыталар, зират---ка пешкән йомыркалар алып баралар.

[1] *Атарлаған* — атаган.
[2] *Төшкә инә* — төшкә керә.
[3] *Цай мәзелесе* — чәй мәҗлесе.
[4] *Қач* — хаҗ.

**Цым** — үлгән кешеләрнең рухын канәгатьләндерү йоласы. **Цым** — татар әдәби телендә **җим**, ягъни **җим > йим, чим, цым**. Үлгәннәрне, әрwахларны туендыру, ашату, аларның рухын олылауга кайтып кала.

### Цымлылар

**Цымлылар** *туб.* соңгы бер ел эчендә үлгән кешеләр; аларның каберенә «өй» куела.
— Цымлыларга өй[1] йасайтылар цымта. Қәсер күбесе тимертән қылаты, әwәле ағацтан ғына қылған. Тимер йарамайты.
Йаңа үлекләргә «цымлылар» тип қатым уқытатлар. Алтан йөрителәр цымлыларға.
Қыш йартыда үлсә дә «цымлы» булаты.

### Цымын қылу

**Цымын қылу** *туб.* үлгән кешеләрне искә алу өчен зиратка бару; өйдә ашамлыклар пешереп догалар укыту.
— Цымын қылабыс астаната[2] қар бетсә. Туғысынцы майта қылатлар цымны. Астанаға баратлар. Үлән йәшәргәц булаты.

### Цым — үлекләр қатымы

— Үлекләр тоға көтеп йататылар. Әркемнең үлеге йата , қатымын уқытаты қырбашқа барып. Май керсә цымын қылабыс, қар бетсә астаната — *туб.*

## Цымқатым

**Цымқатым** *туб*. цым көнендә дини мәҗлес үткәрү.

— Йаңа үлек булған кеше қуй суйаты, аш йасайты, цақыраты күрешеләрне. Антайын цым қатым қылатлар.

Цымта бөтен тоғомына тоға қылалар:

— Цымта:

[1] *Өй* — кабер өстенә агачтан ясап куелган корылма.
[2] *Астана* — изгеләр кабере.

Йетмеш тоғомына, пөтен ыруwына,
*әбәсенә*[1]*, әкәләренә*[2]*, тәтәләренә,*
*пала-пақра*[3]*, цицәләргә*[4]*, өннәмә*[5]*,*
*туған-қарындашлар*
*күрше-қунақлар,*
*үле-тереләргә, ибенә ыруwына тоға қылатылар*.

Үлекләр тоға көтәте — *туб*.

### Цымта қартлар өйдән-өйгә йөриләр

— Цымта қартлар ашығып аwыл буйлап йөритегәннәр, ибенә өйгә керәтегәннәр. Пер көнтә цымны үткәреп йигәле, икенце көнгә қалмасқа.

— Ун-унбиш кеше керәте цымта цақырып алабыс.
«Әйдә, миңа кереҥ, пескә кереҥ Қоръән уқығалы», — тип. Пөтөн кеше цақыраты цымта — *туб*.

### Цымта қырбашқа (зиратка) баралар

**Қырбашқа итәккертән қалған[6] қортқайақлар баралар**:

— Итәккер күрсәҥ[7], пармайсын қырбашқа. Итәккерт ән қалған таса қортқайақлар ибенә ийылып паратылар. Қортқайақлар ақца өләшәте, қайырын салатылар — *туб*.

### Цымта теләк-тәсбих қылалар

— Цымта пөтен ыруwына, йетмеш тоғомына теләк-тәсбих қылатылар. Үлегә дә, терегә дә теләк теләйтеләр, уғынып утыралар, тәсбих тарталар — *туб*.

[1] *Әбә* — апа.
[2] *Әкә* — абый.
[3] *Пала-пақра* — бала-чага.
[4] *Цицә* — апа.
[5] *Өннә* — әби.
[6] *Итәккертән қалу* — хатын-кызның күрем күрүе туктау.
[7] *Итәккер күрү* — күрем күрү.

### Цымта қабер қашына утырып уқыйлар

— Қабер қашына[1], қабер қабағына[2] утырып тоға уқыйтылар. Өйтән пер кеше параты қатым уқытқалы. Үсенеҥ үлгән әрwахларына әргем уқытаты. Быйыл үлгән кешеләргә алданрақ тоға қылабыс кәпләшеп, килешеп — *туб*.

### Цымта қабер өстенә «өй» йасыйлар

— Цымта цымлыларға өй йасайтылар, биш, йете бүрәнәдән өй қуйатылар. Қатақ суқмаған әwәле. Қәсер күбесе тимертән қылатылар, тимер йарамайты ул.

— Цымта өйе тормағаннарға өй қороп китәтеләр, ағацы йемерелеп қуймасын — *туб*.

### Цымта қабер өстенә агач утырталар

— Цымта қырбашқа цығып ағац утысатлар, өц ағац утысатлар қабергә: қосоқ ағац, ыусақ, қайын ағац — *туб*.

### Цымта қабер өстенә көл (гөл) утыртқалы

— Цымта тасарталар қаберләрне. Цым көнне үлгән кешенең қаберенә көл[3] цәцеп көл утыртқалы — *туб*.

### Цым үткәнче йир көрәкләргә йарамайты

— Цым булғанца бергем бернәрсә утысмайты. Йир көрәкләргә[4] йа---рамайты. Үлекләр рухын[5] сақлағалы кәрәк — *туб*.

[1] *Қабер қашы* — қабер кырые.
[2] *Кабер қабағы* — кабер яны.
[3] *Көл* — гөл.
[4] *Йир көрәкләргә* — җир казырга, җиргә көрәк тыгарга.
[5] *Үлекләр рухы* — үлгән кешеләр рухы.

### Цым ашлары

**Цымта қуй суйа, аш үткәсә:**
— Қуй суйабыс цымта, аш үткәсәбес, қартларны, қортқайақларны цақырабыс — *туб*.

### Цымта паwырсақ пешерәләр

— Паwырсақлар пешерәбес майға салып. Цай эцергәле күрше---қунағыңны цақырып кертәбес — *туб*.

### Цымта қоймақ қойалар

— Цымта қоймақ қойабыс. Қоймақны санайтылар:
«Тақ булғалы кирәк», — тиделәр — *туб*.

### Цымта майлы ашлар пешергәле

— Цымта майлы ашлар пешергәле, өйтән-өйгә кереп цай эцеп йөргәле — *туб*.

### Цымта йомортқа пешергәле

Йомортқаны **қалтаға[1] салып, тақ қылып** қырбашқа алып китәтеләр:
— Қалталарға салып алып китәтеләр йомортқаны. Тақ қылып, пер **йетешәрне, туғысарны** аппаратылар — *туб*.

### Цымта йомортқа қабығын цацу

— Йомортқа қабығып цацып китәтеләр қырбашта. Йомортқаны астанаға алып киләте. Аны аппарып, үлекләрнең өстенә арцып таш---лайлар.

[1] *Қалта* — янчык.

— Қар эреп бетсә цымны қылатылар. Өц йомортқа пешереп пирәм цымға баруцыларға. Алар йомортқаның қабығын сытырып үлекнең өстөнә салатылар, йомортқасын қошларға салатылар. Ирәннәр[1], мул---лалар баратылар цымта қырбашқа — *туб*.

### Цымта йомортқаны пыйас қабыққа буйыйлар

— Цымта йомортқа буйайбыс. Пыйас қабыгын[2] қайнатабыс, йомортқа пешерәбес пыйас қабыққа буйап, қысараты ул — *туб*.

### Цымта йомортқаны балаларга өләшәләр

— Цымта йомортқаны пыйас қабықларға буйап балаларға бирәтләр, пала-пақраларға, күрше-қунағына өләшәтеләр. Wақлар ма---сайатылар[3] — *туб*.

### Цымта йомортқа соношалар

— Тәрилкә белән утысабыс йомортқаны, бер-беренә соношып[4] ашайтылар — *туб*.

### Цымта йомортқа суғыштыратлар

— Цымта тышта йомортқа суғыштыратлар. Үләннәр йәшәргән бу---латы — *туб*.

### Цым сарқыты

**Цым сарқыты** *туб*. цым үткәргәндә калган ашамлыклар.

— Цым сарқытын, қартлардан қалған ашны игенце көнгә қалдырмайтылар. Цымнан қалған ашны wақларға, күрше-қунағына өләшәтләр.

### Цымсалыр

**Цымсалыр** *туб*. шул ук цым йолалары, май аенда үткәрелә.

[1] *Ирәннәр* — ирләр.
[2] *Пыйас қабығы* — суган кабыгы.
[3] *Масайатылар* — шатланалар иде.
[4] *Соношу* — бирешү.

— Цымсалыр тип йомортқаны[1] бер-берсе белән суғыштырып уты---раты йәшләр. Поронғылар шалай цымсалыр тип әйтептеләр. Цым---салырта йомортқа пешереп йомортқа ашайбыс. Йомортқаны пыйас қабық суwына[2] қысартып салалар. Цымсалыр ул перенце майта пула---ты. Цымсалырта қырбашқа[3] та паратылар — *туб*.

## КЕШЕ ҮЛГӘЧ КАЙГЫРУ ХАЛӘТЕНДӘ ЙӨРҮ

### Кер тоту, ақлыққа чығу

Әстерхан өлкәсе татарларында кеше үлгәч бер ел дәвамында кайгырып йөрү (траур саклау) йоласы бар. Бер ел үткәч, искә алу мәҗлесе үткәргәч, кайгыру халәтеннән чыгарга тиеш дип, **аклык бүләге** өләшәләр.

Кайгыру, кайгылы халәттә йөрү әстерхан сөйләшендә түбәндәге сүзтезмәләр белән белдерелә.

### Кер кийү

— Кеше үлгәч бер йылға қадәр мәҗлескә бармый, туйларға бар---мый, йақшы кийемне кийеп йалтырап чықмый кеше арасына. Йыл узғач *кер кийү* бетә, истән чыққан була, қоран тастырхан[4] бирелә — *әстр*.

### Кер сақлау

— Әwәлдә кер сақлау дигән. Йақын кешесе үлсә, өйеннән бер кайа да чықмаған, туйға, чақыруға, ат қушқанға бер дә йөрмәгән.

[1] *Йомыртқа* — йомырка.
[2] *Пыйас қабык суwы* — суган кабыгы суы.
[3] *Қырбаш* — зират.
[4] *Қоран тастырхан* — коръән укыткан ашъяулык.

— Өй эчендә кеше үлсә бер йыл булғанча туйға да бармый, җыйылышқа да бармый, халық арасына чықмый, намус сақлый. Апам (анам) үлде, абыйым белән җиңгәм үлде. Қызымның баласы өйләнде, қодағый булып Қазаwылга бара алмадым, чатырға чығып утыра ал-мадым, чығып йөрә алмадым.

— Кеше үлгәндә кигән күлмәген салмаған, йуған да кигән, йаулықны да шул йаулықны бәйләгән, салмаган бер йылға қадәр.

— Кеше үлгәч менә ире үлгән булса хатыны, кызлары үле чыккан өйнең бер йылға хәтле утырышка-нигә бармыйлар, туйларға бармый---лар, анда-монда мәҗлескә кушылмыйлар — *әстр*.

### Кер тоту

— Электә иң қайғылы кеше қара ситсылардан күлмәк кийде, жаулық бәйлиде, туйға-нигә бармайды, жыйынға жөрмиде, қайғылы булып жөриде, бер жылға хәтле кер тотады. Қысқайақлар[1] шулай итәде, ирләр кер тоту жуқ — *әстр*.

— Апам үлде, кер тотып, қызым белән утырдым, апамды қайғырып кер тотып утырдым, чықмадым — *әстр*.

— Кер тотып утырған кешене қунаққа чақырып алады йақыннары, саға бер кисәк мата[2] бирәде, «қайгырма», — диде. Йақын туғаннары чақырып алады қайғырып, уйланып утырған кешене — *әстр*.

— Ире үлгән булса, хатыны кер тотып торады, баласы үлгән булса, анасы кер тотып торады. Жыл узғаннан суң туйга, мәжлескә бармаға булады — *әстр*.

Менә хәзер дә бар бездә кер тоту. Қодағыйым үлде, кер тотып утырдылар балалары — *әстр*.

— Кер тотқан, кер саклаған кеше үлгәч бер йылға тике. Өстендәге күлмәген, башындағы йаулығын да алыштырмый торған булған. Са---лып йуған да тағын шуны кийеп қуйған. Кеше үлгәндә ни зат[3] кигән булған, шуның белән йылына хәтле йөри торған булган. Шул кийемен бер йаққа да аwыштырмаган. Йыртылып та китәде тузып. Хәзер инде аwыштыралар — *әстр*.

[1] *Қысқайақлар* — хатын-кызлар.
[2] *Мата* — тукыма.
[3] *Зат* — әйбер.

— Өйеңнән үле чықса, кем чықса да кер тотасың. Бер йылға қадәр қайа да бармыйсың кеше үлгәч. Ул кер тоту була, қайғылы була — *әстр*.

— Өйеңдә кем үлсә дә кер тоту була, қайнаған үләме, ирең үләме — кер тота. Туйға бармый, ашқа-сыйга, жыйылыш-жыйынға бармый — *әстр*.

### Кер тоттыру

**Кер тоттыру.** Әгә р килен төшкән йортта күптән түгел кем дә булса үлгән булса, битачар йоласын бер елдан соң гына башкарганнар. Яшь килен «кер тоткан», ягъни кайгылы халәттә йөрергә тиеш булган.

— Минем апамның қайнанасы йә рәшеп торғанда үлгән. Килен бу---лып төшкән, чығармағаннар, битен күрсәтмәгәннәр. Қайнанасының йылында битачар булған. Килен шулай кер тотқан. Өйләрендә берәү үлгән булса, киленгә биткүремне бер жылға қадәр йасамаған, битен ачтырмаған, кер тоттырған — *әстр*.

### Кер тотып утырған кеше

**Кер тотып утырған кеше** *әстр*. якын кешесе үлгәч, кайгылы халәттә йөргән кеше.

— Йыл коранында кер тотып утырған кешенең башына ақ йаулық бәйләтәләр, ул ақлыққа чыға.

## КАЙГЫРУ ХАЛӘТЕННӘН ЧЫГУ

### Ақ

**Ақ, ақлық** < ақ + -лық *әстр*. бер елдан соң кайгыру халә теннән чыгу уңае белән уздырыла торган мәҗлестә өләшенә торган бүләк: яулык яки күлмәк, тукыма һ.б.

### Ақ өләшү

**Ак өләшү** *әстр*. бер елдан соң кайгылы халәттән чыгу мәҗлесендә бүләк өләшү.

— Килгән халыққа барысына да ақ өләшәләр, ақ жаулық, мийешенә[1] ақча төйнәп.

### Ақ жибәрү

**Ақ жибәрү, ақны элеп куйу** — әүлия каберенә ак төстәге нинди дә булса тукыма элеп кую.

— Ак җибәрү диләр, әүлийә қаберенә элеп қуйалар, ақны элеп қуйам, ди, тәрәт җаулык[2], фартык[3] элеп.

## Ақлық алып килү

**Ақлық алып килү** *әстр*. ел ашын үткәрү мәҗлесенә яулык яки күлмәк алып килү.

— Ақлықны җылында алып барасың, қырқында да алып барасың, буш бармыйсың, җылында инде ақча бирәде, мата бирәде.

## Ақлық бирү

**Ақлық бирү** *әстр*. бер ел үткәннән соң кайгылы халәттән чыгу. Хуҗа хатын мәҗлескә кунаклар чакыра, алар «аклык» бүләге алып китәләр, өй хуҗасы үзе дә аклык бүләге тарата.

— Йыл коранында бөтен аwыл халқы килә. Ақлық бирә. Йылын уқытқачтын ақлық бирәләр үлгән кешенең хазәйкәсенә.

— Мата[4] биреп чыға, йыл коранын уқыта, ақлық бирә.

«Күргәнең-белгәнең шул булсын,
сунғысы булсын», — дип

ақлық бирәде. Мин уға (аңа) алып китәм, ул маңа бирәде. Менә шундый ғадәт бездә.

[1] *Мийеш* — почмак.
[2] *Тәрәт җаулык* — сөлге.
[3] *Фартык*[< рус.] — алъяпкыч.
[4] *Мата* — тукыма.

— Йылына инде әзерләнәләр ақлық бирергә, күлмәк, мата. Үзләре дә қоры килми, буш қул килми. Йақын-йуwықлар үзләре дә ақлық алып килергә тийешләр. Менә моның улы үлде, йыл коранына мин ақлық алып барырға тийешмен, күлмәк, йақшырақ йаулық. Қәйенсеңлемнең улы үлгәненә бер йыл. Килгән кеше дә ақлық алып килә.

Ақлық тиде, башларына ақ йаулық бәйлиләр йылғоранда[1].

«Ақлығығыз хәйерле булсын,
Қаралар[2] китсен», — ди.

## Ақлық йаулығы

**Ақлық йаулығы** *әстр*. бер елын үткәргәндә кайгырып йөрү халәтендәге кешегә бәйләтелә торган яулык.

— Өч қәйенбикәм[3] бар иде әйем[4] үлгәндә. Мине утыртып ақлық бирделәр. Йыл қораны көнне қоранға хәтле иртә белән йаулығын чишеп ақлық йаулығы бәйләтәләр, халық җыйылғынчы.

— Йыл узғанда ақлық бирәде. Кер сақлағандағы йаулықны[5] чишәде дә башына йаулық бәйлиде, битен-қулын йудырады, аннары башындағы йаулығын чишеп йаулық бәйлиде.

— Йылында үзенең туған-тохомнары көйләген салғызып, йаулығын чишеп, башқа көйләк, башқа йаулық кигезә, қорән уқыта булған.

Йыл қоранын уқытқанда барына да ақлық бирәде өй ийәсе.

— Йыл қоранында «кер сақлады» дип йақын қардәшләре бүләк бирә. Кер тотып утырган кешенең башына ак йаулық бәйләтәләр. Киленнәр була, тәтәләре, җиңг әләре ақлық салалар. Шул салған ақлықның эченнән берсен ала да башына бәйли.

## Ақлық салу

**Ақлық салу** *әстр*. бер елын үткәрү мәҗлесендә кайгырып йөргән кешегә бүләк бирү.

[1] *Йылғоран* — ел коръәне.
[2] *Қаралар* — кайгылар.
[3] *Қәйенбикәм* — иренең апалары.
[4] *Әйем* — әнием.
[5] *Кер сақлағандағы йаулық* — кайгылы халәттә йөргәндә бәйләгән яулык.

— Кер тотып утырған кешегә ақлық салалар қунчылары (күршеләре) тәтәләре, җиңгәләре.

«Артық үлем булмасын».

### Аклык өләшү

**Аклык өләшү** *әстр.* бер елын үткәрү мәҗлесендә аклык бүләге өләшү.

— Үле чыккан өйнең хуҗасы да аклык өләшә, коры чыгармый, мата (тукыма), йә сулык (сөлге) өләшә, акча түнәп йаулык өләшә.

### Аклыкка килү

**Аклыкка килү** *әстр.* бер елын искә алу мәҗлесенә килү. Аклыкка килгәндә мата[1] алып килә кайсы, кайсы сулык[2] әкиләде.

«Аклыкка чыкканың хәйерле булсын», — дип.

### Аклыкка чыгу

**Аклыкка чыгу** *әстр.* бер елын үткәрү мәҗлесендә аклык бүләге өләшеп, кайгыру халәтеннән чыгу.

— Аклык дип әйтәде, йыл коранын укыткан заманда барысына да күлмәклек бирәде. Килгән кеше дә йаулык зат, мата бирәде.

«Аклыкка чыкканың хәйерле булсын», — дип.

Ничә кеше утырды мына, җаны аwырган кеше[3] инде. Җаны аwырмаган, килмәгән кешегә бирелми иде. Йыл буйына кер тотып утыралар. Йыл кораны узгач кына аклыкка чыгалар, туйга-затка бара башлыйлар инде.

— Мата биреп чыга, йыл коранын укыта, аклык бирә, «Ахтыгы шул булсын, артыг үлем булмасын», — дип.

— Йылын укыткачтан инде ул кердән чыга дип әйтәләр, аклык бирәләр.

[1] *Мата* — тукыма.
[2] *Сулык* — сөлге.
[3] *Җаны аwырган кеше* — кайгырган кеше.

— Йылын укыткачтын аклык бирәләр. «Ахтыгы шул булсын, артык үлем булмасын», — дип теләйләр. Ул инде аклыкка чыга, кердән чыга, йөри башлый туйларга. «Аклыкка чыкканың хәйерле булсын», — дип бирәде. Килгән халыкка барысына да ак өләшәләр, ак җаулык, мийешенә акча төйнәп.

### Йөз аклыгы

**Йөз аклыгы** *әстр.* аклык бүләге биргәндә әйтелә торган сүз:

«Ике дөнйада йөзләренең аклыгы өчен булсын, Күзләренең сафлыгы өчен булсын».

## КЕРӘШЕННӘРНЕҢ
## (ХРИСТИАН ДИНЕНДӘГЕ ТАТАРЛАРНЫҢ)
## ҮЛГӘН КЕШЕЛӘРНЕ ИСКӘ АЛУ КӨННӘРЕ,
## ДИНИ МӘҖЛЕСЛӘР

Керәшеннәрдә: *өч көне, тугыз көне, җегерме көне, кырык көне, бер җылы* уздырыла.

### Сагыну

**Сагыну** *т.я.-крш.* үлгән кешене искә алу; дини мәҗлес үткәрү. «Сагыну» үткәргәндә үленең «җанын чакырып» кайталар.

— *Өч көнендә* кимак пешереп сагынып ашилар.

«Үлгән мәндәләргә туклык булсын», — диләр — *т.я.-крш.*

— *Тугыз кенендә* сагыналар[1], кимак куйалар — *т.я.-крш.*

— *Йегерме кене, кырык кенендә* сагыналар, үлгән мәндәләрне[2] сагынып ашилар — *т.я.-крш.*

— Пумилкәсендә, кырык кенендә мазар эстенә барып дәшмәлле, иртүк тороп өчәүләп барып дәшмәлле.

«Әдә, кырк көнең беген», дип, мендәр белән китәләр зиратка да мендәр белән кат’алар. Мендәрне алып кат’алар да эстәл пычмагына куйалар, мендәр эстенә утырып тора диләр энде аны.

[1] *Сагыну* — искә алу.
[2] *Үлгән мәндәләр* — үлгән кешеләр.

Ат җигеп зиратка баралар, әйдә кайт, без сине сагынабыз беген, ди. Анда мендәр куйа ат эстенә, мазарга бара да әйтә: «Әйдә утыр, кайт безен белә. Мазарда шәм җандыралар, сагынып түгәләр.

— Өч кеше китеп чакырып кайталар мазардан. Мендәр белән китәләр, шанарга утырып кат а диләр, таба тимере тотып китәләр.

Теге өч кеше мазарга баргис: «Әйдә, кайтабыз, бүген сине сагы---набыз», — дип дәшеп кайталар. Үлене чакырганда өч җыру җыр---лыйлар.

Өчендә, җидесендә капкадан чыгып өч тапкыр кычкыралар: «Без---нең кат ка ашарга-эчәргә кат».

Кайтты энде диләр, мендәрне кычаклап керәләр дә, күтәреп пыч---макка куйалар. Бер кашык куйа, бер саwыт куйа. Сыра эчә. «Микаилгә туклык булсын», — дип. Ашап-эчәләр. Сагыналар да энде: «әйдә, илтеп куйабыз сине», — диләр. Мендәрне күтәрә дә ылауга куйа, ил---теп куйа мазар эскә.

— Җылында да шулай уздыралар. Ишектән чыгалар да: «Микаил, кайт, беген сине сагынып ашибыз», — диләр. Керәбез, ашибыз. Ашамлыкларны саwытка салабыз да чыгарып кеше йөрмәгән җиргә салабыз.

— Туғызында ару әйбер пешереп шәм җағып утыралар — *т.кам-крш*.

**Тугызы, кыркысы,** табисе (< таба исе) **чыгару**:

— *Тугызы* була, *кыркысы* була. Ак сарык суйабыз *кыркысына*. Са---рыктан була инде. Олы сарык булса да суйабыз. Алай карадан суй---мыйбыз, тәкәдән суймыйбыз инде, бикәчтән суйабыз.

— *Кыркысында* шул таба исе чыгарып атап бер мал суйа инде. Анда бәрәнме, казмы. Туган-тумачаны җыйып шәм җагып утыралар — *т.кам.-крш*.

**Мордва-каратайларда**: *эч кене, тугыз кене, эч атнасы, кырк кенен чугына’лар, алты атнасын чугына’лар, җарты җылын чугына’лар, бер җылын чугына’лар. Эчкен ашка*, үлдүкләр ашына[1] барам дисен.

[1] *Үлдүкләр ашы* — үлгән кешеләрне искә алу мәҗлесе.

## Пуминка, пуминкы

**Пуминка** [< рус. поминки] *глз.* үлгән кешене искә алу (бисер---мәннәрдә — Удмуртия):

— Пуминкада зиратка барабыз, ашау-ичу был а барабыз, пы---шырышып илтабыз. Ак пирапач[1], кабарчы[2], табикмэк, коймаклар. Ул ыкларны пуминат итэбез[3]. Йылына эч кат була пуминкы. Җымга йук, йакшамбы кынны кила.

— Бүген тәкә суйалар, танда пуминка, зират эстегә барабыз диләр.

Кайтасы кырдан, тәкә суйасы, пуминкага барасы дип сөйләшәләр бичырманнар кырда эшләгәндә.

Атналап-атналап була ул пуминка. Белем түгәләр, йомырка бешерәләр, пирәмәч. Кәрзингә бешерешкән ашамаларны[4] тутыралар. Зиратка кабер өсләренә ул ашауларны салып пуминка йасыйлар.

— Пуминкалар төрле wакыт була. **Йазгы пуминка, йәйге пу---минка. Печин чапкан өстөндә дә пуминка** була.

— Ашау пешереп, кәрҗинкәләр белән пуминкага баралар, зират өстөнә. Зират өстөнә җәйешеп, ашаулыкка бешергән ашамаларын куйып, ашаулыкка бешергән ашамаларны куйып, шангиларын куй---ып, пуминка итеп кайталар.

**Пуминкы** [< рус. поминки] *крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесе.

— Чәй, аш, ботқа чыга пуминкыда.

— Пуминкыда иң алдан изге суны, қач манған суны йоталар:

«Барысының да алларында булсын, Фәрештәләр белән тиң булсыннар» — *каз.ар.-крш.*

— Табак белән ипей-тозын, **тәбикмәген** пешереп киләләр пуминкыга барганда. Сөлгесен, җаулыгын да алып киләләр.

— Пуминкы дип без пыкырауда зиратқа барабыз, үлеләрне искә ала---быз. Кәбестә бөккәне, чөгендер бөккәннәре пешерәбез, дурочмаклар. Күкәйләр дә аппарабыз.

«Без ашадық-эчтек,
Сез дә шушылай туқланығыз», — дип — *каз.ар.-крш.*

[1] *Пирапач* — пәрәмәч.
[2] *Қабарчы* — күзикмәк
[3] *Пуминат' итү* — искә алу.

[4] *Ашамалар* — ашамлыклар.

— Пықырау — 14 октябрьдә була. Чөгендер бөккәннәре, қоймақ белән дучмақлар пешереп пуминкага баралар, зиратқа:

«Шуның алдында булсын», — диләр — *каз.ар.-крш.*

**Атап суйу**

**Атап суйу** *крш.* үлгән кешеләр рухына багышлап дини мәҗлескә хайван сую.

— Затыма-зәwеремә дип атап сыйыр суйам аш биргәндә — *нгб.-крш.*

**Дуңғыз атап суйу йарамый** *крш.*:

— Үлгән малайының җыллык ашына дуңгыз атаган бер катын. Менә малайымның ашына дуңгыз атаган ыйым ди. Иртә белән торып чыгуына дуңгыз сузылып йатып үлгән. «Нишләп миңа суң киңәш итмәдең? Без бит керәшеннәр булсак та пуминкыга канатлы кош суйа---быз», — димен. Миңа беренче әйтүче син, диде. Сарык йарый, сыйыр йарый, дуңгыз йарамый.

**Кан чыгарышлы, қан чығару**

**Кан чыгарышлы** *т.кам.-крш.* үлгән кешене искә алып, нинди дә булса хайван яки кош сую.

— Җыллык ашны менә болай үткәрәбез. Сарыгы булган кеше са---рык суйа ололарга, сарык булмаса, таwык суйа. Кечеләргә күкәй сыту да җарый. «Қан чығарышлы», — диләр.

— Қырығында қан чығаралар.

«Җан урынына — җан,
Қан урынына — қан», — дип.

Малны чалдыралар. Үзеңнең бер җақын туғаның мал чала инде.

Мал чалған җиргә бәләкәй генә қоштабақ белән тәбикмәк алып чығалар да ул тәбикмәкне эткә бирәләр — *каз.ар.-крш.*

**Чугыну, чугынырга бару**

Мордва-каратай (татарлашкан мордвалар) сөйләшендә үлгән кешене искә алу мәҗлесенә баруны *чугынырга бару* дип әйтәләр.

— Чугынырга барганда бер шәм илтәсен. Аны җандыралар ул шәмнәрне, чугынган бахытта җандыралар шәмне.

**Чугыну** *м.-кар.* искә алу мәҗлесендә келәү итү.

— Витражны[1] эстәл эстенә куйа, әйбирләрне куйа, чугына’лар да исәнләшәләр. Эстәл эстендә китергән әйберләр тыра тергән килеш. Баскан килеш чугына’лар да укилар. Укыган чакта аны эстендәге тергечләрен ала’лар иде. Укып бетерә’ләр дә ул әйберләрне барысын да ала’лар, чыланга, пычмакка җыйа ул әйберләрне. Хуҗәйке үзенекен тезә, эшти китерә, балы’лар, ипи тури.

**Чугынган — «изгеләндерелгән»**

— **Чугынган витраж** (питрач, ягъни күмәч), **чугынган ипиләр** дә китерәләр эстәлгә, **чугынган балыклар** да куйалар — *м.-кар.*

**Келәү, үле келәwе**

**Келәү** *крш.* теләк итү, дини мәҗлес.

— Келәүләр беткәч үлене «озатып» җибәрәбез. Өч кеше чығып, қойаш чығышына қарап озаталар.

**Үле келәwе** *каз.ар.-крш., чст.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесе; дини мәҗлес.

— Үле келәwендә ашка келәү итәләр дә утыралар. Утыргачын башта тәбикмәк белән бал қабалар, шулай тийеш. Иң башта шулай тәбикмәк белән бал тийеш. Үле келәwенә җабышкынчы өстәлгә тәбикмәк, күмәч, кесәл китереп куйалар — *каз.ар.-крш.*

**Үлдүкләр келәү**

**Үлдүкләр келәү** *м.-кар.* үлгәннәрне искә алу мәҗлесе.

— Карендәшләрне җәшәләр дә үлдүкләр келәү җасилар, пуитси итәләр[2]. Табикмәкне балга буйи, турый да эләшә. Бары да ала чугы---нып. Табикмәкне пешерә хуҗәйке, бал сертеп айыралар.

Җомортка илтсә, җомортка турилар, пәрәпәч пешерәсен, балык жарит итәсен, бутка пешерәсен.

[1] *Витраж* — питрач; кечкенә күмәч.
[2] *Пуитси итү* — көйләп догалар уку.

**Үлдүкләр ашату**

**Үлдүкләр ашату** *м.-кар.* үлгән кешеләрнең җаннары, рухлары өчен дип тәре алдына ипи белән су кую.

— Үлдүкләр эчен дип түргә тәре алдына ыстакан белән су куйа---лар, ипи куйалар, кашык куйалар, кывас куйалар. Аны эчкен ашында куйалар да тугыз кенендә алалар. Бүтәнне куйа. Ул аши диләр инде, ашату диләр. Алты атнага хәтле куйып тыра, алты атнасы тулгынчы.

«Алты атнасында урынга урнаша», — диләр.

Алты атнасына хәдәр кайа ул булган тере вагытында, шул җирләрдә җеретәләр аны. алты атнасы тулгач, кырк кене булгач, урынга куйалар. Килеп тормый, ашами-эчми аннары. Кырк кенгә тәре (кадәр) җаны җери була үлдүкләрнең.

**Келәү кенәгәләре**

**Келәү кенәгәләре** *т.кам.-крш.* дини китаплар.

— Келәү кенәгәләрен келәү сандыгына салып куйалар.

«Чәчелеп, аунап җөрмәсен,
Ару җирдә булсын».

**Ару қыз Марийаны олылап келәү итү** *крш.*:

— Ару қыз Марийаны олылап келәү итәбез, иман җырлыйбыз. Ботқа чығарабыз Ару қыз Марийаны олылап.

**Кечтун**

**Кечтун** [< удм.] **көн** *каз.ар.-крш.* — үлгән кешене искә алу көне.

— Кечтун көнгә кан чыгаралар, сарык суйалар.

**Түгем**

**Түгем** < түк + -ем — түгем *крш.* — барлык үлгән кешеләрне искә алу көннәре. Зиратка ашау әйберләре белән барып, кабер өсләрендә калдырып, «түгеп» кайталар.

**Түгем** — христиан бәйрәмнәре алдыннан яки бәйрәм үткәч була.

— Түгемдә берсе укый, уку арасында иман җыруwын барысы бергә җырлыйлар.

— Түгемдә **арақы қуймыйбыз**:

«Арақы қуйсаң, үлеләргә қуйылган аш җуғала», — диләр.

**Олы көн түгеме**

**Олы көн түгеме** *крш.* пасхадан соң була торган түгем.

— Оло көн үтеп ике көннән соң түгем була. Тәбикмәк пешерәбез, күкәй пешерәбез, жуқа җәйәбез, пирәмәч пешерәбез, бөтен туғаннарны чақырабыз түгемдә, тәберсен итәбез, кастәрләгән кешеләрне чақырабыз.

— Түгемдә берсе уқый, уқу арасында барысы бергә иман җыруын җырлыйлар — *т.кам.-крш.*

Зиратқа барасы көнне өч мал чаласың:
балық чалалар,
таwық чалалар, йә бәрән,
Күкәй чалалар.

Таw ығы жуғ икән, күкәйне алып чығып, шунда чала. Күкәйне чалып, қыздырып, таwық өчен дип алып баралар. Бар кешенең дә булмый ич инде.

Бәрән чалсалар, бәрәннең баш-айағын алып барасың да шунда қабер өстендә қалдырасың — *каз.ар.-крш.* (Җүкәче).

## Пыкырау түгеме

**Пыкырау түгеме.** Пыкырау — 14 үктәбердә. Шул пықырауға ике көн қалғач була түгем. Чебешләр, әтәчләр суйабыз, чөгендер бәлешләре пешерәбез. Пыкырау — Илтәннең пристулни бәйрәме.

— Пықырауда әрбер кеше үзенең үлесенә атап қан чығара. Икмәкләр җыйып беткән, амбарга кергән бит инде, шул сөйөнөчтән үлеләрне искә алалар.

Хәйерләр бирәбез шул түгем көнне. Җәтим қарт-қорыларға **өлеш бирәсең**.
«Минем үлеләрем өчен булсын, аша, эч», —
дип бирәбез инде. Пықырау алдыннан була ул, атна кич.

— Безнең тағын пықырау түгеме була. Пықырауға қарышы көнне пирук пешерәләр инде җармаданмы, нәстәң бар инде. Әби әйтә тор---ган ыйы: пықырау пируғы ашамыйчы җәй чыққан көчләрегез кермәс, дип. Пықырауның өченче көнне түгем көне була. Әтәч суйып, қан чығарып үлеләрне искә алалар — *т.кам.-крш.*

## Питырау түгеме

**Питырау түгеме** *крш.* июль уртасында, питырау бәйрәме алдын---нан үткәреләә, үлгән кешеләрне искә алу көне.

— Питырау түгеменә тәкә суйабыз, питырау түгеменнән соң печәнгә төшәбез — *каз.ар.-крш.*

— Тәкә сарыкны питырау түгеменә булыр, дип әйтеп куйабыз, печән wахыты, питыраудан суң печән башлана — *т.кам.-крш.*

## Тройсын түгеме, симек

**Тройсын түгеме.** — Тройсын түгемен симек дип атыйлар. Тройсыннан дүрт көн алдан була — *т.кам.-крш.*

— Симек ул үлгән кешеләрне искә алу, ул өч көн була. Үлеләр аwылға қайталар. Беренче көнне мунчага керәбез, икенче көнне эсвичәләр қуйабыз, өченче көнне зиратқа барабыз.

— Мунчага кергәндә, эсвичә қуйғанда үлгәннәрне чақырабыз, таз, су, мунчала, сабын қуйасың.
«Әйдә, йуыныгыз», — дисең.

Үзең чабынасың, чабынғач миллекне җуып җибәрәсең дә үлгән кеше исеменә жар бирәсең. Аннары әйтәсең инде:

«Менә сезнең симек бәйрәмегез җиткән, мунча җақтық сезгә».

— Симек ул тройсын атнасында була, мунча йаға торған көн була, үлгәннәрне сыйлый торған көн.

Шул үлгәннәрне искә алғанда ғына тота торған бер тастымал була. Искә алу бетте — ул тастымалны җуып тағын салып қуйалар, җыйып қуйалар.

— Кичкә аш пешерәләр. Дуңғыз ите түгел, таwық суйалар, пәрәмәч, қоймақ пешерәләр. Йәшләр киләләр болонга зират каршысына, шунда йырлап уйнарлар ыйы.

— Симеттә үлеләрнең сөйләшкәне ишетелә, үзләре күренмиләр. Үлеләрнең қайтқанын күрәсең килсә, менә болай итәләр.

Ат қамытын кийәсен кире йагы белән, асты өскә. Аwылдағы иң қырыйдағы өйнең түбәсенә менеп утырасың. Күреп була ди аларны — *каз.ар.-крш.*

### Урыс түгеме

**Урыс түгеме:** — Трочын алдыннан урысның **буш көн түгем** йасыйбыз.

### Чуwаш түгеме

**Чуwаш түгеме:** — Безнең аwылға нигез салып килеп утыручылар чуwашлар булган, шуңа күрә без чуwашларга да өлеш йасыйбыз, кичатна көн чуwашлар түгеме була. Икесе дә ыриза булсын, дибез — *т.кам.-крш.*

### Түгем ашы

**Түгем ашы** *крш.* искә алу мәҗлесенә пешерелгән ашамлыклар.

— Җыл тулган көнне оло ашын үткәрәләр. Кайда үлгән, шунда урын көйлисең. Шунда табак куйып **түгем ашларын** саласың, **таба исен** чыгарганны саласың — *т.кам.-крш.*

— Түгем ашында берсе уқый, уқу арасында иман җыруын барысы бергә җырлыйлар.

**Түгемдә арақы куйылмый:**

— Түгемдә арақы қуймыйбыз. Арақы куйсаң:

«Үлеләргә қуйылған аш җуғала», — дигәннәр — *т.кам.-крш.*

### Түгем-чәчем

**Түгем-чәчем** *крш.* үлгән кешеләрне искә алу көннәре: пасха, симек, покрау һ.б. көннәр алдыннан зиратка ашау ризыклары белән баралар.

— Түгем-чәчем көне диләр инде, зиратка бара торган көн. Питы---рау, казанскида , покыраууда инде кан чыгара торган көн. Әтәс суйа---быз, коймаклар пешерәбез, хәбер өстенә куйабыз.

— Түгем-чәчемгә йомырқа, күзикмәк пешерә, гердә. Шуны ашаулыгы белән бер қарчыққа бирә хәйер итеп. Шуны **түгем-чәчем** дип садака итеп бирәсең, җәйгән ашаулыгы белән бергә бер карчыкка биреп җибәрәсең — *т.кам.-крш.*

— Түгемдә йомырқа пешерәбез, таwық суйабыз, қоймақлар пеше---реп зиратқа барабыз.

Үлгән кеше өстөнә, қабер өстөнә бисмилла әйтеп саласын инде шунда.

Йомырқаларны дүрткә бүләсен дә саласын шунда. Қарғалар ашый аны.

«Син ашаған-эчкән күк булсын» — *каз.ар.-крш.*

**Чәчү**

**Чәчү** *кузн.* дини мәҗлестә мәйетләр рухына багышлап әйбер өләшү.

— Хатемгә буш бармыйлар. Шәлме, йеслекме алып бара, йә чылка---мы, күлмәкме бирә. Чәчү була ул мәйеткә.

**Чәчемнек, чәчәүник**

**Чәчемнек** *т.кам.-крш.* зират янында үлгән кешеләр рухына ба---гышлап келәү итү, хәер өләшү, боламык пешерү урыны.

— Йаз қоры килсә келәү була чәчемнек қырында. Боламық пешерәләр, келәү итәләр, барысы да өйләренә боламық алып қайталар, кеше сайын өләшәләр чәчемнек боламығын, чәчү башлангынчы чәчемнеккә баралар.

— Чәчемнек бар безнең ике шишмә арасында. Үлемтектә[1] дә безнең бер чәчемнек тора. Чәчемнеккә изгеләр төсе қуйалар: Алла анасы, Исус Кристус, Николай әти төсенә қуйалар. Тәре алды эләләр чәчемнеккә. Басмадан[2] тегәсен дә алҗапқыч итеп эләсен. Адарынған кеше қуйа тәре алдын, тәре җаулығын, тәре бистәре. Күкәйләр қуйа чәчемнеккә.

[1] *Үлемтектә* — зиратта.
[2] *Басма* — ситсы.

— Чәчемнеккә қағылырға җарамый, тота. Җә үлә, җә имгәнә.

— Үлемтеккә илткенче чәчемнектә бәхилләшеп қалалар мәйет белән. Чәчемнек — чишмә қырында, чәчемнектә келәү була.

— Чәчемнектә туқтап үлгәннәрне искә алып келәү ителә. Өстәлгә ашау әйберләрен қуйып уқыйсы була. Сыйыр сыйлары, балы, қоймағы, сөзмәсе, күкәйе була. Қабер өстенә дә қуйалар қарғалар өчен дип. Соңгы йулға озатқанда чәчемнеккә кереп ақча саласын.

— Чәчемнекләр аwыл очонда да, бу очта да бар ыйы. Қач йасап қуйалар. Ул түбәле була. Чәчемнеккә анда қатлы-қатлы әйбер эләләр. Кем адарына, шул қуйа. Җаулықлар, бистәрләр элеп қуйалар.

— Чәчемнеккә қәтле җырлап озаталар үлене:

«Святой Алла, Святой Тын,
Үзең җарлықа»

дип җырлап баралар.

Чәчемнектән үлемтеккә алып китәләр үлене — *каз.ар.-крш.*

Симет — читбирек, үлгәннәр җанына зиратқа бара торған көн, туған-тумачаларны искә алырға. Күкәйләр, тәбикмәкләр пешерәбез.

Туған-тумачаларға,
Йәтимнәргә,
Искә алучылары булмағаннарға

дип әйтеп қалдырасың.

Зираттан чыққанда чәчемнек бар, шунда да қалдырып китәсең.

Шишмә йанында чәчемнек бар. Кеше шунда адарынып тастымал қуйа — *т.кам.-крш.*

**Исәнләшү чәчемнеге, саубуллашу чәчемнеге**

**Исәнләшү чәчемнеге** *каз.ар.-крш.* авыл башындагы чәчәүник.

**Саубуллашу чәчемнеге** *каз.ар.-крш.* авылны чыгып киткән урын---га куелган чәчәүник.

— Безнең аwылда шулай ике чәчемнек. Берсе — аwыл бшындағысы — исәнләшү, икенчесе — аwылны чығып киткәндәгесе — саубуллашу. Шунда әйберләр элеп китәләр адарынған кешеләр, җә алҗапқыч элә, җә бистәр.

### Чәчәүник

**Чәчәүник** *каз.ар.-крш.* үлгәннәр рухына багышлап әйбер элү уры---ны.

— Чәчәүник диләр ийе. Су буйында, чишмә қырыйында булған ул. Чәчәүниккә сөлгөме, баш җаулығымы элеп қуйалар.

«Айыпламағыз.
Саулық, сәләмәтлек қодай бирсен».
— Соңғы йулға озатқанда чәчәүниккә кереп ақча саласың, әрмийәә киткәндә чәчәүниккә кереп келәү итеп китә, ақча сала.

— Чәчәүниктә келәү итәләр, ботқа пешерәләр, келәү боламығын өйләренә дә алып қайталар.

### Түгү

**Түгү** *т.я.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесендә бер табак ашамлыкларны йола буенча капка төбенә түгү.

— Үлене сагынганда куймак, бутка пешерәбез, тәкә суйабыз, дуңгыз җарамый. Ашаб-эчәбез дә ашаган-эчкән ризыкны капка төбенә чыгарып түгәбез бер табакка салып «аның өлеше» дип, «Күктәге ата---быз» дип җырлап.

«Бәкиллә, тыныч йат,
Туклыклы бул», — дибез.

— Сагынмача, килә алмача калган туганнары булса да үз ызба---ларында гына сагынып, капка төбенә түгәләр, кийаш унайына таба түгәләр.

**Түгеп куйу** *т.я.-крш.* зиратта үлгән кешенең кабере өстендә ашам---лыклар калдыру.

— Мазар эстенә калач, чыгыт алып баралар да шәм җандырып, түгеп куйалар.

**Түгү** — татарлашкан, ягъни татарча сөйләшә торган, мәҗүси марилар сөйләшендә (Актаныш районы Мари-Суксу һәм Терпеле авылларында язып алынды).

— Симек бәйрәме, җафрак бәйрәме көнне барабыз зиарәткә. «Әйдәгез, безгә кунакка» дип чакырып кайтабыз нәсел-ыруларны. Чакырып кайткачтын чәйләр әзерләп, тәбикмәкләр пешереп қуйабыз.
Үлекләргә бер бәләкәй саwыт белән кашык куйабыз. Ул ашам---лыкларны чыгарып түгәбез.

«Менә без сезне сыйладык,
калганын маллар ашасын».
Калган ашамлыкларны төнйакка таба түгәсе.
«Очтомакта булсын», — дисең.
«Ахирәттә алларында булсын», — дисең.

**Түккән җир** — татарча сөйләшә торган мари авылларында үлгәннәр өлешенә ашамлыклар түгү урыны.

— Үзеңнең түккән җиреӊ була. Калган ашамлыкларны чыгарып түгәсеӊ бер җиргә, йомыркаларны түгәсеӊ аерым бер җиргә.
«Җитсен» дигән сүз була, «шужы» дип түгәсеӊ.

### Күкәй белән түгем итү

— Кан чыгарырга бер әйбер дә булмаган түгемнәрдә **күкәй** кисәбез.

Бер кешене искә алам икән, мин бер күкәй суйам. Зур пуминкы икән, өч кешене искә алам икән, өчне суйам күкәйне. **Парлы** булмасын, **так** булсын.
**Өч күкәй:** — үзебезнеӊ нигездә үлгәннәргә,

үзебезнеӊ йаӊа үлгәннәргә,
исемсез балаларга.

Күкәйнеӊ үзенә кырис[1] йасыйм да кисеп җибәрәм, шул күкәйгә камыр йасим, искә алуга пешерәм — *т.кам.-крш*.

### Үсемлек майы белән түгем итү, өлеш йасау

— Күкәй дә булмаган чакларда **үсемлек майын** кулланабыз, алай да була. Үсемлек майын тамызып-тамызып салабыз исемнәп:

«ололар өлеше»,
«кечеләр өлеше»,
«беркем йуклар өлеше»,
«йардәмчеләр өлеше», — дип.

[1] *Кырис* [< рус. крест] — тәре.

Тамызып салып, камыр басып пешереп, өләшеп ашыйбыз. Камыр---дан күбрәк коймак, пирәмәчләр пешерәбез, күзикмәк пешерәбез, җука пешерәбез. Иманнар белән тәберсе итәбез[1].

### Тәберсен, тийәберсен

Бу сүзләр керәшеннәрдә ашау вакытында, ризыклар янында келәү итү йоласын башкарганда әйтелә. Борынгы төрки халыкларның тәңрегә, күк алласына ышану чорларыннан ук калган сүз (Магомедов, 1983, 155), фонетик яктан берникадәр үзенчәлекле булып, безнеӊ көннәрг ә кадәр килеп җиткән дип уйларга нигез бар (ДТС, 544; Фасеев, 1978, 128): Тәберсен — тәӊре бирсен.

### Тәберсе итү

**Тәберсе итү** — үлгән кешене искә алу көннәрендә ашау ризыклары янында келәү итү.

— Урындыкка мендәр куйып, табакны куйып, табакка гердә[2] салып, тәберсе итәргә чыгалар ыйы — *т.кам.-крш*.

### Тәберсенгә бару

**Тәберсенгә бару** *нгб.-крш*. үлгән кешене искә алу мәҗлесенә бару һәм келәү итү.

— Тийәберсенгә барганда ипәй аппарабыз, җаулык аппарабыз, та---бак җасыйбыз.

— Тийәберсенгә барырга әйтәбез хәрендәш-ыруга. Ипәй салабыз, әзерләнәбез. Анда жаулыг аппарабызмы, бистәр[3] аппарабызмы хәйер бирергә.

## Тәберсен көне

**Тәберсен көне** *нгб.-крш.* искә алу көне.

[1] *Тәберсе итү* — тәңре бирсен итү, ягъни ашамлыклар янында теләк теләү.
[2] *Гердә* — кечкенә ипи.
[3] *Бистәр* — сөлге.

— Тәберсен көнендә мичкә җағасын, қоймақны туғисын, күзикмәк басасын, җәйәсен, пешерәсен, шуларны кигән табақларға бүлеп-бүлеп саласын.

Урындықка мендәр қуйып, табаққа қуйып тәберсе итәргә чыгалар.

«Урыны очтомақта булсын,
Туқлықта җөрсөн», —

ди-ди өйрәтәләр ийе инде әбиләр.

## Тәберсе итә торган көн

**Тәберсе итә торган көн** *чст.-крш.* үлгәннәрне искә алу көне.

— Паскы бәйрәменең өченче көне — тийәберсе итә торган көн була инде, үлеләрне сагыну көне була. Таwык суйып, коймак пешереп, тәбә салып, үзеңнең җакын туганнарыңны чакырасың.

## Тәберсен ашлары

**Тәберсен ашлары** *нгб.-крш.* тәберсен көненә (ягъни искә алу көненә) пешереләә торган ашамлыклар.

— Тәберсен итүче кужайын көрник[1] пешерә. Тәберсен көнне мичкә җағасын, қыймақны туглисын, күзикмәкне басасын, җәйәсен, күзикмәк белән қыймақ барыннан да алдан тәберсен ителәә. Қырық күмәче дибез, аны җасыйсын бер қырықны, иллене дигәндәй. Шуны өстәлгә җыйылғачын табақ җасарға қушабыз ике әбигә. Менә монсы үлг ән кешегә җан табағы, монсо уша табағы, монсо қартлар табағы. Өч табақ җасайлар шул киг ән табақлардан кажныйыннан, анда ничек саласы килә. Шуны җасап беткәчен теге табақларны берәү җыйып тора бушаганын. Бер күзикмәкне салып, қыймақны салып, бер күмәчне салып қуйа да табақларға, теге табаққа тәберсен итәбез. Җан табағыннан, уша табағыннан бич җөрөп тәберсен итәбез дә берсен утыртабыз уша башына, берсен монда. Шунардан тәберсен итеп беттисә өзгән нәстәне, сынықларны чығарып сала түбәгә қош-җәннек ашасын дип. Җан табағын бирә бирәсе кешегә. Қартлар табағы тора, уша табағы балаларға. Аш утыртабыз, ашны эчәбез, бутқа утыртабыз. Бутқаны утыртқачын, мына мин аппарам бер бистәр, теге аппара бер жаулық, теге аппара бер таwар, шуларны өләшәләр, кемгә атап бирәсе кигән кешегә бирә.

Бутқа артыннан көрник, җә ит бирә. Менә сийа т әберсен. Қырық күмәч тәберсен сайын була. Ничә кешегә әйтә, күмәч бирә.

[1] *Көрник* [< рус.] — бәлеш.

## Тәберсен, тийәберсен әйтеп ашау

**Тәберсен әйтеп ашау** *каз.ар.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесләрендә йола буенча тиешле сүзләрне әйтеп кую.

— Тәберсен дип, тийәберсен дип әйтеп ашыйбыз:

Олыларға, нигез хуҗаларына, әрберсенә,
Безнең күк ашасыннар, эчсеннәр,

Туқ булсыннар,
Жулчыларға жулдаш булсыннар,
Исәннәргә җан тынычлығы бирсеннәр,
Булышып торсоннар,
Безгә җақшылық теләгез,
Бәхет теләгез.
Исәнлек-саулық,
Тынычлық теләп йатығыз.

**Әйтеп ашау**

— Әйтеп ашағаннан соң қалған ашамлықларны қапқа бағанасына қуйабыз.

«Нәселе жуқ кешеләр өчен», — дип.

Қайсы кеше «қарғаларға» дип қуйа. «Қарғаға түгел, үлгәннәргә», — дип қуйарға кирәк. «Жаңғыш әйткәнмен шул. Қайтсам, бер қаз бәпкәсен қарға ашап жата».

«Жаңғыш әйтәсең шул, қарға ул бүт эн җирдә дә таба, без менә үлгәннәрне сыйларға килдек», — дим — *каз.ар.-крш.*

**Тәберсендә табақ җасау**

— Тийәберсенгә барырга әйтәбез хәрендәш-ыруға. Ипәй салабыз, әзерләнәбез. Шуннан табақны җасыйбыз үзебезчә, тейгән кеше үлдисә табақ аппарыға кирәк. Анда җаулық аппарабызмы, бистәр аппарабыз---мы хәйер бирергә. Теге кешегә барып җитәбез дә табақларны өстәлгә бич утыртабыз шушылай. Утырабыз да қалық җыйылғынчы табақ җасарға кирәк дип. Мына мынсы — җан табағы, мынсы — уша башы табағы, мынсы — қартлар табағы. Эч табаққа шул табақлардан табақ җасыйбыз. Каждыйына бүлеп-бүлеп саласын. Бу табақны утыртабыз уша башына, бу табақны утыртабыз өстәлгә, җан табағын утырта---быз җан чыққан җиргә. Хуҗайын үзе кемгә бирергә тиеш. Бич йөреп тәберсен итәбез. «Тисен», — дисен инде, — «бусын, ашлы-сыwлы бусын», — дисен. Без шунар атаб итәбез.

«Ашлы-сыwлы бусын, қодай ризыклы итсен», — дисен инде теге йактан. Теге оло табақны биргән кешегә тагын китәбез чәй эчәргә.

«Әйдә гез безгә, табақтан тәберсен итәргә», — дип. Кажныйы утыртып куйа өстәлгә. Бездә узғыралар икә н тәберсен, минем инәмә алар табақ җасый. «Ә мынсы қартларға, элеке үлгән қәрендәш---ыруға, ә ансы инде исемсез, җитем балаларга ашаталар инде. Атадан-инәдән қалған җола буғачын инде. Җыйылышып утырып тәберсен әйтәбез.

Затыбызға-зәwеребезгә,
Затсыз — зәwерсезләргә,
Йомағ ашлары бусын,
Очтомағ ашлары бусын,
Қараңгы гүре йақты бусын,
Аwыр тупырағы йеңел бусын,
Бер қодай, бер тәңре өчен,
Олы-қарылар өчен ,
Инәсе-атасы өчен, —

дип, килгән кешеләрнең барысына да йаулық йабасын.

— Тәберсен итә беләбезме инде, белмибез. Қәрендәш-ырыу, аwыл---күрше җыйа, җыйыштыра , кем киләсе килә, килә бар да. Үзенең күңелендә бар кеше килә бар да. Күтәргән кешеләргә бистәрләр бирәләр — *нгб.* (Париж).

**Тәберсен итү**

**Тәберсен итү** — иман теләү була, коймак, ипей кабу була. Урындыкка тәбикмәк, ипи, балык куйалар, **иман** җырлыйлар, тәберсе итәләр — *т.кам.-крш.*

— Тәберсен итәбез дип башта бал қабалар, қоймақлар. Үлгәннәрне искә алалар. Алдан үлгәннәрне дә, хәзер үлгәннәрне дә — *т.кам.-крш.*

Тәбикмәк — тәберсен итә торған аш ул. Тәберсен итәбез келәүләр иткәч. Башта исәннәрне, аннары үлгәннәрне искә алып тәберсен итәбез.

Үлгәннәрнең җаннары очтомақта булсын,
Җаннары тынычлықта булсын.
И, қодай,
Искә ал үлгән мәндәләрне,
Аларның ирекле-ирексез қылған
Җазықларын кичер.
Аwырту-кийек, қайғылар жуқ җирдә
Мәңгелек тормышта, мәңгегә тынычландыр.
Әүлийәләрең белән бергә урнаштыр, —
дип тәберсен итәбез.

— Тәберсен иткәндә барысының да исемен әйтәсең инде. Үлгән ке---шене иң алдан искә аласың:

Алтмыш ыруwыма,
Җитмеш тамырыма,
Очтымақ ашлары булсын,
Аwыр тупырақлары җиңгел булсын,
Исе-борынына керсен,
Тәме-тамақларына керсен,
Безнең кебек туқлықта булсын,
Сөйенеп-қуwанып торсын.
Қодай тынычлық бирсен, — дибез — *каз.ар.-крш.*

## Гүр тәберсене

**Гүр тәберсене** *нгб.-крш.* — зиратта, үлгән кешенең кабере өстендә ашау әйберләре (йомырка, ипи һ.б.) куеп, аны искә алу:

— Қәбер сайын тәберсе итеп җөрибез зиратта, гүр тәберсене була.

— Пешеренәсен, ипекәйенне аласын, тийәберсен итәбез. Гүр өстенә җыйылып гүр тәберсене итәсен.

Очтомағ ашлары бусын,
Тамақлары туқланып җатсын,
Күңелләре хушланып җатсын,
Қараңгы гүрең йақты булсын,
Танауларына исләре керсен,
Аwызларына т әмнәре керсен,
Барысының да җомағ ашлары бусын.
Ыруым, затым, зәверем, тәңрем өчен бусын
дип, ипи, тоз, күкәйне гүр өстенә қуйасың.

## Үлгәннәр кайту көне

**Үле чыққан көн, үле чығу көне** *крш.* пасха көннәрендә үлгәннәрне искә ала торган көн; мунча ягу — бу йоланың иң төп өлеше.

— Үле чығу көне паскыдан бер атна алдан була. Сабыннар, сулар салып қуйалар, тарақлар қуйалар, табақларға су салып қуйалар.

Үле чығу көнне дә, үле чыққан көнгә қаршы да мунча жағабыз. «Үлгәннәр қайта да жуына», — диләр. Үле чыққан көнне без сезне чақырабыз дип саwытлар тезеп җөриләр ийе.

Эссе салалар үлгәннәргә. Үзе жуынып беткәч, шулай эссе салып чыгып китәләр.

— Тупылларға меңгереп қуйғаннар саwытларны.

Шул үле чыққан көнне өй түбәсенә менеп, җиде қат қыл иләктән қарасаң, үлгән кешеләрнең қайтқаны күренә ди — *каз.ар.-крш.*

— **Үле чыккан көн** — паскының алдагы читбиригендә була инде ул. Үле чыгуга каршы бөтөн кеше мунча җага. **Үлгәннәрне искә ала торган көн дибез.**

— Үлеләр чыққан көн олы көн алдыннан бер атна элек, читвирг көн була ул.

«Үле чыққан көнне җил булса, җыл буйы җил була», — диб әйтәләр ийе бабайлар — *каз.ар.-крш.*

### Үле мунчасы җағу

— Чәршәмбе көнне үле чыққан көнгә қаршы мунча йағалар. Мун---чадан чыққанда ташқа эссе салып чыгалар.

— Менә ирем үлгәчен ташқа өлеш салмый чыққаным шулай мун---чадан. Төшемә керде бит, печәнлектә җөри. Аңа атап сабын, мунча---ла, тарақ, миллек қуйабыз. Шулай мунча жағабыз, үлеләргә **мунча өлеше салып** чығабыз — *каз.ар.-крш.*

### Үле чыгу көне җолалары

— Ул үле чыгу көнне үзенең электән калган җолалары бар:

Үле чыгу көнне иртүк торалар да бакчага **тукмақ аталар**:

«Бәрәңгеләр туқмақ шикелле булсын».

Аннары даған атыналар:

«Урақ урғанда билләр аwыртмасын».

Аннары бақчаға чығып уттан сикерәләр:

«Гәүдәләр җиңгел булсын».

Чишмә башында бөтөн кеше кер жуа чиратлашып. Кер жусаң, имеш:

«Җитеннәр озон була».

Элеке бит җитен чәчкәннәр, җитен суғып киндер җасағаннар. Озон җитеннеке әйбәт чыға киндере — *каз.ар.-крш.*

### Бәйрәмнәү, үле бәйрәме

**Бәйрәмнәү** *м.-кар.* искә алу, зурлау.

— «Килегез, нәсел-җәwер, сезне бәйрәмнибез бүген», — дисен, витраслар (питрач — төче күмәч) пешерәсен.

**Үле бәйрәме** *чст.-крш.* олы көн (пасха) үткәч, үлгәннәрне исә алып, бер-берсенә мәҗлескә йөрешү.

— Олы көннең бер атнасы үткәчен карчыклар җерешәбез таwыклар суйып, пешеренеп.

### Үлеләр бәйрәме, әрәпә

**Үлеләр бәйрәме, әрәпә** *крш*. үлгәннәрне искә алу, зиратка бара тор---ган көн.

— Олы көн — атна көнне, бер атна үтә, субута көнне әрәпә була. Без, Җүкәче аwыллары, әрәпә көнне зиратқа барабыз. Таwық суйабыз, қоймақлар пешерәбез, тәбә салабыз. Тәберсе итәбез, үеләрне сағынабыз — *каз.ар.-крш.*

**Үеләрнең кереп китүләре көне**

— Олы көннән бер атнадан соң — үеләр бәйрәме була. Ул инде үеләрнең кереп китүләре көне. Ул көнне күкәй маналар, бөтен кеше қайта, зиратқа баралар туған-тумачалар. Шунда қуйасың инде күкәйләрне wатып.

«Менә сезгә олы көн күкәйе», — дип әйтеп қуйабыз.

«Мәңгегә туқ булығыз,
Безгә рәнҗемәгез» — *каз.ар.-крш.*

**Үлене сыйлау**

**Үлене сыйлау** *әстр*. үлгәннәрне искә алу, ис чыгару, нәрсә дә булса пешерү, хәер бирү.

— Үлене сыйлау кирәк. Исеңә төштеме үле, нийаз күтәр, ис чығар, белгәнеңне уқып иманыңны әйт. Ул риза булып йатыр ди. Шуның өчен әйткәннәр:

«Үлене сыйлағанның соресе дә ач булмас».
«Үле — ашар,
Тере — йабар», — дигәннәр.

— Үлене сыйлап баw ырсақ пешерәләр, үле коранына. Коран баw ырсағы wақ-wақ була. Килгән кешеләргә ишектән чыкканда би---реп җибәрәләр.

«Сезгә дә аның йәшен бирсен».

Бер қапчық он белән чара-чара баwырсақ пешердек қайнанам үлгәч. Барын да биреп җибәрдек.

«Үлесен сыйлаған кешенең
тересе дә ач булмас», — дигәннәр.

**Тәкәрлек келәwе, үеләр келәwе**

**Тәкәрлек келәwе** *т.кам.-крш*. көн көне үткәрелә торган келәү. зи---ратка барып, барлык үеләрне искә алу көне.

— Тәкәрлек келәwе, үеләр келәwе дип үлемтеккә (зиратка) менәбез. Күкәй, ипи, сөзмәләр алып менәбез. Чәчемнек йанында келәү итәбез дә қаберләр өстенә ашаулық җәйеп тәбикмәккә бал сөртеп қабабыз:

«Очтомақ ашы булсын».

**Табақ, табақ ясау**

Керәшеннәрдә үлгән кешене искә алу мәҗлесенә һәркем табакка салып күзикмәк, тәбикмәк, коймак һ.б. ашамлыклар алып килә. Бер тәҗрибәле кешене (ул табак җасаучы дип атала) шул ашамлыкларның һәркайсыннан әзләп-әзләп алып өч табак ясарга билгеләп куялар. Бу табаклар түбәндәгечә атала.

**Қартлар табағы, олылар табағы**

**Қартлар табағы, олы-қары табағы** *нгб.-крш*. үлгән кешене искә алу мәҗлесендә картлар өлеше дип, өлешләр салып куелган табак.

— *Қартлар табағыннан* әркем аwыз итә, тәберсен итә.

— *Олы-қары табағын* уртаға қуйып, бич өстәл җанында җөрөп тәберсен итәбез.

— Үле ашында менә олылар табағы дип әйтәбез инде. Күкәй, кам---фитлар қуйабыз, жуқа салабыз.

«Үлене кастәрләгән — бай булған», — ди — *каз.ар.-крш.*

**Уша табағы**

**Уша табағы** *нгб.-крш.* уша — мич кырына беркетелгән такта утыргыч. Искә алу мәҗлесендә табакка өлешләр салып ушага куялар, ул — ятимнәр өлеше (җитем-җилпегә).

— *Уша табағын* җитем-җилпегә өләшәләр, караучысы булмаган балаларға, қартларга.

*Уша табагын* ушага куйалар, *уша табағыннан* бич йөреп тәберсен итәбез — *нгб.-крш.*

— Бер җылга хәтле көн сайын қайта, бер җылдан сун кече атна көнне генә қайта ди мәйет. Әwәле *уша буйыннан* ике идәнне җуwып қуйалар ыйы, мәйетләр килеп шунда торалар дип. Төштә күргәч тә мәйетне *уша буйында* торғанын күрәләр.

**Уша** *бөре, минз., перм., каз.ар.-крш., нгб.-крш., т.кам.-крш.* мич кырына беркетелгән тар такта, басма.

— *Ушаға* утырсаң, бәхетсез буласың, диләр — *перм.* Әй ушасы әле ушасы, ушасына қушма қушасы — *т.кам.-крш.*

**Үлеләр табағы, җан табағы**

**Үлеләр табағы, җан табағы** *крш.* — бу табакны үлгән кешенең җаны өчен дип атаклап куялар.

**Үлеләр табагы**: Тәре алдына табак куйыла, үлеләргә дип. Шунда салалар инде ыризыкның төрлесен. Бу — үлеләр табагы була инде. Аннары ул табакны йәтимнәргә кертеп бирәләр.

— Үлгән кешегә дип атап җасалган *табак* була. Шул табакка барыннан да җыйалар аның өлеше дип. Аннары шуны бер ак бүзгә төйнәп кайыр итеп бирәләр — *т.кам.-крш.*

— *Табақ җасарға* кушабыз ике әбигә. Менә монсо үлгән кешегә *җан табағы*, монсо *уша табағы*. Тәберсен итәләр — *нгб.-крш.*

— Үле табағыннан әркем аwыз итеп қуйа инде:

«Йомақлы булсын,
Бәхилләп йатсын».

Утырыр алдыннан әрқайсы шул табақтан аwыз итә инде.

— Өч табақ була. Берсен — хәйергә бирәләр, берсен — җаңа үлгәнгә, берсен — күптән үлгәннәргә.

Үле табағындағы ашамлықларны зиратқа алып менеп китәләр дә шунда қалдыралар.

Иман уқыйлар:

«И, ходайым,
Үзеңнең фәрештәләрең белән бергә
тотсаң ыйы бу үлгән мәндәне».

**Табақ белән килү**

**Табақ белән килү** *каз.ар.-крш.* мәет булган өйгә ашау әйберләре салып табак алып килү.

— Табақ белән киләләр үле йатқан өйгә, жуқаны, қоймақны салалар табаққа. Кем табақ белән килгән, шул табақ белән килгән кешеләрне қырығына да чақыралар, җыллығына да чақыралар.

— Зиратқа чығып киткәнче сарық суйалар. Алар чақырып қайтуға қазан асалар, әзерлиләр, туғаннарын чақыралар. Кем боламық, кем қыстыбый пешереп, әрқайсы үзенең табағы белән килә, шулай табақ асып килә.

### Табақ алып килү

**Табақ алып килү** *т.кам.- крш.* искә алу мәҗлесенә нәрсә дә булса пешереп алып килү: — Табак белән ипей-тозын, **тәбикмәген** пешереп киләләр пуминкыга барганда. Сөлгесен, җаулыгын да алып киләләр.

— Бөтен кеше дә үзенең табагын алып бара, шәм алып бара. Кем кимагын, кем пирәмәч, кем җарма алып килә, камфитын алып килә.

Үзенең табагына шәмен җандырып өстәлгә куйа. Хуҗа шул тәбикмәккә, боткага, балга куйа шәмне.

— Кыркына табак белән киләләр. Килгән табакны буш җибәрмиләр. Кырык бер гердә пешерәләр, ул гердәне табак сайын тараталар. Килгән кеше табакка салып күзикмәген, итен, кампитын, перәннеген алып килә. Өстәлең тула барын өйә торгач — *т.кам.-крш.*

### Табақ аппару

**Табақ аппару** *нгб.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә табакка салып ашау әйберләре һәм хәергә өләшү өчен яулык һ.б. алып бару.

Тейгән кеше (туган тиешле кеше) үлдисә *табақ аппарыға* кирәк. Ипей салабыз, әзерләнәбез. Анда җаулық аппарабызмы, бистәр аппарабызмы хәйер бирергә.

### Зиратқа табақ аппару

**Казан арты керәшен сөйләшендә** (Җөри ав.):

— Алып барған табақны қабер өстенә қуйалар да әйтәләр:

«Әүлийәләр белән бер булып,
Фәрештәләр белән тиң булып,
Ашап-эчеп,
Қуwанышып җөрөгез», — дип — *крш.*

### Табақ җасаучы, өлеш бүлүче

**Табақ җасаучы** *крш.* үлг ән кешене искә алу мәҗлесендә ашамлы---кларны өлешләп табакларга бүлүче.

— Табақ җасаучы итеп белүче қарчықны қуйалар. Ул тәберсен итеп өч табаққа өлешләп сала.

### Табақ җасау

**Табақ җасау** *нгб.-крш., каз.ар.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесендә өстәлгә куелган ашамлыкларның һәркайсыннан өлешләп табакка салып кую.

— Без алып барабыз табақ, бу затсыз-зәwерсезгә, бу оло-қарыға дип атап салабыз wак-төйәкне, бу үлегә дип атап салабыз. Шул табақларны чығарабыз атап ишектән и бирәбез бер җитем әбигә.

— Табақ җасарға қушабыз ике әбейгә. Менә монсы үлгән кешегә җан табағы, монсы уша табағы, монсы қартлар табағы. Өч табақ җасайлар шул кигән табақлардан кажныйыннан, анда ничек сала---сы

килә. Шуны җасап беткәчен теге табақларны берәү җыйып тора бушағанын. Җан табағына, уша табағына бич җөрөп тәберсен итәбез. Тәберсен итеп беттисә сынықларны чығарып сала түбәгә — *нгб.-крш.*

— Кем килә, күчтәнәч китерә искә алырга килгәндә. Барсыннан да алып саласың бер саwытқа. Аннары мин ашын, итен салам, ике штука йомырқа салам. Барысын да әзерләп бетерәм дә:

Кыйаматлық хуҗа,
Менә шундый ашлар,
Ашағыз, қунақ булығыз.

Шәм җандырабыз. Барысы да берәр кисәк икмәк сала теге упши табаққа — *каз.ар.-крш.*

— Қырығына килгәндә табақ белән киләләр барысы да.
«Безнекеләрнең ыризықлары бармы?» — дип әйтерләр ди тыуған---нар. Үлгән тыуғаннар бергә җыйылыша диб әйтерләр ди инде. Табақ алып барабыз, тәбикмәкләр пешерәбез, күкәйен, итен пешерәбез.
Қырығын үткәрүче кеше бер табақ қуйа да шул табаққа әммәбез дә салабыз:
«Олылар өчен», — дип.
«Өлешле булсыннар», — дип — каз.ар.-мам. (керәшен).

## Үлгән җиренә табақ қуйу

**Үлгән җиренә табақ қуйу** *каз.ар.-крш.*:
— Үлгән җиренә табақ көйләп қуйалар үлегә. Шуның ризығын че---метеп-чеметеп кенә қабып чығабыз инде. Бу қырығында, җылында шулай қуйабыз.
Аннары мал суйған җиргә чығып та аwыз итеп керәләр.

«Менә әйбәт кенә ашағыз, эчегез», — дип әйттеләр ди-ди керәләр инде.

## Калган ашамлыкларны урнаштыру

— Қырқысында да , оло ашында да қалған сөйәкләрен қапқа өстенә қыстыралар. Шуннан қошлар ашап бетерә.

— Қоймакларны қанатлы қошларга бирәләр, қалган сынық---саныкларны түбәгә қошларға ырғытабыз. Этләр ашамасын дип.

— Тәберсе итәргә алып чыққан әйберләрне дә бағана башына куй---ып керәләр.

— «Менә, үлгән мәндәләр, шуны ашаб-эчеп китегез, игенче без---не аптыратып җөрмәгез, үзегез жул белән үзегез җөрегез», — диләр. Қалған ашамлықларны кеше йөрмәгән җиргә қуйалар — *т.кам.-крш.*

## Сөйәк озату

**Сөйәк озату** *каз.ар.-крш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесеннән соң калган ашамлыкларны һәм сөякләрне йола үтәп урнаштыру.

— Үле ашын ит әбез дәген икенче көнне иртән **сөйәк озатырга җыйылабыз**. Анда сөйәк озатқанда өч кешеме, биш кешеме кирәк, **тақ кирәк** инде.
Анда қырығына суйған бәкәйнең баш-айақларын чичтартып пе---шерәбез. Аны ашаған кеше ашый, ашамаған кеше ашамый.
Ул бәкәйне чалған чақта башына **тастымал бәйләп чалалар**.

Бөтен сөйәкләрне, өстәл өстөндәге қалдықларны бер иләккә салып апчығабыз, бәкәйнең айағын бәйләгән бамын да шунда қуйабыз, өстөнә бәкәйне чалған чақта башына бәйләгән тастымалны җабабыз.

Өйдән чыкканда ул иләкне **б әкәй чалған кеше** тота, сөйәг озатырға чыкқанда инде. Берәү аш тота, берәү чәй тота, берәү ул көнне пешкән қоймақны тотоп алдан чыға:

«Анық үзенең қоймағы», — диләр.

Ашларны, сөйәкләрне киртә булса, киртә арқылы чығарабыз, киртә булмаса, бақчадағы бер ағач төбөнә салабыз.

**Тастымал** — мал чалған кешегә була, қоймақны өйгә алып керә.

«Моннан соң мондый ашлар үткәрергә ходай насыйп итмәсен, менә малайларны өйләндереп бәйрәм ашлары йасарға насыйп булсын», — дийеп, ул қоймақларны мал чиләгенә салалар.

Бездә шулай үлгән кешегә бағышлап аш итәләр ич инде, қан чығаралар, бәкәй суйалар. Җиделәрендә, қырығында итнең сөйәкләрен озаталар, чичта җиргә күмәләр — *каз.ар.-крш.* (Кукмара).

**Чәчемнеккә сөйәк озату**

— Қырық күмәчен пешерәләр, дучмағын, қоймағын қуйалар табаққа.

Сөйәкле итләрнең сөйәген, күкәй қабықларын салабыз, әйбәт әйберләр дә салабыз. Сөйәк озата торған җиргә, чәчемнеккә түгәбез.

Қыш көне булса, чиләкләре белән қар алып керәләр. Бәләкәй---бәләкәй генә, қалағ очы белән генә қар қабабыз. Җәй көне булса чәчәкләр, баланнар җыйып қайтабыз чиләккә салып.

«Менә шундый-шундый дарулар җибәрде, күчтәнәчләр җибәрде, сезне чақырмады әле», — дип тақмақлап керәләр.

Чиләккә тутырып, чиләк бамын бөйстәр белән тотып баралар сөйәк озатқанда — *каз.ар.-крш.* (Мамадыш).

— Бер тын ашағач, чәчемнеккә сөйәк озатырға барабыз. Анда да әйтеп ашыйбыз, анда өстәле бар:

«Тамақлары туқланып,
Күңгелләре хушланып йатсын».

Анда утырып аwыз итәбез дә қалғанын шунда түгеп қалдырабыз.

Чәчемнектән сөйәк озатып қайтқанда баланнар, йә чәчәкләр алып қайталар шуннан. Шул әйберләрне өләшә башлыйлар.

«Менә, байып беткәннәр,
Әйбәт җаталар, сезгә күчтинәч җибәрделәр».

Қайсы кеше җырлап әйтә:

Быйыл ғына җерләгән җепләремне
Чолғап қына қуйдым җомғаққа.
Без алар өчен қайғырабыз
Алар кергән икән җомаққа — *каз.ар.-крш.*

— Ул **чәчемнек** зират җанында. Анық өстәле бар, утыра торган эскәмийәләр бар. Анда элек өстәл җуғыйы, җиргә генә ташлыйлар ыйы сөйәкләрне. Хәзер өстәлдә алып килгән табақлардан аwыз итәбез дә сөйәкләрне җиргә салабыз — *каз.ар.-крш.*

## ҮЛГӘН КЕШЕЛӘР РУХЫНА БАГЫШЛАП ПЕШЕРЕЛӘ ТОРГАН ЙОЛА АШЛАРЫ

### Әлбә

**Әлбә** — май, он, шикәр комын болгатып пешерелә торган бола---мык. Җирле сөйләшләрдә аның *алба, халба, кәлбә, кәлwә, әлwә* фонетик вариантлары, *қомғабар, қомқабар, қомәлбә, май -әлwә* лексик вариантлары күмү йоласында мифология һәм ырымнар белән бәйле рәвештә еш кулланылалар. Бигрәк тә әстерхан, себер, керәшен сөйләшләре бу яктан бик кызыклы.

**Әстерхан сөйләшләрендә**:

**Алба, халба, хәлwә** *әстр*. әлбә; аны мәет күмгән көнне пешерәләр.

— Үлене күмгәндә пешерәде *албаны*. Үлене күмеп килгәндә баwырсақ пешереп, алба пешереп ашатады. Утырған кеше, җақын---җуwығы баwырсақ белән *албаны* ашап қайтып китәде. Мәйет җиргә төшкәнче шуны ашамаға кирәк, қорән уқытмаға кирәк.

— Қабер қазырға киткәннән суң бороңғыда *алба* пешерә булғаннар, хәзер баwырсақ пешерәләр, қабер қазучыларга ашаталар.

— Қарт кешегә *халва* пешерәләр үлгәч.

«Шуның йәшен бирсен», — дип. Шикәр, май, он белән қуыра. Йәш кеше үлсә пешермиләр *халваны*. Қарт кеше үлсә генә пешерәләр.

— Үлене алып чыққач, башлап қаберчеләргә *халба* қуыра. Қарт кеше үлсә, бөтен кешегә *халбаны* аwыз иттерә.

«Аның гомерен бирсен», — дип.

— *Халбаға* бер пачка май салам, онны салып болғыйм, йарты айақ писук салам. Мәлбәкләргә[1] салып қуйам каберчеләргә. Қалмық чәй, татар чәйе парлыйм.

— Үлегә *хәлwә*, қыйықча баwырсақ пешереләде. Майға қом са---лып болғыйсың, ул қайнап тора, шикәре эреп бетә, әзрәк су салып, он салып болғыйсың, ул қызарады, *хәлwә* булады. Нәлбәкләргә салып қатырасың, кисеп-кисеп қуйасың.

### Алwа қатыру

**Алwа қатыру** *әстр*. әлбә, хәлвә пешерү.

— Әрбер коранда алwа қатырабыз. Бер йомарлам майны эретәм, эрегәч он салам, бутап қайнатам. Зур кораннарға ике йомарлам майдан йасыйбыз. Алwа қайнап күпереп торганда бер айақ сөткә бер айақ шикәр салам, шуны алwа эченә қойоп бутыйм. Шуны қайнатып чыгарасың да қашық белән алып-алып кечкенә айақларға салып чыгасың да пычақ белән шакмаклап кисәсең. Менә саға алwа қатыру була.

### Әлбә

**Әлбә** *каз.ар.-лш.* мәетне искә алу мәҗлесенә пешерәләр.

— Мин үзем әлбәләр пешереп алып киләм. Мәйет ашында әлбә булырға тийеш дип, фуртычкыларны ачып пешерергә қушалар.

«Әлбәнең исе гүргә хәтле иңә», — дигәннәр.

**Әлбә** *каз.ар.-крш.*:

— Бер қашық айбағыр майын[2] салабыз да табаға, шуңа он салып, қуйырғынчы туғыйбыз инде, әлбә булғынчы. Үленең қултығына қуйалар, қулына тоттыралар бәләкәй генә қулҗаулығына төреп.

[1] *Мәлбәк* — тәлинкә.

[2] *Айбағыр майы* — көнбагыш мае.

«Ризық белән барсын», — дип.
«Әлбәне бар кеше дә қабарға, аwыз итәргә тийеш», — диләр.
Қултық асларына сөртәләр әлбәне аз ғына алып:
«Үлгән кеше қурқытмасын өчен» — каз.ар.-крш.
— Бер қалақ қына айбағыр майы салып, онны әwәләп пешереп алалар да үлгән кешенең қултық астына қуйып җибәрәләр, гыру---бында.

Килгән кешеләр дә табадан әлбәне чеметеп кенә алып қабалар, қултық астын уwалар.

Җәнә, үлгән кеше қурқытмый, борчымый була.

— Үлгән кешене гырупқа салғачын қултығына әлбә қыстыралар кечти генә төйенчек белән. Әлбәне табаға айбағыр майы салып, он белән әwәләп пешереп алабыз.

Қайсыбер килгән кешеләр дә әлбәне қултық асларына ышқыйлар:
«Үлгән кеше қурқытмасын».

Әзрәк кенә үзләре дә аwыз итәләр әлбәне — *каз.ар.-крш.* (Чура ав.).
Кеше үлгәч, он белән балны қыздыралар да:
«Тегендә барғач күчтәнәч булыр», —
дип, табутқа тыгып җибәрәләр.

Килгән бар кешегә дә шул әлбәне бәләкәй генә қаптыралар. Шулай әлбә пешерү бар керәшендә (Самара өлкәсе, Урдалы авылы).

### Қорт әлбәсе

**Қорт әлбәсе** *каз.ар.* майлы корт.
— Қорт йасыйбыз сөттән-қатықтан. Озақ қайнатасың, ул қызара, қуйыра. Қорт шул була. Қортны киптереп төйәсең, шунарға сый---ыр майын, сары майны эретеп салып шуны болғаталар. Йуқа ғына тәлинкәләргә салабыз аны. Сыйыр майын қойасың қортқа.

### Әлбә куйу

**Әлбә қуйу, әлбә қабу** себ.:
— Қатым ашка пирбуй әлбә пешерәтләр, өче қатымына, йетесенә, қырығына.
— Ашыңның уртасына утыртатлар әлбә. Қатым уқығаннан суң онаш[1], чәй эчкәндә әлбә утыртатлар. Пороңқыдан қалған саң[2] инде ул.

— Пирбуй песмиллаңны әйтеп әлбә қабасың, өй хуҗасы тайар---лый[3], туғаннары күпме. Пөтөнесе қатым уқытады — *төм*.

### Әлwә

**Әлwә** *себ.-төм*. әлбә.
Әлwә — саваплы аш:
— Әwәле әлwә белән туқац пешереп қатым уғытқаннар қатымнарда. Қайсы кеше белмән пешергән. Әлwә тип сөт белән онны болғап, май салып ашағаннар.
«Саwаплы аш — әлwә», — дигәннәр — төм.

### Май-әлwә

**Май-әлwә** *төм.* әлбә; мәет озатканда һәм искә алганда пешерелә.

— Қырбаштан күмеп килүwенә май-йес тип май-әлwә қылатлар Қырбаштан килгәцен.

— Майны қайнататылар, аңа онны туғыйтылар. Қоп-қозол булғынцы май-әлwәне болғап торадылар. Қоп-қозол булса утызаты---лар. Мәйетне осатып қайтучыларға май-әлwә қылатлар. Май-әлwәне очмағ аш[4] тип пешерәбес.

— Май-әлwә қыласың қырбаштан килгәннәргә. Мәшкә майны[5] қайнатасың та он қуwырасың. Ул май-әлwә тип атала. Май-әлwәне қырбаштан килгән көнне генә пешерәсең, питай оннан қыласың. Майны қысу қайнатасың, майға он туғисың. Он қысарғынца анта қаныт[6] қойасың, цөце су, ул таралып тораты. Аны табацаларға[7] салып утыстасың. Май-әл wәне полай та қылып ашағалы пулаты. Ул туқлықлы нәстә, табацаға wақ саwытларға салып қуйаты.

[1] *Онаш* — токмач.
[2] *Саң* — гадәт, йола.
[3] *Тайарлый* — хәзерли.
[4] *Очмағ аш* — оҗмах ашы.
[5] *Мәшкә май* — ак май, сыер мае.
[6] *Қаныт* — шикәр.
[7] *Табаца* — табак.

— Майға кәлwә пешерәтләр, қаныт салып май-йес цығаратлар.

**Май-әлwә — очмах аш**

— Май-әлwәне очмах аш тиделәр, йес цығарғалы[1] тип пешерәбес. Кәпкер пешерәбес, тақ қыласың аны.

— Май-әлwәне йаңғыр булмаса, суға ботқада да пешерәтеләр.
«Очмах аш», — тиделәр.

**Кәлwә**

**Кәлwә** *төм*. әлбә.
— Майға кәлwә пешерәтлә р йес цығарғалы. Қаныт салып май---йес цығаратлар. Мәйет осатып қайтуцыларға кәлwә пешерәтләр. Тақ кирәк: кәлwә, аш, икмәк.

**Кәлбә**

**Кәлбә** *т.кам.-крш*. әлбә, хәлвә. Кеше үлгән көнне пешерелә, аны «кунақ ашы» дип тә ашыйлар.

— *Кәлбә* дип, қунақ ашы дип он, бал, май белән пешерәләр. Аны кеше сайын өләшеп, қаптырып йөриләр.

Кәлбә дип кажни кешегә өләшеп йөриләр. Үзең дә алып қабасың кәлбә.

«Өлешле булсыннар», — дип. Җәнә шул *кәлбәне* қултығ астында алып бара да өләшә икән үлеләргә, диләр.

— Қунақ ашы дип бал белән онны бутап қайнатып пешерәләр, бер төйенчеккә төйөнниләр дә шуны қуйып җибәрделәр гыруп қырыйына.

**Қомәлбә**

**Қомәлбә** < **қом** + **әлбә** *әстр*. шул ук әлбәне кайбер авылларда шу---лай атыйлар.

[1] *Йес цығарғалы* — ис чыгарырга.

— Мәйет ләхеткә кергәнче қомәлбә пешереп, дастархан җәйеп қор›ән уқиды. «Үленең җатқан җире җомошақ булсын», — дип. Үле жиргә төшкәнче *қомәлбәне* пешереп өлгермәгә кирәк. Үлене затмаға барған кешеләр ашады қомәлбәне.

— *Қомәлбәне* жылына бер мәртәбә пешермә кирәк, ди иде әйем. Пиғамбәребез үлгәндә қомәлбә пешергәннәр, җылға бер мәртәбә пешерә, «Зур саwап», — дип әйтеп.

— *Комәлбәне* мәлбәкләргә[1] салып қуйам қаберчеләргә, қыйыкчаға[2] салып *қомәлбәне* балаларға өләшәсең.

«Анын йәшен бирсен», — дип.

— *Қомәлбәгә* майны қу wырасың, қом шәкәр саласың, он саласың, болғап-болғап пешерәсең. Ике мәлбәккә саласың, баwырсақ өстенә җағып бирәсең, мәлбәккә салып та қуйасың. Күмеп қайтқаннарға бирәсең.

## Қомғабар, қомқабар

**Қомғабар, қомқабар** < **қом + ғабар, қабар** *әстр*. шул ук әлбә.

— Үлене қабергә төшергәнчегә хәтле *қомғабар* дигән зат бар бездә. Қом, майда пешерә, ондан болғап-болғап қазанда. Үлек барып җиткәнче пешерде, анда барғанчыга хәтле қом қапмасын, *қомқабар* қапсын, дип. Қаберчеләр килгәндә чәй дә әзер, тағам[3] да әзер, *қомғабар* да әзер.

— Бер мулла қалаты өйдә. Тастархан җәйәде. Шул мулла қорән уқыды. Қоро тастарханға қомғабарны китереп салаты, чәй бирәт *қомғабарны* бирәт.

— Бүген җирләнде, иртә белән *халва* пешерә, баwырсақ пешерә. *Қомқабары* диделәр шуны, шуны пешерәделәр.

«Мәйетнең аwызына қом тулмасын, *халва* тулсын», — дип шул *қомқабарны* пешермә кирәк диләр.

[1] *Мәлбәк* — тәлинкә.
[2] *Қыйықча* — бавырсакның бер төре.
[3] *Тағам* — ашамлык.

«*Қомқабарығыз* булдымы, чәй биреңез, қорән уқыйбыз», — әйтәләр. Қорән уқыйлар, *қомқабарны*, мамырсаны[1] аwыз итәләр, баwырсақ чәчеп чәй эчәләр.

Қуралға[2] үлене әкиткән сун қомғабарны барсына да қаптыра.

Қомғабарны майға болғап-болғап пешерәде. Барын ашатады, үле ашаған булаты.

## Үленең қомғабары

**Мамырса, қомқабар, үленең қомғабары** *әстр*. әлбә.

— Үле қабергә кергәнче *мамырса* йасыйлар, сары май, шикәр белән онны қуыралар. *Қомқабар* дип тә, *мамырса* дип тә әйтәләр, тәмле була. Шуны кечкенә тустақайлар[3] белән қуйып барысына да ашаталар, қабып-қабып чығалар. «*Үленең қомғабары*» ди.

«Аwызына қом кермәсең», — дип, үле қабергә төшкәнче шуны эшләргә тийешләр өйдә қалған кешеләр.

## Бавырсак

**Баwырсақ** — әстерхан һәм себер сөйләшләрендә үлгән кешене искә алуга, дини мәҗлесләргә пешерелә торган йола ашы.

**Әстерхан сөйләшендә**: бавырсак яссы итеп, тишкәләп пешерелә (үлгән кешегә яктылык керсен!), өстенә әлбә (хәлвә) ягып, мәҗлескә килгән кешеләргә өенә кайтып киткәндә биреп җибәрәләр.

— Баwырсақ пешерәләр, *баwырсақны тишкәлилә р, халва* пешерә---ләр үле коранына. *Баwырсаққа халваны йағалар,* табаққа салып қуйалар баwырсаққа халwа йағып. Кеше сайын нәлб әккә салалар. Үле ашыннан киткәндә кеше сайын биреп җибәрәләр. Киткән кеше үзенең өйенә алып китә. Қапқадан чыққан wахытны өләшәләр иде килгән кешегә.

### Қоран баwырсағы

**Қоран баwырсағы** *әстр*. дини мәҗлескә пешерелгән бавырсак.
— *Коран баwырсағы* wақ-wақ була. Килгән кешеләргә ишектән чыққанда биреп җибәрәләр.

[1] *Мамырса* — әлбә.
[2] *Құрал* — зират.
[3] *Тустақай* — чынаяк.

«Сезгә дә аның йәшен бирсен,
Аның йақшы көннәрен бирсен сезгә дә», —
дип биреп җибәрәләр.
Бер қапчық он белән чара-чара баwырсақ пешердек қайнанам үлгәч. Барын да биреп җибәрдек.

«Үле сыйлаған кешенең
тересе дә ач булмас», —
дигәннәр әзилдә — *әстр*.

### Қыйық баwырсақ, қыйықча

**Қыйық баwырсақ, қыйықча** *әстр*. кыек формалы бавырсак, үлгән кешене искә алуга пешерелә.

— Үле коранына *қыйық баwырсақ* пешерәләр, өстөнә халба йағалар.

— *Қыйықчаға* қомәлбә салып балаларға өләшәләр:
«Аның йәшен бирсен».

### Қыйықчасы

**Қыйықчасы** *әстр*. үлгән кеше рухына багышлап пешерелгән ба---вырсак.

— Үлгән кешене озатканның икенче көнендә кыйык баwырсак пешерәләр, *кыйыкчасы* дип әйтеләде. Катыннар арасында муллабикә[1] коран укый.

«Төшкән җире, туфырагы йомышак булсын» — дип *кыйык* баwырсак өстенә *халwа* салып бирәләр, бавырсакка кайсы кеше мерәппе[2] йагып та куйа.

### Паwырсақ, баwырсақ

Себер диалектларында дини мәҗлескә, искә алуга бавырсак пешерәләр:
— **Тақ йомортқадан**[3] паw ырсақ пешерәтләр қатым ашқа: туғыс, умбер, унөц йомортқаданмы паwырсақ пешерәтләр. Тақ кирәк — *тара*.

[1] *Муллабикә* — абыстай; дини хатын-кыз.
[2] *Мерәппе* — варенье.
[3] *Йомортқа* — йомырка.

## Туқац

**Туқац** *төм*. вак кабартмалар.

— Әwәле туқац белән баwырсақ булған қатымда. Онны ацытып күптесеп пешерәтеләр қатымда. Килен әйтә те: «Мин иртәндән ки---лерем әле туқацыңны пешергәле», — тиде. Мин тордом, туқацым ацып қуйған. Басып қуйтым да туқацымны күптереп қуйтым. Таң атқынцы туқацым пешеп цықты. Килен килгенце туқацым пешеп, сыwынып қуйты.

## Бурәк

**Бурәк** *себ*. бөккән.

— Қатым ашқа бурәкләр дә пешерәләр.

«Йес цығарғалы», — тиләр.

**Қолақ бурәк** *әстр*. пилмән.

— Өчендә пешермәгә кирәк *қолақ бурәк*.

«Мәйетнең күзенә қом кермәсен», — дип пешерелә.

## Пәтер

**Пәтер** [< гар. фытыр, фитыр] *себ*. төче күмәч.

— Қатымда иң беренче пәтер пешерәте.

«Май-йес чықсын».

## Питырац, питырач

**Питырац** < питыр + ац *чст*., **питырач** *кузн*., *лмб*. үлгән кеше ру---хына багышлап, хәергә бирү өчен пешерелә торган кечкенә ипи.

— Үлгән кеше өцен садака китерә, аның өлеше дип.

*Питырац* китерә бер йылга хатле. Ул кецкенә генә түгәрәк була. Йомга көнне китерәләр.

*Питырац* дип күwәсне кырып сала пицкә — *чст*.

— квашн ада калган камырдан питырач пешерәм, хайергә бирәм күршегә — *лмб*.

## Питырац — үлекләр өлеше

— Зур куwашна. Ике пот он салып басабыз. Безнең ә би бар иде. Әпәйне әwәләгән сайын шының тәкле алып әwәләп куйа иде. Пицтә пешереп ала иде әпәйләр белән бергә. Пиц кун ына сала иде аны пи---тырац итеп.

«Үлгән кешеләр өцен,
өлешләре булсын», —
дип куйа иде.

«Кан н ам өцен,
Үлгән бабам өцен,
Аларның өлешләре булсын», —
дип, йәтим әбигә бирә иде.
«Үлекләр өцен», —

дип, укыган кешегә биргәннәр питырацны.

«Бисмилла, үлекләремә садака булсын» — чпр.

## Витрас, витраж

**Витрас, витраж** *м.-кар.* мишәр диалектындагы питрач сүзенең фонетик вариантлары: кечкенә түгәрәк ипиләр.

**Витражны круслы тергеч белән китерәләр**:

— *Витрас лар* йасилар чугынырга барыга, шәм илтәсен, җоморткa, эстәл эстенә куйасын. «Килегез нәсел-җәвер, сезне бәйрәмнибез бүген», — дисен, чугынасын.

— *Витражны* тергечкә терә’ләр дә китерә’ләр. Тергеченә крус тегеп куйган була, витражны тереп китерә дә аны җийып куйа тергечне. Алда тавычка салып тергеч белән тереп китерә’ләр иде, круслы тергеч белән.

**Витрасны үле чеперәгенә төреп китерәләр**:

— Витрасны алда үле чеперәгенә тереп алып килә’ләр иде, кара---дан тегеп куйган кырус, җә җүләп куйган, чушылый үле чеперәгенә тергеченә терә’ләр иде, кул ычында илтә’ләр иде чугынырга бар---ганда. Ад’аларыбызга бахыт булмаса без балаларны җибәрә’ләр иде.

## Пишка

**Пишка** [< рус. пышка] *күрш.* кабартма. Үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә, хәергә бирелә.

— Пишкаларны зиде зиргә цырнап бирәсен күләкләргә цырнап.

## Гердә

**Гердә** [< фарс.] *каз.ар.-крш., т.кам.-крш.* кечкенә кабартма, вак күмәч. Аны керәшеннәр кырыгын үткәргән көндә пешерәләр.

**Гердә** сүзе шул ук мәгънәдә Татарстанның тау ягы сөйләшләрендә, Казан артының лаеш сөйләшендә (хәергә бирелә торган вак күмәч) билгеле. Бу сүз башка төрки телләрдә дә бар. Мәсәлән, уйгур телендә **гирдә** — вак күмәч, **гош гирдә** — итле бәлеш, караим телендә **гирдә** — катлы бәлеш.

— Кыркысына *кырык гердә* әwәлиләр, җәйләү-җәйләү кәдәре була ул. Кырыгына ничә кеше килә, тәлинкәгә саласың инде.

— Кырыгына *гердә* пешерәбез, *кырыкны* да, *кырыкберне* дә әвәлибез. Кеше сайын берәрне куйабыз мәйет ашына, пумилкәгә килүчеләргә — *т.кам.-крш.*

— Қырқысына *қырық гердә* пешерәбез. Урындыққа мендәр қуйып, гердә салып, тәберсен итәргә чығабыз — *т.кам.-крш.*

## Башламаган гүчтинәч, түгәрәк гүчтинәч

Керәшен сөйләшләрендә искә алу мәҗлесенә пешерелә торган гердәне, ягъни кечкенә кабартманы яки ипине шулай әйтәләр.

— Үлегә башламаған *түгәрәк гүчтинәч* қуйалар, *гердә* қуйалар, тәбикмәк қуйалар.

— Үле өчен биргәндә *гүчтинәче* шулай түгәрәк булсын дигәннәр, *қырық бер гердә* әwәләп, өстәл буйлап тезеп чығалар.

Кырығына кырық *гердә* пешерәләр, кырык берне дә пешерәләр. *Гердәне* айырым-айырым тезеп куйалар ыйы өстәлгә. Өстәл буйлап тезеп чыгалар. Пуминкыдан киткәндә шул гердәне куйа, тәбикмәген қуйа, әзерәк гүчтинәч куйалар ыйы шулай — *чст.-крш.*

## Чыгыт, чыгыт-көлчә

**Чыгыт** — тау ягы керәшен сөйләшендә эремчекне түгәрәкләп пичкә куеп пешерелә торган ашамлык, ул йола ашы булып исәпләнелә.

— Йоморы икмәк кебек итеп чыгыт пешерәбез. Сөтне ойылдырасын[1] да капчыкка салып сарыктырасын. Аннан басасын. Без аны йомырка салып басып, марлыга чүлкәп[2] пичкә куйабыз. Марлы белән чүлкәп куймасан ул чыгыт җәйелеп китә. Түнәгән җире аста кала. Пичкә тыкканда марлы белән тыга да пешеп чыга. Суынгис ул чыгыт катып китә, марлыны кубарып ала.

**Чыгыт башлау** *т.я.-крш.* түгәрәкләп пешерелгән эремчекне (чы---гытны) кеше гомеренең әһәмиятле мизгелләрендә йола ашы итеп күмәкләп авыз итү.

Бала тугистан да, малый өйләнгәндә, кыз кийәүгә киткәндә дә шал чыгытны башлибыз.

*Кеше үлгистән дә чыгыт башлыйбыз.* Үлене сагынганда[3] мазар өстенә[4] чыгыт алып барып, ул чыгытны үленең тишеге[5] өстендә аши башлилар. Ул чыгытны ашап бетермиләр, кайткис ызбада[6] калган кешеләргә өлешләп бирәләр.

«Чыгыт-көлчә[7] биреп җибәрде», — дип. Кабарту-калач[8] сындырып, өстенә чыгытны куйып өләшеп чыгалар әр кеше сайын.

## Күмәч

**Қырық күмәче** *нгб.-крш., т.кам.-крш.* искә алу мәҗлесенә пешерелә торган күмәчләр.

— Элек кечти-кечти күмәчләр пешерәлә р ийе, қырық күмәче диләр ийе. Нәнә алып қайтып безгә ашата торған ыйы. Шул қырық күмәчне қырық кешегә өләшәләр ийе — каз.ар.-крш.

[1] *Ойылдыру* — оету.
[2] *Чүлкәп* — чолгап.
[3] *Үлене сагыну* — үлене искә алу.
[4] *Мазар өсте* — зират өсте.
[5] *Үленең тишеге* — үленең кабере.
[6] *Ызба* [< рус.] — өй.
[7] *Чыгыт-көлчә* — кучтәнәч итеп бирелә торган чыгыт.
[8] *Кабарту-калач* — өйдә пешкән ак икмәк.

— *Қырық күмәче* дибез, аны җасыйсың бер *қырықны*-иллене дигәндәй — нгб.-крш. — *Қырқысына қырық күмәч* пешереп, табақлар сайын өләшеп салып қуйабыз — *т.кам.-крш.*

**Үтми’ ’үмиче** *кас.* икмәк камырыннан пешерелгән вак ипиләр; икмәк күмәче.
— ’ыры’ ’ичисини үтми’ ’үмиче wa’-wa’ итеп пешерилир.

## Праспара, чиркәү қалачы

**Праспара** [> грек. просфора (приношение)] чиркәүгә китерелгән хәер.

— Чиркәүдә пуп келәү иткәчен чиркәү қалачын өләшәләр, праспа---ра дип тә әйтәләр аны — *каз.ар.-крш.*

Ул чиркәү қалачын праспараны үзебез пешерәбез.

Онны эссе су белән болғатып пешерә дә аннары суwық су салып болғата. Әз генә тоз сала, әз генә чүперә сала. Ике сәғәт әчи, аннары шуны бик озақ басасың қаты иттереп. Май да, йомырқа да салынмый.

**Ул қаты итеп басқан қамырны җәйәләр.** Башта зурырағын җасый, аннары бәләкәйләрен җасый. Аннары олосына қапқач кирәк өстәнә, бәләкәйсенә қапқач кирәк өстәнә. Олосына қач белән басып ала. Аннары шуларны қабарта да, қабартқачын қапқачларын су белән майлап җабыштырып чығалар да дүрт җиргә инә белән төртеп чыға. Тигез қабарсын өчен. Аннары сун шуны пешереп ала табаға салып — *каз.ар.-крш.*

— Дары эчкән көнне праспараны пупқа алып барабыз. Ул праспа---раны қач манған су белән ашыйбыз. Аның җазуы да бар:

Қач манған су белән праспара
Җазықларымны бетерсен,
Қәлсезлеклә ремне, нәпесләремне
Бастырырға булсын ыйы, — дип җазған.

Онын пешереп җасағач тәмне була ул. Башта қайнар суға сала, аннары суwық суға салып баса — *каз.ар.-крш.*

**Праспара** — күмәч шикелле түгәрәк ипи була. Пуп уқый, үлгәннә рне, исәннәрне җазып бирәбез. Праспара өләшәләр чиркәүдә. Ул төче күмәч була. Шуның белән без чәй эчәбез.

## Кәпкер

**Кәпкер** *төм.* төче қамырны юка итеп җәеп, тишекләп пешерелгән җаймә. Аны так санда итеп, мәет ашына дип, тишекләп пешерәләр. Кәпкер — себер диалектларында һәм әстерхан сөйләшендә тишекле чүмеч (дуршлаг).

### Кәпкер — үлекнең ашы

— Йомортқаны сытапыс, он беләң басапыс, кәпкер пулаты. Үлекнең ашы пулаты ул. Қырбаштан килгән кешеләргә пешерәтләр.

### Кәпкер — тақ булаты

**Қырықбер күс кәпкер,**
**утыс бер күс кәпкер,**
**йегерме бер күс кәпкер:**
— Кәпкерне йегерме бер күс, йә утыс бер күс қыласың. Қырықбер күс кәпкер пешерәте үлгән көнне. Йылына да пешерәтләр кәпкер.

**Кәпкер — өц тақ,**
**кәпкер — биш тақ,**
**кәпкер — унтуғыс тақ:**

— Тақ кирәк кәпкер. Өц тақ, биш тақ, унтуғыс тақ қылатлар. Үлеккә қылған ашны пестә пиш тақмы, өц тақмы қылатлар.

### Кәпкер — йепсес[1] була

**Кәпкер — йегерме бер,**
**кәпкер — қырық бер,**
**кәпкер — алтмыш бер була.**
— Тақ булырға тейеш ул кәпкер, йепсес, йегерме бер дә була, қырық бер, алтмыш бер дә була. Кеше үлгәнтә пешерәтеләр кәпкер.

[1] *Йепсес* — парсыз; так санда.

### Кәпкер — ацытмайын була

— Ацытмайын[1], қақтан[2] пулаты кәпкер. Йомошағрақ итеп бармақ беләң цигәсең. Тотыш қуйалар, сынтырып ашайлар. Қартлар үлсә пешерәләр.

### Кәпкер — уртасын тишекләп пешереле

— Кәпкерне үлг ән көнне дә пешерәтләр. Йәйәсең, йуқарақ итеп йәйәсең дә уртасын тишекләп-тишекләп пешерәсең. Тишекле булған өцөн кәпкер әйтелә.

### Кәпкер-оллы[3] кеше үлсә пешерелә

— Йәш кеше үлсә пешермиләр, оллыға пешерәләр кәпкер. Қартырақ кеше үлсә пешерәләр кәпкерне.

### Үлек күзе

**Үлек күзе** *срг.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә торган ашамлык; ул бик вак итеп, итле пәрәмәчләр формасында пешерелгән. Аны олы кешеләр генә хәтерлиләр, яшьләр белмиләр.

— Кимак , күптермә, *үлек күзләре* пешерә идек. Менә шының тәкле генә йәймә, пилмин йәймәсе кебек, шының тәкле генә берцәк ит куйасың да бөрәсең. Вәт ул үлек күзе. Пицтә пешерәбез үлек күзен. Ашап беткәц табак белән китерәсең үлек күзен, аны китерәсең дә куйасың өстәлгә.

### Үлек күзе — әҗерле, саwаплы

— *Үлек күзен* йеде кицендә пешерәбез. Мәйетне йыл да искә алганда да пешерәбез. Ул бик әҗерле, саwаплы. Без олан wакытта[4] шылай әниләр үлек күзе пешерделәр. Хазер алай пешермиләр, белмиләр аны йәшләр.

[1] *Ацытмайын* — ачытмыйча.
[2] *Қақтан* — төчедән.
[3] *Оллы* — олы.
[4] *Олан wакытта* — бала вакытта.

— Үлек күзен бар да кес әсенә сала иде, оланнарга дип. Үзләре берәрне генә кабалар, шылай тийеш. Оланнарына алып китәләр.

«Оланнарым озын өмерле булсын,
оланнарның күзләре йакшы күрсен», —
дип, выт аны барысы да уцлап кесәләренә салалар иде.

— Үлек күзе диләр иде, хазер алай йук. Wак кына итеп, күзгә оша---тып эшлиләр иде, шылай ат’алар иде картлар. Өстәлгә куйалар, ашап беткәннән суң ул — *срг.*

### Үлек пәрәмәце

**Үлек пәрәмәце** *срг.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә торган вак пәрәмәчләр.

— Үлек пәрәмәце диләр, аны бик вак кына итеп пешерәләр. Элек аны үлек күзе дип тә ат’каннар. Үлек пәрәмәцен йедесенә, йеде кицәсенә пешерәләр, куй[1] итеннән.

[1] *Куй* — сарык.

Элек цөцедән генә эшлиләр иде, ацыдан йарами диләр иде wак пәрәмәцне, үлек пәрәмәцен.

### Чәлпәк, цәлбәк, чәлбәк

**Чәлпәк** — әдәби телдә камырдан ясалган вак-вак җәймәләрне — юкаларны кайнап торган сары майда пешереп әзерләнгән ашамлык; юка. Казар арты мамадыш сөйләшендә аның *чәлп әк, җәлпәк* варианты да бар. **Чәлпәк** сүзе татар теле сүзлекләрендә дә күрсәтелгән (ТТАС, 1981, т.з.). **Чә лпәк** — фарсы теленнән кергән сүз, ул йола ашы буларак башка төрки телләрдә кулланыла: *башк.* **сәлпәк**, *к.-*

*калп*. **шелпек**, *кум*. **чапелек**, *үзб*. **чалпак**, *төркм*. **челпек**, *кырг*. **челпек**, *уйг*. **чәлпәк**, *монг*. **ielbed** — коймак.

**Цәлбәк, чәлб әк** себернең тубыл-иртыш диалекты төмән сөйләшендә үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә торган йола ашы булып санала, аны мәйетнең «үс ашы» дип атыйлар. **Цәлбәк, чәлбәк** пешерүнең күп кенә ырымнары, нечкәлекләре бар. Аны так сандагы йомыркага баскан камырдан, «йепсес», ягъни так санда пешерәләр.

### Цәлбәк — мәйетнең үс ашы

— Цәлбәкне мәйет ашына ғына пешерәләр. Ул мәйетнең «үс ашы» булаты. Қыйықца итеп кисәтләр аны — *төм*.

### Цәлбәкне пешергәндә тәмләмәйләр

— Цәлбәкне пешергән цақта тәмләмәйтеләр[1]. Цәлбәк — мәйет ашы пулаты. Аны өстәлгә салатлар.

Цәлбәкне **кем пешерәте, шул башлайты** ашағалы цәлбәкне.

### Цәлбәк — қатымға бойоролаты

— Қатымға бойоролаты[2] цәлбәк. Йуwан[3] май қасан[4]. Құрны ацыта---сың, ацу сөт[5] мән басасың, майда пешерәсең.

Цәлбәкне аш қабатына[6] тесеп цығаты.

**Цәлбәкне тақ сандагы йомырткага басып пешерәләр:**
**өц йомортқадан цәлбәк; биш йомортқадан цәлбәк;**
**йете йомортқадан цәлбәк; туқыс йомортқадан цәлбәк.**

— Цәлбәкне өц йомортқаға басып, өцкә кисеп пешерәтеләр.

Цәлбәкне күп пешергәле йарамый. Өц кенә йомортқа белән пешерәләр. wақ-wақ кисеп кенә пешерәләр. Қалық күберәк булса биш йомортқа, әзрәк булса өц йомортқа да йитә — *төм*.

[1] *Тәмләмәйтеләр* — кабып карамыйлар.
[2] *Бойоролаты* — тиеш дип кабул ителә, кушыла.
[3] *Йуwан* — зур.
[4] *Май қасан* — май кайнату казаны.
[5] *Ацу сөт* — ачыган сөт.
[6] *Аш қабаты* — аш яны.

### Цәлбәк — ашап петерерлек булсын

— Чәлбәк аш дигәннәр. Үлгән кеше өчен пешерәтеләр. Йоқақ[1] қына пулаты. Аны ашап петерү кирәк. Тақ йомыртқаға пешерәтләр, йә йетегә, йә туқысға. Ашап петерерлек пулсын — *төм*.

### Йепес цәлбәк

**Цәлбәк — йете күс,**
**цәлбәк — туғыс күс булаты.**

— Йепсес цәлбәк тип әйтептеләр, шалай йепсес пешергәле кәрәк. Цәлбәкне йәйгәннәр, кискеләгәннәр.

— Цәлбәк аш тип йете күс, туғыс күс цәлбәк пешерәтеләр. Йете йә туғыс йомортқадан басатылар — *төм*.

### Цәлбәк — карт кеше үлсә генә пешерелә

— Қарт қортқайақлар үлсә, чәлбәк пешергәле. Йәшләргә пешермәйтеләр. Қырығына, йөсенә, йылына қарт кешегә чәлбәк булған. Инәм бағыр пешергән оллы қасанта.

### Цәлбәгеңә йарасын

— Берәр нимә ошамаса әйтәтләр:

«Цәлбәгеңә йарасын,
атаwыңа йарасын,
тамағыңа торсон».

**Цәлбәккә төртек төртәләр** (теге дөньядагы кешегә яктылык кер---сен)

— Цәлбәкне үлгән гешегә генә пешерәбес. Борнағы[2] йоға ғына қылып, оллы қасанныңы төбенә йәйеп пешерәтеләр, қасан төбен майлап.

[1] *Йоқақ* — юка.
[2] *Борнағы* — әвәле, элек.

### Цәлбәккә төртек төртеп пешерәтеләр

**Өценә — өц рәт,**
**йетесенә — йете рәт,**
**қырығына — қырық рәт,**
**йөсенә — йөс рәт** төртек йасайтылар.

— Пеләмсен цәлбәкне? Йоға ғына йәйә теләр, қаплап пешереп уты---ратылар, өйөп-өйөп әйләндереп. Йомошақ қына булаты, йабышмайты.

Қырығы буламы — қырық төртек, йөсе буламы — йөс төртек төртәделәр цәлбәккә. Әрғайсына өләшеп бирәтеләр цәлбәкне йыртып---йыртып. Күмәк йөрителәр пала-пақралар[1], пицәләр[2] — *төм.*

### Қоймақ, кимак

**Кимак** *миш.д.* коймак:
— Эц кенендә *кимаклар* пешерәсен, таба исе цыгарасын, бер азбарга[3], ике азбарга илтәсен — *күрш.*

— Элгәре күмеп кат кач та таба исе чыгарып *кимак* пешергән, мулла абзины ашатып йибәргән — мәл.

— Мәйет ашына *кимак* пешерәләр.

«Тончыксаң йарар иде, *кимагыңны* ашар идем, йылы *кимагыңны* ашар идем», — дип әйтәләр кайсы кеше — *кузн.*

### Үле кимагы

**Үле кимагы** *чпр.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә тор---ган коймак.

— Үле кимагы бар әле бездә. Да, бездә кимак пешерәләр үле бар амына.

[1] *Пала-пақра* — бала-чага.
[2] *Пицә* — хатын.
[3] *Азбар* — хуҗалык.

Кимакны үле бар амына күп пешермиләр, ашап бетерерлек кенә булсын. Тарилкәдә артып калса, аны ашамилар. Имеш, үләсен. Да, актыктан калганны ашамилар. Ул кимакны коцокка цыгарып бирәләр. Үңгә нәстәне ашилар, ә кимакны — йук. Хазер дә шылай. Берәр кимак кына алып ашилар.

Үле бар амына кимак пешереп баралар иде. Оны булмый, кешедән бурычка алып булса да кимак пешерә иде. Кимакны бер тарилкә пешереп алып бара үле бар›амына.

Аләмәт инде ул, кимак пешерегә кирәк. Әби-бабадан калган.

### Алма кимак

**Алма кимак** *хвл*. үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә тор---ган вак коймаклар.

— *Алма кимак* пешерәләр, май эчендә шылай калкыта камырны, мәйет ашына пешерә, эчәр-чара[1] куйалар.

### Коймаҡ ҡойу

**Ҡоймаҡ ҡойу** *себ.*:

— *Ҡоймак* та ҡойолаты. «Йес чыҡсын», — дигән сүз булаты. Өстәлгә утысатылар.

«Әрwахлар, рухлар иснәгәле тейеш», —

диләр. Баwырсаҡ та пешерәләр, туғач[2], бурәкләр дә пешерәтләр.

— Мәйетне күмеп ҡырбаштан ҡайтып киләләр. Икеме-өчме *ҡоймаҡ ҡойоп* йес чығарып ҡуйатлар. Чәй эчә мулла.

— Пер таба *ҡоймаҡ ҡойапыс*. «Май-йес цыҡсын». Паwырсакның өстенә таратып цығабыс аны. Йомортҡа күп кәсер. Йомошаҡ наннар[3] салапыс — *туб*.

**Ҡоймаҡ ҡойу** *перм., себ.*:

— Мәйетне алып чығып китүгә мичкә йағып *ҡоймаҡ ҡойалар*, таба исе чыгаралар — *перм*.

— Мәйет җийып озатҡач мичкә утын тығып ҡуйалар да ҡоймаҡ, идән-сәкене жуып алғач та:

«Таба исе чыҡсын».

[1] *Эчәр-чара* — чәй янына куела торган тәм-томнар.
[2] *Туғач* — кабартма.
[3] *Нан* [< фарсы] — икмәк.

Мәйетне озатҡач уҡ ҡоймаҡ ҡойалар. Йыраҡтан килгәннәрне, үзенекеләрне сыйлап ҡайтаралар. Барысы да керәләр ҡоймаҡ ашамаға.

«Саwап булсын» — дип — перм.

— Ҡоймаҡ ҡойатылар гүр ашы тип. Үлгән көнне үк килгән кешеләр тәмләп цыккалы тейеш.

— Ҡырбаштан ҡайтып киләләр мәйетне күмеп. Ҡоймаҡ ҡойоп ҡуйатлар. Чәй эчә мулла — *туб*.

### Ҡоймаҡ пешерү

— Мәйетне алып чығып китteләр исә, сөсе ҡамырдан туҡып ҡына алалар да ҡоймаҡ пешерәләр бездә — *к.-уф*.

— Мәйетне алып сығып киткәч үк бездә *ҡоймаҡ пешерәләр*, туҡып ҡына алып ҡамырдан. Самаwыр ҡуйып торалар — *к.-уф*.

— Үлекне зиратка алып киткәндә коймак пешерәбез дә шәм җандырып озатып калабыз. Бөтен кеше дә коймакны кабып-кабып чыгып китә.

Башта өч коймак пешерә, аннан соң биш, аннан соң җиде, аннан соң туғызны пешерә коймак — *т.кам.-крш.*

**Ахирәт коймак**

**Ахирәт коймак** *перм.* кеше үлгән көнне һәм искә алу мәҗлесләренә пешерелгән коймак.

— **Ахирәт коймак** дип әйтәләр аны. Мәйетне алып чығып китәләр дә пичкә ут төртәләр ахирәт коймакка.

Әwәлдән калған, хәзер дә бар ул. Зираттан кайтканнар да, үдәгеләр дә аwыз итәләр бары да. Хуҗалар үзләре дә ашыйлар.

— Коймак койалар күб итеп. Ачыткан коймак була. Мәйетне алып чығып киткәч, озаткан кешеләр кергәнче коймакны койоп утырталар майлап. Әни коймакны табактағы майға салып кына алайы.

— Кырығына да коймак койалар, чәкчәк пешерәләр.
— Коймак ачытып коймак койалар:

«Мөрҗәләрдән исе чығып торсын,
ләхетенә барып җитсен исе» — *перм.*

**Хәйер коймағы**

**Хәйер коймағы** *крш.* искә алу мәҗлесе өчен пешерелә торган коймак.
— Мына атап саласын табаға коймак.

Бер тәңре, бер кодай өчен
Җир атасы, җир анасы,
Койаш атасы, койаш анасы.

Мына оло-карыға, атам-инәмә дип ул *коймакны* бер әбигә бирәсен. «Минем үле-теремне искә ал», — дип әйтеп — *нгб.-крш.*

**Куймак**

**Куймак** *т.я.-крш.* коймак, үлгән кешене искә алганда, «ис чыгар---ганда» пешерелә.
— Куймаклар пешереп сагынып алабыз. Куймак исе чыгаралар.

«Бакилләсен, тук булсын
Бакытлы килеп, бакытлы китсен,
Кыйын-азап бирмәсен,
Куркызмасын,
Саулык бирсен безгә дә.
Безнен кебек ул да тук булсын», —
дип сагынып ашибыз энде.

**Куймак пешерүче**

**Куймак пешерүче** *т.я.-крш.* мәет озатканда, искә алганда коймак пешерү өчен махсус билгеләнеп куелган кеше.
— Куймак пешерүчене кыркына да чакыралар.

**Кайнари, пәрәмәчә**

**Ӄайнари, пәрәмәчә** *әстр*. пәрәмәч, үлгән кешене искә алу мәҗ---лесенә пешерелә.

— Үлене сыйлап *ӄайнари* пешерәләр, *ӄайнари* ул пәрәмәчә инде. *Ӄайнари* дип урап, чорнап ӄуйабыз.

**Келчә**

**Келчә** *т.я.-крш*. күчтәнәч, икмәк.
— Мазар эстән кайтып керәләр дә:

«Менә, Микаил *келчә* биреп җибәрде сезгә», — ди. *Келчәсен* турам---турам биреп җериләр.

**Көлцә, көлчә**

**Көлцә** *себ*. көлчә.
— Өстәл түгә рәккә икмәк, көлцә, кәпкер саласың. Өстәлнең урта---сына утыстасың. Пөтөн нимәне таӄ ӄыласың үлеккә — *төм*.

**Көпшәк**

**Көпшәк** *күрш*. кабартма.
— *Көпшәкләрне* зиде зиргә цырнап бирәсең зидесендә, зидесен күтәргәндә бирәсең.

**Нан**

**Нан** [< фарс.] *себ*. икмәк.
— Йомошак *наннар* салапыс ӄатым ашӄа. «Йес цығарғалы».
— Өстәлгә ашлар утыстып ӄуйапыс ӄәбер ӄасап килүцеләргә, йомошаӄ наннар салабыс.

**Ӄоразыӄ**

**Ӄоразыӄ** *баст*. камыр ашлары.
— Җыйында алдан *ӄоразыӄ* ӄуйалар, ләwеш, ӄатлама, белен, чәй ӄуйалар, хатем уӄыйлар.

**Күптермә**

**Күптермә** *баст*. кабартма.
— Күптермә пешерәләр өчне йә бишне, җыйынға ӄоразыӄ ӄуйалар.

**Ӄатлама**

**Ӄатлама** *каз.ар.-крш*. кабартма; кечкенә ипи.
— Үле ашына чәй, җә камфит алып киләләр хәзер, йә аӄча алып бара. Ӄайсылары ӄатлама итеп алып килә. Ӄоймаӄтан ӄалынраӄ, ипидән жуӄараӄ була ӄатлама — *каз.ар.-мам*. (Җөри).

**Казан катламасы**

**Казан катламасы** *срг*. май эчендә пешерелгән кабартма.
— Ӄул белән кискән тоӄмач, ӄуй ите шулпасында, челдермә (кош теле), ӄазан ӄатламасы, уртасы тишкән була, май эчендә пешә пәрәмәчә, пилмәннәр дә пешә. Шәкәр белән кан аткан варинйә, курләк варинйәсе.

Кайгыларны бүлешеп килгән аwылдашлар барысы да килә кырыгына да, йылына да — *срг*.

## Җуқа

**Җуқа** *каз.ар.-дөб., т.я.-к.т.,* **җука** *чст.-крш.* камырдан юка итеп җәеп майда пешерелгән ашамлык.

[Җуқа — үлгән кешегә аш булып бара, имеш]:

— Мәйет ашына *җуқа* пешереп апкилә, үлгән кешегә бара, имеш, аш булып — *каз.ар.-дөб.*

— Мәйет өчен килгән аш саваплы ди, мәйет ашына күбрәк *җуқа* пешереп баралар, буш қул бармыйлар — *каз.ар.-дөб.*

[Җука — кырыкбер итеп пешерелә].

— Кырыкбер җука җәйәбез пуминкага, кырыкбер келчә җасыйбыз. Килгән кешеләргә табакка салып җибәрәбез — *чст.-крш.*

— Кырыкбер җука пешергәннәр, таба исе чыгарганнар. Җуканы шулай кискәннәр дә аның эстенә келчә куйганнар. Зур чара табақ белән аш, бутка табын уртасында. Каҗер инде күп нәстә куйалар — *чст.-крш.*

— Үле ашларына аш әзерләгәндә җуқа җәйәбез җуқа ғына иттереп.

Қамырлар басып җуқалар җәйдем
Җуқаларым җуқа булсын дип.
Бу ашларны ә зерләдем
Туғаннарның күңеле булсын дип — *каз.ар.-крш.*

[Җуқа — сыңарлаш пешерелә]:

— Җуқаны төчегә басып, май, сөт, йомырқа, суды салып, җуқа итеп җәйеп, табада пешереп алабыз. Қаймаққа бассаң да җарый. Қаз майы қушып бассаң бик җомошақ була. Җуқа — таба зурлығында була.

— Мәйет ашына сыңарлаш җасыйлар җуқаны. Аның өстенә қабартма өйеп чығара табынға — *т.я.-к.т.*

## Күзикмәк

[**Күзикмәк** — келәүле ипи *нгб.-крш.*]:

**Күзикмәк** *нгб.-крш.* искә алу мәҗлесендә иң кадерле аш булып исәпләнә; төче камырны юка итеп җәеп табада пешерелгән камыр ашы.

— *Күзикмәк* барыннан да алда тәберсен ителә, ин келәүле ипи диб әйткәннәр эбиләр.

## Коры күзей

**Қоры күзей** *каз.ар.-крш.* күзикмәк.

— Қоры күзей дип пешерәбез үле ашына.

Тақ санда пешерергә кирәк, дигәннәр.

## Җәүликмәк

[**Җәүликмәк** — мәет ашы итеп пешерелә, мәҗлестән киткәндә һәркемгә өлешләп биреп җибәрәләр]:

**Җәүликмәк** *каз.ар.-лш.* — төче камырдан табага салып пешерелгән камыр ашы. Борынгы төрки jag — май + икмәк, ягъни майлы икмәк.

— Мәйет ашына *җәүликмәкләр* пешереп киләләр. Бер табынчы була, ул кеше сайын өләшә алып килгән *җәүликмәкләрне*. Мәйет ашыннан буш китәргә тийеш түгел, ди.

## Сөртмәч

**Сөртмәч** < сөртмә аш. Бу ашамлык турында мәгълүматлар себернең том диалекты калмак сөйләшеннән язып алынды (Кемерово өлкәсе). Сөртмәчне элек йомыркага җамыр басып, юка итеп җәеп, казанда майда пешергәннәр.

**Туғыз сөртмәч.** Гадә ттә аны тугызар-тугызар итеп, берсе өстенә берсен өеп, тугыз җиргә куя торган булганнар.

— Сөртмәч төгөрөк болғон, майда бешерәтләр. Сөртмәчне өчайақлы қазанда әйләндереп-әйләндереп бешергәннәр. Аны май---да бешерәләр, қамырын тоғомға (йомыркага) басалар да майда әйләндереп бешерәләр.

— **Сөртмәчне туғызны бешергәннәр.** Ник туғызны бешергәннәр? Белмим. Қоръән ашларына сөртмәч болот.

## Туғыз җиргә туғыз сөртмәч

— Сөртмәчне туғыз җиргә туғызарны бешереп қуйғаннар. Шул сөртмәчнең өстөнә самзалар бешереп өйгәннәр қоръән ашларында.

— Зур қазаннарда берәрне генә салып бешергән сөртмәчне. Аны түгәрәкләп йасаған җәйеп. Туғыз ыштук, туғыз урында. Тастырханға шулай матурлап қуйа сөртмәчләрне, баwырсақлар чәчә.

## Йопқа

**Йопқа** *тара*. юка; майда пешкән күзикмәк. Аны үле ашына қырықбер итеп санап, тишекләп пешерәләр.

— Йопқа пешерәтеләр қатым ашқа. Паwырсаққа басқан ши---келле қурны[1] басып , табақца[2] ман кисеп, йопқа пешерәтеләр. Аны қырықбер штук пешергәле кәр әк, парлы пешерү йарамайты. Паwырсаққа басқан қурны табақца ман кисеп, уртасын цәнцеп---цәнцеп қуйатылар.

[1] *Қур* — камыр.
[2] *Табақца* — чынаяк тәлинкәсе.

## Сумса

**Сумса** *бәр*. вак бөккән.
— Мәйет ашына бик күп әзерлиләр. Сумса пешерерләр ийе майға салып, андыра бәлешен салырлар ыйы — *бәр*.

## Табикмәк, тәбикмәк

**Табикмәк, тәбикмәк** < таба + икмәк — әче камырдан табага җәеп пешерелә торган, беленнән калынрак ашамлык.

Күмү һәм искә алу йолаларында *табикмәк, тәбикмәк* ашамлыгы Урта Урал (Свердловск өлк.), керәшен, мордва-каратай сөйләшләрендә телгә алына.
**Мәет күмгән көнне табикмәк пешерү** *к.-уф.*:

— Ә менә күрше аwылда *табикмәк* пешерәләр, мәйет чығып киттисә.
Усал кеше булса алай әйтә:
«Мин синең *табикмәгеңне* ашарға тийешмен,
син мийән алдарақ үләргә тийешсең», — дей.

**Мәйетне өйдән алып чыгып киткәндә тәбикмәк бирү** *крш.*:
— Үлгән кешене алып чығып киткәндә кем очырый, балалармы, оло кешеме, тегәрҗеп белән ақ йаулыққа ураган *тәбикмәк* бирәләр — *т.кам.-крш.*

**Табикмәк**

**Табикмәк** — керәшеннәрдә һәм мордва-каратайларда искә алу мәҗлесенә куела:

— *Табикмәк* саласың табага «үлеләр өчен ди-ди, туклыкта җөрегез, зыйан-заурәт җибәрмәгез» — ди-ди — *крш.*

— Эч *табикмәк* пешерә, аны кеше сайын кисеп қуйа wak-wak итеп — *м.-кар.*

**Табикмәк тураучы** *м.-кар.* үлене искә алу мәҗлесендә йола куш---канча итеп турый белүче кеше.

— Табикмәкне, витраҗны бер тураучы була. Бал сертеп шуны тури. Ашарга утыргынчы, чугынып, шуны тешлиләр.

— Табикмәк — икмәк камырыннан була. Эчне пешерә, икене тури, берсе кала.

**Тәйекмәк**

**Тәйекмәк** *минз.* — тәбикмәк; ул үлене искә алу мәҗлесенә пешерелә.

— Тәйекмәк пешерелә, аш, тоқмач пешерелә. Тәйекмәксез әйбәт булмый, тәйекмәк тейеш диләр инде. Кем күпме әзерли ала, әзерли тәйекмәк, ботқа. Мәйеткә, қоръән ашына ботқа, тәйекмәк тийеш.

**Пирук**

**Пирук** *чпр.* пирог. Аны үле ашына пешермиләр.
— «Пирук пешермәгез, үле күп була», — дигәннәр.

**Әпәй**

**Әпәй** *чпр.* ипи.
— Йомшак әпәй пешерәләр үле бар амына. Аны бөтөн мәзелескә кисәләр. Элекеләр түгәрәк әпәй пешергән.

**Бал**

«*Бал* — әҗәл ачысын бетерә», — дигән ышанулар нигезендә керәшен, м.-каратай сөйләшләрендә бал белән коймак, тәбикмәк куела. Әстерхан, себер диалектларында *әлбә, халба ком әлбә, комкабарлар* пешерү дә, ягъни баллы ашамлыклар пешерү дә шул борынгылыкларның чагылышы булып тора.
**Табикмәккә, коймакка бал ягып ашату.**
**Мордва-каратайлар искә алу мәҗлесендә табикмәккә бал сөртеп өләшәләр**:

— Үзене икмәге хуҗәйкәне, шул икмәг эстенә эч табикмәк куйа инде, шуны турап бал сертә дә кеше сайын эләшә. Шул бахытта үлдүкләр аши ди’ләр инде. Әҗәл ачысы бетсен эчен бал куйа, бал әҗәл ачысын бетерә, — ди.

— Эч табикмәк пешерә, аны вак-вак итеп кисеп куйа кеше сайын, бал белән сертеп эләшә’ләр пирбуй табикмәк. Эләшеп чыга аны эстәл җанында бер бабай ылатлап-ылатлап. Кечкенә-кечкенә генә турап ай---ырып чыгалар.
— Табикмәкне бер тураучы була, бал сертеп тури, ашарга утырган---чы чугынып шуны тешли. Эч табикмәк була, икене тури, берсе кала.

— Гүр казучыларга шулба пешерә, эшти, бутка пешерә, кесәл куйа, ин актыктан **бал куйалар**. «**Бал әҗәл** ачысын бетерә», — ди.

### Коймакка бал йағып қабу

— Искә алғанда пуминкыларда қоймак белән бал. Қоймаққа бал йағып қабалар. Қалақ белән алып, балны қоймаққа йағып қабасың, аннан соң инде төрлесен ашыйлар. Бал — әҗәл ачысын бетерә диләр — *т.кам.-крш.*

### Тәбикмәккә бал йағып қабу

— Түгем ашында иң элек тәби *кмәкк ә бал йагып* қабалар, шулай тийеш. Қырық күмәчен дә қайсы кеше бал йағып қаба. Саwаплы, диләр — *т.кам.-крш.*

### Ипи белән, бал белән тәберсен итү

— Ин алдан ипи белән бал қуйалар. Үлене искә алып ипи белән бал қабасын, тәберсен итәсен.

Қодай үзе дә терелеп торғач ипи белән бал ашаған. Шуның өчен башта ипи белән, бал белән искә алалар үлгән кешене.
Әйтәсен инде:

> «Менә фәлән кешене искә алабыз,
> җаннары қотылсын,
> Булған җазықларын қодай кичерсен» — каз.ар.-крш.

### Саwым

**Саwым** *т. я., төм.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә китерелгән ашамлыклар, алар так санда булырга тиеш.

— Тирә-күрше, хәрендәше китерә саw ымны. Аш қуйа, итен, аннан сун саwымны китерә башлый. Әwәле өч күмәч ийе, хәзер биш күмәч қуйа саwымға. Жуқа пешереп қуйа, жуқаны җидене, туғызны қуйа, сыңарлаш була. Жуқаны алтыға, дүрткә кисә, өлеш чығара — *т.я.-трх.*

— Әwәле саwымға доға қылалар. Мәйет ашына саwымға өч төрле әйбер кирәк: биш күмәч, қаз, таwық алып баралар, мәйет ашына жуқа да пешереп килә, сыңарлаш итеп җаси жуқаны — *т.я.-трх.*

— Җыл ашына да зурлап, саwым белән килә, аш белән. Атап суйа хуҗа үзе нәрсә булса да, сарықмы. Элгәре қабартма-жука йы.

— Үлек ашы иттереп **саwым** алып киләләр инде. Зур табаққа салып, җаймә белән түнәп күтәреп илтәләр саwымны, үлек ашын зурлап.

— Саwым сайын өч төрле әйбер була. Саwымга өч **күмәч**, өч йә **җиде жуқа,** йә җиде җақмыш, таwық, йә қаз пешерәбез. Унар саwым була қайсы кешедә. Һәр саwымға доға уқыйлар — *т.я.-к.т.*

### Үле саwымы

**Үле саwымы — сыңарлаш** була.
— Үлек өстенә саwым алып киләләр. Үле саwымы дип сыңарлаш була ул: өч, биш, җиде йә туғыз булсын. Саwымны үз йақыннары ғына алып килә. Менә мин өч паштит салдым, җиде йуқа, бер таwық алып килдем — *т.я.-к.т.*

Өч, йә биш күмәч алып килә саwымга — т.я.-к.т.

— Саwымны туғаннары, күршеләре алып килә. Саwымда өч төрле әйбер була иде. Әwәле жуқа пешерәләр ийе, чәйен, жуwачасын қуйадырыйы инде. Инде өчтән артық иттерсә, биш иттерергә кирәк. Сыңғарлаш иттерергә кирәк инде аны. Парлы булырға тийеш түгел. Туйға барғанда ғына парлы иттереп алып баралар бөтен нәстәне.

### Саwым аш

**Саwым аш** *төм.* искә алу мәҗлесе өчен әзерләнгән ашамлыклар. Алар так санда булырга тиеш.

— Йепсес пулғалы тиләр саwым ашын. Цәлбәк, цәй, тукац пешерәтеләр.

### Саwым тураучы

— **Саwым тураучы** була. Ул кешеләр алып килгән саwым ашларын өлешләп-өлешләп турый бер зур табакқа. Аңа әйтеп қуйған була.

Саwым тураучы жуқаны өлгеләп-өлгеләп кисеп турый. Жуқа ул таба зурлыгы була — *т.я.-к.т.*

### Саwым өләшүче

— **Саwым өләшүче** була. Саwым өләшүче саwым ашларын килгән кешеләрнең табағы сайын өлешләп- өлешләп салып чыға. Қырық-илле кеше булса да өлеш чыға барысына да.

Саwым китергән кешенең үзенә дә өлеш сала — *т.я.-к.т.*

### Саwым күчтәнәче

— **Саw ымны** үзебез табакқа салған өлешне өйгә алып қайтабыз. Малайлар қаршы жүгереп килә бит аштан қайтқан чағында, күчтәнәч итеп аларға ашатабыз саwымны. «Саwаплы» диләр.

«Саwым күчтәнәче ашағыз,
бәхетле булырсыз,
озын ғомерле булырсыз», —

дип өләшәбез балаларға. Алар қаршы киләләр ийе чабышып — *т.я.-к.т.*

### Саwым садакасы

**Саw ым садақасы** — саwым ашлары чыккач өләшенә торган хәер---садака. — Саwым садақасын барыбыз да өләшәбез.

**Саwым** — қырығында һәм жыл ашында ғына була, өчесендә дә, җидесендә дә булмый. Тегеләрендә сәдәқә өләшеп кенә аш үткәрәләр — *т.я.-к.т.*

### Саwымға қоръән уқу

— Саwым чыққан сайын қоръән уқып доға қылабыз, әрwахларыбызға доға уқыйбыз — *т.я.-к.т.*

### Сарқыт

**Сарқыт** — себер диалектлары, әстерхан сөйләшләрендә хөрмәтле олы кешеләрдән, қартлар табынында калган ашамлыклар. Аларны серле, тылсымлы көчкә ия дип исәплиләр.

« Бабаңның сарқыты, эцеп қуйың цайын. Аның йәшен пирсен сиңа та», — тиделәр.
Муллаларның, қартларның сарқыты тип қуйатлар.

— Қартларның *сарқыты* дип қартлардан қалғанны бирә.
«Қартларның җәшен бирсен, саға да жуш булсын», — дип — *әстр.*

— Йәш кеше үлсә сарқыт бирмиләр, аны алмыйлар да. Қарт кеше йақшы йәшәп үлсә генә анарға сарқыт салалар.

«Аның жәшен бир», — дип.

Чара[1] ман зурларға тәмле тәғамнарны[2] салады, жәшләргә сарқыт бирәде.

«Ашаңыз безнең сарқытыбызды.
Мә, айнанай, минем жашымды бирсен,
Минем сарқытымны эч», — диде — *әстр.*

— Йақын кешегә туйға килә. «Сарқыт бир», — ди.
«Қартларның сарқыты», — ди.
«Қартларның жәшен бирсен, саға да жуш булсын», —

дип, туйдан қалған сарқытны табынға қуйаты, қартларның сарқыты дип қартлардан қалғанны бирә — *әстр.*

## Тибәрлек

**Тибәрлек** *әстр.* коръән ашыннан, дини мәҗлестән калган ашам---лыклар. Алар изге саналалар, күчтәнәч итеп өйләренә алып китеп һәркемгә авыз иттерәләр.

— Менә мәүлет ашында тәстерханда қалған ашларны бары---быз да өйебезг ә алып қайтып балаларыбызға, киленнәребезгә, қардәшләребезгә аwыз иттерәбез, алар бисмиллаларын әйтеп ашый---лар, ул *тибәрлек* дип әйтелә.

[1] *Чара* — табак.
[2] *Тәғам* — ашамлык.

— Қартлар үлгәндә баwырсақ пешереп халwа қатыра да:
«Қарт кешенең тибәрлеге,
саға да йуш булсын», —
дип өләштерәде.

## Цәйнәмә

**Цәйнәмә** *төм.* ашамлык кисәге; картлардан, муллалардан калган кисәк изге, тылсымлы санала. к. сарқыт.

— Мулланың *цәйнәмәсен* пала-пакраға пирәтләр.

«Антай мулла пулайын, антай қарт пулайын. Талашып ашаң қартлардан қалғанны. Антай қарт пулырсыс», — тип. Алар сыптырып ашайты.

## Ботка, сетләш

Үлгән кешене күмгән көнне ботка пешерү керәшен сөйләшләреннән язып алынды.

— Үлене күмеп кайткач мунча йагалар, *бутка* пешерәләр, *бутка* ашарга утыралар — *т.я.-крш.*

— Таң атқанда *ботқа* пешерәләр, өстәл өстенә аның өчен (үлгән кеше өчен) дип бер қоштабақ, бер қашық қуйалар — *т.кам.-крш.*

## Бутка

**Бутка** *чпр.* ботка. Аны үлене искә алу мәҗлесенә пешермиләр, тиеш түгел, диләр.

— Үле бар амына бутка пешерегә йарами. Йармалы әйбер, пирук та йарамый.

«Үле күбәйә, арта», — дир, бутка пешерсә. Кимак пешерәләр үле бар амына, әпәй.

**Йөземле бутқа**

**Йөземле бутка** *т.кам.-крш.* искә алу мәҗлесенә пешерелә:

— *Йөземле бутка* суга гына пешә, сөт салмыйсың. Йөземле бутканы иң алдан бирәләр. Сөтле бутка айырым пешә — *т.кам.-крш.*

**Қунақ бутқасы**

**Қунақ бутқасы** *т.кам.-крш.* мәет күмгән көнне пешерелә торган ботка.

— Үлене күмеп қайтуға идәннәрне жуwалар, *бутқа* пешерәләр, бутқа ашарға утыралар.

«*Қунақ бутқасы*» диләр аны, «ул бутқаны ашап бетерегә», — диләр.

**Сетләш, сетләш-бутка**

**Сетләш** *срг.* сөтле ботка.

**Сетләш-бутка** *срг.* сөтле ботка. Искә алу мәҗлесенә сөтле ботка куелмый.

— Сетләш-бутка куймилар хатемдә.

«Сетләш-бутка куйырта», — дир. Сетләшне куймилар шуның өчен, йорттан үле кат-кат цыкмасын, куйырмасын, күбәймәсен.

**Сөткә пешкән бутка** *т.кам.-крш.*:

— *Сөткә пешкән бутка* да чыга пуминкыда, анысына иман җырлап келәү итәләр.

**Йомортқа**

**Йомортқа** *себ.* йомырка; май аенда үлгән кешеләрне искә алу көненә — цымга пешерелә.

— Майның туғысында цым тип *йомортқа* пешерәпес пыйас қабыкқа[1] буйап. Бер-беренә соношып[2] ашыйлар, аны үлекләрнең өстенә[3] арцып ташлыйлар қырбашқа[4] алып барып.

**Йомортқа буйау**

**Йомортқа буйау** *себ.* йомырка кызарту, пыйас (әд. суган) кабыгы---на буйыйлар.

[1] *Пыйас қабық* — йомырка кабыгы.
[2] *Соношып* — бирешеп.
[3] *Үлекләр өсте* — каберләр өсте.
[4] *Қырбаш* — зират.

— *Йомортқаны* пыйас қабықларга буйап балаларға бирәтләр, теләк-тәсбих қылдыратлар. Тәтәмә, цицәмә, өннәмә, әкәмә тип, уқытатлар.

**Йомортқаны тақ санда алып баралар:**

— Йомортқаны тақ қылып алып баратлар. Қалтаға[1] салып әпки---тәтләр йомортқаны. Пер йетешәрне, туғысарны тақ қылып аппаратлар.

**Йомортқа суғыштыру**

**Йомыртқа суғыштыру** *себ.* үлгән кешеләрне искә алу (цым) көнендә йомырка тәгәрәтеп уйнау.

— Үлән йәшәргәц цым тиделәр. Йомортқа буйап алып цыға, суғыштыралар йомортқаны.

**Җомортка**

**Җомортка** *м.кар.* йомырка.

**Җомортка калҗасы** *м.-кар*. йомырка тәбәсе.

— Таwычка[2] куйып җомортка калҗасы китерәләр үлдүкләр ашына.

**Изге су**

**Изге су, қач манған су** *крш*. — кач ману (< рус. крещение) көнендә алып кайтылган су. Аны керәшеннәр искә алу (пуминки) мәҗлесендә табынга куеп, барысы да «изге су» дип авыз итәләр.

**«Изге» су, кач манган суны йоту:** — Пуминкыда иң алдан *изге су, кач манган суны* йоталар, тәберсе итәләр ару кыз Марийаны олылап — *т.кам.-крш*.

**Шәрбәт**

**Шәрбәт** *себ*. ширбәт, баллы су.
**Шәрбәт су** *себ*. баллы су.

**Шәрбәт су куйу** *себ*. үлгән кешене искә алу, дини мәҗлестә баллы су кую.
— Катымга пирбай кергәндә *шәрбәт су* куйалар. Шуны аwыс итәләр.
«Үлеккә шунтай су насыйп итсен», — тип эцерәтләр.

[1] *Қалта* — янчык.
[2] *Таwыч* — тәлинкә.

**Кесәл**

**Кесәл** *крш*. крахмалдан, бал яки шикәр салып пешерелә, үлгән ке---шене искә алу мәҗлесендә иң ахырдан куела.

**Кесәл — үлеләр келәwенә куйыла:**

— Кесәлне үлеләр келәwенә өч җиргә қуйабыз, зур булмаған ташайақлар[1] белән, әркем сузылып алырлық итеп. Қалақлары белән алып қабалар.

*Кесәл* — иң ақтықтан куйыла. Шул өч ташайақның берсе булса да бушап қалырға тийеш диләр. Кесәл ашағачын да иман җырлап келәү итәләр.

**Кесәлгә келәү итү**

**Кесәлгә келәү итү** *т.кам.-крш*. кесәл ашар алдыннан дога уку.

— *Кесәлгә* келәү итеп иң арттан ғына кесәл қабалар. Өч төштә кесәл қуйалар.
«И қодай! Үзеңнең изгеләрең белән бергә урнаштыр», —
дигән сүзләр әйтелә.

«И қодай! Җирдәге дәүләтең белән безне
туйындырғаныңа сиңа тау итәбез[2]».

«И қодай! Күктәге дәүләтеңнән дә безне
буш қалдырма!»

Өстәлдән торгач шуны әйтәбез.

**Кесәлгә тәберсен итү**

— *Кесәлне* өстәлгә тәберсенгә куйалар. Әрбер кеше ул *кесәлне* ашый, аwыз итә, тәберсен итә — *т.кам.-крш.*

Алтыннан да артық син,
изге Мәрйәм анабыз,

Көмештән дә артық син,
изге Мәрйәм анабыз,
Очтомақ ийәсе син,
изге Мәрйәм анабыз,
Тәңре анасы син,
изге Мәрйәм анабыз — *т.кам.-крш.*

[1] *Ташайақ* — фарфор савыт, җамаяк.
[2] *Тау итәбез* — рәхмәт әйтәбез.

### Аш

**Аш** — гомумән ашамлык; мәҗлес.
**Қабер қасап килүцеләргә аш** *себ.*:

— Өстәлгә ашлар утыстып қуйапыс қәбер қасап килүцеләргә. Ибенә ақца өләшеп цығапыс, йомошақ наннар салапыс, паwырсақ пешергәле.

**Ашлар тақ булырға тиеш:**
— Өц төрле әйбер. Так кирәк: *аш, кәлwә, икмәк*. Цай булмаган.
«Йеп булмасын», — тип — *туб.*

### Күмеп кайтучыларга аш

— Күмеп кайтучыларга бичтә *ашлар* пешереп торам — *т.я.-крш.*
— Зираттан күмеп қайтучыларға аш пешерү бар:
«Теге дөнйада ач йөрмәсенгә», — *т.кам.-крш.*

### Аш бирү

**Аш бирү** *нгб.-крш.* үлгәннәр хөрмәтенә корбан чалу, мәҗлес үткәрү.

— *Аш бирү* болай була инде. Михайлов көнне, көҗминкә көнне бирәләр, атыйлар сыйыр, башын җыwалар. Менә йәш сыйырны атап суйам затыма-зәwеремә дип әйтеп. Ишегалдына зур қазан куйалар. Йарты йақны кисеп салалар қазанға, башын да, үпкә-баwырын да сала, үзенең хәрендәш-ыруларын җыйып чақыра.

— *Аш бирә* болай. Мал суйа, үгез булмасын, сыйырмы, танамы, өч җылға чақлы бирелә. Ул сыйырны инде атап суйалар. Абзардан апчыққанда сыйырның мөгезенә җеп белән бистәр бәйлиләр. Апчығалар да суйалар. Аш биргәндә малның сул йағын салалар. Ашны тышта пешерәләр, пешерүче үзенә беренче бүлә. Ирләр пешерә. Аш пешкәчен бер малайны ат атландырып чығаралар ашқа чақырырға. Табақ җасыйлар ыйы анда өч җиргә. Җан табағы дигәнен сыйыр суйған кешегә бирәләр.

### Аш илтү

**Аш илтү** *м.-кар.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә азыклар алып бару.

— Алда *аш итәләр* иде чугынырга: кайсы булка, кайсы җомортка калҗасы китерә тавычка куйып, алмалар, алма бавырлары[1], баланлар илтәләр, кем ни илтсә дә йари. Әле инде ипи генә илтәләр, түгәрәк ипи генә.

### Аш итү

**Аш итү** *каз.ар., крш.* дини мәҗлес үткәрү.
— Орқыйа аппайлар *аш итәләр* бүген, қоръән ашы — *каз.ар.-блт.*
— Үлгән кешене күмгәч аш итәләр ич инде, қан чығаралар, бәкәй суйалар. Җиделәрендә, қырығында итнең сөйәкләрен озаталар, чичта җиргә күмәләр — *каз.ар.-крш.*

**Аш йидерү**

**Аш йидерү** *себ.-бараба*. ашату, сыйлау.
— Төнәткәле[2] баралар қортқайақлар. Уғынып утыралар. Үwендә *аш йидергән* йоқ.
— Бер үwендә хатыннар болған, бер үwендә ирләр болған, чағырып-чағырып *аш йидергән*.

**Аш куйу**

**Аш қуйу** *әстр*. кеше үлгәндә аш-су белән сыйлау.
— *Аш қуймаса*, үлгәндә хөрмәтләмәде диләр, көзәтеп торалар.

**Аш сөрөп килү**

**Аш сөрөп килү** *әстр*. үлгән кешенең бер елын искә алу мәҗлесенә ашамлыклар һәм акча китерү.

— Йыл коранына инде үлегә *аш сөрөп килү* диләр, берәү дөгесе белән чәйен китерә, берәү куй бирә, берәү акчалата бирә. Мин шул кешеләргә аклык әзерләргә тийешмен.

[1] *Алма баwырлары* — алма компоты.
[2] *Төнәткәле* — үлгән кеше янында утырып төн уздырырга.

**Аш-йес чыгару**

**Аш-йес чығару** *туб*. аш исе чыгару.
— Қатымда иң беренче *аш-йес чығара*, баwырсақ пешерә.

**Ашқа тау итү**

**Ашқа тау итү** *т.кам.-крш*. түгемдә, мәет ашында рәхмәт әйтү.
— И аллабыз!

Җирдәге дәүләтең белән безне туйдырғаныңа сиңа *тау итәбез*. Күктәге дәүләтеңнән дә безне буш қалдырма!
Өстәлдән торгач шуны әйтәбез.

**Атау ашы**

**Атау ашы** *хвл*. үлгән кешене искә алу өчен уздырыла торган дини мәҗлес.

— *Атау ашы* дип хатем укилар, атау ашына буш бармыйлар, чәй дә шикәр илтәләр түвенчек белән.

**Бөтен аш**

**Бөтен аш** *т.я.-к.т*. үлгән кешене искә алу мәҗлесенә алып бары---ла торган ашамлыклар. Ул өч төрле ашамлыктан тора: кумәч, юка, тавык.
— *Бөтен аш* дип қызыл ашаулыққа төйнәп алып барырлар ыйы.

**Гүр ашы**

**Гүр ашы** *туб*. кеше үлгән көнне пешерелә торган коймак.
— Гүр ашы тип қоймақ қойоп утысатылар, қортқайақлар цай эцәтеләр, мәйетне күмеп килүцеләр тә тәмләйтеләр.

**Дини аш**

Өчесен, җидесен, кырығын, илле бер көнен, җылын үткәрәләр. Остабикәләр башҡара дини ашларны — *минз*.

### Йыл ашы

**Йыл ашы** *себ.* бер ел үткәч үткәрелә торган искә алу мәҗлесе; ел саен үлеләр рухына багышлап үткәрелә торган мәҗлес.

— Йылына аш үткәрә. *Йыл ашын* йыл да сайын үткәреп тораты.

### Ҡатым аш

**Ҡатым аш** *себ.* — дини мәҗлес, үлгән кешене искә алу мәҗлесе, хатем аш. Ҡатым < гар. хатем.

— Үлекне искә алып өцесенә бер аш, йетесенә бер аш, қырығына, йөсенә, йылына аш үткәрәсең. *Ҡатым аш* үткәрә. Йыл ашын йыл да сайын үткәреп тораты. Бер йылға бер искә алғалы кәрәк.

Йатҡан туфраҡлары йомошаҡ булсын,
Қараңгы гүрләре йарыҡ булсын,
Чаннары очмаҡта булсын,
Очмаҡ ишекләре ачыҡ булсын,
Очмаҡ йемешләре белән туҡланғалы йассын,
Песнең теләгән теләкләребес үлекләребескә ахирәт ашлары, Ахирәт йемешләре булып барып йетсен.

### Ҡатым ашны тәм итү

**Ҡатым ашны тәм итү** *себ.* хатем ашын кабып, тәмләп карау.

— *Ҡатым аш* тип төмән-төрлөтән тәм итеп цығатылар.

**Ҡатым аштан соң туwа (дога) қылу:**

Киң ыризыҡлар, киң тәүләт бир,
Килер йулларын киң кыл ,
Чығар йулларын қылдин қыл,
Алла тәғалә ошу биргән ыризыҡларны
Тән-саулыҡ-сәламәтлек белән
Ашап-эчеп йәшәгәле насиб әйлә, йарабби. — *бараба*.

### Ҡатым ашын өстәп салмыйлар

— Ашны өстәмиләр. Аш эчеп алалар табаҡлар ман. Ашны өстәмисең қатым ашқа. Өстәлгә тезеп йабып қуйасың. Муллаға питйаулыҡ[1] саласың да ул уҡый. Иң элек өй ийәсеннән уҡый, туған-тумачалары, қысы, малайына уҡый.

[1] *Питйаулыҡ* — сөлге.

— Ҡатым ашын өстәп салу йарамыйты. Қалған ашны қорткайаҡлар[1], йәтим-йесерләргә[2] өләшәсең.

— Өстәлгә ашны өстәп салғалы йарамайты. Ырисығыңны туты---рып қуй өстәлгә, өстәп салма — *себ*.

### Ҡатым ашта қәйер салғалы

— Катым ашта катым уғытҡанда қәйер салғалы кирәк. Қәйер салмасаң әрwахқа қоры қуғыс табаҡ қына бара дип әйткәннәр — *туб*.

### Қатым ашын тақ қуйалар

— Ашны тақ қуйалар. Аш, кәлwә, икмәк. Йеп булмасын, тақ кирәк ти. Цәй булмаган, йеп булмасын тип.

— Өстәл түгәрәккә икмәк, көлцә, кәпкер саласың, өстәлнең урта---сына утызтасың. Пөтен нимәне тақ кыласың үлеккә — *туб*.

### Өч тақ, биш тақ... аш

**Өч тақ,**
**биш тақ,**
**унтугыс тақ,**
**қырықбер тақ** қылатлар үле ашын.

### Йегерме бер күс, қырықбер күс кәпкер

**Күс** — түгәр әк формадагы камыр ашы.
Йегерме бер күс,
утыс бер күс, йә қырық бер *кус* кәпкер пешерәте үле ашы тип — *себ*.

[1] *Қортқайақлар* — карчыклар.
[2] *Йәтим-йесерләр* — ятимнәр.

### Қоры аш

**Коры аш** *срг*. камыр ашлары.
— *Коры ашлардан* зиде төрле аш була зиде кицәсендә: цәй, пилминчә, катлама, белен, кимак, цөце катлама, катык.

### Қоръән ашы

**Қоръән ашы** — дини мәҗлес.
**Қорән ашына** зур табада бәлеш пешерәбез, қашық белән саwытларга бүлеп-бүлеп бирәләр — *каз.ар*.

### Қунақ ашы

**Қунақ ашы** *т.кам.-крш*. кеше үлгән көнне пешерелә торган әлбә, хәлвә.

— Бал, май, онны болғатып пешерә дә, *қунақ ашы* дип кеше сайын шуны қаптырып чыға. Йөз кеше булса, йөз кешегә дә қаптыра. *Қунақ ашы* диләр аны.

— Кәлбә диләр, кажни кешегә өләшеп йөриләр. Үзең дә алып қабасың. «Өлешле булсыннар», дип. Җәнә шул *кәлбәне өләшә* икән үлеләргә, култық астына қуйалар үленең.

— Қунақ ашы дип бер ақ җаулыққа төйнәп кәлбәне үленең гыру---бына қуйалар. Тегендә барғач үлеләрне сыйлый ди.

### Мәйет ашы

**Мәйет ашы** *каз.ар.-лш., хвл.* үлгән кешене искә алу мәҗлесе.

— *Мәйет ашына* барғач, өстәлдә хуҗа әзерләгән табынға доға қылалар да алып килгән җәүликмәк, күмәчләрне чығаралар. Һәркайсына айырым-айырым доға қылалар, мәйеткә барып җитә ди. Бер табынчы була, ул кеше сайын өләшә алып килгән җәүликмәкләрне, қош телләрен — *каз.ар.-лш*.

— Җәүликмәк, кош теле, күмәч-әхрәт алып барабыз. Хәзер аш алып барулар дәү жуғ инде, қоймақ қойоп алып баралар. Мәйет ашын---да алып килгән ризықларны иң соңыннан чығарып утырталар, доға қылалар. Берәр кисәк өлешен бирәләр җәүликмәген-әхрәтен. Бер табынчы була инде, ул өләшә, қайтқанда буш китми, тийеш түгел диләр — *каз.ар.-лш*.

— Мәйет ашына пешеренеп алып киләләр, қоръән табыны була. Пешкән әйбер, табын әйберләре қуйалар, әрwахлар шатлана.

**Мәйет ашы** *к.уф.*:

— Мәйет ашына бәлеш пешерәң, үрә пешерәң, кампут йасыйсың, сарық суйаң.

*Үрәгә тоқмас* кисеп салаң, *макарун йарамый* үрәгә. Нақыс қына кәрәк мәйет ашына.

Менә макарун салған икә, төшөнә шул уқ көнне кергән.

— Мәйет ашына *ашны төрләндермәң*, диделәр. Ничек әзерли алаң, шулай ғына булсын. Кеше чақырам дигәч төрләндерәбез шул.

**Ырым** *хвл.*:

— Мәйет ашына пешкән ашны үгә биреп җибәрә, *ишсез* куйа. Мә выт сиңа, *өчне, бишне, җиде* кисәккә тәке куйа, *ишсез* куйа. «Мәҗлескә пешкән ашым ди, алыгыз», — ди. Түвенчек белән үгә алып китә. Эстәленә куйасың, мәйет ашы дийәсең, җомаг ашы дийәсең. «Тәңре кунагы син», — дип кергән кешегә бирәсең, урамнан узган кешегә бирәсен — *хвл*.

**Күмеп килгән көнне мәет ашы:**

— Аш, кәлвә, икмәк куйалар, тақ кирәк, өц төрле әйбер, цай булма---ган, йеп булмасын тип — *себ*.

— Үлене алып чыккинча эстәл эсте тулук була. Күмеп кайтучы---ларга бичтә ашлар пешереп торам — *т.я.-крш*.

### Оло аш

**Оло аш итү** *крш*. бер ел тулгач үлгән кешене искә алу.

— *Оло аш* итәләр бер җыл ту(л)гачын. Кан чыгарып тәберсен итәләр. Калган сөйәкләрне чиләккә тутырып зиратка итәләр — *т.кам.-крш*.

### Очмағ аш

**Очмағ аш** *себ*. оҗмах ашы.

— Май-әлwәне *очмағ аш* тип пешерәбес, қырбаштан мәйетне осатып килгәннәргә май-әлwәне қылабыс.

### Питай аш

**Питай аш** *себ*. бодай, бөртекле ашлык.

— Аш пирәтләр гүр сәтәқәсе итеп. Электә *питай аш* пулған, муллаға пирәтләр.

### Саwым аш

**Саwым аш** *т.я., себ*. искә алу мәҗлесенә әзерләнә торган ашамлы---клар.

— *Саwым ашлары* йепсес булғалы тейеш. Цәлбәк пешерәтеләр, цәй алып киләтеләр — *төм*.

— Цәлбәк, кампит әпкерәтләр саwым аш тип. **Парсыс** утырғалы тейеш ырисық, **йепсес** пулғалы тейеш саwым аш — *төм*.

### Түгем ашы

**Түгем ашы** *крш.* искә алу мәҗлесенә әзерләнгән ашамлыклар.

— Қайда үлгән, шунда урын көйләп, табақ қуйып, *түгем ашларын* саласың, таба исен чығарғанны саласың. Аны ашаулығы белән бергә бер йәтим қарчыққа бирәсең.

## Урташ

**Урташ** < урта аш *лмб.* үлгән кешене алты айдан соң искә алып үткәрелә торган дини мәҗлес.
— Кан амның *урташын* үткәрдем.

## Чәлбәк аш

**Чәлбәк аш** *себ.* кош теле кебек пешерелә торган ашамлык, аны бары тик мәет ашына гына пешерәләр.

— *Чәлбәк аш* тигәннәр. Үлгән кеше өчен пешерәтләр. Йоқақ қына пулаты. Аны ашап петерү кирәк. Өстәлгә салатлар. Тақ йомырқаға пешерәтләр, йә йетегә, йә туқызға. Ашап петерерлек булсын.

## Үлдүкләр ашы

**Үлдүкләр ашы** *м.-кар.* үлгән кешеләр өчен дип тәре алдына куел---ган ризыклар.

— *Үлдүкләр* эчен дип түргә ыстакан белән су куйалар, ипи куйалар, кашык куйалар, тәре алдында тора. Аны эчкен ашында куйа’лар да тугыз кенендә ала’лар, бүтәнне куйа. Алты атнасына хәтле куйып тора, анан сун ул ипиләрне очар кошларга бирә’ләр.

## Үле ашы

**Үле ашы** *каз.ар.-дөб., чпр., крш., себ.* — үлгән кешене искә алу мәҗлесе, дини мәҗлес.

— Үле ашына **ләкшә**[1] пешерәбез, **бутка пешермибез**.
Сөтне эретеп **эремчек кәлҗемәсе**[2] пешерәбез.
**Кыстырымби**[3] пешерәбез алма[4] төйеп.
**Кәкәш** пешерәбез алма белән.

**Тура**[5] пешерәбез эремчектән. Эремчеккә йомырка сала, он сала да баса, пичтә пешерә — *чпр.*
**Үле ашына аш белән киләләр** *каз.ар.-дөб.:*
— Күрше-күлән, туған-тумача аш белән киләләр *үле ашына*. Буш бармыйбыз беребез дә. Жуқа, қош теле алып барабыз — *каз.ар.-дөб.*

**Үле ашына дуңгыз ите куймыйлар** *т.кам.-крш.:*
— Ару әйбер кирәк *үле ашына*, қанатлы қош кирәк, дуңғыз җарамый үле ашына — *т.кам.-крш.*

**Үле ашына арақы қуймыйлар** *крш.:*
— Үле ашына беркайчан арақы қуймыйлар бездә. Қабер қазыған кешеләргә дә бирмәскә диләр дә бик суықта бирә инде қайсы кеше, балчық эше, аwыр эш дип.

**Керәшен уразасында үле ашы** *крш.:*

[1] *Ләкшә* — токмач.
[2] *Эремчек кәлҗем әсе* — эремчек бөккәне.
[3] *Кыстырымби* — кыстыбый.
[4] *Алма* — бәрәңге.
[5] *Тура* — эремчекле күмәч (сырник).

— Уразада үле ашына қан чығару булмый, уразача әзерлисең инде. Ураза булғанда ит-май, күкәйләр, сөтләр булмый. Сыйық май белән генә әзерлиләр — *каз.ар.-крш.*

**Үле ашы, үлек ашы**

**Үле ашы, үлек ашы** *себ.* үлгән кешене искә алу мәҗлесенә пешерелә торган ашамлыклар; дини мәҗлес.

**Үле ашын так кылалар** *себ.:*

— Үле ашын тақ қыласың. Кәпкер, цәлбәк тақ булаты — *төм.*

— Үлекнең үсе әйтеп қуйған әйберләрен пешерәсең үлек ашқа.

«Миңа шал ашны пешерең, шал ашны йаратам», — тип әйтеп қуйған мин.

«Мин үлсәм, миңа шал ашны пешерең, туқац, қоштел пешерең»,— тип әйтеп қуйған мин — *тара*.

**Үлек аш**

**Үлек аш** *глз.* үлгән кешене искә алу мәҗлесе.

— Кабарчысын да, тәбиген дә бешерәсе була үлек ашка.

— Wак тәбик түгәләр пич алдында таба белән.

— Коймак пешерәләр май эчендә, андай әйбер.

— Бөккән пешергәлиләр. Кайсы шоморт белән, кайсы геби (гөмбә) белән.

— Йералма шанги, курайләк шанги пешерәләр — Гүрйә — кала.

**Үс ашы**

**Үс ашы** *себ.* — үлгән кешене искә алу мәҗлесенә генә пешерелә торган ашлар.

— Мәйетнең *үс ашы* пулаты кәпкер, цәлбәк, ул *үле ашы*, үс ашы тиләр.

**Җомақ ашы**

**Җомаг ашы** *хвл.* искә алу мәҗлесенә генә пешерелә торган ашам---лыклар.

— Мәйет ашын түвенчек белән биреп җибәрә: «Җомаг ашы», — ди. Ишсез бирә, өчне, бишне.

**Җыл ашы**

**Җыл ашы** *әстр.*, **җыллык аш** *крш.* — үлгән кешене бер елдан соң искә алу мәҗлесе.

— *Җыл ашына* қуй суйады, хәле тартса қара мал суйады — *әстр.*

— Үлгән малайының *җыллық ашына* сарық суйған.

**Йамбаш ашау**

**Йамбаш** *нгб.-крш.* суелган малның янбаш өлеше, итле җире.

**Йамбаш ашау** *нгб.-крш.* — искә алу көннәре мәҗлесе.

— Икенче көнне *йамбаш ашарга* барасын. Аны пирwуй көнне пешерәләр, икенче көнне җылытасын, ашисын, тийәберсен итә сен. Икенче кеше чакыра. Аннан чыккач өченче өйгә барасын, анда үле җыруwы җырлыйбыз. Кодагый, башлый беләсенме, башла, без катышырбыз.

Бийекәй тауның башларында
Сарыдан сары чәчәк бәйләме.
Без ашыйық, җырлашыйық,
Туғаннарның қалдық бәйрәме — *нгб.-крш.*

## Он

Мәет озаткан көнне аның яткан урынына он куялар:
**Кәнди белән он** *минз.*,
**Қоштабақ белән он** *минз.*:

— Мәйет йатқан урынға бер бәләкәйрәк кәнди белән он кертеп куйалар.

«Мәйет ыризығын қалдырып киткән булсын,
эрәнҗеп китмәсен», — дип.
Ул онны доға қылып, бер йәтим әбигә бирәләр.

— Өйдән мәйетне алып чығып китқәч, урынына он қуйу ыйы, бер қоштабақ он қуйу ыйы. Хәзер аны қуймыйлар инде.
**Бер тәлинкә он қуйу, умач уwып қуйу** *каз.ар.-крш.:*
— Менә Үрәчбашта кеше үлгәч бер тәлинкә он қуйалар да сыйық май белән шул оннан умач уwалар. Кечти җанчық тегәләр дә шул умачны салып, гырупқа үленең култық астына қуйалар:

«Анда барғач ашарға,
андағы үлеләргә өләшергә», — дип.

## Онаш

**Онаш** < он + аш *себ.* токмачлы аш.
— Қатым уқығаннан соң онаш, чәй эчкәндә әлбә утыртатлар.

## Ләкшә

**Ләкшә** *миш.д.* токмач.
— Үле бар амына үзе кисеп ләкшә пешергән, кимак та әпәй пешергән. Бутка, пирук пешерегә йарамый үле бар амына.

## Эшти

**Эшти** *кузн.* аш.
— Эшти ашата атауда. Эштине күтәрәләр, эстәлне seберәләр, чәй бирәләр. Бер корка эштине артык пешерәләр. «Тәңре кунагы өчен».

## Нәүмәт, тамақ

**Нәүмәт** [< гар.] ашамлык.
— Ызбадан үлене алып чыгып киткәч ул ызбада *нәүмәт* кабарга йарами. Өч кичендә генә йарый — *кузн.*
**Тамақ** *әстр.* — ашамлык.
— Үле-тереләргә өлеш —
дип *тамақ* илтәләр мичеткә.

## Ис чыгару

**Ис чығару** *әстр.* үлгән кеше рухына багышлап, нинди дә камыр ашын майда пешерү.
— Үлене алып чыққач, башлап баwырсақ пешерәләр, ис чығару дип. Мулла түбәдән қайтып кереп қорән укый.
**Ис чыгарып тору** *әстр.* һәр атнакич (пәнҗешәмбе) көн саен май белән нәрсәдер пешереп, үлгән кешене искә алып тору. Әстерхан сөйләшендә кече йома — пәнҗешәмбе көне.
— Җылына хәтле ис чыгарып торалар, кече җомасын уқытып. Кажни кече җома майға баwырсақ пешерә, ис чығаралар баwырсақ белән. Май исе чығара, пылау, затлар пешерә.

— **Кече йома** көнне әйтәм:

«Зөһрә, пешер бащырсақ, ис чығарчы,
Үле-тереләргә хәйер булсын», — дип.

Йақын-йущық балаларға өләшәм бащырсақ. Утыртып чәй эчертеп бащырсақ биреп җибәрәм. Анаусы анаудан, монаусы монаудан килеп кенә торалар балалар. Алар килсә йаратам.

## Май исе чыгару

**Май исе чыгару** *кузн.* май белән камыр ашлары пешереп, үлгән кешеләрне искә алу.

— Өч киченә чәре ашарга йарами үле чыккан үдә. Өч көнендә *май исе чыгарырга* кирәк, катлама пешерәләр, өстәлгә тоз куйалар.

**Май исе чығару** *әстр.*:

— Һәр кече йома көнне *май исе чығарасың*, уқыйсың қылыхуалланы. Мин мулладан сорадым мичеткә барып. Йарый, қабул була диде, искә алмый ғына қалма, диде.

Үлеләрнең рухлары килеп йөрә өй түгәрәгенә. Кечки җома сайын май ташлап ис чығара, бащырсақ пешерә.

«Майның исен чығарып йатыр,
Корәнемне уқытып йатыр», —

дип әйтәде үлекләр. «И безне искә алған икән бүген» дип әйтерләр ди.

«Үлек төшеңә иңсә — ис чығар,
Майның исен үлеләр җаратады».

«Килен, табаға май ташлап ис чығар» дип қулымдағы киленгә.

«Үле риза булса,
Тереләр байыр», — диде — *әстр.*

**Май исе чыгару** *глз.*:

— Җомга көн *май исе чыгарасы*, үлекләр сөйенеп китэр, ди.

— Йаңа йылда *май исе чыгарабыз*. Төнлә тороп тәбикмәк йасама йабыша:

«Май исе чықсын».

## Аш-йес, май-йес чығару, йес цығарғалы

**Аш-йес май-йес чығару** *төм.* — аш исе, май исе чыгару.

— Қатымда иң беренче *аш-йес чығару*, пәтер пешерәме, *май-йес чықсын*.

**Май-йес чығару** *себ.* үлгәннәр рухына багышлап нинди дә булса камыр ашларын майда пешерү.

— Өйтән үлек цығып китсә, табаға май салып, май эретеп, май-йес цығаратлар. Өйне тасартып йущып қуйатылар. Ул йақ өйгә, бу йақ өйгә май-йес цығаратылар.

Мәйетне алып цығып китте, пөтөн халық йуған өйгә кереп айланып цығып утырат — *төм.*

— Майға кәлщә пешерәтләр, қаныт салып *май-йес цығаратлар*.

— Қырбаштан күмеп килүцеләргә *май-йес* тип май-әлщә қылатлар — *себ.*

Мәйетне апчығып барғанда табаны қысдырабыс, май-йес чығарабыс.

— Үлек цығып киткенце майның йесен цығару гәрәк. Майның йе---сен цығармасаң, мәйет әйтәте:

«Ник минең артымнан май-йес цығарматығыс?»

Май-йес цығару гәрәк, әсерләп қуйалар табаға майын салып. Шалай — *туб.*

## Пәйшәмбе[1] көн май-йес цығару

— Пөтөн мәйетләребеснеке рухлары пәйшәмбе көнне ирт ә белән килеп, тирәсә бескә утырып қуйалар игән. Пес йес цығармый қалсақ, сатақа бирми қалсақ, алар йылап қайтып китәләр игән.

[1] *Пәйшәмбе* — пәнҗешәмбе.

Пәйшәмбе көн май-йес цығарабыс. Үлекләребесгә бағышлап Қоръән уғыту гәрәк.
Ә йома көн терекләргә теләү гәрәк:
«Исәнлек-саулықларына» — *туб*.

**Әрwахлар, рухлар иснәгәле тейеш:**

— Май-әлwәне «йес цығарғалы» тип пешерәбес.
«Әрwахлар, рухлар иснәгәле тейеш».

**Қоймақ қойып йес чығару, бурәк пешереп йес цығарғалы**

— Қоймақ та қойолаты.
«Йес чықсын», —
дигән сүз булаты.

— Пер таба қоймақ қойабыс.
*«Май-йес цықсын»*. Паwырсақның өстенә таратып цығабыс аны — *туб*.

— Қатым ашқа қоймақлар, бурәкләр[1] дә пешерәләр.
«Йес цығарғалы», — тиләр — *туб*.

**Таба исе чыгару**

**Таба исе чыгару** — майлы табада нинди дә булса камыр ашы пешерү, үлгән кешеләрне искә алу.

**Таба исе чыгару** *крш., урт.д., миш.д.* таба майлап нәрсә дә булса пешерү.

— Берсе әйтә төшемдә. Син бит бүген *таба исе чығармадың*, ди. Сикереп тордом да қамыр йасадым. Күкәй сытып тәҗел[2] генә қоймақ пешердем. Бу — түгем көне,пуминка көне булған, мин белми калдым, ул миңа төшемдә әйтте — *т.кам.-крш.*

— Кеше үлгәчен, җаны чыгу белән, *таба исе чығарып* қоймақ пешерәбез. Таба исен аның исеменә дип чыгарабыз — *каз.ар.-крш.*

[1] *Бурәк* — пирог.
[2] *Тәҗел* — тиз, ашыгыч.

— Тәбикмәк пешерәсен, *таба исен* чыгарасын йаңа йыл көнне — *нокр.*
— Элгәре күмеп кат кач та *таба исе* чыгарып кимак пешергән, мулла абзины ашатып йибәргән — *мәл.*

— Үлекне апчыкканда гына мичне тергезеп *таба исе* чыгаралар — *т.кам.-крш.*

— Эц кенендә кимаклар пешерәсен, *таба исе* цыгарасын, бер азбарга, ике азбарга илтәсен — *күрш.*

— Мәйет артыннан *таба исе* чығаралар, қоймақ пешерәләр.

— Мәйетне алып чығып китүгә мичкә йағып қоймақ қойалар, *таба ис* чығаралар — *к.-уф.*

— Кечәтнә көнне т*аба исе* чығармаға қушалар қый, қоймақ қойасың, шәңгә пешерәсең — *к.-уф.*

— Кечәтнә көнне *таба исе* чығармаға қушалар қый, қоймақ қойасың, шәңгә пешерәсең — *к.-уф.*

— *Таба исе* чығарабыз. Таба исе чығармасақ, фирештәләр килеп иснәр икән дә таба исе чықмаса, мәхрүм булып китәр икән дип әйтәләр ийе. Шулай таба исләре чығарабыз мөрҗәдән. Җомға көннәрне, ғайет көннәрне шулай чамалайбыз — *минз*.

### Кечатна (пәнҗешәмбе) көнне таба исе чыгару

— Кечатна көнне үлекләр қайта дип, кичтән үк ашаулық җәйеп қуйабыз, мендәр салабыз, ашамлықлар қуйабыз, тәйекмәк, қысты---быйлар пешереп таба исе чығарабыз:

«Утырыгыз, ашағыз».

Хәзер дә кечатна көнне мунча йағабыз, алар йуынырға киләләр, аш-чәй қуйабыз — *т.кам.-крш.*

**Табис < таба ис(е) чыгару:**

— Кыркысында шул *табисе чыгарып* атап бер мал суйа инде, анда бәрәнме, казмы — *каз.ар.-крш.*

— *Жыйында табис чыгарып* хатем укыта, белен белән *табис чыгара*, күптермә казанда пешерә. Өч көнендә дә, җиде көнендә дә тере җан суйып *табис чыгарып* хатем йаси (Рязань өлк. Тархан ав.).

**Үсемлек майы белән үлгән кешене искә алу** *т.кам.-крш.:*

— *Үсемлек майын тамызып* исемләп салабыз. Тамызып салып, қамыр басып пешереп, өләшеп ашыйбыз. Қамырдан күбрәк қоймақ, пирәмәчләр пешерәбез, күзикмәк, жуқа пешерәбез, иманнар белән тәберсе итәбез.

## «ТЕГЕ ДӨНЬЯ», ДИНИ МИФОЛОГИЯ

### Җәннәт

**Җәннә т** [< гар.] — оҗмах; дин буенча: үлгәч, тәкъва кешеләрнең җаны бик рәхәт, күңелле яши торган урын.

«Йатқан җирләре җәннәттә булсын,
рухлары шат булсын», —
дип телибез — *урт.д*.

**Җәннәт ишеге** *әстр.*:

— Қырық көнгә тийен бала тапқан қатынны урамға чығармаға йа---рамый, диде. Җәннәт ишеге ачық тора, диде. Ике дөнйа уртасында тора икән анасы да, баласы да — *әстр*.

**Җәннәт қапқасы**:

Миңа килгәндә әҗәл кастасы,
Ачык булса иде *җәннәт капкасы*.
(Мөнәҗәтләр, 46)

**Җәннәт нигъмәтләре**:

Ходайым сезне сыйласын
*Җ әннәт нигъмәтләре* белән.
(Мөнәҗәтләр, 49)

**Фирдәвес җәннәте** (Фирдәвес — бакча, оҗмах):

— Әйтик әле мөнәҗәтне
Барыбызда — дин хаҗәте
Бер ходайым бирсә идее
Фирдәвес дигән җәннәтне.

**Җәннәт хөлләләре** *әстр*. җәннәт киемнәре.

«Җәннәт *хөлләләрен* кийәргә нәсиб ит,
тәмуғ утын тигезмә», — дип дуwа кыла.

Ачкычыңны ача бир,
Рәхмәтеңне чәчә бир,
Өсләренә *хөллә* бир,
Башларына таҗ бир — *әстр*.

«Кыйссаи Йосыф»та **хөллә** сүзе:

Хөллә киде, тәғам йэди, шөкер қылди (76 б.).
[Хөллә киде, ашап-эчте, шөкер кылды.]

Йүзи балқыр игнендәге хөллә тундан, —
йэрдән күкгә нурдан дерәк улур имди (118 б.).

Өстендәге хөллә йөзен һәм балкытты, —
җирдән күккә нурдан терәк менәр имди.

*Хөллә туннар* кийәрләр,
Пырақларга менәрләр.
Хур кызларын кочарлар
Аллаһ дигән бәдәвам («Бәдәвам» китабы)

Урны ирде Фирдәвеснең түр башы,
Истибрактан ирде *хөлләсе* (Ш.Бабич).

**Сигез җәннәт**: — Сигез җәннәт ишекләре рамазан айында ачылыр...

## Оҗмах

Җирле сөйләшләрдә: **очмах, очтомақ, җомак, йомақ** вариантлары да кулланыла.

**Сигез оҗмах ачқычы**:

Лә илаһы иләллабыз
сигез оҗмах ачкычы...

**Сигез оҗмах суwы**:

— Кәфенне кигезгәч шулай әйтәбез:
И раббым солтаным,
Сән җараттың бу мәйетнең үзен,
Сигез оҗмах суwы белән
Җуwа күрегез йөзен — *минз*.

**Сигез оҗмах хакы** (теләк теләгәндә еш әйтеләә):

Сигез оҗмах хакы өчен килгел,
йә бәхет, йә дәүләт,
Мөэминнәр хакы өчен килгел,
йә бәхет, йә дәүләт.

**Уҗмах** сүзе XIII гасыр язма истәлеге «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (1983, 228).

Уҗмах ичендәдер, бәс, аның җани, —
бу дөнйадан интиқаль қыйлды имди.
Инде оҗмах түрендәдер аның җаны —
Бу дөньядан күптән күчеп китте имди.

## Очтомақ

**Очтомақ** *т.кам.-крш., каз.ар.-крш.* оҗмах.

Килепләр дә кердем өйемә
Кара бүрекәйләре лә чөйдә җуқ.

Безнең туғанайны сорасағыз
Очтомаққа киткән өйдә жук.

**Очтомак күлмәге**

**Очтомақ күлмәге** *к.-уф.* — оҗмах күлмәге, кәфенлек.
— *Очтомақ күлмәгенең* үңере (изүе) ачық була.

**Җомак**

**Җомаг ашы** *хвл.* искә алу мәҗлесенә пешерелгән ашамлыклар.

— Мәйет ашын түвенчек белән биреп җибәрә: «Җомаг ашы», — ди. Ишсез итеп бирә, өчне, бишне.

**Очмах, очмақ**

**Очмах** *себ.* оҗмах, җәннәт.
**Очмах ишеге** *бараба.*:

— Башым салдым йастыққа
Күңелем бирдем аллаға.
Алла, алла дигәндә
Очмах ишеге ачылсын,
Сөбханалла дигәндә,
Қараңғы гүрем йақтырсын.
Урны очмақта пулсын,
Тар қаберләре киң пулсын,
Қараңғы гүре йарық булсын,
Иманы йулташ пулсын —
тип туwа қылапыс.

**Очмах ишеге төбендә Ғерәйеш атлы йылан**

Корәйеш — Мөхәммәт пәйгамбәр туган ыруның исеме, дини мифологиягә дә шуңа бәйләнешле рәвештә кергән булырга тиеш.

**Бараба диалектында: Ғерәйеш йылан турында**

— Ул Ғерәйеш атлы йылан очмах ишеге төбендә торыр ди. Сез---не йотқалы торған йылан шушы дуwаны уқып қуйсағыз очмах ишекләрен ачып қуйар, ди. Сез иманлы бәндә булып очмахқа кереп китәрсез, дип безне өйрәтә иде күрше башлығым[1] менә бу дуwаны[2] үсмер чағымда:

Бисмиллаһиррахман иррахим,
Йаттым тыныч,
Йастығым — кирпеч,
Динем — ислам,
Теләгәнем — иман.
Ғерәйеш атлы йылан,
Ғерәйеш атлы йыланға бездән сәлам,
Тәмуғ уты бездин харам.

Ул дуwаны уқып йөрсәгез, үлеп wафат булсағыз, ул йылан очмах ишеге төбендә булыр, ди.

**Әстерхан сөйләшендә: Қырайыш атлы йылан**

— Үлене урап, табутына күтәреп салганда уқыйбыз:

[1] *Башлық* — карчык.
[2] *Дуwа* — дога.

Қырайыш атлы йылан,
Иман белән китәйем,
Ислам белән китәйем,
Йаратқаным йаппарым,
Күптер минем гөнаһым,
Гафу қылғыл илаһи
Өметем — җәннәт,
Түшәгем — туфрақ,
Йастығым — йафрақ,
Қырайыш атлы йыланга
Мәңгелек салаwат!

**Перм сөйләшендә: Қорәйеш атлы җылан**

— Қорәйеш атлы җыланға уқыйлар мәйетне алып чығып киткәч тә айағ очтан торып. Алып чыққан чақта әйтмәгә кәрәг инде аны, қапқадан чыққан чақта, ченазаны алып чыққанда.

Йылан килер аwызын ачып
Аwызыннан утлар чәчеп.
Рәсүлүллабыз булмаса
Котыла алмабыз качып.

— Қорәйеш дип уқыйлар мәйетне җыйып, алып чығып киткәндә. Қапқа төптә озатып қаласың. Қорәйеш дип қушып-қушып уқып қалалар.

— Әнә шул Қорәйеш атлы җылан ченазаны алып чыққанда җилкәсенә атланып қалыр ди җә ишегеннән чыққанда, җә қапқа---сыннан чыққанда атланып қалыр ди. Ишектән чыққан чақта атлан---маса, қапқасын чыққан чақта атланыр ди. Шул Қорәйеш атлы җылан тегендә, теге дөнҗада үзең белән бергә булыр ди — *перм*.

**Мөнәҗәтләрдә қорәйеш атлы җылан**
(Самара өлкәсе, Гали авылында)

Мәдинәдә Мәккәдә
Булыр бер көн қыйәмәт.
Илтеп гүргә қуйарлар
Миннән сөаль сорарлар.
Қорәйеш атлы йыланға
Сәлам биреп қуйарлар.

**Қорайыш атлы йыланга догаи сәлам**

Йаттым — тыныч,
Йастығым — кирпеч.
Динем — ислам,
Теләгәнем — иман.
Қорайыш атлы йыланга
Миннән догаи сәлам.

**Мөнәҗәтләрдә Корши атлы җылан**

Гөнаһларым кабул итеп

и Ходайым, үзең пакьлә,
Кори ш атлы җыланнан,
и Ходайым, үзең сакла (мөнәҗәт).

### Хур, хур кызы

**Хур** [< гар.] җәннәт кызы.

**Хур кызы** — ислам дине буенча җәннәткә кергән кешеләргә вәгъдә ителгән кыз.
**Җәннәт хуры** — җәннәттәге кыз.
Кунак өйе — җәннәт түре,
Түр қунақлар — җәннәт хуры.
Қыйәмәт көн насыйп булсын
Рәсүлуллабыз нуры — *каз.ар.*

### Пырак

**Пырак** [< фарс.] җәннәттә фантастик ат.

Ачқычыңны ача бир,
Рәхмәтеңне чәчә бир,
Өсләренә хөллә бир,
Башларына таҗ бир,
Сират күперен кичкәндә,
Атланырға *пырақ* бир — *әстр.*
— *Пырақларга* менәрлә р,
Хур қызларын қочарлар («Бәдавәм» китабы)
— Рәсулулла *пыраклары*
Көмештәндер тояклары.
Сират күперен үткәндә
Пырак атландырыр микән,
Фирдәwес җәннәтенә кертеп
Безне шатландырыр микән (мөнәҗәтләр).

### Тәразу

**Тәразу** [< фарс.] үлчәү, бизмән.
*Тәразуга* салғанда,
Ғамәлемне аwыр ит,
Гөнаһымны җиңел ит, дип
теләк телибез — *каз.ар.*
**Тәразу** — үлчәү («Кыйссаи Йосыф» 1983, 140):
Таҗир әйдүр: «Тәразуйә алтун қуйғыл,
бу уғланның ағырынчә алтун виргел.

Дәгыйр әйтте: «Үлчәвеңә алтын сал син,
Авырлыгы аның Йосыф кадәр булсын...

Тәразуйә тәлим алтун дәхи қуйди,
Тартдылар — Йусеф илә тиң кәлмәди (140 б.)

Үлчәүг ә ул тагын алтын өстәп куйды,
Алары да Йосыфтан күп җиңел булды.

### Зәмзәм

**Зәмзәм** [< гар.] Мәккә шәһәрендә «изге» коеның исеме.

Һаҗәр ана сәхрәләрдә
Ялгыз калган коры җирдә.
Сабырлыгы хөрмәтенә
*Зәмзәм* чыккан ди шул җирдә
(Мөнәҗәтләр, 153 б.)

### Кәүсәр

**Кәүсәр** [< гар.] дини караш буенча: оҗмах чишмәсе, оҗмахтагы бик татлы су.

Төшемдә оҗмах эчен күрдем. Бер тарафта балдан вә сөттән гыйбарәт *кәүсәр* елгасы агып ята (Г.Тукай).

**Кәүсәр шәрабы** — оҗмах чишмәсе суы.

Рәсүл кулында Кәүсәр шәрабы
Безгә эчерсен иде ул аны.

Рәсүлебезнең чыкмыйк юлыннан,
Кәүсәр шәрабын эчерер кулыннан.
(Мөнәҗәтләр, 468 б.)

Кыйәмәт көн насиб иткел,
Безгә *кәүсәр* шәрәбләрен
(Мөнәҗәтләр, 31 б.)
Сират күперен үткәчтен
Кәүсәр шәрабын эчәрмен...

### Қыйәмәт, қыйәмәт көне

**Қыйәмәт** [гар.], **қыйәмәт көне** — дини тәгълимат буенча: ахыр заман җитеп, Исрафил пәйгамбәр сур өргәннән соң, үлгән кешеләр барысы да терелгәч, аларга алла тарафыннан үткәрелә торган хөкем, суд.

Уқыйқ Қоръән,
Әйтик салаwат,
Рәсүл алланың үсенә.
Қыйәмәт көне булғанда
Қарыйбыз аның йөсенә (мөнәҗәттән) — себ.

Кыйәмәт көне булғанда
Нурлы булыр йөзегез.
Җәннәт булыр урыныгыз
Күп доғалар қылдыгыз — *каз.ар.*

Бу дөнйадан китәр безләр
Әҗәл суwын эчәр безләр.
Бер ғамәлсез үләр булсақ
Қыйәмәттә нишләр безләр.

### Тәмуғ

**Тәмугъ** — дин тәгълиматы буенча гөнаһлы кешелә рнең җанын мәңгелек ут һ.б. белән газаплый торган урын, җәһәннәм. Тәмуг җиде катлы, җиде гөмбәзле итеп сурәтләнә. Ул тирән упкыннан, мәңге сүн---мәс уттан гыйбарәт, дип әйтелә.

— Йакшы исемнәр куйарга әтәләр ат кыцкырткanda. Ахирәттә йакшы исемнәр кирәк икән.

«Йакшы исемнәр тамугка кертми», — дир,
Үлгәцтән исемнәреңне эзләрләр, дир — *чпр.*

**Тәмугъ казаны** (мөнәҗәтләрдә):
— Тәмугының кызуыннан
Кайнар тәмугъ казаннары.
Тәмугыга туры китәр
Бәндәләрнең азганнары.

**Тәмугъ уты**: — Қабергә салғанда әйтәләр:
«Ахирәткә иман белән күчәргә насыйб ит,
тәмуг утларын харам қыл».

Тәмуғ уты — «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (1983, 68):
Уҗмах виреб, тәмуғ утин сатуп алмаң, —
Тәмуғ эчрә бақи қалмаң сезләр имди.

Оҗмах биреп, тәмуғ утын сатып алмыйқ, —
Ул тәмугъда мәңге калып янмыйк имди.

**Җиде тәмугъ**:
Җиде тәмугъ ишекләре
Рамазан айында йабылыр...

— Җиде тәмугның утларын
Хәрәм кыйлгыл тәннәремә

Үзеңнең рәхмәтеңне салгыл
Безди зәгыйф бәндәңезгә (мөнәҗәттән).

Җиде тәмуг хакы өчен килгел,
йә бәхет, йә дәүләт,
Хәдим Ризван хакы өчен килгел,
йә бәхет, йә дәүләт! (мөнәҗәттән)

**Сақчы**:
Қабер сақчысы,
*Оҗмах сақчысы,*
*Тәмуг сақчысы* —
дога укып багышлаганда искә алыналар:
Оҗмах сақчыларына, кабер сақчыларына, тәмуг сақчыларына бағышладым — *әстр*.

### Җәһәннәм

**Җәһәннәм** [< гар.] тәмуг.
Җиде тәмуг өстенә
Сират күперен тартырлар.
Җаwыз булған бәндәләрне
Җәһәннәмгә атырлар (Самара өлкәсе, Камышлы).

### Мәхшәр

**Мәхшәр** [< гар.] — динчеләр уенча, кыямәт көнендә яңадан терелгән кешеләрнең җыелу урыны яки вакыты. — Аллаһе тәбарәкә вә тәгалә хәзрәтләре мәхшәр көнендә зур дәрәҗәләр бирер. Ш.Камал.

Әстерхан сөйләшендә дога укыганда багышлауда:

— Ахирәтемездә иманымыз булуға,
Қаберемездә йулдашымыз булуға,
*Мәхшәр көнендә* күләгәмез булуға,
Сират күперен кичкәндә җитәкчелек булуға

бағышладым — *әстр*.

Мөхәммәдъярның «Нуры Содур» әсәрендә (1997, 242):

Кайчандыр ул *мәхш әр* көне булганда,
Җирнең өсте халык белән тулганда.

### Сират: сират күпере

**Сират** [> гар. юл].

**Сират: сират күпере** — дини мифологиядә җәһәннәм уты өстеннән оҗмахка үтә торган, кеше ышанмастай тар күпер: кылдан нечкә, кылычтан үткен.

— *Сират күперен* кичкәндә җәшен тик тизлек белән кичәргә насыйп булсын.

**Изге сират күпере:**

Җәһәннәмдә изге сират күпере бар,
Қылдин нечкә, менә шуннан үтәсе бар.

**Сират кичү, сират күперен кичү:**

Безне, Раббым, җәннәтеңнән айырма,
Сиратыңны кичкәндә, айағымны тайдырма — *каз.ар*.
(Мөнәҗәттән).

— *Сират күперен* кичкәндә җитәкче булсын, тар қаберләре киң булсын — *әстр*.

— *Сират күперен* кичкәндә
Айағымны тайдырма.
Ғайшә белән Фатыйманы
Йулдаш қыйғыл сән аллаһ (дини догадан).
Иман белән, аман белән
Сират күперен кичәйен.
Ике йағымда ике фәрештә
Иманыма танық өчен.
Илаһи нийәт қылдым
Қоръән уқымақ өчен.
Сират күперен кичкәндә
Читәкчелек булмақ өчен — *тара*.

### Коръән

**Коръән** [< гар.] — мөселман дине кануннарын эченә алган һәм шуларны аңлаткан, «изге» саналган китап.

**Коръән чыгу** (уку) — дини йола буенча: кемнең дә булса авыруын дәвалау яки гөнаһларын ярлыкау, бетерү йөзеннән берәр руханиның коръәнне тулысынча укып чыгуы.

### Қоръән баwырсағы

**Қоръән баwырсағы** *әстр*. дини мәҗлескә пешерелә торган бавырсак.

— Қоръән баwырсағы wақ-wақ була.

### Қоръән-қатем

**Қоръән-катем** *әстр*. дини мәҗлес.

**Катем** [< гар. хатим] — коръәнне укып чыгу.

— *Қорән-қатемгә* җыйылған затқа бүләк бирәделәр, бүлеп-бүлеп бирәделәр.

«Саулық-сәләмәтлек бирсен,
Төрле афәтләрдән, күренер-күренмәс бәлаләрдән сақласын», —

дидек, доға қылып, сәдәқәне салып чәй эчтек.

## Қәтем-қоръән

**Қәтем-қоръән** *әстр*. дини мәҗлес.
— Мичеттә қәтем-қоръән булады. Үле-тереләргә өлеш дип тамақ илтәләр мичеткә.

## Қоръән табыны

**Қоръән табыны** *каз.ар.-лш*. дини мәҗлес.
— Қоръән табынына пешеренеп киләләр, кем нәрсә пешерә, җәүликмәкме, қоймақмы.

## Қоръән җәймәсе

**Қоръән җәймәсе** *т.я.-к.т*. қоръән укыганда җәелә торган җәймә, ашъяулык.

— Өстәлгә җәймә җәйеп, муллаға қоръән уқыталар. Аннары ул җәймәне үзенә бирәсең муллаға, қоръән җәймәсен.

## Қоръән тастархан

**Қоръән тастархан** *әстр*. дини мәҗлестә җәелә торган ашъяулык.

— *Қоръән тастарханны* идәнгә җәйәләр иде, өстәлдә уку йазық диләр. *Қоръән тастарханда* алма да, җимеш тә, халва да.

## Қоръән тастырхан печү

**Қоръән тастырхан печү** *әстр*. коръән укыганда җәелә торган ашъ---яулыкны кисү.

— Кә фен печкән wақытта қоръән тастырханын да печеп, әзерләп қуйалар. Эченә бер айақ салып, айаққа тоз салып қуйалар. Қоръән уқыйм дигәндә қоръән тастырханны қаршыңа китереп салалар. Шунарға қоръән уқыйсың.

## Қоран тастархан бирү

**Қоран тастархан бирү** *әстр*. коръән ашы үткәрү һәм коръән ашъ---яулыгын урнаштыру.
— Кеше үлеп бер йыл узгач кер кийү бетә, қоран тастархан бирелә.
— Ул қоран тастырханы тора йыл қоранына қадәр. Йыл тулғаннан соң қабергә төшкән көнендә уқыта қоран. Қабергә төшкән көнендә әр йылны уқыта. Ә қоран тастырханны мөчәле көнендә (51 көнендә) уқыған кешегә бирәләр. Саwыты, тозы, тастырханы белән бергә бирәләр.

— *Қорән тастарханда* ни зат қына йуқ, туйнықы кебек, алма да, җимеш тә, баwырсақ та, халва да. Үлене бик зурлыйлар, сыйлыйлар бездә.

— *Корән тастарханны* идәнгә җәйәләр иде, өстәлдә уку йазық диләр иде (Киләчи).

## Қоръән йаулық, қоръән тастырхан

— Қоръән йаулық, қоръән тастырханны бер йылында муллаға бирәтләр — *әстр*.

## Қоран тастырхан күмү

**Қоран тастырхан күмү** *әстр*. бер елдан соң зиратка барып күмәләр.

— *Қоран тастырханны* ди, мәйет башына қабергә алып китеп күмәргә кирәк ди. Мин мичеткә барып сорадым. Менә ничә қат уқылады қорән тастырханда, бер йылдан соң күмәргә кирәк ди.

## Кор′ән укыту

— Үлгән әбиләренә, үлгән бабайларына, корга кайwаннары чык---са кайwаннарына *коран укыталар* инде Йунды аwыл бичырманнары. Элек алар мысылман булганнар, чилум керткәләгәннәр керәшенгә йунды аwыл бичырманнарын. Аларның татар зиратлары бар әле дә йунды аwылның. Үлгән ә бибабайларына укытып торгаладылар. Укытмага кем йомырка, кем он, кем май салгалады — *глз*.

## Йыл кораны

**Йыл кораны** *әстр*. бер елын искә алу мәҗлесе.

— *Йыл қоранын* уқытқанда қаберчеләргә, йуучыларга зурырак бүләк бирәбез. Кем килсә дә мата биреп чығарады, ақлыққа чыға.

— Кеше үлгән көнне һәр йылны *уле қораны* уқытабыз, йыл қораны уқытабыз, үлене искә алып торма кирәк икән.

— *Йыл қоранына* инде әзерләнәләр, ул бик олы аш була. Зурлап әзерләнәләр, сәдәхә өләшәләр.

Сәдәхәң — тәмуқтан фәрдә булсын
Тар қабереңдә йулдаш булсын,
Белгәнен алла тәғалә кабул итсен,
Белмәгәнен ғафу итсен,

дип доға уқыдым. *Йыл қоранында* пылау пешердем, йимешләр, қырма (хөрмә) қуйдым тастарханда.

Менә мин Гөлшәрифәнең йыл қоранында утырам, үземә теләк теләп, алламнан йалwарып утырам.

## Җыл қораны

**Җыл қораны** *әстр*. бер елын искә алу мәҗлесе. Бу мәҗлескә ашам---лык табакларын так санда куялар.

— Җыл қоранында унөч, умбиш шара[1] алпама, унҗиде, унтугыз, җегерме бер шара алпама җасады шулпа салып. Алпама — қыйықлап кискән җәймә, токмач. Алпама өстөнә ит қуйатлар, майны суған белән қайнатып ит-алпама өстөнә қойатлар.
Җыл коранында әйтәделәр:
«Шуның қыйынлығын бирмәсен,
Шуның җашын бирсен», —
диде. Қарт кешенең җылында алай әйтәделәр.

[1] *Шара* — чара (агач табак).

— Җыл булғанда табаққа ит өстенә җәймә салаты. Җәймәне майға салып пешерә, қыздырмыштай булаты җәймә. Җыл қоранына чақырмый да киләләр.

## Йылқоран

**Йылқоран** *әстр*. ел коръәне.

— Йылқоран уқыта бер йыл булғанда. Ирләргә күлмәк, қысқайақларға йаулық, мата бирә, башларына ақ йаулық бәйлиләр.

Бер йыл булғанда йылкоран уқытады:
«Ақлығың хайырлы булсын,
Қараларың китсен», — диде.

## Кече йома кораны

**Кече йома қораны** *әстр.* һәр атнакич (пәнҗешәмбе) көнне үлгән кешегә багышлап дога уку.

— Әр *кече йомада қоран уқытабыз* бер йыл эчендә. Қырқы үттеме, әрбер *кече йома қоран уқытасың*, бер мәлбәк баwырсақ пешерәсең, мулла чақырасың. Әрбер *кече йома сайын қоран уқытасың*. Кече йома көн рухлар килә дип уқыйсың.

— Өч көне, җиде көне, қырығы, бер йылы уқытыла. Әр *кече йомада қорән уқыта* һәр атнада.

— Кече йома коранын муллабикә өйөнә килеп уқыйды, баwырсақ---қыйғача пешерәде.

## Суңгы коран, хәйерле коран

**Суңғы қоран, хәйерле коран** *әстр.* бер ел тулгач үткәрелә торган искә алу мәҗлесе.

«Ақлыкқа чыкқаның хәйерле булсын», — дип бирәде.
«*Суңғы қоран, хәйерле қоран* булсын», —
дисең, бер башйаулық китерәсең.

## Үле кораны, үле ашы

**Үле қораны, үле ашы** *әстр.* үлгән кешене искә алу мәҗлесе, дини мәҗлес.
— *Үле қоранына* ирләрне чақыра, кысқайақларны чақырмый. Ирсез хатыннарны ғына чақыра, ире бар кешенең ирен генә чақыра. Ирен чақырғач хатыны белән, қоран ашына барырға кирәк.

Ике қазан пылау пешерәләр әүләдә, бөтен аwыл килә. Күп килә халық.

— Ирләрне ашатып чығарасы чақырып, қатыннар бары да үзе килә:

«Баш сау булсын» әйтеп чығабыз, йақшы түгел килмичә», — дип.

— *Үле қоранына* аwыл халқы чақырмыйчы да килә. Аш-су, пы---лау пешерәделәр үле қоранына. Татулыкта, берлектә уздырдық. Чақырмыйчы да киләләр үле қоранына.

— Үле қоранына халва пешермәгә кирәк. Нәлбәкләргә салып қуйады халваны.

— Үле қоранына чақырмыйчы килгәнне бик саwаплы кеше дип әйтәбез. Болай инде аwыл җирендә чақырып чығабыз, йырақтағы туғаннарыбызга әйттерәбез, көнен белсеннәр дип, көнен-сәғәтен белсеннәр дип. Йырақтан килгән туғаннарына, килмәгәннәренә пакитқа салып бирәбез. Киткәндә үк *өлешен* салып қуйабыз. Тирә---қунчыга (күршегә) бирәсең. Йақшы, рәтле аwылыбыз.

— *Үле қоранына* тастырханға алмасын да, камфитын да, бурәген дә салады, баwырсағын да салады.
«Ул туй», — диде, «иң соңғы туй», — диде.

## Ахирәт, әхирәт

**Ахирәт** [гар. теге дөнья]. Ислам дине буенча, кеше кыямәт көнендә кабат терелеп, мәңге яшәячәк. Бәндәләрнең әнә шул мәңгелек галә---ме — «ахирәт» дип атала.
Ахирәт сүзе «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (1983, 68):
Тәңридән қурқың, батил ғәмәл қылмаң,
ахирәтдә вәбальдуг, ғаеп улмаң.

Тәңребездән куркыйк, яман эшне кылмыйк,

Ахирәттә гөнаһлылар булып калмыйк.

**Ахирәт бәйете**

**Ахирәт бәйете** *чст.-крш*. кеше үлгәч, төн саклап утырганда көйләп җырлана торган җырлар.

*Ахирәт хәлен белмәдем*
*Монда килерем димәдем.*
*Монда килерем димәдем*
*Бер хәйер дә бирмәдем.*

**Ахирәт ғоселе**

**Ахирәт ғоселе** *минз*. мәетне йуып бетергәч соңгы тапкыр арулау, коендыру. **Ғосел** [< гар.] коену, юу.

**Ахирәт госеле, камил тәһарә т** алдыра җуып бетергәндә.
«Илаһи нийәт қылдым ахирәт ғоселе қылдырмаға.
Илаһи үзең рәхмәтең wә кәрамың белән қабул қыл ошбу бәндәнең белеп қылған, белми қылған гөнаһларын қабул қыл, тулы җәннәтләреңә насип қыл», — дибез. — *минз*.

**Ахирәт қоймақ**

**Ахирәт қоймақ** *перм.* мәет озаткан көнне пешерелә торган коймак.

— Ахирәт қоймақны ашарға зираттан қайтқан кешеләр дә керәләр. Қыш көне булса туңып қайта қый.

**Ахирәт қорбаннық**

**Ахирәт қорбаннық** *перм*. мәет озаткан көнне суелган хайван: са---рык, сыер һ.б.

— Үлене җыйған көнне, күмгән көнне чалдырды исә ахирәт қорбаннық була.

— Мәйет озатқан көнне қорбаннық суйалар. Үзендә булмаса, кешедән сатып алып суйалар.

**Ахирәт йаулығы**

**Ахирәт йаулығы** *әстр*. мәетнең башына урый торган тукыма.
— Ахирәт йаулығы була ирләргә дә, қысқайақларға да.

**Ахирәт кешесе**

**Ахирәт кешесе** *туб*. мәетне юып, кәфенләп куйгач, «ахирәт кешесе» булып санала.

— Кәбеннәп алған сын үлгән кешене қалған тере кешеләргә күрсәткәле бойормай тоғаннар. Йуwынып эше бетсә, ул ахирәт кешесе булаты, ахирәттә генә күрешкәле тийәте. Ә хәсер әйтәләр, эше беткән, хушлашып қалың. Алай дөрес түгел, йарамайты.

**Ахирәт күлмәге**

**Ахирәт күлмәге** *урт.д*. кәфен, кәфеннек.
— Ахирәт күлмәге җилкәдән алып айақ йөзенә хәтле төшеп тора. Ахирәт күлмәге ул тегелми — *каз.ар*.

**Ахирәт күлмәге** *глз.*:

— Ахирәт күлмәген кыз-катынга айак корсагына хәтле кисәбез, ә ирләргә тезгә хәтле. Икенче каты айак балтырга хәтле була. Ахирәт күлмәге тегелмиче кийелә.

**Ахирәт күләге** *әстр*. ахирәт күлмәге.
— Ахирәт күләге йәшел булсын, нәзек булсын, нәзек булған сайын саwаплы, ди.

### Ахирәт мендәре

**Ахирәт мендәре** *к.уф*. кабердә мәетнең баш астына салу өчен әзерләнгән мендәр.

— Кеше үзенә үзе баш астына салырга йапырақтан *ахирәт мендәре* тегә. Қырда үскән қамышларны киптереп қоротып қуйа.

### Ахирәт ыштаны

**Ахирәт ыштаны** *әстр*. кәфеннекнең бер өлеше.
— Ахирәт ыштаны тегәтләр кипен печүчеләр.

### Ахирәт дус, әхирәт дус

Бер-берсенә бүләкләр бирешеп, ахирәткәчә дус булырга килешү, сердәш булу.
— Намазлар уқыдық, ул миңа алйапқыч бирде, мин шәлйаулық бирдем, ахирәт дуслар булыштық — *каз.ар.-лш.*

— Бармаклар белән тытынабыз шалайга, чәнти бармак белән, әтәбез:
«Үмерлеккә — тамырлыкка ахирәт,
Үмерлеккә — тамырлыкка сердәш,
Үмерлеккә — тамырлыкка ташламаска» — *кузн*.

**Әхирәт дус** *к.-уф.*:
— Әхирәт дус булған кеше дөнйа усаллықларын, **йаматайлықны** әхирәткә алып китәргә тейеш түгел. *Әхирәт дуслық* ул бик зур. Мөхәммәт пәйғамбәр әйткән, *әхирәт дусың* туры оҗмахқа алып керер, дигән, сират күпереннән чығармый ғына алып керер, дигән. Менә **садақа** бирәләр икән, садақаны күрсәтеп бирергә йарамый.

— Менә берәй бәйрәмдә, ашта берәй кеше сийа ошаса, *әхирәт дус* итәсең, эләсең **берәй нәрсә**. Менә мин сине *әхирәт дус иттем* дип, кирәкле доғаларын уқып тастымал эләсең, йә шәлйаулық, йә күлмәклек эләсең. Шулай сақырып алып бер әзерләнгән wахытында ул сине дә әхирәт дус итә, берәй нәрсә элә сийа да. Шулай *әхирәт дус* булалар инде.

— *Әхирәт дус* ул сине сират күперен кичми генә алып керемен оҗмахқа дигән. Шуның өсөн *әхирәт дуссыз үләргә йарамый*. *Әхирәт дусыңа* сүз җибәрегә йарамый, аныңа син қарарға тейеш, анықынча булырға тейеш. Кеше белән бәйләнеп, ақырып-бақырып йөрөгә йарамый *әхирәт дуслы* булған кешеләргә. Сине әрләсә дә син бер сүз дә әйтмичә борылып қына сығып китәргә **тейешсең**.

Йә Раббым, йарлыка безне
Дәхи ата -анабызны.
Җәннәт белән бәхетле кыл
*Ахирәт дусларыбызны*.

### Ахирәт тус

**Ахирәт тус** *себ*. ахирәт дусы. Бер-берсенә бүләкләр бирешеп, дус---лашып кую.
— Туслашасың бүләк биреп.
«Менә тустым, ахирәтем өчен. Йаулығым да, күлмәгем дә сиңа».
Ахирәт тустым бар аwылда.

## Ахирәтлек

**Ахирәтлек дус** *әстр*. ахирәт дусы.
— *Ахирәтлек дус* булса чәнәтәй бармакларны кочаклатасың да

«Ахирәт, айырмас, күбәләгем, гүзәлем», —
дисең — *әстр*.

**Ахирәтлек қушылу** *әстр*. мәңгелек дус булу өчен махсус йола башкару.

— *Ахирәтлек кушылу* инде менә. Алар үзләренә бер көн җыйылып, без үзебезгә бер көн җыйылып, затлы ашлар пешереп, эти-әниләренә бүләклә р, бер- берсенә бүләкләр бирешеп кушылышалар, ахирәтлек булдык диләр. Алар ахирәт булып йөриләр гомер буйы.

## Әхирәтлек: әхирәтлек күлмәк

**Әхирәтлек күлмәк** *бараба*. кәфенлек.
— Әхирәтлек күлмәккә ақ таwар алдым.

**Әхирәтлеккә ыриза булу** *бараба*. дога кылганда әйтелә.
«Йалған дөнйа қалды, иткән тәрбийәгә,
әхирәтлеккә ыриза бул», —
тип туwа қылабыс.

## Мәңгелек йорт

**Мәңгелек йорт** — мөнәҗәтләрдә кулланыла торган сүз; ахирәт, кабат терелеп мәңге яшәү урыны.

*Мәңгелек йортқа* барып җитәрбез,
Тапкан малларны ташлап китәрбез.
Караңгы гүргә, каты балчыкка
Барабыз бер көн, *мәңгелек йортка*.

## Мулла

**Мулла** [гар. маула, фарсы. молла].
Екатерина II патша вакытыннан алып мулла махсус указ белән билгеләнгән һәм билгеле бер мәчеткә караган.
**Мулла** — мөселманнарда дин әһеле.
— Мулла түбәдән (зираттан) қайтып қорьән уқый, баwырсақ белән чәй эчә — *әстр*.

## Мулла абзый

**Мулла абзый** — муллага олылап эндәшү.
— Мулла абзый, миннән гүр садакасына сарық, ди — *минз*.

## Мулла әби

**Мулла әби** *чпр*. абыстай.
— Үле өстендә утырганда төн ката укилар. Мулла әби китап сүли. Мөнәҗәтләр әтәләр.

## Муллабикә, муллабигә

**Муллабикә** *әстр*., **муллабигә** *себ*. абыстай, мулла хатыны.
— Қатыннар арасында муллабикә қорьән уқый — *әстр*.

**Муллинә**

**Муллинә** < мулла + инә *себ.* дини, дин тәртибен белә торган хатын-кыз; абыстай.
— Менә Тимербигә мама муллинә иде, хәзер муллинәбез йуқ.

**Мулла қортқайақ**

**Мулла қортқайақ** *себ.* мулла хатыны; абыстай.
— Үлте — мулла қортқайақ йасин чыға.

**Муллапи**

**Муллапи** *глз.* мулла баласы.
— Муллапи укыгалады җеназасында. Мулла балаларын муллапи диләр.

**Остабикә астай**

**Остабикә астай** *чст.* абыстай.
— Остабикә астай табында аш өләшә.

**Доға**

**Дога** [< гар.] теләк теләү, ялынып сорау, үтенү.

«Мәйет — доғадан туймый,
Җир — судан туймый», — дигәннәр — *т.я.-к.т.*

**Доға қылу**

**Доға қыйлу** *к.-уф.*:
— Өстәлнең дүрт мөгөшендә дүрт фириштә булыр дей. Алар безгә *доға қыйлырлар* микә дип утырырлар дей көтөп. Әнә шуларға доға қыйлабыз.

Хөзер Илйас пәйғамбәребез бар, йулға чыққанда уқырға кәрәк. Қапқаңны чықтың, қырға чыққан дип чутланыла қый. Аныңа *доға қыларга* тейешбез, йомға көнне айәт уқырға тейешбез.
— Өчендә, җидесендә, қырығында — бөтен әрwахларға доға қылабыз — *мам.*

**Доға қылу** — «Кыйссаи Йосыф» әсәрендә (192 б.):

Йағқуб сәүчи әл қалдырди, доға қылди,
доғасы ул хақ қаршында мәқбуль улди.

Йагъкуб сәүчи кул күтәреп дога кылды,
Ул дога да хакъ алдында кабул булды.

**Доғачы**

**Доғачы** *әстр.* дога кыйлучы, теләк теләүче.
— Үсеп утырған оныкларыбыз, балаларыбызға, үзенең ата-анасына *доғачы булуға* насиб әйлә.

**Дуwа**

**Дуwа** *т.кам.-крш.* искә алу мәҗлесе, дини мәҗлес.
— Өченә, җидесенә атқа атланып чыгалар да чақырып җөриләр: «*Дуwаға* килегез».
**Дуwа қылу** *әстр.* дога кылу.

Қараңғы гүрең йақты булсын,
Тар қаберең киң булсын,

Йатқан җиреӊ нур булсын,
Бақый иман йулдашыӊ булсын,
Җәннәт хөлләләрен кийәргә нәсиб ит,
Тәмуғ утын тигезмә, — дип дуwа қылды.

**Дуwа** *срг*. дога.

Атай кәбәм, бирнә бирәмен,
Уӊ кул белән генә алсана.
Анай кәбәм генә, мин китәмен,
Изге дуwаӊ белән калсана...

### Туwа

**Туwа** *себ*. дога.

— Зираттан қайтқач бабайлар Қоръән уқып туwа қылалар — *бараба*.

### Күкрәк туwа, дийалык

**Күкрәк туwа** *төм*. җаваплама догасы.

— Күкрәк туwалар барыбысныкы да әсерләп қуйылаты. Минеке дә кәбеннегем, тунныкларымның өстенә қуйылған.

### Дийалык

**Дийалык** *чпр*. җаваплама догасы.

— Күкр әгенә куйабыз мөһри шәриф дигән дийалык. Ахирәт күлмәгенеӊ өстенә куйабыз.

### Зекер

**Зекер** [< гар.]: **зекер әйтү** — алланы зурлап һәм мактап дога уку; тәсбих тарту.

Бер ходага *зекер әйтеп*
Фирдәвес оҗмахны сорыйк.
(Мөнәҗәтләр, 126 б.)

**Зекер салаwат** [< гар.] мактаулы догалар.

*Зекер салаwатлар* әйтеп
Рушан тотыйк телебезне.

**Зекер-тәсбих** [< гар.]:

Намаз, *зекер-тәсбихләрне*
Күӊелләрдән алма, раббым.

### Тәсбих

**Тәсбих** [< гар.] — дисбе, четки.

Кәмәре бар иде аныӊ билендә,
*Тәсбихе* һәрчак иде әлендә (кулында)
(«Мөнәҗәтләр», 2007, 48).

**Тәсбих саwаплары**:

Килеп кердем өйегезгә,
Тәсбих күрдем чөйегездә,
Тәсбих саwапларын бирсен
Бер ходайым үзегезгә (Мөнәҗәттән).

### Тәсбих тарту

**Тәсбих тарту** — җеназа тәртибенең бер өлеше. Үлене кә фенләп куйгач, янына кереп, берникадәр кешеләрнең тәсбих тартып, тәһлил әйтеп, корьән укып багышлавы; тәсбих тарту — т әсбих төймәләрен берәм-берәм тартып, алланы зурлый торган сүзләр әйтеп тору.

— Мәйет сақлағанда тәсбих тартып утырабыз төн буйынча — *каз.ар.*

**Теләк-тәсбих қылдыру**

**Теләк-тәсбих қылдыру** *себ.* дога укытып теләк теләү.

«Аwыр туфырағың йеңел булсын,
Иман байлығы бирсен,
Йомахта урының булсын».
Алай теләк теләп утырапыс, уқынапыс.

— Цымта йомортқаларны пыйас қабықларға буйап балаларға бирәтләр. Балалар масайыша торғаннар. Теләк-тәсбих қылдыратлар — *туб.*

**Тәһлил әйтү**

**Тәһлил** [< гар.], **тәлил, ат у** *срг., кузн., чпр.*, **тәлил, тәһлил әйтү** *урт.д.* мәетне өйдән алып чыкканда әйтелә торган дога сүзләре: лә илаһә иллә аллаһы — «бер алладан башка алла юк» дигән җөмләне әйтү.

— Ирләр ченазага куйып алып цыгалар, абзарга алып цыгалар да *тәһлил ат алар. Тәһлил ат уцылар* йакын нәсел-нәсәбәләре була — *срг.*

— Ченазаны алып чыккач, идән кырк адым атлисын, туктаталар и тәһлил әйтмә кирәк — *баст.*

**Тәһлил бағышлау**

— Үле киткәнче *тәсбих тартып, тәһлилләрен бағышлап* җибә---рәләр — *әстр.*

— Җеназа алдында *тәһлил әйтәләр* әүләдә (ишек алдында), йөз тапқыр *тәһлил әйтеп* бағышлыйлар — *әстр.*

— Үлгәлләргә тәһлил чығып бағышлыйм — *бәр.*

**Тәлил карцықлары**

**Тәлил карцыклары** *чпр.* мәет янында тәһлил әйтүче карчыклар.

— Тәлилгә зиде карцык зийабыз үле өстенә. Тәлил карцыкларына йаулыклар аппаралар.

**Тәһлил садакасы**

**Тәһлил садакасы** — тәһлил әйткәч өләшенә торган хәер, үлемтек әйберләре: яулык, тастымал, сабын һ.б.

— Тәһлил садакасына берәр исле сабын өләштердем — *минз.*

**Тәлил салфиты**

**Тәлил салфиты** *чст.* тәһлил тастымалы, ягъни үлгәч өләшенергә тиешле тастымал.

— Акцаны зират эстендә эләшәләр. Йортта акца эләшү йук, салфит эләшәләр.

— Менә *тәлил салфиты* үлгәц эләшергә йыртта бабайларга. Элгәре уникене йасаганнар, хазер йездән дә артык йасилар. Кеше күп килә.

**Тәһлил тастымалы**

**Тәһлил тастымалы** *минз.* җеназада өләшенә торган тастымал.

**Тәһлил тастымалы** дийеп җеназа уқығаннан соң қартларға садақа, тастымал, йә битҗаулығы[1] тарataлар, **тәһлил садақасы** була.

— Ирләр җеназаны күтәреп алып чығып киткәнче ирләргә таратырға дип әзерләп қуйған тастымалым бар. Әнә оло сандықта ирләргә **тәһлил тастымалым** да күп, шәлҗаулығым да күп. Ишек алдында тәһлил тастымалы тарataлар.

### Тәлил тарту

**Тәлил тарту** *себ.*, *чпр.* тәһлил әйтү.

— Тунnықлағац[2] қабырғасы белән қыйбылаға қаратып салабыс, тәлил тарттырабыс. Шуны бағышлата. Тәлил тартып беткән сун йасин уқый, тәбарәк уқый — *төм.*

— Мәйет көткәле барабыс, тәлил тартып утырабыс — *бараба.*

— Үле өстендә утырганда тәлил тарта идек дисбе белән санап, укып утырабыз — *чпр.*

### Тәһлилгә керүчеләр

**Тәһлилгә керүчеләр, тәһлил тартучылар, тәһлил чыгып утыручылар** *т.я.-к.т.* мәет янында тәһлил әйтүчеләр. Аларга хәер итеп әйберләр өләшәләр.

[1] *Битҗаулығы* — сөлге.
[2] *Тунnықлағац* — кәфенләгәч.

**Йаулықлар, сабыннар, тастымаллар өләшәләр:** — Тәһлилгә керүчеләргә сабын, тастымаллар, бит җаулығы өләшәләр.

### Тәһлил әйтү, тәһлил уку

— *Тәһлил уқыйбыз* барыбыз да. *Тәһлил* белән үткәрегә қушқаннар бағышлауны — *к.-уф.*

— Тәһлил әйтелгән мәйетне бик хуплап қаршы алырлар ди, тәһлиле күп моның дип — *бәр.*

— Тәһлил ул ахирәт йул ачкычы,
Тәһлил ул ахирәт — җәннәт ишек баскычы,
Тәһлил ул ахирәт җәннәт урын ачкычы — *глз.*

Әстерхан сөйләшендә тәһлил әйтү мөнәҗәте:

Лә илаһа илаллаһның
қарамағыз әзенә,
Лә илаһа илаллаһ ул
мәңге бетмәс хәзинә.
Лә илаһа илаллаһ әйтсәң
қараңгы гүреӊ йактырыр,
Лә илаһа илаллаһ ул
ғайеп маллар таптырыр.
Лә илаһа илаллаһ ул
ғазапларда қалдырмас,
Лә илаһа илаллаһ ул
тамукларда йандырмас.
Лә илаһа илаллаһ ул
җәннәттәге күбәләк,
Лә илаһа илаллаһ ул
тәһлил шәриф мөбарәк.
Лә илаһа илаллаһ ул
һәр зекердән қадерле,

Лә илаһа илаллаһ ул
мәхшәр көне әҗере.
Лә илаһа илаллаһны
телдән салма берзаман
Лә илаһа илаллаһдан
айырылған бик йаман.
Лә илаһа илаллаһ ул
мәхшәр көнне күләгә,
Лә илаһа илаллаһ ул
изге телдән сүләнә.
Лә илаһа илаллаһ ул
қараңғы гүрем йақтысы,
Лә илаһа илаллаһ ул
сигез оҗмах ачқычы.
Лә илаһа илаллаһи
Мөхәмәде рәсүл аллаһи,
Қыйл безләргә шәфәғать
Нурмөхәммәт салаwат.

**Тәһлил уку**

**Тәһлил уку** *чпр*. тәһлил әйтү.
— Мәйет өстендә тәһлил укилар.
«Алла ризалыгы өцен
Ошбу укыган тәһлилләремне
Ошбу бәндәнең рух-шәрифләренә ирештер», —
дип багышлыйсың.

**Тәһлилне ата аты белән уку** *чпр*. тәһлилне әтисенең исемен әйтеп, үлгән кешегә багышлап уку.

— Кемгә укысаң да тәһлилне дә, йасинны да ата аты белән укырга кушалар, ата атын әтеп.

«Аты белән әтмәсәң, тиз бармый, адашып йөри дир укыганнарың».

**Тәһлил укыган кеше, тәһлил укыту** *чпр*.:
— Бездә бөтен бар амында да йиде кешегә тәһлил укыталар. Өценә йийылгацтан да тәһлил укилар. Йидесендә, кырыгында, йыл бар амында да йиде кешегә тәһлил укыталар.

Тәһлил укыган кеше биж wакыт намаз ийәсе булырга тийешле. Намазың булмаса, кемгәдер тәһлил укырга рөхсәт ителми.

Шының өцөнгә тәһлилне укуцы ә билә р була. Алар алалар тәһлилне. Аларга сәдәкә бирәләр хәленә күрә. Зур мунца сөлгесе белән йөз сум акца бирәләр.
Лә илаһа илаллаһның
Карамагыз әзенә.
Лә илаһа илаллаһ ул
Әхирәттә хәзинә.
Лә илаһа илаллаһы
Сигез оҗмах ачкычы,
Лә илаһа илаллаһы
Әхирәтнең бачкычы.
Лә илаһа илаллаһны
Әйтүчеләр йанында,
Уңда сулда фәрештәләр
Очып йөри алдында.
Лә илаһа илаллаһны

Әйтмә кирәк әр заман,
Лә илаhа илаллаhны
Әйтмәгән тел бик йаман — *чпр.*

**Җаwаплама, җаwапнамә**

**Җаwаплама** — дин буенча: үлгән кешенең теге дөньядагы җавап---лары.

**Җаwаплама** *әстр.*:

Тәннәреңне йуwарлар.
Илтеп җиргә куйарлар.
Кырык адым җир киткәч
Җаwабыңны сорарлар.

Бер йалгыз башың
Керер қабергә.
Раббым, йардәм бир,
Җаwап бирергә.

— Үле өстендә гүрне җаwып бетергәч мулла қала. Ул җаwаплама қайтарып торма тийеш, уқып торма тийеш.

**Җаwапламаға қалған кеше** *перм.* мәетне җирләгәч, кабер янында калган кеше.

— Җаwапламаға қалған кешегә тастымал бирәбез, ул анда уқып утыра қый.

**Йаwаплама** *миш.д.*:

— Кеше үлгәч, ләхеткә куйганда кәфеннек эченә күкрәгенә **йаwап---лама дывасы** куйалар. Йаwап бирергә бит теге дөнйада.

Ак камыштыр түребез
Караңгыдыр гүребез.
Туфрак басар, җир кысар
Ни йаwабын бирербез.
Алла димен, Раббым Алла
Йома көнсез йанымны алма.
Гүр азабы каты икән
Ни йаwап бирербез анда — *влгг.*
Уйла бәндә үләсеңне
Кара җиргә керәсеңне.
Кара җир астына кергәч
Ни йаwаплар бирәсеңне — *влгг.*

**Йаwапнамә**

**Йаwапнамә** *чпр.* җаваплама.

— Йаwапнамә куйабыз мәйеткә. Элек-электән куйганнар аны әби---бабайлар. Без дә куйабыз. Торып утырып уки торган итеп алдына, күкрәгенә куйабыз. Сорауларын, җаwапларын укысын, җаwап бирсен. Шынарга куйабыз йаwапнамәне. «Мөhри Шәриф»не куйабыз. Шуны укып, йаwап бирерлек итеп, рәтләп куйабыз.

**Чаwаплама**

**Чаwаплама** *себ.* җаваплама сүзләре.

— Чаwаплама қуйа мәйетнең күкерәгенә. Очмах көйләк[1] өстенә чаwаплама қуйасың түшенә. Чаwап бирү кәрәк, ғуй — *төм.*

Тәннәреңне йуwарлар,
Илтеп йиргә қуйарлар.
Қырық адым йир киткәч
Чаwабыңны сорарлар.

— Үлгән чақта күкрәкләренә чаwапламалар йасдырып қуйатлар, қултыг асларына қыстырып қуйатлар — *тара*.

— Кабердә бездән сорамаклар:
«Рухың кемдә?» — дәмәк.
«Рухым алла тәгаләдә», — дәмәкмен.

[1] *Очмах көйләк* — кәфеннек.

Пәрештәләр әйтмәк, бездән сорамак:
«Динең кемдер?»
«Динем ислам дине», —
дәмәкбез, созыып әйтмәкбез — *Бараба*.

**Күкрәк-туwа**

**Күкрәк- туwа** *туб*. мәет өстенә, кәфенлек астына куела торган дога; үлгән кешенең теге дөньядагы җаваплары.

— Күкрәк-туwалар қуйабыс үлгән кешенең күкрәгенә. Аны алтан уқ әсерләп қуйабыс.

**Иман**

**Иман** [гар.] — аллага инануны белдерә торган дога сүзләре.

**Иман ағачы**

**Иман ағачы** *нокр*. артыш агачы; аны үлгән кешенең каберенә, ләхеткә салалар.

— Иман ағачы диләр артыш ағачны. Аны ләқыткә салалар артыш ағачны иман ағачы дип.

**Иман белән үткәрү**

**Иман белән үткәрү** *себ*. дога укыганда әйтелә:

Йаттым йә алла,
Торсам иншалла.
Бу йатудан торалмасам
Иман белән үткәр аллам.

**Иман күwесе**

**Иман күwесе** *крш*. дини җырлар.
— Кешене алып чыгып киткәнчә *иман күwесе* җырлилар — *т.я.-крш*.

**Иман салу**

**Иман салу** *эстр*. үлгән кешене кабергә төшергәндә әйтелә торган сүзләр.

«Иманың — җулдаш булсын,
Тар қаберең — киң булсын,
Артта қалғаннарга рәнҗемә,
Йатқан җирендә тыныч йат».
Шул *иман салу* дип әйтеләде.
«*Иман салындымы* икән қаберенә?» — диделәр.

## Иман теләү

**Иман теләү** *бараба*. үлгән кешене кабергә салганда әйтелә торган дога сүзләре.

«Иманың — йулташ булсын,
Қаберең нур булсын
Алдың — үзеңә,
Артың — безгә», —
тип иман теләп туwа қылабыс.

## Иман уқучы

**Иман уқучы** *крш*. дин тотучы.
— *Иман уқучылар* бәкегә барып қач манып кайталар.

## Озату иманы

**Озату иманы** *каз.ар.-крш*. үлгән кешене өйдән чыгарганда укыла торган дога.

— Озату иманын уқығанда бар кеше дә шәм тотып тора. Белгән кешеләр қушылып җырлыйлар.

## Иман әйтү

— Түремдә *иманымны ә йтеп,* изге көннәрдә, саф җан көйенчә дөнйадан үтәргә нәсиб итсәң иде — *каз.ар.-мам.*

## Иман җыруwы

**Иман җыруwы** *т.кам.-крш*. дини җырлар.
— Үлемтеккә (зиратка) *иман җыруwы* җырлап баралар. Түгемдә берсе уқый, уку арасында барысы бергә *иман җыруwы* җырлыйлар.

## Иман җырлап келәү итү

**Иман җырлап келәү итү** *крш*. искә алу мәҗлесендә дини җырлар җырлау.

**Чәй, аш, ботка** чыга пуминкыда. Моносы инде сөткә пешкән бутка, анысына келәү итәләр. Изге кыз Марийаны ололап ботка шуның исеменә чыга. *Иман җырлап келәү итәләр*. Балыклар чыга эрәте-эрәте белән.

## Иманчы

**Иманчы** *крш*. иман укучы, дини кеше.
— Кеше үлгәчен *иманчыны* чақыралар.

## Азан

**Азан** [гар.] намазга чакыру. Азан әйткән кешене «мөәзин» (азанчы) дип атыйлар. Азанның мәгънәсе:

Аллаһ иң олугтыр,
Аллаһыдан башка Иляһның юклыгына
  таныклык бирәм,
Мөхәммәд чыннан да Аллаһының илчесе
  икәнлегенә таныклык бирәм.

Намазга ашыгыгыз,
Котылырга ашыгыгыз,
Аллаһ иң олугтыр,
Аллаһыдан башка Иляһи юк.

**Азанчы, азанцы** — азан әйтүче.

— Азанцы азан кыцкыра аwыз ацарга. Керәм дә йогорып, әтәм: «анай, азан кыцкырдылар» — *срг*.

## Аман

**Аман** [< гар. әман] — тынычлык, иминлек.

Дөнйалыкта *аман* өчен булсын,
Ахирә ттә иман өчен булсын,
Сират күперен кичкәндә
Йулдашың булсын — *әстр*. (хәер-сәдака биргән
кешегә шулай дип теләк телиләр).

**Аман-исән** *әстр*. исән-сау.

— Салдатка киткән улларыбызға бурычларын үтәп, аман-исән кайтып ата-аналарын қуандырмага насиб ит, йәрабби. Балаларның қайғы-хәсрәтләрен, кийекләрен күрсәтмә, йарабби — *әстр*. (хәер---сәдака биргәч әйтелә).

## Айәтелкөрси

**Айәтел көрси** [< гар.] Коръ әндә Әл-Бакара сүрәсенең 255 бите. Бу аять Аллаһы тәгаләнең тәхете турында бәян итә.

— Озатқан чағында айателкөрси уқып, тәлил чығып қалабыз — *туб*.

Айәтелкөрси зур айәттер
Аны һәркем зурласын.
Аны зурлаған бәндәләр
Оҗмахларға туры барсын.

Ходай безгә йардәм итеп
*Айәтелкөрси* йараткан.
Бөтен мөэмин мөселманга
*Айәтелкөрси* тараткан (Мөнәҗәтләр, 156 б.).

## Салаwат

**Салаwат** [гар.] мактаулы догалар.

— Мәйетне төнәтеп утырғанда тәлил әйтеп, салаwат әйтеп қалалар.

Ул Мөхәммәт Мостафага күп салаwат,
Бу салаwат һәр бәндәгә сөннәт имди.

Уқыйқ Қоръән,
Әйтик салаwат,
Рәсүл алланың үзенә — *себ*.
Иртә торып ал т әһарәт
Барча тәнең пак булсын.
Уқы Қоръән, әйт салаwат
Күңелең синең шат булсын — *себ*.
(Мөнәҗәтләр, 154 бит)

## Тәбәрәк

**Тәбәрәк сүрәсе** [гар.] — Коръәндәге сүрә.
**Тәбәрәк сүрәсе уку** *бараба.*:

— Мәйетне күмеп беткәч тәбәрәк сүрәсен уқып туwа қыласың. Мәйетнең урынына килеп тағын уқыйсың. Мәйеткә бик туры килмәк — *бараба*.

**Тәбәрәк уқу** *т.я.-к.т.*:
— Зиратларға барып җиткәнче ди-ди тәбәрәк уқыйлар.

## Тәбәрәк уқу

— Минем туған энемнең бичәсенең тутайы уқый тәбәрәкне мәйет ашында — *к.-уф*.
— Тәбәрәк уқырға кирәк, ул қабер ғазабын күтәрә, диләр — каз.ар.

## Тәкбәр

**Тәкбәр** [гар.] тәкбир.
**Тәкбәр әйтү** *к.уф*. тәкбир әйтү.
— Мәйетне алып киткән чағында *тәкбәр әйтеп* қалалар. Бик әйбәт җыйалар мәйетне.

## Ғамәл, әмәл, амәл

**Гамәл** [гар.] эш, хәрәкәт.

Таразуга (үлчәүгә) салганда
*Ғамәлемне* аwыр ит,
Гөнаһымны җиңел ит.

Бер үлмәк бар, терелмәк бар
Гамәлләрдән соралмақ бар.
Ләхетең тар, қачар җир йуқ
Шунда рәхмәтеңне сал...

Җирнең куйнында
Йалгыз калырсың.
Гамәлләреңнән
Сән соралырсың

Гамә л кылган бәндәләрнең
Утта йанмас сөйәге.
Ни кадәрле мал җыйсаң да
Булмас аның кирәге (мөнәҗәттән).

**Амәл, әмәл** [гар.] эш, хәрәкәт.
**Чүпрәле сөйләшендә:**

Әмәл кылмадым
Йәш wахытымда.
Ничек йатырмын
Тар ләхәтемдә.
  Кабер өстенә
  Куйарлар такта.
  Әмәл кылыгыз
  Исән-сау чакта.
Менәлмәдем бийек тауга
Басалмадым wак ташына.

Амәлем аз, гөнаһым күп
Ничек барыйм хак каршына.

## Гөнаһ, йазык

**Гөнаһ** [< фарс.] — язык, ярамаган эш.
**Йазык, җазык —** борынгы төрки сүз: ярамаган эш.

— Қоръән тастырханны идәнгә җәйәләр, өстәлдә уку йазық, диләр — *әстр*.
**Җазык** — керәшен сөйләшләрендә, догаларда:

Әй, Қодай , җазықлардан мине сақла.
Әй, Қодай Аллабыз,
Җазыклылардан җырақ җөрет,
Җақшыларға җақын ит.

## Саwап

**Саwап** [гар.] дөреслек, турылык, изге гамәл.
— Кәбеннеккә йәшел йаулық алып қуйтым. Туннықлағалы ақ таwар, йәшел йаулық — әшкәрә оллы саwап.

Қортқайақларға йәшел йаулық булса — *оллы саwап*. Йәшелтән қылу — әшкәрә *оллы саwап* — *себ*.

**Әҗер саwабы**:
— Шушы дини мәҗлескә җыйылған дин қардәшләребез уқыған намазларның *әҗер саwабын* биргәй идең — *әстр*.

**Саwаплы кеше**:
— Үле коранына чақырмыйчы килгәнне бик *саwаплы кеше* дип әйтәбез — *әстр*.

— Түбәгә йәшләр йогортып алып китәләр, атлап та җитә алмыйсың. Йогортып алып киткән үле — бик *саваплы* ди. Йәшләр кош итеп очорып алып китәләр, берен-бере алмашып очортып алып баралар — *әстр*.

## Мөнәҗәт

**Мөнәҗәт** [гар.] — ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, Аллаһе Тәгаләгә мөрәҗәгать итү, ярлыкауны сорау диг ән мәгънәне аңлата; дини-интим эчтәлекле әсәр. Дини мәҗлесләрдә Коръән укылганнан соң хатын-кызлар бергәләп мөнәҗәт әйтү йолалары бар; мәет саклап төн утырганда да мөнәҗәтләр әйтелә.

Мөнәҗәтләр әйтәм сезгә
Изге йадкәр булсын өчен.
Бу мәҗлестә утырганнар
Күп догалар қыйлсын өчен.
Мөнәҗәтләр әйтәм сезгә
Күңелләрегез ачылсын.
Сигез оҗмах эчләренә
Ризыкларыгыз чәчелсен.

## Мөнәҗәт әйтү

— *Мәйет караулаганда* мин *мөнәҗәт әйтәм*:

Үлем дигән ачы ағу
Берәү дә татымый қалмас.

Үлем уты атар туры
Бераү дә қотыла алмас — *к.-уф*.

Анадан туwадыр бала
Дөнйа утында йана.
Дөнйа утында йана-йана
Азраил йаныып ала — *чпр*.

**Мөнәҗәт әтү**

— Бездә мөнәҗәтләрне үле күмгәннән соң әтәләр. Үле турысында мөнәҗәтләрне күп беләбез.

Бисмиллаһи әтеп кенә
Башлиг әле мөнәҗәтне.
Мөхәммәт өммәте өцен
Йараткан сигез җәннәтне.
Һәр кешегә үлем киллер
Килгән кебек караңгы төн.
Йакты дөнйа бар ам булып
Кала бер көн, кала бер көн.
Менәлмәдем тау башына
Басалмадым ак ташына.
Амәлем аз, гөнаһым күп
Ницек барим хак каршына.
Су буйына төшкән идем
Йар буйлары куwак кына.
Кадерләрен белеп йәшик
Без дөнйада кунак кына — *чпр*.

**Тәңре**

**Тәңре** — борынгы төрки сүз. Гарәп һәм фарсы телләреннән алла, ходай сүзләре кергәнче үк кулланылган.

Тәңре сүзе XIII йөздә «Кыйссаи Йосыф» дастанында:
Йусеф әйдүр: «Бу гәз иш андан кэчди,
тәңренең хөкме улды, тәдбир шишди» (142 б.)

Йосыф әйтте: «Бу мөмкинлек инде үтте,
Тәңребезнең хөкме булды, чара бетте».
Тәңрейә сығынды — Йусеф қачди,
қодрәт берлә йите қапу халиқ ачди.

Тәңресенә сыйынды да Йосыф качты,
Кодрәт белән җиде капка халикъ ачты.

Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр иҗатында:
Барча хәлен анлар белделәр,
Тәңрегә чуқ шөкерләр қылдылар...

Себер диалектларында әйтем:
Пашны түмән игәле кәрәк.
«Түмән игән башны қылыц кисмәй», — тигәннәр.
«Тәкәбберне тәңре орат» — тигәннәр.

**Тәңре кунагы**

**Тәңре кунагы** *кузн*. дини мәҗлескә чакырылмыйча, очраклы рәвештә килеп кергән кеше.

— «Тәңре кунагы өчен», — дип, атауда бер корка эштине артык пешерәләр. Тәңре кунагы килеп керсә, саwаплы мәҗлес була.

### Ходай

**Ходай** [фарсы.] — алла.

Сабырларны ходай сөйгән
Сабырсызны ләғыйн сөйгән.
Сабыр итик, сабыр итик
Ходайның қушқан эшенә (Мөнәҗәттән).

— Бер ходай, бер тәңре өчен дип әйтеп қоймақ пешерәбез түгемдә — *т.кам.-крш.*

### Алла, Аллаһ

**Алла, Аллаһ** — гарәпчә илаһи зат, тәңре, ходай. Ислам дине буенча күкне, җирне, кешене — бөтен нәрсәне бар итүче, бөтен дөнья белән идарә итүче.

Илаһым утта йандырма
Мәңге тәмугъта калдырма.
Рәхмәтләреңдин айырма
Әйтик: «Аллаһ, Аллаһ» дийеп.

**Аллаһы тәғалә** [гар.] бөек һәм югары булган алла; аллага ялвару, мөрәҗәгать сүзе.

И аллаһы тәғаләм,
Илемә — йортыма,
Аwыл — күршемә тынычлык бир!

### Алла бабай

**Алла бабай** *крш.* тәре, икона.
— «Алла бабай манғандыр инде қачны бездән дә алда», — дийешә---дийешә алабыз суны.

### Алла бабайға элү

**Алла бабайға элү** *крш.* тәрегә бизәү әйберләре элү.
— Тәре бистәрләре, тәре алҗапқычы суғалар ыйы, чигәләр ийе қызлар, *алла бабайға эләләр* ийе.

— Тәре бистәре диләр бездә. Ул шуның киңнеге, итәге була, ике балақ була, араларында челтәрләр була. *Алла бабайға* бистәр, алҗапқыч эләләр, бистәрне җә суғалар, җә чиккән була.

### Тәре бабай

**Тәре бабай** *крш.* икона, тәре.
— Тәре бабай алдына бәрмәнчек қуйалар, бәрмәнчекне чуқлап қуйалар — *каз.ар.-крш.*

### Бабай

**Бабай** *т.я.-крш.* икона, тәре.
— *Бабай* алдына шәм жагып куйабыз үлене сагынганда, *бабай* сөлгесен элеп куйабыз.

### Дәҗҗал

**Дәҗҗал** [< гар.] — дини мифология буенча кыямәт булыр ал---дыннан чыгачак бер алдакчы зат. — Дәҗҗал чыгар, күктән хәзрәти Гайса иңәр, җир йөзенең асты өскә килеп буталыр да кыямәт булыр. Г.Ибраһимов.

## И раббым, йә раббым, йарабби

**Йарабби, йә раббым** [гар.] «я аллам» мәгънәсендә аллага мөрәҗәгать итү сүзе: гаҗәпләнүне, нәфрәтләнү һ.б.ш. хисләрне белдерә. Ярабби, монысы нинди язу инде тагын? (Г.Бәширов). Яраббым, мондый холыксыз кешене күргәнем юк иде (Ш.Мөхәммәдев).

Теләк теләгәндә кулланыла. Хәерле генә эшләр булсын инде *ярабби*! (М.Фәйзи). Илаһи үзең сакла, *ярабби* (Ш.Камал).

«Йә раббым, укыған Қоръән айатым синең ыризалығың өчен булл---сын.

**Әстерхан сөйләшендә** дини мәҗлестә теләк теләгәндә әйтелә торган сүзләр:

*Йә раббым*, бер аллам, уқыған қорән айатым сәнең ыризалығың өчен булсын. Хәзрәте рәсүлебез Мөхәммәт пәйғамбәребез ыризалығы өчен булсын.

Шушы йортта тереклек итә торған бәндәләрнең барчасына хәйерле тазалық, хәйерле тынычлық бирсен.

*И, раббым*, бер аллам! Сораған бәндәлә ргә бирермен дигән wә ғъдәң бар. Уқыған доғаларым қабул булсын. Ошбу йорттан доға өмет иткәннәргә бағышладым, йорт хуҗаларығыз, нигез хуҗаларыгызға бағышладым.

## Йарлықау

**Йарлықау** — гафу итү, гөнаһларын йолу, аклау, кичерү.
«Йа раббыйым, бу сәтәкә биргән бәндәнең барча гөнаһларын йарлықа».

Йараббыйым *йарлықа*,
Дошманнарын тарлықа,
Барча гөнаһларын йарлықа — *әстр*.

Шөкер кылдым барлыкка
Төшерմәче тарлыкка.
Без гөнаһлы бәндәләрнең
Гөнаһларын йарлықа — *каз.ар*.

## Фәрештә, пәрештә

**Фәрештә** [фарсы.] — дини өйрәтмәләрдә: табигатьтән өстен зат, алла илчесе. Сөйләшләрдә: пәрештә, фирештә фонетик вариантлары да кулланыла.
— Пәрештәләр әйтмәк, бездән сорамақ:
«Динең кемдер?» — *бараба*.

**Уң жақтағы фәрештә, сул жақтағы фәрештә:**
Ике жағында ике фәрештәң бар.
**Уң жақтағы фәрештә** — жақшылығыңны жазып бара.
**Сул жақтағы фәрештә** — начарлық қылсаң, жазықларыңны жазып бара, ди.
Қолақ чыңлый икән, әйтергә ди:
«Уң фәрештәм — уңға жаз», — дип (керәшен).
(Самара өлкәсе. Урдалы авылы).

— Уң йақ фирештәләренә,
Сул йақ фирештәләренә бағышладым — *төм*.

— Күк пәрешт эләребестә, күк тәхетебескә, йете қат күкнең хәки---мебесгә тип туwа қылып алам.

Күккә қарап, аллаһымнан сорап, күк пәрештәләребесгә туwа қы---лып утырам.

— Ике иңемдәге ике *фирештәмә*,
Күктәге wә җирдәге *фирештәләремә*
дип әйтә йөрим — *минз*.

— **Дүрт мөгөштә дүрт фәрештә** булыр ди өстәлдә. Доға көтеп утырырлар ди алар. Доға уқымасалар, кимсенеп китәләр ди — *перм*.

— Йатқан урынына лампы қуйалар, лампы торады, ут йанып тора---ды. Қараңгы итмә йарамиды, фәрештәләр килеп торады, шуның өчен лампы йағып қуйалар.

Ғазраил — җан алучы фәрештә.

Картлыкның бер чиге җитә,
Хәбәр булып, Ғазраил килеп җитә.
Үлем килер үзебезгә,
Күренмичә күзебезгә.
Җан алучы фәрештәне
Күркәм күрсәт күзебезгә...

Микаил — гөнаһлы белән гөнаһсызны айыручы.
Җәбраил — пәйғамбәрләр белән аллаһы арасында сүз ташучы.
Ризуан — җәннәт сақчысы.
Зобани — тәмуқ сақчысы — *әстр*.

## Мөнкир-Нәнкир

**Мөнкир-Нәнкир** [гар.] кабердә сорау алучы фәрештәләр.
Фани дөнйа алдап йөртә
Қара җиргә, гүргә кертә.
Анда килер Мөнкир-Нәнкир
Рәхим қыйлсын үзе Аллаһ.

Йылама балам, йәшең түкмә
Айырылып миннән қалғанда.
Бер ходайым тел ачқычы бирсен
Мөнкир-Нәнкир җаwап алғанда.
(Мөнәҗәттән).
— Муллаға әйтепте:

«Мин үлгәц син минең қырымнан китмәң, чаwап биреп тор», тий---епте. Мулла йуғарыдан чаwап биреп утырыпты.

Мөнкир-нәнкирләр килепте сорау алғалы. Чаwаплама қуйғалы тийеш — *туб*.

Қабердә бездән сорамақлар:
«Рухың кемдә?» — дәмәк.
«Рухым алла тәғаләдә», — дәмәкмен. Пәрештәләр әйтмәк, бездән сорамақ:
«Динең кемдер?» «Динем ислам динедер», — дәмәкбез, созып әйтмәкбез —
*бараба*.

Караңгы гүрнең эче тар
Анда Мөнкир-Нәнкир бар (мөнәҗәттән).

Кабер эченә кергәчен
Килер ике фәрештә.
Исемнәре мөнкир-Нәнкир
Сөал булыр һәр эштә
«Раббың кем?» дийәләр,
«Динең нәдер?» дийәләр.
Пәйғамбәрең сорарлар,
Телем йомма, ходайым.
Раббым Алла, дисәмче,
Динем ислам, дисәмче.

Пәйƶамбәрем Мөхәммәт дип
Җаwап бирә белсәмче (Мөнәҗә т...)
(Самара өлкәсе, Гали авылы)

### Сорау алу фәрештәләре

— Дүрт кеше кабернең дүрт цитендә кала безнең. Алар пөтен йа---синны дүрткә бүлеп укилар, кат ып китәләр.

Алар китеп, кырк адым аwылга кат кац, сорау алу фәрештәләре килә, дир — *чпр*.

### Рәхмәт фәрештәләре

Кабергә төшергәндә әтәләр:

«Рәхмәт фәрештәләре каршы алсын,
Аwыр туфырагың йиңел булсын» — чпр.

## ҮЛГӘН КЕШЕНЕҢ ҖАНЫ ТУРЫНДАГЫ ЫШАНУЛАР

### Җан, рух

**Җан** [< фарсы.] — кешенең җаны, рухы.

*Йан* фонетик варианты мишәр диалекты сөйләшләрендә һәм *чан* себер диалектында кулланыла.

**Рух** [< гар.] — җан.

### Үленең «җанын озату»

Керәшен сөйләшләрендә: искә алу мәҗлесендә үленең «җанын озату».

— Келәүләр[1] беткәч үлене озатып җибәрәбез инде. Бер ике-өч кеше чыгып, «озатып» керәләр. Үле озатканда өч җыру җырларга тийеш.

«Безгә изгелек теләп китегез,
тыныч кына йатыгыз, зыйан китермәгез», —
дип озатып керәләр. «Китеп бардылар инде», — дип керәләр.

— Пуминкыда үлене озаталар бит ашап-эчеп бетерг әч. Өч-дүрт кеше җыйыласың да, өстәлдән әйберләреңне аласың, шул үленең уры---ныңдагы әйберләрне аласың ашаулык белән. Ите дә шунда, балыгы да шунда, бөтенесе шунда. Чыгасың да капка төбенә, иманнарыңны укып, җырлап, капканы ачып җибәрәсең дә озатасың җырлый---җырлый.

« Бакил, бакил, Ибан кийәү, китәсең бит, актык минутларың», — дип озаттык.

Берәр кат ашны чыгарып бетерәләр инде. Ашны чыгарганнан сун аннары сәгат җитә озатырга дисең дә, барың да кузгалып чыгасың. Урындыкка мендәр куйасың да ашшаулык җәйәсең. Шунда табикмәк куйасаң, балыгын да куйасың, күкәйен дә. «Затабыз инде, затабыз», дип кемнең чыгасы килә, шунда затырга чыга. Бар да килеп-килеп аwыз итәләр.

«Шул кеше туклыкта җөрсөн, очтомаг ашлары[2] булсын », — ди. Аннары капканы ачасың да койаш чыгышына карап озатып каласың артыннан, «бакилләп[3] кит», — дип. Кер әләр дә җырлап утыралар. (Мәҗлестә үзенчәлекле моңлы көй белән үлгән кешене искә алу һәм сагынуны чагылдырган эчтәлекле җырлар җырлана һ.б.)

[1] *Келәү* — теләк.
[2] *Очтомақ ашлары* — оҗмах ашлары.
[3] *Бакилләп* — бәхилләп.

Идел буйларының и лә р камышы,
Шаw-шаw итә анын ла таwышы ,
Башка туганнарыбыз бар да лар монда
Җуқ бит бертуганнарның таwышы.

Тирәзәдә төбемдә тук чикләwek,
Ашыйсым да килми лә туксынам,
Өйлә ргә дә керәм тышка чыгам,
Шул туганайымны да ла йуксынам.

Урман буйкайларын өч әйләндем
Тайанырга тайак тапмадым.
Җаннарыңа кереп сүләшер идем
Ишекләреңне лә тапмадым.
Зират җулы җуллар түгел
Миләш агачлары җуг икән.
Кайтыркай дип көткән идеек
Кайтыр өметләрең җуг икән.
Айу-бүре түгел күрергә
Гөл-тасмалар түгел үрергә.
Чыга-чыга карарларга
Җир йөзендә түгел күрергә.

Урындыкка мендәр куйып, табакка қоймак куйып тәберсе итәргә чыгалар.

«Урыны очтомакта булсын,
Туклыкта җөрсөн», —
ди-ди өйрәтәләр ийе инде әбиләр.

— Үленең җанын озатыш була. Аңа йаңа чиста кийемнәр әзерләнә. Озатқанда бөтен кийемнәрен: туфли, наски, чалбар, күлмәкләрен күтәреп чығалар, берсен дә қалдырмыйлар — *т.кам.-крш.*

Койаш чыгышына карап озаталар аны, игенче өйнең почмагына кадар.

— Үлене озатырга чыгабыз. Чокыр белә су алып чыгасың да аны багана башына куйасың. Табикмәк куйасын үзеңнең әйтмешеңне әйтеп. Теләгеңне телисең дә кереп китәсең инде.
«Ашагыз, эчегез, җөҗҗәшәгез», —
дип әйтте дип.
«Биг эрәкмәт тә биг эрәкмәт», — диләр инде — *т.кам.-крш.*

— Мендәрне түргә куйабыз, аның урыны шул була. Үлене сагы---нып килгән кешеләр йоморкасын, боткасын алып киләләр.

«Урыны очтомакта бусын,
Туклыкта җөрсөн», — дип — *т.кам.-крш.*
«Туклыкта булсын, ач йөрмәсен», — диләр.

— Ашаб-эчкис озатабыз, акитеп куйабыз. Ашамнык-эчемлеген шанда куйып калдырабыз энде, калагын, кимагын.

«Безнең кебек ашап-эч,
безнең кебек туклыкта бул,
очтомагында бул,
җакшы урын булсын», — дибез — *т.я.-крш.*

— Ашағанда өстәлнең бер почмағына аш белән қалақ қуйалар үлегә дип, чәй қуйалар. Аны соңыннан алмағач төбенә чығарып са---лалар.

«Святой Алла, Святой Тын» дип җырлап озатабыз үлене, урамда да шуны җырлап озаталар.

«Үзең җарлықа» дип әйтеп, чәчемнеккә[1] хәтле җырлап озаталар. Чәчемнектән үлемтеккә алып китәләр үлене — *т.кам.-крш.*

— Барысы да утыралар, ашыйлар, озатырға чығалар. Теге үлегә дип қуйған саwытны алалар, үле зату тастымалын алалар, өстәлне этеп қуйалар. Үле мендәрен, үлегә дип салган мендәрне алалар.

Ахирәттә алдыгызда булсын,
Туқ булығыз,
Кийаматлык дөнйагыз йакты булсын,
Йаткан җирегез йомошақ булсын,
Безгә тормышқа җүн биреп торыгыз,
Усаллардан, дошманнардан сақлағыз, —

дип әйтәләр дә керәләр.

«Бик сыйландық, бик рәхмәт», —

дип әйтеп киттеләр, дип керәләр. Кереп әзрәк утыралар, чәй бирәләр, қайтып китәләр — *т.кам.-крш.*

## Озату, урнаштыру

**Озату, урнаштыру** *т.я.-крш.* үленең «җанын озату».

— Озатканда мендәр белән, ат белән озаталар, урнаштыру, диләр — *т.я.-крш.*

**Озату** *чст.-крш.*:

— Үлене озатканда башта өч кимак пешерә, аннан соң биш, аннан соң җиде, аннан соң тугызны пешерә кимак.

**Үле җыруы җырлап озату** *крш.*:

Өч җыру җырларга тийеш. Теге дөнҗага барғач:

«Сиңа җырладылармы, жуқмы», — дип әйтерләр, ди.

[1] *Чәчәмнек* — зират янында ясалган чәчәүник; келәү итү урыны.

Җырламасалар:

«Син әйбәт кеше булмагансың икән», — дип әйтерләр, ди.

Ак тастымал элдем читәнгә
Җилфер-җилфер ит әргә.
Туганайыбыз җөри китәргә
Без белмибез никал итәрг ә — *чст.-крш.*
Базарларга барып ла сөлге алдым
Бәйрәм көннәрендә дә эләргә.
Безнең теләк менә шундый идее

Бергә йәшәп бергә үләргә.
Ишекләрне ачып ла түргә уздым
Түр тастымалларым чөйдә жуқ.
Туганайым кайда дип сорасагыз
Очтомакка китте өйдә жук.
Кара урманнарга кергән чакта
Күренепкәй калды кыр бите.
Сез туганым кайта дигәч
Булды очтомакның бер чите.
Бийекәй дә тауның башларында
Кыр кәзәсе кылган кимерә.
Син туганайларымны күрер өчен
Ике күзкәйләрем тилмерә.
Ары карасам да ары жук
Бире карасам да бире жук.
Кабер өсләренә кырпак төшкән
Жатып жыласам да жук — *т.кам.-крш.*

**Жаны сур мөгөзенә керә**

**Сур** [гар.] быргы. **Исрафил** — мәшһүр фәрештә.
Исрафил сурын өргәй,
Йә, Хәбибем, тор, дигәй (мөнәжәттән).

Қырығында соңғы мәртәбә өйөнә килер жаны дигәннә р. Шуңан сун сур мөгөзенә керә инде артаба. Қырық көндән сун сур мөгөзенә керә дей — *перм*.

— Бер йылға тике атна кич сайын кайта жаны. Бер йылдан суң **сур мөгөзенә керә**, тынычлана.
— Жан ул чыккан уңайына күккә аша. Шайтаннар күккә менә ал---маганнар ди.
— Әрwахның аның жаны исән. Жыл тулғанчы ике-өч көн алдан қорән уқытырға кушалар. Шуңанчы йамансулап жан килер икән ди. Жыл тулғанчы уқытсаң, жан сур мөгөзөнә керә ди, тынычлана ди. Жыл тулгач уқытсаң, жан һаман да урнашмыйча йөри икән ди — *минз*.

— Йыл wәғдәсендә сур мегезенэ кергэч жаны қайта алмас ди. Эшиткэн бар. Сур мегезенэ кергэч жаны қайта алмас ди. Эшиткэн бар. Сур мегезенэ кергэч, сорамый-эзлэмэй чықмайлар икэн — *нокр*.

**Жаны оча**

— Өче, жидесе, қырығы, йылы була. Жәй көне булса, ишекләрне ачып қуйалар. « Керсен» дип. Қырығына хәтле қайтып йөри ди жаны. Өченә хәтле гел китмәс ди.
Аннан инде «жаны очар», — диләр — *туб*.

**Жан күккә аша**

— Жан ул чыққан уңайына күккә аша. Шайтаннар күккә менә алмағаннар, ди — минз.

**Жаны ужмах таба оча:**
XIII йөз язма истәлеге «Кыйссаи Йосыф»та жаны очу турында (1983, 282):

Шәриф тәндин айырулды ғәзиз жаны, —
қушә бинзәб ужмах таба учар имди.

Изге тәннән аерылды газиз жаны, —
кошка охшап, оҗмах таба очар имди.

**Жаны бистәргә** (сөлгегә) **қунып тора, дип ышану** *крш.*:

— Үлгән кешенең *җаны* кырык көн *бистәргә* (сөлгегә) *куныып торор*, ди. Аның бистәрен элеп куйалар җаткан урыны җанына — *т.кам.-крш.*

**Җан күбәләге**

**Җан күб әләге** *каз.ар., т.кам.-крш.* үлгән кешенең җаны, ул күбәләк булып өйгә кайтып йөри дип сөйлиләр.

— Кырқына хәдәр көн дә қайта ул мәйет, кырқыннан сун кечат---на көнне генә қайта, қош булыпмы, күбәләк булыпмы. Өйартында очып җөри кечатна көнне күбәләк. И улым, син қайттыңмыни, мин дә қайтып киләм дип сөйләшеп кердем. Монаули-монаули гына очып җөри күбәләк. Бар инде, улым, қайтып җат дигәч очты да китте күбәләгем — *каз.ар.-лш.*

— Җыл тулғанчы қайта диләр күбәләк булып, қайтып матчада то---рор, ишег өстендә торор, морҗа буйында қучқарда торор ди — *бәр.*

**Үлекнекесе күбәләк**

**Үлекнекесе күбәләк** *глз.* үлгән кешенең җаны, имеш, күбәләк бу---лып очып кайта.

— Үлекнекесе күбәләк ул менә тәрәзәгә очып килә. «Кайткан инде бабамыгыз, кайткан инде әбийегез», — дип хайыр бирәсе була инде.

**Җанпапа**

**Җанпапа** [< гар. җан + удм. папа’кош’] *глз.* күбәләк, җан күбәләге. Ышанулар буенча ул үлгән кешенең җаны, күбәләк булып өйгә кай---тып йөри. **Папа** — удмурт телендә кош, кошчык.

— Җанпапаны бездә карчыклар эзге санайлар.

«Бабамыз кайткан», — дип, әбей садака бирмәгә әйтә иде.

**Папа**

**Папа** [*удм.*] глз. күбәләк.

— Кычатна кыннарны кила папа, кычатна сайын садака бирмага куша.

**Үлекләрнең папалары, үлек папа**

**Үлекләрнең папалары, үлек папа** *глз.* үлгән кешеләрнең җаны.

— «Үлекләрнең папалары килгән, хәйер көтеп килгәннәр», — дип әйткәлиләр иде.

Зур ич ул, очып килә. Тәрәз әгә килә, тә рәзәдән китә. «И, әбийебез килгән, хәйер өчен килгән», — дип әбиләр әйтерләр ийе.

— «Үлек папа керде өйгә», — дип аны үтермәгәннәр, чыгарып йибәргәннәр.

— «Үлек папа өйгә керсә: «кем ки кайта, хабар итә», — дип тә әйтәләр.

Менә ике үлек папа өйгә кермә тырыша. Байым (ирем) әйтә:

«Йибәрә се аларны, керсеннәр, кайтып керер оланнар», — ди.

Сарайда ике үлек папа очкалап йөриләр. Ике йегет кайтып керделәр өйгә. Берсе улым, берсе иптәше.

**Үлекнең аты**

— «Үлекнең аты килгән, үтермәгез, үлекнең аты ул», — дилир. Козыллы папа, козыллы күбилик килсэ — *глз.*

**Җаны қайта**

— Бер җылға тикле хәбердән өйгә қайта ди җаны, тәрәзәгә килер, нишләгәлләрен қарап торыр ди — *бәр*.

— Бер җылга хәтле көн сайын қайта, бер җылдан сун кече атна көнне генә қайта ди мәйет. Әвәле уша буйыннан[1] ике идәнне җуып қуйалар ыйы, мәйетләр килеп шунда торалар дип. Төштә күргәч тә мәйетне уша буйында торганын күрәләр — *т.я.-трх*.

— Җылы тулгынчык көн дә кайта мәйет, җылы тулгач кесе атна көнне қайта — *каз.ар.-дөб*.

— Йылна чақ кайтыр ди мәйет, йылында сыктап[2] китәр, ди, инде актык қайтуларым, тип — *перм*.

— Кырығына хәтле йаны килеп йөри диләр, тәрзәне қағып **чыпчық булып килә**, ти — *перм*.

— Мәйетнең җаны қайта ди қый, ызба түбәдә утыра ти — *перм*.
— Кечатна көн мәйетләр килә, *җаны* «Сез безне сагыныгыз», — диләр, дывадан туймилар — *т.я.-крш*.

— Җаны кайта дип сүләйләр корок көнгә хәтле. Кучаг астына[3] йөри икән кечатна көннәрне — *глз*.

[1] *Уша буйы* — моржа буе.
[2] *Сықтап* — елап.
[3] *Кучак асты* — тәрәзә асты.

— «Җаны кайткан», — дийәләр. Өйдә очып йөрә **күбәләк** тәрәзәгә утырды, очып йөрә.

«Әйдә, кер, кер, аш итәм», — мин әйтәмен — *глз*.
— Кечатна көнне кич кайталар, җомга көнне ахшамда китәләр үз җулларына. Садака тапканы куанышып китәр, ә тапмаганы бик моңайып китәр.

— Кечатна, йомга укытма кушалар үлгән кешеләр өчөн — *глз*.
— Үлгән кешенең кабер өстөннән китерәсе була балчыгын. Ул бал---чыкны китереп, монда Кистем зиратка күмәсе була. Җаны монда кай---та дилир — *глз*.

**Мәйетнең җаны кайту турында ышанулар** — Урта Урал (*к.-уф.*) сөйләшендә:

— Әтнәкөн[1] хәйер бирегә дей, мәйетләр өсөн. Әтнәкөнне ике ғәйеттән артық булыр тиләр — *к.-уф*.

— Мәйет килеп йөри дей ул, төшенә дә инә — *к.-уф*.
— **Мылтықлар** белән аттыралар — *к.-уф*.
— Тупсаға **дағa** қақтыралар — *к.-уф*.
— **Артыш** җимешләрен асып җыйалар — *к.-уф*.
— Шул бер кешенең мәйете биш җыл қайтып йөргән. Арта қайтмый башлады дей.

— Ул кеше *дағаны* ишекнең тупсасына қақтырған. Ул йаңа дağa түгел дей. Атның айағыннан тузып, төшеп қалған булсын дей. Шунан беткән — *к.-уф*.

Мәҗлестә сүләгәннәрен үзем ишеттем. Тәрәзә төбеңне атна кич көнне бисмилла әйтеп сөртеп ал, мин үзем генә килмим, без күп киләбез, дип төшенә кергән. Ул хәзер үлде инде ул қатын, аның сүләгәне минең исемдә қалды. Мин кешегә әйтәм шулай дип.

— Йылына чақ қайтыр ди мәйет, йылында сықтап китәр ди, инде ақтық қайтуларым тип.

— Қырығына хәтле йаны килеп йөри диләр, тәрзәне қағып **чыпчық булып килә** ди.

— Мәйетнең **жаны қайта** ди қый, **ызба түбәдә** утыра ди.

**Йаны кат′а**

**Йаны кат′а** *чпр.*:

[1] *Әтнәкөн* — пәнжешәмбе.

— Кешенең йаны цыгып йөри ала дир. Кат’алар. Менә күбәләк бу---лып кат’алар.

«Алар күктә дә түгел,
йирдә дә түгел,
йир белән күк арасында», — дир.

Кешеләрнең йаннары үлми, цыгып-китеп йөри алалар. Баралар, кат›алар.
**Кецатна көнне йаны кат′а** *чпр.*:
— Кецатна көнне мәйетләр ката дир, ул мәйетләр көне була дир.
Кецатна көнне кимак пешерә дә өләшеп йөри иде әби. «**Мәйетләр көне** бүген», — дип.
Баш көнне дә йакшы диләр мәйетләргә.
**Кече атна көне қайта, уша буйында тора** *минз.*:

— Бер жылга хәтле көн сайын қайта, бер жылдан сун кече атна көнне генә қайта ди мәйет. Әwәле уша буйыннан ике идәнне жуwып қуйалар ыйы. Мәйетләр килеп шунда торалар ди. Төштә күргәч тә мәйетнең уша буйында торғанын күрәләр.

**Үлгән кешенең жаны турындагы ышанулар** — себер диалектларында:

— Пер йылғаса алғасап[1] йата ти үлгән кеше. «Қайтам өйөмә», — тийеп. Үрәнмәй ти.

— Йаны қайта. Pawан йан йыл қатымын уқытқанча үзен үлгәнгә исәпләми ти.

Зинһар әйтәм балам , уқыт корән
Иң газизем син бит, бәбкәйем.
Атна кич житкәч **йаным қайтыр**
**Ақ күбәләк булып**, бәбкәйем — *том.*

**Гөнаһлы кешенең жаны**

**Гөнаһлы кешенең жаны, имеш, убыр булып чыгып йөри** *минз.*:
— Гөнаһлы кешенең жаны, имеш, қаберне тишеп чығып йөри, убырға әйләнә. Элек гел әйтәләр ийе.

— Зиратта тишек булған, чығып йөргәннәр убыр булып.

Жаны убыр булып чығып йөрмәсен дип **имән қаdық** қағып қуйалар ул қабергә.

[1] *Алғасап* — ямансылап.

**Жан сәдәкәсе**

**Жан сәдәкәсе** *әстр.* далага чыгып, корбан чалып теләк мәжлесе ясау.

— Аw ыл қартлары эстипкә чығып ашап доға қыла доған иделәр. Аны жан сәдәқәсе диделәр.

**Жанын ашату**

**Җанын ашату** *м.-кар.* үлгән кешенең җаны ашасын дип тәре алды---на ашамлыклар кую.

— Су, икмәк, кашык куйалар үлдүкләргә тәре алдына, ул аши була инде, «җанын ашату» ди’ләр. Алты атнасы тулгынчы тора ул. «Алты атнасында урынга урнаша» — ди’ләр, алты атнасына хәдәр, кайа ул булган тере вагытында, шул җирләрдә җеретә’ләр аны. Алты атнасы тулгач, кырк кене узгач урынга куйа’лар, килеп тормый, ашами, эчми аннары. Кырк кенгә тәре (кадәр) җаны җери була инде.

## Җанын чақыру, җанын озату

**Җанын чакыру, җанын озату** *крш.* искә алу көннәрендә үлгән кешенең җанын зиратка барып «чакырып кайту» һәм мәҗлес беткәч «озатып җибәрү».

— Қырқына безнең авылда сарык суйабыз, тәбикмәк пешерәбез, кичкегә чақырыға барабыз зиратқа. Җанын чақырып қайтабыз. «Әйдәгез безнең белән, синең азаққы ашынны үткәрәбез», — дип чақырып қайтабыз. Җыйылғачын шәм җандырабыз, аш утыртабыз, оло кешегә сыра пешерәбез. Килгән кеше җоморқа алып килә, тәбикмәк. Үлгән кешегә урынны пич җанында қуйалар, киштәгә тастымалын элә, урындыққа әйбер җәйәләр, шунда утыра, диләр. Таң атқанда бытқа пешерәләр, өстәл өстенә анын өчен дип бер қоштабақ, бер қашық қуйалар, җырлап озаталар — *т.кам.-крш.*

— Ат җигеп зиратка баралар, әдә кайт, без сине сагынабыз беген ди. Анда мендәр куйа ат эстенә, мазарга бара да әтә: «әдә утыр, кайт безен белән». Мазарда шәм җандыралар, сагынып түгәләр. Ашаб-эч---кис озаталар — *т.я.-крш.*

— Мазарга[1] эчәүләп барып дәшмәлле. Мендәр белән китәләр, мендәр белән кат алар. Ул шында мендәр эстендә утырып тыра, ди.

— Өчендә, җидесендә капкадан чыгып өч тапкыр кычкырабыз:
«Безнең кат ка ашарга-эчәргә кат›!» — дибез — *т.я.-крш.*

— Пумилкәсендә[2], кырк кенендә мазар эстенә барып дәшмәлле, иртүк тороп өчәүләп барып дәшмәлле. «Әдә, кырк көнең беген», — дип мендәр белән китәләр зиратка да мендәр белән кат›алар — *т.я.-крш.*

— Мендәрне алып кат алар да эстәл пычмагына куйалар, мендәр өстенә утырып тора диләр энде аны — *т.я.-крш.*

— Ат җигеп зиратка баралар, әйдә кайт, без сине сагынабыз беген, ди. Анда мендәр куйа ат эстенә, мазарга бара да әйтә, әйдә утыр, кайт безен белә. Мазарда шәм җандыралар, сагынып түгәләр — *т.я.-крш.*

— Кайтты энде диләр, мендәрне кычаклап керәләр дә, күтәреп пычмакка куйалар. Бер кашык куйа, бер саwыт куйа. Сыра эчә, «Микаилгә туклык булсын», — дип. Ашап эчәләр. Сагыналар[3] да энде, әйдә, илтеп куйабыз сине ди, китәләр. Мендәрне күтәрә, ылауга куйалар, илтеп куйалар мазар эскә[4] — *т.я.-крш.*

— Җылында да шулай уздыралар. Ишектән чыгалар да: Микаил, кайт, беген сине сагынып ашибыз, — диләр. Керәбез, ашибыз, эчәбез. Ашамлыкларны саwытка салабыз да чыгарып кеше йермәгән җиргә салабыз.

«Менә, үлгән мәндәләр,
Шуны ашап-эчеп китегез,
Икенче безне аптыратып җермәгез,
Үзегез җул белән үзегез җерегез», —
диләр — *т.я.-крш.*

— Аш пешерәбез дә аш пешкәчен зиратка менәбез, анда чакырып кайтабыз инде.

«Әйдә, бүген синең ашың», — дип — *т.я.-крш.*

[1] *Мазар* — зират.
[2] *Пумилкә* [рус. поминки] — үлгән кешене искә алу көне.
[3] *Сагына* — искә ала.
[4] *Мазар эс* — зират өсте.

— Үле ашы иткәндә, олы кеше үлсә сарық суйалар, зиратқа чақырырға баралар.

Мин менә бақча башына чығып қына чақырдым:
«Ашыңны үткәрәбез, қайт», — дийеп.

Аш иткәндә айырым тәлинкәгә ашау қуйасың, қашық қуйасың.
Қалған ашларны қошларға чығарабыз — *каз.ар.-крш.*

— Үле ашын үткәргәндә зиратқа барып чақырабыз. Өч кеше бара---быз. Ипиләр алып барабыз, су, чәй, ризықлар.
«Сине алырға килдек, бүген синең ашың».
«Туғаннар, тумачалар, барығыз да өйгә қайтығыз», — дип.
Үле өчөн дип тәлинкәсен, қашығын қуйалар, ашамлығын салалар.
«Аның өлеше» — дип.
Ул ашамлықны суынтын малға салалар — *каз.ар.-крш.*

— Қырығында, җыллығында зиратқа барып қаберне өч тапқыр әйләнәбез:

«Атаның, улның ,
Святой Тынның исеменә амин,
Әрберегез қайтығыз», —
дип чақырабыз инде.

— Үлекне күмеп қайтабыз да икенче көнне иртән қойаш чыққанчы барып қайтабыз.

Сәләм илтәбез, сәләм алып қайтабыз қойаш чыққанчы. Қойаш чыққанчы барырға кирәк, зират қапқасыннан чығарға кирәк.

Менә иртән иртүк үзем барып қайттым, шушылай пинжәгемне җабындым да сыпырдым гына зиратқа, чақырып қайттым, сәләм илтеп қайттым.
Җаңа үлгән кешене шулай барып чақырырға кирәк.

— Күмеп қайталар да икенче көнне иртәнге қойаш чыққынчы **чақырып қайталар**. Өчесендә, җидесендә, қырығында баралар. Утыз сигез, җә утыз туғыз көннән баралар.

Йәкшәмбе көнне барырға йарамый, ул — теләк көне.
Йәкшәмбегә туры килсә, бармыйлар.

«Әйдә, сине алырға килдек, сине искә алабыз», — дип таң белән барабыз — *т.кам.-крш.*
— Чақырырға барғач әйтәбез:
«Әйдәгез, қайтайық, сезне алырға килдек. Сезнең бәйрәмегезне үткәрәбез, сезне искә алабыз», — дип.
Чақырырға барабыз да қабер өстенә ипи қуйабыз.
«Инәйләр, әтәйләр, бабайлар, әбиләр, барығыз да қайтығыз, сезне алырға килдек», — дип шәм җандырабыз.

Элегрәк үзебез җасайдырыйық шәмне балаwыз белән, ғөрләп җана.

— Чақырырға барғанда камфит-мазарларны баш өстенә қабер өстенә қуйып қалдырабыз:

«Менә, күчтәнәчләр белән килдек сезгә, қабул итеп алығыз».
Өчесендә, җидесендә дә чақырабыз.

Чақырырға барғанда да уртаға мендәр қуйып, җыйылып, җырлый---җырлый бара торған ыйық. Элек инәйләр урам тутырып җырлап йөрерләр ийе.

— Кичтән үк чақырып қайтабыз да **мунчалар йағып** торабыз әле чақырып қайтуға.

«Мучаға барайық», — дип мучаға чақырабыз. Чиста, йаңа пин---некләр қуйабыз чайқап әйбәтләп. Қайын себерке инде.
«Чабынығыз», — дип — *т.кам.-крш.*
Зираттан қунаққа чақырабыз да муча йағабыз, чәй утыртабыз, аш утыртабыз үлегә.
Иртән тәбикмәк пешерәбез.

— Өчесендә өч тапқыр әйләнәбез қаберен.
«Әйдә, синең бәйрәмең, қайт», — дибез.

Җидесендә дә шулай җиде тапқыр әйләнәбез қаберен.
Зиратқа барып чақырып қайтабыз:

«Сезне чақырырға килдек,
Бүген сезнең қырық көнегез,
Бар туған-тумачаны,
Қода-қодағыйларны үзегез белән бергә чақыр, қайтығыз», —
дисен — *каз.ар.-крш.*
**Симек бәйрәме, җафрақ бәйрәме көнне үлеләрне чакыру** *т.кам.-крш.*:
— Симек бәйрәме, җафрақ бәйрәме җитте. «Әйдәгез, безгә қунақ---қа», — дип чақырып қайтабыз. Ипи илтәбез қаберенә, ипи илтеп қайтабыз.
«Нәсел-ырулар, қайтығыз», — дип.

— Иртәгә симек диг ән көнне барабыз зийаратқа, чақырып қайтабыз. Зийаратқа күбрәк мин барам, әби өйдә пешеренеп, әзерләп тора.

Олы бәйрәмдә дә чақырып қайтабыз, олы көндә дә. Иртән үк шәмнәр җандырып, мунча йағып қуйабыз.

## Йола

**Йола** *төм.*, *туб.* кешенең рухы, җаны. Ул кеше үлгәнче үк чыгып, күренеп йөри, имеш. «Йола» сүзе төрки халыкларда җан белән рухны билгеләгән «рух», «тын», «кот» мәгънәләрен дә аңлаткан булса кирәк. Димәк, «йола» төшенчәсе борынгы төрки телдә киң мәгънәле, универсаль төшенчә формасында яшәгән бер уртак сүз вазифасын үтәгәндер дип фараз ителә (Абдулкадир И., 1998, 12).

### Йола — кешенең үзенә ошаган була

— Күремце[1] булған ул қарт. Йола да күргән ул.

«Йолаң цыққан», — тиде. Йола ул үсеңә ошаған нәрсә була, тиде, үсеңә ошап йөри, тиде. Үсеңнән цығып китеп, аны геше күрәйткән ите. Минең әкәм[2] күремце булатқан ите (Тобылтура).

### Үләсе кешенең йоласы күренә

— Мин йоланы үс күсем белән күртем тис әм дә була. Былтыр ғына шал бақчамда кәртүк сабақлары [3] йантырып йөрим. Перәү килә теге йақтан, әкерен генә атлап килә. Қарайым инте әллә кем килә, тип. Утны сүндермәг әч кереп китеп булмый, уттан қурқам. Күр әмен инде, перәү килә теге йақтан. Килде-килде дә қурасына[4] кереп китте пы. Қурасына кереп китте, өйенә кермәде, йуқ булды. Иртә белән

торуға бер кеше үлте. Шаның йоласы булған икән. Үсе айақлы, килеп утыра. Күршегә әйтәм: «Син күрдеңме берәйен?» — тим. «Йуқ», — тийә. Мин аман инде утны сүндереп кереп киттем. Йола булған ул. Кеше үләсе булса, йоласы күренә икән аның.

[1] *Күремце* — күрәзәче.
[2] *Әкәм* — абыем.
[3] *Кәртүк сабағы* — б әрәңге сабағы.
[4] *Қура* — ишек алды.

— Ғомереңдә бер күрерсең. Күргән wақытта ул сиңа ғомеренең соңғы йағы булса — төштән соң күренер, ә осақламый үлә торған булса, киц алдында күренер. Ә ақшам wақытында булса — аwырып йатып алыр. Әгәр дә иртәнгелек иртән күренәткән булса, ул тис үләткән кеше булаты.

### Йола белән гәпләшү йарамайты

— Йола белән гәпләшү йарамайты, тамақ қырып керү гәрәк. Гәпләшсәң, ул сиңә төгерер, синең ғомерең қысқарыр, тиде.

### Йоланы ошлағалы (тотып карарга) йарамайты

— Менә синең гәүдәң йөри ти, битең син, синең йолаң йөрите. Түлке ул гәпләшмәс. Батыр геше булып болай ошлағалы иткән булса, ул геше буылаты, ул геше булмайты. Менә берәү үлеп қуйты йәшләй генә. Ул аның йоласын геше дип белгән, әрwақ дип белмәгән, аралашқан тусы тип белгән. Ул тусы булмаған, аның йоласы йөргән, гәүдәсе, сурәте. Син аны болай итеп ошласаң — ул йуқ. Менә кичкелек күләгә күренәткән. Йола ул шантай нәрсә.

### Йоланы күргән кеше үләте

— Кешенең йоласын аwылта сеңлем гүргән. Қасаннық тәрәсәсенә[1] барған та тәрәсәгә қапланған, тиде. Йола йөреп утыраты. Кешенең йоласын гүрү йарамайты. Күрше малайның ап-ақ йоласын гүртем, арты белән тораты. Сырасы үлеп қуйты бағырцық[2].

### Йоланы пау белән бәйләп куйалар

— Йоланы пау белән бәйләп қуйалар игән осақ йөреп китсә. Аны бәйләп қуйатылар игән күреп. Перәр йаманлық уйлап, тис үлсен пы геше тип бәйләп қуйатылар булыр.

[1] *Қасаннық тә рәсәсе* — казан өе, кухня тәрәзәсе.
[2] *Бағырцық* — бәгырькәй.

Йола ул йаманлыққа йөреми, йақшылыққа, шатлыққа йөри игән. Перәү қайғырып китсә, йоласы чығып китә тиг ән. Аны күргән кеше бәйләп қуйа тигән. Үлмәйен осақ йөресә, аны кисәтеләр тигән (Тобылтура).

### Йола — кеше үзе йөргән җирләрне йөреп бетерә

— Менә шул йола синең йөргән йирләреңне йөреп бетерә икән. Шуннан суң ғына үлә икән кеше. Менә мин мөкцийәләр[1] йийып йөрдем, йылым тартып йөрдем. Минем йолам шуларны йөреп бетермиче үлмим игән мин. Менә шул йоласы ул йөргән йирләрне йөреп бетергәч кенә үлә игән кеше.

### Йола — ак булып, кәбеннектән (кәфенлектән) күренсә, кеше үлә

— Үсеңнең йолан ул үс төсең белән була икән, түлке әйбәт булмый, йәмсес генә була икән. Кәбеннек[2] белән күрсәң, ақ кийемнән күрсәң, тис үлә икән, ғомере бетеп күренә икән. Аны күрүчеләр бар. Ул менә ғомере бетеп кәбенгә кергән кешенеке ақ булып күренә икән, ә инде кәбенгә кермәгән кешенеке үс кийеме белән күренә икән.

«Кәбенгә кереп[3] қуйты йоласы, бер-ике көннән қалмас, үлә р», — тиде. «Күртем, менә ап-ақ булып кәбенгә кереп қалған», — тиде, «йоласы йөри», — тиде. «Пер-ике көннән Латип қарт үләте», — тиде (Матуши).

**Йола тунныңтан (кәфенлектән) күренсә, кеше үлә**

— Тунныққа[4] гереп қуйыпты йоласы, ап-ақ туннық, осақ қалмас, тиделәр. Әллә ниләр күреп гәпләйсең.

Қара туннық кийеп қуйса, үләте тиделәр — *төм*.

— Тунныққа кереп қуйты йоласы, тиде, қапқа итәгентә пағанға сөйәлеп йиргә қарап тораты. Қаратан туннық кигән, осақ тормас. И-и, әллә киләр кәплисең[5], тиде. Қаратан туннық кийеп, башына бәйләсә дә үлә тиделәр. «Инәкәү[6], йоласын күрдем», — тиде. Қанчабыр (ав. ис.) муллаға барып киләйен, петерсен синең алай йола күрүеңне. Өшкергән ул мулла.

[1] *Мөкцийә* — мүк җиләге.
[2] *Кәбеннек* — кәфенлек.
[3] *Кәбенгә керү* — кәфен белән уралу.
[4] *Туннық* — кәфенлек.
[5] *Кәпли* — сөйли.
[6] *Инәкәү* — әни.

— Йоланы аны ақ кийеме белән дә күрәләр. Тис үләткән геше ақ кийеме белән күренә икән. Ақ кийемнән булса — тунныгы була инте. Йола дип әйтәтеләр, әрwақ тип тә әйтәтеләр. Алла тәләм сиңа гүрсәтер, курықма.

**Йола — кешенең үз киеменнән күренсә, кеше озак яши**

— Менә минең ошо[1] қарт Тимерғали әкәне толыбы белән гүргән. Толыбын кийеп өй итәгенә[2] килеп утырған булған йоласы. Пы инде қурығып тисерәк өйөнә кереп киткән. Тимерғали әкә бик осақ йәшәте. Толыбы белән, әлеге қышқы туны[3] белән гүрг ән. Йонны тиреләрдән йасалған тун ул толып. Ул қурығып кергән дә әйткән: «Инә[4], шулай---шулай йоласын күрдем Тимерғали әкәнең, өй қураға[5] сөйәлеп утырып қуйған», — тиде. Үс кийеме белән күрсәң, осақ йәши икән кеше. Ә инде кибеннеге[6] белән күрсәң, тис үлә икән кеше. Кешенең йоласы чықса, кеше осақ аурап йөри икән.

**Чыккан йоланы кире кертә торган кешеләр, тамырчылар булган**

— Менә мин тың аwырған[7], минең йолам чыққан булған. Йолам чығып, хәлем бетеп аwырып йөргән. Тамырчы[8] минең қул тамырымны ошлап[9]:

[1] *Ошо* — кебек.
[2] *Өй итәге* — өй яны.
[3] *Қышқы тун* — кышкы кием.
[4] *Инә* — әни.
[5] *Өй қура* — өй киртәсе.
[6] *Кибеннек* — кәфенлек.
[7] *Тың аwырған* — каты авырган.
[8] *Тамырчы* — тамырны тотып карап авыруны белүче, имче.
[9] *Ошлап* — тотып.

«И-и, Майра, синең йолаң чыққан, синең йолаңны кертқәле ки---рәк», — тиде.

«Менә мин аны сиңә қыwып апкилермен, күрсәм йолаңны. Син йатырсың, мин сиңә итәгеңә апкереп салырым», — тиде.

Менә шул wақытта мин урынға йаттым, урын ул қасанча сәке инде. Ул аны шулай:

«Әйтә, кер, кер, қайта йорисең, әйтә кер», — тип миңә апкереп салты шул йоламны. Чыққан булған. Йолам чығып, мин аwырып йөргән булған. Ул йола чықса, көче бетә икән кешенең. Шул Шәмши әби йоланы кертеп салган. Мин рәхәтләнеп кийерелеп йибәрдем, тирләп йибәрдем.

Миңә әйтә:

«Йә, килтеме йолаң йаныңа, кертеме, ничек булып китте?»

Мин әйтәм:

«Менә рәхәт булып китте, кийерелеп йибәрдем. Әмән тәнемә әллә нимә килеп суғылған шигелле булды».

Шулай менә кешегә йоласы керсә, сыw ық қына булып қағылып китә икән, тәне йасылып китә икән. Менә шул Шәмшүк[1] қортқайақ алып кереп салган минем йоламны (Матуши).

## Йоланы ақ малға урап алып килеп салалар

— «Йоласы цығып китсә, ул йоланы кергесә торған кеше булса, пе---рас йәшәйсең, төсәләсең, тиде. Ул цығып китсә инте, йоласын ақ малға[2] урап алып киләтләр йанына», — тиде. Ул йоланы кергесмәсәләр, көцем петәте тип әйтеп, аwыруға салышып үлеп китәте. Кешенең йоласына үсем дә очораган мин.

— Йоласы цығып китепте тип әйтәтеләр. Ул йола күренепте. Күрүцеләр булған, пеләтеләр.

Аның йоласын аwырған кеше йанына алып килеп салғаннар ақ нимәгә[3] урап. Ул аwырған кеше өшеп китәте йоласын алып килеп салсалар.

«Син қыймылтамаң, тыныц қына йатың» тигәннәр.

Шының йоласы кире керә ти. — (Тобылтура).

[1] *Шәмшүк* — Шәмсия.
[2] *Ақ мал* — ак тукыма.
[3] *Ақ нимә* — ак әйбер.

## Ақтан кийенгән нәмә

**Ақ нәмә, ақтан кийенгән нәмә** *минз*. күзгә күренә торган мифоло---гик персонаж, үлгән кешенең актан киенгән рухы.

— Бабайларның ишегалдына килгән бит оdон ғына, ақтан кийенгән нәмәләр. Алар dират қырыйындайы. Шулар dираттан килеп, тағын dиратқа кереп киткән.

Оdон ғына, ақтан кийенгән нәмә килде, бер нәмәкәй әйтмәде.

— Үмәнәйне чыққачтын да тегермәннән қайтучылар адаша торған ыйы. Тарлау дигән җир ул, **адаштыра**.

Дираттан бер **ақ нәмә** чыға тип әйтәләр ийе. Атны туқтаталар ди. Арқылы салайық, буйға салайық чананы, диләр.

Тиd генә атқа суғып чаптық диләр.

— Миңа бер ақ нимә утырып килде, атым атламай диде. Суғам, суғам, ат бармай, дийе.

Мин сүгенгәчтен ат тартып алып китте. Теге ақ нәмә төшеп қалды — *минз*.

## Рух

**Рух** < гар. җан.

## Үлгән кешенең рухы

**Урта Урал сөйләшләрендә**:

— Җидесе үткәнче үленең рухы **өйнең тыкырыгында** торор, дигән.

— Өйдә ни хәл булганлыгын тары бөртегенә хәдәре белә ди үле, үзе үлсә дә бөтен нийәте килеп тора, йөзенә хәтле җаны кайта икән.

— Үләр чағында кешенең рухы чығып китте. Құргән кеше күрәте, күрмәгән кеше тawышын эшитәде. **Черкәй**[1] булып, **күбәләк булып** күренәте рухы — *к.-уф*.

## Рухлар килә

**Себер, Урта Урал, әстерхан сөйләшләрендә**:

— Кырқ көнгәцә рухы килеп тораты. Шәмне йағып қуйасың қырқ көнгәцә. Қараңгыга килмәсен — *себ*.

[1] *Черкәй* — черки.

— Ишек суғылаты, руғы килеп китәте. Кеше үләр алдыннан ишег ацылып китәте. Ишекне йапқалы уғынып, артың ман барғалы кәрәк. Иртән ишетәсең, ул кеше үлгән — *тара*.

— Үлгән кешенең рухы бер йыл йөри, тәрәсәгә дә килә. Ул үсенә йақшы урын эсли. Ишегең ацық булса өйгә дә керәте.

**Рухлар черкәй (черки), күбәләк булып күренәләр, кош булып та киләләр**:

— Пасқарақка[1] чыгып утырам. Қош булып киләте, черкәй, күбәләк булып киләтеләр рухлар, өйгә дә керәтеләр — *бараба*.

**Пәйшәмбе (пәнҗешәмбе) көнне рухлар килә**:

— Пәйшәмбе сайын аш бешереп, қатым уғытып утырғаннар, йес цығарғаннар, қоймақ қойоп утырғаннар. Пәйшәмбе көнне рухлар киләте. Йылына хәтле қатым уғытып торғаннар — *тара*.

**Атна кич көнне рухлар килә** *к.-уф*.:

— Тәрәзә төбеңне атна кич көнне бисмилла әйтеп сөртеп ал. Мин үзем генә килмим, без күп киләбез дип төшенә кергән — *к.-уф*.

**Кече йома көн (пәнҗешәмбе) рухлар килә**:

— Кече йома көн рухлар килә дип уқыйсың, баwырсақ пешерәсең, ис чығарасың — *әстр*.

**Рухлар хәйер көтә**:

— Рухлар киләте, хәйер көтәтеләр. Хәйер бирсәң, сөйөнәтеләр.

«Бүләк алып килтем», —

тип бер-беренә өләшәтеләр.

**Рухлар тирәс башта тора**:

— Қатым уғығанда рухлары тирәс башта[2] тораты тиделәр — *туб*.

## Орық

**Орық** [гар.] җан, рух.

— Қатым ашта орықларны искә алып хәйер өлиләр[3].

Әткәм-әнкәмнең орықларына,
Кецегәләрем[4] орықларына,
Йир кучасы куча Баwетдин орығына,
Өч йөз алтмыш алты әүлийә орықларына,
Йете қыс әүлийәләр орықларына — *туб*.

[1] *Пасқарақ* — баскыч башы.

[2] *Тирәс баш* — тәрә зә башы.
[3] *Хәйер өли* — хәер өләшә.
[4] *Кецегәләр* — үзеннән кечеләр.

## «Рухлар килсә» ырымнар башкару

### *Қаберенә қазық қагалар*

Үлгән кешенең рухы килеп торат диде гуй.

Каберенең баш йагына казык кагасың, ырым инде ул өлкәннәрнең. Нинди тирәктән булса да йарый казык — *әстр*.

**Кече йома (атнакич) корънне уқыталар**:

— Кече йома коранын укытып, нийазын биреп, каберенә барып әйт диде.

«Син ни затка мага риза булмайсың. Мин синең кораннарыңны укытып йатырмын, садакаңны биреп йатырмын, кече йома кора---нын укытып йатырмын», — дип әйт диде. «Икенче көнне иртә белән кайнаган су кой бусагаңа», — диде.

Шуннан суң килми, сирәкләнде диде, анда-санда бер генә төшкә инә, диде — *әстр*.

— Төшеңә инә бирә үлек, нийаз күтәрәсең, кечки җома көнне ис чығарамыз.

«Ни кирәк саға? Мин саға коран уқытып йатырым», — дип шамғанмаға[1] кирәк. Шунда ул инми төшкә, ди — *әстр*.

## Әрwах

**Әрwах** [гар.] үлгән кешеләрнең һәм аларның җаны, рухы турында әйтелә.

— Кечатна[2] көнне доға қылам бөтөн әрwахларға, тушы китапларым---ны уқыйм. Кечатна көнне әрwахлар қайталар, йомаға[3] көнне өйләдән сун китәләр икән ди абыстай әйтә. Йомаға көнне сәдәхә бирәләр — *бәр*.

— Әрwахлар кечатна көнне, җома[4] көнне киләләр. Хәйереңне бирәсең икән қан көнне[5] бирәсең инде — *перм*.

[1] *Шамғанмаға* — ачуланырга.
[2] *Кечатна* — пәнҗешәмбе.
[3] *Йомаға* — җомга.
[4] *Җома* — җомга.
[5] *Қан көн* — чәршәмбе.

— Әрwахлар әнә қый, уқу барып җитмәдисә киләләр ди алар. Қан көн, этнә кич[1] уқымаға кәрәк әрwахларға. Белгәннәрне уқыйбыз, хәйер-садақа да бирәбез — *перм*.

**Җәмғый әрwахлар** < җәмгъ [< гар.] барлык, бөтенесе, ягъни барлык әрвахлар, барлык рухлар.

Хәзрәт, әрвахлар рухына берәр аять рәхим итегез (М.Гафури). Без, зыяратка барып, әрвахларга, мәетләргә коръән укып багышладык (М.Гали).

### Әрwахлар рухына бағышлау

— Мәйетне алып киткәч, хатын-қызлар җыйылып керәбез дә, белгәннәребезне уқып, әрwахның рухына бағышлап доға қылабыз, мәйетләргә, үзебезнең әрwахларга доға қылабыз:

Нигезләре таралмыш,
Исемнәре йуғалмыш булған,

Доғаға мохтаҗ булып йатқан
Әрwахларыбызға бағышладым.
Йарабби, уқыған доғаларыбыз кабул булсын, — дибез — *минз*.
Шушы искә алынған әрwахларыбызның,
Бездән доға өмет иткән туған-қардәшләребезнең,
Үзләренең хозурына барған дөнйалықта,
Бәндәчелектә белеп қылған, Белми қылған гөнаһларын,
Хаталарын, кимчелекләрен үзең йарлықа,
Бездән барчабыздан да разый қыл, йарабби.
Җәмғый әрwахларға, артында берәү дә булмаған
Әрwахларға да бағышлыйм,
Бездән разый булсыннар — *әстр*.
Уқыған айәтләремнең
Әҗер сажапларын
Миннән өмет иткән
Әрwахларға ирештергәй идең,
Аларның рухларын
Үзең шатландырғай идең, йарабби — *перм*.

[1] *Әтнә кич* — пәнҗешәмбе.

## Себер диалектларында әрwахлар

### *Қабердәге әрwахлар*

Кабер тигән мәкәй сарай
Ишеге йук ачып пулмай.
Кабердәге *әрwахларның*
Ич хәлләрен пелеп пулмай — *бараба*.

### *Әрwахларға йес (ис) чығару*

— Қатым ашта:
«Әрwахлар, рухлар йеснәгәле тейеш».
«Йес чықсын», —
дигән сүз булаты. Қоймақ қойатлар, бажырсақ пешерәтләр — *төм*.

### *Әрwахларны искә алу*

— Менә бөтен әрwахларны да искә алып, нәнәүнең[1] йылын уқытып йатам — *том*.

— Пәйшәмбе кичтә әрwахларны искә алып, әрwахларға Қоръән чығып алам — *төм*.

### *Әрwахларға сәләм бирү*

— Қырбашқа қырық адым йитмәйен сәлам биргәле кирәк әрwахларға.
«Әссәләмәғаләйкем, көлле әрwахлар» — *туб*.

### *Әрwахлар өстенә су қойғалы*

— Йаңғыр йаумаса зиратқа су ташыйбыз, әрwахлар өстенә су қойғалы.
«Бәрәкәтле йамғырлар бир», — дип теләдек — *туб*.

### *Әрwахлар йөри*

— Әрwахлар алар әдәм үлгәнце йөрителәр. Кешенең әрwағы йөрите. Кәбән башта[2] торам ди пецән цапқанда. Күк көйләге, бөркәнцек йабынған, ә бәм китеп бараты. Ә өйдә әбәм икмәк салып йөрите. Қорбан әйет йеткеле, қорбан әйеткә қайттық. Өйләре қантала, тышта йоқлайбыс.

[1] *Нәнәү* — әни.
[2] *Кәбән баш* — кибән башы.

— «Қурата әрwах йөри, қулында қалтасы[1] бар, үсе сықтайты», — тиде. Әйет көннең иртәсе. Шуның кицендә әбәм[2] wафат булды.

— Фәймә көпкәгә[3] кереп китте. Өйгә керсәм, өйдә утыраты, тиде. Әрwағын күргән әллә ницек булып. Осақ тормай Фәймә үлгән, бичәсе инде — *туб*.

***Әрwахларға бағышлап доға уку***

**Пы төнйаның теге төнйасы** — бу дөньяның теге дөньясы;
**Қатым-туwа уку** *туб*. — дога уку.

— Көлле ә рwахларны искә алу, қатым-туwа уғу кәрәк. Пы төнйаның теге төнйасы да бар — *туб*.

Әрwахларыбыс йад ителсеннәр[4],
Пестән доға көтеп йатқан,
Мәғърипт ән мәшриқътә,
Исемнәре онытылған,
Нәселләре киселгән,
Көлле әрwахларның рухи шәрифләренә
Ирештерсәң иде.
Қылған доғаларыбыс,
Теләгән теләкләребес қабул булсын.
Ошбу әрwахларыбысға барып йитсен.
Қаберстанда йатқан әрwахларыбыс
Риса булып йатсыннар, амин — *тара*.

**Өрәк, аурақ, әрwах**

**Өрәк** — үлгән кешенең башкаларга күренә торган рухы. Татар, башкорт телләрендә **өрәк**, чуваш телендә **ерех**. Себер диалектларында: **аурақ, әрwах, орык** (< гар. әрвах; рух сүзенең күплек саны). Себер диалектларында «**аурақ күрү**» турында бик күп текстлар, мифлар язып алынды.

[1] *Қалта* — янчык.
[2] *Әбә* — апа.
[3] *Көпкә* — абзар.
[4] *Йад ителсен* — искә алынсын.

**Өрәк**

**Өрәк** *каз.ар.* үлгән кешенең жаны. Ул зираттан ут булып чыгып, кешегә күренә икән.

— Өрәкләр буладырыйы аржақ зиратында, жанып утырадырыйы ут булып. Басуда очрасаң, ул сине адаштыра. Әwәл урманға читләwеккә барадырыйық арбаға төйәлеп. Менә арба астыннан чыгып ут жанып қалғанны күргәннәр. Күрше үлгән булған, қан чыққан жир булған, шунда йанып қалған (Биектау районы, Әлдермеш авылы).

**Аурақ**

**Аурақ** [< гар.] *төм.туб.* рух, өрәк.

— Йеңгәм үлде, аурағы керде. Йоқлап йатам. Төн. Мич түбәтә[1] миски утыра , мискине түрт мәртәбә чиртте. Аурақ йөрите. Бер йыл алтан йөрите аурақ, аны күрүчеләр булаты. Аурақны мин күрмәгән — *төм.*

## Аурақ күрү

**Аурақ күрү** *төм.* аурак кайчагында кеше булып йөри. Аны күреп киемен танысалар, исән кеше шул киемне әлеге ауракны күргән ке---шегә салып бирергә тиеш, дигәннәр.

— «Килен, аурағыңны күртем, пескә кереп цыкты», — тиде. Қайнанам ышанып қуйты:

«Көйләгеңне[2] пир. Нинтәй көйләктә йөрисең, сине ул көйләктә аурағыңны күргән кешегә ул көйләкте биргәле кәрәк».

«Көйләгеңне қысы кисен, пиреңә», — тиде.

Өстемә кейеп йөргән йаңы көйләгемне тишеп бирдем.

Баланы йаратмай икән ул аурақ , аурақ үлтергән минең балаларны.

«Қайсы кейем белән күрәсең кешенең аурағын, шул кейемне биргәле кәрәк», — тиделәр.

[1] *Мич түбә* — мич башы.
[2] *Көйләк* — күлмәк.

## Аурақ белән гәпләшү

— Мин аурақ белән дә гәпләшкән. Кеше булып йөрите ул үлмәстән алта.

«Мин килтем, аң ишекне», — тиде. Кисрәсе[1] килте. Менә мин күргән аурақны. Үләтегән кеше үсе булып йөрите. Пес аны аурақ тидек.

— Аурақ йөри тегән. Кицен сәғәт алтыта сыйыр саудым та цығып киттем өйтән. Цығып торған ыйым, Сәйтүнә әбә[2] кереп киләте. Песнеңке элек қапқа түгел, күсәнәк[3] кенә. Күсәнәкне ацты, кереп киләте. Мине күреп йибәрде дә кире йөреп китте. Пашта болай тәрәсәгә қарап алты, мин қуwам.

«Сәйтүнә әбә, әйтә кереңә», — тим.

Йүгереп цықсам, иц қайа йуқ. Аурақ күртем мин — *туб*.

## Аурақ — иске сыйараттан ут булып цыға

— Иске сыйаратта ут йана, ул аурақлар цыға.

«Әйтә, пергә қайтайық, мин сыйараттан қурқам, анта ут йана», — тиде.

Күгелчем булып күренде ут.

## Аурақны мылтық белән ату

— Күремце булған килене. Йелбегәндә[4] аурағын күргән. Ул мылтық алып атқан да қуйған нәнәмнең аурағын, аусына эләккән. Аурағын атып қуйсалар, кеше үләте.

Менә тәтәм үлепте. Тәтәмә эләккән. Аурағы йөрите. Аны суғып қуйыпты.

## Аурақ — бер ел алдан йөри башлый

— Пер йыл әwәлтән йөрите ул аурақ. Аны күрәтеләр. Менә миңә аурақ кермәйте. Минең фәрештәм сақлай мине. Мин күрмәгән, белмәгән аурақны — *тара*.

[1] *Кисрәсе* — шәүләсе.
[2] *Әбә* — апа.
[3] *Күсәнәк* — арата капка.
[4] *Йелбегәндә* — җилпеп имнәгәндә.

**Аурағы йөри башласа — кеше үлә**

— Кеше қартайғалы булып китсә, аурағы да йөреп китәте ғуй. Шыпыртап йөрите аурақ. Күргән кеше күрәте. Әйтүгә әйтәтеләр. Пер айданмы, ике айданмы үләте ул кеше аурағы йөрсә.

— Менә шалай булаты, кереп әйтәтеләр:

> «Шал кешенең аурағы йөрите,
> Пы кешенең аурағы йөрите», — тип — *туб*.

**Аурақ — балаларны йаратмый**

— Балаларны йаратмый икән ул аурақ. Аурақ үлтергән минең ба---лаларны — *туб*.

**Қупқан, қупқын**

**Қупқан** *себ*. үлгән кешенең рухы. Ул явыз рух булып кабереннән кубып чыга, янәсе. Чуваш телендә **капкан** — өрәк, рух (Ашм., Сл. VI, 78; Федотов, 1996, т.1, 226).

— Қупқан тип сөйләйтеләр. Үлгән кеше төнлә қәбереннән цығып бетереп қуйа тегән. Аннан қурқатылар кешеләр. Игенце көнне тағын киләтегән. Қупқан ул йаман тиләр. Менә инәсе қупқан тиләр. Сыуны ташып қуйсалар та иртә беләнгә сыу петә тиделәр. Қупқан килеп, сы---уны эцеп қуйа икән — *туб*.

— Қупқан тиделәр, үлгән кеше қубып китәте, кешене қурқытаты. Астыған[1] пешеп йитсә:

«Анта қупқан йөрите», — тиләр ите. Кеше қурғып қуйаты.

Үлгән кеше йөрешә, қупқан тиләр. Мулланы алып киләләр ите, үлекләргә, күмелгән йиренә басалар. Қабер тишегенә **ыусақ ағацы**[2] **тығалар**.

Қупқан булыпты. Ул йөргән йил[3] булып. Үлгән кеше йөрөнә.

[1] *Астыған* — кура җиләге.
[2] *Ыусақ ағацы* — усак агачы.
[3] *Йил* — җен.

«Қурғамсың қупқаннан?» «Ник қурғыйм, тигән. Алай булса түргә цығып йат», — тигән. Көртәсен[1] йабынып қуйған. Менә йыwан[2] телле эт булып килгән, йыwан қарағыш[3] булып та килгән.

**Тереләй қупқан**

**Тереләй қупқан** *туб*. кеше үзе үлгәнче үк йөри башлаган өрәк, рух.

— Кешеләр күрәткән ите. Қупқан тип, мәцкәй тип, тереләй қупқан кешене әйтәтләр.

**Туңқыс қупқан**

**Туңқыс қупқан** *тара*. үлгән кешенең явыз рухы, кабереннән куп---кан, дуңгыз булып купкан.

— Туңқыс қупқан тип әйтәтләр, антай сүс бар пестә. Кеше үлгәннән соң қубып йөреп утыраты, тиләр.

— Туңқыс қупқан күренәте. Ул қартайып алса, пер хайwан бу---лып йөри тегән. Ул үлсә, кентегеннән туп-туры ыусақ ағацын қағып қуйатылар, кентек турысыннан. Аннан да цығып киткеле, тигән.

— Атам көн дә киләте ди бала, үлгән атасы киләте. Қаберенә ба---рып қарасалар, тишек бар ди. Айәт уғып ул тишеккә аусақ ағацны суққаннар. Ул уғынып белгән. Ул цығып йөргән, туңғыс қубу булған. Ул цуцқа[4] булып йөргән, кешенең қанын эцкән.

### Мәцкәй булып қупқан

**Мәцкәй булып қупқан** *туб*. убыр булып, явыз рух булып купкан.

— Мәцкәй булып қубаты. Бис тунньқларны[5] ашап бетерәте тә өскә қубып цығаты. Үлә алмайын тип сикереп йөри ти. Баш өстөнә аусақ[6] қақсаң шанан йөрите. Қуба ти қабертән. Қупқан кешегә шалай йәш аусақ қағу гәрәк — *туб*.

[1] *Көртә* — бишмәт.
[2] *Йыwан* — зур.
[3] *Қарағыш* — каракош.
[4] *Цуцқа* — дуңгыз.
[5] *Тунньқ* — кәфенлек.
[6] *Аусақ* — усак.

### Мәцкәй булып қупқын қупқан

**Мәцк әй булып қупқын қупқан** *туб*. явыз рух булып үлгән кешенең җаны кубып, кабереннән чыгып йөри, имеш.

— Мәцкәй булып қубаты. Син беләмесен қупқынны?

Мылтыққа атылып үләме, қан-қуwық белән күмеләме, шантай кеше қубаты. Тасалап күмсәләр, қупмайты, имеш. Қупқын ул гешене йотып қуйа дигән, паш тиресе генә қала, тигән. Уғынып йиңәләр, тигән. Мин уғымышын[1] белмәйем, әшкәрә[2] қолағым эшитмәйде.

Гешенең мий әсеннән[3] оцоп цығып гитә тигән қупқын булып. Геше үлеп қала тигән. Қупқын ул мәцкәй булып қан эцеп гилсә, ийәсе терелә тигән, өйдә ге ийәсе. Ә қупқын булып оцоп цығып китсә, ул үлеп қала дигән күгәреп . Қупқын кире оцоп килсә, терелә тигән. Үлгән гешенең қанын эцә тигән, йаңы үлгәннекен. Шалай гәпләйтеләр.

[1] *Уғымыш* — дога, дини сүзләр.
[2] *Әшкәрә* — бөтенләй.
[3] *Мийә* — ми, баш мие.

## ДИНИ МӘҖЛЕСТӘ РУХЛАРГА БАГЫШЛАУ
## ҺӘМ ЯЛВАРУЛЫ ТЕЛӘКЛӘР

### Әүлийәләр

**Әүлийә** < *гар*. изге кеше. Әүлияләр турында легендалар бигрәк тә әстерхан, себер диалектларында сакланып калган.

**Әстерхан түгәрәге әүлийәләре** — әстерхан төбәге әүлияләре.

**Әүлийәләрне йаз итү** *әстр*. әүлияләрне искә алу.

— Әүлийәләрне йаз итеп торабыз, нийаз салабыз. Әүлийәләрне йаз итмәсәң аwырлықлар килә, айақ-қулың тартыша.

### Әүлийәләр турында

— Безнең Әстерхан түгәрәгендә иллеләп әүлийә бар дип әйтәләр. Безнең Әстерханны уттан да, судан да шул әүлийәләр саклый дип әйтә ләр. Минем әйем[1] әйтә иде, бездә бер зат[2] та булмас, бездә әүлийә күп, қызым, әүлийә күтәрә безне, әүлийәгә тапшырығыз, диде — *әстр*.

### Бабай атам әүлийә

— **Бабай атам әүлийә** — самый икөн (өлкән) әүлийә. Анyң мәйетенә барған кеше — саwығып қайта.

— **Бабай атам** дигән әүлийә бар. Анда зур итеп таштан салынған өйе бар. Аураған кешеләргә шул әүлийәгә барып қунмаға кирәк икән. Анда қараучы кеше бар. Шунда нийазыңны[3] әкитәсең. Чәй әкитәсеңме, кәнфит әкитәсеңме, нийаз сала торған сандық[4] бар. Шунда кергезәсең акчаңны.

Менә без «йаланнарда, йапаннарда[5] җан тәслим иткән әүлийәләр---нең, әмбийәләрнең рухларын шат ит», — дип доға қылабыз.

— **Бабай ата әүлийәгә** чәлпәкләр[6] пешереп алып барабыз. Җиде бабамыз булған өчен җиде чәлпәк пешерәмез — *әстр*.

### Бабатай әүлийә

— Бабатай түбәдә *Бабатай әүлийә* йата. Шул *Бабатай әүлийә*

сақлап тора аwылыбызны, қуй суйып қорән уқытабыз. Бабатай әүлийә мәйетенә[7] күп аwыллардан киләләр, хәйерлек[8] тараталар — *әстр*.

[1] *Әйем* — әнием.
[2] *Зат* — әйбер.
[3] *Нийаз* — хәер, сәдака.
[4] *Нийаз сала торған сандық* — сәдака сала торган сандык.
[5] *Йапан* — дала.
[6] *Чәлпәк* — юка итеп пешерелгән төче күмәч.
[7] *Мәйет* — зират.
[8] *Хәйерлек* — хәер, сәдака.

### Байаз баба әүлийә

Менә кендек мамайның[1] әйткәне бар. **Байаз баба** йул уңайына йата икән. Ул әйткән, мин **Күгәне бабаның** йанына китәм, шул түбәгә[2] китәм, дип — *әстр*.

### Биш қыз әүлийә

— Қазаwылның үзендә генә бер әүлийә бар. Нариман тийәгәндә безнең әүлийә бар. **Мөгелсем әүлийәнең** рухына дип нийазыбызны биреп китәбез, йулыбыз уңсын, дип. Қала йанында **биш қыз әүлийә** бар — *әстр*.

### Бурабута әүлийә

— Бурабута әүлийә бар. Ул әйткән:
«Айақларыннан-қулларыннан тотармын мине йаз итмәгән кешеләрнең», — дигән — *әстр*.

**Ғазиз җегет әүлийә,**
**Ғазизә әүлийә** *әстр*.
**Гайшәхан, Ғайшә ханым әүлийә** *әстр*.
**Даwыт баба әүлийә** *әстр*.
**Йирағасы әүлийә** *әстр*.:

Менә **Йирағасы әүлийә** Қартузан аwылында, ул бик көчле әүлийә булған. Анyң өйе йанында суы бар. Ул Қартузандағы әүлийәнең суы бик тирән диләр. Анда ике үрдәге булған, өйен зур итеп йасағаннар. Анyң мөнәwире[3] булған сақлый торған, бер сукыр қарт, Қартузан аwылында тора. Әүлийәг ә нийаз бирәйәк, қорән уқытып чығайақ булсалар, шул мөнәwиргә киләләр. «Безг ә әчәрен[4] бир, без Йирагасы әүлийә өйенә қорән уқытабыз», — дип. Арба белән болар китәйәк булса, бабай әйтә икән: «Миннән сәләм әйтегез, Йирагасы әүлийәгә». Болар әйт ә икән, и бу күзе күрмәгән кеше нинди сәләм җибәрә икән әүлийәгә, үлгән-беткән кешегә», — дип.

[1] *Кендек мамай* — кендек әби.
[2] *Түбә* — зират.
[3] *Мөнәwир* — кабер сакчысы.
[4] *Әчәр* — ачкыч.

**Исемен белмәгән әүлийәләр** *әстр.*:
— Мәғриптән мәшриққә, мәшриқтән мәғрипкә исемен белмәгән әүлийәләр рухына бағышладым.

**Йегет әүлийә** *әстр.*,
**Қарағач әүлийә** *әстр.*:
— Безнең кыругта әүлийә күп дип сөйлиләр. **Қарағач әүлийә** бар. Әүлийә өйенә әләм[1] күтәрәбез, өйе бар безнең кыругта.

**Қодырата әүлийә** *әстр.* Хөзер ата әүлия, Хөзер Илйас әүлия.
«Кодырата әүлийә җулдашыгыз булсын» — дип доға уқыйм.

**Қыз әүлийә** *әстр.*:
— Безнең Кондраuда **қыз әүлийә** бар, нийаз сала торған сандығы бар, кылпытас[2] дигән ташы бар. Шуған тупырақ аласың, әүлийә қабереннән. Аураған кешеләр шуны суға сала, қойона. Арғы тийәктә, Нариман тийәктә **қыз әүлийә** бар дип тә әйтәләр. Җиде әүлийә икән менә безнең түбәдә. Кеше аwырса-нитсә әүлийәгә сәдәқә җибәрәбез дип йөриләр. Менә мин бер майчиләк[3], бодай җибәрдем Мөгелсем әүлийәгә.

**Күгәне баба әүлийә** *әстр.*:
**Байаз баба** әүлийәнең өйе бар. Қызанда **Күгәне баба әүлийә** бар.

— **Байаз баба Күгәне баба** түбәсенә киткән ди. Анда зур түбә бар. Шул Байаз бабаның, Күгәне бабаның рухына нийаз бирәләр.
**Күз әүлийәләре** *әстр.*,
**Күз әүлийәсе Күккүз атам** *әстр.* күз авырткарны төзәтә торган әүлия.

— Күккүз әүлийәгә күзе аwыртса нийаз күтәрәде, Күккүз атам рухына, дип.

**Мөгелсем әүлийә** *әстр.*:
— Нариман тийәгендә әүлийә бар. Мөгелсем әүлийәгә дип нийазы---бызны биреп китәбез.

**Нората, Норәхмәт әүлийә** *әстр.*,
**Нурмөхәммәт әүлийә** *әстр.*:
— Менә **Нурмөхәммәт әүлийә** бар. Аның қабере йул йанында була. Шул **Нурмөхәммәт әүлийә** халықның төшләренә иңә, мине йул йаныннан алығыз, дип. Менә аны безнең Йанға- Әскәр аwылында хөрмәтлиләр, мал суйалар, бәйрәм итәләр. Шул қабер йаныннан узғанда уқыйсың:

Аллаға аманәт, дисең
Йатқан җирендә тыныч йат, дисең,
Рухың шат булсын, дисең.

[1] *Әләм* — байрак, флаг.
[2] *Қылпытас* — кабер ташы.
[3] *Майчиләк* — кечкенә чиләк.

— Әүлийәне менә ничек күмгәннәр, шул көйе қып-қызыл нур сибеп тора балчығыннан ди. Менә Нурмөхәммәт әүлийә өйендә әләмдә җилфер -җилфер итеп тора йаулықлар ди. Нурмөх әммәт әүлийәгә килеп зийарат итәләр, кем аwырый, күзсез каламы, айағы аwыртамы:

Дәнемә дәрман бир,
Күземә шифа бир, дип эчкәннәр суын.

**Сынык әүлийәсе** *әстр.*,

**Сынык әүлийәсе чупаш бабам** *әстр.* сынып имгәнгәнне төзәтә торган әүлия.

— Сынык әүлийәсе — чупаш бабам. Айағы сынамы, қулы сынамы, шуның рухына бағышлап нийаз бирә.

**Сыныкчы әүлийә чупаш бабам рухы** *әстр.*:

— **Күз әүлийәсе Күккүз атам, сыныкчы әүлийә чупаш бабам** рухына бағышладым.

**Тумак әүлийә** *әстр.*:

— *Тумак әүлийә* тумак түбәдә. Тумак түбә бетсә, дөнйа бетә дигәннәр.

**Тукаш баба әүлийә** *әстр.*,

**Фатыйма әүлийә** *әстр.*,

**Хәсән-Хөсәйен әүлийә** *әстр.*,

**Җайдак баба әүлийә** *әстр.*,

**Җайдак бабай әүлийә** *әстр.*,

**Нората, Кодырата, Йегет әүлийә, Ғайшә ханым, Фатыйма, Багаутдин әүлийә** дип уқыйбыз. **Җайдак бабай әүлийәне** дә безгә китереп салдылар. Бездә күп әүлийәләр күмелгән. Әүлийә күтәрә безне дип әйтәләр.

**Гайшә ханым, Фатыйма әүлийә, Норәхмәт, Нурмөхәммәт әүлийә, Даwыт бабам, Зәңки бабам, Күккүз әүлийә, Тукаш баба, Коппи Кужа**, күземнең нуры, җәннәт бизәкләре **Хәсән-Хөсәйен, Газизә әүлийә** бар ул әтрафта.

**Әүлийә зираты, әүлийә қабере**

**Әүлийә зират** *глз.* изгеләр зираты.

— Гурйа-калада әүлийә зират бар. Нәсел-тамыры булган кешеләр баргаладылар.

**Әүлийә зират**ына адарыну *каз.ар.-доб.* әүлия зиратына нәзер әйтеп нәрсә дә булса илтеп элеп кую.

— **Әүлийә зират**ына адарыналар, җаулыкмы, ситсамы бәйләп қуйалар чардуған қырыйына. Мин дә җыл сайын бер җаулык бәйләп қуйам.

**Әүлийә мәйете** *әстр.* әүлия зираты.

**Әүлийә түбә** *әстр.* әүлия зираты.

— *Әүлийә мәйете, әүлийә түбә* бар бездә.

**Әүлийә мәйете** — Сәйет бабаның үлг ән җире. Қуй суйып, қалыкны җыйнап, намаз уқытып ашын бирделәр, бишбармак, чәй бирделәр.

Қалык җақшылыкта торсын,
Байлық булсын, татулық булсын,
Дөнйаға тынычлық булсын,
Бәлә-қазадан сақласын.

**Әүлийә кабер** *глз.* изге кеше каберлеге.

— Әүлийә кабер булма тийеш безнең зиратта. Зиратлар астыннан су килә. Элек тагарак куйып маташканнар ыйы.

— Әүлийә қабергә қорбан чалалар татарлар да, бичырманнар да. Әүлийә қабер тау биттә, урам буйда.

— Әүлийә кабергә қорбан чалалар иде. Үзебез арада акча йукалап, сарык алып суйалар иде.

Сарык суйып бутка пешерәләр иде, йаман йәмле була иде. Килгән кеше сайын айырып салып бирәләр иде.

— Әүлийә кабер ул Урйа-Калада. Анда кереп: «Зират кылма кил---дек», — дип укып утыргалилар иде.

«Әүлийә кабергә булсын», — дип садака биргәләдек.

**Әүлийә қабере** *әстр.*:

— Үле түбәдә[1] әүлийәләребез бар, әүлийә қаберләре бар.

— Әҗәрханның әнисе үзенең өйен бирде, әүлийә қабере өстенә қуйдылар өйен. Күле бар, әүлийә күле диләр.

**Әүлийә қабере** *каз.ар.-дөб.*:

[1] *Үле түбә* — зират.

— Әүлийә қаберенә сөлге, тастымал илтеп эләләр чирләгән кешеләр.

**Әүлийә қабере** *төм.* изгеләр кабере.

— Тубыл түбәтә песнең астана ғуй, әүлийәләрнең қаберләре.

**Җиде қыз әүлийә** *т.я.-нрл.*:

— Қайыннық бар бездә. Җиде қыз әүлийә күмелгән диләр, изге қызлар. Жаңғыр телиләр қайынныққа барып, тастымал эләләр ағачка. Қошларға тары сибәләр.

### Әүлийә қыслар

**Әүлийә қыслар** *төм.* изге кызлар.

— Астаната әүлийә қыслар: Сабира, Сәрбийамал, Сариба тиделәр аларны. Алар итәкләре белән йир ташып түбә қылғаннар. Өчтүбә тип атала.

— Беснең астанаата әүлийәләр йататы:

Қыз әүлийә;
Йете қыс әүлийә;
Ақылбигә әүлийәләр.

**Әүлийәгә нәсер-сатақа салу:**

— Әүлийәгә тип нәсер-сатақа салсалар йуғалған әйберләре табы---латы — *туб.*

### Әүлийә қыз

**Әүлийә қыз** *әстр.* изге қыз.

— Әүлийә қыз бар мәйетебездә[1]. Ис чығарғанда искә алабыз.

### Көмөш қыслар

**Көмөш қыслар** *төм.* изгеләр зиратында «көмеш кызлар» (ягъни изгеләр) ята, дигәннәр (Түбән Тәүде районы, Тарман авылында).

— Көмөш қысларға тип әнийем тоға қылатқан иде. Кемнәр ул көмөш қыслар?

Ураса wақытта ул көмөш қысларның утлары йанып тора иде. Қурас[2] булып аларның таwышлары эшилеп торыпты. Искеле сират — әwәлге сират. Ул сиратта Қоръән аwасы эшителә. Искеләр[3] цығып утырғалы булған анта. Аны әйтү гәрәк. Сиратны қоршап[4] алыптылар, қаберләре цитәнсес қалды.

[1] *Мәйетебездә* — зиратыбызда.
[2] *Қурас* — этәч.
[3] *Искеләр* — изгеләр.
[4] *Қоршап* — коймалап.

Арғаwыл сиратта йата торған көмөш қыслар рухларына тип тоға қылатлар иде. Алар сиратның арғы оцонта. Анда ицкем барып оронмай ул оцқа.

Көмөш қысларға арнап[1] сатаға та салабыс.

«Көмөш қыслартан, искеләртән күргәле йассын».

## Әүлийә күле

**Әүлийә күле** *эстр.* изге сулы күл.

— Әүлийә өйе йанында йаңғыр теләгәндә баралар шул әүлийә куленә, айақ сызласа, күз аwыртса баралар. Әүлийә күленнән су алып қайтып эчәләр, күзләрен йуwалар. Менә бер мама[2] килгән иде, Миңҗан мама. Шул айақлары белән йөри алмый иде, шушы су төзәтте. Бутилкәләр белән килеп алдылар шул суны. Айақларына сөрткән иде дәрман булды, шул су.

**Әүлийә күленә сәдәқә салу** *эстр.*,

**Әүлийә күленә нәзер әйтү** *эстр.*:

— Әүлийәне хөрмәт иткән кешеләр Йанға-Әскәргә баралар. Әрмийәгә китсәләр дә, сау-исән қайтсам әүлийәгә барыр идем дип нәзер әйтәләр. Минем үлгән әбийемнең зур қызы йыл да бара булған. Әүлийә күле дә бар анда, пар үрдәге дә бар. Әүлийә күленә сәдәқә ташлыйлар, йалтырап судан күренеп йата ди. Әүлийә күленең суын да алып қайталар. Барған халықлардан «Миңа дә бер бутилкә су алып қайт шул әүлийә суыннан», — дип әйткәннәрен ишеткәнем бар.

**Әүлийә рухы** *эстр.*

— Мал суйғаннар Ирәгәзе әүлийә рухына бағышлап.

**Әүлийә сақчылары** *эстр.*:

— Алар мөнәwир бабаның сәламен тапшырғач теге ике йылан йуққа чыққан. Алар әүлийәнең сақчылары булғаннар.

**Әүлийә суwы** *эстр.*:

[1] *Арнап* — багышлап.

[2] *Мама* — әби.

— Бик кечкенә wахытта күзләрем аwырды. Әүлийә өйенә кереп, әүлийә күленнән су алып чықтылар да шул су белән йудылар. Әүлийә өйендә ақча, йаулықлар элгән әләмгә. Шунда суға ақча ташлап әүлийә суын алып қайталар. Бәйрәмдә әүлийә өйенә бара балалар. Өй эченә кереп уқыйлар, қорбанны анда барып чалалар. Килгән халық қылыхуалла уқып әүлийә күленнән су ала. Аның суын алып, йаға суын[1] қушып эчәләр, қурыкқаннан, күз тигәннән алалар.

Мин шул аwылда туған инде, ишетә беләм, бик қадерле әүлийә, көчле әүлийә ул, дип. Берәүнең қулында йарасы булса, ул су белән йараны йуғаннар, күзләрен йуғаннар.

**Әүлийә үрдәге** *эстр.*:

— Анда электә үрдәкләре бар иде, ике үрдәк. Үрдәк әүлийә диләр иде.

Әүлийәнең ике үрдәге булған, суда йөзеп йөргәннәр. Берәү дә тимәгән. Шул Ирәгәзе әүлийә суын аwылға алып қайтқаннар, ул су ничә йыл торса да бозылмый ди, қыш та қатмый, йаз да бозылмый, бер җирдән керми дә, чықмый да, шулай тора ул су. Аның ике үрдәгенең берсен бер азамат[2] атқан икән, ул ир айақ-қулсыз қалған ди. Алар әүлийә бабаның[3] сақчылары булғаннар.

## Әүлийә йорты, әүлийә сарайы, әүлийә өйе

— Әүлийә бар, әүлийә түбә бар Хансарай дигән аwылда сарайы бар, йазуы бар. Қорманнық[4] суйалар әүлийә сарайы йанында. Шунда қунып йаталар.

**Әүлийә йорты** *эстр.*:

— Әүлийәләрнең йортын йасадылар саманнан[5] зур итеп.

**Әүлийә өйе** *эстр.*:

— Болар бара, керәләр, әүлийә өйенең ишеген ачалар. Атла---рын бәйләп қуйалар. Кереп, әүлийә өйенең эчендә қорән уқыйлар, доғаларын уқыйлар да чығып китәләр.

**Әүлийә өйе байрағы** *эстр.*:

[1] *Йаға суы* — елга суы.
[2] *Азамат* — егет.
[3] *Әүлийә баба* — әүлияне олылап әйтү сүзе.
[4] *Қорманнық* — корбан.
[5] *Саман* — тирес белән саламны кушып ясалган кирпеч.

— Әүлийә қаберенең өстендә әүлийә өйе бар. Өй эчендә утырғыч бар. Өйләрен батпак[1] изеп сыладық. Әүлийә өйе түбәсендә байрақ тора, ақ байрақ.

**Әүлийә өйе йаулығы** *әстр.*,

**Әүлийә өйе сөлгесе** *әстр.*: — йаулықлар элеп қуйалар, читләрдән китерәләр, аwыллардан килгән халык йаулықлар бәйлиләр әүлийә өйенә. Бик фәкыйр кешеләргә алырға йарый ул йаулықларны. Йаулықларның мийешенә[2] ақчалар бәйләп қуйыла.

— Әүлийәбез йақшы. Өй салдылар әүлийәгә. Ақ сөлге, йә ақ йаулық элә әүлийә өйенә. Анда намазлығы да, қомғаны да бар. Тәһәрәтләнә, тәсбих тарта. Шунда эленеп җилфердәп тора сөлге-йаулықлар.

**Әүлийә өйе әләме** *әстр.*:

— Менә безнең қазан өйебез[3] бар. Мамай әйтә: «Шулхәдәр өйем йақшы. Давай, без бу өйне әүлийәгә қуйыйқ», — ди. Ирләр чақыралар да бу өйне әүлийә қаберенә илтеп куйалар. Ул өй шунда тора. Ул өй өстенә ақ зәһәннән[4], әләм элеп қуйалар.

Ураза бәйрәмендә, қорман бәйрәмендә, әүлийә өйенә зур әләмнәр әкитеп салып торабыз, йаңартып торабыз. Ақ матыдан[5], ақ зәһәннән әләм қуйыла, ул шунда җилфердәп тора әүлийә әләме.

**Әүлийә йулы** *әстр.*:

— Килгән халық туры әүлийәгә баралар. Мин бара алмыйм, ақчамны башымнан-күземнән әйләндереп бирәм:

«Әүлийә йулына» дип.
«Минем йулым уңсын» дип барабыз Нурмөхәммәт әүлийәгә.

**Әмбийә** *әстр.* пәйгамбәр.

— **Әмбийә** дип әйтеләде шундый кешегә. Менә үлде — артыннан бер кеше дә йуқ, бала да йуқ, қардашы да йук. Менә әмбийәләр шундый кешегә қорман уқыйды.

**Әүлийә, әмбийә рухы** *әстр.*:

— Барча әүлийәләр, әмбийәләрнең рухына бағышладым.

[1] *Батпақ* — балчық.
[2] *Мийеш* — почмак.
[3] *Қазан өйе* — ишек алдындагы кечкенә өй; җәйге кухня.
[4] *Ақ зәһән* — ак ефәк.
[5] *Ақ маты* — ак тукыма.

## Анамыз

**Анамыз** — дини мәҗлесләрдә дога багышлаганда, әүлияләрне, пәйгамбәрләрне искә алганда әйтелә торган олылау сүзе.

Әстерхан сөйләшендә:

**Әминә анамыз** рухына бағышладым,
**Мәрйәм анамыз** рухына бағышладым,
**Фатыйма анамыз** рухына бағышладым,
**Хаwа анамыз** рухына бағышладым...

## Атам, атамыз

Дини дога багышлаганда әүлияләрне олылап әйтү сүзе.

**Бабай атамның** рухына бағышладым,
**Әдәм атамызның** рухына бағышладым...

### Шупаш атам

**Шупаш атам** *әстр.* сынык әүлиясенә эндәшү сүзе.
**Шупаш атам** диделәр, менә қулың сынады, айағың сынады, ул сынғаннарға йардәм итәде. Шупаш баба рухына, әгъзалары аwырған кешеләр рухына дип.

### Атамның башы

**Атамның башы** *әстр.* әүлия кабере.
— *Атамның башына* барабыз қуй суйып, қодай җулға барабыз.

### Аға, ағам

**Бабай ағамның** рухына бағышладым,
**Җыйын ағаларымның** рухына бағышладым — *әстр.*

### Баба

**Баба** — хөрмәтле карт ир кеше; үткән буыннарның аеруча билгеле, хөрмә тле вәкиле; нәселнең, халыкның борынгы чыгышын тәшкил иткән кабилә, ыруг, кеше.
Әстерхан сөйләшендә дини мәҗлестә дога укып багышлаганда түбәндәге «баба» — әүлияләр искә алына:
*Баба Йатам, Байаз баба, Зәңки баба, Йаңғырчы баба, Кара Хуҗа баба, Козыр баба, Күгәне баба, Мансур баба, Мәхмүт баба, Мөнәwир баба, Нур баба, Нурмөхәммәт баба, Нурәхмәт баба, Сары Хуҗа баба, Сындық баба, Туқаш баба, Төкле баба, Түрә баба, Шупаш баба, Әүлийә баба, Җайдақ баба, Җиде Султан баба, җиде әби, җиде баба.*

**Мөнәwир баба** *әстр.* әүлия кабере сакчысы.
**Мөнәwир** < *гар.* нурландыручы, яктыртучы дигән сүз.

— Чығып китәйәк булғаннар. Қарасалар, ишек төбендә ике йы---лан торған, чығармый ди. Болар қурыққаннар. Бу ни хәл бу, аты---быз да қачып киткәндер инде. Шуннан қайсыныңдыр исенә килгән. И, Мөнәwир баба сәләм әйтеп җибәргән иде бит, без әүлийәгә аның сәламен бирмәгәнбез», — дип. Алар әйткән: «И изге рухлы Ирәг әзе әүлийә, мөнәwир баба сиңа сәләм әйтеп җибәрде, қабул итеп ал сәламне», — дип.

### Астана баба

**Астана баба** *төм., туб.* изгеләр кабере — астанага күмелгән кешене шулай әйтәләр.

— Байыш астанада йатқан астана бабаларны искә алып туwа уқыйбыс.

### Әүлийә баба

**Әүлийә баба** — төмән сөйләшендә:
— Қанчәбер сиратларында йатқан әүлийә бабаларның рухына бағышладым...

### Түрә баба

**Түрә баба** *саз.я.* укымышлы, олы кешене хөрмәтләп әйтү сүзе.
— Түрә бабаның урыны түрдә.

### Җайдак баба

**Җайдак баба** *әстр*. юлчыларга булышучы баба.
**Җайдак баба** дигән әүлийә бар, **йулға чыкқан кешегә** йардәм итә.
**Җиде баба, җиде әби** *әстр*. дини мәҗлестә дога укып багышлаган---да искә алыналар.

Илаһи нийәт қылдым, бағышладым,
Җиде әбиләр, җиде бабаларыма,
Йорт хуҗаларына, абзар хуҗаларына,
Җир хуҗаларына, су хуҗаларына,
Кендек әбиләренә, остатларыма.

**Баба изгеләр**

**Баба изгеләр** *т.я.-к.т*. догалар багышлаганда искә алыналар.

— Баба изгеләр, таудағы изгеләр, су изгеләре дип бөтенесен тақмақлап уқыйсың кече атна көннәрендә.

**Баба тау**

**Баба тау** *т.я.-к.т.* изгеләр күмелгән тау, изгеләр зираты.
— Арғы Баба, Бирге Баба таулары бар. Менә бу Бирге Бабада изгеләр зираты. Әwәле Баба таwына менеп йаңғыр теләгәннәр. Ике рәқәғәт намаз уқып сорағаннар:

«И раббым, хәйерле йаңғырлар бир».
Себер диалектларында:

**Түрә баба** *саз.я.* укымышлы, олы кешене хөрмәтләп әйтү сүзе.
— Түрә бабаның урыны түрдә.

**Бабаларымыз**

**Бабаларымыз** — әстерхан сөйләшендә дога багышлаганда искә алыналар.

Әүлийә бабаларымыз,
Қыдыр аталарымыз,
Сәйет бабаларымыз,
Аданас кардашларымыз
Бала-чағаларымыз,
Үземнең аталарым,
Қәйен аталарым,
Туған-тоқомнарым, ыруларым.

**Бабай**

**Бабай** — хөрмәтле карт ир кеше. Әстерхан сөйләшендә әүлийә---бабайлар: *Қодырата бабай, Қодыр бабай, Султан бабай, Җайдақ бабай* һ.б.
Қырда — **Кыдыр бабай** йардәмчең булсын,
Суда — **Султан бабай** йардәмчең булсын.
**Бабай түбә** *әстр*. зират.

**Бабай ағам**

**Бабай ағам** *әстр*. хөрмәтле, өлкән ир кешегә карата әйтелә.

— Бабай ағаларымны искә алып, қоръән тастырхан җәйеп, баwырсақ чәчеп чәй эчтек.

— Бабай ағам рухына бағышлап садака биреп торам.

### Бабай атам

**Бабай атам** *әстр.* өлкән әүлия.

— Бабай атам рухына бағышлап ққуй чалабыз.

### Бабам

Әстерхан сөйләшендә әүлия бабаларны *бабам* дип атау да бар: *Ақбаба бабам, Даwыт бабам, Нората бабам, Чупаш бабам, Кендек бабам.*

**Нората бабам** *әстр.*:

— Нората бабам дип безнең зиратта әүлийә өйе бар. Байрагы бар, ақ зәһәннән байрағы. Өйенең эче бийек, өлкән әүлийә булған, ул әзилдә булған.

**Чупаш бабам** *әстр.* сынык әүлиясе.

— Чупаш бабам — сынық әүлийәсе. Айағы сынамы, қулы сынамы, шуның рухына багышлый, нийаз бирә. Ул үзенең рухын җибәреп, айағыңны төзәтеп китәде. Шуның рухына нийаз күтәрәсең.

«Минем айағым-кулым өчен», —

дип бирәсең нийаз биргәндә.

### Ғаиб ирәннәр

**Ғаиб ирәннәр** — дини мифологиядә, дога багышлаганда искә алыналар.

**Ғаиб** < гар. яшерен, билгесез, берәүгә дә билгеле булмаган.

**Ирән** — дини: Аллага якын, изге кеше; **ғаиб ир әннәр** — күзгә вакыт -вакыт күренеп, бәхетсезлектә ярдәм итә торган изге кеше. *Юлы уңсын инде, илаһи, гаиб ирәннәр ярдәм күрсәтсен үзенә* (С.Баттал).

— Ғаиб ирәннәр алар мәчетләрдә күренеп китә торған булғаннар — *каз.ар.-мам.*

**Багышлауда**: — Өч йөз алтмыш алты гаиб ирәннәренә бағышладым — *әстр.*

Көн ирәннәре,
Төн ирәннәре,
Гаип ирәннәре дип укып багышларға кирәк.

### Хәзрәт, хәзрәте

**Хәзрәт** < *гар.* зур кешеләрне хөрмәтләү, олылау сүзе. Җирле сөйләшләрдә дога багышлаганда искә алына торган әүлия---пәйгамбәрләр:

**Хәзрәте Гали, хәзрәте Ғаптулла, хәзрәте Ғосман, хәзрәте Ғомәр, хәзрәте Әминә, хәзрәте Хәлимә** рухына бағышладым — *әстр.*

**Хәзрәте Ғайшә, хәзрәте Фатыйма, хәзрәте Хәдичә рухына** бағышладым — *минз.*

**Хәзрәте рәсүл** *әстр.* пәйгамбәргә карата әйтелә. **Рәсүл** < *гар.* илче, пәйгамбәр. — **Хәзрәте рәсүлебез** Мөхәммәт пәйғамбәребез ыризалыгы өчен булсын — *әстр.*

**Рәсүл рухы** *әстр.*:

Әй раббым аллам, шушы сүрәләремне бағышладым рәсүлемезнең рухына, рәсүлемезнең ата-анасы, әби-бабаларының рухына бағышладым.

### Хуҗа

**Хуҗа** < *фарс.* 1. хуҗа, ия; 2. белемле өйрәтүче, укытучы; 3. затлы нәселдән.

*Қара Хуҗа баба,*

*Сары Хуҗа бабаның* рухына бағышладым — *әстр.*

*Қыппи Хужҗа* — ул теләгән теләкләрне қабул итә — *әстр.*

## ДИНИ МӘҖЛЕСТӘ ДОГА БАГЫШЛАУЛАР ҺӘМ ЯЛВАРУЛЫ ТЕЛӘКЛӘР

### Корән ашында багышлау — минзәлә сөйләшендә:

Уң йақ фирештәләремә,
Сул йақ фирештәләремә бағышлыйм.
Хәзрәте Фатыйма, хәзрәте Гайшә,
Хәзрәти Хәдичәгә,
Хәсән-Хөсәенгә бағышлыйм,
Җәмиг әрwахларға бағышлыйм.
Рухларын шат қыл , йарабби ходайым.
Йорт хуҗаларына, абdар хуҗаларыма
бағышлыймын.
Үзеңнең рәхмәтеңне ирештер,
йарабби ходайым.
Шушы сәдақә ийәсенең сәдақәсен қабул итеп алдым.
Җаннарына тынычлық бир,
Тәннәренә сихәт бир,
Малларына бәрәкәт бир,
Ил — көннәрнең иминлеген насип қыл.
Балаларыңның рәхәтен күр,
Хәләл җефетең белән тигезлектә йәшә,
Бетмәс-төкәнмәс хәләл дәүләтләреңне
арттыр, йарабби.
Йақшы сүз белән, тулы иманыбыз белән
үз теләгәнеңә ирешергә насиб ит.
Әрwахларның рухларын шат қыл,
Илләргә-көннәргә тынычлықлар бир,
Патшаларга сабырлық бир,
Куанычлы тормышлар насыйп ит.
Ике иңемдәге ике фәрештәгә,
Шәһитләргә,
Доғадан киселмешләргә,
Алар рухына дип,
Йорт хуҗалары , су хуҗалары,
Җир хуҗалары дип доға қылабыз.
Илаһи нийәт қылдым, бағышладым,
Җиде әбиләр, җиде бабаларыма,
Йорт хуҗаларына, аб dар хуҗаларына,
Җир хуҗаларына, су хуҗаларына,
Кендек әбиләренә, остаdларыма,
Сөннәт бабаларыма,
Нигезләре таралмыш ,
Исемнәре йуғалмыш булган,
Доғаға мохтаҗ булып йатқан
Әрwахларыбызға дип бағышладым,
Хуҗалар таwы изгеләре рухына бағышладым,
Җир шәйехләренә,
Су шәйехләренә,
Кендек әбиләренә,
Остаdларыма — барына да доға
насыйп булсын.

Җир анасына,
Йорт анасына,
Ике иңемдәге ике фирештәмә,
Күктәге wә җирдәге фирештәләремә,
Туған-тумачаларыма,
Қода-қодағыйларга,
Ир туғаннарыма,
Қыз туғаннарыма,
Зәңки бабай рухларына,
Мал хуҗаларына», —
дип әйтә йөрим (Тәйсуган авылы).
**Багышлау** — минзәлә сөйләшендә:
Шушы уқыған қоръәннәрем аллаһының ризалығы өчен булсын.
Аллақайым, үзекәйең қабул қыл,
Уқуымда булған барча кимчелекләрне гафу қыл,
Атабыз Әдәм, анабыз Хаwаның
Рухларына ирешеп,
Рухларын шат қылсын.
Алар арасында килеп киткән
Барча пәйғамбәрләрнең рухларына
Барып ирешсен.
Шушы нигездән өмет итүче әрwахларға барып ирешеп,
Қаберләрен йақты қылсын,
Рухларын шат қылсын.
Ахирәт көннәрендә җәннәтләргә
Керергә насиб итсен.

Аллаһының ризалыгы өчен булсын,
Хәйереңне қабул итеп алдым.
Җәмәғатең белән тигез гомер кичерегез,
Балаларығыз мәрхәмә тле балалар булсын.
Җөргән җирләрегездә имин җөрегез,
Эшләғән эшләрегезнең файдасын күрегез,
Тәннәрегезгә сәләмәтлек
Җаннарығызға тынычлық бирсен.

Дөнйалықта әмәл өчен,
Ахирәттә иман өчен,
Әрwахларны шатландырырға
Җәннәт түрләрендә булу өчен
Атабыз Әдәм,
Анамыз Хаwа рухына бағышлыйм,
Барлық пәйғамбәрләр рухына бағышлыйм.
Мәгърип белән мәшрикъ арасында
Шушы гаиләдән өмет иткәннәр
Рухына бағышладым (Күҗәкә авылы).

**Мамадыш районы Дусай авылында дога багышлау**

Раббым аллаһым,
Хәйерле рәхмәтең белән
Шушы уқыған қоръән шәрифләребезнең
Әҗер-саwабын йарабби бер аллам,
Үзеңә бағышладым.
Мөхәммәт Мостафа салаллаһи галәйһи әссәламның
Рух шәрифләренә бағышладым.

Атабыз Әдәм,
Анабыз Хаwа рух шәрифләренә бағышладым.
Җир йөзенә килеп киткән барча
Пәйғамбәрләрнең рух шәрифләренә бағышладым.
Әүлийәләрнең, әмбийәләрнең
Рух шә рифләренә бағышладым,
Бездән доға өмет итүче
Барча әрwахларның рух шәрифләренә бағышладым.
Хуҗа Баhаwетдин хәзрәтләрнең
Рух шәрифләренә бағышладым.
Тар ләхетләре киң булсын,
Қараңғы урыннары йақты булсын,
Гүрләре җәннәт бақчалары булсын,
Йатқан җирләре йомшақ булсын,
Уқыған ғамәлләребез қабул булсын,
Рухлары шат булсын ,
Урыннары җәннәттә булсын,
Илгә-көнгә, hәммәбезгә
Хәйер-доғалар уқып йатсыннар.
Барчабызға да сират күперләрен
Ансат қына кичәргә йазсын,
Аллаhы тәғалә wәғъдә иткән
Җәннәтләрендә урын бирсен.
Уң йақтағы, сул йақтағы, қаршыдағы
Күршеләрнең дә әрwахларына,
Рухларына бағышлыйбыз.
Алар да өмет итеп йаталар бит.
Бәрәкәт — йа кадир Аллаh,
Шәфәғәт — йә Рәсүлуллаh,
Мең шөкер биргәнеңә
Ислам динендә булғаныбызға
Дәwам ит дәүләтеңне,
Ирештер җәннәтеңне.
Раббым, үзеңнең ризалығың өчен
Ошбу уқылмыш
Қоръән шәрифләрендә
Булған хаталарымны, кимчелекләрне
Гафу иткән хәлдә
Киң рәхмәтең илә қабуллықлар қыйлсаң ыйы.
Уқыған доғаларымны
Ике иңемдәге ике фәрештә өчен бағышлыйм.

Пәйғамбәребезнең, сәхабәләрнең
Әбүбәкер, Ғомәр, Гали
Рух шәрифләренә ирештергәй идең.
Хәзрәти Гайшә,
Хәзрәти Фатыйма,
Хәзрәти Әминәләрнең дә
Рух шәрифләренә ирештергәй идең.
Зәңки баба,
Ғамбәр әбиләрнең дә
Рух шәрифләренә ирештергәй идең.
Нигез хуҗаларына,
Җорт хуҗаларына,
Зират әhелләренә,
Қабердә қаршы алучы

Рәхмәт фәрештәләренә,
Сарай хуҗаларына,
Идән асты хуҗаларына
Ирештергәй идең йарабби бер аллам.
Ике иңемдәге ике фәрештәнең
Хақы өчен бағышладым.
Ике җиһанға җибәрелмеш
Мөхәммәт пәйғамбәрнең рух шәрифләренә
Ирештергәй идең.
Җиде қат җирдәге,
Җиде қат күктәге фәрештәләрнең
Рух шәрифлә ренә ирештергәй идең.
Озақ йату чирләреннән,
Ут афәтләреннән,
Су афәтләреннән,
Җил-даwыллардан һәммәбезне үзең саклағай идең.
Сигез оҗмах ишеген ачып
Җиде тәмуғ ишеген йабып қуйғай идең, бер Аллам.
Сират күперләрен чыққан чақта
Айағыбызны тайдырмасаң ыйы,
Иманыбыздан айырмасаң ыйы,
Мизаннарға салғанда
Ғамәлебезне аwыр итсәң ийе,
Гонаһыбызны җиңел итсәң ийе,
Хәзрәти Әминә,
Хәзрәти Фатыйма,
Хәзрәти Гайшәләрне
Ахирәттә йулдаш итсәң ийе. Амин.

**Мамадыш районы Түбән Яке авылында дога багышлау**

Бездән доға өмет итүче
Барлық әрwахларның да
Тар ләхетләре киң булсын,
Қараңғы гүрләре йақты булсын
Йатқан җирләре йомшақ булсын
Рухлары шат булсын ,
Урыннары җәннәттә булсын.
Илгә-көнгә һәммәбезгә
Хәйер-догаларын биреп йатсыннар
Йақшы ғамәлләре мизаннарда аwыр килсен,
Сират күперләрен ансат қына
Кичәргә насыйб итсен,
Аллаһы тәғаләнең
Wәгъдә иткән җәннәтләрендә
Урыннары булсын.
Уң йақтан да, сул йақтан да чыққан
Күрше әрwахларның да
Рухларына бағышлыйм.
Алар да өмет итеп йаталар
Мең-мең шөкер биргәнеңә,
Ислам динендә булғаныма,
Дәwам ит дәүләтеңне,
Ирештер җәннәтеңне,
Хәзрәти Ғайшә,
Хәзрәти Фатыйма,

Хәзрәти Әминәләрнең дә
Рух шәрифләренә ирештерсәң ийе.
Зәңки бабам,
Ғамбәр әбиләрнең дә
Рух шәрифләренә ирештерсәң ийе.
Җул анасы Җулбикәгә,
Җир анасы Җирәнбикәгә,
Су анасы Сылубикәгә,
Зәңки баба, Чулпан атаға бағышладым.
Белгәнне қабул ит,
Белмәгәнне ғафу ит.
Нигез хуҗаларына,
Җорт хуҗаларына,
Сарай хуҗаларына,
Идән асты хуҗаларына
Қабердә қаршы алучы
Рәхмәт фәрештәләренә,
Ике иңемдәге ике фәрештәләргә,
Җиде қат күктәге,
Җиде қат җирдәге фәрештәләребезгә бағышлыйм.
Сигез оҗмах ишекләрен
Ачып қуйсаң ыйы,
Җиде тәмугъ ишекләрен йабып қуйсаң ыйы,

Йаман чирләрдән;
Озақ йату чирләреннән
Ут афәтләреннән,
Су афәтләреннән
Җил-даwыл афә тләреннән
Раббым бер Аллам,
Һәммәбезне үзең сақла
Сират күперләрен чыққан чақта
Айақларыбызны тайдырмасаң ыйы,
Иманыбыздан айырмасаң ыйы,
Мизаннарға салғанда
Ғамәлебезне айыр итсәң ийе.
Хәзрәти Фатыйма,
Хәзрәти Ғайшә,
Хәзрәти Әминәләрне
Қыйәмәттә йулдаш итсәң ийе.
Йақшы сүзләребез телебездә булсын, әмин!

**Татарстанның Мамадыш районы Түбән Ушмы авылында дога багышлау**

И раббым ,
Уқығанда булған хата-кимчелекләрне
Үзең кичергәй идең дөресләп
Уқыған доғаларымның
Әҗер саwапларын пәйгамбәребез
Мөхәммәт Мостафа салаллаһи
Рухына бағышлыйм,
Атабыз Әдәм, анабыз Хаwа рухына бағышлыйм.

Ике арада килеп киткән
Барча пәйғамбәрләрнең,
Изгеләрнең, сәхәбәләрнең,

Әүлийәләрнең, әмбийәләрнең,
Заһидләрнең, габидләрнең,
Җиде буын бабаларның,
Җиде буын әбиләрнең,
Ғәзиз әти-әниләрнең,
Имчәктәш қыз туғаннарның,
Ир туғаннарның,
Wафат булған күршеләрнең,
Қайнана-қайнаталарның,
Ахирәт дусларымның рухына бағышлыйм,
Суғыш қырларында шаһит киткәннәрнең
Рухына бағышлыйм.
Ил-көннәребезгә,
Гаиләләребезгә, патшаларыбызга
Татулықлар биреп,
Һәр барчабызга ике дөнйа
Рәхәтендә йәшәргә насыйб әйлә
Тәннәребезгә саулық,
Күңелләребезгә сафлық,
Җаннарыбызға тынычлықлар бир.
Амин, уқыған доғалар қабул булсын,
Урыннары оҗмахта булсын,
Төшкән балчықлары мамық булсын — *каз.ар.-мам*.

**Багышлау — Удмуртиядәге глазов сөйләшендә (Кистем авылы):**

Иске зиратларга,
Куҗа-кала зиратларга,
Әүлийә каберләргә,
Кистем зиратларда булган нәсел-тамырларга,
Туганнарыма, —
дип багышлаймын мин садаканы алай.

Койаш тумыштан алып
Койаш байышка чаклы,
Мәгъриптән мәшриккә,
Мәшриктән мәгърипкә
Кем дә кем Йофарбикәдән өмет итүчеләргә, —
дип багышлаймын мин җомгага каршы кич.

**Удмуртия, глазов сөйләше Дасис (Засеково) авылында дога ба---гышлау:**

Коръән сүрәсен укуда булган кимчелекләрне
Ходайым гафу итсән иде
Атабыз Адәм галәйссәлам
Анабыз Һаwа рух шәрифләренә багышлаймин
Мөхәммәт пәйгамбәребезнең рух шәрифләренә
багышлаймин.
Шулай ук килеп киткән
Җәмгы пәйгамбәрләргә,
Барча остазларга,
Әүлийә — әмбийәләргә,
Мөэмин — мөэминәләргә,
Нәселләре киселеп , дуwага мохтаж булган
Әрwахларның рух шәрифләренә багышлаймин.
Барчасының да рухларын шат кылып
Кабер газапларын күтәрсәң иде,

Йаткан каты йирләре
Йомшак бәләкәй (мендәр) булса иде,
Шулай ук җиде катлы зиратта йаткан,
Җиде катлы әби-бабайларның,
Бийем-бийаталарның, Әти-әниләребезнең,
Ир wә кыз туганнарыбызның,
Барчасының да рух шәрифләренә багышлаймин.
Шулай ук бергә эшләп йөргән иптәшләремнең,
Кемнәр дә кемнәр бездән дога өмет итүче
Җиде катлы әби-бабайларның
Барчасының да рух шәрифләренә багышлаймин.
Шушы җирдә тороп,
Туфыракка әwерелгән
Олы wә кече әрwахларның
Рух шәрифләренә багышлаймин
Барчасының да рухларын шат кылып,
Безләргә разый булсалар иде,
Йаткан йирләре йомшак бәләкәй (мендәр) булса иде, амин! Шушы укыган коръән саwабын
Мөхәммәт пәйгамб әребезнең рух шәрифләренә ирештерсәң иде.
Җиде катлы әби-бабаларның
Рухларына ирештереп, рухларын шат кыл,
Барча әрwахларның,
Мәгъриптән мәшриккә,
Мәшриктән мәгърипкәчә
Бездин өмет итүчеләрнең
Рухларына ирештер,
Нәселләре киселеп, дога өмет итүчеләрнең
Рухларына ирештер.
Ахирәттә иманнары йулдаш булсын.
Зиратның дүрт сирәгенә (почмагына) утырып йасин укыйбыз:
Укыган догаларым кабул булсын
Кабер тупыраклары мамык булсын.

**Удмуртиядәге (глазов сөйләше) Гурья-Кала авылында дога ба---гышлау:**

Биргән садакасына багышлап дога кыламин.
Әти-әниләренең алдыларында булсын,
Әби-бабаларының да алдыларында булсын,
Чүплектән эзләп йөрмәсеннәр,
Барсының да каршыларына алла тәгәлә китерсен,
Йортына-йиренә исәнлек-саулык,
Дәүләт-бәрәкәт керсен,
Эшләгән йирендә исән-сау эшләсен,
Түрәләренә йантартымлы булсын,
Нахак б әләләргә табылмасын,
Теләгән теләкләре кабул булсын,
Нәсел-нә сәпләренең дә каршыларына калсан,
Бийатай, бийеме бар,
Аларның да алдысында булсын.
Ахирәттә алларында булсын.
Үзем белгәннәрне укыймин, үзем белгәннәргә багышлаймин мин садака биргәннәргә.

Алла тәгәлә исәнлекләр бирсен,
Оҗмакта булсыннар,
Җиде катлы нәсел-тамырларга булсын,

Җиде катлы зиратларга булсын,
Әүлийә **каберләргә**,
Бийем-бийаталарга,
Әби-бабамнар,
Әни-әтиләргә,
Атсыз-затсызларга,
Әминә-Фатыймаларга,
Кем ди кем бездин эмет ити,
Алларында булсын!
Башым салдым йастыкка
Күңелемне бирдем
Аллага. Алла, алла дигәндә
Оҗмах ишеге ачылсын,
Тәмуг ишеге йабылсын,
дип әни әйтә иде ич.

Бу йорт-җирләрне дывасыз тотма, монда укымышлы кешеләр торганнар, ди.

**Удмуртиядәге глазов сөйләше Падера (Паюра) авылында ялварулы теләкләр**:

Барча балаларымны,
Балаларымның балаларын,
Барча туганнарымны,
Күршеләремне,
Нәсел-нәсәпләрен
Хак-нахак сүзләрдән,
Бәлә-казалардан,
Ут-күзләрдән,
Җил-даwыллардан,
Хәwеф-хәтәрләрдән,
Дошманнардан,
Йаwыз-залим бәндәләрдән,
Кисәк үлемнәрдән,
Йаман чирләрдән,
Балалар кайгы-хәсрәтеннән,
Имгәнү-сугылулардан
Үзең сакласаң иде дип әйтәмин.

**Бәрәңге сөйләшендә (Марий Эл) дога багышлау (Мазар башы авылы)**:

Илаһи амин, йарабби галәмин.
Шушы биргән сәдәхәләрне
Аллаһы тәғаләнең рәхмәте илә
Қабуллардан қыйлсаң иде.
Йарабби, шушы йақты дөнйаға килеп киткән
Пәйғамбәрләр рухына монда уқыған доғаларыбыз
Сәләмнәребез булып барса иде.
Шушы с әдәхә бирүчеләргә
Хәйерле изге йулларда йөрү насыйп булсын,
Алланың рәхмәте йауған йулларда йөрсеннәр,
Хөзер булсын йулдашлары,
Изге булсын йуллары,
Исән-сау илләренә қайтып,
Балалары , гаиләсенең тигезлеген ,
Игелеген күреп җәшәргә насыйп булсын.
Сан-сағышларына хәйерле сәләмәтлек биреп,

Йәшләргә эшләрендә зур уңышлар бир,
Эшләгән эшләренең қуанычын күреп йәшәргә насыйб ит, Қартларға қартлық көнендә
Җан тынычлығы белән,
Җан рәхәте белән йәшәргә насыйб ит.
Йәш балаларыбызны шайтан wәсwәсәсеннән,
Кара эчле кешеләрнең хөсетлегеннән,
Усалларның күзләреннән сақлағай идең,
Залимнәрнең золымыннан сақлағай идең,
Уқыған айәтләремнең
Әҗер-саwапларын
Миннән өмет иткән
Әрwахларға ирештергәй идең,
Аларның рухларын
Үзең шатландырғай идең.
Дөнйалықта белеп қылған,
Белми қылған ғөнаһларын
Гафу қылгай идең,
Мизаннарға салғанда
Ғөнаһларын җиңел қылып,
Изгелекләрен аwыр қылгай идең,
Ике дөнйа сәғадәтен насыйп қылгай идең.
Ахирәткә киткән ни бар әүлийәләр,
Ни бар әмбийәләрнең барчасының
Рухларына бағышладым.
Оло Қыр зыйаратындагы изгеләргә,
Әрwахларга , туған-тумачаларға,
Су ийәләре, урман ийәләре,
Җир ийәләренә бағышладым.
Төн ирәннәре, Көн ирәннәре,
Гайеп ирәннәргә багышладым.
Йаратқан бер Аллам,
Шушы биргән сәдәхәләрнең саwабын
Җирдән күккә ашыр,
Күктән иңә торған бәлә-қазаларның
Йулларын бикләә.
Йортларының, җирләренең тынычлықлары булса идее
Нигез ийәләре, җир-су ийәләре өчен булса иде,
Йарабби, wақытында йаңғырлар йаwып,
Аллаһының рәхмәтендә йәшәсәк иде,
Йараббым бер Аллам,
Үзеңгә тапшырдым, бер дип белдем,
Барчасына разый булдым,
Биргәненә шөкер,
Бер шөкер түгел, мең шөкер,
Тағы да бирсәң, тағы шөкер.
Үзеңнең рәхмәтең белән қабуллардан қыйл, амин!

**Багышлау** — тау ягы кама тамагы сөйләшендә:
Шушы уқыған қоръәннәрем аллаһының ризалыгы өчен булсын.

Аллақайым, үзекәйең қабул қыл,
Уқуымда булған барча кимчелекләрне гафу қыл,
Атабыз Әдәм, анабыз Хаwаның
Рухларына ирешеп,
Рухларын шат қылсын.
Алар арасында килеп киткән
Барча пәйғамбәрләрнең рухларына

Барып ирешсен.

Шушы нигездән өмет итүче әрwахларға барып ирешеп,
Каберләрен йаķты ķылсын,
Рухларын шат ķылсын.
Ахирәт көннәрендә җәннәтләргә
Керергә насиб итсен.
Җәннәт ләззәтләрен
Күрергә насыйб итсен
Аллаһының ризалығы өчен булсын,
Хәйереңне ķабул итеп алдым.
Җәмәғатең белән тигез ғомер кичерегез,
Балаларығыз мә рхәмәтле балалар булсын,
Җөргән җирләрегездә имин җөрегез,
Эшләгән эшләрегезнең файдасын күрегез,
Тәннәрегезгә сәләмәтлек,
Җаннарыгызга тынычлык бирсен.
Дөнйалыķта әмәл өчен,
Ахирәттә иман өчен,
Әрwахларны шатландырырга
Җәннәт түрләрендә булу өчен.
Атабыз Әдәм,
Анамыз Хаwа рухына бағышлыйм,
Барлыķ пәйғамбәрләр рухына багышлыйм.
Мәгърип белән мәшриķ арасында
Шушы гаиләдән өмет иткәннәр
Рухына бағышладым.
Таудагы изгеләр,
Баба изгеләре,
Су изгеләре,
Нигез хужаларына багышладым.

И раббым, син бу сәдәķә биргән бәндәне үзеңнең рәхмәтеңнән, пәйгамбәребезнең шәфәғатеннән ташлама.

Хөзер галәйссәләмнең ķултыķ астыннан, чыгарма, йул сәфәрләрен имин ķыл. Җомах бүләкләрен, җомах ашларын насыйп әйлә.

Горурланма йөзеңнең айлығына
Масайма син байлығыңа.
Дөнйа малы — бетә торған буйау тик,
Йәш ғомерләр үтә — чылтырап аķķан чишмә тик,
Ķарыйлыкḷар киләдер йөгереп ат тик.

Сират күперен кичкәндә җәшен тик тизлек белән кичәргә насыйп булсын! (Турай авылы).

**Апас районы Караборнаш авылында ķоръән уķығаннан соң дога бағышлау тексты**:

Дөнйалыķта аман өчен,
Ахирәттә иман өчен,
Мәхшәрдә өстендә күләг ә булмаķ өчен,
Сират күперен кичкәндә җитәкче булмаķ өчен,
Тәмуғ утында пә рдә булмаķ өчен
Дөнйалыķта киң дәүләт, киң ризыķ бир,
Ахирәттә җәннәт рәхә тен насыйб ит, йарабби!
Кирәмәт чирәмендәге изгеләр өчен,
Биби әби чирәмендәге изгеләр өчен,
Баба таwы изгеләре өчен,
Ķыз таwы изгеләре өчен,

Қараwыл таwы изгеләре өчен,
Мәмәт чардыwаны изгеләре өчен,
Ташбилге изгеләре өчен,
Ташбилге зиратындагы
Тыштагы wә эчтәге изгеләр өчен,
Уқсын таwы изгеләре өчен.
Дөнйада булған көллөге изгеләрнең рухына булсын,
йарабби!
Шушы Қараборнаш зиратында булған,
Қоштаwы зиратында булған,
Балтай зиратында булған көллөге доғаға мохтаҗ булған әрwахларға ирештер!
Қоръән бағышлағанда, доға бағышлағанда изгеләрне исә алып, аларға бағышлап уқыйбыз.
**Биби чирәме** — анда Биби әби күмелгән. Ул Қара Борнаш белән Қоштаwы арасында.

**Алмағач чирәме** — Қоштаwында. Алмағач чирәмендәге изгеләргә бағышладым, ди.

**Уқсын таw ы изгеләре** — Апас йанында.
**Баба таwы изгеләре** — Турай йанында.
**Қыз таwы, Қараwыл таwы изгеләре** — Дәwеш йанында.
**Кирәмәт асты** — калку җир, Қоштаwылга таба.

— Кирәмәт ул тау, анда изгеләр күмелгән. Кирәмәт таwына менеп йаңғыр теләгәннәр.

**Мәмәт чардыwаны** — безнең изге урын, доғадан қалдырмыйлар.
**Ташбилге изгеләре** — Қолғына аwылы йанында.
Қоръән бағышлаучы шуларның барысын да искә алып әйтеп чыға — *т.я.-к.т.*

— Шушы сәдақә биргән қулларығыз белән җәннәт ишекләрен ачып керергә насыйп итсен, йарабби.

Тәненә с әламәтлек ,
Хәйерле гумеренә бәрәкәт,
Җанына-күңеленә тынычлық бир.
Үзеннән олыларға мәхәббәтле күренсен,
Камил ақылларында йөрергә насыйб итсен!
Килер җирен киң қыл,
Хәләл маллар, хәләл ризықлар насыйб ит, йарабби!
Бақый иманын йулдаш ит.

Қаберләрдән қубарылғанда бақый иман белән қубарылырға насыйб ит.
Сират күперен кичкәндә җәшен тик тизлек белән кичәргә насыйп булсын.
Мәхшәр майданында мәхшәр күләгәләрен насыйп ит,
Ғамәл дәфтәрең уң қулыңнан бирелсен,
Тәмуғ утларын хәрам қыл,
Сигез җәннәт рәхәтен күрергә насыйп булсын,
Кәүсәр шәрабларын эчәргә насыйп булсын,
Ни сорады, ни теләде — морадына ирешсен, йарабби!
Изге йулны йулдаш итик,
Йаман йулға йулықмыйқ.
Бу дөнйада қунақ қына
Булуыбызны онытмыйқ!
(Караборнаш. Сәләхова Гайшә — 94 яшьтә)

**Урта Балтай авылында дини мәҗлестә әйтелгән теләкләр**:

И сәғадәт, бир бә рәкәт,

Изге җиһан, изге дәүләт,
Ач итмә, җалангач итмә,
Үзеңнән түбәннәргә дучар итмә,
Хағыннан — нахағыннан,
Бәләсеннән — қазасыннан үзең сақла!
Дәwам ит дәүләтеңне
Насыйб ит җәннәтеңне.
Бәрәкәт бир қадер мәүлә
Шәфкәтле Рәсүлалла.
Сигез оҗмах суwы белән
Җусаң ыйы җөземне.
Пәйгамбәрләр шәфәгатеннән
Мәхрүм кылма үземне.
Олуғланма дөнйаның байлығына,
Ғорурланма йөзеңнең айлығына.
Дөнйа малы бетә торған қырау тик,
Қарыйлықлар киләдер йөгереп ат тик.
Ақ б әхетләр, киң ризықлар
Тән с әләмәтлеге, җан тынычлығы бир,
Иман белән тудық, иман белән
үтәргә насыйб ит, йарабби ходайым.
(Урта Балтай. Галәветдинова Нурзидә — 89 яшьтә)

**Лаеш районы Атабай авылында дога багышлаганда:**
**Ханкирмән таwы изгеләренең** рухына багышлап доға қылабыз.

Таwык аталап суйабыз, җаңгыр теләргә дә шунда, ханкирмән таwына барабыз.

**Пермь өлкәсе Барда районы Сараш авылында дога багышлау**

***Җиде ғазизләр, тау ғазизләре***

— Җиде тауда җиде ғазизләр, исемнәре билгеле, доға бағышлағанда искә алабыз. Алар тау башында ут йағып, дошманнар килә башласа, бер-берсенә хәбәр бирешкәннәр.

Тол башы — Солтан Әхмәт,
Султанбай — Солтан Гази,
Қызылйар — Хәсән Шәйех,
Ойық Таwы — Солтан Гали,
Җирмийә — Морат Хаҗи,
Боза Тау — Сәйет Сәлим,
Урал Тау — Миңнемәгъсүм.

Безнең йақларда электән килгән риwайәт бар шулай. Шушы риwайәт буйынча, элекке заманда дошманнар килгәндә учақ йағып хәбәрләшкәннәр. Халық дошманнарны қаршы алырға әзерләнгән.

Менә шул тау газизләренең исемнәре дә сакланган.

**Қала тау** дип тә әйтәләр. Берсе — Боза тау. Җите малайлар — бертуғаннар алар. Элек тау-таш араларында элемтәләр булмаған. Бу җите ғазизләр менә шушы бийек тауларның башларында торғаннар.

Илаһи амин,
Алла ризалығы өчен
Доға қылабыз
Барча өмет иткүчеләргә,
Әүлийәләргә, әмбийәләргә,
Барча өмет иткүче
Әрwахларға бағышладым.
Йарабби Аллам! Ошбу уқыған

Қоръән айәтләрендә булған
Хата-кимчелекләрне үзеңнең
Рәхмәтең белән кичергәй идең.
Қабуллардан қылғай идең.
Су хужаларына,
Җир хужаларына,
Җул хужаларына,
Җите ғазизләргә бағышладым,
Җите ғазизләрнең
Җите урыннарын белеп бағышладым,
Қабул итмиче қара итеп йөземә орма,
Қабуллықларың белән шатландыр.
Барча изгеләрнең, остазларыбызның,
Җите ғазизләрнең,
Җите солтаннарның,
Қәрт әниләрнең,
Қәрт этиләрнең,
Ата-бабаларның,
Унбер Әхмәтләрнең,
Ислам динендә wафат булған әрwахларның
Аwыр туфрақларын җиңгел қылып,
Иман нурлары белән нурландырып,
Ахирәт нигъмәтләрен насыйб әйләсәң ийе.
Дөнйалықта белеп қылған,
Белми қылған ғөнаһларын
Ғафу қылғай идең,
Мизаннарға салғанда
Ғөнаһларын җиңел қылып
Изгелекләрен аwыр қылғай идең.
Қыйәмәттә, мәхшәр көннәрендә
Җәһәннәм утларыннан сақлағай идең.
Һәм дә пәйгамбәребезнең шәфәғатенә ирештереп
Аларға үзең йардәмче булғай идең.
Хәйерле-бәрәкәтле гомерләр насыйп әйлә,
Җәннәт дидарларын да күрергә насыйп әйлә.
Җәннәттә мәҗлестәшләрең булырға насыйп әйлә,
Рәхмәтләрең киң,
Мәрхәмәтләрең чиксез, илаһи амин!
Йарабби Аллам,
Ризалығыңнан айырмасаң иде,
Саулықта, тынычлықта, тигезлектә,
Балаларға, онықларға сөйенеп
Йәшәргә насыйб әйләсәң иде.
Озын ғомерле булың,
Исән-сау булың,
Минең кебек туқсан йете йәш булың.
Йортларға-җирләргә иминлек,
Тормышларына бәрәкәт биреп,
Бәләләрдән-қазалардан,
Афәтләрдән-аwырулардан сақлағай идең.
Доға бағышлағанда хаслап бағышлыйбыз.
Йараббым, шушы уқыған айәтләрнең
Әҗер саwапларын
Үзеңнен ризалығың белән,
Уқуwымда булған йалғышлықларны,
Хаталарны ғафу иткән хәлдә

Җир йөзенә килеп киткән барча
Изгеләребезнең, пәйғамбәрләребезнең,
Миннән доға өмет итүче
Барлық әрwахларның рухларына
Бағышлыйбыз.

## Әстерхан сөйләшендә багышлаулар

Әй, раббым Аллам,
Шушы сүрәләремне багышладым
Рәсүлемезнең рухына,
Рәсүлемезнең ата-анасы,
Әби-бабаларының рухына бағышладым.
Әдәм атамызның рухына бағышладым;
Хаwа анамызның рухына бағышладым;
Хәзрәте Ғали, Әбүбәкер, хәзрәте Ғосман,
Хәзрәте Ғомәр рухларына бағышладым;
Хәсән-Хөсәйен рухларына бағышладым;
Әминә анамызның рухына бағышладым;
Фатима анамызның рухына бағышладым;
Мәрйәм анамызның рухына бағышладым;
Җайдақ бабаның рухына бағышладым;
Кендек бабаның рухына бағышладым,
Мансур бабаның рухына бағышладым;
Нур бабаның рухына бағышладым
Сары Хуҗа бабаның рухына бағышладым;
Қара Хуҗа бабаның рухына багышладым
Җиде қыз әүлийәләрнең рухына бағышладым;
Җиде султан бабаның рухына бағышладым;
Унбер Әхмәт бабаның рухына бағышладым;
Төкле бабаның рухына бағышладым;
Мәхмүт бабаның рухына бағышладым;
Сындық бабаның рухына бағышладым;
Йаңғырчы бабаның рухына бағышладым;
Нурмөхәммәт, Нурәхмәт бабалар рухына бағышладым;
Өмет әүлийәләрнең рухына бағышладым;
Күз әүлийәләренә бағышладым;
Қырда Қозыр баба рухына бағышладым;
Суда Султан бабаның рухына бағышладым;
Мәғриптән мәшриққә, мәшриқтән мәғрипкә
исемен белмәгән әүлийәләрнең рухына бағышладым.
Үземнең атам-анам, бабам-мамаларым рухына
бағышладым.
Иремнең, қайнанамның, қайнатамның,
Туган- тохомнары рухына бағышладым.
Тумақ әүлийә рухына бағышладым,
Мансур әүлийә рухына бағышладым,
Күгәнле әүлийә рухына бағышладым
Үзебезнең үле түбәдә булған,
Исемнәре онытылган,
Җирләре тигезләнгән әрwахларның рухына бағышладым;
Туқсан туғыз мөшейақларға бағышладым,
Унбер Әхмәтләргә бағышладым,
Өч йөз алтмыш алты гаиб ирәннәренә бағышладым.
— Уқылған қорән-намазларымны Мөхәммәт пәйғамбәр рухына бағышладым.
Барча әүлийәләр, әмбийәләр рухына бағышладым;

Хәзрәти Әминә, хәзрәти Ғаптулла,
Хәзрәти Хәлимә рухына бағышладым,
Оҗмах сақчыларына, Қабер сақчыларына,
Тәмуғ сақчыларына бағышладым.
Әстерхан түгәрәгендәге,
Үзебезнең аwылдағы
Ғазиз җегет әүлийә,
Норатан, Ғәйшәхан, Фатыйма әүлийәләрнең,
Нурмөхәммәт бабам рухына бағышладым.
Күз әүлийәсе Күккүз атам,
Сынықчы әүлийә Чупаш бабам
Рухына бағышладым (Киләче авылы).

**Дини мәҗлестә туган-токымнарына багышлау**
(әстерхан сөйләшләрендә)

Қоръән ашлары, дини мәҗлесләрдә дога багышлауда туганлык җепләренә нык игътибар итеп, кеше исемнәре дә аерым-аерым атап әйтелгәнлектән, әстерхан сөйләшендә язып алынган багышлаулар эчтәлекләре һәм лексикасы ягыннан аеруча үзенчәлекле.

Үземнең атам-анам,
Бабам-мамаларым рухына бағышладым,
Иремнең, қайнанамның, қайнатамның
Туған-тохомнары рухына бағышладым.
Иман җулдашлары булсын,
Тар қаберләре киң булсын,
Йатқан җирләрендә тыныч йатсыннар.
Укыган корән сүрәләремез шушында утырған
**Мөслихә тәтәмездән** доға өмет иткән
**Усман бабасы** рухына,
**Мухамбит этисенең** рухына,
**Уразбикә энисенең** рухына,
**Шәрифә мамасының** (әбисенең) рухына,
**Рабиға тәтәсенең** рухына,
**Сәлимә кайнанасы** рухына,
**Нурҗамал мамалары** рухларына һәм башка
ир һәм қыз қардәшләре рухларына бағышладым. Барсының да рухларын шат әйлә, қаберләрен нур қылып, иманлы бәндәләр булып йатсыннар.

— **Сафура тәтәмезнең Әптелгәзиз атасы** рухына,
**Мәрйәм анасы** рухына,
**Хәким энесе** рухына,
**Қобби сеңлесе** рухына,
**Әбибә қайнанасы** рухына,
**Қолби кәйембикәсе** (иренең апасы) рухына,
**Аптулла қайнағасы** рухына багышладым.
— Шушында утырган **Лүцийәнең Маннап атасы** рухына,
**Разийа анасы** рухына,
**Асийә тәтәсе** рухына,
**Ғыйззәтулла қайнатасы,**
**Хәлимә қайнанасы** рухына,
**Кажбибә, Саҗидә тәтәләре** рухларына,
**Нурсолтан җизнәсе** рухына,
**Әйшәби тәтәсе** рухына багышладым.
— **Ғомәрбик, Ризабик қахамнар** (абыйлар) рухына
бағышладым,

**Норби , Зөрә мамамнарның** рухларына бағышладым,
**Сәрби тәт әм, Йосып қахам** рухларына,
**Қайбулла қахам** рухына,
**Зариф, Хәмит қахам** рухына,
**Сажидә тәтәм** рухына бағышладым.
— **Зөбәйдә кардәшемезнең Ураз атасы** рухына,
**Зөләйха тәтәсе** рухына,
**Нәфисә қайнанасы** рухына бағышладым.
— **Разийа тәтәмезнең Сабир хәләл жефете** рухына,
**Мөхәррәм атасы** рухына,
**Мәрйәм анасы** рухына,
**Қасим ағалары** рухына,
**Фатыйма, Нәғыймә тәтәләре** рухына бағышладым.
— **Нуржамал тәтәмезнең Ибраһим ағасы** рухына,
**Фатыйма, Нәгыймә, Миннекамал әнисе** рухына,
**Камали ағасы** рухына,
**Баһаwетдин қахасы** рухына бағышладым.
— Минем үземнән дога өмет иткән **Кәрим бабам улы**
**Нәсир атам** рухына бағышладым,
**Рәхимә мамам** рухына бағышладым,
**Йосыбәле бабам** рухына бағышладым,
**Шәрифә мамам, Маймана мамам** рухына,
**Хәким бабам, Йөрежек бабам,**
**Уразбикә, Нуржамал, Жәннәтхан мамаларым** рухларына
бағышладым.
**Исмәгыйл бабам, Зәйнәп тәтәм,**
**Туқтамыш қахам** рухына,
**Нурсәнә жиңгәм** рухына бағышладым,
**Көлби йаучыбикәм** рухына бағышладым,
**Фирүзә аданашым** рухына бағышладым.
— **Зөлхәбирә тәтебезнең Фәрит атасы** рухына,
**Қомарбик ағасы** рухына,
**Ноғман бабасы** рухына,
**Хәнифә тәтәсе** рухына,
**Аптулла, Мәүлет, Хәмит ағалары** рухына бағышладым.
— **Зөһрә қызыбыздан** доға өмет иткән **Юныс бабасы,**
**Абдулла атасы** рухына,
**Хәдичә мамасы, Миңлебай бабасы** рухына,
**Әхәт ағасы** рухына,
**Илдус ағасы** рухына, ир һәм кыз кардәшләре рухына
бағышладым.
— Безнең йаныбызда утырган **Рәмзийәдән** дога өмет иткән үзенең **Нурғали атасының** рухына,
**Колби анасының** рухына,
**Әжәрхан мамасының** рухына,
**Ибраһим бабасы** рухына,
**Сагындық жизнәсе** рухына,
**Қормаш қайнатасы** рухына,
**Жома кызы Орқыйа қайнанасы** рухына,
**Зәғыйфә мамасы** рухына,
ир һәм қыз қардәшләренең барысының да рухларына
бағышладым.
**Мағира мамам, Әйшә мамам,**
**Галиәкбәр бабам, Сажидә тәтәм,**
**Бибиғайшә мамам, Айынби жиңгәм,**
**Хәбибә, Көлләчә киленнәре,**

**Ибрай баба, Көлби, Норҗамал, Акби тәтәм,**
**Уразбик ә әйем, Курман баба,**
**Пахруш мамам, Мақыт бабам,**
**Җомагали баба, Қодрәйхан мама,**
**Ибләбин қахам, Байсалық,**
**Ақбабай бабам** рухларына бағышладым.
Йаткан җирләре җәннәттә булсын, рухлары шат булсын.
**Асийә тәтәмезнең Қасим агасы** рухына,
**Кәрим хәләл җефете** рухына,
**Рәмзийә қәйен сеңлесе** рухына,
**Мөтәлип җизнәсе** рухына багышладым.
**Санийә тәтәмезнең Самат атасы** рухына,
**Насир мулла** рухына,
**Салихат тәтәсе** рухына,
**Саҗидә сеңлесе** рухына,
**Зөлхәр қахалары** рухына,
**Қолби мамасының** рухына,
**Зәйкән җиңгәсе** рухына,
**Әҗәрхан, Әминәхан атайбикәләре** (әтисенең апалары) рухына,
**Норби тәтәләре** рухына,
**Маннап қайнатасы, Зурахан қайнанасы** рухына,
**Сәрби тәтәсе** рухына,
**Қапиз бибиатасы** рухына,
**Қапиз биби әйесененең** рухларына бағышладым.

— Мәүлет айында пәйгамбәребезнең туган көнен котлап **Хәнифә кардәшебез** баwырсақлар, кәнфитләр биреп җибәргән.

Тормышларына бәрәкәт бирсен,
хәләл ризықлар бирсен,
аңардан доға өмет иткән
ир һәм қыз қардәшләренең рухлары шат булсын,
қайнатасы-қайнанасының рухлары шат булсын,
урыннары җәннәттә булсын.

— **Мәрҗән маманың** (әбинең) **кызы Сөйембикәнең** дә алып килгән бәйрәмашларын аллаһы тәгалә қабул итсен,

гаиләсенә сәламәтлек, татулық,
аwызберлекләрен бирсен,
тормышларында бәрәкәтле маллар,
хәләл ризықлар бирсен,
бабалары, мамалары,
ир һәм кыз қардәшләре рухлары шат булып,
тормышларының хәйерен күреп йәшәмәгә насиб итсен.
— Барча бездән доға өмет иткән
баба-мамаларыбызның,
қайната-қайнаналарыбызның,
қәйембикә, ир һәм қыз қардәшләребезнең, қәйенсеңелләребезнең,
хәләл җефетләребезнең рухына бағышладым.

Килер җирен киң ит,
Чығарын тар ит,
Дус теләген бир,
Дошман теләген түбән ит,
Йақшыға йулдаш ит,
Илгә-йортқа тынычлық бир.
Атам-анам,
Барча қардәш-ыруларымның
Рухлары шат булсын,
Тар гүрләре киң булсын,

Қараңгы гүрләре йақты булсын,
Аwыр туфрақлары җиңел булсын,
Йатқан җирләре җәннәт булсын.
Йаланнарда, йапаннарда
Җан тәслим иткән
Әүлийәләрнең, әмбийәләрнең
Рухларын шат ит.
И аллам, әҗәлләргә сабырлық бир,
Аwыруыма шифа бир,
Балаларыма теләкче булып утырмаға нәсиб ит.
Шушы қызым кийәүгә барып игелеген, бибийен
күрмәгә нәсиб ит.
Илемә-йортыма тынычлық бир,
Аwыл-күршемә тынычлық бир.
Төрле бәла-қазалардан саклагайсың,
Ут бәләсеннән, су бәләсеннән
Үзең сақлағайсың, —
дигән сүзләр белән доға бағышлыйбыз.
Шушы искә алынған әрwахларыбызның,
Бездән доға өмет иткән туған-қардәшләребезнең,
Үзләренең хозурына барған дөнйалықта
Бәндәчелектә белеп қылған, белми қылған
Гөнаһлары, хаталары, кимчелекләрен
Үзең йарлықа, бездән барчабыздан
Разый қыл, йарабби.
Қараңғы гүрләре йақты булсын,
Тар қаберләре киң булсын,
Йатқан җирләре нур булсын,
Бақый иман йулдаш булсын,
Җәннәт хөлләләрен кийәргә нәсиб ит,
Тәмуғ утын тигезмә, —
Җәмғый әрwахлар,
Менә артында берәү дә булмаған
Әрwахларға да бағышлыйм (Кызан авылы).

**Дини мәҗлестә ялварулы теләкләр**

**Әстерхан сөйләшендә:**
И аллаһы тәғаләм,
Илемә-йортыма тынычлық бир,
Аwыл-күршемә тынычлық бир,
Бар балаларыма да саулық-сәламәтлек,
идайәтлек, тәүфик, шәпқатлек бир,
Қызларыбызға-кийәүләребезгә,
Улларыбызға-килennәребезгә,
Өлфәт мәхәббәтләрен биреп,
Тигезлекләре, татулықлары белән,
Аwызберлекләре белән
Йәшәмәгә насип ит, йа Рабби.
Ачқычыңны ача бир,
Рәхмәтеңне чәчә бир,
Өсләренә хөллә бир,
Башларына таҗ бир,
Атланырга пырақ бир.
Төрле бәла-қазалардан үзең сақлағайсың,
Ут бәләсеннән, су бәләсеннән үзең сақлағайсың,

Күренер-күренмәс нахак бәлаләрдән үзең сақлағайсың,
Тапқан табышларының, малларының хәйерен
күргәйләр иде,
Бәрәкәтле табышлар булғай иде,
Үземә дә саулық биргәй идең.
Әгәр әҗәл бирсәң, иман бир.
Түремдә иманымны әйтеп, изге көннәрдә саф-йан көйенчә дөнйадан үтәргә нәсиб итсәң иде.

Менә шуларны әйтеп садакамны салам, туған-тохомнарымның ба---рысын да йаз итәм.
Дөнйалықта аман өчен булсын,
Ахирәттә иман өчен булсын,
Сират күперен кичкәндә йулдашың булсын.
Балаларның қайғы-хәсрәтлә рен, кийекләрен күрсәтмә, йарабби!
Кийәүгә бармаған қызының бәхете ачылып, шатлығын күрмәгә на---сиб итсен, йарабби.
Шушы эшләп торған хезмәтендә
Илгә иләүле, халыққа қаләүле,
Эшендә дәрәҗәле булып йөрмәгә насиб итсен.
Шушы йортта ғомер иткән бәндәләргә
Төн тынычлығын бир,
Көн қуанычын бир,
Без бәндәңне ач итмә,
Үзеңнән ғайрегә мохтаҗ итмә,
Хәләл ризықлар насыйб ит,
Харамнардан йырақта йөрет,
Йаратқан ғазиз аллам!
Мин риза ғумер биргәнеңә,
Қалған ғумеремә саулық бир,
Бер зат та сорамыйм, Аллам тәғаләм.
Дөнйабыз бар, байлық бар, балаларым аман, башым қадерле, Алланың биргәненә шөкер.
Йаз көнендә үсеп утырған игеннәребезгә уңышлар бир,
Мал-туwарларыбызға бәрәкәт бир,
Туған-кардәшләребезгә,
Үсеп утырған балаларыбызга
Тәүфыйқ идайәт бир,
Бәхетле қартлықлар насыйб ит,
Түшәк-җастықларға салып
Кеше қулына қалдырма.
Аз аwырулар, җиңел үлемнәр
Бирмәгә насыйб әйлә!
Йалғыз балаларыбыз,
Йалғыз қызларыбыз булса,
Буй җитеп торған йегетләребезгә
Хәләл ана сөте имгән
Бәндәләр насыйб итеп,
Бәхетләре ачылып,
Тормышларында шатлықлар,
Қуwанычлар күрмәгә насыйб итсен.
Өй-йортларыбызны җил-даwыллардан,
Җирнең тетрәwеннән сақласын,
Йәшен төшүдән,
Шайтаннардан, сихердән сакласын,
Йаман күзләрдән сақласын.
Балаларыбыз-кардәшләребез
Қайда йөреп торсалар да
Хөзер Илйас йулдаш булсын,
Шайтаннардан, сихердән сақласын,

Йаман күзләрдән сақласын.
Әйткән нәзер-нийәтләре өчен булсын,
Онытылған нәзер-нийәтләре өчен булсын,
Әйткән нәзер-нийәтләре өчен,
Унике саннары сәламәт булсын өчен,
Ике күзләренең йақтылыгы өчен булсын
Җирдән-күктән иңә торған афәтләргә
Пәрдә булсын өчен, амин, аллаһы әкбәр.

Шушы йортта тереклек итә торған бәндәләрнең барчасына хәйерле тазалық, хәйерле тынычлық бирсен.

Көн тынычлығын,
Көн қуwанычын бир,
Маллары әз булса да
Күп қуwанычлар бир,
Ахирәттә иман бир,
Дөнйалықта йөзләрнең ақлығын бир.
Йараббыйым йарлықа,
Дошманнарын тарлықа,
Барча ғөнаһларын йарлықа (Киләче авылы).

**Самара өлкәсе татарларында ялварулы теләкләр**
**һәм дога багышлаулар**

Похвистнево районы Гали (Алькино) авылында ялварулы теләкләр

***И, илаһым, йарлыка***

И, илаһым, ярлықа,
Йарлықағучы йаппарсың,
Сақлағучы саттарсың,
Сақладисәң бәләдән,
Телебезне тотлоқторма доғадан,
Дәwерле эшкә дәүләт бир,
Хәйерле эшкә бәрәкәт бир,
Бу дөнйадан киткәчен,
Бездин доға өмет иткәчен,
Әрwахларның рухына,
Сырхауларға дару бир,
Йулға чықсаң — йул булсын,
Малыбыз — мөлкәтебез күп булсын,
Сезгә дошман булғаннар,
Сезгә килеп қол булсын,
Хурлағаннар жуқ булсын,
Әр барчабызға җәннәттә урын булсын.

***Тубый агач***

Тубый ағач төбендә
Торса идем, ходайым.
Тубый ағач йафрағын
Күрсә идем, ходайым.
Илтеп гүргә қуйарлар,
Миннән сөал сорарлар,
Корайыш атлы йыланга
Сәлам биреп қуйарлар.
Мәдинәдә-Мәккәдә
Булыр бер көн кыйәмәт
Гөнаһларны гафу әйлә,

Бер ходайым үзең йақла.
Корайыш атлы йыланнан
Бер ходайым үзең сақла.

### *Йаттым, йә Алла*

Йаттым, йә алла ,
Торымын, инша алла.
Бу йатудан торалмасам,
Иманымны бир алла.
Йаттым тыныч,
Йастығым — кирпеч,
Динем — ислам,
Теләгәнем — иман.
Иманым аныҡтыр,
Фирештәм таныҡтыр.
Йан йулдашым имандыр
Иманымны бир алла.
Башымны ҡуйдым йастыҡҡа
Күңелемне бирдем аллаға.
Аллаһы, аллаһы дигәндә
Караңғы гүрем йактырсын.
Собханалла дигәндә
Оҗмах ишеге ачылсын.
Тирә йагым тимер казык
Керә алмасын бәдбәхет.

*Самара өлкәсе Похвистнево районы Гали авылы.*
*Моратханова Наилә, 1936 елгы*

### *Илаһи, тәүфик бир*

Илаһи, көндин көн тәүфик бир,
Берен бирсәң — барын бир,
Дөнйалыкта — дөнйа рәхәте,
Ахирәттә — ахирәт рәхмәте бир.
Каһәрең салсаң — ҡаһәрең бар,
Ҡаһәреңдин ҡурҡуым бар,
Рәхмәтең салсаң — рәхмәтең бар,
Рәхмәтеңдин өметем бар.
Колларыңа кол итмә,
Дошманыңа йар итмә.
Тәрәзуға салғанда
Гамәлемне аwыр ит,
Гөнаһымны җиңел ит.
Тубый ағач төпләрендә
Ғарши күләгәсендә утырырға
Насыйб ит.
Иманыбызны йулдаш ит,
Ҡаберебезне нурлы ит,
Сират күперен үткәндә
Айаҡларны тайдырма.
Иман нуры Фатыйма,
Иманыбыздан айырма.
Атам-анам,
Дус-ишләрем белән бергә

Ғайшә—Фатыймага йулдаш ит.

*Самара өлкәсе Камышлы районы, Яңа Ярмәк авылы. Гарифуллина Миннегаян Сәгыйт кызы. 81 яшьтә*

**Самара өлкәсе Камышлы районы, Иске Ярмәк авылында дога багышлаулар**

Бер ходайым, үзеңә тапшырдым,
Шушы уқыган догаларымның
Әзен күп итеп,
Белмәгәнеме белгән итеп,
Дөрес итеп, күп итеп,
Қабул итеп алсаң ыйы
Пәйгамбәребез Мөхәммәт салаллаһи
Ғалиәссәләмнең рух шәрифләренә бағышлыйм.
Җиде буын әби-бабаларыма,
Әти-инәйләргә,
Барча туғаннарға,
Кардәш-кабиләләремә бағышлыйм.
Йатқан урыннарын йомошақ ит,
Тар гүрләрен киң ит, нурлы ит,
Рәхмәт фәрештәләре йаннарында
Йардәм итеп тореын,
Урыннары оҗмахта булсын.
Мәңге-мәңге, һәрбарчабызға
Урыннарны оҗмахта насыйб итсәң иде.
Җүкәле тау изгеләре рухына
Дип тә бағышлыйбыз.
Барасы туфырағыма,
Йатасы туфырағыма,
Йөрисе туфырагыма да бағышлыйм.
И ходайым,
Шушы укығаннарымы қабул ит,
Дөнйалықта балаларга
Йулларын уңышлы ит,
Тормышларын бәхетле ит,
Безгә шәфкатьләрен насиб ит,
Бергәләшеп, сөйләшеп, киңәшеп
Йәшәргә насиб ит,
Йөргән йулларын уңышлы ит, ходайым.
Барчабызга оҗмахта булырга насиб
Итсәң ийе, йараббый ходайым.

*Камышлы районы. Иске Ярмәк авылы.*
*Шәйдуллина Заһидә Гыйльметдин кызы. 1928 елгы*

**Самара өлкәсе Похвистнево районы**
**Иске Мәчәли авылында дога багышлаулар**

Биргән садакаң Аллаһы тәгаләнең
Ризалыгы өчен булсын,
Рамазан айының садакасы булсын,
Синнән доға өмет иткән әрwахларға
Нур булып барсын,
Әби-бабаларыңа,
Әтийеңә-әнийеңә,

Кан′н′а-кан′атаңа ,
Ир туганнарыңа, кыз туганнарыңа,
Кардәш-кабиләгә,
Газиз балаларыңа,
Илаһым хаҗ саwапларын, әҗер саwапларын бир,
Йарабби, дөнйалыкта исәнлек-саулык,
Тыныч көннәр, хайерле гомерләр,
Хәләл ризыклар, бетмәс дәүләтләр,
Бакый иман бир.
Илаһи кәрим, гафур рәхим,
Ошбу биргән садакаң
Ут-су бәләсеннән,
Җир-күк афәтләреннән,
Хәwеф-хәтәрләрдән
Саклагай иде.
Булган хәзинәләр,
Булган дәүләтләрегезнең
Хайерлеген күреп йәшәгез,
Балаларыгызның үзләренә
Игелекле дәүләтләр насыйб итсен, йарабби.
Хайерле исәнлек-саулык,
Тыныч көннәр,
Хәләл ризыклар,
Бетмәс дәүләтләр, бакый иман,
Башларыбызга камил акыл,
Зирәк зиһен бир,
Йаннарыбызга тынычлык бир.
*Иске Мәчәли авылы*
*Булатова Гамбәр, 1933 елгы*

**Самара өлкәсе Похвистнево районы**
**Яңа Мәчәли авылында дога багышлау**

Уң кулың белән биргән садакаң
Аллаһы тәгәләнең ризалыгы өчен булсын,
Сөйекле пәйгамбәребез Мөхәммет салаллаһи
Галиәсаәлам рухи шәрифенә,
Әүлийәләргә, әмбийәләргә,
Барча булган табиблар, хабиблар
Рухы өчен булсын.
Җөргән җирләрендә Җабраил фәрештә
Канатын җәйеп торсын.
Хөзер Илйас йулдашың булсын.
Туганнарың-тумачаларыңа,
Әзиләрең-абыстайларыңа,
Җиде буыннан тотынып
Җитмеш буынга тикле
Әҗерләрен насыйб ит.
Башларыгызга сәламәтлек,
Җаннарыгызга тынычлык бирсен,
Бетмәслек чирләр,
Аwыр хәсрәтләр бирмә,
Ике күзләреңнән, ике айакларыңнан,
Ике кулларыңнан мәхрүм итмәсен.
Исән-сау йөреп,
Дәрәҗәле булып картайырга насыйб ит,

Ризыгың киң булсын,
Барыр җирең җәннәт булсын.
*Яңа Мәчәли авылы,*
*Субеева Нәбирә, 1930 елгы*

Раббым, аллакайым,
Укыганнарымны кабул ит,
Гөнаһларымны кичер,
Укыганнарымның әҗерен насыйб ит.
Кендек әбиләрем,
Сөннәтче бабалар,
Хәреф эреткән укытучылар рухына
Йарабби ходайым,
Каберләренә нур булып барсын, амин.
*Яңа Мәчәли авылы,*
*Дәүликамова Вәлимә, 1938 елгы*

**Самара өлкәсе Похвистнево районы Гали авылында дога багышлау**

Илаһым, ошбу уқыған
Қоръән шәрифемне тапшырдым
Үзеңнең ризалығың өчен,
Үзеңнең ғафу хөрмәтең өчен,
Кимчелек-хаталарны ғафу қылынып,
Төзеклекләрдән саналып,
Қабуллықларға ирештер, йарабби, йарабби.
Бағышладым: рә сүлемез Мөхәммәт Мостафа
Салаллаһи рухы шәрифләрен.
Багышладым: барча пәйгамбәрләр,
Әүлийәләр, әмбийәләр, шәһрийарлар рухына.
Бағышладым: сөйекле әтекәйем рухына,
Рухын шат қыл,
Урынын җәннәттә қыл,
Миннән разый кыл, йарабби.
Бағышладым: сөйекле инәкәм рухына,
Аллаһым, үзең қабул қыл,
Урынын җәннәттә қыл,
Миннән разый қыл, йарабби.
Багышладым: сөйекле балаларым рухына,
Рухларын шат қыл,
Урыннарын җәннәттә қыл,
Миннән разый қыл.
Бағышладым: әбиләрем, бабаларым рухына,
Барча ир туғаннар,
Барча қыз туганнар рухына.
И, Аллаһым, кимчелекләре белән ғафу кыл,
Йөзләремә кире қайтарма, йарабби.
Өметләнеп, йалварып сорыйм,
Кулларығызны күтәреп теләгән теләкләрегезне,
Қылган доғаларығызны
Қабул итәрмен дигән wәгъдәләрең бар,
Wәгъдәләреңнән қалдырма,
Күтәргән қулларымны буш қылма,
Өметләнеп сорыйм,
Йалварып сорыйм,
Бер мескен қолың,

Фирештәләрнең амин дигәненә туры китереп,
Турыдан-туры қабул ит, йарабби, йарабби.
Аллаһымның сөйекле бәндәләренә
Зәнки бабай рухына бағышладым,
Гали бабай рухына бағышладым,
Морат бабай рухына бағышладым.
И, раббым, рәхмәтең киң,
Қодрәтең киң, рәхмәтеңнән ташлама, раббым.
*Гали авылы, Моратханова Наилә, 1936 елгы*

**Самара өлкәсе Камышлы районы,**
**Яңа Балыклы авылында дога багышлау**

Аллаһының рәхмәте йаусын,
Шушы садакалар кыйәмәткә хәтле җитәкләсен,
Илаһи бер ходайым,
Кылган гамәлләрегезнең ззе күп булсын,
Уң йак дәфтәренә изгелекләр йазылса иде.
Газиз ата-инәләреңә,
Әби-бабаларыңа,
Ахирәт дусларына,
Кендек әбиләреңә,
Сөннәт бабаларыңа,
Ир һәм кыз туганнарыңа,
Җиде күршеңә ирешсә иде, йарабби.
Дөнҗа бәләләренә,
Ахирәт бәләләренә фәрдә кылса иде.
Актык сулуларыбыз шушы садака хөрмәтенә
Камил булып кына китсә иде.
Нурлы иманыбыз йулдаш булса иде.
Шушы биргән садакалар
Илтеп гүргә куйганда
Үзеңне каршы алса иде.
Кеми атасы булыр,
Кеми анасы булыр,
Кеми угланы булыр.
Мин синең садакаң, ди, каршы ала.
*Яңа Балыклы авылы,*
*Багаветдинова Сара, 1916 елгы*

**Самара өлкәсе Похвистнево районы**
**Яңа Мансур авылында дога багышлау**

Биргән садакаларың Аллаһы тәгәләнең
Ризалыгы өчен булсын.
Пәйгамбәребез мөхәммәт Мостафа салаллаһи
Галиәссәлам рух шәрифләре өчен булсын.
Шагъбан айының садакасы булсын.
Ошбу җомга көннең садакасы булсын,
Әби-бабаларың, әти-әниләрең,
Кан′ата-кан′аналарның,
Хәләл җефетләреңнең өлеше булсын,
Чәйеңнең бөртеге сайын
Әҗер саwапларын бирсен Аллаһы тәгалә,
Йөргән йулларында
Хөзер Илйас йулдаш булсын,
Хәтәр-хәwефтән,
Бәла-казаларданАллаһы тәгалә үзе сакласын,

Һәммәбезне туры йулга кертергә булсын.

*Яңа Мансур авылы*
*Шиапова Тәнзилә, 1936 елгы*

Бу биргән садакаларың Аллаһы тәгаләнең
Ризалыгы өчен булсын.
Синнәт доға өмет иткәннәрнең
Рухлары шат булсын,
Қаберләре нурлы булсын,
Үзегезгә сәламәтлек, тыныч тормыш бирсен,
Йергән җирләрегездә,
Торган җирләрегездә
Үзегез теләгәнгә ирешергә насыйп булсын,
Мәйетләргә нур булсын,
Терекләргә хуш булсын
Әҗәлләргә сабырлык,
Түрәләргә, падиша хәзрәтләргә иминлек бирсен.
Аллаһы тәгалә күңелләренә
Йактылыклар салсын.
Уқығаннарымны қабул кыл,
Йарабби раббым,
Шәфәгатләр насыйп кыл,
Җир йөзенә килеп киткән
Көлле пәйгамбәрләргә,
Унбер анабызга багышладым.
Җирдән күккә,
Күктән җиргә,
Синнән дога өмет иткән
Әби-бабалар, ата-аналар,
Қардәш-қәбиләләр,
Ир қардәшләр, қыз қардәшләр,
Туған-тумачалар,
Көлле мәйетләр рухына бағышладым,
Доға өмет иткәннәрнең
Қаберләре нур булсын,
Рухлары шат булсын.
Бисмиллаһи — безнең ишегебез,
Тәбарәк — безнең диварыбыз,
Йасин — безнең түбәбез.

*Яңа Мансур авылы,*
*Миназеева Гилменур, 92 яшьтә*

## СЕБЕР ДИАЛЕКТЛАРЫНДА ДИНИ МӘҖЛЕСТӘ БАГЫШЛАУЛАР

### Дога укыгач үлгәннәр рухына багышлау

**Түмән сөйләшендә**:

— *Мәйетләр ыруғына* булсын. Кирәйет сираттағы, Арғаwыл сиратта, Эрбет сиратта йата торған *мәйетләр ыруғына* ошо сәдәқәне қабул ит — *төм*.

Теге дөнйадағы йақыннарыбысның
Урыннары очмахта булсын,
Рухлары шат булсын,
Гүрләре йақты,
Туфрақлары йомшақ булсын.
Әмбийаларның, әүлийаларның
Рухларына тоға қылайық.
Қанчабыр сиратларында йатқан

Әүлийа бабаларымның рухына булсын!
Сатақаға сары булып[1] йатуцы
Йәтимнә рнең дә рухларына булсын.
Атылып үлгән мулла бабаларымның
рухларына да булсын.
Қайтыр йулың йарық булсын,
Бәғытле, ырисықлы булып йәшәң.
Сиратыбыста йатқан йақшыларыбысның,
Ишаннарыбысның рухына ирештерсәң иде, амин.

[1] *Сатақаға сары булу* — садака көтеп тору.

Йатқан туфрақлары йомошақ булсын,
Қараңгы гүрләре йарық булсын,
Чаннары очмақта булсын,
Очмақ ишекләре ачық булсын
Очмақ йемешләре белән туқланғалы йассын,
Песнең теләгән теләкләребес
Үлекләребескә ахирәт ашлары,
Ахирәт йемешлә ре булып барып йетсен
Үлек — қатымға туймайты,
Йер — сыуға туймайты, —
тип әйтәтеләр порнағы кешеләр[1].

Мәйеткә рухына бағышлап уқыла, ә терекләргә йан сәләмәтлегенә тип уқыла. Алай нийәтләп уқыла.

Үлгәннәр рухына бағышлап қорбанның чалабыс — *төм*.

Қатым аштан соң туwа қылабыс:

Аш-сыуларығысқа бәрәкәтләр бирсен,
Аш-сыуларығыс өстәл қашлартан өселмәсен,
Қыйәмәт көнен көтеп йатқан әрwахларыбысға
Бүләк булып барсын,
Қабер ғазаплары йиңел булсын,
Бәндәчелек белән қылған ғонаһларын йарлықағыл, —
Киң ыризықлар, киң дәүләт бир,
Килер йулларын киң қыл,
Алла тәғалә ошу биргән ыризықларны
Тән-саулық, сәламәтлек белән
Ашап-эчеп йәшәғәле насип әйлә, йарабби...

**Дини мәҗлестә әүлияләр һәм үлгәннәр рухына багышлау**

**Тара сөйләшендә:**

Әрwахларыбыс йад ителсеннәр[2].
Пестән доға көтеп йатқан,
Мәгърибтән мәшрикътә,
Исемнәре онытылған,
Нәселләре киселгән,

[1] *Порнағы кешеләр* — борыңгы кешеләр.
[2] *Йад ителсеннәр* — искә алынсыннар.

Көлле әрwахларның рухи шәрифләренә
Ирештерсәң иде.
Қылған доғаларыбыс,
Теләгән теләкләребес қабул булсын,
Ошбу әрwахларыбысға барып йитсен.

Қаберстанда йатқан әрwахларыбыс
Риса булып йатсыннар, амин — *тара*.

**Тубыл сөйләшендә:**

Сопра астаната йатқан
Әүлийәләр рухына бағышлыйм.
Күбәк астанада йатқан
Қасыйм ата рухына бағышлыйм
Раббым, үзеңнең ырисалығың өчен,
Шайтаннан йырақ булмақ өчен,
Барча ғаиб ирәннәрнең,
Шәйех бабаларыбысның,
Куца бабаларыбысның,
Сәңки бабаларыбысның
Астаната йатқан өч йөс алтмыш алты
Әүлийәләрнең, әмбийәләрнең,
Остасларыбысның рухына бағышлыйм,
Кентек нәнәләрем,
Қолағинәм, қолақам Қорманбигә
рухына бағышлыйм,
Ахирәттә иман өчен,
Сират күперен кичкәндә йитәкче булмақ өчен
Қабердә йулташ булмақ өчен,
Урыннары очмақта булмақ өчен — *туб*.
Аллам тәғәләм, фани дөнйада
Қәwеп-қәтәрләрдән сақлап йөртсен,
**Қозер-Илйас бабаларығыз** йулдаш булсын,
Ике иңбашыңдагы ике **фирештәләр**
Шәфәғәтче булсын,
**Дошман қапқаларығыз** йабық булсын,
**Дәүләт қапқаларығыз** ачық булсын,
Қайда йөрсәгез дә
**Бала-бақраларығыз**,
**Тоғомдашларығыз** ғомерле булсын,
**Йирдәге-күктәге фирештәләрдән,**
**Су фирештәләре,**
**қыр фирештәләреннән**
Йардам булсын,
Үстергән бала-бақраларығызның
Рәхәтен күрегез — *туб*.

Уң йак фирештәләренә,
Сул йак фирештәләренә бағышладым,
Күк пәрештәләребесгә,
Күк тәхетебескә.
Йете қат күкнең хәкимебесгә бағышладым.
Күккә қарап, аллаһымнан сорап,
Күк пәрештәләребесгә туwа қылып утырам — *туб*.

### Дини мәҗлестә садака биргән өчен дога багышлау

**Тубыл сөйләшендә:**

— Биргән садақаларығыс очмақ бүләкләре булып барсын.

«И раббым, син бу садақа биргән бәндәнең улларын, қысларын үсеңнең рәхмәтеңнән ташлама! Пәйғамбәребеснең шәфәғатеннән ташлама!

**Хөсер Галәйссәламнең** култык астыннан,
**Җәбраил фәрештәнең** канат астыннан чыгарма!
Йул сәфә рләрен имин кылып,
Исән-сау әйләнеп кайтқалы насыйп қыйлсаң иде.
Очмак бүләкләре, очмак ашлары булсын,
Алла тәгалә бесне тәгамнәрдән айырмасын! — *туб*.
Ахирәтт ә иман өчен,
Кабердә йулташ өчен,
Сират күперен кичкәндә
Йитәкче булмак өчен багышлыйм.
Урыннары очмакта булмак өчен багышлыйм.
Тәннәренә тазалык, сәләмәтлек бирсен,
Кыр бәләсеннән,
Сыу бәләсеннән.
Ут б әләсеннән саклaсын.
Кач саwапларын ирештерсен.
**Хәким аталардан**,
**Тимертөп бабалардан** йартәм булсын.
**Кысыр Илйас, Кыппи куца**,
Әүлийәләр, әмбийәләр,
Шәйекләр, шыклартан йартәм булсын.

Пиргән хәйер-садакаларың **тугыс сират әһелләренә** пүләк булсын, амин!

Садакага сары булып йатуцы әрwахларның,
Садакага сары булып йатуцы йәтимнәрнең,
Садакага сары булып йатуцы әүлийә бабаларыбызның,
Йакшыларыбызның да рухына булсын.
Йөсләрегес йарык булсын,
Йөргән йулларыгыс хәйерле булсын,
Көсер Илйас йулташ булсын.
Әйшә-Патима,
Хәсән-Хөсәйеннәр,
Кыппи-кучалар,
Хәким аталар,
Куча Багаутин, Бәйрәм шәйек,
Карлыгач аналарыбыз,
Су аналарыбыз
Йардәмче булып йөрсөннәр.
Әсәлләрегескә сабырлык бирсен,
Ут-судан, қәтәр-әфәтләртән,
Йел-сәхмәтләртән,
Кайгы-хәсрәтләртән йырак булсын.
Эшләгән эшләрегез уң булсын,
Сикыр -бәләләртән йырак булсын,
Йаман күсләртән,
Йаwыс сүсләртән, гайбәтләртән сакласын, инша алла, амин!
Ут әфә тлә ртән,
Йәшен — күкертләртән,
Йаман корт-куңыслартан,
Йирдәге, күктәге күренер һәм күренмәс бәләләртән,
Йил-куслартан сакласын.
Кичер аллам песнең гөнаһларны,
Гафу ит йалгыш хаталарны — *туб*.

**Астана катымда дога багышлау**

**Тубыл сөйләшендә:**
Астана[1] қатымда[2] астана садақа өләгән[3] сун туwа уғып бағыш---лайбыс.

Астанада йатқан
Йақшыларыбысның рухлары
Шат булсын,
**Пайыш астаната** йатқан
**Хәким ата, Қыппи қуца**,
**Сәңки бабаларның** рухларына бағышладым.
Йегерме сигес **пәйгамбәрләрнең** рухларына бағышладым. **Күбәк астаната** йатқан шәехләрнең,
Өч йөз алтмыш алты **әүлийәләрнең**,
**Әмбийәләрнең** рухларына бағышладым.
Судағы **Сөләйманнар**,
Кырдағы **Хысыр Илйаслар** йулташ булсын.
Раббым, үзеңнең ыризалығың өчен,
Шайтаннан йырақ булмақ өчен,
Барча гаиб ирәннәрнең
**Шәйех бабаларыбызның**,
**Куча бабаларыбызның**,
**Сәнки бабаларыбызның**,
Астаната йатқан өч йөз алтмыш алты
Әүлийә, әмбийәләрнең,
Остасларыбысның рухына бағышлыйм.
**Сопра астаната** йатқан
Әүлийәләргә бағышлыйм — *туб*.

Үлекләр тоға көтәте:
Ата-бабалар,
Куца тоғомнарыбыс,
Йақшылар тоғомнарына,
Әүлийа-әмбийаларға,
Әрwахлар руғына бағышлыйпыс.
Йетмеш тоғомына,

[1] *Астана* — изгеләр кабере.
[2] *Қатым* — хатем; дини мәҗлес.
[3] *Өләгән* — өләшкән.

Пөтөн ырywына,
Әбәсенә, әкә ләренә, тәт әләренә
Пала-пақра, пицәләргә, өннәмә,
Туған-қарындашлар,
Күрше-қунақлар,
Үле-тереләргә,
Ибенә ырywына тоға бағышлыйм.

**Волгоград сөйләшендә дога укыгач багышлау (Лятошинка авылы).**

Дөнйалыкта иман өчен,
Ахирәтт ә дидар өчен,
Кабердә йулдаш өчен,
Кийамәттә тәмуг утыннан пәрдә өчен,
Мәхшәр көнендә нур булып үзегезне
Каршы алырга йазсын.

**Рухларыгызның рухлары** шат булсын, йарабби,
Мәрхүм булган **әни кәбәсенең** рухы шат булсын.
Кабере нурлы булсын ,
Бакый иманы йулдаш булсын,
Йатыр урыннары җәннәттә булсын,
Мәрхүм **ә ти кәбәсенең**,
**Бер тума кардәше** абыйсының
Үзеннән туган баласының да
Рухлары шат булсын,
Каберләре нурлы булсын,
Әтисе белән әнисеннән, **түтешләреннән**
Риза булып йатсын.
Ике йактан килгән
Җиде буынга чике
Әби-бабаларының рухлары шат булсын.
Җиде бабаларның
Җитмеш тогымына чике
Рухлары шат булсын.
**Бер тума кардәшләренең**
**Кан әткәләренең,**
**Кан әнкәләренең,**
**Кан быратларының,**
**Ахирәт дусларыбызның**
Рухлары шат булсын,
Каберләре нурлы булсын,
Иманнары йулдаш булсын.
**Кан әбиләрегезнең,**
**Кан бабаларыгызның,**
**Кан кардәшләрегезнең,**
**Тирә-күршеләрегезнең,**
**Дус-ишләрегезнең,**
**Тума-тумачиларыгызның,**
**Тудык-тудыкаларыгызның,**
**Дәдәләрегезнең, йезниләрегезнең,**
**Әнәнәләрегезнең,**
**Кода-кодагиларыгызның**
Барчасының рухлары шат булсын,
Бакый иманнары йулдаш булсын,
Йатыр урыннары җәннәттә булсын.
Үзегезгә озын каста бирмәсен,
Күз нурыгыздан айырмасын,
Камил акылыгыздан
Айак-кулыгыздан айырмасын.
Үлем wакыты йиткәч
Ару үлем,
Ак кифен булсын,
Тулы иман белән китәргә
Ходайым нәсиб әйлә, йарабби.
Дөнйаларга тынычлык,
Падишаларга сабырлык бирсен,
Кан сугышларын күрсәтмәсен.
Ач итмә, йалангач итмә,
Үзеңнән ғайрегә мохтаҗ итмә.
Тамак туклыгы белән,
Аwыз берлеге белән,

Йан тынычлыгы белән
Йәшәргә йазсын
Үзегезгә хайерле үмер бирсен,
Йортыгызга бәрәкәт бирсен,
Куша картайыгыз,
Оныкаларыгызның туйларын күрергә
Ходайым нәсиб итсен, амин, йарабби.

**Сергач сөйләшендә** (Түбән Новгород өлкәсе) **дини** мәҗлестә дога багышлау (Чембили авылы).

Садаканың олосы булсын,
Алла ризалыгы өчен булсын,
Дөнйада аманнык өчен,
Ахирәттә дидар өчен,
Ахырзаманда иман өчен,
Кабердә йулдаш өчен,
Кийаматлыкта тәмуг утыннан пәрдә өчен,
Мәхшәр көнендә нур булып каршы алырга
Ходайым нәсиб әйләсен.
Җәннәт бакчаларында
Әти-әниләре белән,
**Бер тума кардәшләре** белән
Күрешергә ходайым нәсиб ит.
Мәрхүм булган **эти кәбә сенең**,
Мәрхүмә **әни кәбәсенең**
Рухлары шат булсын
Каберләре нурлы булсын,
Бакый иманнары йулдаш булсын,
Йатыр урыннары җәннәттә булсын.
Балаларыннан, оныкларыннан
Риза булып йатсын, йарабби.
Шулай ук wафат булган
**Әнәнәләренең,**
**Абзиларының, абыз түтешләренең, йезнәләренең, Күршеләре, дус-ишләре,**
**Тума-тумачилары,**
**Тудык-тудыкаларының**
Әрwахлары шат булсын,
Бакый иманнары йулдаш булсын
Каберләре нурлы булсын,
Урыннары җәннәттә булсын,
Үзләренә саулык-сәләмәтлек,
Йортларына бәрәкәт,
Йаннарына тынычлык бир.
Ахыр сулуларыбызда
Иманыбызны йулдаш кылып,
Иң соңгы сүзебез
Лә илаhи илаллh,
Мөхәммәде рәсүл аллаh
Кәлимә се белән үтәргә нәсиб әйлә.
Тамак туклыгы белән,
Аwыз берлеге белән
Йан тынычлыгы белән йәшәргә йазсын.
Айак өстендә,
Акылың дөресендә,
Күз дарйагыз белән үмер итегез.
Сау-сәләмәт булып
Туган илегезгә кат›ып йитегез,
Кайгы-хасрәтсез йәшәгез,

Дөнйага, ил-көнгә тынычлык булсын,
Айыпламагыз! Көлле бәлә-казалардан
Ходай сакласын!
Хак-нахак бәләләрдән,
Ут бәләсеннән,
Су бәләсеннән,
Усал эшләрдән,
Усал кешеләрдән,
Усал сүзләрдән,
Усал күзләрдән, Гөнаһлы эшләрдән
Йарабби, үзең сакла.
Биргән садакаларыгыз
Кийамат көнендә
Йардәмче булса иде,
Дөнйада йәшәгәндә шайтан зәхмәтеннән
Күктән иңгән бәла-казалардан
Сакласа иде, Амин!

**Татарстанның чүпрәле сөйләшендә дога багышлаулар**

**Теке авылы**

Илаһи нийәт кылдым
Биргән садакаларыгызны
Абыз бабайның рух шәрифләренә
Аның тирәсендә булган
Әрwахларның рух шәрифләренә багышларга.

[Абыз бабайның исеме Кодакай булган. Аның бер туганы Төкле баба Әстерхан җирендә күмелгән. Абыз бабайның изгелекләре күп булган. Ул укып, өшкереп кешеләрне айакка бастырган.

Майның соңгы атнасында, йома көнне халык зийылып килә Абыз бабайның кабере йанына. Шунда корбан цалалар, аш пешерәләр. Йат аwыллардан да күп киләләр.

Карцыклар зийылып дисбе тартып утыралар].

Актүбә бабай,
Кодокай бабай рух шәрифләренә
Кодокай бабай — ул абыз бабай.
Актүбә бабай — ул абыз бабайның әтисе.
Актүбә бабай — ул әстерханда.

Абыз бабай ул изге булган. Ул бара икән урманга алашаеын йигеп. Утынны сала, кат а. Алланың рәхмәте белән утынны төйиләр, архан белән бәлиләр икән.

Барча пәйгамбәрләрнең,
Сәхәбәләрнең,
Изгеләрнең, әүлийәләрнең,
Мөслим-мөслимәләрнең
Нәселләре киселеп,
Догага мохтаҗ булган ә рwахларның
Сугыш кырында wафат булган,
Кәфенсез, ченазасыз күмелгән
Мөселман кардәшләребезнең
Иман әһеле булып,
Фани дөнйадан бакый дөнйага күчкән
Барча әрwахларның рухларына ирештереп,
Рухларын шат кыйлсаң иде.

Без йасин укыган wакытта

Абыз бабайларга
Көн ирәннәренә,
Төн ирәннәренә,
Аиб ирәннәргә

диб этеп багышлыйбыз.

Аннары кас ы йортка киләбез, шул йорттагы әрwахларга, көллө хуҗаларга багышлыйбыз.

Көллө хуҗаларга каралты хуҗасы,
Йорт хуҗалары.
Йул хуҗалары,
Йардәмче хуҗалар,
Тимерләр хуҗасы,
Су хуҗасы,
Җир хуҗалары да керә.

Укыганнарыбызны иң беренче ызба хуҗаларына, аиб ирәннәргә, абыз бабайларга дип багышлыйбыз.

Табыннарда утырганда да абыз баба рухына дип дога кылабыз.

**Каракитә авылында дога багышлау**

Йасин бар амнарында да дога укыйбыз да багышлыйбыз, теләкләр телибез.

Йараббым, бер аллам, тукландырдың,
Киләчәктә дә ризыкларыбызны киң кылып,
Туганнар, тумачалар белән
Шушындый табыннарда утырырга насиб ит.
Шушы бүгенгесе
Бәрә’әт кичәсе хөрмәтенә
Ошбу бәндәләрнең биргән сәдәхәләрен
Киң рәхмәтең белән кабул кыйлсаң иде.
Шушы бәндәләрнең теләгән теләкләре
Теләгән моратлары кабул булса иде.
Үзләренә, балаларына, оныкларына
Тәүфик, шәфкәт, мәрхәмәт бир.
Залимнәрнең золымыннан сакланып,
Тулы саулык, олы дәрәҗәләр
Киң ризыклар, байлыклар, саулыклар
белән тыныцлыкта
Йәшәсеннәр иде.
Үзеңә гыйбадәт кылып,
Гыйбадәтче булсыннар иде.
Балалары да тәүфикле, шәфкәтле булса иде.
Әбине әби дәрәҗәсендә,
Әтине әти дәрәҗәсендә,
Әнине әни дәрәҗәсендә
Күрсеннәр иде.
Аң-зиһенле, тулы саулык белән
Йәшәргә насип булсын. Амин.
Аллаһыдан сорыйм сезгә
Бу дөнйаның рәхәтен.
Мәңгелек йортка баргачын
Бирсен ходай җәннәтен.
Йарабби, шушы садакалар
Сират күперендә җитәкче,
Мәхшәр көнендә тәмуг утыннан
Пәрдә булып
Каберләребездә йардәмгә килә торган
Әҗер садакалары булса иде.
Илгә-көнгә тыныцлык
Падишаларыбызга саулык-сәләмәтлек бирсә иде

Һәр кайсыбызга хәйерле сәламәтлек бирсә иде.
Амин, укыган догаларым кабул булсын,
Кабер туфраклары мамык булсын.
Садака биргән бу балаларның
Әби-бабалары,
Кан -кан аталары,
Җиде бабага хәтле булган
Туганнары рухына,
Бергә укыган, бергә эшләгән
Бу дөнйадан киткәннәр рухына,
Бүгенге көнгә хәтле
Килеп киткән
Барча пәйгамбәрләребез,
Барча заһидларыбыз,
Барча габидларыбыз,
Барча мөшәйакларыбыз рухына.
Кемнәр догага бик мохтаҗ булган,
Кемнәрнең нәселе киселгән,
Һәммәсенең дә рухларына
Ирештерсәк иде.
Йарабби, рухларын шат кыл,
Каберләрен нурлы кыл,
Туфракларын җиңел кыл,
Гөнаһларын гафу кыл.
Йарабби, шушы биргән садакаларыгыз
Сират күперләрендә җитәкче,
Мәхшәр көннә рендә
Тәмуг өстөндә пәрдә булып
Каберләребездә сорау wакытында
Йардәмгә килә торган
Нур булып барса иде.
Телебезне гайбәттән.
Үзебезне зинадан,
Кулыбызны харамнан,
Колакларны йук сүздән
Сакласа иде ходайым.
Илгә-көнгә тыныцлык,
Падишаларыбызга саулык-сәламәтлек,
Исән-имин эшләп торырга йазсын,
Барчабызны да раббыбыз ташламаса иде.
Амин, Аллаһы әкбәр, Аллаһы әкбәр.

**Чүпрәле районы Түбән Чәке авылында дога багышлау**

Әгузе билләһи минәшайтан-и-раҗим,
Бисмиллаһи-рахмани-рәхим.
Йә, Раббым, Аллаһы тәбәрәкә wә тәгаләм,
Йә, Раббым, Йә, Раббым, Йә, Раббым.
Биргән садакаң ходай тәгәләнең
Ризалыгы өчен булсын.
Йулда йөргән бу бәндәләрнең
Тәннәренә саулык,
Тормышларына тыныцлык бир,
Балаларына бәхет бир
Йул бәләсеннән,
Ут бәләсеннән,

Су бәләсеннән үзең сакла.
Су хуҗалары,
Җир хуҗалары,
Йул хуҗалары,
Алар йулга чыгалар,
Илаһи, йардәм бир.
Җиде көннең җиде хуҗасы бар.
Бегенге көннең хуҗасы,
Илаһи, аларга йардәм ит!
Сау-исән килгәннәр,
Сау-ис ән әйләнеп кат ырга
Насип булсын,
Йуллары уңышлы булсын.
Миңа биргән садакалар
Аларга килгән бәлә-казаларга
Каршы тора торган булсын, йарабби.
Исәпләмә ғән йирдән,
Гайептән бир, йарабби аларга.
Саулык, тыныцлык белән
Йәшәргә насиб ит, амин.
Хисап сораганда менә шушы
Уң кулың белән биргән садакаларыгыз
Раббым, җитәкче булып,
Малыңнан **зәкийә т** булсын,
Дәүләтеңнән **өмер** булсын.
Үзегезне илгә-көнгә
Күркәм күрсәтеп,
Ике дөнйаның дәрәҗәсен
Үз кулыгызда тотарга
Насип булсын.
Ике дөнйа ацкыцы
Кулларыгызда торсын,
Мал ийәсе булып
Йәшәргә насиб итсен, амин!

## КҮМҮ ҺӘМ ИСКӘ АЛУ ЙОЛАЛАРЫНДА ЕЛАУ-СЫКТАУЛАР

### Сықтау

Борынгы төрки Кюль-Тегин язмаларында кеше үлгәндә йола буенча җырлап елау, такмаклау турында мәгълүматлар бар. Анда **сығыт** термины һәм **сығытчы** — елаучы, ыңғырашучы сүзләре кул---ланылган (*Малов, 1951, 36, 43*).

Мәет күмгәндә җырлап елауның борынгы болгарларда булуы турында Ибн-Фадлан язмаларында әйтелә (*Путешествие, 1939, 77*).

Йола буенча такмаклап йылау Саян-Алтай төбәге халыкларында, мәсәлән, хакасларда сакланган (*Дьяконова, 1975:53*).

Кеше үлгәч кычкырып такмаклап елау, гомумән, татар халкында күзәтелми. Әмма Әстерхан, Себер татарлары, мордва-каратайлар (татарлашкан мордвалар), керәшеннәрдә бу бик борынгы йоланың кайбер үрнәкләре әле безнең көннәрдә дә күзәтелә.

**Җырлап сықтау** — керәшен сөйләшләрендә, **сықтау** — елау мәгънәсендә мишәр диалекты, перм сөйләшләрендә билгеле (*ТТДС, 379*).

### Сықтау — себер диалектларында

«Туй — үпкәсес пулмыйты,
Үлем — сықтаусыс пулмыйты».
Сықтаған сығытларым кән.
— Үлмәстән алта әйтеп қуйған була.

«Син минем пөтөн қылған эшемне әйтеп тақмақлап-тақмақлап сықта, қысым», — тип. Қысы пөтөн нимәсен әйтеп-әйтеп сықтайты. Пөтөн кеше сықтайты. Үсе wәсийәт қылған.
— Пөтөн нимәсен әйтеп сықтайлар йақын туғаннары.

«Бу төнйада ицбер рәхәт күрмәте, очмағынта пулсын рәкәте», — тиләр. Раднуйлары сықтағалы тийеш.

— Қыслары-палалары инәм-инәм тип сықтайтылар. «Йәш башың белән ник үлеп киттең», — тиләр.
Иртән тороп тышқа чыксам
Кошлар сайрый таллықта.
Инәкәйем, күп сықтама,
Қайғы күрдең қартлықта.

— Қарт қортқайақ үлсә «Балаларың йәшәсен, син аш ашатың, йәш йәшәтең, сиңа туй қорткайақ», — тип әйтәсең оллоларға.

«Пала-пакраларға[1] синең йәшең пирсен, осон гомер пирсен, палаларың йәшәсен», — тип сықтайсың. «Сиңа туй инте қарт кешегә, балаларыңа осон гомерләр киң дәүләтләр бирсен», — дисең.

[1] *Пала-пақра* — бала-чага.

— Оллы кеше үлсә «Алланың рәхмәтендә булсын», — тиләр. Йәнкөйәрең[1] үлсә сықтыйлар.
Урны очмақта пулсын,
Тар қаберләре киң пулсын,
Қараңгы гүре йарық булсын,
Иманы йулташ пулсын —
тип туwа қылапыс.
— Рухына бағышлыйсың айәтне:
«Қылған гөнаһларын ғафу қылғайсың, раббым.
Қаберен — нур қыл,
Рухын — шат қыл,
Иманын йулташ қыл».

## Әстерхан татарларында мәетне елап озату

Үле күрке — җылау,
Туй күрке — җыр диләр.

## Бузлау

**Бузлау** *әстр.* елау.

**Бузлаучы** *әстр.* үлгән кеше янында такмаклап елаучы. Элекке ва---кытларда махсус тел остасы «бузлаучы» хатыннарны чакыра торган йола булган. Ногай телендә **бозлау** — үлгән кеше янында такмаклап елау (Калмыков И.Х., Керейтов Р.Х., Сикалиев А.И.-М. Ногайцы. Историко-этнографический очерк. Черкесск, 1988).

— *Бузлаучылар* бик тақмақлап йылыйлар, йылайақ кешеләр йылыйлар бар да.

## Тақмақ әйтеп йылау, җылау

**Такмаклап йылау, жылау** *эстр.* — үлгән кешене озатканда күп сүзләр әйтеп, кешенең яхшылыгын искә алып елау.

Безнең нуғай тақмақлап жылады. Муллалар қушмайды алай жыламаға.
«Күз жашы үлекне суда жатқыза» диде.

[1] *Йәнкөйәрең* — сөйгәнең.

«Жатқан жирендә жәннәтле булсын» дип теләңез, диде.
Тақмақлап жылады:

«Инде ни зат итәйем, қайда барайым»

дип жылады айтып-айтып. Борыннан қалған тақмақлап жылау, безнең мамалар үлегә барғанда тақмағ әйтеп жылайдылар.
Үле түрдә жатқанда да тақмақ әйтеп жылайлар, үзенең эчендәген әйтеп-әйтеп:

«Әни, без синсез ничек торыбыз,
Фәрештә кебек идең , бетен серебез
сиңа сыйа иде, инде кемгә сөйләрбез», —

дип, қычқырып тақмағын әйтеп йыламаға тийеш.

«Әйем, ау, жаным ау,
«Үстердең безне, йакшылығымны
күрәлмәдең, нигә үлеп киттең», —

дип жылай.
— Кеше үлгәч қычқырып йылайды ғуй, йыламасаң аwыру буласың, йөрәгең тотады, қаның күтәреләде.

Апам ыриза бул , тәтәм ыриза бул,
Мине ашаттың, уқыттың,
Килгәндә қаршы алдың,
Син дә ыриза бул,
Мин дә ыриза булыйм

дип, қычкырып-қычкырып йылайды. Йыламаса эчендә қалады ғуй.
Қайнанасы килененә әйтәде.
«Мин үлгәндә тымтын қалма, кеше көләде. Әнә, қайнанасы үлгәндә қуанып йатыр», — дип.
«Утырып йылағыз мин үлгәндә», — дип әйтәде қайнанасы.
«Мин үлгәндә жылаң», — дип әйтәм килennәргә мин дә. «Қызларың бар, қызларың бар, қызларың жылар», — диләр.
— Тақмақлап йылау бар. Армастан (яшь көенчә, картаймыйча) үлеп киткән кешегә бик тақмақлап йылыйлар. Шунда муллалар шамғана (ачулана):
«Бик алай йыламағыз, үлене суда йөздерәсез», — дип.
Чыдамағаны йылый инде. Менә мин дә тақмақлап йыладым ирем үлгәч.
«Бу балалар белән ничек көн күрәм, ни ашатам, ни кийенде---рәм», ди.

«Алдың үзеңә йарасын ,
Артың безгә йарасын», — дип йыладым.

Минем ирем бик сыйлы кеше иде. Йылайақ кеше йылый иде, чыдамыйсын инде. Такмақлый инде жылайақ кеше. Йөрәге басылырға кирәк бит.
— Әйтеп-әйтеп жылады. Ире үлсә әйтә:

— Мине хөрмәтли торған иде, ау,
Маға аwырлық салмый торған иде, ау, —

дип әйтеп-әйтеп жылайды.

— Қарындас булсын, заты булсын, жылый иде, апам (анам) дип жылай иде.

Ыриза булып кит, апам, апам

Кичер инде килешмәгән җирем булса,

дип әйтеп-әйтем җылайды. Бөтен халық та җылайды, қушылып---қушылып та җылайдылар. Ишетеп тора, ғуй.

Инде мәңгелек җиргә китәсең, апам
Инде мәңге күрәлмим сине.
Йақшылығың алладан қайтсын инде», —

дип әйтеп- әйтеп җылайды.
Баласы үлсә, җылый:
— Җанбалам, алтыным, нигә мине ташлап киттең икән», — дип җылай.

**Җылау**

**Җылау көйе** — мөнәҗәтләрдә искә алына торган сүз.

Җылау көйләрен уйнатып
Уенчылар озата.
Җылашулар, моңлы көйләр
Хәсрәтләрне кузгата («Мөнәҗәтләр», 527 б.).

**Мордва-каратай сөйләшендә үлгән кешене елап озату**

**Җылату** *м.- кар.* үлгән кешене озатасы көнне өйдә һәм зиратта якыннары һәм туганнарының такмаклап елавы. М.-каратайларда шундый әйтем дә бар:
*Туйны иләме (яме) — җыр белән,*
*Үлене иләме (яме) — җылату белән.*

— Җылата’лар җакыннары, җылап бара үзе туганнары, җакыннары. Үле җанына кергәчен җылата башли’лар инде. Гүрләргә илткән чакта да җылатып китерә’ләр. Бар кеше дә җылый җылатканда. Җылатми барса — начар.

— Адʹикайым[1] үлде мына, җылатып илттем гүрләр эстенә[2]:
Адʹикай дим, кайсы сандугачтан тыңларым инде сине тавышыңны. Кайсы җулдан кетәрем инде сине,
Кайсы җулга гына карасам, кайан гына
Кетсәм дә син булмассын инде, адʹикай.
Кайсы агачтан гына карарбыз инде сине буйыңы, ад›икай.
Сине кебек мине кем кетәр инде, кем затыр, ад›икай.
Эштән кайтып керә идем дә, кайнар ашың пешкән була иде.
Кайнар чәйеңе, самавырыңы кайнатып кетә идең, адʹикай.
Инде сине кебек мине кем кет әр.
Ашисым килсә ашың гутуви[3] иде.
Эчәсем килсә чәйең гутуви иде,
Кем кетәр инде ад›икай сине кебек,
Барып карар идек гүреңә,
Чыгып сүләшергә ишегең булмас,
Тәрәзәң булмас пийаладан карарга,
Тагы борылып китәрем җылап, адʹикай.
Кайсы гына сандугачка калдырып китәсең телеңе, ад›икай.
Ничек кенә затып җибәрем җир куйнына сине, ад›икай.
Караңгы җир астына ничек кенә илтәрем, адʹикай, китәсең,
кайтмас җиргә, адʹикай.
Дүрт угылга[4] җаңгызымны калдырып китәсең, адʹикай.
Тайанырга тайагым булмады синнән башка, адʹикай.

Ад›икайым да син булдың,
Закунгынам да син булдың, ад′икай.
Кайсы жулга карасам да кайтмассың, ад′икай.
Читтәге әрем кебек селкенергә калдырасын, ад′икай,
Актык минутларыңы тырасың ад′икай җакты ызбаңда
Җакты ызбаңы караңгы итеп калдырып китәсең, ад′икай.
Тулы ызбаны буш калдырып китәсең, ад′икай.

[1] *Ад′икайым* — әнекәем.
[2] *Гүрләр өсте* — зират.
[3] *Гутуви* (рус. готовый) — әзер.
[4] *Угыл* (рус. угол) — почмак.

Ай пачиба[1], йакшыга эрәткәнеңә, ад′икай,
Кем җәлләр инде сине кебек,
Кайгыны кем кайгыртыр сине кебек,
Севенечеме кем севенер сине кебек, ад′икай.
Җитәр җакты җәйләр, төрле чар кыш терле җирдән кайтыр, ад′икай.
Терле чар кыш терле телдә сайырар, ад′икай.
Терле үлән терле чәчәк атар,
Сине үләнең чәчәк тә атмас, адикай.
Ай сау бул, адикайым,
Йакшы теләп кенә торсаң иде, ад›икай.
Куркытмасаң иде, эркетмәсән иде, ад′икай.
Ай прусти[2], ад′икай.
Мужыт[3] күңелеңә авыр чагы да булгандыр, ад′икай,
ай прусти, ад′икай.
Җиде көн, җиде тен эзләсәк тә табалмабыз инде сине, ад′икай,
Канат астында үстерг ән бәбекәң
Мишаны ничек беген җерәге чыдый микән,
Аши торган булса кулынан кашыгы тешсен, эшли тырган
булса, кулынан эше тешсен, ад′икайын күмәргә килә алмады.

Үлене алып киткәндә җанына утырып җылатасын, урамда да җылатасын:

Актык узуын инде кин урамнан, ад›икай,
Пачиба кара калыкка
Бар да сине затырга килде, ад›икай,
Бар да йакшы сагына икән, ад›икай.

— Гүрләргә төшергәнче урамнан кычкырып җылатып бара инде. Битсеберләр[4] бирәләр ирләргә, хатын-кызларга җаулык бирәләр гүргә төшергәндә — м.-кар.

Гүргә тешергәндә, гүрләр эстендә дә җылата:

Сау бул инде, ад›икай,
Ничек кайтып керем инде игә, ад›икай,
Син булмагач иләмсез кала,
Сау бул инде, адикай,
Ташлап киттең багытсыз.

[1] *Пачиба* [рус.] — рәхмәт.
[2] *Прусти* [рус.] — кичер, гафу ит.
[3] *Мужит* [рус.] — бәлки.
[4] *Битсебер* — сөлге.

Авыр тупырагын җиңгел булсын,
Артын бәк булсын[1]

дип тупырак сибәсен гүргә, эч тапкыр сибәсен тупыракны.

Үле җанына кергәчен җылата башлилар инде.

Аджи (әни) үлгәч жыладым:
Урында җаттың, күрми җаттың,
Җакты кийашны күрә алмадын,
Кеше күзенә карап тордын,
Коры агач күк кородын,
Сары йапырак күк саргайдын, аджи,
Уфтандын җирдән басып җерергә,
Урап киләдер идем магазин алдыннан,
Аджи күрсен мине килгәнеме дип,
Боролып кари алмагач
Чушы пийаладан каридыр иден,
Ана, Нина килә,
Ишекне ачкач: Нина, син тегелме?
Мин, дип әйткәс, кайан килден,
Җулдан килденме,
Күктән төштенме, дип әйтер иден, аджи,
Уфтандын җирдән басып җерергә,
Урап киләдер идем магазин алдыннан,
Аджи күрсен мине килгәнеме дип,
Боролып кари алмагач
Чушы пийаладан каридыр иден,
Ана, Нина килә,
Ишекне ачкач: Нина, син тегелме?
Мин, дип әйткәс, кайан килден,
Җулдан килденме,
Күктән төштенме, дип әйтер иден, аджи,
Алай әйткәс тә бит җылас килә аны,
Әллә җирдән килденме,
Әллә җулдан килденме болай,
Кайан килден,
Ник зак килми тордын,
Малайларның җазуы бармы,

[1] *Бәк булсын* — тыныч булсын.

Ни җаза, җакшы җазамы,
Куркынычлы җазмимы, дип соридыр иден, аджи,
Инде кем сорар сине кебек, аджи,
Кем җәлләр безне,
Кем кетәр безне сине кебек, аджи,
дип әйтеп җылаттым.
Аджикай да син булдың,
Тәтәй дә син булдың безгә,
Җилкәң белән җылыттың,
Телең белән ашаттың,
Ничек сүлим сүзеңе, аджикай,
Ничек әйтеп җырлим җырыңы, аджикай. — *м-кар*.
Әтине тужы шулай. Эч җыл күздән калып тырды, җылатып озаттым:
Чырайыбызны башыбызны күрмәден, тәтәй,
Күрсән иде, ни тели икән сезне
Чырайыгыз, башыгыз, диб әйтәдер идең, тәтәй.
Җакты кийашны күрмәден,
Барасы тышыңа бара алмадың, тәтәй,
Эҗ җыл ыфтанып тордын,
Таwыштан танидыр идең ишекне ачкач,
Нина синме? Мин, тәтәй, диб әйтәдер идем.

Инде кем кетә р шулай,
Ишекне ачкач та җәшүче булмас инде, тәтәй,
Кайа барыбыз инде тәтәй,
диб әйтеп җылаттым — *м.-кар*.

## Үле озату җырлары

**Актаныш районы Терпеле, Мари Суксу** авылларындагы татар---ча сөйләшә торган, татарлашкан марилардан язып алынган йола җырлары. Алар үзләрен «без бер диндә дә түгел» дип әйтәләр.

— Үлене озатқанда җырлап озатыш. Җырлап озатмасалар йакшы булмый. Теге дөнйада әйтерләр ди:
«Сиңа җырламадылар, син йақшы кеше булмағансың», — дип.

Базарларға барып ла сөлге алдым
Бәйрәм көннәрендә дә эләргә.
Безнең теләк менә шундый идее
Бергә йәшәп бергә үләргә.
Ишекләрне ачып ла түргә уздым
Түр тастымалларым чөйдә җуқ.
Туғанайым қайда дип сорасағыз
Очмақларға китте өйдә җуқ.
Урман буйқайларын өч әйләндем
Тайанырға тайақлар тапмадым.
Җаннарыңа кереп сөйләшер идем
Ишекләреңне лә тапмадым.
Иртән торып тышқа чықсам
Қошлар сайрый миләштә.
Йаннарымда бер кем дә йуқ
Кемгә барыйм киңәшкә
Ағыйделнең арйағында
Өйем-өйем қом бит ул.
Кеше әйтә җыру дийеп
Җыру түгел, моң бит ул.
Җуwаларны җыйар ыйым
Җул буйқайларында җуwа җуқ.
Җүгерепкәй барып күрерләргә
Зират эчләрендә җуллар җуқ.
Зират җулы җуллар түгел
Миләш ағачлары җуғ икән.
Қайтырқай дип көткән идек
Қайтыр өметләрең җуғ икән
И туғаннар, туғаннар
Туғаннардан кемнәр туйғаннар.
Үзе туғаннарым килер дийеп
Бик күп өлеш бүлеп қуйғаннар.
Урманнарға кереп озақ йөрдем
Тайанырға тайақ тапмадым.
Үләннәр дә үскән, туфрақ басқан
Үз әнкәйемне лә тапмадым
Айу-бүре түгел күрергә
Гөл-тасмалар түгел үрергә.
Чыга-чыга қарарларға
Җир йөзендә түгел күрергә.

## Үле җыруwы

**Үле жыруwы** — нагайбәк керәшеннәрендә.

— Кеше үлгәчен өч жылға чақлы аш бирәләр, атап сыйыр суйа---лар. Аш биргәндә малны сул йағыннан салалар. Зур қазан. Затына---зәwеренә атап сала. Анда үле жыруwы жырлыйбыз. Қодағый, башлый беләсенме, башла, без қатышырбыз.

Гөбер-гөбер майлар йаздым,
Гөбеләрдә қалды әйрәне.
Без ашыйық, без эчийек
Туғаннарның қалдық бәйрәме.

Ақ йаулықның читләре
Бер бөккәчтен ничек сүтелсен.
Туғанқайны күмеп қуйдың
Бер үлгәчтен ничек терелсен.

Ақ қайыннарны чапқаннар
Жомочқасын қайа қуйғаннар,
Ақ кипеннекләргә чорнап
Туғанайны гүргә қуйганнар.

Жөгереп кердем мин өйләргә
Чөй жаулықайларым чөйдә жуқ.
Безнең туғаннарны сорасағыз
Очтомаққа киткән өйдә жуқ.

Аwада очқан аққошларның
Айағында алтын божора.
Киткән туғаннарым исемә төшеп
Татлы жоқоларны очора.

**Мамадыш районы Владимир авылында үле озату жырлары:**

Иртән торып тышқа чықтым,
Чықланғаннар үләннәр.
Ашадық та эчтек хөрмәт күрдек
Бәхилләп үк жатсын үлгәннәр.

Урманнарға кердем, ай мин жөрдем
Чықланғаннар әле ди үләннәр.
Ашадық та эчтек, искә алдық
Бәхилләп үк китсен ди үлгәннәр.

**Самара өлкәсе Урдалы (Назаровка) авылында үле озату жыр---лары:**

— Өч жыру жырларға тийеш булғаннар. Жыру жырламасалар, теге дөнжәдә әйтәләр ди: «Син жақшы кеше булмагансың, сиңа жыр---ламағаннар», — дип.

Шуның өчен жыру жырлап жанын озатабыз.

Суның буйларына төшкән идем
Балан әле чәчәк атмаган.
Без ди туганайны күрер идеек
Қара тупырақкай қаплаған.

Бийекәй тауның башларында
Күренепкәй қала тау қашы.
Ике қулын күкрәгенә қуйып
Нишләп жата икән бер башы.

Қара ғына қитат жиләнеңне
Қараңғыда кисәң танырмын.
Қараңғылар дийеп килми қалма
Қаршылар чығып алырмын.

Кулжаулықлар тотып зиратқа таба озатабыз. Ишекләрне, қапқа---ларны ачып қуйабыз.

«Тынычлансын инде жаны,
Жақшылар қаршы алсыннар», — ди без.

Қырығынчы көнне жаны күккә күтәрелә, ди.
Көймә генә көймә керләр жудым
Киртәләргә элдем лә кипмәдий.
Қайтыр әле дийеп көткән идем
Қайтыр да җирләргә лә китмәдий.

**Түбән Кама тирәсе керәшеннәре сөйләшендә үлене искә алу (пуминка) мәҗлесендә үлгән туганнарын чакырып җырлау**

Алтын чиркәү йанадыр,
Алтыннары тамадыр.
Алтын кебек туганнарым
Җир астында йатадыр
И туганнар, туганнар,
Туганнардан кемнәр туйганнар.
Үз туганнарыбыз килер дийеп
Табақ сайын өлеш куйганнар.
Тау астында йәшел тирәк
Аның йапырагын җил қойар.
Чит җирләрдә wафат булғаннарны
Малибеннәр укып кем қуйар.
Күке кайа кычкыра ди
Зират киртәсе уртасында.
Зират кирт әсе уртасында
Дүрт такта эчендә.
Ак киндере битендә,
Йылан кебек шуып чык,
Чыпчык кебек очып чык,
Кәлтә булып кисеп чық,
Күбәләк булып очып кил,
Тәрәз төбенә килеп утыр,
Минем таwышымны ишетеп утыр.

**Җырлап сықтау**

**Җырлап сыктау** *т.кам.-криш.* үлгән кешене искә алу мәҗлесендә җырлана торган җырлар (Алабуга районы, Иске Бигәш (ст.Гришкино) авылы).

Әнекәй-әнекәй дигән чакта
Әү бәбекәй дийүчем жук минем
Өзгәләнеп җырласам да
Чү сабыр ит дийүчем жук минем.

Зират тирәли әйләндем
Табалмадым тәңкәмне.
Туфрак баскан, чирәм чыккан
Күр(ә) алмадым әнкәмне.

Әйдәгез лә, туганайлар, ай сунарга
Төлке айакайлары ла тунарга.
Урыннары җәйгән кийеме калган,
Туганайлар, кайтмый ла кунарга.

Кара да кара күренәдер
Кара карлуганнарның да куагы.
Караңгылар дийеп килми калма,
Сез караңгы төннәрнең лә кунагы.

Көймә генә көймә керләр дә җудым,
Кибәр генә дидем лә кипмәдей.
Кайтыр гына ди-ди көткәннәр ийем,
Кайтыр да җирләргә лә китмәдей.

Ак җүкәгач суйдыгыз,
Кабыгын кайа куйдыгыз,
Ак кипенгә сардыгыз,
Туганайны кайа куйдыгыз.
Урман аwызлары лай тарлар аwыз
Агач башы сарылай балаwыз.
Сагынган да сайын лай күрешергә
Җырағырақ булды лай арабыз.

Сайысканнар кайда ла ай шыкырдый
Мәчет манарасы башында.
Безнең туганайлар кайда лай җата
Аwыр тупыракайлар астында.

Тирәзә төбемдә тук чикләwек
Ашыйсым ла килми туксынам.
Өйлә ргә лә кереп, тышка чыгып
Шул туганайымны ла йуксынам.

Беләзекләрең ай биш мыскал
Җуган чакта кайларга куйарсыз.
Җыракайлар куйма җуйарсыз
Исегезгә төшкәч җыларсыз.

Алтын чиркәү җанадыр
Алтыннары тамадыр.
Алтын кебек туганнарым
Җир астында йатадыр.

Көймә генә көймә керләр җудым
Кибә микән безнең лә керебез.
Өчәү генә дүртәү лә торган ыйык
Кайларга китте безнең лә беребез.

Килепләр дә кердем өйемә,
Кара бүрекәйләре чөйдә җук.
Безнең туганайны сорасагыз,
Очтомакка киткән, өйдә җук.

**Керәшен сөйләшләрендә иман җырулары**

***Батышка күwесе, иман күwесе***

**Батышка** [рус. батюшка] күвесе, иман күвесе, иман җырулары *крш.* дини җырлар.

— Кешене алып чыгып киткәнчә батышка күвесен җырлилар, ма---зар эстенә җиткенчүк җырли — *т.я.-крш.*

— Үлене мазарга илткәндә иман җыруларын җырлап илтәләр — *т.я.-крш.*

И, қотқаручы,
Бу мәндәнең җанын

Җомактағы ил-көннәрнең тыннары белән
Тынычландыр.
И, кеше сөйүче,
Аларны үзеңнең рәхәт тормошыңа сақлап тор.
И, қодай,
Бар әүлийәләрне тота торган тыныч урында
Бу мәндәнең җанын да тынычландыр.
И, кеше сөйүче,
Син бер генә.
Шөкөр, Атаға, Улға,
Святой Тынға.
Тамуғта , тотқонда торған кешеләрне
Азабтан қотқарған Алла син.
Әле дә мәндәнең җанын
Кейегеннән қотқар,
Үзең тынычландыр.
Әле дә, ғомердән ғомергә амин!
И, қодай,
Үлгән мәндәне рәхәтлеккә кертеп
Тынычландыр!
Мәңгегә исеңдә тот,
Мәңгегә исеңдә тот!

Бу **қотқаручы** дип атала, басып җырлап озаталар. Үлгәч тә, қырығында да, барысында да җырлана инде ул, җылында да.

Святой Алла,
Святой қодрәтле,
Святой үлемсез, безне җарлықа!
Шөкөр Атаға, Улға,
Святой Тынға,
Әле дә, ул чақта да,
Ғомердән ғомергә амин!
Күк патшасы,
Қайда булса да бар син,
Әр төрле җақшылықларға бай син,
Җаннарыбызны қотқар,
Әй, күктәге атабыз,
Данлы булып торсон
Патшалығың синең,
Бүгенге көнге икмәгебезне бир син,
Бурычларыбызны кичер,
Безгә алданырга ирек бирмә,
Җаманнардан қотқар.
Святой үлемсез, безне җарлықа,
Безне җарлықа,
Анын җанын рәхәтлеккә кертеп тынычландыр.
И, қодай, җарлықа,
И, қодай, җарлықа, бәхиллә.

Зиратқа барғанда шулай иман җырлап барылар, белгәннәр қушы---лалар. Белүчеләр күп хәзер, чиркәү аwылда булғачыннан. Сигез гылас белән җырлана. Менә шулар күккә күтәрелгәнне, терелгәнне аңлата, төрлө көй генә була.

Иртә белән торғач, битне җуғач, Алла бабай қаршына килеп әйтәм:

Үлгәннәрнең урыннары ожмақта булсын,
Изге теләктә торҫоннар,
Аwыр тупрақлары җиңгел булсын,

Тар гүрләре йакты булсын,
Безне қаршы алучылар булсыннар.
Святой Алла,
Святой Үлемсез,
Безне җарлықа.
Атаның, улның,
Святой Тыннын
Исеменә амин.
Күк патшасы,
Җанға тынычлық, күңелгә бәйрәм бирүче
Данлы булып торсон исемең синең
Синең патшалығың
Күктә дә, җирдә дә булсын,
Әртөрле җақшылықларға бай син,
Безгә алданырға ирек бирмә,
Бүгенге көн икмәгебезне бир безгә,
Бурычларыбызны кичер,
Җазықларыбыздан қотқар.
Әр җирдә дә,
Әр қайда да бар син,
Әр нәрсәгә қодрәтле син,
Әр нәрсәне күрәсең, ишетәсең,
Безгә бүген ашарлық икмәкне бир,
Җылларыбызға тынычлық бир,
Бәхетләребезне, тәүфиқләребезне бир,
Эшләгән эшләребездә уңышлар бир,
Җөргән җулларыбыз уңсын — *каз.ар.-крш.* (Чура)

**Паскы теләүләре** дә була:
Әй, Кристус,
Үлгәннән терелеп торған,
Үлгәннеге белән үлемнең қуәтен бетергән,
Үлгән кешеләргә дә терелек биргән.
И қодай,
Синең қаршыңа баш орабыз,
Син безнең Аллабыз,
Синнән башқа бүтәнне белмибез,
Синең исемеңне данныйбыз.
И җақтыртучы Алла, шөкөр сиңа,
Күктәге чирүләр сине күреп әйткән,
Синең терелеп торуың даннаулы.
Безне қотқара торған нәстәләрне
қылуың даннаулы.
Безне қотқаручыға баш орыйық,
Игелекле Аллаға инәлийек,
Җазықларны кичереп бетерсен ийе. — *каз.ар.-крш.*
(Чура ав.)

И, қодай,
Тереклек бирә торган
Қадерле қачыңның қуwәтен
Әйләнәбездә тотып,
Безне әртөрле усаллардан сақла!
Атаның, Улның,
Святой Тынның
Исеменә амин, —
дип, дүрт почмаққа қач қылабыз (Урдалы авылы).

И, Алла,
Без җазыклыға изгелекле бул,
И. Қодай,
Мин җазықлыны қотқара күр,
Атаның, Улның,
Святой Тынның
Исеменә амин!
Святой үлемсез,
Безне җарлыка (Урдалы авылы).
И, Алла,
Тамукка төшөп
Тотқында торған кешеләрне
Азабыннан коткарган Алла син,
Әле дә мәндәнең җанын
Көйөгеннән коткарып
Үзен тынычландыр.
Башта син безне
Җомақ бақчасына кертеп
Аны эшләп
Кастәрләп торога
Урыннаштырған.
Бойорығыннан җазғачын
Җомақтан куwып чығарган.
Инде, Котқаручы,
Мәндәңнең җанын тынычландыр.
Әле дә,
Әр чакта да,
Гумердән гумергә амин.
Шөкер, Атага, Улга,
Святой Тынга да.
Өстәлгә қач қылырга кирәк,
Арыуланган су сибәргә кирәк.
(Самара өлкәсе, Келәүле р-ны, Урдалы ав.).

Үле туган, чумылмаган (христиан дине йоласы буенча чиркәүдә чукындырылмаган **балалары** өчен ана булган кеше түбәндәге **теләү сүзләрен** әйтә):
й, ходай,
Минем эчемдә үлгән
Балаларымны җарлыка,
Минем ышануым,
Күз җәшем буйынча,
Үзеңнең изгелегең қақына,
Әй, ходай,
Аларны үзеңнең
Аллалық җақтылыгыннан
Буш калдырмасаң ыйы.
(Самара өлкәсе Келәүле районы Урдалы авылы)

**Керәшеннәрд ә үлгән кешеләр өчен теләү рәтен, аш үткәрүне аңлату**

Бу теләү рәте бер кеше өчен дә җарый, күп кеше өчен дә җарый. Айырмасы берлекне-күплекне күрсәтүдә генә. Бер кеше өчен ителсә: үлгән **мәндәңнең җаны** дип әйтәсе, күп кеше өчен ителсә, **үлгән мәндәләреңнең җаннары** дип әйтәсе.

Күп кешеләр өчен теләк иткәндә барысының да исемен әйтергә (по---минание укырга) кирәк.

**Келәү иткәндә** өстәлдә дә, изге тәреләр карышысында да эшәмнәр җанып торсон. Келәү итеп бетергәч, ашар алдыннан әйтелә торган иманнарны җырлыйык: Әй, Күктәге Атабыз ... ны.

Аннары: Әй, Ходай, бар кешеләр дә
Сиңа өмөт итеп торалар ... ны җырлагач,
Атаның, Улның,

Святой Тынның исеменә амин, дип өстәлгә қач қыларга кирәк, җә арыуланган су сибәләр.

Ашарга утыргач та, икмәк белән бал алып, үлгән кешене искә алып кабалар.

Үлгән кеше ашында бүтән ашамлыкларны ашагач, торып: Әй, Христус, үз мәндәңнең җанын ... ны җырлыйлар да, тагы утырып кесәлдән аwыз итеп үлгән кешене искә алалар.

Үлгән кешене искә алу көне **уразага** туры килсә, **ураза ашы** гына әзерләргә тийеш. Олы ураза булса, җә Спас уразасы булса, балык та рөксәт ителми. Ураза булмаса бүтән ашамлыклар да җарый.

Алай да **аракы да**, бүтән **исерткеч эчемнекләрне қуйарга да үле ашына ич тә рөксәт ителмей**.

Ашны Аллага җараулы булсын,
Үлгән туганыбызның җанына
пайда китерсен дип,
теләк белән генә үткәрергә тийеш.
Ашап торгач әйтәбез:
Әй, Аллабыз,
Җирдәге дәүләтең белән
Безне туйдырганыңа
Сиңа тау итәбез,
Күктәге дәүләтеңнән дә
Безне буш калдырма.
Аллага тау итеп,
Өйләребезгә таралабыз.
(Самара өлкәсе Келәүле районы Урдалы авылы)

## ТУБЫЛ-ИРТЫШ ДИАЛЕКТЫНДА КЕШЕНЕҢ ЖАНЫ, РУХЫ ТУРЫНДА МИФОЛОГИК ТЕКСТЛАР

### Мәцкәй булып қупқын қупқан

**Мәцкәй булып қупқын қупқан** *туб.* явыз рух булып үлгән кешенең җаны кубып, кабереннән чыгып йөри, имеш.

— Мәцкәй булып қубаты. Син беләмесен қупқынны?

Мылтыққа атылып үләме, қан-қуwық белән күмеләме, шантай кеше қубаты. Тасалап күмсәләр, қупмайты, имеш. Қупқын ул гешене йотып қуйа дигән, паш тиресе генә қала, тигән. Уғынып йиңәләр, тигән. Мин уғымышын[1] белмәйем, әшкәрә[2] қолағым эшитмәйде — *туб.*

Гешенең мийәсеннән[3] оцоп цығып гитә тигән қупқын булып. Геше үлеп кала тигән. Қупқын ул мәцкәй булып қан эцеп гилсә, ийәсе терелә тигән, өйдәге ийәсе. Ә қупқын булып оцоп цығып китсә, ул үлеп кала дигән күгәреп. Қупқын кире оцоп килсә, терелә тигән. Үлгән гешенең канын эцә тигән, йаңы үлгәннекен. Шалай гәпләйтеләр.

### Рухы қупқан

**Рухы қупқан** *тара.* дини йола буенча, кадерләп күмелмәгән ке---шенең рухы кубып йөри, дигәннәр.

— Ченасасыс күмелсә, рухы **қупқан**, — тиделәр, үсенеке кийеме мән йөрите. Менә бер бала үлте, ченасасыс күмелте. Киц пулса, ул пала йөрите. Күрәләр ите. Аwылыбыс сур, перәү ул йақта күрәте, перәү пы йақта күрәте. Пер нәрсә қылу кәрәк, тиделәр.

Қатым уғылмаса та кеше **қупқан** булып қубаты, усал кеше тә **қупқан** булып ққубаты.

— Арак эцкән, пы төнйата сыусыс киткән кешеләр қубаты.

Менә монтайын табақ белән сыу утысам аранға. Шал сыуны килеп цалық-цалық эцәте қупқан. Мин песмиллалап уғынып йатам, қарап йатам. Иртәнгесен қарасам, шал табақның төбен йалап қуйаты **қуп---қан** — *тара.*

[1] *Угымыш* — дога, дини сүзләр.
[2] *Әшкәрә* — бөтенләй.
[3] *Мийә* — ми, баш мие.

## Қупқан қупмасын

— Қупқан қупмасын тип үлгән кешенең күкерәк аwысына күк мунцақ[1] қуйып күмәтләр.

— Купкан булса, көн дә хайwаннар кырылган. Хәсер йук антай нимә. Көн булса, йөреп утыра, тиде, кермәй ти қәмергә[2]. Элек булған антай нимә. Қупқан **қ**упмасын — *тара.*

## Қупқан қусғайа

**Купкан кусгайа** *туб.* купкан кузгала.

— Қупқан қусғайаты, усал геше кусғайаты. Қупқан қусғайса, мул---лалар басаты.

## Қупқан басу

**Купкан басу** *туб.* купкан чыкмасын дип кабергә догалар салу, усак казыгы кагу.

— Қупқан басатқан муллалар булған. Туwа йасып, йете тишектән қағасын[3] төшерәтләр қабергә. **Йете тишектән қубып цығаты** ул.

— Қупқан булған ул. Муллалар ыуса**қ** қасық[4] белән басқаннар йете тишек тишеп. Йақ-йаққа тыwалықлар[5] қыстырғаннар.

— Пер мулланың қортқайагы[6] үлте, купқаны йөреп утыраты. Анан аппарып йәш аусақ цабып қагыпты баш өстөнә. Қабердән қубаты төнйатан туймаған кеше.

— Элекеләр күргән, қупқан ул ут булып йөреп утыра тигәннәр. Ул ут ноуға[7] барып туқтаган.

Қупқан қабере өстенә ыусақ қасық қаққаннар: «Йөреп утырмасын». Қаберенең өстен тасартып торғалы йарамайты. «Тимәң қабер өстен---дәге үләннәргә» тиделәр.

[1] *Күк мунцақ* — күк муенса.
[2] *Қәмер* — қабер.
[3] *Қагас* — кәғазь.
[4] *Ыусақ қасық* — усак казык.
[5] *Тыwалық* — догалык.
[6] *Қортқайақ* — карчык.
[7] *Ноу* — болын.

— Тирәскә килеп утыраты қупқан. Қупқан кешенең кәмере тишек була тейән. Аңа ыусақ қагып, ыусақ қасық белән цәнецәтеләр игән, купқан тыныцлана игән. Инәм алай тийән.

Қупқанны қабергә қуйсалар, ул шешенәте, сыймайты каберенә, цығаты. Төннә ишегеңә тә киләте синекенә. Ашың бармы, ашыңны эцәте, сыwыңны эцәте. Аны муллалар беләтеләр. Аның қабере өстенә ыусақ агац қағатылар. Ул аннан пасылаты. Шалай усақ ағац белән бикләп қуйалар купқанны.

— Күмгән йирдән тишеп цығып китәте қайсы геше. Менә эленеп үлгән кеше кубып китәте. Менә төннә киләте ти. Муллалар әйтепте, ыусақны оцлап, ыусақ белән пасқалы тиде. Ишек төпләренә тә ыусақ белән пасқалы тиде. Менә қабере тишек булаты тиделәр, қаберен барып қарап та йөрителәр.

— Қупқан ул қубып өйгә килә игән, күрәләр игән. Ич нимә сөйләш---ми. Кулыңны тийереп бақсаң, күбек кенә кебек.

— Пер мулланың қортқайагы[1] үлте, қупқаны йөреп утыраты. Анан аппарып йәш аусақ цабып қағыпты баш өстөнә. Қәбердән қубаты төнйатан туймаған кеше.

— Элекеләр күргән, қупқан ул ут булып йөреп утыра тигәннәр. Ул ут ноуға[2] барып туктаган.

Қупқан қабере өстенә ыусақ қасық қақаннар: «Йөреп утырмасын». қабернең өстен тасартып торғалы йарамайты. «Тимәң қабер өстендәге үләннәргә» тиделәр.

— Тирәскә килеп утыраты қупқан. Қупқан кешенең кәмере тишек була тейән. Аңа ыусақ қағып, ыусақ қасық белән цәнецәтеләр игән, қупқан тыныцлана игән. Инәм алай тийән.

Қупқанны қабергә қуйсалар, ул шешенәте, сыймайты қаберенә, цығаты. Төннә ишегеңә тә киләте синекенә. Ашың бармы, — ашыңны эцәте, сыwыңны эцәте. Аны муллалар беләтеләр. Аның қабере өстенә ыусақ агац қағатылар. Ул аннан пасылаты. Шалай усақ ағац белән бикләп қуйалар қупқанны.

— Күмгән йирдән тишеп цығып китәте қайсы гецде. Менә эленеп үлгән кеше қубып китәте. Менә төннә киләте ти. Муллалар әйтепте, ыусақны оцлап, ыусақ белән пасқалы тиде. Ишек төпләренә, тә ыусақ белән пасқалы тиде. Менә қабере тишек булаты тиделәр, қаберен барып карап та йөрителәр.

— Қупқан ул қубып өйгә килә игән, күрәләр игән. Ич нимә сөй---ләшми. Қулыңны тийереп бақсаң, күбек кенә кебек.

[1] *Қортқайақ* — карчык.
[2] *Ноу* — болын.

## Ақшабыр

**Ақшабыр** *туб.* купканны шулай дип әйтергә кушканнар.

— Ақшабыр тип әйткәннәр йөргән кешене, исеме белән әйтеп утырмайты. Ақшабыр йөрепте, тиделәр. Қупқан ул, қупқан тип әйт---мителәр.

## Йөремнек

**Йөремнек, йөремцәк, өрәй** *туб.* өрәк.

— Йөремнек йөрәй өц көн. Өрәй[1] йөрәй тип әйтәтеләр.

Кеше үлсә, ул йелле[2] йиргә күмелсә, йөреп китә тип әйтә тегән булғаннар. Қабер тишелеп қуйа тип кәпләйтеләр. Йөремнек, кешенең аурағы йөрите.

— Қайсы кеше бала китәрәте[3]. Ул китәргән баланы ыспайлап астанаға күмгәле кәрәкте. Қайсыбер кеше күммәй, йәшереп тығып қуйаты. Ул қыс пала пулса китеп қалаты, қыс пала пулмаса анта йәшите имеш, өйләнәте.

Йуwып, тасартып астанаға күмгәле кәрәк икән китәргән баланы. Йеренә йеткермәсәң, ул алай йөреп китәте, имеш, йөремцәк булаты.

Итәктән киткән[4] ир бала йөремнек булыпты, шайтан булыпты тип кәпләйтеләр ите. Итәктән киткәне бар, ул олғайған булыр кәтерсес кылып күмгән булса. Итәктән киткәне пар, ул йелле, йарбаш йелле, анта пармаң, йелгә суғылуығыс пар, тиделәр. Үләр алдыннан йөрем---неге йөргән тип әйтеп қуйатылар.

[1] *Өрәй* — өрәк.
[2] *Йелле* — җенле.
[3] *Бала китәрә* — бала төшерә.
[4] *Итәктән киткән бала* — төшерелгән бала

## Йөремнек йөри

— Үлә тегән кешенең йөремнегe йөрите, өйләргә керәте. Аwырған кешенең қәле бетәте. Ул йөремнек кешегә керәте, үсен танытмайты, питен йәшереп тораты. Тубысы аwылы бар монта. Тубысыта тораты минеңкә әбәм. Қунаққа бартым, мин қарап йатам. Перәү керте, цацын болай төшергән. Мин таныттым аны. Ул қыңғыр қарайты. Ул миннән цығып күрешегә кереп китте, күреше пицәгә. Ул пицә

үлеп китепте. Пер йыл, ике йыл йөрите йөремнеге. Әйттем мин күрешеләргә. Ул йөрите қырық көнгәцә, пер йылғаца.

### Йөремнекне күрсә

— Кешенең йөремнеген күрсә, өстендәге кийемен салып сатақаға биргәннәр, ғомере осайаты — *төм*.

### Йөремце

**Йөремце** *туб*. йөремнек, әрwах.
— Йөремце ул кешенең аурағы булыпты.
— Йөремцеләр, йөремнекләр кермәскә артыш кыстыратылар.